ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

## *Актаныш*

КАЗАН • 2021

УДК 39 (470.41)+008 (470.41)
ББК 70 (2Р354)
М48

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

***Редколлегия:***
*К. М. Миңнуллин (рәис), Э. Н. Фәттахов,
Р.Р. Салихов, О. Р. Хисамов*

***Төзүче-мөхәррир***
*Э. И. Сафина*

**М48 Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш. –** 2 нче басма. – Казан, 2021. – 572 б. – («Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе. Беренче китап).

ISBN 978-5-93091-366-8

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күргән бу тәүге китап танылган нәселләр һәм авыллар тарихы, гореф-гадәтләр һәм тел үзенчәлекләре турында бай мәгълүмат бирә. Анда шулай ук җирле осталарның кул эшләре һәм халык талантларының көй-сүз иҗаты белән дә танышырга мөмкин. Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең тикшеренүләрен эченә алган әлеге басма киң катлау укучыларда кызыксыну уятыр дип ышанабыз.

ISBN 978-5-93091-366-8

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2021

## СҮЗ БАШЫ

Һәр төбәкнең табигать, анда яшәүче кешеләр, аларның ышанулары һәм дөньяга карашлары йогынты ясый торган язмышы, йөзе, рухи үзәге-асылы бар. Әлеге үзенчәлекне тою-аңлау өчен, шул төбәктә яшәү, һич булмаса, андагы тормышны өйрәнү һәм халык белән аралашу кирәк. Болар төбәкнең хәзерге хәл-халәтен күзалларга мөмкинлек бирә.

Үткән-тарих исә күпмедер күләмдә чыганакларда саклана; аларны археологик тикшеренүләр үткәреп тергезәләр; архив документларыннан һәм тарихи һәйкәлләрдән, ташъязмалардан эзлиләр. Археолог-галимнәр борынгы кешеләр турында мәгълүмат сакланган урыннарда разведка уздыра, казу эшләре оештыра һәм, табылдыкларга нигезләнеп, бик ерак тарих хакында төгәл мәгълүматлар китерә. Археологик тикшеренүләр вакытында эралар-чорлар да, шул заманнарда билгеле бер урында яшәгән кешеләрнең кайсы халыкка каравы, көнкүреше, һөнәрләре, нинди технологияләргә ия булуы, ышанулары да, күпмедер күләмдә зәвыгы, мәдәни казанышлары да ачыклана. Алар тарихи чыганаклар булмаган ерак заманнарны кабат күзалларга мөмкинлек тудыра. Тарихи чыганаклар (архив материаллары, документлар, эпиграфик һәйкәлләр һ.б.) исә безгә якынрак чорлар хакында сөйли.

Алар да күрсәтә алмаган бик күп сәхифәләрне шәҗәрәләр һәм гаилә истәлекләре дә; төбәк кешеләре хәтерендә буыннан-буынга тапшырылып килгән мифлар һәм легендалар, җырлар һәм бәетләр дә; халыкның тел-сөйләм, әдәби фикерләү хасиятләре, көнкүреш һәм мәдәни үзенчәлекләре; матди һәм мәдәни кыйммәтләр дә үзендә саклый. Боларны күрә, аңлый, өйрәнә һәм аңлата белергә генә кирәк. Гаҗәеп күренеш: археологик һәм тарихи чыганакларда сакланмаган мәгълүматлар еш кына кешеләр хәтерендә, төбәкләрнең тормыш-көнкүрешендә яшәвен дәвам итә! Аларны төрле өлкә галимнәре төбәкләргә экспедиция-сәфәрләр уздырып барлый, таба, өйрәнә... Аннары бу материаллар кабат халыкка кайта, шушы урынның, төбәкнең һәм бердәм татар милләтенең тарихи-мәдәни байлыгына әйләнеп яши бирә.

Татарстандагы академик фән дә, тарихи, археологик тикшеренүләр белән бергә, төбәкләргә чыгып, урыннарда халыкның яшәешен, көнкүрешен, матди һәм мәдәни хәл-халәтен өйрәнү белән һәрвакыт шөгыльләнә. Мондый тикшеренүләр әле XIX–XX гасыр чикләрендә аерым татар зыялылары инициативасы белән уздырыла: бик күп татар җырларын, әкиятләрен, мәкаль-әйтемнәрен, миф-легендаларны язып алырга, татарларның тел-сөйләм үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Мәсәлән, К. Насыйри беренчеләрдән булып татар халык авыз иҗаты материалын җыю, тарихи-этнографик тикшеренү эшен башлап җибәрә, 1871 елдан үзенең «Казан календаре»нда фольклор үрнәкләрен бастыра. Бу эшкә Р. Ф. Фәхреддин, Г. Н. Әхмәрев, Х. Б. Бәдигый, Җ. Җ. Вәлиди һ.б. бик күп фикер ияләре кушыла.

XX гасырның аерым бер чорларында мондый тикшеренүләрне оештыруда активлык күзәтелә. 1920–1930 елларда – бигрәк тә Гыйльми Үзәк эшчәнлеге белән бәйле махсус экспедицияләр фәнни нигездә уздырыла башлый. Н. И. Воробьев, А. С. Башкиров, Ф. И. Терегулов, М. С. Гобәйдуллина, К. С. Гобәйдуллин, С. Г. Вахиди һ.б. тарафыннан Арча, Әлки, Балык Бистәсе, Мамадыш, Минзәлә, Спас, Чаллы, Чистай төбәкләрендә шундый кыр тикшеренүләре үтә; аларда этнография, фольклор, сәнгатькә, тарихи-мәдәни мираска караган материаллар туплана.

Мондый эшчәнлек хәтта Бөек Ватан сугышы чорында да тукталмый. 1950–1980 елларда аерым бер тармак галимнәренең махсуслаштырылган экспедицияләргә чыгуы киң тарала. Бигрәк тә эпиграфик (Һ. В. Йосыпов), археографик һәйкәлләрне (М. И. Әхмәтҗанов, М. Г. Госманов һ.б.), диалектларны (Л. Җ. Җәләй, Л. Т. Мәхмүтова, Н. Б. Борһанова, Д. Б. Рамазанова, Ф. С. Баязитова һ.б.), төрки-татар фольклорын (Х. Х. Ярмөхәммәтов, И. Н. Надиров, Х. Ш. Мәхмүтов, Л. Ш. Җамалетдинов һ. б.) җыю-барлау максатыннан, Татарстанда һәм аннан читтә яшәүче татар авыллары һәм шәһәрләрендә тикшерү эшләре башкарыла. Экспедицияләрдә тупланган материал күптомлы фундаменталь хезмәтләр: «Татар халык иҗаты», 2 томда (1951, 1954), «Татар халык әкиятләре», 2 томда (1946, 1956), «Татар халык җырлары» (1965), «Татар халык иҗаты», 12 томда (1972–1990), «Татар халык сөйләшләре», 2 томда (2008), «Татар теле-

нең диалектологик сүзлеге» (2009), «Татар халык сөйләшләренең атласы», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) кебек коллектив монографияләр, мәдәният-сәнгать тарихы, милли һөнәрчелек, кульязма һәм басма китап тарихы һ.б. өлкәләр буенча күпсанлы китаплар нигезендә ята.

XXI гасыр башында, Татарстан Фәннәр академиясенең системалы эшчәнлеге нәтиҗәсендә, бу эш яңа баскычка күтәрелә: һәр елны милләттәшләребез яшәгән төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештырыла башлый. Комплекслы өйрәнгәндә, тел, әдәбият, фольклор, сәнгать юнәлешенең төбәк хәзинәсендә булган барлык төр байлыгы – буыннан-буынга тапшырыла килгән авыз иҗаты үрнәкләре, бәйрәмнәре, йола-гадәтләре, музыкасы, бәйләү-чигү осталыгы, йорт-каралты бизәкләре, кием-салымы, тел үзенчәлекләре, эпиграфик һәм археографик мирасы – һәрберсе барлана-туплана һәм җентекләп бәяләнә. Татарстанда Актаныш (2009), Апас (2010), Кукмара (2011), Чүпрәле (2012), Мамадыш (2013), Арча, Әтнә (2016), Минзәлә, Мөслим (2017), Азнакай, Буа (2019) районнарындагы татар авыллары һәм поселокларда шундый кыр тикшеренүләре уза.

Татарстаннан читтә: Түбән Новгород, Курган (2009), Оренбург (2010, 2015), Мари Илендәге Бәрәңге районы (2011), Удмуртия Республикасы (2012), Пермь краендагы Барда районы һәм Әстерхан өлкәсе (2013), Себердәге Омск һәм Самара (2014), Томск (2015), Чиләбе өлкәләре, Казакъстан Республикасы (2016), Новосибирск, Башкортстан Республикасы (2017), Ульяновск (2017, 2018), Иркутск, Киров (2018), Пенза, Төмән өлкәләре, Үзбәкстан Республикасы (2019) җирләрендә булып, анда яшәүче милләттәшләребезнең тел-сөйләш үзенчәлекләрен, тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен, сәнгатен, кульязма һәм ташъязма мирасын барлау, аларны фәнни эшкәртү, тикшерү эше җайга-системага салына.

Экспедициядә җыйган материалларны тикшерү, өйрәнү, фәнни әйләнешкә кертү белән бергә, шушы вакыттан Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында 1950 –2000 елларда шул ук төбәкләргә, авылларга уздырылган экспедиция материалларын барлау, яңа кайткан мәгълүматлар белән чагыштыру башкарыла. Шул җир-

лектә фәнни хезмәтләр әзерләнә. Әйтик, бүген инде галимнәребез «Татар халык иҗаты»ның 25 томлыгын төгәлләү алдында.

Элегрәк тупланган һәм өр-яңа материалларны бергә җыеп, «Милли-мәдәни мирасыбыз: фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» исеме астында фәнни-популяр китаплар сериясе әзерләү эше башлана. Ул – халыкның рухи байлыгын үзенә кайтару, популярлаштыру, аны тарихка кертеп калдыру, шушы мәгълүматлар ярдәмендә татар халкының милли үзаңын ныгыту максатлары куеп эшләнә.

Бүген инде бу сериядән 20 китап дөнья күрде, яңаларын әзерләү дәвам итә. Китапларда сәфәр кылынган төбәкнең мәдәни тарихы, танылган нәселләр һәм авыллар-шәһәрләрнең үткәне, гореф-гадәтләре һәм тел үзенчәлекләре турында бай мәгълүмат бирелә. Шулай ук шәҗәрәләр, җирле кул осталарының эш үрнәкләре, кызыклы экспонатлар белән дә танышырга мөмкин.

Әлбәттә, дөнья буйлап чәчелеп яшәгән татар халкының рухи асылын, тарихи-мәдәни сыйфат-билгеләрен бары тик төрле урыннарга фәнни экспедицияләр, кыр тикшеренүләре оештырып күзалларга һәм бербөтен тарих итеп тергезергә мөмкин. Чөнки бу яшәеш борынгыдан килә, татар халкы Евразиянең гаять киң территориясендә формалашкан! Төрле табигый, тарихи, конфессиональ шартларда, төрле этник тирәлектә (төрки халыкларның төрле төркемнәре, фин, угор, славян этнослары янәшәсендә) татарларның этнотерриториаль (Идел-Урал буе, Себер, Әстерхан татарлары), субэтник (Казан, Касыйм татарлары, мишәрләр), субконфессиональ (керәшеннәр, иштәкләр, нагайбәкләр) төркемнәре барлыкка килгән. Бу төркемнәр традицион матди һәм рухи мәдәният үзенчәлекләрен саклап яши. Әмма алар гомумтатар милли үзаңына ия.

Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты уздыра торган экспедиция материаллары шул хакта сөйли, һәр сәфәр шушы фикерне куәтли.

Әлбәттә, уртак милли үзаңның нигезен татар теле хасил итә. Төрки телләрнең кыпчак төркеменә караган татар теле иң борынгы телләрдән санала. Татар теленең төп лексик, фонетик, грамматик үзенчәлекләре борынгы төрки телдә үк формалашкан. Шуңа күрә дә дөньяның төрле кыйтгаларын-

да яшәүче татарларның, төрле сөйләш вәкилләре булсалар да, тел-сөйләмнәре уртак лексик, фонетик, грамматик калыпларга-кануннарга нигезләнә. Шуңа күрә без борынгы рун язулы истәлекләрне укып, эчтәлегенә төшенә алабыз, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан һ.б. төрки телләрне дә аңлыйбыз, татар теленең төрле диалектларында да зур аермалар сизмибез.

Татар милли әдәби теле исә XIX–XX гасырлар чигендә Казанда, Уфада, Оренбургта, Троицкида, Әстерханда һ.б. шәһәрләрдә һәм алар тирәсендәге авылларда бер тел булып оешып җитә. Тукай теле, Туфан теле, Еники теле – барыбыз өчен дә уртак байлык.

Татар әдәби теле үсеше барышында кайбер традицион хасиятләр һәм формалар югала, әмма алар сөйләшләрдә сакланып кала. Димәк, төрле урыннарда сибелеп яшәгән татарларның сөйләшләре борынгы уртак телебезнең үзенчәлекләрен югалтмавы белән дә кадерле. Экспедицияләр материалы безгә шул хакта да сөйли.

Татарларның мәҗүси заман ышанулары, ислам дине белән бәйле күзаллаулары бүген дә халык арасында яши. Бигрәк тә безнең халкыбыз тарихында мең еллык урыны булган ислам диненең һәм матди, һәм мәдәни тормышка йогынтысы халыктан җыелган материалларда аермачык күренә. Каберташ язмалары, борынгы китаплар һәм кульязмалар, шәкерт дәфтәрләре, күчереп язылган текстлар, әдәп-әхлак кагыйдәләре, йола-гадәтләр, ышанулар һәм күзаллаулар, бәйрәмнәр һәм ырымнар татарларның барлык этник төркемнәрендә дә мәдәни уртаклыкларга ия. Ислам мәдәнияте гадәти көнкүреш һәм кеше тормышындагы иң мөһим вакыйгаларга (туу, исем кушу, өйләнү, гаилә кору, бакыйлыкка күчү) бәйле йолаларда этник мәдәнияткә үрелеп китә. Вакытны күрсәткән азан тавышы, намаз-догалар, җомга көнне бәйрәм дип карау белән бергә, татар халкының мәдәни хәтеренә бәетләр, мөнәҗәтләр, дини-суфичыл текстлар кереп урнаша. Традицион бәйрәмнәр: Сабан туе, Җыен, Корбан гаете, Ураза гаете, өмәләр уздыру, Карга боткалары һәм Яңгыр боткалары – болар да уртак байлыгыбыз һәм татарлыгыбызның аерылгысыз билгеләре.

Комплекслы экспедицияләр вакытында төрле җирлекләрдә кием-салым, һөнәрләр, азык-төлек әзерләү рәвеше, архитектура, музыка сәнгате буенча да күзәтүләр ясала. Әйтик, төрле

җирләрдә яшәүчеләрнең киемнәрендә үзгәлекләр булса да, татарларның традицион гомуммилли өс киеме Казан татарларыныкы йогынтысында формалашкан дигән фикер безнең материаллар белән дә тагын бер тапкыр раслана. Татарлар кайда гына төпләнмәсен – мәчет торгыза. Халкыбызның һәрчак белемгә-гыйлемгә омтылышы, балалар тәрбияләүгә зур әһәмият бирүе, олыларга аерым бер хөрмәт белән каравы, туган җир һәм нәсел-ыруның һәр кешене саклаучы-яклаучы көч дип санавы, шигърияткә-иҗатка тартылуы да кыр тикшеренүләрендә чагылыш таба.

Әлбәттә, хәзерге заманда татар тормышы, аның вәкилләре кайсы кыйтгада гына яшәмәсен, Татарстан белән бәйләнгән. Республикабыздагы күтәрелеш татар дөньясының җанлануына, милли үзаң уянуга, татарларның үзләрен бердәм халык итеп тоя-карый башлавына китерде. Хәтта элек-электән туган җирләре, ватаннары бик еракта – әйтик, Польшада яки Литвада, Әстерханда яки Иранда, Уралда яки Себердә, Кытайда яки Финляндиядә булса да, уртак тарих, уртак мәдәният һәм Казан, Татарстан татарларны берләштерүче үзәк булып кала.

Һәр милләт булып җитешкән бердәмлек төрле мәдәниятләрнең хасиятләрен үзенә туплый. Бу – аксиома. Көчле мәдәният үз тирәсенә башкаларны тарту сәләтенә ия. Алтын Урда чорында ук «татар казаны» күп кабиләләрне кайната, шул исәптән болгарларны да татар политонимына юнәлдерә.

Татар тарихы сикәлтәле, б. э. к. III гасырдан башлап язма истәлекләрдә күзаллана. Шул ерак гасырлар чоңгылында Бөек кытай диварыннан төньяктарак төрки телле һун империясе төзелә. II гасырда ул хәзерге Казакъстан далаларына күченә. Идел һәм Урал арасында угорлар белән укмаша, IV гасырда Европага юнәлә, халыкларның Бөек күчешен башлап җибәрә. Һуннарның нәсел тамгасы – казан – безнең башкалабыз Казанның да үзәгендә, Казансу буеннан милләттәшләребезне сәламли.

V гасырда һун империясе таркала, Бөек кытай диварыннан Дунайга кадәр җирләрдә Бөек Төрки каганлык калкып чыга. Аның җимерелүе исә Болгар цивилизациясенең чәчәк атуына китерә. Көнчыгышта куәтле татар халкы үзенең дан-шөһрәтен яңгырата. Алтын Урда таркалгач, аның варислары ханлыклар төзи. Бүген алар касыйм, әстерхан, себер, румын татарлары,

мишәрләр, керәшеннәр, нагайбәкләр һ.б. төркемнәр булып яши. Аларны бер тел, бер югары мәдәният – Мәрҗани фәһеме, Тукай шигырьләре, Сәйдәш музыкасы, Урманче сурәтләре берләштерә.

Татар асылын, аның рухи үзәген, татарлыкның гомуми һәм үзенчәлекле сыйфатларын аңлау-төшенү өчен, шиксез, тарихи барышны гына түгел, бәлки халыкның хәтерендә яшәгән рухи кыйммәтләрне дә барларга, өйрәнергә кирәк. Татарстан Фәннәр академиясе, аның институтлары, шул исәптән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре шуның белән шөгыльләнә. Дөрес, татарлар элек-электән күпләп яшәгән барлык урынчылыклар да өйрәнелгән дияргә иртәрәк әле. Димәк, бу эш дәвам итәргә тиеш.

Фәнни күзлектән караганда, борынгы һәм бай тарихлы, үз әдәби теле, профессиональ әдәбияты һәм сәнгате булган бердәм татар милләте без. XX гасырда татар югары мәдәнияте, мәгариф һәм фән нык үсеш ала. Бу процесста төрле җирләрдә яшәгән, төрле этнографик төркемнәргә караган татарларның өлеше бар. Безнең көчебез – бердәмлектә.

* * *

2009 елда ТӘһСИ оештырган беренче комплекслы экспедиция Актанышта үткәрелгән һәм милли-мәдәни мирасыбыз сериясенең беренче китабы Актаныш районына багышлап чыгарылган иде. Бу бер дә очраклы хәл түгел. Татарстанның бик матур җирендә урнашкан бу төбәк кабатланмас татар колоритын саклап кала алуы белән үзенчәлекле. Матур аһәңле һәм ифрат бай туган телебез, әби-бабаларыбызның ядкяре булып киләчәк буыннарга тапшырыла килгән моңлы көйләребез, татар йортларының үзенчәлекле милли бизәлеше, алтын куллы осталарның зәвыклы кул эшләре – болар барысы да биредә күз карасыдай кадерләп саклана. Күпләрнең өендә әле дә иске кульязмалар һәм китапларны очратырга мөмкин. Урта гасырлар болгар-татар әдәбияты җәүһәре «Кыйссаи Йосыф» дастанының 19 кульязма күчермәсе дә нәкъ менә Актаныш районында табылган иде. Бу үткән буыннарның укымышлы һәм югары мәдәнияткә ия булуын, халкыбызның киләчәккә өмет белән каравын, ата-бабалары истәлеге алдында үзләрен җаваплы санауларын тагын бер

кат дәлилли. Гомумән, милли мәдәниятебезгә ихтирамлы һәм сакчыл караш, туган якны, кешеләрне, тормышны ярату хезмәт сөючән актанышлыларның һәр гамәлендә чагылыш таба.

Бу төбәкнең күңел хәзинәләрен туплау һәм өйрәнү Бөек Ватан сугышыннан соң ук башлана. Хәер, шагыйрь Мөхәммәт Садри Актаныш ягы авылларында әле 1939 елда ук берничә бәет язып алган була («Пугачев бәете», «Перепись бәете», «Беренче бөтендөнья сугышы бәете»). Бу әсәрләр фольклор җыентыкларында һәм хрестоматияләрдә кабат-кабат басылдылар. Ә инде 1948 елда күренекле фольклорчы Хәмит Ярми җитәкчелегендәге фольклор экспедициясе (әгъзалары Халидә Гатина һәм булачак язучылар Нурихан Фәттах, Шаһидә Максудова), Актаныш төбәгендәге 27 авылда булып, 5 меңгә якын халык авыз иҗаты әсәрләрен язып ала.

Актаныш ягының җыр-моң чишмәсенә танылган композиторларыбыз да игътибар итә. Александр Ключарев бу якларда 1939–1946 елларда 21 көй язып ала. Җәүдәт Фәйзи дә 1952 елда ике дистәләп җыр яздырып кайта. «Актаныш басмалары», «Ярминкә такмаклары», «Ай, тыр-дыр, там-там» исемле җырлар бүген дә эфирдан һәм сәхнәләрдән нәкъ менә Җ. Фәйзи язып алганча яңгырыйлар...

Укучыларыбызга тәкъдим ителгән китап – 2009 елда әзерләнгән хезмәтнең икенче, яңадан эшкәртелгән, тулыландырылган басмасы.

2009 елда хакимият башлыгы Энгель Нәвап улы Фәттахов ярдәме белән Актаныш районына Институт тарафыннан оештырылган экспедиция Татарстан гуманитар фәнен җитди яңа табышлар белән баетты. XIX гасырда – XX гасыр башында күренекле дин әһелләре Габдессәлам бине Габдеррахман һәм Мөхәммәдьяр Солтановларның якын туганнары күмелгән Мәчти каберлеге табылу – шундыйларның берсе. Әлеге һәм башка казанышлар сезнең кулыгыздагы китапта чагылыш тапты.

Халкыбызның үткәне белән кызыксынучыларга филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗановның Актаныш төбәгендә табылган шәҗәрәләрне; тарих фәннәре кандидаты Рәшит Кадыйровның кулъязма мирас һәм эпиграфик ядкярләрне тикшерү нәтиҗәләре бай мәгълүмат бирә. Һәрберсе үз өлкәсендә абруйлы

белгеч булган галимәләребез – филология фәннәре докторлары: Дария Рамазанованың җирле халыкның тел үзенчәлекләренә анализ ясавы, Флера Баязитованың Актаныш районы мисалында халкыбызның гореф-гадәтләре, йолаларына багышланган мәкаләсе, Фирдәвес Гарипованың авыллар тарихын күзәтүе белән укучыларыбыз бик теләп таныштылар. Танылган сәнгать белгече Рауза Солтанованың үз туган ягындагы мәдәни мирас, татарларга хас кәсепләр, һөнәр төрләре һәм аларның бүгенге көндәге торышы турындагы бай материалы укучы күңеленә бик хуш килде. Филология фәннәре кандидаты Ленар Җамалетдинов 1981, 1987 елларда Актаныш районының 10 авылын өйрәнеп, 500 берәмлектән артык фольклор хәзинәсе туплаган иде. Бу китапта аларның бер өлеше, шулай ук сәнгать фәннәре кандидаты Эльмира Каюмова яздырып алган музыкаль фольклор үрнәкләре тәкъдим ителде.

2009 елда Актаныш районына ясалган экспедиция Актаныш авылына нигез салынуның – 300, район төзелүнең 80 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә үткәрелгән иде. Бу сәфәр Институт галимнәре күңелендә җылы матур тәэсирләр калдырды. Яңа ачышлар һәм табышлар шатлыгы халыкның кунакчыллыгы, ачык күңеллелеге белән кушылып, нәтиҗәле, бәрәкәтле уңышларга китерде һәм күләмле хезмәт язуга нигез булды.

2020 елда актанышлылар инде Актаныш авылына нигез салынуның – 310, район төзелүнең 90 еллыгын бәйрәм итәләр. Әлеге уңайдан Институт районга тагын бер экспедиция үткәрергә җыенган иде. Ләкин бөтендөньяга таралган коронавирус пандемиясе әлеге планнарга үзгәрешләр кертергә мәҗбүр итте: яңа экспедицияне оештырып булмады. Ләкин топонимика, гамәлидекоратив сәнгать материалларын без актанышлылардан анкета юлы белән җыеп алдык. Ифрат күп, бик тә файдалы материал тупланды. Бу эшне оештыруда зур булышлык күрсәткән Актаныш районы администрациясенә һәм урыннарда халыктан материалны җыеп алуда ярдәм иткән белгечләргә үзебезнең рәхмәтләребезне җиткерәбез. Алар булышлыгы белән китапның икенче басмасы тагын да баетылды.

Укучыга тәкъдим ителгән китапның яңа басмасында Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты хезмәткәрләренең төбәк тарихына багышланган бик тә мәгълүмати мәкаләсе бирелде.

Мәкалә Актаныш тарихын болгар чорларыннан ук күзалларга ярдәм итә. Районда хәзер яшәүче авыллар һәм инде юкка чыккан авыллар турында филология фәннәре кандидаты Г. К. Һадиева мәкаләсе урнаштырылды. Югарыда әйтеп кителгәнчә, анкета ысулы белән район авылларыннан 1500 микротопоним (җирле географик объект атамасы) тупланды. Әлеге атамалар филология фәннәре кандидаты О. Р. Хисамов тарафыннан анализланып, сүзлекчә формасына китерелде. Әлеге микротопонимнар сүзлеге һәм аларны анализлаган мәкалә шулай ук китапта урын алды.

Актаныш районы халкы, билгеле булганча, татар теле урта диалектының минзәлә сөйләшендә аралаша. Филология фәннәре докторы Ф. Ю. Йосыпов үзенең мәкаләсендә әлеге сөйләшнең фонетик үзенчәлекләрен бик тә җентекләп анализлый һәм әлеге сөйләш, һичшиксез, татар теленең урта диалектына карый һәм урта диалектның башка сөйләшләре һәм татар әдәби теле белән зур уртаклыклар күрсәтә дигән нәтиҗәгә килә. Әлеге фикер китаптагы барлык мәкаләләрдә дә кызыл җеп булып сузыла.

Халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Илсөяр Закированың «Әкият дигән дөнья бар» исемле мәкаләсе 1948 елгы экспедиция вакытында Актаныш районында язып алынган әкиятләргә һәм әлеге районның әкиятчеләренә багышланган. Бу мәкаләдә якташларыгыз исемнәрен күрү, «Татар халык иҗаты» җыентыкларында дөнья күргән әкиятләр арасында Актаныш районыннан язып алынган текстлар булуын да белү, әкиятче әби-бабайларыгызның яки әти-әниләрегезнең исемнәрен очрату туган якны яңа яктан ачарга булышыр.

Сәнгать фәннәре докторы Р. Р. Солтанова 2009 елда язылган мәкаләсен яңа мәгълүматлар белән тулыландырды. Актанышлылар тарафыннан ясалган сәнгать эшләнмәләренең фотолары өстәлде.

Шул рәвешле, Актаныш авылына нигез салынуның – 310, район төзелүнең 90 еллыгына багышлап әзерләнгән бу китап актанышлыларга Казан галимнәреннән истәлекле бүләк булып барып ирешсә иде.

***Ким Миңнуллин,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы*

## КЕРЕШ СҮЗ

Актаныш муниципаль районы республикабызда милли йөзен, халкыбыз гореф-гадәтләрен саклап яшәгән саф татар районнарының берсе булып тора. Монда яшәүче халыкның 99% ы татар милләтеннән. Актанышка килгән һәркем чын татар мохитенә эләгә, татар авылларының матурлыгын, халкының тырышлыгын күреп соклана.

Бай табигатьле төбәгебез саф һавасы, елга-күлләре, урманнары-кырлары белән дан тота. Табигатьтән күчкән хозурлык авыл урамнарына да үтеп керә: һәркайда яшеллек, төзеклек, чисталык хөкем сөрә, йорт яннарында, оешмалар, социаль объектлар территориясендә утыртылган аллы-гөлле чәчәкләр тормышыбызга ямь бирә.

Әнә шул матурлыклар, милли мохит тәэсирендә яшәгән районыбыз халкы Татарстанда гына түгел, дөнья күләмендә танылган шәхесләрне тәрбияләп үстерде. Алар арасында 1927–1928 елларда ТАССРның Халык Комиссарлары Советы рәисе Шәйгардан Шәймәрдән улы Шәймәрдәнов, Татарстан Республикасының Беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев кебек дәүләт эшлеклеләре, халык җырчысы Әлфия Авзал кызы Авзалова кебек күренекле иҗатчылар бар. Гомумән алганда, районнан чыккан бик күп шагыйрьләр, язучылар, галимнәр, рәссамнар, җырчылар, төзүчеләр һәм башка һөнәр ияләре татар халкының күренекле шәхесләренә, милли горурлыгына әверелделәр.

Районыбызның күрке булган Актаныш игенчеләре республикада уңыш алу буенча һәрвакыт алдынгы урыннарны яулый. Әлеге юнәлештә без тагын да югарырак үрләр яулау максаты белән янабыз. Икмәк булса, җыр да була, дигән элгәреләрдән килгән мәгънәле сүзләрне истә тотып яшибез.

Киләчәгебез дә өметле. Актаныште урнашкан Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернатына белем алырга, татар телен тирәнтен өйрәнергә дип районыбыз авылларыннан гына түгел, республиканың, илнең төрле төбәкләреннән балалар җыела. «Бүләк» лагере исә халыкара дәрәҗәгә чыкты. Бездә белем

алган һәм ял иткән балаларның киләчәктә милләтебезнең төп көчләре булачагына иманым камил.

Тарихтан хәбәрдар булган очракта гына алдагы көннәр турында сүз йөртергә мөмкин. Актаныш районы төзелүгә 90 ел, аның үзәгенә нигез салынуга 310 ел дип исәпләнсә дә, безнең якның күпкә борынгырак, күпгасырлык бай тарихы бар. Ямьле Агыйдел, җырлы Сөн буйларына сыенып утырган төбәгебез турында сөйләгәндә, аның түп-түгәрәк зәңгәр күлләре, иркен басулары белән бергә шушы якны үз итеп, шушы җирдә тормыш корган бабаларыбыз күз алдына килеп баса.

Галимнәр әйтүенчә, Актаныш районы территориясендә беренчел болгар авыллары XI гасырларда ук барлыкка килгән. Семиостров археологик истәлекләре комплексы, ачылган культура катламнары һәм табылдыклар (аерым алганда, балчык савыт-саба, тимер ук очлыклары) моны ачык чагылдыра.

Район халкы бүген дә үзенең ерак бабаларын, аларның гореф-гадәтләрен, традицияләрен онытмый. Бу хакта сезнең кулыгыздагы китап та сөйли. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән әлеге хезмәттә район халкының искиткеч зур әһәмияткә ия булган рухи мирасы тупланган. Халыктан бөртекләп җыелган әлеге материал киләчәк буыннарга гореф-гадәтләребезне җиткерү өчен дә зур роль уйнаячак. Район халкы, җитәкчелеге һәм шәхсән үземнең исемнән Институт хезмәткәрләренә зур рәхмәтләребезне җиткерәм!

Актанышның милли йөзен саклап калу, аны бөтен дөньяга танытуда үз максатларыбыздан тайпылмаячакбыз. Бу иң беренче чиратта безгә – актанышлыларга, милләттәшләребезгә кирәк.

Актаныш кешеләре – зыялы, тыйнак, фидакяр халык. Менә шушы уңай сыйфатларны үзенә туплаган районашларыбыз тотрыклы, имин тормыш белән, иртәгәсе көнгә ышаныч белән яши. Мин аларга ихластан ныклы саулык, куанычлы озын гомерләр, рәхәт тормыш телим.

***Энгель Фәттахов,***
*Актаныш муниципаль районы башлыгы*

# АКТАНЫШ РАЙОНЫ: ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Радик Салихов,*
*Айдар Ногманов,*
*Марат Гыйбатдинов,*
*Радик Исхаков,*
*Шамил Садыйков*

Актаныш төбәге Агыйдел һәм Чулман (Кама) елгалары кушылган җирдә урнашкан. Ул үзенең матур табигате белән генә түгел, кабатланмас татар рухын саклап калуы белән дә үзенчәлекле. Матур һәм бай Актаныш ягы борынгыдан күп кенә кабиләләрне, шул исәптән борынгы бабаларыбызны да үзенә тарткан. Әлеге төбәктә без борынгы татар кабиләләренең варислары – гәрәйләр, кыпчаклар кебек атаклы нәселләрен дә күрәбез.

«Агыйдел» исеме турында бик күп матур легендалар бар. Кызганычка каршы, бу турыда бернинди төгәл чыганаклар сакланмаган. Инде фәнни фаразлау турында сөйләсәк, төбәкнең елгалар исемен комплекста карарга кирәк. Мәсәлән, Уфа елгасы шулай ук Караидел буларак билгеле. Шулай итеп, бу – борынгы төрки бабаларыбызның дөнья якларын төрле төсләр белән билгеләүләре белән бәйле[1]. Төньякны – караңгылык, кара төс; көнбатышны ак төс белән бәйләгәннәр[2]. Әле дә төрекләр төньяк диңгезне – Кара диңгез, көнбатыштагысын (Урта диңгезне) Ак диңгез диләр.

---

[1] *Кононов А. Н.* Семантика цветообозначений в тюркских языках // Тюркологический сборник. – 1975. – М., 1978. – С. 160.

[2] Шунда ук. – Б. 164.

Шулай ук «ак» сүзе кайбер географик атамаларда «агым су», «тиз агышлы» мәгънәсендә кулланыла. Елгалар арасында «ак су» дип «тау карлары эрүдән чыккан сулар белән тулыландыра торган» елгаларны атаганнар[1]. Шулай ук ике елга бүленгәндә (кушылганда), В. В Бартольд әйтүе буенча, «үзенең элеккеге юлы белән аккан елганың төп агымы – Аксу, Ак-Дарья, ясалма канал – Карасу, Кара-Дәрья диелгән»[2]. Белгәнебезчә, Караидел (Уфа елгасы) Агыйделгә кушыла.

Актаныш төбәгенең борынгы тарихын 1956–1960 елларда СССР Фәннәр академиясе Археология институтының тарих фәннәре докторы А. В. Зубарев экспедициясе, А. П. Шокуров (1957) һәм 1957, 1977–1979 елларда археолог Е. П. Казаков[3] өйрәнгәннәр. Моннан тыш, 2009 елда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан Актаныш җирлегенә зур экспедиция оештырылды.

Бу җирлектә кешеләр инде берничә мең ел дәвамында яши (безнең эрага кадәр II меңьеллык) – Буралы, Чиркәскул, Пьянобор, Кушнаренко, Болгар. Төбәктә табылган археологик ядкярләрнең күпчелеге Пьянобор (фин-угор) культурасына нисбәтле. Пьянобор культурасы якынча безнең эрага кадәр III гасырга – безнең эраның II гасырына карый, ул үзенең асылы буенча Ананьино, Мазунино, Караабыз һәм Азелино культуралары белән охшаш. Алар игенчелек, терлекчелек, аучылык һәм балыкчылык белән шөгыльләнгәннәр[4].

Борынгыдан инде төбәктә төрки һәм фин-угор халыкларының бабалары бергә яшәгәннәр.

---

[1] *Кононов А. Н.* О семантике слов кара и ак в тюркской географической терминологии // Известия Отделения общественных наук Академии наук Таджикской ССР. 1954. – Вып. 5. – С. 83–85.

[2] *Бартольд В. В.* Аксу // Сочинения: в 9 томах. – Т. 3. Работы по исторической географии. – М.: 1965. – С. 316.

[3] Актаныш – ак илем: тарих, икътисад, мәдәният, шәхесләр / төз. И. Хәлиуллин. – Казан: Идел-пресс, 2010. – Б. 15, 17.

[4] Шунда ук. – Б. 17.

Халыкларның бөек күчешенең соңгы чорында, VI–VII гасырларда хәзерге Татарстанның көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш төбәкләренә борынгы венгрлар (мадьярлар) күченә. Борынгы венгрлар беркадәр дәрәҗәдә үзләренә кардәш Көнбатыш Себер угор кабиләләре белән бергә Кушнаренко археологик культурасын (хәзерге Башкортстан Республикасы Кушнаренко авылы янындагы каберлеккә нисбәтле рәвештә шулай атала) төзүдә катнашалар. Баштарак Кушнаренко кабиләләре Урал алдында яшиләр. Соңрак, VII–VIII гасырларда, үз территорияләрен киңәйтеп, Кама аръягының көнчыгышында көн күргән Турбаслы-Имәнкискә культурасы кабиләләренең җирләрен билиләр. VIII–IX гасырларда борынгы болгарлар (барсилләр) йогынтысы белән җирле угорларның бер өлеше төркиләшә һәм исламны кабул итә, икенче өлеше күченеп китәргә мәҗбүр була[1]. IX гасырның 60–70 нче елларында булып узган мадьяр-бәҗәнәк сугышларыннан соң кушнаренколыларның күпчелеге көнбатышка китә, шулай ук борынгы венгрларның (мадьярлар, маҗарлар) зур өлеше хәзерге Венгрия җирләренә юнәлә.

922–1236 елларда хәзерге Актаныш төбәге җирләре Идел буе Болгар дәүләте составына керә. Хәзерге Актаныш районы территориясендә беренчел болгар авыллары XI гасырларда барлыкка килә. XII гасырда тагын берничә авыл (мәсәлән, Татар Ямалы авыллыгы) төзелә.

Болгар дәүләтенең көнчыгыш чикләре Агыйделнең түбән агымы, көньяк-көнчыгыш чикләре Җаек (Урал) елгасының уң як яры буйлап уза. 1229 елда болгарлар әлеге елга буенда монголлар белән сугышалар, һәм җиңелгән гаскәр Актаныш-Минзәлә яклары далалары аша Биләргә кайта.

Семиостров археологик истәлекләре комплексы, ачылган культура катламнары һәм табылдыклар (аерым алганда, балчык савыт-саба, тимер ук очлыклары) моны ачык чагылдыра. Бу

---

[1] Актаныш – ак илем: тарих, икътисад, мәдәният, шәхесләр / төз. И. Хәлиуллин. – Казан: Идел-Пресс, 2010. – Б. 19.

комплекстагы авыллар буш урында түгел, кайчандыр Пьянобор культурасы кабиләләре яшәп киткән торак урынында нигезләнә.

Алтын Урда чорында (XIII гасырның икенче яртысы – XIV гасыр) дәүләтнең Болгар вилаяте халкы[1] көнчыгыш районнарга, хәзерге Актаныш төбәгенә тагын да активрак керә, җирле халыкта ислам тагын да көчәя бара. Кайбер очракларда татарлар җирле халык яшәгән җирләргә килеп утыралар. Такталачык археологик комплексы моның бер чагылышы булып тора. Әлеге комплекска кергән каберлектә 1969–1972, 1976–1979 елларда Е. П. Казаков тарафыннан тикшерелгән 350 дән артык кабернең ин зур күпчелеген (274 кабер) мөселман каберләре тәшкил итә. Ләкин аларда мәҗүсилек эзләре ачык күренә. XIII–XIV гасырларга караган Чиялек авыллыгында да кайчандыр мөселманлашкан Урал алды халкы яшәгән, II Чишмә курганлы каберлегендә дә (өч курган) шул халык вәкилләре җирләнгән[2].

Рус елъязмаларында (1469) Актаныш җирләре, ягъни Агыйделнең көнбатыш җирләре («Беловоложския земли» буларак күрсәтелә) Казан ханлыгы составында була. Казан ханлыгы 1552 елда яуланганнан соң, алар Казан сарае приказына караган Минзәлә воеводасына буйсына. Казан ханлыгы җимерелгәч, татарлар һәм Идел-Чулман буенда яшәгән башка халыкларның көнчыгыш төбәкләргә күчеп килүчеләр кискен арта. Нәтиҗәдә XVII гасырда Асылтүш, Кәзкәй, Әнәк, Чалманарат, Буранчы, Әтәс, Иске Сәфәр, Иске Әлем, Иске Айман, Такталачык, Калмаш, Чәчер, Чат, Чапкын, Качкын кебек авыллар барлыкка килә. Бу инде төбәктә зур күченүләрнең төп, өченче дулкыны була (беренчесе – XI–XII гасырларда, икенчесе Алтын Урда заманында).

XVIII гасырда барган көчләп чукындыру нәтиҗәсендә Каманың уң ярыннан күчеп чыгучыларның яңа (дүртенче) дулкыны килә. Алар арасында күрше – хәзерге Минзәлә районы җирләрендә яшәүчеләр дә була. XVIII гасырның беренче ярты-

[1] Алтын Урда дәүләтендә болгар, кыпчак һәм башка төрки кабиләләр нигезендә бердәм татар халкы формалаша.

[2] Актаныш – ак илем: тарих, икътисад, мәдәният, шәхесләр / төз. И. Хәлиуллин. – Казан: Идел-пресс, 2010. – Б. 20.

сында Иске Кормаш, Мерәс, Пичмән Елга, Табанлыкүл, Үмәнәй, Чөгәнә, Әгъбәс, Богады кебек авыллар барлыкка килә.

Актаныш крестьяннары Е. Пугачев хәрәкәтенә аеруча актив катнаша. 50–300 кешелек татар отрядлары дворян утарларына һөҗүм итәләр. Крестьяннар армиясе Сарсак-Омга, Аккүз, Сукман һәм башка авылларны үтеп, Алабугага киткән.

Актаныш төбәгендәге татар авылларының борынгылыгын бүгенге көннәргә кадәр сакланып калган эпиграфик истәлекләр дә раслый. 1998 елда галим М. Әхмәтҗанов тарафыннан Әҗәкүл авылы зиратында 1682–1683 елларга караган, Килди би улы Ишкәй каберенә куелган таш табылган. 2009 елда ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган комплексны экспедиция вакытында тарихчы Рәшит Кадыйров[1] Актаныш районының 14 авылы зиратында 53 эпиграфик истәлек ачыклаган. 2014–2015 елларда Актаныш төбәге эпиграфик истәлекләренең байтак өлешен Башкортстан тарихчысы Илья Васильев өйрәнгән. Ул, нигездә, районның көньяк-көнбатышында урнашкан авылларга гына игътибарын юнәлткән, шул рәвешле, районның 16 авылында 95 эпиграфик истәлек ачыклаган (шуларның өчесе – кириллицада язылган мари ташлары).

XVI гасырның икенче яртысында – XVIII гасырда Актаныш төбәге Уфа өязенең Казан даругасына[2] караган. Үзәге Уфа шәһәре булган әлеге өяз XVIII гасыр башына кадәр Казан сарае Приказына[3] буйсынган, 1708 елда Казан губернасы составына кергән. 1719 елда аның җирләре сенатка буйсынган Уфа провинциясенә бирелә, 1744 елда Оренбург губернасына кушыла.

---

[1] Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш. – Казан, 2010. – Б. 60.

[2] Даруга (даруха, дорога), «дарга» сүзеннән – монголча баш, командир, җитәкче. XIII–XVI йөзләрдә Җүчи Олысында (Алтын Урдада), Казан ханлыгында, XVI–XVIII йөзләрдә Казан һәм Уфа өязләрендә административ-территориаль бүленеш, төбәк, өлкә.

[3] Казан сарае Приказы (XVI гасыр – XVIII гасыр башы) – яулап алынган Казан ханлыгы һ.б. җирләр белән идарә итү өчен билгеләнгән үзәк дәүләт идарә оешмасы.

Е. И. Пугачев җитәкчелегендәге 1773–1775 елгы Крестьян сугышын бастырганнан соң, Екатерина II Россиядә административ-территориаль бүленеш реформасын уздыра. Аның нәтиҗәләре буенча 1781 елда Актаныш районы территориясе Минзәлә өязе составына кертелә, XX гасыр башына кадәр шунда калдырыла. 1796 елдан өяз – Оренбург губернасы составында, ә 1865 елда яңа гына оешкан Уфа губернасына кушыла. Идарә органнарыннан тыш, идарә итү берничә авылны берләштергән волостьлар дәрәҗәсендә дә алып барылган. 1913 елда өяз составында 31 волость булган[1], шулар арасында хәзерге Актаныш районына караганнары – Актаныш, Байсар, Поисев, Семиостров, Такталачык волостьлары.

Минзәлә өязендә идарә итүнең үзенчәлекләре 1798 елда аның территориясендә, идарә итүнең традицион системасы белән беррәттән, кантон[2] системасы кертелүдән гыйбарәт була. Ул Урал буенда Россиянең көньяк-көнчыгыш чикләрен ныгыту һәм башкорт баш күтәрүләрен булдырмау максатыннан төзелә. Әлеге системаны кертү барышында төбәктәге башкорт, мишәрләр һ.б. халыклар йомышлылар сословиесенә күчерелә, алардан махсус «Башкорт-мишәр»[3] гаскәре төзелә. Башкорт һәм мишәрләр яшәгән җирләрне административ берәмлекләр-

---

[1] Крестьянское хозяйство Уфимской губернии. Подворная перепись 1912–1913 гг. – Уфа, 1914. – С. 2–264.

[2] Кантон системасы – Уфа, Сембер, Оренбург, Вятка, Пермь төбәкләрендә идарәне хәрби нигезләрдә төзү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Урал алдында хәрби хезмәт алып барган йомышлы катлам вәкилләре яшәгән җирләр, командалар (йорт-юрт)лардан торган кантоннарга бүленә. Кантон начальниклары, – гадәттә офицерлар, генерал-губернаторга буйсынган.

[3] Башкорт-мещеряк гаскәре (1855 елдан Башкорт гаскәре) – хәрби хезмәт итүче йомышлы катлам вәкилләрен берләштерүче регуляр булмаган гаскәр. Гәскәргә башкырт (башкирец), мишәр (мещеряк), типтәр, бобыль кебек социаль катлам вәкилләре тупланган. Биредә «башкырт» һәм «мишәр» терминнары катламны (сословиене) аңлата. Әлеге төшенчәләр хәзерге милләтләр белән тулысынча туры килми. Мәсәлән, башкырт (башкирец) сословиесенә күп кенә татарлар, марилар, мордвалар, удмуртлар, чувашлар һ.б. милләт кешеләре кертелгән. «Башкырт гаскәре»ндә татар халкының күп кенә этник төркемнәре (мишәрләр, типтәрләр) хезмәт иткән.

гә – кантоннарга бүләләр, алар һәрвакытта да өяз чикләре белән туры килмәгән.

1855 елда «Башкорт гаскәре»нә типтәрләр һәм бобыльләр[1] кушылу белән, кантоннар саны 28 гә җитә. 1863–1865 елларда кантон системасы бетерелгәннән соң, алда искә алынган 28 кантон өяз принцибы нигезендә атала башлый.

Актаныш районы халкы XIX гасыр башларыннан алып Россия империясе алып барган сугышларда катнаша. Архив мәгълүматларына караганда, аларның 1806–1807 елгы Рус-прусс-француз сугышында булулары билгеле. Моннан тыш, 11 нче кантоннан 1812 елгы Ватан сугышында һәм рус армиясенең чит илләргә яуларында катнашу өчен, 3 нче, 5 нче, 6 нчы, 19 нчы һәм 20 нче полклар оештырыла. Актаныш районына караган авыллардан алынган сугышчылар күбесенчә 5 нче һәм 6 нчы полкларга кергәннәр. Актанышлыларның әлеге сугышларда катнашулары турында җентеклерәк рәвештә Башкортстан Республикасы Милли архивындагы И-2 фондында (Оренбург хәрби губернаторы канцеляриясе) сакланган формуляр исемлекләр буенча өйрәнергә мөмкин.

Идарә итүнең кантон системасы кертелү белән, халыкның социаль-хокукый хәле дә үзгәрә. Шактый өстенлекләр биргән хәрби йомышлы статуска карамастан, халык бик күп санда йөкләмәләр үтәгән. Мәсәлән, Оренбург чик буе сызыкларын һәм башка урыннарны саклау һәм Россия империясенең хәрби кампанияләрендә катнашудан гыйбарәт булган төп хәрби эшчәнлекләре белән беррәттән, кантоннарда яшәүчеләр юллар, күперләр салу, урман кисү, Оренбург чик буе сызыгының яңа өлешләрен җайга салу һәм анда йөк ташуда катнашканнар. Түрәләр файдасына атлар китерү, ямчылык, юл төзү, йортка төшерү (постой) йөкләмәләре халык өчен бигрәк тә зур авырлыклар тудырган. Акчалата салымнар да түләгәннәр, төрле түләүләрдә,

---

[1] XVIII йөз башында башкортларның вотчина җирләренә килеп урнашкан кешеләр (припущенниклар) типтәр һәм бобыльләргә бүленгәннәр. Типтәр дип – төрки телле халыклар (татарлар, чувашлар, башкортлар), бобыльләр дип фин телле халыклар (марилар, удмуртлар, мордвалар) аталган.

кантон идарәләрен, канцелярияләрне ипи кибетләрен тотуда катнашлык күрсәткәннәр.

Көнчыгыш Татарстандагы торак пунктлар, шул исәптән Актаныш районындагы авыллар да үзләренең катлаулы социаль составлары, күп сословиеле булулары белән үзенчәлекле. Төп «башкорт» сословиесеннән тыш, кайбер авылларда типтәрләр, ясаклы татарлар да яшәгән. Әлбәттә, татар халкының әлеге төркемнәренә салынган налоглар, йөкләмәләр вотчинниклардан аерылып торган. 1795 (V), 1816 (VII), 1834 (VIII), 1850 (IX) һәм 1858 (X) еллардагы ревизияләр нигезендә Актаныш районы авылларына ясалган демографик анализ халыкның бер сословиедән икенче сословиегә күчеп торуларын исбатлый. Әлеге күчешләр беренче чиратта җир кишәрлекләренә ия булу һәм алардан файдаланудагы үзгәрешләр белән бәйле була.

Актаныш ягы – татарларның борынгы шәҗәрә үрнәкләрен саклаган иң бай төбәк. Мәчти авылындагы нәселләрдән калган Туксаба шәҗәрәсе XI–XII гасырларда Тын (Дон) елгасы һәм Каф тавы (Кавказ) буйларында яшәгән борынгы кыпчак кавемнәре тарихы белән бәйле. Туксаба шәҗәрәсенең яңа замандагы дәвамы – Күҗәкә авылында сакланган Акъюл нәсел шәҗәрәсе чылбыры.

Нократтан чыккан Кара бәк шәҗәрәсе шулай ук бик борынгы чорларга карый. Кара бәк нәселе Алтын Урда ханнары токымына барып тоташа. Бу нәселдән булган солтаннарның кайберләре Әтнә төбәгенең Олы Мәңгәр һәм Иске Мәңгәр авылларында яшәгәннәр. Әгерҗе якларыннан күчкән нократ морзаларының Актаныш төбәгендәге кайбер авылларга нигез салуы да билгеле. Бу үрнәкләр Актаныш төбәге халкының нәсел тамырлары бик борынгыдан килүен дәлилли.

Төбәкнең иң зур шәҗәрә үрнәге – «Гәрәй хан» шәҗәрәсе. Тарихтан мәгълүм булганча, гәрәйләр XIV гасыр ахырында Кырым, Кара диңгез якларыннан Идел-Урал буйларына күченә. Аларның оешып урнашкан җирләре Татарстанның Актаныш, Сарман, Минзәлә, Башкортстанның Краснокама һәм Илеш төбәкләренә туры килә. Кырым якларында калган нәкъ менә Гәрәй кабиләсе татарлары арасыннан Кырым һәм Казан ханна-

ры нәселе күтәрелеп чыга (Казанда 1521–1549 елларда Сахиб Гәрәй һәм Сафа Гәрәй идарә итә).

Агыйделдә яшәгән гәрәйләрнең биш шәҗәрәсе сакланган, нәкъ менә алар нәселнең таралыш географиясен күрсәтә. Мәсәлән, Актаныш районы Куян авылы шәҗәрәсе гәрәйләрнең башта Агыйделнең уң як ярында, соңрак сул (көньяк) ярга чыгып таралулары турында сөйли.

Гәрәй шәҗәрәләрен туплауга һәм саклауга Актаныш төбәге белән бәйле драматург Риза Ишморат, Такталачык авылыннан чыккан археограф Альберт Фәтхи һәм Түбән Гәрәй авылында туып үскән Тәлха Анамовлар зур өлеш кертәләр.

Актаныш гәрәйләре нәселеннән күп кенә танылган шәхесләр килеп чыккан. Алар арасында Мутиннар морза нәселе дә бар. Аларның нәселе Уфа губернасының морзалар шәҗәрәсе китабының II өлешенә керә. Әлеге татар нәселе вәкилләре – Россия тарыхына шактый эз калдырган шәхесләр. Алар арасында сәүдәгәрләр (Габдрәшит Мутин), дин әһелләре (Баһаутдин Мутин), артистлар (Ильяс Мутин) һәм башка өлкәләрдә дан казанган шәхесләр шактый. Әмма әлеге исемнәр арасыннан бу нәселнең өч вәкилен аерым атап үтмичә булмый. Болар – Тимер Мутин, Илдархан Мутин һәм Мөхтәр Мутиннар.

Тимер Мутин – Гәрәй өязе башлыгы, 1756–1763 еллардагы сугышта катнашучы, Гросс-Егерсдорф янында сугышкан батыр. Ул – татар-башкорт хокукларын яклаучы. Нәкъ Тимер Мутин патшабикә Елизаветага петиция яза, аны империя башкаласына барып үзе тапшыра. 1759 елда Петербургта вафат та була.

Илдархан Мутин башкорт хакимияте әгъзасы булып тора, Башревкомда да төрле вазифаларны башкара. Башкорт хәрби шурасы әгъзасы да була. Аннары, большевиклар белән юллары аерылгач, Зәки Вәлиди белән Урта Азиягә китә һәм советларга каршы баш күтәрүләр оештыра.

Мөхтәр Мутин исә киң җәмәгатьчелеккә артист буларак мәгълүм. Ул «Нур», «Ширкәт» труппаларында хезмәт итә. Казанда театр бүлеген җитәкли. Зур шөһрәт казанган атаклы артист Мутин – татар сәхнәсенә героик пафос, романтик юнәлеш алып килгән, гаҗәеп темпераментка ия булган олы трагик талант.

Моннан тыш, Актаныш ягының горурлыгы булып **Солтановлар** нәселе тора. Мәчти авылында атаклы Солтанов морзаларның берничә буын вәкилләре яшәгән.

Солтановлар XIX гасыр урталарына кадәр Башкорт-Мишәр гаскәрендә хезмәт иткәннәр. Әлеге татар нәселенең иң атаклы вәкиле булып Россиянең бишенче мөфтие Мөхәммәдьяр Солтанов тора. Ул – Мәчти авылында 1837 елда Мөхәммәдшәриф Баязит улы гаиләсендә туа, 1859 елда Башкорт-Мишәр гаскәрендә урядник, 1861–1866 елларда кантон башлыгы, 1886–1915 елларда мөфти. Үзе Уфада җирләнгән булса да, аның хатыны (Хәнифә Якуп кызы) кабере Мәчти авылында әле дә сакланган.

Мәчти зиратында шулай ук Россиянең икенче мөфтие Габдессәлам бине Габдеррахманның (мөфтилек еллары – 1825–1840) гаилә әгъзалары: икенче хатыны Фәрхибану, кызы Сәрвиҗиһан (1842?), оныклары Бибигазизәбану (1841), Бибишәмсиҗиһан (1842), Бибихөсниҗиһан (1854) һәм кияве Шәйхелислам бине Мөхәммәдеррәхим Солтанов (1888) җирләнгән.

Әлбәттә, әлеге шәхесләрне үстерер өчен, билгеле бер җирлек булырга тиеш, әлеге функцияне белем бирү йортлары – мәктәпләр һәм мәдрәсәләр үтәгән. Актаныш җирлегенең һәр авылында диярлек мәчет һәм мәктәп ачарлык үз мәхәлләсе булган. Мәсәлән, Аеш авылында 1882 елдан, Актаныш авылында 1855 елдан, Ахун, Әҗәкүл авылларында 1831 елдан, Буазкүл авылында 1816 елдан мәчет һәм мәдрәсә эшләп килгән. Әлеге исемлеккә Актанышның һәрбер авылын кертергә мөмкин.

XVIII гасыр ахыры – XIX гасырның беренче чирегендә нигез салынган мәчет белән мәдрәсәләр татар халкының төп белем учагы булган һәм авыл халкы аларга зур игътибар биргән. 1917 елгы Октябрь революциясенә кадәр төбәктәге 109 авылның 42 сендә 11 мәдрәсә һәм 53 мәктәп, шулай ук Мәчтидә, Пучыда, Яңа Әлемдә, Адайда, Байсарда, Мари Суыксуында татар, рус-башкорт, рус-мари мәктәпләре эшләп килгән.

Актанышта шулай ук һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге була. XIX гасырда ук монда тимерче остаханәсе, XX гасыр башында – 2 тегермән, 5 кибет (мануфактура һәм азык-төлек), ярма

киптергеч, эре авылларда атна саен базарлар, Актанышта көзге ярминкәләр эшли.

* * *

Актаныш халкы 1917 елгы Октябрь революциясе, Гражданнар сугышы һәм сәнәкчеләр фетнәсендә актив катнаша. 1918 елның 24 сентябрендә Минзәләдә (өяз үзәгендә) җирле совет оешмаларының җыелышы уздырыла. Анда ревком төзү мәсьәләсе карала, халык мәгарифе, хезмәт, сәүдә һәм сәнәгать, социаль тәэминат, сәламәтлек саклау һәм юстиция эшләре буенча бүлек мөдирләре билгеләнә.

1920 елның 27 маенда Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитетының һәм Халык Комиссарлары советының Автономияле Татар Совет Социалистик Республикасы (АТССР, ТАССР) төзелү турындагы карары кабул ителә.

Республика составына 5 төрле губерна: Казан, Уфа, Самара, Вятка һәм Сембер губерналарының җирләре кертелә[1]. Татарстанның башка төбәкләр белән тышкы чикләрен билгеләү 1921 елның көзенә кадәр сузыла. Бу процесска зур өлеш керткән кешеләрнең берсе – Иске Байсар авылында туган **Шәйгәрдән Шәймәрдән улы Шәймәрдәнов** ТАССР чикләрен билгеләүче комиссия әгъзасы, соңрак ТАССР Үзәк Башкарма комитеты рәисе урынбасары, 1924 елдан Татарстан Башкарма комитеты рәисе, соңрак республика Совнаркомы, хөкүмәте рәисе. Аның шәхси катнашы белән ТАССР Конституциясе проекты әзерләнә. 1939 елда ул репрессиягә дучар ителә. 2020 елның 15 сентябрендә Шәйгәрдән Шәймәрдәновның тууына 130 ел булды.

1920–1930 елларда Актаныш җирләре яңа гына оештырылган Минзәлә өязенә, соңрак кантонына[2] керә. ТАССРда 1920 елда төзелгән 10 кантон арасында Минзәлә кантоны – иң зурысы (13259 км$^2$).

1927 елда республикада эксперимент буларак беренче 8 район оеша. Бу реформа хакимият органнарын халыкка якынайту,

---

[1] *Файзуллин С.А.* Административно-территориальное устройство ТАССР в 1920–1930-е гг. Казань, 2015. – С. 199–201.

[2] 1920–1941 елларда РСФСРда кулланылган административ-территориаль берәмлек.

алар өчен район үзәкләрен якынрак ясауны күздә тота. Кантон системасы вакытында үзәк белән кантоннар арасында 100 км дан да артыграк ара булган. Авыл халкы өчен бу кыенлыклар тудырган. Мәсәлән, эш буенча Тыңламас яки Аеш авылына барырга кирәк, ди. Бу пунктларга атлы арбада барыр өчен күпме вакыт кирәк булачак...

Илнең адинистратив-территориаль яктан төрлелеге хөкүмәт карарларын тормышка ашыруга зур авырлык китергән. Бер үк вакытта һәм кантоннар, һәм районнар булу ТАССРда гына түгел, илнең башка төбәкләрендә дә күзәтелгән.

Әмма районнарга бүлүдә төп, хәлиткеч сәбәп идарә итүне оештыруда түгел, ә коллективизация булган. Урта Идел буенда аны 1930 елның көзендә, я инде 1931 елның язына тәмамларга уйлыйлар[1]. Административ-территориаль реформаны исә 1930 елның 1 октябренә кадәр тәмамларга кирәк, ягъни бу өлкәдәге үзгәрешләр авылны аграр үзгәртеп коруга кадәр тәмамланырга тиеш була. Яңа төзелгән идарә органнары коллектив хуҗалыклар төзелү процессын контрольдә тотарга, аларга юнәлеш бирергә тиеш санала.

ТАССРны районнарга бүлүнең соңгы проекты Татарстан Үзәк башкарма комитетының 1930 елның 24–26 июлендә узган сессиясендә тәкъдим ителә. Бу документ нигезендә республикада кантоннар һәм волостьлар бетерелә, районнар төзелә. ТАССРда элеккеге дүрт баскычлы система (авыл советы – волость – кантон – үзәк) урынына өч баскычлы система (авыл советы – район – үзәк) кулланыла башлый. Барлыгы 46 эре район барлыкка килә. Алар арасында Актаныш районы да була.

Яңа районнарның чикләрен һәм үзәкләрен билгеләүдә проект авторлары түбәндәгеләрдән чыгып эш иткәннәр:

а) халыкның милли составын;

ә) авыл хуҗалыгының үзенчәлекләрен һәм табигый шартларны истә тоту;

---

[1] КПСС в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК. – М., 1984. – Т. 5. – С. 73.

б) экономик һәм социаль-мәдәни үзәкләрнең географик яктан дөрес урнашуын тәэмин итү (базарлар, ярминкәләр, кулланучылар кооперациясе, медицина, агро һәм ветеринария пунктлары, икенче баскыч мәктәпләр булу һ.б.);

в) кирәкле инфраструктура һәм элемтә чараларының булуы (райисполком белән Казан һәм авыллар арасында элемтә, телефон, телеграф һәм почта бүлекчәләре).

Проект нигезендә барлыкка килгән вакытында Актаныш районының зурлыгы 1700 км$^2$, халкы 54 813 кеше тәшкил итә. Районга 53 авыл советы, 98 торак пункт, 12 417 крестьян хуҗалыгы керә[1].

Алда искә алынганча, районнарның чикләрен билгеләүдә халыкның милли составына зур игътибар бирелә. Проектны эшләүчеләр халыкның тел ягыннан да мөмкин кадәр бертөрле булуына омтылганнар. Шулай ук район үзәкләрендә яшәүче халыкның милли составы да районда яшәүче төп милләткә туры килергә тиеш булган.

Актаныш районы баштан ук татар милли районы итеп төзелә. Халыкның 95,7% ын татар, 2,7% ын руслар, 1,5% ын башка милләт вәкилләре тәшкил иткән[2]. ТАССР Үзәк башкарма комитетының 1930 елгы карары нигезендә мондый районнарда эчке эш, рәсми документлар татар телендә алып барылырга тиеш булган. Шул ук вакытта татар булмаган милләт вәкилләренә үз ана телләрендә хезмәт күрсәтелгән[3].

Яңа төзелгән Актаныш районының үзәге итеп Актаныш билгеләнә. 1926 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, анда 1274 кеше яшәгән[4]. Халык саны буенча бу районның иң эре торак пункты булмый. Мәсәлән, Такталачыкта бу вакытта 2272 кеше исәпләнгән, ягъни бер меңгә күбрәк. Яңа Әлемдә

---

[1] Списки сельсоветов и населенных пунктов по районам ТАССР. – Казань, 1930. – С. 152–155.

[2] Шунда ук. – Б. 155.

[3] *Файзуллин С.А.* Административно-территориальное устройство ТАССР в 1920–1930-е гг. – Казань, 2015. – С. 145.

[4] Списки сельсоветов и населенных пунктов по районам ТАССР. – Казань, 1930. – С. 152.

2201 кеше яшәгән. Актаныш белән чагыштырганда зуррак авыллар булып Иске Байсар (1885 кеше), Татар Әҗбие (1647 кеше; хәзер бу авыл юкка чыккан), Иске Сәфәр (1558 кеше), Күҗәкә (1360 кеше) саналган. Иң күп кешеле торак пункт булып хәзер юкка чыккан Старое Семиострово (2317 кеше) авылы торган[1]. Шулай итеп, район үзәген билгеләгәндә төп күрсәткеч булып халык саны тормаган. Актаныш, мәсәлән, районда беренче машина-трактор станциясен урнаштыру өчен уңайлы урын дип табыла. МТС – крестьяннарның яңа тормышка күчүенең төп символы, коллективлаштыруның материаль-техник базасы һәм идеологик үзәге саналган. МТС парткомнары ВКП(б) район комитетлары кебек үк дәрәҗәгә ия булган һ.б.

**Бөек Ватан сугышы геройлары**

Бөек Ватан сугышы Актаныш төбәге халкына зур югалтулар һәм хәсрәтләр китерә. Район авылларыннан сугышка 19 577 кеше китә, аларның күбесе – 11 655 кешегә туган ягына кайтырга насыйп булмый. Актанышлылар арысланнар кебек сугышалар. Каһарманлыклары өчен Баян Дәүләтов, Николай Орлов (Гатаулла Минаев), Хәсән Заманов, Сергей Фадеев, Гомәр Һадимөхәммәтовка Советлар Союзы Герое исеме бирелә, ә Сөрәнчәк егете – Польша партизаннары бригадасы командиры Александр Кузнецов – Польша Халык Республикасының Милли Герое исеменә лаек була. Актаныш халкы Кызыл Армиягә икмәк, җылы киемнәр, оекбашлар, бияләйләр генә түгел, самолет-танклар бүләк итү өчен җыелган зур суммаларны да оборона фондына тапшыруны оештыра.

Тыныч тормыштагы фидакярлекләре өчен Сәгыйрь Гыйльманов, Зөфәр Иманов, Госман Латыйпов һәм Александр Сальников Социалистик Хезмәт Герое дәрәҗәсенә ирештеләр. 48 район кешесе – Ленин, 18 е – Октябрь революциясе, 137 е – Хезмәт Кызыл Байрагы, 7 се – Халыклар дуслыгы, 148 е – «Почёт билгесе», 7 се – Хезмәт Даны орденының II һәм 79 ы III дәрәҗәсе белән бүләкләнде.

[1] Файзуллин С.А. Административно-территориальное устройство ТАССР в 1920–1930-е гг. – Казань, 2015. – С. 152–155.

Шулай ук Актаныш үзенең мактаулы гражданнары белән горурлана. Алар арасында Россия Федерациясенең халык артисты Әлфия Авзал кызы Авзалова, Актаныш районы авылларын газлаштыруда актив катнашкан Владимир Васильевич Бартенев, РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы инженеры Имаметдин Низаметдин улы Билалетдинов, I дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Ленин ордены, «Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исеме иясе Миргаяз Заман улы Заманов, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Риза Фәхретдин улы Ишморатов, Татарстан Республикасы атказанган төзүчесе Кәшби Закирҗан улы Кулиев, ике тапкыр Ленин ордены иясе Гадел Касыйм улы Сәлахетдинов, Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Рәүхәт Салихҗан улы Салихҗанов, Татарстан Республикасының Беренче Президенты Миңтимер Шәрип улы Шәймиев.

Күргәнебезчә, Актаныш – бай тарихлы, бай мираслы як. Әлеге җирлектә күпсанлы атаклы вәкилләр булуы, халыкның укымышлы, югары мәдәниятле һәм хезмәт сөючән икәнлеген дәлилләгән фактлар искиткеч күп.

## ТАМЫРЛАРДАН ТАНЫРЛАР

### Актаныш төбәге – татар шәҗәрәләрендә

*Марсель Әхмәтҗанов*

Шәҗәрә, гади генә итеп әйткәндә, борынгы ата-бабалар белән аларның хәзерге замандагы токымнары арасындагы нәсел буыннары чылбырын тасвирлаган документ. Борынгы заманнарда ул үзара кардәшлекне раслаучы нәсел-ыру таныклыгы булып торган.

Татар халкының шәҗәрәләр тарихы озын һәм бай. Нәсел елъязмасының 20, хәтта ки 50 буынга кадәр җиткән үрнәкләре бар. Тамыры урта гасырларга тоташкан шәҗәрәләр, гадәттә, 15–17 буынны колачлый. Күпсанлы күчермәләре булган шәҗәрәләрнең кыйммәте тагын да зуррак, чөнки һәрбер кульязма текст тарихка үз яңалыгын өсти. Мисал өчен, Актаныш халкы тарихына бәйле «Кара бәк» шәҗәрәсенең 30 лап кульязма тексты бар. Мондый күпвариантлылык фактик материалның тулырак саклануын тәэмин итә.

Ата-бабаларның эзлекле чылбырын күрсәткән нәсел-ыру шәҗәрәләре, гадәттә, ирләр ягыннан гына килгән. Ислам дине буенча, ана ягыннан булган нәсел дәвамын белү дә бик мөһим. Мәрхүм ата-бабалар рухына дога кылу өчен, алардан һәрберсенең исемен җиде буынга хәтле белү тиеш дип санала. Укымышлы кешеләрдән исә шәҗәрәне тугыз буынга кадәр белү таләп ителгән. Соңгы елларда татар шәҗәрәләре язмаларына хатын-кыз ягыннан кардәшлек буыннары өстәлә башлау – бик уңай күренеш.

Әхлакый һәм рухи кыйммәтләр югала барган чорда буыннар тарихы белән кызыксыну, шәҗәрәләр төзү, ата-бабаны хөрмәтләп искә алу кебек матур йола кешеләрне кардәшлек рухында тәрбияләүнең үтемле бер чарасы булып тора. Бигрәк тә яшьләрне, балаларны нәсел тарихы белән кызыксындыру, үз шәҗәрәләрен төзергә өйрәтү бик фарыз эш. Бүгенге көндә язма шәҗәрәләр генә сакланып калган булса, элек аларның телдән-телгә тапшырылып барылуы да мәгълүм. Яңа буыннарга да бу йола ирешсен дисәк, шәҗәрәләрне, әлбәттә, язма рәвештә саклау кирәк.

Актаныш ягы – татарның борынгы шәҗәрә үрнәкләре сакланган иң бай төбәк. Без биредә татар кабиләләренең варислары – гәрәйләр, кыпчаклар белән очрашабыз.

Мәчти авылындагы нәселләрдән калган Туксаба шәҗәрәсе XI–XII гасырларда Тын (Дон) елгасы һәм Каф тавы (Кавказ) буйларында яшәгән борынгы кыпчак кавемнәре тарихы белән бәйле. Туксаба шәҗәрәсенең яңа замандагы дәвамы – Күҗәкә авылында сакланган Акъюл нәсел шәҗәрәсе чылбыры.

Нократтан чыккан Кара бәк шәҗәрәсе шулай ук бик борынгы чорларга карый. Кара бәк нәселе Алтын Урда ханнары токымына барып тоташа. Бу нәселдән булган солтаннарның кайберләре Әтнә төбәгенең Олы Мәңгәр һәм Иске Мәңгәр авылларында яшәгәннәр. Аларның бер вәкиле булган Бузнак солтан Иске Мәңгәр зиратына күмелгән. Әгерҗе якларыннан күчкән нократ морзаларының Актаныш төбәгендәге кайбер авылларга нигез салуы да билгеле.

Тасвирланган шәҗәрә үрнәкләре Актаныш төбәге халкының нәсел тамырлары бик борынгыдан килүен дәлилли. Бу кабиләләрнең аксөякләре Нугай Урдасы дәүләтендә дә мәгълүм. Әлеге төбәккә фин-угыр халыкларыннан күпмедер дәрәҗәдә мари гаиләләре катнашкан булуы мөмкин, әмма башкортлар катнашу файдасына чыганаклар күренми.

* * *

Актаныш төбәге Ак Идел һәм Чулман (Кама) елгалары кушылган җирдә урнашкан. Һәр яктан зур елгалар, күлләр, сазлыклар белән әйләндереп алынганлыктан, бу җирләргә урта

гасырларда зур гаскәри көчләр белән керү кыен булган. Шул ягы белән әлеге географик урын Идел буендагы татар кавемнәрен кызыктырган да инде.

Бу төбәктә сакланып калган язма тарихи чыганакларның иң борынгылары XIII гасырның беренче яртысына карый. Алар, асылда, шәҗәрә һәм кабер ташларыннан гыйбарәт.

Шәҗәрәләрнең иң борынгы мәгълүматлары Кара бәк һәм аның бабаларының нәсел тарихын чагылдырган кулъязмаларда күренә. Аларга караганда, XIV гасырның соңгы чирегендә ушкуйникларның һәм рус кенәзләренең туктаусыз талау һөҗүмнәре уздыруы аркасында, Болгар Олысының икътисади хәле һәм хуҗалыгы нык какшый, халкы зур югалтулар кичерә. Шуны истә тотып, 1380 елда Сарай шәһәре тәхетенә менгән Туктамыш хан Урта Иделгә 17 мең тирмә татарлар белән Габдулла ханны җибәрә.

Габдулла хан урдасы Кара диңгез буйларындагы һәм Кырымдагы татар ыру-кабиләләреннән туплана. Алар, башта Иделне кичеп, Җаек (Урал) елгасына Сакмар кушылган урында, Актүбә дигән шәһәр тирәсенә тукталалар. Актүбәдән Җаек елгасы буенча менеп, Агыйдел елгасына чыгалар һәм хәзерге Дүртөйле каласыннан ерак булмаган Өчбүлә дигән урында тирмә коралар.

Кара бәк шәҗәрәләренең утызга якын кулъязмасы мәгълүм булып, шуларның берсендә генә аны «Кырымнан килгән Габдулла хан» дип атаганнар. Әлбәттә, Габдулла Болгар Олысына хан булып түгел, фәкать олыс бәге сыйфатында җибәрелгән. Ул 1361, 1368 елларда Сарайда тәхет биләп караган була инде. Әмма көнче кардәшләре аны тәхеттән куып җибәрәләр.

Кара бәк титулы Габдулла ханга бирелгән «Төньяк бәге», ягъни «Болгар Олысының бәге» дигән дәрәҗәне аңлата. Моннан тыш, аны «олыс бәге» дип тә атаганнар. Әмма шәҗәрәләрнең күпчелегендә Габдулла ханны «Кара бәк» титулы белән теркәп куйганнар. Аның Нар бәк һәм Ишем солтан дигән туганнары булган.

Түбән Оры һәм Югары Ушма авыллары белән бәйле Кара бәк шәҗәрәсе текстларында аның атасы Канбар бәк, бабасы Калдар (Кабалдар) бәк, бабасының атасы Балым бәк, Балым

бәкнең атасы Бачман (Пачман) солтан исемнәре күрсәтелә. Аларның Идел белән Урал арасында үз җир биләмәләре булуына һәм шуларга хуҗа булып яшәүләренә ишарә бар. Канбар бәкнең биләмәсе хәзер Камбарка шәһәре урнашкан төбәк булса, Балым бәк Ык һәм Зәй елгалары буйларын биләп Бүләр шәһәрендә яшәгән. Русия хөкүмәте кәгазьләрендә Канбар бәк «царевич» дип телгә алынган. Бачман солтан Сакмар тамагындагы Актүбә өлкәсе хакиме булган. Тарихи чыганакларда Актүбә юкка гына «Бачман солтан йортыдыр» дип язылмаган.

Балым бәкне татар риваятьләрендә «Балым хуҗа», «Мәлем хуҗа» дип тә искә алалар. Аның каберенә килеп мөселманнар гына түгел, мәҗүси чувашлар, христиан руслар да корбан чала.

Сафа Гәрәй (1510–1549) ханның Балым бәк дөрбәсен төзәттерүе хакында тарихи мәгълүмат бар. Сәет Вахиди кульязмасы буенча, Яуш морза нәселеннән Каныш (Ханыш) морза да 1677–1678 елларда Балым хуҗа дөрбәсен төзәттерү һәм анда суфилар такыясе булдыру юлында йөргән. Балым бәк Зәй һәм Ык буйларын әтисе Бачман солтан исән чакта ук биләп, ике як ярларындагы җирләргә хуҗа булган. Димәк, Аксак Тимер Алтын Урда шәһәрләрен җимереп йөргән заманда Бүләрдә хан булып утыручы самат ыруыннан булган Амәт хан да Балым солтан нәселеннән чыккан.

Нократ татарларының XIII–XIV гасырларда ук Ык белән Дим елгалары ярларындагы җирләрне биләү документлары булуы мәгълүм.

Идел белән Урал арасындагы җирләр, Алтын Урда төзелгәч үк, аның түрәләренә асаба хокукы белән (ярлыклар белән беркетелеп) бирелә. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Болгар Олысы әүвәлге Болгар дәүләте биләгән җирләрнең варисы саналган һәм аның белән Җүчи ханның улы Тукай Тимер хан нәселләре идарә иткән. Димәк, татарлар монда беренче булып утырып, милек ияләре буларак, ул җирләрне документлар белән XIII йөздә үк канунлаштырганнар.

Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, бу сугышта руслар ягыннан катнашкан Нократ һәм Нугай Урдасы татарларына

ихтыяҗ калмый. Аларны, бер урыннан икенче урынга күчереп, биләгән җирләрен тартып алып, үз нигезләреннән куа башлыйлар. XVII гасырда Алат юлы һәм Иш елгасы тирәсеннән җирләр биреп, Нократ елгасы буйларында яшәгән татарларның да этник берлекләрен таркаталар. Ләкин алар бу якларның борынгыдан кендекләре береккән җирләр икәнлеген документлар белән раслый алалар.

Моның шулай икәнен, ягъни Сакмар тамагындагы җирләр югарыда искә алынган шәҗәрәдәге Бачман солтанның төп йорты булуын, Балым бәкнең инде XIII гасырда ук Ык белән Зәй елгасы буйларын башыннан ахырынача биләп, Бүләрдә хан булып торуын, Ак Идел тамагы Кара хан (бәк) йорты икәнен һ. б. ны аннан соңгы тарих бик ачык күрсәтә. Татар халкының туган җирендәге хокукын билгеләү өчен болар саллы дәлилләр!

Актаныш төбәгендәге «Йәнәйски волость»ка кергән Әҗәкүл, Аккүз, Апач, Бикчәнтәй, Уразай, Меңнәр, Адай, Байсар, Әҗмәт, Мәсәде, Гәрәй һ. б. күп кенә авылларга Нократ, Казан, Нугай Урдасыннан чыккан татарларның нигез салуы тагын да борынгырак документлар – шәҗәрәләр һәм кабер таш язулары белән раслана.

Нугай Урдасы белән бәйле Меңнәр кабиләсеннән, Бүләр шәһәрен Аксак Тимер җимергәннән соң, бер туганы – Актаныш төбәгенә, икенчесе – Чердынга (Пермь өлкәсендәге шәһәргә), өченчесе Тау ягындагы Гөбенә елгасы буена (Апас төбәгенә) күчеп киткән затларның шәҗәрәләре Актаныш төбәгендә XIII гасырдан бирле татарлар яшәгәнне күрсәтә.

Төбәкнең иң зур шәҗәрәсе булып «Гәрәй хан» шәҗәрәсе тора. Гәрәйләр нәселе Актаныш төбәгендә генә түгел, күрше Краснокама һәм Илеш төбәкләрендә дә авыллар корып утырган. Бу китапта әлеге шәҗәрәләрнең берничә төрен тәкъдим итәбез.

**Гәрәй кабиләсе шәҗәрәләре**

Татар халкының милләт буларак формалашу процессы XIV гасырда Алтын Урда дәүләте составында бара. Моның

шулай икәнлеген бүгенге Идел – Урал буе, Көнбатыш Себер, Кырым, Кавказ һәм Урта Азиянең Харәзем өлкәләрендә яшәүче халыклар арасындагы рухи-мәдәни бәйләнешләр, уртаклыклар раслый.

Татарларның этник тарихы һәм аның соңгы гасырлардагы үсеш-үзгәреше фәнни яктан әле тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән.

Батый хан җитәкчелегендәге татар кабиләләренең бүгенге татар этногенезындагы урынын объектив өйрәнми торып, без дөрес, гадел этник тарих яза алмыйбыз. Ә үткәнебезне белмәү халкыбызның милли бердәмлегенә, хәтта киләчәк язмышына куркыныч булып янарга мөмкин. Тарихның бу өлкәсендә чын галимнәрнең җитмәве әлеге бушлыкны тиешле һөнәри әзерлеге булмаган белгечләр белән тутыруга китерде. Алар исә асыл чыганакларны белмиләр, белгән очракта да, сәяси амбицияләренә, конъюнктурага яраклаштырып файдаланалар. Уфа тарихчысы, профессор Р. Г. Кузеевны, мәсәлән, соңгылары рәтенә кертергә мөмкин[1]. Бу галим урта гасырларда ничә дәүләт (Алтын Урда, Казан, Кырым, Себер, Хаҗи Тархан, Касыйм, Нугай урдасы һ. б.) төзегән татарларга ниндидер «төссез» төрки масса һәм алардан, кирәк очракта, теләсә нинди этник кавем оештырырга мөмкин булган материал итеп кенә карамакчы. Әмма фәнгә билгеле шәҗәрәләр һәм гәрәйләрнең теле, аларның таралышы кебек фактик материаллар Р. Г. Кузеевның концепциясенә һич кенә дә туры килми.

Тарихтан мәгълүм булганча, гәрәйләр XIV гасыр ахырында Кырым, Кара диңгез якларыннан Идел – Урал буйларына күченә. Аларның оешып урнашкан җирләре Татарстанның Актаныш, Сарман, Минзәлә, Башкортстанның Краснокама һәм Илеш төбәкләренә туры килә. Мәгълүм шәҗәрә текстларында шул төбәкләрдәге авыллар искә алына.

Кырым якларыннан Гәрәй кабиләсе татарларының барысы да күчмәгән, зур өлеше анда калган. Соңрак алар арасыннан Кырым ханнары күтәрелеп чыга, һәм XVIII гасыр ахырына

[1] *Кузеев Р. Г.* Происхождение башкирского народа. – М.: Наука, 1974.

кадәр Хаҗи Гәрәй, Хәйдәр Гәрәй, Дәүләт Гәрәй, Миңле Гәрәй һәм Гәрәй кабиләсеннән чыккан башка ханнар идарә итәләр[1]. Казанда 1521–1549 елларда шулай ук гәрәйләрдән булган Сахиб Гәрәй һәм Сафа Гәрәй ханнарның идарә иткәнлеге мәгълүм. Ихтимал, идарә дәверендә Агыйдел тамагындагы гәрәй-татарлар аларның төп таянычлары булганнардыр.

Гәрәйләрнең Агыйдел тамагында яшәгән бабаларына бәйле биш шәҗәрә сакланып калган. Әлеге шәҗәрәләр, гәрәйләр тарихыннан һәм ата-бабаларының исемнәр чылбырыннан тыш, нәселнең таралыш географиясе буенча да күп мәгълүмат бирәләр. Мәсәлән, шәҗәрәнең хәзерге Актаныш районы Куян авылына караган тармагында гәрәйләрнең башта Агыйделнең уң як ярында яшәгәнлекләре, соңрак сул (көньяк) ярга чыгып таралулары теркәп калдырылган. Чынлап та, Башкортстанның Краснокама төбәгендәге авыллар исемлеген карасак, аларның Актаныш төбәгендәге гәрәйләр нигезләгән авылларның исемнәре белән тәңгәл килүен күрербез (шәҗәрә текстларында Краснокама төбәгендәге Яңа Кабан, Яңа Нугай, Куян һ. б. авыл атамалары искә алына).

Актаныш төбәгендәге Әҗәкүл авылында бөтен бу як авылларындагы бабаларның нәсел башы булган *Шәгълүвәт баба* исеме күрсәтелә. Шушы авылдан дүрт баба – Солтанай, Йамакай, Йосыф, Бикбай, – аймаклар ясап, Куян авылына күчеп киләләр. Бу бабаларның исемнәре 3 нче шәҗәрәнең 13 буынын тәшкил итә. Куян авылы халкы үзләрендәге дүрт аймакның исемен хәзер дә борынгы бабалары хатирәсе итеп саклый.

Без тәкъдим иткән үрнәкләр Актаныш төбәгендә шәҗәрә төзүнең борынгы чорлардан ук килгән традициясе барлыгын күрсәтә. «Гәрәй хан» нәсел шәҗәрәсенең 1837–1973 елларда язылган биш күчермәсе Актаныш ягындагы шактый авылның халкы бер бабадан таралган нәсел икәнлеген күз алдына китерә.

Гәрәй шәҗәрәләрен туплауга һәм саклауга гомер юлы Актаныш төбәге белән бәйле драматург Риза Ишморат, Такталачык

---

[1] *Босворт К. Э.* Мусульманские династии. – М.: Наука, 1971. – С. 209–211.

авылыннан чыккан археограф Альберт Фәтхи һәм Түбән Гәрәй авылында туып үскән Тәлха Анамовлар зур өлеш керттеләр.

### *1. Гәрәйләр шәҗәрәсенең Риза Ишморат күчереп алган варианты*

Бу шәҗәрә текстын Риза ага Ишморат 1972 елның 27 ноябрендә туганы Хәйдәр Лотфулла улы Ишморатовта саклanган нөсхәдән үз кулы белән күчереп биргән иде. Язма укучылар дәфтәренең куш битенә яшел кара белән күчерелгән һәм бүгенге көндә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының мирасханәсендә 99 нчы коллекция, 1 нче тасвир, 98 нче эш берәмлеге булып саклана. Ул 1995 елны нәшер ителгән «Татар шәҗәрәләре» җыентыгында «Чабынчы шәҗәрәсе» исеме белән урын алган иде. Мирасханәгә әлеге шәҗәрәнең 1837 һәм 1930 елларда эшләнгән төп һәм күчермә текстлары кергәч, аның урта гасырларда Кырым якларыннан килгән Гәрәй кабиләсенә нисбәтле икәнлеге мәгълүм булды. Шунлыктан шәҗәрәнең исемен дә татарларның Гәрәй кабиләсе этнонимы белән билгеләдек. Риза Ишморат шәҗәрәне борынгыча итеп, агач рәвешендә, астан өскә таба бәян иткән. Китап җаена туры китерү өчен, шәҗәрә текстында буыннар тәртибе борынгыдан хәзергегә таба күрсәтелеп эшләнде.

Шәҗәрәнең төп бабасы Чабынчы исеме белән билгеләнгән. Бу исемнең асыл рәвеше Йабынчы (Җабынчы) булуын расларга җөрьәт итәбез. Йабынчы алда сүз барган Шәгълүвәт бабаның туганы дип исәпләнә. Нәселнең өченче буын бабасы булган Азан/Узан башка текстларда очрамый, ул, мөгаен, Уразак исеменнән кыскартылгандыр. Ә инде 4, 5 нче буын бабаларның исемнәре булган Ювар, Уар, бераз үзгәртелеп, 3 нче номерлы текстта Җуар, Һуар рәвешендә очрый. Боларда XIV гасырда Урта Иделдә мәгълүм булган Югра (Төньяк Урал) иле атамалары чагылмый микән, дигән сорау туа. Чөнки XIV гасырда Алтын Урда дәверендә куелган кабер ташларыннан күренгәнчә, Болгар вилаяте сәүдәгәрләренең Төньяк Уралга барып йөрүчеләре үзләренә «Йуари» тәхәллүсе (кушамат) алган булганнар.

Гәрәйләр шәҗәрәсенең Риза Ишморат күчергән тексты:

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Чабынчы | |
| | *II буын* | |
| 2. | Шәгълүвәт | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Азан-Узан | 2 |
| | *IV буын* | |
| 4. | Ювар | 3 |
| | *V буын* | |
| 5. | Уар | 4 |
| | *VI буын* | |
| 6. | Чарлак Диван | 5 |
| | *VII буын* | |
| 7. | Яхшыхуҗа | 6 |
| | *VIII буын* | |
| 8. | Тимкән | 7 |
| | *IX буын* | |
| 9. | Мумыш | 8 |
| | *X буын* | |
| 10. | Җугыначты | 9 |
| | *XI буын* | |
| 11. | Аккына | 10 |
| | *XII буын* | |
| 12. | Җантимер | 11 |
| | *XIII буын* | |
| 13. | Атнаш | 12 |
| | *XIV буын* | |
| 14. | Ает | 13 |
| | *XV буын* | |
| 15. | Ишморат | 14 |
| | *XVI буын* | |
| 16. | Хисаметдин (1781 елда туа) | 15 |
| | *XVII буын* | |
| 17. | Минһаҗетдин (1825 елда туа) | 16 |
| | *XVIII буын* | |
| 18. | Фәхретдин (1875 елда туа) | 17 |
| | *XIX буын* | |
| 19. | Ризаэтдин (1903 елда туа) | 18 |
| | *XX буын* | |
| 20. | Рафаэль (1938 елда туа) | 19 |
| | *XXI буын* | |
| 21. | Антуан (1967 елда туа) | 20 |

Искәрмә. Әлеге нәсел дәвамчылары Актаныш районының Түбән Гәрәй, Урта Гәрәй, Уразай авылларында яшиләр.

## *2. Гәрәйләр шәҗәрәсенең Гыйсмәтулла Галькәй улы төзегән нөсхәсе*

Шәҗәрә текстының 1837 елда төзелгән төп нөсхәсен Актаныш төбәгенең Түбән Гәрәй авылында туган Тәлха Анамов ерак Ташкент якларыннан табып кайтып, безнең Институт мирасханәсенә тапшырды. Соңрак ул аның йөз елга соңрак күчерелгән нөсхәсен дә китерде.

Текстлар начар сыйфатлы кәгазьгә язылганлыктан, нык таушалганнар. Аеруча мөһим булган ике кисәге бөтенләй югалган. Язу карасының уңуы текстны укуны тагын да кыенлаштыра.

Шәҗәрә гарәп графикасы нигезендә татарча эшләнгән. Аерым кисәкләре югалса да, ике нөсхәне чагыштырып уку текстны канәгатьләнерлек дәрәҗәдә күз алдына китерергә мөмкинлек бирде. Искәрмәләр Гәрәй нәселенең Актаныш төбәгендәге Югары Гәрәй, Түбән Гәрәй, Уразай, Әҗәкүл авылларына, Сарман төбәгендәге Күтәмәле, Янурыс, Башкортстанның Краснокама төбәге Яңа Кабан, Яңа Нугай һ. б. авылларга сибелгәнлеген күрсәтәләр.

Кульъязма 85,5×34 см зурлыкта. Текстлар татар теленең урта диалектына хас булганча, «җ»лаштырып һәм «ч»лаштырып язылганнар. Шәҗәрәләр Мирасханәдәге 99 нчы коллекция, 1 нче тасвир, 328 а һәм 328 б эш берәмлекләре булып сакланалар.

Шәҗәрәдә (328 а) түбәндәге искәрмә мөһим:

«Такталачык волостенда грамота алган бабаларның исемнәре: әүвәл Уразак нәселендә Күҗем Биккенә углы, икенче Бакты Ураз нәселендән Ишкенә Тимәкәй углы.

1837 нче йылда ушбу шәҗәрәләрне барча бабаларымызның исемнәрен калдырмаенча йазып – Гыйсмәтулла Галькәй углы кулым куйдым.

Түбән Гәрәй бабасы – Йакшыхуҗа, Йабынчы

Урта Гәрәй бабасы – Ко..[1], Колсары...»

Тәлха Анамов тапкан текстның бер өлеше сакланмаган. Шунлыктан аның борынгы өлешендә булырга тиешле, Риза Ишморат күчергән вариантта нәсел башын билгеләгән берничә исем күренми. Ул исемнәрнең 1837 елгы дата белән күрсәтелгән

[1] Танылмаган сүзләр, хәрефләр күп нокта белән билгеләнде.

чыганакта булуына шигебез юк, шулай да аларны биредә яңадан өстәп язып тормадык.

Тәлха Анамов тапшырган нөсхәне, гарәп язуыннан кирилл хәрефләренә күчереп, китап бите мөмкинлек биргәнчә тәкъдим итәбез.

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Төнләче | |
| | *II буын* | |
| 2. | Шәгълүвәт, Әҗәкүл бабасы | 1 |
| 3. | Байтирәк | 1 |
| | *III буын* | |
| 4. | ... | 2 |
| 5. | Мөхәммәди | 2 |
| 6. | Тимкән | 2 |
| 7. | Мерәс | 3 |
| 8. | Төкин | 3 |
| 9. | Җир(ү)че | 3 |
| 10. | Тайдун | 3 |
| | *IV буын* | |
| 11. | Уразак | 4 |
| 12. | Әҗкә | 5 |
| 13. | Кармыш | 6 |
| 14. | Мамыш | 6 |
| 15. | Туктамыш | 6 |
| 16. | Дөнәй | 8 |
| 17. | Таңатыр | 9 |
| 18. | Туйчы | 9 |
| 19. | Дусмәт | 9 |
| 20. | Җүҗәң | 10 |
| 21. | ... | 10 |
| | *V буын* | |
| 22. | Исәндәүләт | 11 |
| 23. | Күзәй | 12 |
| 24. | Ишкилде | 12 |
| 25. | Иламан | 13 |
| 26. | Биксүәр | 14 |
| 27. | Йаушик | 15 |
| 28. | Көтексә | 15 |
| 29. | Йамантай | 18 |
| 30. | Карашай | 18 |
| 31. | Теләкәй | 19 |
| 32. | Әйүб | 20 |
| 33. | Мокач | 21 |
| 34. | Котлымәт | 21 |
| | *VI буын* | |
| 35. | Төнләче | 22 |

[1] Һәр буын эчендә, аңлашыла ки, бер-берсенә кардәш (туганнан туган) булган шәхесләрнең исемнәре теркәлгән. Буыннар санынннан чыгып, аларның якынча кайсы дәвердә яшәгәнлеген ачыкларга мөмкин.

Таблицадагы беренче багана шәҗәрәгә кергән исемнәрнең тәртип санын күрсәтә. *«Ата-ана исеме тәртибе»* дигән баганадагы сан исеме аталган затның кем улы булуын аңлата. Мәсәлән: 13–15 тәртип саннары белән билгеләнгән Кармыш, Мамыш, Туктамыш – Тимкән (тәртип саны – 6) уллары; 3 нче баганада билгеләнгән санга (8) күз салсак, 16 нчы санлы Дөнәйнең Төкин улы булуы аңлашыла.

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 36. | Бикмәт | 23 |
| 37. | Кушкилде | 24 |
| 38. | Йаубүре | 25 |
| 39. | Йаукачты | 26 |
| 40. | Тиң | 27. |
| 41. | Нугай | 28 |
| 42. | Әбли | 30 |
| 43. | С...аш | 31 |
| 44. | Хөсәйен | 31 |
| 45. | Хәсән | 31 |
| 46. | Йосыф | 32 |
| 47. | Йөзәй | 32 |
| 48. | Айдар | 32 |
| 49. | Гомәр | 33 |
| 50. | Йакый | 33 |
| 51. | Мөслим | 34 |
| 52. | Мостафа | 34 |
| 53. | Салих | 34 |
| | *VII буын* | |
| 54. | Мимәт | 36 |
| 55. | Байгора | 37 |
| 56. | Сарыйм | 37 |
| 57. | Тимершәех | 37 |
| 58. | Карабай | 37 |
| 59. | Йаугилде | 37 |
| 60. | Аккына | 39 |
| 61. | Петен | 40 |
| 62. | Тукай | 41 |
| 63. | Исхак | 44 |
| 64. | Ихсан | 44 |
| 65. | Күчем | 44 |
| 66. | Сәфәр | 45 |
| 67. | Гозәйер | 45 |
| 68. | Аскар | 46 |
| 69. | Гайсә | 46 |
| 70. | Ракай | 46 |
| 71. | Касыйм | 46 |
| 72. | Габдекәй | 47 |
| 73. | Ракай | 47 |
| 74. | Акай | 47 |
| 75. | Гали | 47 |
| 76. | Батырша | 47 |
| 77. | Гаделша | 47 |
| 78. | Ибрай | 48 |
| 79. | Габдулла | 48 |
| 80. | Колшәриф | 49 |
| 81. | Әбүшахмә | 49 |
| 82. | Мөрсәлим | 51 |
| 83. | Әхмәт | 51 |
| 84. | Мөстәкыйм | 51 |
| 85. | Муса | 52 |
| 86. | Салих | 52 |
| 87. | Тимәкәй | 53 |
| 88. | Галькәй | 53 |
| | *VIII буын* | |
| 89. | Уразмәт | 54 |
| 90. | Дөмәй | 55 |
| 91. | Ырыс | 57 |
| 92. | Урсай | 58 |
| 93. | ... | 59 |
| 94. | Илчебай | 59 |
| 95. | Айдаш | 62 |
| 96. | Дәйнулла | 63 |
| 97. | Имангыл | 63 |
| 98. | Җәүһәр | 65 |
| 99. | Сәлим | 65 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| 100. | Сабанай | 68 | 131. | Миңлегыл | 113 |
| 101. | Зайсан | 69 | 132. | Кужакай | 114 |
| 102. | Сәйфулла | 70 | 133. | Назаргыл | 115 |
| 103. | Гыйбадулла | 70 | 134. | Миңлекәй | 116 |
| 104. | Мостафа | 70 | 135. | Хөсәйен | 116 |
| 105. | Габдулла | 71 | 136. | Җакырбай | 119 |
| 106. | Атнагыл | 78 | 137. | Калмыш | 120 |
| 107. | Миңлекыл | 83 | 138. | Ишкенә | 121 |
| 108. | Миңлекәй | 85 | 139. | Сармыш | 122 |
| 109. | Миңлегәрәй | 85 | 140. | Таңатыр | 123 |
| 110. | Галькәй | 86 | 141. | Тукбылат | 123 |
| 111. | Тимәкәй | 86 | 142. | Рәхмәтулла | 125 |
| | *IX буын* | | 143. | Хисмәтулла | 125 |
| 112. | Сәфәр | 89 | 144. | Һадиулла | 125 |
| 113. | Нәдер | 90 | 145. | Гыйльман | 126 |
| 114. | Чарлак | 91 | 146. | Гыймран | 126 |
| 115. | Айдагыл | 92 | 147. | Габделгазиз | 128 |
| 116. | Бурсык | 92 | 148. | Габделҗәлил | 128 |
| 117. | Пәһлуан | 92 | 149. | Йосыф | 128 |
| 118. | Касай | 92 | 150. | Йагкуб | 128 |
| 119. | Айгилде | 92 | 151. | Исламгәрәй | 129 |
| 120. | Чирү | 93 | 152. | Мәүлүкол | 129 |
| 121. | Турай | 94 | | *XI буын* | |
| 122. | Урай | 94 | 153. | Салих | 132 |
| 123. | Таңкилде | 94 | 154. | Сәйфелмөлек | 133 |
| 124. | Кормаш | 95 | 155. | Кужагыл | 133 |
| 125. | Хәсән | 102 | 156. | Җомагыл | 133 |
| 126. | Самат | 104 | 157. | Ишкилде | 133 |
| 127. | Насыйр | 104 | 158. | Карабай | 136 |
| 128. | Габденасыйр | 104 | 159. | Бик…ау | 137 |
| 129. | ...кыл | 107 | 160. | Арыслан | 138 |
| | *X буын* | | 161. | Солтанморат | 139 |
| 130. | Ырысбай | 112 | 162. | Мортаза | 140 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 163. | Колсары | 141 |
| 164. | Чарлак | 141 |
| 165. | Хаммадулла | 143 |
| 166. | Хәбибулла | 143 |
| 167. | Хәмидулла | 143 |
| 168. | ... | 151 |
| 169. | ... | 151 |
| 170. | ... | 151 |
| 171. | Хәйереланам | 152 |
| 172. | Госман | 152 |
| | *XII буын* | |
| 173. | Йахшыгыл | 156 |
| 174. | Атнагыл | 156 |
| 175. | Сийүндек | 157 |
| 176. | Сагындык | 157 |
| 177. | Таңатар | 157 |
| 178. | Шәһидулла | 158 |
| 179. | Биккыл | 159 |
| 180. | Иш...де | 160 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 181. | Туйыш | 161 |
| 182. | Мәүлекәй | 162 |
| 183. | Йанурыс | 163 |
| 184. | Биккенә | 164 |
| 185. | Йосыф | 171 |
| 186. | Мирсалих | 171 |
| 187. | Айыткыл | 174 |
| 188. | Габдеррәшит | 175 |
| 189. | Габдессәлам | 175 |
| 190. | Хәсән | 181 |
| 191. | Муллагыл | 182 |
| 192. | Ишбулды | 183 |
| 193. | Галә | 184 |
| 194. | Тәлха (1932 елда туган) | |
| | *XIV буын* | |
| 195. | Нәгыймелнасыйр | 190 |
| 196. | Мифтахетдин | 191 |
| 197. | Бикмөхәммәт | 192 |

Искәрмәләр.

1. II буын № 2 – Шәгълүвәт – Әҗәкүл һәм шәҗәрәдә искә алынган башка күрше авылларның төп бабасы.

2. VI буын № 35 – Төнләче; X буын № 130–131 – Ырысбай, Миңлегыл нәселләре – Кабан авылы бабалары.

3. XI буын № 153 – Салих; № 154 – Сәйфелмөлек нәселләре – Яңа Нугай авылы бабалары.

4. XII буын № 173 – Яхшыгыл; № 174 – Атнагыл; № 175 – Сийүндек; № 176 – Сагындык; № 177 – Таңатар; № 178 – Шәһидулла нәселләре – Бурсык авылы бабалары.

5. XII буын № 179 – Биккыл; № 180 – Иш...де; № 181 – Туйыш; № 182 – Мәүлекәй; № 183 – Йанурыс; № 184 – Биккенә нәселләре – Күтәмәле авылы бабалары.

6. V буын № 34 – Котлымәт нәселе –Түбән Гәрәй авылы бабалары.

## *3. Гәрәй кабиләсе шәҗәрәсенең Казан университеты фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә 2484Т шифры белән саклана торган нөсхәсеннән*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Җуар | |
| | *II буын* | |
| 2. | Һуар | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Чарлак Диван | 2 |
| | *IV буын* | |
| 4. | Иламан | 3 |
| | *V буын* | |
| 5. | Яхшыгуҗа | 4 |
| 6. | Шәгълүвәт | 4 |
| (Уразай, Мерәс авылы бабалары шуннан таралган) | | |
| | *VI буын* | |
| 7. | Мәхмүт | 5 |
| 8. | Әҗәк | 5 |
| 9. | Мөң | 5 |
| 10. | Уразак | 5 |
| 11. | Тимәкәй | 6 |
| | *VII буын* | |
| 12. | Күнкә | 7 |
| 13. | Бакты | 8 |
| 14. | Кармыш | 11 |
| 15. | Туктамыш | 11 |
| 16. | Мөл… | 11 |
| | *VIII буын* | |
| 17. | Бикмәт | 12 |
| 18. | Исәнҗул | 13 |
| 19. | Нугай | 14 |
| (Уразай, Мерәс авылы бабалары шуннан таралган) | | |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 20. | Йаугач | 16 |
| | *IX буын* | |
| 21. | Смак | 17 |
| 22. | Җаубүре | 18 |
| 23. | Аккына | 20 |
| | *X буын* | |
| 24. | Бийор | 22 |
| 25. | Әхмәр | 22 |
| 26. | Тамай | 22 |
| 27. | Эткол | 22 |
| 28. | Рәкәш | 22 |
| | *XI буын* | |
| 29. | Акман | 24 |
| 30. | Кинҗәкәй | 24 |
| 31. | Апча | 24 |
| 32. | Ачтай | 24 |
| 33. | Мирзай | 25 |
| 34. | Айыт | 25 |
| 35. | Атнагыл | 25 |
| 36. | Әсәй | 25 |
| 37. | Әкәш | 25 |
| 38. | Мирзагилде | 26 |
| 39. | Кангилде | 27 |
| 40. | Күгеш | 28 |
| | *XII буын* | |
| 41. | Кәшәй | 29 |
| 42. | Иман | 29 |
| 43. | Митрәй | 29 |
| 44. | Сарым | 30 |
| 45. | Ырсай | 30 |
| 46. | Йавыш | 30 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 47. | Чүчләй | 31 |
| 48. | Ирмәк | 32 |
| 49. | Шамак | 32 |
| 50. | Әли | 32 |
| 51. | Җансай | 32 |
| 52. | Чырак | 33 |
| 53. | Ырсай | 33 |
| 54. | Атан | 37 |
| 55. | Йулдаш | 37 |
| 56. | Алдагыл | 38 |
| 57. | Йосыф | 39 |
| 58. | Күгәй | 40 |
| | *XIII буын* | |
| 59. | Җамакай | 41 |
| 60. | Урман | 41 |
| 61. | Ишем | 42 |
| 62. | Хәсәнәй | 43 |
| 63. | Шәриф | 43 |
| 64. | Качман | 43 |
| 65. | Шимәрдән | 43 |
| 66. | Сийөндүк | 43 |
| 67. | Ишкилде | 43 |
| 68. | Карабаш | 43 |
| 69. | Мәмәт | 43 |
| 70. | Сөлүк | 45 |
| 71. | Айдар | 46 |
| 72. | Атабай | 46 |
| 73 | Солтанай | 47 |
| 74. | Солтангол | 47 |
| 75. | Кенәз-Ниаз | 47 |
| 76. | Ирмәш | 48 |
| 77. | Әҗем | 48 |
| 78. | Исхар | 52 |
| 79. | Бикбай | 53 |
| 80. | Морат | 55 |
| 81. | Имангол | 56 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 82. | Кадрәк | 56 |
| 83. | Ирмәш | 57 |
| 84. | Ишли | 57 |
| 85. | Тансар | 57 |
| 86. | Исхак | 58 |
| | *XIV буын* | |
| 87. | Мостай | 59 |
| 88. | Табай | 59 |
| 89. | Бә… | 59 |
| 90. | Мортаза | 59 |
| 91. | Сәлим | 61 |
| 92. | Мәсҗаб | 62 |
| 93. | Мөхәррәм | 63 |
| 94. | Макъсуд | 63 |
| 95. | Йортбай | 63 |
| 96. | Әлкәш | 64 |
| 97. | Әхмәр | 65 |
| 98. | Бигешәй | 68 |
| 99. | Тугуч | 68 |
| 100. | Гол (?) | 69 |
| 101. | Җобан | 69 |
| 102. | Этман | 69 |
| 103. | Похарай | 70 |
| 104. | Сагындык | 71 |
| 105. | Әптекәш | 72 |
| 106. | Гомәр | 73 |
| 107. | Габдекәй | 73 |
| 108. | Йәркәй | 73 |
| 109. | Карасай | 73 |
| 110. | Караман | 73 |
| 111. | Аблай (Абкай?) | 73 |
| 112. | Абтай | 73 |
| 113. | Адай | 76 |
| 114. | Хисаметдин | 76 |
| 115. | Ибрай | 77 |
| 116. | Муса | 77 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 117. | Габдессәлам | 78 |
| 118. | Биккол | 81 |
| 119. | Гайсә | 82 |
| 120. | Йулдаш | 82 |
| 121. | Мәдийар | 83 |
| 122. | Кинҗәкәй | 83 |
| 123. | Габдерәшит | 84 |
| 124. | Габдерәхим | 84 |
| 125. | Габделкәрим | 84 |
| 126. | Локман | 85 |
| 127. | Габдессадыйк | 85 |
| 128. | Хәбибула | 85 |
| | *XV буын* | |
| 129. | Әбдүш | 87 |
| 130. | Йулдаш | 87 |
| 131. | Рамай | 88 |
| 132. | Әбтәм | 88 |
| 133. | Мөнасыйб | 88 |
| 134. | Чарлак | 88 |
| 135. | Бакый | 89 |
| 136. | Йакый | 91 |
| 137. | Йагъкуб | 91 |
| 138. | Муса | 91 |
| 139. | Нәдержук | 98 |
| 140. | Сәрдүк | 98 |
| 141. | Миңлебай | 98 |
| 142. | Хәсән | 100 |
| 143. | Йараш | 100 |
| 144. | Өметбай | 100 |
| 145. | Касыйм | 101 |
| 146. | Габдулла | 105 |
| 147. | Ишкилде | 106 |
| 148. | Габдесәлам | 107 |
| 149. | Шәфи | 107 |
| 150. | Касый | 107 |
| 151. | Калмык | 107 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 152. | Камай | 107 |
| 153. | Мортаза | 107 |
| 154. | Абызай | 110 |
| 155. | Бәкер | 110 |
| 156. | Батырша | 110 |
| 157. | Тәбә | 115 |
| 158. | Этәм | 115 |
| 159. | Исхак | 116 |
| 160. | Нугай | 116 |
| 161. | Габделҗәлил | 117 |
| | *XVI буын* | |
| 162. | Искәндәр | 129 |
| 163. | Ишмөхәммәт | 129 |
| 164. | Корбан | 130 |
| 165. | Гали | 130 |
| 166. | Сәфәргали | 131 |
| 167. | Сәлимҗан | 131 |
| 168. | Шәмгун | 131 |
| 169. | Карасай | 133 |
| 170. | Габдессәлам | 134 |
| 171. | Габденнасыйр | 134 |
| 172. | Салих | 135 |
| 173. | Сәйфулла | 137 |
| 174. | Солтанбәк | 139 |
| 175. | Җәлил | 141 |
| 176. | Җәмил | 141 |
| 177. | Шәриф | 141 |
| 178. | Габделмәннан | 144 |
| 179. | Җомагыл | 145 |
| 180. | Низаметдин | 147 |
| 181. | Хисаметдин | 147 |
| 182. | Габдерәхим | 148 |
| 183. | Илийас | 149 |
| 184. | Идрис | 149 |
| 185. | Габделмәҗит | 150 |
| 186. | Габделҗаббар | 150 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 187. | Зәйет | 151 |
| 188. | Бәшир | 151 |
| 189. | Габделкәбир | 152 |
| 190. | Бикташ | 152 |
| 191. | Габделмәннан | 153 |
| 192. | Габденасыйр | 154 |
| 193. | Габделмәҗит | 154 |
| | *XVII буын* | |
| 194. | Мөхәммәтәлим | 162 |
| 195. | Йармөхәммәт | 163 |
| 196. | Мөхәммәткәрим | 163 |
| 197. | Хәбибулла | 166 |
| 198. | Мөстәкыйм | 167 |
| 199. | Имангыл | 167 |
| 200. | Мөхәммәтгали | 169 |
| 201. | Мөхәммәтша | 169 |
| 202. | Карлы | 169 |
| 203. | Әхмәтби | 169 |
| 204. | Сәмигулла | 170 |
| 205. | Мөсфулла | 170 |
| 206. | Габделгазиз | 171 |
| 207. | Әхмәтҗан | 171 |
| 208. | Җамалетдин | 171 |
| 209. | Габдессадыйк | 171 |
| 210. | Габденнафигъ | 171 |
| 211. | Исламгыл | 172 |
| 212. | Гыйсмәтулла | 173 |
| 213. | Ишкәй | 177 |
| 214. | Исәнгыл | 179 |
| 215. | Шаһимәрдан | 180 |
| 216. | Камалетдин | 180 |
| 217. | Габделҗәмил | 182 |
| 218. | Габделгаффар | 182 |
| 219. | Габделбәшар | 185 |
| 220. | Габделҗаббар | 185 |
| 221. | Әхмәтгали | 186 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 222. | Габденнасыйр | 189 |
| 223. | Сираҗетдин | 190 |
| 224. | Шәмсетдин | 190 |
| 225. | Нәҗметдин | 190 |
| 226. | Сәгъдулла | 190 |
| 227. | Габделгазиз | 191 |
| 228. | Мөхәммәтрәхим | 192 |
| 229. | Гыймадетдин | 192 |
| | *XVIII буын* | |
| 230. | Сираҗетдин | 194 |
| 231. | Шәмсетдин | 194 |
| 232. | Мөгътәсим | 196 |
| 233. | Әхмәталла | 197 |
| 234. | Мостай | 198 |
| 235. | Мостаҗәп | 199 |
| 236. | Габдессалих | 211 |
| 237. | Габделкадыйр | 211 |
| 238. | Гыйбадулла | 212 |
| 239. | Хәбибулла | 212 |
| 240. | Әскот | 213 |
| 241. | Искәндәр | 214 |
| 242. | Хөснетдин | 215 |
| 243. | Габделхәким | 217 |
| 244. | Габделхәлим | 217 |
| 245. | Әхмәтхафиз | 218 |
| 246. | Сәрдар-Ислам | 218 |
| 247. | Шәмселгарафас | 219 |
| 248. | Хафизелсәйен | 219 |
| 249. | Фикъһә | 219 |
| 250. | Вәладегаләм | 219 |
| 251. | Шаһгали | 221 |
| 252. | Шаһсолтан | 221 |
| 253. | Шаһвәли | 221 |
| 254. | Мөхәммәтзәки | 221 |
| 255. | Җамалетдин | 222 |
| 256. | Сәйедгәрәй | 223 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 257. | Абызгәрәй | 223 |
| 258. | Әкмалетдин | 224 |
| 259. | Хәбетдин | 225 |
| 260. | Минһаҗетдин | 225 |
| 261. | Зыятдин | 225 |
| 262. | Ногман | 227 |
| 263. | Әхмәтвәли | 228 |
| 264. | Мөхәммәтша | 228 |
| 265. | Сәлахетдин | 229 |
| | *XIX буын* | |
| 266. | Хөснетдин | 230 |
| 267. | Фәсхетдин | 231 |
| 268. | Шәмсетдин | 232 |
| 269. | Шәйхетдин | 232 |
| 270. | Нигъмәтулла | 232 |
| 271. | Ибраһим | 234 |
| 272. | Хөснетдин | 235 |
| 273. | Габделмәннан | 236 |
| 274. | Габделбәкер | 237 |
| 275. | Әхмәтвәли | 243 |
| 276. | Яхъя | 244 |
| 277. | Кәшиф | 244 |
| 278. | Мәрдигариф | 247 |
| 279. | Әлмөхәммәтраки | 247 |
| 280. | Кәшфеләсрар | 247 |
| 281. | Габделбари | 247 |
| 282. | Нурылзаһидин | 248 |
| 283. | Шакирҗан | 248 |
| 284. | Гарифҗан | 248 |
| 285. | Хәбибрахман | 248 |
| 286. | Нурылгайан | 249 |
| 287. | Галимелбәйан | 249 |
| 288. | Мәрдәшәриф | 250 |
| 289. | Борһанетдин | 255 |
| 290. | Хәбибрахман | 263 |
| 291. | Мөхәммәтсадыйк | 264 |
| 292. | Әхмәтзариф | 264 |
| 293. | Исрафил | 264 |
| 294. | Госман | 264 |
| 295. | Әхмәтхаҗи | 264 |
| 296. | Мөхәммәтхаҗи | 264 |
| 297. | Фазлыйәхмәт | 264 |
| | *XX буын* | |
| 298. | Закирҗан | 278 |
| 299. | Шәрифҗан | 278 |
| 300. | Хәниф | 278 |
| 301. | Габдулла | 278 |
| 302. | Мулланур | 278 |
| 303. | Хатиб | 279 |
| 304. | Габдулла | 279 |
| 305. | Габделбари | 282 |
| 306. | Әхмәтфатих | 283 |
| 307. | Әхмәтгариф | 283 |
| 308. | Габдерахман | 290 |
| 309. | Минлегали | 290 |
| 310. | Лотфулла | 290 |
| 311. | Габдулла | 290 |
| 312. | Габидулла | 290 |
| 313. | Мөхәммәтфатих | 290 |
| | *XXI буын* | |
| 314. | Галибәк | 308 |
| 315. | Хөсәйенбәк | 308 |
| 316. | Мидхәт | 309 |

Искәрмә. Бу нәсел Актаныш төбәгенең Уразай, Мерәс, Илчебай, Әҗәкүл, Куян һәм башка авылларының бабаларын тәшкил итә.

## *4. Гәрәйләр шәҗәрәсенең Казан университеты фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә 2486Т шифры белән саклана торган нөсхәсеннән (Куян авылы тармагы)*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Солтанай | |
| | *II буын* | |
| 2. | …баба | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Габдекәй | 2 |
| | *IV буын* | |
| 4. | Касай | 3 |
| 5. | Мортаза | 3 |
| 6. | Камай | 3 |
| | *V буын* | |
| 7. | Габделмәҗит | 4 |
| 8. | Габделмән мулла | 5 |
| 9. | Габделхәбир | 6 |
| | *VI буын* | |
| 10. | Габделбәшар | 7 |
| 11. | Габделҗаббар | 7 |
| 12. | Әхмәтхаҗи | 8 |
| 13. | Газиз | 8 |
| 14. | Карман | 8 |
| 15. | Мөхәммәт хаҗи | 8 |
| 16. | Бикташ | 9 |
| | *VII буын* | |
| 17. | Ислам мулла | 10 |
| 18. | Фәкиһ | 10 |
| 19. | Хафизелислам, азанчы | 10 |
| 20. | Шәмселгарифьян | 10 |
| 21. | Әхмәтгали | 11 |
| 22. | Мәмәдйар мулла | 11 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 23. | Тимершәех | 12 |
| 24. | Мөхәммәт | 12 |
| 25. | Ногман | 13 |
| 26. | Абзал | 14 |
| 27. | Мәҗит | 14 |
| 28. | Фазлыйәхмәт | 15 |
| 29. | Шәмсетдин | 16 |
| 30. | Гыйлаҗетдин | 16 |
| 31. | Нәҗметдин | 16 |
| | *VIII буын* | |
| 32. | ... | 17 |
| 33. | Нурылгаян | 18 |
| 34. | Хәбибрахман мулла | 19 |
| 35. | Шакирйан | 19 |
| 36. | Нурзаһидин | 19 |
| 37. | Әхмәтзәки | 20 |
| 38. | Мирзагариф | 20 |
| 39. | ... | 21 |
| 40. | Шаһвәли | 21 |
| 41. | Шаһгали | 21 |
| 42. | Бикчәнтәй | 22 |
| 43. | Мөхәррәм | 24 |
| 44. | Габденнасыйр | 26 |
| 45. | Гыймадетдин | 26 |
| 46. | Мөхәммәтгәрәй | 28 |
| 47. | Вәлкәй | 28 |
| 48. | Әкмал | 29 |
| 49. | Миңлехаҗи | 30 |
| 50. | Әхйар | 31 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| | *IX буын* | | 70. | Нургали | 49 |
| 51. | Гадел | 31 | 71. | Йамалетдин | 51 |
| 52. | Закирйан | 33 | | *X буын* | |
| 53. | Галимйан | 33 | 72. | Флүс | 57 |
| 54. | Газизйан | 35 | 73. | Әхмәтвәли | 64 |
| 55. | Әмин | 35 | 74. | Әхмәтнәби | 64 |
| 56. | Таһир | 35 | | *XI буын* | |
| 57. | Гариф | 35 | 75. | Хәбибрахман | 73 |
| 58. | Фатих | 36 | 76. | Исрафил | 74 |
| 59. | Бари | 36 | 77. | Садыйк | 74 |
| 60. | Хәниф | 38 | | *XII буын* | |
| 61. | Мулланур | 38 | 78. | Гобәйдулла | 75 |
| 62. | Мәбри | 40 | 79. | Габдерахман | 75 |
| 63. | Оркыя | 41 | 80. | Миңнегали | 75 |
| 64. | Мөхәммәтрәхим | 44 | 81. | Миркасыйм | 76 |
| 65. | Әгъламетдин | 45 | 82. | Мансур | 77 |
| 66. | Миңлегәрәй | 46 | | *XIII буын* | |
| 67. | Әкрәм | 48 | 83. | Муллаәхмәт | 80 |
| 68. | Зәкия | 48 | | *XIV буын* | |
| 69. | Муллагали | 49 | 84. | Васыйл | 81 |

Искәрмә.

Шәҗәрә кульъязмасына түбәндәге искәрмәләр өстәлгән:

«Безнең адрес

1917 нче елга кадәр патша хөкүмәте вакытында Уфа губернасы, Минзәлә өязе, Такталачык волосте, Куян авылы Гәрәй халкы булып йөргәннәр. Безнең карт бабаларыбыз Башкортстандан Ак Иделнең көн ягына күчеп чыкканнар».

«Куян авылына Әҗәкүлдән 4 аймак һәм нәсел күчеп килгән: I – Йосыф аймагы. Болар түбән урамнарга, хәзерге магазин якларына, һәм II аймак – Йамакай аймагы. Болар Илчебай очына күчеп килгәннәр. III нче Бикбай аймагы булыр, мәктәпнең көнчыгыш ягында булганнар. IV нчесе Солтанай аймагы Әтмәч очында ... урыннарда булганнар».

## *5. Гәрәйләр кабиләсеннән Түбән Гәрәй бабасы Йахшыгуҗа, Йабынчы һәм Урта Гәрәй бабасы Колсары шәҗәрәсе*

Шәҗәрә тексты 105х70 см кәгазьгә шәмәхә кара белән гарәп графикасында язылып, бөкләнгән җирләреннән 8 кисәккә өзгәләнгән, 25х35 см зурлыктагы баш өлеше югалган. Кәгазьнең сыйфаты бик начар, язмалар төсен югалткан. Бөкләнгән урыннарның теткәләнүе һәм язмаларның уңуы укуны нык кыенлаштыра. Шәҗәрәне Тәлха Анамов Ташкент ягыннан табып кайтып, 1998 елда Мирасханәгә тапшырды. Кулъязма фрагментлары 99 нчы коллекция, 1 нче тасвирда 328 б эш берәмлеге булып саклана.

Шәҗәрәнең татар этник тарихы өчен автохтон (беренчел, тамыр) тарихи язма чыганак булуын искә алып, аның дефектлы текстының укылышын басмага тәкъдим итәргә булдык.

Текст өчкә бүленеп, хәрефкә-хәреф күчерелде. Баштагы беренче һәм икенче өлешләр шактый тулы зур кисәкләр булып, шәҗәрәнең борынгы дәверенә карыйлар. Бер үк нәселгә кагылсалар да, үзара бәйләүче чылбыр булмаганлыктан, аларның һәрберсе мөстәкыйль шәҗәрә итеп теркәлде.

Өченче кисәк соңгырак буыннарны күрсәтә, урыны-урыны белән ул өзелгән чылбырның аерым исемнәре-буыннары хәленә килгән. Аларның соңгы, ягъни яңа дәвергә кагылышлы икәнен гарәп-фарсы теленнән кергән алынмалардан ясалу калыплары күрсәтеп тора.

Бу текстта барлыгы 446 кеше исемен укып булды. Шәҗәрә, Түбән Гәрәй, Урта Гәрәй авылларыннан тыш, хәзерге Башкортстанның Краснокама районына караган Яңа Нугай һәм Яңа Кабан авыллары бабаларын да тарихта саклаган. Искә алынган Яңа Кабанның Татарстандагы Лаеш төбәге Кабан авылы белән кардәшлеге археограф С. Вахиди тарафыннан ачыкланган[1].

Инде Гәрәй шәҗәрәсенең Түбән Гәрәй кулъязмасындагы текст фрагментлары белән танышыйк.

---

[1] *Әхмәтҗанов М. И.* Мәдәни мирасыбыз сакчысы // Татарстан. – 1997. – № 5. – Б. 39.

## *Беренче фрагмент*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | ... | |
| | *II буын* | |
| 2. | Сийөндек | ? |
| 3. | Йахшыгуҗа | ? |
| 4. | …мөхәммәт | ? |
| | *III буын* | |
| 5. | Мәхмүт | 3 |
| 6. | Бактуры | 4 |
| | *IV буын* | |
| 7. | Җәнбәк | 5 |
| 8. | Мәмәт | 6 |
| 9. | Тимкән | 6 |
| 10. | Кәсебал | 6 |
| | *V буын* | |
| 11. | Җәнҗегет | 7 |
| 12. | Әлмәкән | 8 |
| 13. | Истәк | 9 |
| 14. | Сүрмәт | 10 |
| 15. | …ислам | 10 |
| | *VI буын* | |
| 16. | Ашбакты | 11 |
| 17. | Бичура | 11 |
| 18. | Әлбан | 12 |
| 19. | Икбәт | 13 |
| 20. | Йәшмәт | 13 |
| 21. | Айбар | 14 |
| 22. | Кинҗәгыл | 14 |
| 23. | Котый | 14 |
| 24. | …рда | 15 |
| | *VII буын* | |
| 25. | Айтуган | 17 |
| 26. | Габдулла | 18 |
| 27. | Габделваһаб | 19 |
| 28. | Гомәр | 20 |
| 29. | Йанурыс | 24 |
| 30. | Биккенә | 24 |
| | *VIII буын* | |
| 31. | Итемирас | 26 |
| 32. | Гаделвахит | 27 |
| 33. | Салих | 28 |
| 34. | Исәнбай | 29 |
| 35. | Искәндәр | 29 |
| 36. | Мотый | 29 |
| 37. | Сөлек | 29 |
| 38. | Сафур | 29 |
| 39. | Сарман | 29 |
| 40. | Тимкән | 29 |
| 41. | Иштүк | 30 |
| 42. | ... | 30 |
| | *IX буын* | |
| 43. | Исламгыл | 31 |
| 44. | Килди | 33 |
| 45. | Хөсәйен | 34 |
| 46. | Мортаза | 35 |
| 47. | Таһир | 35 |
| 48. | Төхфәт | 35 |
| 49. | Миртимер | 36 |
| 50. | Атнагыл | 36 |
| 51. | Харрас | 37 |
| 52. | Миңкафил | 37 |
| 53. | Миңнекәй | 37 |
| 54. | Йулдаш | 38 |
| 55. | Йөзүкәй | 39 |
| 56. | Төнләче | 39 |
| 57. | Байдийар | 39 |
| 58. | Уразбай | 39 |
| 59. | Госман | 39 |
| 60. | Илдәш | 39 |
| 61. | Биккенә | 40 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 62. | Айтуган | 40 |
| 63. | Атнагыл | 41 |
| 64. | Мансур | 41 |
| 65. | Касыйм | 41 |
| 66. | Кулынбирде | 41 |
| 67. | Кушанай | 41 |
| 68. | Касыйм | 41 |
| | *X буын* | |
| 69. | Габделкәрим | 45 |
| 70. | Габдеррәшит | 45 |
| 71. | Габит | 45 |
| 72. | Сәгыйть | 45 |
| 73. | Туйак | 45 |
| 74. | Әбеди | 49 |
| 75. | Габдерәшит | 50 |
| 76. | Зәйнелгабидин | 50 |
| 77. | Сәфәр | 50 |
| 78. | Әхмәр | 54 |
| 79. | Гомәр | 54 |
| 80. | Күчем | 54 |
| 81. | Гаделша | 54 |
| 82. | Миңнекәй | 54 |
| 83. | Айтуган | 54 |
| 84. | Бикташ | 55 |
| 85. | Миңтимер | 55 |
| 86. | Шакмай | 59 |
| 87. | Шакмәт | 59 |
| 88. | Шаукай | 59 |
| 89. | Сибеләй | 59 |
| 90. | Гоффан | 59 |
| 91. | Йагкуб | 61 |
| 92. | Йөзекәй | 61 |
| 93. | Сыртлан | 62 |
| 94. | Хисаметдин | 62 |
| 95. | Сәфәргали | 63 |
| 96. | Гәрәй | 63 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 97. | Биктимер | 63 |
| 98. | Зөлфокар | 64 |
| 99. | Корбангали | 64 |
| 100. | Сәфәргали | 64 |
| 101. | Казак | 68 |
| | *XI буын* | |
| 102. | Динмөхәммәт | 74 |
| 103. | Нурмөхәммәт | 74 |
| 104. | Әхмәт | 74 |
| 105. | Мөхәммәткәли | 77 |
| 106. | Мәнди | 78 |
| 107. | Йакый | 78 |
| 108. | Габделлатиф | 79 |
| 109. | Тимершәех | 82 |
| 110. | Миңтимер | 82 |
| 111. | Әсәдулла | 84 |
| 112. | Галиулла | 84 |
| 113. | Бакый | 86 |
| 114. | Габдерәшит | 87 |
| 115. | Сәгыйть | 88 |
| 116. | Бакыш | 88 |
| 117. | Гали | 88 |
| 118. | Кинәш | 89 |
| 119. | Ибрай | 101 |
| | *XII буын* | |
| 120. | Габдекәй | 107 |
| 121. | Габдулла | 107 |
| 122. | Гобәйдулла | 107 |
| 123. | Мөсифулла | 109 |
| 124. | Әмирзаһид | 109 |
| 125. | Шәрәфеләнвәр | 111 |
| 126. | Миңлегали | 112 |
| 127. | Шәйхелислам | 115 |
| 128. | Шәмсетдин | 115 |
| 129. | Габделмәннан | 119 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *XIII буын* | |
| 130. | Игүмәрдән мулла | 121 |
| 131. | Габид кантун | 121 |
| 132. | Мирзашәрәф | 125 |
| 133. | Әхмәтшәриф | 125 |
| 134. | Фәхрелислам | 127 |
| 135. | Габдулла | 127 |
| 136. | Фәхразый | 128 |
| | *XIV буын* | |
| 137. | Габделмәннан | 130 |
| 138. | Шаһийаздан | 130 |
| 139. | Мулла Әхмәт | 131 |
| 140. | Мулла Мөхәммәт | 131 |
| 141. | Шәймәрдән | 136 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *XV буын* | |
| 142. | Әсәдулла | 137 |
| 143. | Габделвәһаб | 137 |
| 144. | Габделшәкүр | 138 |
| 145. | Габделхай | 138 |
| | *XVI буын* | |
| 146. | Фазулла | 142 |
| 147. | Гобәйдулла | 142 |
| 148. | Муллаҗан | 144 |
| 149. | Габделхак | 144 |
| | *XVII буын* | |
| 150. | Шәйхелислам | 146 |
| 151. | Дәүләтулла | 146 |

*Ертылган бит почмагындагы исемнәр:*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *... буын*[1] | |
| 1. | Котлыбай | ? |
| 2. | Биккенә | ? |
| 3. | Хөсәйен | ? |
| | *... буын* | |
| 4. | Шәүкәт | 1 |
| 5. | Әмин | 1 |
| 6. | Гаделша | 3 |
| 7. | Ишкилде | 3 |

[1] Буыннар бәйләнешен билгеләп булмый.

## *Икенче фрагмент*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Төнләче | |
| | *II буын* | |
| 2. | Шәгълүвәт | 1 |
| 3. | Байтирәк | 1 |
| | *III буын* | |
| 4. | Бай | 2 |
| 5. | Мөхәммәди | 2 |
| 6. | ... | 2 |
| 7. | Төкем | 3 |
| 8. | Чирүче | 3 |
| 9. | Тайдым | 3 |
| | *IV буын* | |
| 10. | Йуныс | 4 |
| 11. | Әҗкә | 5 |
| 12. | Ырысбай | 6 |
| 13. | Сәфәр | 6 |
| 14. | Уразак | 6 |
| (Ырысбай, Сәфәр, Уразак – Яңа Кабан бабалары) | | |
| 15. | Ырысбай | 6 |
| 16. | Мәҗит | 6 |
| 17. | Бикмөхәммәт | 6 |
| 18. | Кадермәт | 7 |
| 19. | Дуванай | 7 |
| 20. | Дусмак | 8 |
| 21. | Туйчы | 8 |
| 22. | Таңатар | 8 |
| 23. | ... | 9 |
| | *V буын* | |
| 24. | Хәсән | 10 |
| 25. | Күзәй | 11 |
| 26. | Ишкилде | 11 |
| 27. | Исәндәүләт | 14 |
| 28. | Зәбир | 18 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 29. | Мокай | 19 |
| 30. | Айдагыл | 19 |
| 31. | Калакан | 20 |
| 32. | Карашай | 21 |
| 33. | Йамантай | 21 |
| 34. | Җүбәң | 23 |
| 35. | Мифтах | 23 |
| | *VI буын* | |
| 36. | Кушкилде | 26 |
| 37. | Салман | 31 |
| 38. | Хәсән | 31 |
| 39. | Хөсәйен | 31 |
| 40. | Әбләй | 32 |
| 41. | Йосыф | 34 |
| 42. | Әйүб | 34 |
| 43. | Йакый | 35 |
| 44. | Гомәр | 35 |
| 45. | Котлымәт | 35 |
| 46. | Мөсәллим | 35 |
| 47. | Сәлим | 35 |
| 48. | Әхмәт | 35 |
| 49. | Сийөндек | 35 |
| | *VII буын* | |
| 50. | Байгора | 36 |
| 51. | Гозәйер | 38 |
| 52. | Сәфәр | 38 |
| 53. | Күчем | 39 |
| 54. | Ихсан | 39 |
| 55. | Исхак | 39 |
| 56. | Макъсуд | 40 |
| 57. | Илийас | 40 |
| 58. | Шәриф | 40 |
| 59. | Айдар | 40 |
| 60. | Аксарай | 41 |
| 61. | Йисәр | 41 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 62. | Казый | 41 |
| 63. | Касыйм | 41 |
| 64. | Йөзекәй | 42 |
| 65. | Айдар | 42 |
| 66. | Йосыф | 42 |
| 67. | ... | 44 |
| 68. | Колшәриф | 44 |
| 69. | Сәлим | 45 |
| 70. | Мостафа | 45 |
| 71. | Муса | 45 |
| 72. | Хәлим... | 45 |
| 73 | Миңнекәй | 47 |
| 74. | Гыйбадулла | 47 |
| 75. | Гата | 47 |
| 76. | Әбүбәкер | 47 |
| 77. | Миңлекол | 48 |
| 78. | Аси... | 35 |
| 79. | Йахшымәт | 35 |
| 80. | Иңкел | 48 |
| 81. | Йалбан | 48 |
| 82. | Афзал | 49 |
| | *VIII буын* | |
| 83. | Дөмәй | 50 |
| 84. | Җәүһәр | 53 |
| 85. | Сәлим | 53 |
| 86. | Имангыл | 55 |
| 87. | Сабалай | 60 |
| 88. | Зайсан | 61 |
| 89. | Сәйфулла | 62 |
| 90. | Гыйбадулла | 62 |
| 91. | Мөсифулла | 62 |
| 92. | Габдулла | 63 |
| 93. | Лакан | 64 |
| 94. | Габдекәй | 64 |
| 95. | Аккына | 64 |
| 96. | Гали | 64 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 97. | Батырша | 64 |
| 98. | Гаделша | 64 |
| 99. | Кадергыл | 65 |
| 100. | Габдулла | 65 |
| 101. | Ибрай | 65 |
| 102. | Гайсә | 70 |
| 103. | Габбас | 70 |
| 104. | Исламгәрәй | 77 |
| 105. | ... | 77 |
| 106. | Мөәм... | 78 |
| 107. | Котлыкадәм | 82 |
| 108. | Икай | 82 |
| | *IX буын* | |
| 109. | Нәдер | 83 |
| 110. | Зәйнулла | 86 |
| 111. | Хәсән | 88 |
| 112. | Идиятулла | 90 |
| 113. | Гатаулла | 90 |
| 114. | Сәмигулла | 90 |
| 115. | Сибгатулла | 90 |
| 116. | Локман | 91 |
| 117. | Габденнасыйр | 91 |
| 118. | Гыймран | 92 |
| 119. | Таҗетдин | 92 |
| 120. | Имангыл | 99 |
| 121. | Амангыл | 101 |
| 122. | Шәйхелсама . . . | 104 |
| 123. | Әхмәтхуҗа | 104 |
| 124. | Мәүлүкол | 105 |
| 125. | Әхмәтша | 107 |
| | *X буын* | |
| 126. | Миңлекол | 109 |
| 127. | Рәхмәтулла | 111 |
| 128. | Мулламөхәммәт | 112 |
| 129. | Әхмәдулла | 113 |
| 130. | Фәтхулла | 113 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| 131. | Гыйльман | 116 | 149. | Закир | 134 |
| 132. | Гыймран | 116 | 150. | Әбүбәкер | 134 |
| 133. | Хәйереланам | 124 | | *XII буын* | |
| 134. | Госман | 124 | 151. | Хамматулла | 136 |
| 135. | Миңнехан | 125 | 152. | Мөхәм | 139 |
| | *XI буын* | | 153. | Лотфырахман | 140 |
| 136. | Хисмәтулла | 127 | 154. | Фазлыйәхмәт | 140 |
| 137. | Мөсәннаф | 128 | 155. | Мөхәммәткасыйм | 140 |
| 138. | Вильдан | 131 | | *XIII буын* | |
| 139. | Локман хәким | 131 | 156. | Хәбибулла | 151 |
| 140. | Хөббихуҗа | 132 | 157. | Хәләф | 155 |
| 141. | Гафиятулла | 132 | 158. | Фелүс | 155 |
| 142. | Гобәй | 132 | | *XIV буын* | |
| 143. | Вахит | 132 | 159. | Фәррахетдин | 156 |
| 144. | .... лы | 132 | | *XV буын* | |
| 145. | Йосыф | 133 | 160. | Хисаметдин | 159 |
| 146. | Мирсалих | 133 | 161. | Гыйлаҗетдин | 159 |
| 147. | Мирзаһит | 133 | | *XVI буын* | |
| 148. | Мөхәммәтгазый | 134 | 162. | Әхмәт | 161 |

*Тагын бер тармак*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| | *I буын* | | | *V буын* | |
| 1. | Шайгъ... | | 5. | Кужакай | 4 |
| | *II буын* | | | *VI буын* | |
| 2. | Урман | 1 | 6. | Салих | 5 |
| | *III буын* | | | *VII буын* | |
| 3. | Шәхмәт | 2 | 7. | Сәйфелмөлек (Яңа Нугай авылы бабалары) | 6 |
| | *IV буын* | | | | |
| 4. | Чарлак | 3 | | | |

## *Өченче фрагмент*

Әлеге текст шәҗәрәнең соңгы буыннарына карый. Алар төп бабага эзлекле рәвештә бәйләнми. Ләкин шунысы хак: бу затларның барысы да бер нәселгә барып тоташа. Монда буыннарга бүленеш тә шартлы рәвештә генә алып барыла.

Өченче фрагмент үзе аерым кисәкләргә бүлгәләнгән.

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | ***1 нче кисәк*** | |
| | *I буын* | |
| 1. | Шәйхи | |
| 2. | Хөснегәрәй | |
| | *II буын* | |
| 3. | Гали... | |
| 4. | Хөснемәрдән | |
| 5. | Шаһимәрдән | 2 |
| 6. | Галимәрдән | |
| 7. | Х...мәрдән | |
| 8. | Гафиятулла | Бер ата балалары (6–11) |
| 9. | Вәлиулла | |
| 10. | Морда | |
| 11. | Шаһиәхмәт | |
| | *III буын* | |
| 12. | Мидехәт | 4 |
| 13. | Ырысмәт | 6 |
| 14. | Шаһимәрдан | 6 |
| 15. | Зарифулла | 8 |
| 16. | Гарифулла | 8 |
| 17. | Сафиулла | 9 |
| 18. | Шәрифулла | 9 |
| 19. | Нурлыгайан | 9 |
| 20. | Минлегайан | 9 |
| 21. | Әмирҗан | 11 |
| 22. | Галимҗан | 11 |
| 23. | Әмирхан | 11 |
| 24. | Гыйлемҗан | 11 |
| 25. | Мәгъфүрҗан | 11 |
| 26. | Сафийан | 11 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 27. | Әдһәм | 11 |
| 28. | Мөйәссәр | 11 |
| 29. | Хәсәнҗан | 11 |
| | *IV буын* | |
| 30. | ... | 13 |
| 31. | Әдһәм | 13 |
| 32. | Фәндәс | 13 |
| 33. | Тимершәйех | 13 |
| 34. | Фәнис | 14 |
| 35. | Катиб | 14 |
| 36. | Заретдин | 15 |
| 37. | Әбүзәр | 16 |
| 38. | Харрас | 16 |
| 39. | ... | 16 |
| | ***2 нче кисәк*** | |
| | *I буын* | |
| 1. | Наил | |
| 2. | Зөфәр | |
| 3. | Макъсуд | |
| 4. | Эрифат | |
| 5. | Ширийаздан | |
| 6. | Хәйрелмәрдән | |
| 7. | Миргалим | |
| 8. | Сәлимгәрәй | |
| 9. | Хәтмулла | |
| 10. | Бәхтигәрәй | |
| 11. | Мөхәммәтшәйех | |
| | *II буын* | |
| 12. | Шәйхелислам | |
| 13. | Сәлим | |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 14. | Хуҗа | |
| 15. | Гаптерахман | |
| 16. | Абызгәрәй | 8 |
| 17. | Мөхәммәтсәлим | 8 |
| 18. | Мөхәммәтнәкый | 11 |
| | ***3 нче кисәк*** | |
| 19. | Рәхмәтулла | |
| 20. | Хамматулла | |
| | *I буын* | |
| 21. | Ширийаздан | |
| 22. | Хәйерлемәрдән | |
| 23. | Миргалим | |
| 24. | Сәлимгәрәй | |
| 25. | Рәхмәтулла | |
| 26. | Бәхетгәрәй | |
| 27. | Мөхәммәтшәфыйг | |
| | *II буын* | |
| 28. | Әбүбәкер | 21 |
| 29. | Миңтимер | 22 |
| 30. | Мөбәрәкша | 22 |
| 31. | Мөхәммәтсәлим | 24 |
| 32. | Абызгәрәй | 24 |
| 33. | Әмир | 24 |
| 34. | Шәриф | 24 |
| 35. | Мөхәммәтнәкый | 27 |
| | *III буын* | |
| 36. | Сөләйман | 29 |
| 37. | Мансур | 29 |
| 38. | Сәйетмөхәммәт | 30 |
| 39. | Мөхәммәттакый | 30 |
| | ***4 нче кисәк*** | |
| | *I буын* | |
| 40. | ... | |
| | *II буын* | |
| 41. | Хисмәтулла | 40 |
| 42. | Хамматулла | 40 |
| | *III буын* | |
| 43. | Фазулла | 41 |
| 44. | Гыйззәтулла | 42 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 45. | Ибәтулла | 42 |
| 46. | Гобәйдулла | |
| 47. | Миңнехан | |
| 48. | Корбангали | |
| 49. | Шәрифулла | |
| | *IV буын* | |
| 50. | Хуҗа | 43 |
| 51. | Исламхуҗа | 43 |
| 52. | Зөбәйер | 43 |
| 53. | Шәйхелислам | 43 |
| 54. | Ихсан | 43 |
| 55. | Мөхәммәтхуҗа | 43 |
| 56. | Исламхуҗа | 43 |
| 57. | … ислам | 43 |
| 58. | Гыйниятулла | 44 |
| 59. | Гайнелсәлим | 44 |
| 60. | Нурулла | 45 |
| 61. | Хөснулла | 45 |
| 62. | Фәйзулла | 46 |
| 63. | Сәйфулла | 46 |
| 64. | Нурлыгайан | 47 |
| 65. | Нургани | 48 |
| 66. | Хәбибелнаҗар | 48 |
| 67. | Хәбибелфаҗар | 48 |
| | *V буын* | |
| 68. | Габделхак | 53 |
| 69. | Мөхәммәтзакир | 54 |
| 70. | Миргалим | 58 |
| 71. | Әхмәтсәлим | 62 |
| 72. | Гыйльмегалийан | 62 |
| 73. | Зөлфенун | 62 |
| 74. | Гай… | 62 |
| 75. | Миргалим | 65 |
| 76. | Мирфәйез | 65 |
| 77. | Әдһәм | 66 |
| 78. | Хуҗагали | 43 |
| 79. | Миркасыйм | |
| 80. | Мулланур | |

**Бүләр (Бараж) шәҗәрәсе**

Әлеге шәҗәрәне 1964 елда Иске Сәфәр авылында яшәүче Мирзашәриф Шаһингәрәй улы Гардановта (1885–196?) сакланган тексттан Уфадан килгән фольклорчы Фәнүзә Надыршина күчереп алган. Фәнүзә Надыршина аны, башкорт теленә яраклаштырып, 2000 елда «Агыйдел» журналының 7 нче санында бастырып чыгарган иде. Текстның татарча варианты 2009 елда дөнья күргән «Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы» китабында урын алды[1].

2004 елда шул ук шәҗәрә текстының Әлмәттә саклануы мәгълүм булды, һәм без әлеге тарихи язмаларның икесен бергә янәшә куеп карый алдык.

Ике текст белән дә танышкач, түбәндәгеләр мәгълүм булды:

Иске Сәфәр авылындагы шәҗәрә 1925 елның 5 апрелендә язылып төгәлләнгән. Ул Ризаэддин бине Фәхреддиннең 1925 елда барча имамнарга һәм әүвәлге укымышлыларга мәхәллә тарихларын һәм шәҗәрәләрне язып мөфтияткә җибәрү хакындагы мөрәҗәгатенә җавап рәвешендә эшләнгән булса кирәк.

Шәҗәрә ияләрендә истәлекнең өч күчермәсе сакланган булып чыкты. Аларның икесе – 1924, 1964 елларда күчерелгәннәре – гарәп графикасында (беренче тапкыр 1924 елның 5 апрелендә, икенче тапкыр 1964 елның 8 ноябрендә күчерелеп бетә). Өченче текст 1964 елдан соң (1965 елда булса кирәк) рус графикасына күчерелә һәм тулыландырыла. Аны исеме мәгълүм булмаган бер әби күчереп язган дигән мәгълүмат бар.

1924 елгы текст коңгырт кара белән матур, төзек итеп 6 бит кәгазьнең ике ягын тутырып язылган. Кайбер урыннарында зәңгәр каләм белән аерым исемнәр өстәп куелган. Кәгазьнең форматы 17×22 см. Ул бик таушалган.

Икенче һәм өченче текстлар 1961 елда типографиядә эшләнгән шакмаклы дәфтәргә язылган. Дәфтәр 17×20,6 см зурлыкта, аның беренче битеннән кирилл хәрефләренә күчерелгән текст башлана, ул шәмәхә кара белән пөхтә итеп язылган. 1 нче

---

[1] *Әхмәтҗанов М. И.* Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 351 б.

битнең астагы өч юлына башка кеше кулы белән «1964 елның июль аенда Закирзянова Клара Мәүлид кызына бу дәфтәр тапшырылды» дигән җөмлә теркәлгән.

12 битле шакмаклы дәфтәрнең 10 битендә кириллицада соңгы редакциядәге шәҗәрә тексты язылган (1–10 битләр), өстәмә итеп шактый иске, кәгазьләре саргаеп беткән юллы дәфтәр кисәге теркәлгән. Дәфтәрнең арткы ягыннан башлап 1964 елда гарәп хәрефләре белән язылган әлеге текст 18 битне тәшкил итә (ике яклап язылган 9 бит). Текст Институт мирасханәсендә 99 нчы коллекциядә 1 нче тасвир, 401 нче берәмлек булып саклана.

*Бүләр йорты бабаларының исемнәре*

Бүләр йортының бабаларының исемләре шәҗәрәләре; Бүләрдин Бәк Барач дигән халыклар иде. Бүләр дийүләре бер сәнәви исем имеш. Әүвәл олуг бабамыз Бүләр хан, андин туган Йәдәш. Аның углы Ихсан, Ихсан углы Әлмөхәммәт, аның углы Калмөхәммәд, аның углы Тукмөхәммәд. Тукмөхәммәд углы Тылак, аның углы Шәмәк, аның углы Тугай, аның углы Симән. Симән углы Ындырчы, аның углы Сөләйман, аның углы Сабанчы. Сабанчыдан туган өч угыл: берсе Тәкәнеш, вә икенчесе Туктамыш, вә өченчесе Кодайбакты. Йәнә Тәкәнешдин туган Бийурган. Андыйн туган Бикәй, андыйн туган Мохит, Мохиттән туган өч угыл: берсе Тугай, Тугайдан туган Туктар. Туктардан туган дүрт угыл: берсе Йахшыкай, вә икенче Сәфәр, вә өченчесе Госман, дүртенчесе Солтанай.



*Бүләр дәфтәренең бер бите*

Менә Йахшыкайдан туган Ишдәүләт, андыйн туган Бикташ, йәнә Сәфәрдән туган Килмөхәммәт. Килмөхәммәттән туган Рәхмәтулла. Андыйн туган Вәлид. Госмандан Гали, Галидән туган биш угыл. Әүвәл Хәсән, йәнә Ихсан, Габделнасыйр, вә йәнә Габделкаһар, вә йәнә Даут.

Ихсандан туган биш угыл:

әүвәл Габделлатыйф, йәнә Габделбәшир, вә йәнә Габделгали, вә йәнә Габделгани, вә йәнә Мөхәммәди.

Беренче углы Габделлатыйфдан биш угыл:

әүвәл Фәхрази, икенче углы Хаммадула, өченче углы Байазит, дүртенче углы Сахибгәрәй, бишенче углы Сафийан. Фәхразидан туган сигез угыл:

әүвәл Имамрази, йәнә Шәйехрази, йәнә Сәйедгәрәй, йәнә Шәйехрази, йәнә Сәйедгәрәй, йәнә Хәйерзаман, йәнә Вәли, йәнә Миңнегали, йәнә Шәйехенур, йәнә Кәшшафетдин. Имамразидан туган дүрт угыл: әүвәл Шәвәли, йәнә Шәйехгали, йәнә Шаһдәмин, йәнә Хәсән, йәнә Шаһвәлидән туган угыл Төхфәтгали, йәнә Шаһгалидән туган Нәҗиб. Хаммадулладан туган җиде угыл: Сибгатулла, йәнә Шаһибәк, йәнә Шаһҗиһан, йәнә Әхмәд, йәнә Шәйехгаттар, йәнә Мирсаяф, йәнә Мирсәйед.

Йәнә Сибгатулладан туган бер угыл – Зиннәт, йәнә Шаһибәкдән туган бер угыл – Солтанбәк. Йәнә Шаһиҗиһандан туган алты угыл: әүвәл Шәрифҗан, йәнә Әдһәм, йәнә Илдархан, йәнә Гарифҗан, йәнә Нургали, йәнә Мирхат. Йәнә Әхмәтдән туган бер угыл – Һади, йәнә Шәйехгаттардан өч угыл: берсе Мирзанур, йәнә Фәтхелбәййан, йәнә Әхмәтфатыйх: йәнә Мирсайафдан туган дүрт угыл – әүвәл Гата, йәнә Сафа, йәнә Искәндәр, йәнә Йуныс. Йәнә Сафийандан туган дүрт угыл – әүвәл Солтангәрәй, Насыйри, йәнә Минһаҗетдин, йәнә Әкмалетдин. Йәнә Солтангәрәйдән туган дүрт угыл – әүвәл Харрас, йәнә Зийазетдин, йәнә Заһретдин, йәнә Садретдин.

Йәнә Харрасдан ике угыл – Миңнезаһит, йәнә Байазит.

Йәнә Насыйридан туган ике угыл: Вәҗетдин, йәнә Сахабетдин, йәнә Минһаҗетдин туган бер угыл – Гаязетдин. Йәнә Гаязетдиндән туган – бер угыл Мөхәммәдийә. Йәнә Әкмалетдиндән туган дүрт угыл – әүвәл Нурлыгаян, йәнә Шәйехҗан, йәнә Мирзашәриф, йәнә Мөхәммәдфарси. Мөхәммәтфарсидан (Мөхәммәтхарисдан?) ике угыл – Зәлиф (Мәхфүрҗан).

Йәнә Шәйехҗандан туган ике угыл.

Йәнә Сахибгәрәйдән туган ике угыл – әүвәл Габделкаюм, йәнә Миргали. Йәнә Габделкаюмдан туган ике угыл – берсе Нур-

лыгаян, йәнә Нургали. Йәнә Нурлыгаяндан туган ике угыл – Дифит, йәнә Наил. Йәнә Нургалидән туган бер угыл (?).

Йәнә Габделвәлидән дүрт угыл – әүвәл Сәүбән, йәнә Әхмәд, йәнә Таҗимәрдән, йәнә Мирзаҗан.

Йәнә Сәүбәндән ике угыл – әүвәл Шаһисолтан, йәнә Шаһгали.

Шаһисолтандан туган өч угыл – әүвәл Мөхәммәтсолтан, йәнә Шәбәк, йәнә Арсланбәк.

Йәнә Мөхәммәтсолтандан ике угыл – әүвәл Мәссәлим, йәнә…

Йәнә Шаһгалидән туган ике угыл – әүвәл Шаһгали, йәнә Мирзагали.

Йәнә Мирзагалидән туган бер угыл – ... (Шаһибәк?).

Йәнә Шаһибәкдән туган бер угыл – ...

Йәнә Әхмәдтән ике угыл – Арслангали, Нургали.

Йәнә Арслангалидән туган ике угыл – Миңнегали.

Йәнә Миңнегалидән туган ике угыл – Гыйльмегали, йәнә Мәлих.

Нургалидән туган бер угыл – Гаделэтдин.

Гаделэтдиндән туган ике угыл (Роберт, Азат).

Таҗмәрдәндән туган өч угыл – әүвәл Сәлимгәрәй, йәнә Сәлахетдин, йәнә Сәйедгәрәй.

Йәнә Сәлимгәрәйдән туган ике угыл – әүвәл Газизҗан, йәнә Мирзамөхәммәт.

Мирзамөхәммәттән туган ул йук.

Йәнә Мирзаҗандан туган дүрт угыл – әүвәл Әмирҗан, йәнә Газизҗан, йәнә Галимҗан, йәнә Шәрифҗан.

Йәнә Әмирҗандан туган ике угыл – Рәхимҗан, йәнә Нигъмәтҗан.

Йәнә Газизҗандан туган өч угыл – әүвәл Исламҗан, йәнә Закирҗан, (Инсаф).

Йәнә Галимҗандан туган дүрт угыл – Әхтәмҗан, йәнә Фәрит, йәнә Мәхмүтҗан.

Йәнә Габделгазиздән туган өч угыл – әүвәл Сәяхетдин, йәнә Җиһангир, йәнә Ширияздан.

Йәнә Сәяхетдиндән туган – әүвәл Салихҗан, йәнә Шәрифҗан, йәнә Мирас.

Йәнә Җиһангирдән туган бер угыл – Фәхрелгаян.

Йәнә Шириязданнан туган өч угыл – Шаһиәгъзәм, йәнә Шаһиҗиһан, йәнә Разетдин.

Йәнә Шаһиәгъзәмдән туган ике угыл – әүвәл Давыт, йәнә Миркасыйм.

Йәнә Мөхәммәдидән туган ике угыл – Шаһигәрдән, йәнә Шаһимәрдән.

Шаһигәрдән(нән) туган дүрт угыл – әүвәл Мирзамөкәриф, йәнә Мөхәммәдгафис, йәнә Мирзариб, йәнә Йагусыф.

Йәнә Мирзамөкәрифдән туган ике угыл – әүвәл Хәсән, йәнә Фоат.

Йәнә Мөхәммәдгавистан бер угыл – Файдак.

Йәнә Мирзарибтан туган бер угыл.

Йәнә Шаһимәрдәндән туган ике угыл – әүвәл Байазит, йәнә Мөхәммәтшәриф.

Йәнә Байазитдан туган бер угыл – Миркасыйм.

Йәнә Мөхәммәтшәрифтән туган ике угыл – Гариф.

Гали углы Габделнасыйрдан туган өч угыл – әүвәл Шаһингәрәй, йәнә Әхмәтгәрәй, Сәлимгәрәй.

Шаһингәрәйдән туган бер угыл – Сәхибгәрәй.

Сәхибгәрәйдән туган ике угыл – әүвәл Дәүләтгәрәй, йәнә Исламгәрәй.

Йәнә Дәүләтгәрәйдән туган бер угыл.

Исламгәрәйдән туган бер угыл.

Йәнә Әхмәтгәрәйдән туган өч угыл – әүвәл Сәлимгәрәй, йәнә Сәйедгәрәй, йәнә Мөхәммәдгәрәй.

Йәнә Сәйедгәрәйдән туган ике угыл – Бәхетгәрәй, йәнә Мәлих, Батыргәрәй.

Батыргәрәйдән туган бер угыл – Әбүзәр.

Йәнә Бәхетгәрәйдән туган бер угыл – Мәлих.

Йәнә Мөхәммәтгәрәйдән туган бер угыл – Абызгәрәй.

Йәнә Гали углы Габделкаһирдан туган өч угыл – әүвәл Габделсаттар, йәнә Шаһибетдин, йәнә Шаһимөхәммәт.

Габделсаттардан туган өч угыл – әүвәл Әхмәтситдыйк, йәнә Әхмәтхафиз, йәнә Шаһигәрдан.

Габделсаттар улы Әхмәтситдыйктан туган алты угыл – әүвәл Галимәрдән, йәнә Мирхәйдәр, йәнә Шаһихәйдәр, йәнә Мирзаһит, йәнә Салихҗан, йәнә Муллаҗан.

Әхмәтситдыйк углы Галимәрдәндән туган ике угыл – йәнә Мирзагали, йәнә Сәйедмөхәммәт.

Йәнә Мирхәйдәрдән туган бер угыл – Вагыйз.

Йәнә Шаһихәйдәрдән туган бер угыл – Әбүзәр.

Йәнә Мирзаһиттән туган биш угыл – әүвәл Мирзариб, йәнә Миргалим, йәнә Мирзанур, йәнә Хәсән, йәнә Хөсәен – игезләр, йәнә Миргазиз.

Йәнә Салихҗандан туган ике угыл – Йосыф, йәнә Мөхәммәддин.

Муллаҗандан туган ике угыл – әүвәл Хаммат, йәнә Фаил.

Йәнә Габделсаттар углы Хафиздан туган ул юк.

Йәнә Габделсаттар углы Шаһигәрдандән туган өч угыл – әүвәл Мирзашәриф, йәнә Әхмәтхафиз, йәнә Закирҗан.

Йәнә Мирзашәрифтән туган өч угыл – йәнә Миркасыйм, йәнә Мирхат, йәнә Мирьат. Миркасыймдан туган ул юк.

Мирхатдән туган ике угыл, әүвәл Вәгыйз, йәнә Салих.

Йәнә Мирхатдән туган бер угыл – Азат.

Закирҗандан туган ике угыл – Мөнәвир һәм Хәлаф.

Мөнәвирдән туган бер угыл...

Йәнә Габделкаһир углы Шиһабетдиндән туган өч угыл – Гыйльметдин, йәнә Заһеретдин...

Йәнә Гыйльметдиндән туган ул юк.

Йәнә Заһеретдиндән туган – әүвәл Бәзретдин, йәнә Мөхәммәтдин, йәнә Сәлахетдин.

Йәнә Бәдретдиндән туган бер угыл – Зиннур.

Йәнә Зиннурдан туган ике угыл – әүвәл Марсил, йәнә Рифгать.

Йәнә Сәлахетдиндән туган ике угыл – әүвәл Сәрвәр, Әнвәретдин.

Мөхәммәддиндән туган ул юк.

Шиһабетдиндән туган Әкмалетдин, андан туган өч угыл – әүвәл Гайнетдин, йәнә Нуретдин, йәнә Миңнезаһит.

Йәнә Гайнетдиндән туган бер угыл – Тимер.

Йәнә Нуретдиндән туган өч угыл – әүвәл Миргазийан, йәнә (Мирхаҗийан), йәнә Миркасыйм...

Йәнә Миргазийандан туган бер угыл...

Йәнә Габделкаһир углы Шаһимөхәммәдтән туган өч угыл – Әбелмәгъдән, йәнә Әхмәтхан, йәнә Мәгъдәнур.

Йәнә Әхмәтхандан туган өч угыл – әүвәл Әхмәтфатыйх, йәнә Мирзакасыйм, йәнә Мирзахан. Йәнә Әбелмәгъдәндән туган ул юк.

Йәнә Әхмәтхан углы Әхмәтфатыйхдан туган бер угыл…

Әхмәтхан углы Мирзафатыйхдан туган бер угыл…

Әхмәтхан углы Мирзахандан туган бер угыл – Фаил.

Йәнә Мәгъдәнурдан бер угыл – Мирзанур.

Йәнә Гали углы Даутдан туган ике угыл – Нурислам, йәнә Хәйерзаман.

Йәнә Нурисламдан туган өч угыл – әүвәл Мирзакай, йәнә Шәйхелислам, йәнә Шәйхелмәрдан.

Йәнә Мирзакайдан туган бер угыл – Шаһимирза. Йәнә Шаһимирзадан туган ике угыл.

Йәнә Шәйхелисламдан туган бер угыл – Яңа Сәфәрдә яши.

Йәнә Шәйхелмәрдандән туган ике угыл – әүвәл Тимер, йәнә Салих, йәнә Тимер.

Йәнә Туктар углы Солтанайдан туган ике угыл, берсе Байсарда, берсе Габдрахман, берсе Әхмәр. Габдрахмандан туган Байазид, Габделлатыйф.

Бу шәҗәрә язылган 1925 нче елда 5 апрельдә, шәүвәл аеның 5 нче көнендә. Без күчердек 1964 нче елда, нуябернең 8 ендә, кар йауган иде, бәйрәм иде.

### Кара бәк шәҗәрәсе

*Сәет Вахиди нөсхәсе*

«Хәзрәти Нух галәйһе әс-сәлам, Йәфәс, Булмас түрә, Чин хан, Коры хан, Бай Тархан, Корлу хан, Карагыл хан, Кийкобад падиша, Коһрасып, Гистасып, Әсфәндийар, Баһман, Дәраб (Искәндәр Зөлкарнәйин хәзрәти Дәраб углы), Сасан, Бабек, Ардашир шаһ, Шабур мәлик, Һәрмиз мәлик, Зарси мәлик, Бәһрамгүр мәлик, Фәйрүз мәлик, Кобад мәлик, Нәүширван гадел (кырык сигез ел падиша улды». Бигаять гаделлек әйләде. Аның заманында гаҗәм халкының (иранлыларның) милке мәгъмүр (төзек) иде. Аның бер углы Киран иде, аның углы Хәйердан, аның

углы Шәһрияр вә Ардашир Мирзабан, аның углы Сабит, аның углы Ногман хәзрәте Әгъзам, Әбүхәнәфи Рәхмәтулла Галиядер, Чүбинә, Бәһрам, Саман, Савыш хан, Әсад хан, Исмәгыйль хан, Әбүмансур, Байбек хан, Байсуб хан, Фәрсуб хан, Агут хан, Күләб хан, Бастук хан, Туктимер хан, ике углы булган.

1) Түмәнә хан, Кабил хан, Сүгән хан, Чынгыз хан (тарихның алты йөз 29 нчы елда, рамазан аенда вафат тапкан). Чыңгыз хан – Тукыз хан – углы булганнар: Күргән хан, Күк хан, Сүенеч хан, Кешелек хан, Җидай хан, Ләйтүк хан, Алтай хан, Хуҗа хан, Түли хан, Чыгтай хан. Түли хан (алты хан углы булган: Мүнкәй хан, Кублай хан, Иплү хан, Чингиз хан, Сөткенәй хан, Сәбәк-Тәгин хан), Һәләку хан (бу тарихның алты йөз 19 нчы елда вафат).

Һәләку хан. 13 углы хан булган: Шамйут хан, Тургай хан, Астыбай хан, Сүдер хан, Савыч хан, Колнар хан, Төшсин хан, Тикшер хан, Чорнай хан, Тимер хан, Телдар хан, Миңнү хан, Абакай хан. Бу ханнарның һәр каюларының аслы, кирәк казани улсын, кирәк кырымлы вә кирәк Хаҗитархани, вә кирәк ширванлы улсын, Дәшти-Кыпчактан хәрәкәт итеп, Русиягә килеп, 1243 нче сәнәләрдә кадәри бөтен Русияне забыт итмештер (басып алган).

Чыңгыз хан углы Баид хан иде (ягъни Бату хан күздә тотыла. – *М. Ә.),* өч йөз сәнәләр кадәр Русия өлкәсе булып ханнарның хөкемендә булындылар. Урыс кнәзләре ханнарга бәйгать вирүб (буйсынып), ханнарның вәкиле булып, әмрен эчрәя килтерүр иделәр. 3 йөз сәнәләрдин соң кысада уграеп хөкумәтләре кем хәлчә бозылды. Мондыйн соң Русияләрнең эшләре куәтләнеп... калынып, башка бер иттифак халә Русия ханлык кнәзләре уртадан күтәрелеп урыслар Мәскәү кнәзлеген алып падишаһлык сурәтинә керде вә куәтләнде, ханнарның... ахрысы ханнарны бетерер забыт (буйсындыру. – *М. Ә.)* вә истиляҗ (буйсындыру, җәелү. – *М. Ә.)* кылмая Мәскәүлек дәүләте зурланды вә көчләнде. 1552 елны Казан ханлыгы Русия тәгърифенә (кул астына) керде, канә 1554 елда Хаҗи Тархан ханлыгы Русиягә калды. 1582 елда Сибирия ханлыгы Русиягә калды. 1783 елда кырымнар Русиягә калды, вә бәгъдә Кавказияләр һәм Баку вә Ширван халыклары Русиягә кушылдылар. Сахиб имтияз (биеклек

иясе) Исмәгыйль бәк Гаспринскийның нөсхәсендән ушандак йад иделди. 1905 нче елда, 10 нчы мартта, 20 нче нумерлы нөсхәсендә (сүз «Тәрҗеман» газетасы хакында бара. *– М. Ә.)* иде, һиҗрәтнең 1323 нче сәнәдә, мөхәррәмнең 20 нче көнендә тәзкирә өчен (истәлеккә. *– М. Ә.)* йад яздым, бән Байсар карьясендә мөәзин Биктимер Габделнасыйр углы, Алкай хан, Аргын хан, Хужа хан, Чыгтай хан.

2) Бакый хан, Байсонкар хан, Кайынтур хан, Турай хан, Акылтуг хан, Байназар хан, Кызылбога хан, Акйалып хан, Сөләйман хан, Госман газый (диңгез кичен, Рум иленә барып әүвәл газа идән – бу Сөләйман падиша иде, тәбакыя Госмания дирләр), Урхай газый, Сары Бакый, Морал газый, Галәэтдин газый (Эрзырум шәһәрендә әмире бизрәк Галәэтдин иде. Бабалары Сәлҗук илә Төркестандин килмеш иде Хорасанны, Гыйракны вә үзгә вилаятьләрне мөсәхыйр кылып (яулап алып), йитмеш ел халифәт әйләде. Тәварихның алты йөз 680 нче ел вафат улды. Тәбакыя Сәлжукыя-и дирләр, Кондыз хан, Йолдыз хан, Байу хан, Телдәр хан, Миңдәр хан, Байбик хан, Пачман хан.

Пачман хан Эрзырум шәһәрендин чыгып, килеп Сакмар сувының тамагында рузгяр кичерде (яшәде. *– М. Ә.).*

Пачман хан бабамыз сахиб кыйран (падиша) Искәндәр Зөлкарнәйин нәселендәндер. Эрзырум шәһәрендән бахурфи (?) бар вакытта чыгып рабыйге мәскүнең (язлыкта кеше яши торган урын. *– М. Ә.)* жанүбе шәркыя килеп, Сакмар сувының тамагында кальгә (кала. *– М. Ә.)* ясап, хан улып торды, кинә аның углы Балым солтан Ык суы буенда мәкам тотты. Ык сувының ике яклап Зәй сувы буеның ике яклап, аяк бәйләп торды. Пачман хан – Балым солтан – Калдар бик – Канбар бик – Кара бик кенәз – Гали кенәз – Әлсуфый би – Сәйтәк би – Шәйсуб би – Әзмәт би – Җәнән би – Әбдал – Дәвләт суфый – Морад хуҗа – Морад Суфый – Тургай суфый – Таңатар – Йупан – Сапай – Килкә – Халит – Байсары – Йансары – Уразмәт – Айдар – Рафик (Ракай).

«Ибраһим Колшәриф углы, Колшәриф Дәвекәй углы, Дәвекәй Бохармәт углы, Бохармәт Исәнбай углы, Исәнбай Симәнәй углы, Симәнәй Бикбау углы, Бикбау Исәнгол углы, Исәнгол Бакты суфый углы, Бакты Суфый Морад хуҗа углы». – Бу Туктар

агайның[1] шәҗәрә язуыннан күчерелде. Безнең шәҗәрәнең язуына аның хилаф (каршы. – *М. Ә.)* киләдер, кайсы дөрестер, вә әмма язган язуымыз шәҗәрә китабыннан карап күчердем, гафил улмаң.

1. Югарыдагы шәҗәрәдә искә алынган Дәүләт суфый улы Морад хуҗаның икенче улы – Бакты суфый нәселе:

Бакты суфый – Бизүргән – Бүрәис – Казанчы – Муса – Ярмөхәммәт – Ишмөхәммәт.

Басыйр Халит улының тагы да булган угыллары: Шәмсетдин, Мөхетдин.

Уразмәт Йансары улының балалары – Абызай, Госман, Мәсгуд. Абызай углы – Шәриф, Шәриф углы Габделҗәлил.

2. Морат хуҗа улы Морат суфыйның башка балаларының нәселләре: Морат суфый – Хөсәен (Бикбау авыллары бабасы).

Морад суфый углы Бүзкүз – Күгәй, әүвәл грамота алган бабай. Йәнәйски булысының Тукыз түбәсе, Тутай аймакының Байсар авылында торлук кылгучыларның грамота алган бабаларының исемнәре түбәнендә беленүр. Әүвәл Күгәй бабай грамота алган.

Күгәй углы Борнаш, Борнашның Сака, Сәвәләй исемле угыллары бар.

Сәвәләйдән Бикчура, Урай, Сөләйман һ. б.

Сакадан Тутай (жалованный грамота алган бабай), Аккүз, Әткүнә, Урай, Туйтак.

Тутайдан Үтәк, Апач.

Аккүздән Солтангол.

Әткүнәдән Йуныс, Иш...дә, Ишмәкәй, Урайдан Урмач, Урмач углы Ирмәш (Апач авыллары).

Туйтак углы Илчебай, Илчебай углы Йүбәнәй һ. б.

Апачтан мулла Сөендек, Мортаза, Бәшир, Хәлил, Сәгыйт.

Үтәктән Чуаш, Йосыфкол.

Солтанголдан Бикчәнтәй.

Йуныстан Кыдрач.

Иш...дә Кинзә (аннан Сагындык, Сөендек).

---

[1] 1851 елда шәҗәрәне Туктар Ибраев күчереп язган.

«Кара бәк шәҗәрәсе»нең Туктар Ибраев тарафыннан 1851 елда күчерелгән варианты гаять зур тарихи кыйммәткә ия. Әлеге мәгълүматлар башка күчермәләрдә бөтенләй кабатланмый. Шунысын да искәртү кирәк: шәҗәрә, хокукый документ буларак, кыйммәтен бүгенге көнгә кадәр җуймаган.

Ишмәкәйдән Ишмән (Ишмәннән Конгыр) һ. б.

Грамота алган бабамыз.

Кайсыдыр кем әүвәл Күгәй, вә һәм Сәвәләй, вә һәм Сака, вә һәм Тутай бабаларымызның балалары Минзәлә өязе Байсар авылыңда ике йөз дә илле дүрт душ, Апач авылыңда алтмыш биш душ, Аҗи авылында ике йөз дә тугыз душ. Вәтски губернасы Сарапул өязендә Исәнбай авылында ике йөз дә кырык биш душ – сигезенче ревизиядә...»

Искәрмәләр.

Кара бәк шәҗәрәсен шартлы рәвештә өч өлешкә бүләргә мөмкин.

I. Кара бәк нәселләре үзләренең ерак бабаларын борынгы иран, грек, сәлҗук, гарәп династияләре белән бәйләнештә күрсәтергә телиләр. Әлбәттә, бу үзенчәлек урта гасырлардан бирле хакимлек итүче күп нәселләрнең шәҗәрәләренә хас. Шәҗәрәдән нәселнең ерак бабасы Пачман ханның Эрзырум (Эрзурум) шәһәреннән килгәнлеге ачыклана.

II. Тарихта 1237 елларда Батый хан гаскәрләренә ныклы каршылык күрсәткән кыпчак солтаннарыннан Пачман (Бачман) солтан шәхесе мәгълүм (Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. – II. – М., 1941. – С. 35–36).

«Дәфтәри Чыңгызнамә» әсәрендә дә Пачман ханның Сакмар тамагында кала тотып яшәве хакында язылган (Фасыл дастан нәселе Чынгыз хан һәм Аксак Тимер... – Казан, 1882. – 42 б.). Алда әйтелгәнчә, анда «Актүбә Пачман ханның йортыдыр» дип күрсәтелә (XVIII гасырда яшәгән рус тарихчысы Петр Рычков хезмәтләрендә Актүбә шәһәренең хәзерге Оренбург урынында булуы хакында мәгълүмат бар: Рычков П. И. История Оренбургская (1730–1750). – Оренбург, 1896. – С. 69).

Пачманның улы Балым солтан хакында хәбәрләр юк.

Балым солтан улы Калдар бәкнең исеме исә «Дәфтәри Чыңгызнамә» дастанында, Чыңгыз бәкләре арасында искә алына: «Әй, Калдар би, синең агачың сандал вә кошың күгәрчен, вә ораның «Арнау» вә тамгаң чүмеч булсын» (Җингиз хан вә Аксак Тимер... – Казан, 1819. – 54 б.).

Калдарның улы Канбар турында яңа мәгълүматлар табылды. Канбар хан нәселләреннән Ташкент якларында яшәүче берәү бабалары хакында кызыклы хәбәр язып җибәргән. 1930 елларда аның әтиләрендә күн тышлы «Канбар хан шәҗәрәсе» исемле кульязма китап була. Әмма ул вакытларда Канбаровлар гаиләсен эзәрлекләү башлана. Шәҗәрәне яндыралар. Анда хәзерге Камбарка шәһәре урынында Канбар ханның олыс үзәге булуы язылып, киң таралган нәсел тамырлары тасвирланган була. Канбаровлар фамилиясен йөртүчеләр Актаныш, Мөслим, Минзәлә, Илеш, Краснокама төбәкләрендә әле дә очрарга мөмкин.

III. Канбар, Кара бәк нәселләре Сакмар суы буйларыннан Нократтагы Карино авылына һәм Чувашия чигеннән Уфага кадәр булган

киң мәйданнарны биләп яшиләр. Аларның саны йөзләрчә мең кешегә җитә. Шунлыктан Кара бәк нәселенең Идел–Урал буе татарлары этник тарихында урыны зур.

Кара бәк халкын тәшкил иткән угыз-кыпчак ырулары Идел – Урал буе татарларының зур бер компонентын тәшкил итә. «Кара бәк шәҗәрәсе» белән бер үк дәверләргә караган башка нәселләрнең шәҗәрәләре этник тарихыбыздагы татар катламын тагын да ныграк ачалар.

### Акъюл шәҗәрәсе

Актаныш төбәге Күҗәкә авылыннан Акъюл нәсел шәҗәрәсе матбугатка беренче мәртәбә тәкъдим ителә. Аны филология фәннәре докторы Дария Бәйрәм кызы Рамазанова табып алып кайткан иде. Шәҗәрә Акъюл нәселе вәкиле Шәехов Әхмир Әбүбәк улы тарафыннан төзелгән.

Акъюл шәҗәрәсе Мәчти авылында язып алынган Туксаба шәҗәрәсенең дәвамы һәм төрдәше булып тора. Борынгыдан калган Туксаба шәҗәрәсенең үзәк тармагы түбәндәгечә:

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| | *I буын* | | | *VII буын* | |
| 1. | Туксаба | | 7. | Габделҗәлил | 6 |
| | *II буын* | | | *VIII буын* | |
| 2. | Сәвәләй | 1 | 8. | Байазид | 7 |
| | *III буын* | | | *IX буын* | |
| 3. | Тәүкил | 2 | 9. | Мөхәммәдшәриф | 8 |
| | *IV буын* | | | *X буын* | |
| 4. | Чубан | 3 | 10 | Мирза Мөхәммәдьяр Солтанов[1] | |
| | *V буын* | | | | |
| 5. | Мәмәт | 4 | | | |
| | *VI буын* | | | | |
| 6. | Солтан | 5 | | | |

Бу нәселнең бабалары йомышлы татарлар булып, «башкорт сословиесе»ндә торганнар. Уфа өязендә хезмәт итүче йомышлы татар морзаларыннан саналып, соңыннан Русия хөкүмәтенең ышанычын казанган нәсел ул. Юкка гына әлеге фамилиядән

[1] *Мәрҗани Шиһабетдин.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар. – Казан, 1900. – Б. 212–213.

мирза Мөхәммәдьяр Солтановны рәсми хөкүмәт тәкъдиме белән 1886–1915 елларда Уфадагы дини идарәгә мөфти итеп билгеләмәгәннәр. Аның кабере Уфада, Диния нәзарәте мәчете кырыенда. Кабер ташында гарәп шрифты белән түбәндәге сүзләр язылган:

«Хаҗел хәрамин Мөхәммәдьяр бине Мөхәммәдшәриф Солтанов.

1915 елда 16 июньдә 79 яшендә вафат. Уфада мөфтилек хезмәтендә 29 ел гомер иткән. Асыл ватаны Минзәлә районы Мәчти авылында 1836 елда туган».

Туксаба нәселеннән татар музыкасын өйрәнү фәнендә беренче профессор Солтанов Мансур Ислам улы (1875 – 1918) мәгълүм. Ул Саратов шәһәрендә консерваториядә укыткан.

Шәҗәрәнең төп башлангычы итеп күрсәтелгән Туксаба исеме XII–XIII гасырларда Дон буйларындагы көчле кыпчак кабиләсенең исеменә туры килә. Бәлки, ул баба исеменнән киләдер, дигән фараз бар.

Күҗәкәдә табылган Акъюл шәҗәрәсе дә «Туксаба» дип мәгълүм булган борынгы ыруг-кабилә нәселенә тоташа. Бу очраклы хәл түгел. Чөнки Ык һәм Дим, Кенәле елгалары буйларында XII–XIII гасырлардан ук кыпчаклар яшәгән. Аларның тарихи эзе кеше исемнәрендә, җир-су атамаларында, шәҗәрәләрдә, кабер ташларында яхшы сакланып калган.

Түбәндә Акъюл шәҗәрәсенең китап варианты китерелә.

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Акъюл | |
| | *II буын* | |
| 2. | Әбләй | 1 |
| 3. | Әхмир | 1 |
| | *III буын* | |
| 4. | Ваһап | 2 |
| 5. | Ханнан | 3 |
| 6. | Мәннан | |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *IV буын* | |
| 7. | Каһир | 4 |
| 8. | Хәсән | 4 |
| 9. | Хөсәен | 4 |
| 10. | Гыйрфан мулла | 4 |
| 11. | Вәли мулла | 4 |
| 12. | Гани | 4 |
| 13. | Вилдан | 4 |
| 14. | Ногман | 4 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 15. | Гыйльман | 4 |
| 16. | Төхбәвәли | 4 |
| 17. | Габделнәфикъ | 5 |
| 18. | Габделвәли | 5 |
| 19. | Мирзашәрип | 5 |
| 20. | Габделкәрим | 6 |
| 21. | Габҗәмил | 6 |
| 22. | Габделбарый | 5 |
| 23. | Габделрахшап | 6 |
| 24. | Габделгазиз | 6 |
| | *V буын* | |
| 25. | Гали | 7 |
| 26. | Сәләхетдин | 7 |
| 27. | Габделвәли | 7 |
| 28. | Шакир | 8 |
| 29. | Закир | 8 |
| 30. | Бәдретдин | 9 |
| 31. | Фәррахетдин | 9 |
| 32. | Акмалетдин | 9 |
| 33. | Мирзаян | 10 |
| 34. | Шәрипҗан мулла | 10 |
| 35. | Барый | 11 |
| 36. | Даян | 12 |
| 37. | Муллагали | 12 |
| 38. | Гыймран | 13 |
| 39. | Суфиян | 14 |
| 40. | Шәйехзаман | 15 |
| 41. | Хәйдәрҗан | 16 |
| 42. | Мирзаһит | 17 |
| 43. | Әбүшәйех | 17 |
| 44. | Миркасыйм | 17 |
| 45. | Ильяс | 17 |
| 46. | Нурлыгаян | 18 |
| 47. | Фарсый | 18 |
| 48. | Мохтәр | 18 |
| 49. | Фәтхелбәййан | 18 |
| 50. | Миргалим | 18 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 51. | Надим | 18 |
| 52. | Әхмәтзыя | 18 |
| 53. | Мирзазариф | 19 |
| 54. | Габдулла | 19 |
| 55. | Гатаулла | 19 |
| 56. | Мозаффар | 19 |
| 57. | Мөнәвир | 19 |
| 58. | Фатих | 20 |
| 59. | Баязит | 22 |
| 60. | Фоат | 22 |
| 61. | Васил | 22 |
| 62. | Госман | 23 |
| 63. | Мәснәви | 24 |
| 64. | Мәккәни | 24 |
| | *VI буын* | |
| 65. | Арслан | 25 |
| 66. | Нурлыгаян | 25 |
| 67. | Әхмәткәрим | 25 |
| 68. | Фатих | 26 |
| 69. | Нәҗип | 26 |
| 70. | Габдерахман | 27 |
| 71. | Мортаза | 27 |
| 72. | Әхмәтсафа | 27 |
| 73. | Зәки | 27 |
| 74. | Шакирҗан | 27 |
| 75 | Муллаян | 27‘ |
| 76. | Галимҗан | 27 |
| 77. | Сабир | 28 |
| 78. | Морат | 28 |
| 79. | Гыйльмегаян | 28 |
| 80. | Габдулла | 29 |
| 81. | Габидулла | 29 |
| 82. | Гыйльметдин | 30 |
| 83. | Мияссәр | 30 |
| 84. | Вәҗетдин | 32 |
| 85. | Мисбахетдин | 32 |
| 86. | Хиразетдин | 32 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 87. | Флүн | 32 |
| 88. | Шамил | 32 |
| 89. | Мәхмүтҗан | 33 |
| 90. | Га… | |
| 91. | Ситдыйкҗан | 33 |
| 92. | Хәсәнҗан | 33 |
| 93. | Сәлимҗан | 33 |
| 94. | Шамил | 34 |
| 95. | Наил | 34 |
| 96. | Гыйрфан | 38 |
| 97. | Ахунҗан | 39 |
| 98. | Сабирҗан | 39 |
| 99. | Шәйгәрдәп | 40 |
| 100. | Шәйхәйдәр | 40 |
| 101. | Хәсән (Советлар Союзы Герое) | 40 |
| 102. | Зөфәр | 42 |
| 103. | Әбүбәк (хатыны Абдуллина Нурфика) | 43 |
| 104. | Данбәк | 43 |
| 105. | Өлфәт | 44 |
| 106. | Фенүн | 44 |
| 107. | Гавис | 45 |
| 108. | Әндәс | 45 |
| 109. | Зөфәр | 45 |
| 110. | Васил | 48 |
| 111. | Наил | 48 |
| 112. | Расих | 50 |
| 113. | Револь | 50 |
| 114. | Илгиз | 50 |
| 115. | Ринас | 50 |
| 116. | Мияссәр | 54 |
| 117. | Фәрит | 54 |
| 118. | Әбелгас | 58 |
| 119. | Баязит | 61 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *VII буын* | |
| 120. | Зөлфәт | 69 |
| 121. | Назиф | 69 |
| 122. | Таһир | 69 |
| 123. | Газинур | 69 |
| 124. | Тимершәйех | 70 |
| 125. | Габделхак | 70 |
| 126. | Габделхай | 70 |
| 127. | Сәхип | 71 |
| 128. | Зәки | 71 |
| 129. | Индүс | 79 |
| 130. | Рафис | 79 |
| 131. | Фәндүс | 79 |
| 132. | Фарсый | 82 |
| 133. | Мәүләви | 82 |
| 134. | Мөхтәсәр | 83 |
| 135. | Мөдәккәр | 83 |
| 136. | Ришат | 88 |
| 137. | Мингали | 97 |
| 138. | Сәйетгали | 97 |
| 139. | Мирсәйет | 97 |
| 140. | (кызлар) | 100 |
| 141. | Гөлҗиһан | 101 |
| 142. | Гөлмәрьям | 101 |
| 143. | Искәндәр | 103 |
| 144. | Әхмир (1948 елда туган) | 103 |
| 145. | Алмаз | 104 |
| 146. | Рөстәм | 104 |
| 147. | Ренат | 105 |
| 148. | Рәшит | 106 |
| 149. | Наил | 108 |
| 150. | Рәсим | 110 |
| 151. | ... | 111 |
| 152. | Альберт | 113 |
| 153. | Револь | 113 |
| 154. | Мөнир | 119 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *VIII буын* | |
| 155. | Дилшат | 120 |
| 156. | Фәнис | 121 |
| 157. | Дәнис | 121 |
| 158. | Илгар | 123 |
| 159. | Зөфәр | 128 |
| 160. | Фәнис | 128 |
| 161. | Фирдәвес | 128 |
| 162. | Рөстәм | 128 |
| 163. | Фәндүс | 129 |
| 164. | Ренат | 132 |
| 165. | Рафис | 133 |
| 166. | Рөстәм | 134 |
| 167. | Мозафар | 134 |
| 168. | Мөдәрис | 134 |
| 169. | Альберт | 145 |
| 170. | Руслан | 145 |
| 171. | Артур | 146 |
| | *IX буын* | |
| 172. | Руслан, мулла | 162 |
| 173. | Алмаз | 162 |
| 174. | Айдар | 168 |

Актаныш төбәге тарихын ачыклауда шәҗәрәләр белән бер үк вакытта каберташ язмалары бәһале чыганак булып тора. 1998 елның августындагы экспедиция вакытында тарихи кыйммәте зур булган шундый бер ташъязмага юлыккан идек.

Әҗәкүл җирендә сакланган әлеге бердәнбер кабер ташы ак таштан кисеп ясалган. Язылышы, ташның эшкәртелеше, күләме ягыннан ул Кама елгасының уң ягындагы татар авыллары зиратларында сакланып калган эпитафик истәлекләрдән әллә ни аерылмый.

Ярым дугаланып, очлаеп торган вертикаль һәйкәлнең биеклеге, иң түбәндәге язулы юлны да кертеп, 105 см тәшкил итә. Әлбәттә, аның җир астына баткан 50 см чамасы язусыз өлеше дә бар. Ташның киңлеге – 54, калынлыгы – 17 см. Мондый зурлыктагы ташбилгеләр, нигездә, XVII гасырның соңгы чиреге һәм XVIII йөз башы татар эпиграфик истәлекләренә хас.

Ташның сул яктагы язулы өлеше кителеп төшкән. Йөзлегендә күпертеп язылган алты юл текст урнашкан. Тексттан өскә, ташның югары ягына Казан ханлыгы дәвереннән бирле кабер ташларына ясалып килгән чәчәк орнаменты төшерелгән. Текст һәм ташның бизәге турысызыклы һәм овал рәвешендәге

кысалар эчендә калдырылган. Кыса сызыклары таш йөзлегенә уеп төшерелгән. Таш йөзлегендәге күпертеп язылган гарәп графикасындагы җөмләләр дүртпочмаклы оялар эчендә калганнар.

Текстның баштагы ике юлы һәм өченче юлның башы гарәп телендәге догалардан гыйбарәт булып, калган текст юллары саф татарча итеп гарәп язуының сөлес стилендә язылганнар.

Әлеге эпитафик таштагы язма – Актаныш төбәгендә XVII гасырда барган этник миграция күренешләренең бер документы. Анда Килди би углы Ишкәй нәселенең Әҗәкүл авылына хәзерге Әгерҗе төбәгендәге Үтәгән авылыннан күчеп килгәнлеге язылган, һәм бу кабер һиҗри 1094, милади 1682/83 елларда үлгән кешенеке булып чыга.

Актаныш төбәгендәге Уразай, Әҗәкүл, Байсар, Солтанай, Илчебай һ.б. авылларның Нократтан чыккан татар биләре тарафыннан нигезләнүе Әҗәкүлдәге Килди би углы Ишкәйнең дә шул ук Нократ биләре – морзалары нәселеннән икәнлеген күрсәтә. Таштагы Ишкәй углына ташбилге куйдыручы Фәйтке Гөлимкәйнең кушаматы аның чыгышының Фәйтке, ягъни Вятка (Нократ) ягыннан икәнен күрсәтә.

Чал тарихтан сәлам булып килгән ташъязмалар турында бу китапның алдагы сәхифәләрендә тәфсилләбрәк сөйләнер әле.

# ТАШКА УЕЛГАН СӘХИФӘЛӘР

## Актаныш районында эпиграфик һәм археографик эзләнүләр

*Рәшит Кадыйров*

Тарихи эпиграфика (ташъязмалар) дигәндә, иң әүвәл, кабер ташлары күздә тотыла. Аларның XX гасыр башларына кадәр куелганнары аеруча бәһале, кыйммәтле чыганак дип санала.

Актаныш төбәгенең эпиграфик истәлекләре моңарчы комплекслы рәвештә өйрәнелмәде. Аерым табышлар (мәсәлән, Әҗәкүл авылында Марсель Әхмәтҗанов тасвирлаган 1682/83 тарихлы кабер ташы) булса да, райондагы язулы ташбилгеләрне барлап, мөмкин кадәр тулы эпиграфик атлас төзү мәсьәләсе әле дә көн тәртибендә кала.

2009 елгы экспедиция вакытында 14 авылның (Күҗәкә, Татар Суыксуы, Иске Сәфәр, Иске Әлем, Каратал, Калмаш, Мерәс, Аеш, Чалманарат, Уразай, Шәрип, Карач, Чуракай, Мәчти) зират ташларын карап чыгу мөмкин булды. Барлыгы 53 ташбилге укылды. Иң күп ташлар Иске Сәфәрдә (10), Чуракайда (7) һәм 1970 елларда юкка чыккан Мәчти (25) авылы янындагы каберстанда табылды.

Ташъязмаларның күбесе артык зур түгел. Бу – җөмһүриятебезнең башка төбәкләрендәге кабер ташлары өчен дә хас күренеш. Шул ук вакытта, Актаныш районындагы һәм аның күрше төбәкләрендәге каберташ язмаларының үзенә бер схемасы күзәтелә.

Язуларның башлам өлешен Корьән аятьләре һәм хәдисшәрифләр тәшкил итә (кайбер очракларда беренче юлга дата

куелган). Калган өлешләрендәге язу мәрхүмнең һәм аның атасының исеменнән, үлгән вакытыннан (елы, күп очракта ае һәм көне), шәхси сыйфатламалардан гыйбарәт. Азакта еш кына кабер ташы янына килүчеләрдән мәрхүм рухына «Фатиха» сүрәсен укулары сорала. Тагы шунысын да әйтергә кирәк: XIX гасыр урталарына кадәр куелган ташлар шактый зур булып (җир өстендәге өлешләренең биеклеге 150–160 сантиметрга җитә), аннан соңгы чорлардагы ташбилгеләр тәбәнәгрәк һәм таррак.

Аерым ташларга килгәндә, язу рәвеше һәм бизәлеше ягыннан Мерәстәге Фәттахетдин Шыгак угылына (вафат булган елы 1885), Аештагы Шәмсимөнәвәрә Габделхәким кызына (1902), Уразайдагы Нурижиһан Нуриәхмәд хәләленә (хатынына), Иске Сәфәрдәге Шаһгали Исламгол угылына (1914), Шаһимәрдан Корбангали угылына (1912), Корбангали Биктәш угылына (1889), Габделхәлим Габделгалим угылына (?), Чуракайдагы Шәйхетдин Батыршаһ [угылына] (1895), Рәмгол Аккулай угылына (1871), Гыйлембану Мөхәммәдбәдыйк хәләленә (1903)[1] куелган кабер ташлары җирле эпиграфик сәнгать үрнәкләре булып саналырга лаеклы.

Ташларның язулары, нигездә, бик пөхтә итеп һәм зур осталык белән башкарылган. Эпитафияләрне маһир хаттатлар (каллиграфлар) күпертеп яки уеп, сөлес, нәсех һәм тәгъликъ стильләрендә язганнар.

Ташлар бизәлеш ягыннан да кызыклы. Юллар бер-берсеннән тар күпертмә (яисә уйма) буйча белән аерылган. Гадәттә, текст кыса эченә алынган, кысада төрле характердагы орнаменталь бизәкләр ясалган. Араларында, XIII–XIV гасыр болгар кабер ташларындагы кебек, соляр (кояшны чагылдырган) мотив-

---

[1] Чуракай, Җылан, Мәчти авыллары белән бәйле тарихи чыганакларны барлаганда, бүгенге көндә шул авылларда яшәүче милләттәшләребезнең нәсел җепләре (силсиләләре) дә ачыкланды. Мисал өчен, үзәге Чуракайда урнашкан «Алга» авыл хуҗалыгы җитәкчесе Назыйм Шәехев һәм аның бертуганы, шул ук җирлектәге фермер хуҗалыгы җитәкчесе Хавил Шәехевләрнең силсиләсе түбәндәге рәвештә: Чурагол (XVIII гасыр азагы) – Вәли – Төхфәтулла – Хәбибулла – Шәехмөхәммәд – Габдессалих – Шәех – Зөфәрит – Назыйм белән Хавил.

лар очрый, шул ук вакытта бары Мәчти, Актаныш төбәге һәм әтрафы өчен генә хас булган бизәмәләр дә бар. Бирелә төбәкнең эпиграфик язу осталарының һөнәри үзенчәлекләре һәм эш алымнары, төрле язу төрләрен кулланганда ничегрәк эш итүләре аермачык күренә.

Гомумән алганда, Актаныш районындагы эпиграфик истәлекләр, бу төбәкнең тарихын (шул исәптән сәнгать тарихын) өйрәнү өчен, кыйммәтле чыганак ролен үти.

### *Мәчти авылы каберстаны*

Элекке Мәчти авылының зираты аның төньягында урнашкан. Авылда барлыгы 25 кабер ташы (иң искесе 1824, иң соңгысы 1908 елда куелган; тарихы ягъни датасы хәрефләр һәм саннар кителеп төшү сәбәпле укуы мөмкин булмаган берничә таш та бар) һәм берничә җимерек төрбә калдыгы сакланган. Аларның текстларыннан аңлашылганча, авылда өстен катлау вәкилләре: дворяннар, мәэмүрләр (чиновниклар) һәм дин әһелләре яшәгән[1]. Мәсәлән, анда атаклы дворяннар нәселеннән морза Солтановларның берничә буын вәкилләре шактый ук ишле гаиләләре белән тормыш иткәннәр. 1824 елда вафат иткән Габделҗәлил Солтан улының гына да җиде улы[2] булган. Габделҗәлил морза административ-хәрби берәмлек – кантон башлыгы булып торган. Солтановлар XIX гасыр урталарына кадәр Русия патшасы хакимияте тарафыннан оештырылган Башкорт-Мишәр гаскәрендә хезмәт иткәннәр.

Мәчти зиратында шулай ук Россиянең икенче мөфтие Габдессәлам бине Габдеррахманның (мөфтилек иткән еллары 1825–1840) гаилә әгъзалары: икенче хатыны Фәрхибану Рәхмәтулла кызы (?), кызы Сәрвиҗиһан (1842?), оныклары Бибигазизәбану

[1] XIX гасыр урталарында Мәчтидә яшәгән кешеләрнең исемлеге «Кушымта»да бирелә.

[2] Чалманарат авылындагы ялгыз таш язуыннан аңлашылганча, анда Габделҗәлил улы Бәязит җирләнгән (1843 ел). Ул да Мәчти Габделҗәлил «Кантун»ның улыдыр дип фаразларга мөмкин. Мәчти авылында 1859 елда Бәязит уллары Мөхәммәдшәриф белән Шаһиәхмәт яшәгәннәр («Кушымта»ны кара). Зиратта 1874 елда үлгән штаб-ротмистр Мөхәммәдшәриф бине Бәязитнең ташы бар.

(1841), Бибишәмсиҗиһан (1842), Бибихөсниҗиһан (1854)[1] һәм кияве Шәйхелислам бине Мөхәммәдеррәхим Солтанов (1888) җирләнгәннәр.

Мәчти – бишенче мөфти Мөхәммәдьяр Солтановның (мөфтилек иткән еллар – 1886–1915) туган җире. Ул монда 1837 елда Мөхәммәдшәриф Бәязит улы гаиләсендә туа, 1859 елда урядник дәрәҗәсендә Башкорт-Мишәр гаскәрендә хезмәт итә, 1861–1866 елларда кантон башлыгы вазыйфаларын башкара. Аның беренче хатыны Хәнифә Якуп кызының кабере шулай ук Мәчтидә.

Мәчти авылы каберстаны тарих, аерым шәхесләр, кайчандыр шактый ук мәшһүр булып та онытылган исемнәр, эпиграфик сәнгать истәлекләре җәһәтеннән бик мөһим матди һәм мәгънәви комплекс булып тора. Ул – җөмһүриятебезнең, һичшиксез, аерым әһәмияткә ия тарихи-мәдәни ядкяре.

* * *

Мәчти авылы зиратындагы ташларның язулары юл-юл рәвешендә, хронологик тәртиптә бирелә. Хәзерге укучыга аңлашылмаган яки авыр аңлашылган сүзләрнең тәрҗемәсе һәм аңлатмалар түгәрәк җәя эчендә күрсәтелә. Эпитафияләрдә хәрефләре кителеп төшкән һәм укыла алмаган (яисә фараз рәвешендә укылган) урыннар күп нокта шәкелендә дүрткел җәя эченә алына.

### *I таш*

*Алгы ягында*

1. Тарихе румийә (милади) илә 1824
2. Тәкәббер булсаң бу төрбәнең иясендин кыл пөрсиш (сора)
3. Нәдер (нидер) исеме нәдер җисеме бәян кыл әйләмә (итмә) тәшвиш
4. Зәлилийәт (түбәнлек)не җәлилә (бөеклеккә) изафә әйлә (куш) и ага
5. Тәләффызда (әйтелештә)булыр Габделҗәлил лаек мөсәммага (исемләнергә)

[1] Сәрвиҗиһанның балалары турында язган Ризаэддин Фәхреддин (Фәхреддин Ризаэддин. Асар. – Казан, 2006. – 1 т. – 156 б.) бу өч баланы, бәлки алар кече яшьтә үлүләре сәбәпле (дөрес, Бибихөсниҗиһан 17 яшенә җитеп үлгән), каләмгә алмый. Мөгаен, аның кулында җитәрлек мәгълүмат булмагандыр.



6. […] Солтан угылы […]
7. Мөләккабтыр (кушаматлы) ки Кантун ләфыз (сүз) бер[лә?]
8. Хөкүмәт илә дәүраны (дәверне) кәчерде
9. Дип суре нәфех (мәхшәр көнне сур быргысын кычкырту) соңында
10. Җәлил (бөек) кыл әйләеп тәҗрид (аерылып) ки гыйсъяндин
11. Илаһи кыл ки[…] мизанны (мәхшәр көнне кеше кылган игелекләр һәм гөнаһлар үлчәнеләчәк үлчәү) кылма суз (көйдергеч, яндыргыч) мәҗрух

*Артқы ягында*

1. Тарих һиҗрәтен-Нәби галәйһис-сәлам 1239
2. Нәчә (күпме) сәгый әйләеп (тырышып) сарикъны (каракны) вә тәгын (биредә – хурлаучы, сүгүчеләрне ) әйләде бәрһәм (саташтырды)
3. Моның гасрында күп илләрне (авылларны) бостан (бакча) әйләде ул һәм
4. Кәрим (Аллаһның исеме) сән рәхим әйләеп бу колга әйләгел мәдәд (ярдәм)
5. Кыямәт көнендә аны пәнаһдар әйлә (сакла) йа Әхәд (Аллаһның исеме)
6. […]әбьятың (бәетләрнең) хоруфе ахирига (соңгы хәрефләренә) сән
7. Назар кыл (кара) әйлә сән назыймың (бәет язучының) […]
8. Дәхи кылсаң назар бу шигырьнең әүвәл хоруфына (хәрефләренә)
9. Буласән (табарсың) [фәүт (улем)] тарихын (датасын) боңа кыл шөкер гамь йимә (кайгырма)
10. Йәнәдин сәнең нәдер тарихе фәүтдер ләфыз кылгыл (әйт)
11. […]

*Уң кырында*

Үлемне даим[ән] яныңда белгел
Аның илкен (кулын) гәрибаныңда (якаңда) белгел

*Сул кырында*

Йа вакыйфан бикабри мүтәфәккирән биәмри

Биләмси күнтү мисликә тәсыйрү гадән мисли
(Әй каберем янында туктаган, Аллаһның әмере турында уйлаган!
Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем кебек булачаксың.)

***II таш***

1. Тарихе румийә 1841
2. [Шәүввәл аеның...] заман мөрүрендән сәрәнҗам (заманнар үтүнең нәтиҗәсе)
3. Белеңезләр Мөхәммәдеррәхим әлмәрхүм исем[...] төҗҗарындин (сәүдәгәрләреннән) […]
4. Атасыдыр Габделҗәлил Солтан угылы җиһан (дөнья) улды (булды) аның гасырында асаеш (тынычлык, тәртип)
5. […]
6. Бу мәрхуми догада әйләңез яд (дога кылып искә төшерегез) кыла күреңез рухын шад
7. Илаһи әйлә бу мәдфүни (җирләнгәнне) мәгъфүр (гафу кылынган) дәхи кыл мәркаден (каберен) нур
8. Рихләт кылмакы (күчеп китүе) [дарел-бәкайа (бакый йортка)] фәүкыс-сәмайа (күкләрдән югарырак)

***III таш***

1. 1256 тарихе гарәбийә вә тарихе румийә 1841
2. Дөлү бөрҗенең (Сукояр йолдызлыгының) әүввәлге гашәрәдән (ун көненнән) көн илә Шәйхелислам
3. […] фәрзәндәсе (баласы) Бибигазизәбану әл-мәрхүмә вәл-мәгъфүрә (гафу кылынган)
4. Котбез-заман (заманның котыбы, югары ноктасы) мөфти әл-аван (дәвернең мөфтие) Габдессәлам әл-мәрхүмнең нәбирәсе (оныгы)
5. 7349 Адәм галәйһис-сәлам дарел-бәкайа рихләт әйләде (мәңге йортка күчте)
6. 5157 Нух галәйһис-сәлам



***IV таш***

1. Һуввәл-Халлакуль-Бакый (бөтен барлыкны яраткан вә бакый Аллаһтыр)

2. Ля иләһа илләллаһ Мөхәммәдү рәсулүллаһ саллаллаһу
3. Нәгузу билләһи Тәгалә мин фитәнил-кабри вә мин әһвалил
4. -хәшри вән-нәшри вә нәсьәлүллаһа Тәгалә мәгъфирәтә вәл
5. -гуфрана бил-җәннәти вәр-рәхмәти вәр-ризвани (кабернең вәсвәсәненнән һәм кыямәт көненең дәһшәтеннән Аллаһы Тәгаләгә сыгынабыз һәм Аллаһы Тәгаләдән безне гафу итүен вә ярлыкавын, безне җәннәткә, рәхмәткә вә җәннәт сакчысына кавыштыруын үтенәбез) әл-мәрхумә
6. Бибишәмсиҗиһан туташ бинте Шәйхелислам
7. дөхтәре Сәрвиҗиһан (Шәйхелислам белән Сәрвиҗиһанның кызы) бинте мөфти әз-заман (мөфти Габдессәлам Габдеррахман улы күздә тотыла) сахибел-
8. җаһ (югары урын биләгән) вәс-сәха (юмартлык иясе) вәл-фәнаэ фи һәзаль-вилдани (үзеннән дә ныграк бу балаларын сөйгән) дарел-
9. фәнадан (фани йорттан) дарел-бәкайа рихләт әйләде (күчте) 3 ел
10. алты ай гомер кичерде тарих румийә илән
11. 1842 елда сентябрнең 29 мәдфүн (җирләнгән) Фатиха (мәдфүннең рухына Коръәннең «Әл-Фатиха»сүрәсен уку сорала)

***V таш***

1. Кәфә билмәүти вагыйзан (үлем иң ышандыргыч вәгазь)
2. Ля иләһа илләллаһ Мөхәммәдү рәсулүллаһ
3. Нәгузу би[лләһи] Тәгалә мин фитәнил-кабри вә мин
4. әһвалил-хәшри вән-нәшри вә нәсьәлүллаһа Тәгалә
5. мәгъфирәтә вәл-гуфрана вә әдхилнәл-җәннәтә (һәм безне җәннәткә керт) йа Рах[ман]
6. [әл]-мәрхумә вәл-мәгъфурә Бибисәрвиҗиһа[н бинте]
7. [Га]бдессәлам (кызы) мөфти әһлел-ислам зәүҗәтү [Шәйхелислам] (хатыны)
8. дарел-фәнадин дарел-бәкайа интикаль әйләд[е] (күчте)
9. илле яшендә 2 угыл 2 кыз догачылар куйды
10. Габи[дә] (гыйбадәт кылучы) сәхийәләрдән (юмартлардан) улып (булып) сәхавәт (юмартлык) мәйданында
11. гасырында һәмта вә назыйре (тиңдәше) улмады фөкара вә йатамаларны (фәкыйрь һәм йәтимләрне)
12. мохт[аҗларны] мәрхәмәт илән шад әйләде (кылды)
13. Тарих миладин 1842 елда майның
14. 22 көнендә зөлхиҗәнең 4 көнендә сәһшинбә көн
15. мәдфүн (җирләнде)

### *VI таш*

1. Һуввәл-Халлакуль-Бакый
2.Ля иләһа илләллаһ Мүхәммәдү рәсулүллаһ саллаллаһу (аңа Аллаһның саләте булсын)
3. Әл-мәрхумә Бибихөснижиһан бинтү
4. Шәйхелислам дөхтәре Сәрвиҗиһан бинтү
5. мөфти әз-заман сахибел-җаһ вәс-сәха вәл-фәнаэ фи һәза
6. әл-вилдани дарел-фәнадан дарел-бәкайа рихләт
7. әйләде 17 яшендә майның 11 көнендә
8. 1854 елында мәдфүн улды казаи
9. әсман (язмыш) вә тәкъдире раббани (Раббының тәкъдире) юлыкып (юлыгып) күп ел-
10. лар мәсруг зәхмәте (эпилепсия чире) илән мөбтәла улып (дучар булып) ахыр
11. әл-өмур (ахыр чиктә) зәгыйфәнең әҗәленә сәбәп улды
12. Догаи Фатиха

### *VII таш*

*Алгы ягында*



1. Һуввәл-Халлакуль-Бакый
2. Ля иләһа илләллаһ Мүхәммәдү рәсулүллаһ
3. Нәгузу билләһи Тәгалә мин фитәнил-кабри вә мин
4. әһвалил-хәшри вән-нәшри вә нәсьәлүллаһа
5. әл-мәгъфирәтә вәл-гуфрана билҗәннәти вәр-рәхмәти вәр-ризвани әл-мәрхумә
6. Хәбибҗамал бинтү Кырымкай (кызы) хәлале Мөхәммәдрәхим (хатыны) әл-мөләккаб
7. бил-Кантун (кушаматлы) дарелфәнадан дарел-бәкайа интикаль әйләде (күчте)
8. йитмеш яшендә салихалардан (изге, гөнаһсызлардан) ирде (иде) хосусан 4 ел микъдары (4 ел дәвамында)

9. зәүҗендән (иреннән) әрәмлә (тол) калып фирагатьлек (аерылу) илән гомерен сәҗҗадә (намазлык)
10. өстендә тәгать (намаз-нияз) вә гыйбадәт илән кичерде догачылар ике
11. угылы Шәйхелислам вә Шәйхелмәрдан вә бер кызы Бибихөсни[җиһан]
12. ны куйды […] мәхәббәт сәгадәттә дәүләт солтанәттә...

*Арткы ягында*

1. Әсмәү әсхабил-кәһәф (Мәгарә ияләренең исемнәре)
2. Йәмлиха Мәксәлмина Сәлмина Шаднуш
3. Дәбәрнуш Мартуш Кәгаш Татыюш Кыйтмир
4. Тарих румийә 1857 елда фибралның 24 көне
5. мәдфүн Фатиха

### *VIII таш*

*Алгы ягында*

1. Кәфә бил-мәүти вагыйзан
2. Ля иләһа илләллаһ Мүхәммәдү рәсулүллаһ
3. Нәгузу билләһи Тәгалә мин фитәнил-кабри вә мин[әһвалил-хәшри вән-нәшри вә нәсьәлүллаһа]
4. әл-мәгъфирәтә вәл-гуфрана бил-җәннәти вәр-рәхмәти вәр-ризвани
5. [Әл]-мәрхум Шәйхелмәрдан бине Мөхәммәдрәхим дарел-фәнадан
6. дарел-бәкайа интикаль әйләде 43 ел гомер кичерде
7. Догачылар әүладлары (балалары) ике кызлар вә әһлиясе (хатыны) калды
8. Әгъниялар гөруһындан (байлар катлавыннан) вә […] фөругындан (тармагыннан) ирде (иде)
9. вә бабе сәха (юмартлык ишеге)[…] вә фөкараи мөслиминләргә (фәкыйрь мөселманнарга) зиядә (күп)
10. мәрхәмәте […] ...нлы улмакында (булуында) гасырында назыйре (тиңдәше)



11. вә әмсале (охшашлары) улынмады (булмады) Илаһи рәхмәте Хак (Хак Тәгаләнең рәхмәте) вә фазле Рабб (Раббының мәрхәмәте һәм юмартлыгы) үзә
12. үзрә мөстәгърак (чумдырылган) улгай (булса иде) Амин Фатиха

*Уң кырында*

1. Тарихе румийә 1858 нче елда синтәбер аеның
2. 4 яүмендә (көнендә) мәдфүн Фатиха

*Сул кырында*

Йа вакыйфан бикабри мүтәфәккирән биәмри биләмси күнтү мисликә гадән тәсыйру мисли

### *IX таш*

*Алгы ягында*

1. Кәфә билмәүти вагыйзан
2. Ля иләһа илләллаһ Мүхәммәдү рәсулүллаһ
3. саллаллаһу Тәгалә галәйһи вә сәлләм (аңа Аллаһы Тәгаләнең саләте вә сәламе булсын)
4. Әл-мәрхумә вәл-мәсу[нә] (якланган) вәл-мәгъсумә (гөнаһсыз)
5. Бибиәсма туташ бинте Шәйхеззаман
6. дарел-фәнадан дарел-бәкайа интикаль
7. әйләде тарих мәсихийә (милади) 1872
8. нчы елда априлнең 19 көнендә
9. вөҗүдә кәлеп (туып) 1873 нче елда
10. мартның 31 нче көнендә мәдфүн улды (җирләнде)

*Сул кырында*

Йа вакыйфан бикабри мүтәфәккирән биәмри биләмси күнтү мисликә гадән тәсыйру мисли

### *X таш*

*Алгы ягында*

1. Кәфә билмәүти вагыйзан
2. Ля иләһа илләллаһ Мүхәммәдү рәсулүллаһ
3. Нәгузу билләһи Тәгалә мин фитәнил-кабри вә мин әһвали
4. л-хәшри вән-нәшри вә нәсьәлүллаһа Тәгаләл-мәгъфирәтә вәл-гуфрана
5. вә әдхилнәл-җәннәтә йа Рахман (Аллаһының сыйфаты – мәрхәмәтле) әл-мәрхүмә [...] Хәнифә
6. бинте Ягъкуб (кызы) зәүҗәте Мөхәммәдьяр (хатыны) бине Мөхәммәдшәриф

7. дарел-бәкайа интикаль әйләде 32 яшь гомер кичерде
8. 1874 елда майның әүвәл көнендә мәдфүн
9. улды догачылар ике угыл вә ике кызлар калды
10. Габидә (гыйбадәт кылучы) вә саҗидә (Аллаһе Тәгаләгә сәҗдә кылучы) вә салиха (изге, гөнаһсыз) вә сәхияләрдән (юмартлардан) иде
11. Аллаһуммәгъфирләнә вә лиҗәмигыйль-мөслимин (Йа Рабби безне һәм барча мөселманнарны кичер!) Амин Фатиха

*Уң кырында*

Безә (безгә) Коръән укып багышлаясыз гомер тиз үтәрен сагышлаясыз

*Сул кырында*

Йа вакыйфан бикабри мүтәфәккирән биәмри биләмси күнтү мисликә гада тәсыйру мисли

***XI таш***

1. Кәфә билмәүти вагыйзан
2. Ля иләһа илләллаһ Мүхәммәдү рәсулүллаһ
3. Калә Рәсулүллаһ (Рәсулүллаһ әйтте) саллаллаһу Тәгалә галәйһи вә сәлләм (Аллаһе Тәгаләнең рәхмәте һәм сәламе аңа төшсен!)
4. Әл-кабрү имма раузату мин риязил-җәннәт әү хәфрәтү[….] (кабер ул йә җәннәт бакчалырыннан бер бакча йә ....чокыр)
5. Аллаһуммәҗгаль кабрәһү һәзаль-мәйити мин риязил-җәннәти (Йа Рабби! Бу мәетнең каберен җәннәт бакчасы кылсаң иде!)
6. Әл-мәрхүм штаб-ротмистр Мөхәммәдшәриф Бәязид
7. [угылы] Солтанов дарел-бәкайа рихләт әйләде (бакый йортка күчте)
8. [....]ы 1874 нче ел[да]

***XII таш***

1. Кәфә билмәүти вагыйзан
2. Ля иләһа илләллаһ Мүхәммәдү рәсулүллаһ
3. саллаллаһу галәйһи вә сәлләм
4. Әл-мәрх[үм] [….] әл-җинан (җәннәтләр)
5. [….] бине хәзрәт
6. [….] Солтанов
7. [….] интикаль
8. [әйләде] вафат 188[1]
9. елда синтәбер аеның 12 көнендә мәдфүн (җирләнгән)
10. Фатиха

**_XIII таш_**



1. Ля иләһа илләллаһ
2. Мүхәммәдү рәсулүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм
3. Нәгузу билләһи мин фитәнил-кабри вә һәүлил-хәшри
4. вән-нәшри вә нәсьәлүллаһа Тәгаләл-мәгъфирәтә вәл-гуфрана
5. бил-җәннәти вәр-ризвани әл-мәрхүм Габделҗәббар бине Габдеррәхим
6. Солтанов дарел-фәнадан дарел-бәкайа рихләт
7. әйләде 54 яшендә 1884 сәнәи мәсихийә (милади)
8. 15 гыйнварда мәдфүн улды
9. Җәгаләллаһу Тәгалә кабрәһу нуран вә сираҗән мөнирән (Аллаһы Тәгалә аның каберен нурлы һәм якты итсә иде!)
10. Догачы угылы Шаһиҗиһан[дан] тәзкирәседер (бу урында – истәлеге)
11. Фатиха

**_XIV таш_**

1. Йа Аллаһ
2. Һәзаль-кабрү (бу кабер)
3. Ля иләһа илләллаһ
4. Мүхәммәдү рәсулүллаһ
5. Мән кәнә йатлубу гыйбрәтән
6. фәл-мәкабирү йәкфиһ (гыйбрәт эзләгәнгә каберләрне күрү дә җитә)
7. Һувә (Ул=Аллаһ)
8. Сахибүл-җуд вәл-ихсан вә сахибүл-кәрәм вәл-әнам (юмартлык, игелек,олы җанлылык иясе)
9. Шәйхелислам әл-мәрхүм вәл-мәгъфур (кичерелгән, гафу ителгән) ибне Мәхәммәдер[рәхим]
10. Солтанов 74 яшендә гомер сөреп 1888 сәнәдә (елда)
11. 13 нче хәмәлдә (Иранда гамәлдә булган кояш елының беренче ае; март-апрельгә туры килә) вафат булып 15нче хәмәлдә мәдфүн булды

12. Догачылары дүрт угыл вә өч кызлары тәрк
13. әйләде (калдырды) голәма вә фөкара вә толәбайа (галимнәргә, фәкыйрьләргә һәм шәкертләргә) [….]

### *XV таш*

*Алгы ягында*

1. Ля иләһа илләллаһ
2. Мүхәммәдү рәсулүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм
3. Каләллаһу Тәгалә (Аллаһы Тәгалә әйтте) күллү нәфсин заикатүл-мәүти (һәрбер җан үлем тәмен татыячак)
4. Нәгузу билләһи мин газабил-кабри (кабернең газабы) вә
5. һәүлил-хәшри вә нәсьәлүллаһа Тәгалә
6. әл-мәгъфирәтә вәл-гуфрана [….]
7. Мөхәммәдсадыйк 1823 елгы 5 нче априлдә туган
8. 1890 нчы елда вафат Аллаһ рәхмәт әйләсен (итсен)

*Арткы ягында*

1. И туктагучылар безем
2. мәзарымызда (безнең каберебездә) белер булмадыңыз
3. мы әлбәттә белерсез
4. Хакыйкатьдә үлем без
5. вә сезгә бәрабәр (бергә) килгүчедер
6. Алдамасын сезне
7. дөнья аның [өен]
8. хакыйкатьтә сез бина
9. кыласыз вә ан ки (ул вакытта)
10. үлем бозадыр
11. бинаңызны
12. Әгәр дә сез [итсәңез?]
13. бу илгә ягъни кәлсәңез
14. безем (безнең) каберстанга әлбәттә таныр
15. сыз
16. Хезмәт итдергән
17. Байла (бай белән) хезмәтчеләр
18. бердер

*Уң кырында*

Дварянин Мөхәммәдсадыйк Мөхәммәдҗан угылы

***XVI таш***



1. Ля иләһа илләллаһ Мүхәммәдү рәсулүллаһ
2. Әл-мәрхүмә вәл-мәгъфүрә
3. Бибинәккаш бинте Салих (кызы) зәүҗәи
4. мирза Сөләйман Батыршин (хатыны)
5. дарел-бәкайа интикаль кылды (мәңгелек йортка күчте)
6. 1892 нче сәнәдә кавәснең (ирани кояш елының тугызынчы ае; ноябрь-декабрьгә туры килә)
7. 11 яүмендә вафат булды
8. 28 нче [ну....]
9. [….]
10. рәхмәт [….]
11. 65 яшьтә Әл-фатиха

***XVII таш***

*Алгы ягында*

1. Бу кабердә
2. мәдфүн Габделхәлим
3. Габделкәрим угылы
4. Күҗәкәдән Мәчтигә
5. килеп мөәззин булып
6. торды 1832 нче елгы
7. фибралдә вөҗүд[ә] кәлеп (туып) 1900 нче
8. елгы 30 нчы июлдә....

*Арткы ягында:* XV таштагыча

***XVIII таш***

*Алгы ягында*

1. Ля иләһа илләллаһ
2. Мүхәммәдү рәсулүллаһ саллаллаһу галәйһи
3. вә сәлләм каләллаһу Тәгалә күллү нәфсин
4. заикатүл-мәүти нәгузу билләһи мин
5. газабил-кабри вә һәү[л]ил-хәшри вә нәсьәлү
6. Аллаһа Тәгаләл-мәгъфирәтә вәл-гуфрана
7. Мәдфүнә (җирләнгән) [….] Гөл Габде

8. лкаһир кызы Мөхәммәдсадыйк
9. Солтанов хәләле (хатыны) исән (?) [....]
10. әүвväлендә төшкән

*Артк ы ягында:* XV таштагыча

*Уң кырында*

85 яшендә 1908 нче елда

**XIX таш**

*Алгы ягында*

1. Ля иләһа илләллаһ Мүхәммәдү рәсулүллаһ
2. саллаллаһу галәйһи вә сәлләм каләллаһу Тәгалә
3. Күллү нәфсин заикатүл-мәүти (һәрбер җан үлем тәмен татыячак) нәгузу билләһи
4. мин газабил-кабри вә әһвалил-хәшри вә нәсьәлү
5. Аллаһа Тәгаләл-мәгъфирәтә вәл-гуфрана бу
6. кабердә мәдфүн Шәйхзаман
7. Шәйхелислам угылы вөҗүдә кәлде (туды)
8. 1841 сәнәдә 1908 сәнәдә 18нче дикабердә
9. [....]

*Арткы ягында:* XV таштагыча

*Уң кырында*

Дарел-фәнадин дарел-бәкайа рихләт әйләде

***XX таш***

1. Һуввәл-Халлакуль-Бакый (Ул барлык нәрсәне Яратучыдыр, Мәңгедер)
2. Ля иләһа илләллаһ Мүхәммәдү рәсулүллаһ
3. Нәгузу билләһи мин газабил-кабри вә мин әһвали
4. әл-хәшри вә нәсьәлүллаһа әл-мәгъфирәтә вәл-гуфрана
5. бир-рәхмәти вәл-мәгъфирәти вәр-ризвани әл-мәрхүмә
6. Фәрхибану Рәхмәтуллаһ кызы мөфти
7. әһлел-ислам Габдессәлам хәзрәтләренең зәүҗәсе (хатыны)
8. дарелбәкайа рихләт әйләде 70 [....]

***XXI таш***

*Алгы ягында*

1. Ля иләһа илләллаһ



2. Мүхәммәдү рәсулүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм
3. Калә Аллаһу Тәгалә күллү нәфсин заикатүл-мәүти
4. Нәгузу билләһи мин газабил-кабри вә әһва
5. лил-хәшри вә нәсьәлүллаһа Тәгаләл-мәгъфирәтә
6. вәл-гуфрана бу кабердә Гайнелхәят
7. мулла Гыйльман кызы вөҗүдә кәлде (туды) 1846 сәнәдә
8. июль 2 сендә Кәзкәйдән Мәчтигә....

*Арткы ягында:* XV таштагыча

***XXII таш***

*Алгы ягында*

1. Кәфә билмәүти вагыйзан (үлем иң ышандыргыч вәгазь)
2. Ля иләһа илләллаһ Мүхәммәдү рәсулүллаһ
3. саллаллаһу галәйһи вә сәлләм
4. Аллаһуммәҗгаль кабрә һәзаль-мәйити мин риязил
5. -җәннәти әл-мәрхүм Мөхәммәдгәрәй
6. Габделҗәлил угылы дарел-фәнадан
7. дарел-бәкайа рихләт әйләде
8. 80 ел гомер кичерде Фатиха
9. [….]

*Арткы ягында*

1. Догачылары
2. ике угылы биш кыз[ы] вә зәүҗәсе (хатыны)

*Уң кырында*

Безә Коръән укып багышлаясысыз гомер тиз үтәрен сагышлаясысыз

*Сул кырында*

1. Йа вакыйфан
2. бикабри
3. мүтәфәккирән биәмри
4. Бил-әмси күнтү
5. мислико

6. тәсыйру гадән
7. мисли

***XXIII таш***

1. Йа вакыйфан бикабри
2. [....]

***XXIV таш***

1. Әд-дүнья сәгатән (дөнья бер сәгатьлектер)
2. Гаҗҗилү бит-тәүбәти кабләл-мәүти (үлгәнче тәүбә кылырга ашыгыгыз)
3. вә гаҗҗилү бис-саләти кабләл-фәүти (вафат булганчы намаз укырга ашыгыгыз)
4. Раббем Аллаһу Әхәдү нәбием Мөхәммәд
5. вә динем ислам
6. Габделмәлик бине Габдессадир

***XXV таш***

*Алгы ягында*
[....]

*Арткы ягында:* XV таштагыча

*Уң кырында*
[бәка]йа рихләт әйләде Аллаһы Тәгалә мәркаден (каберен) нур кылгай Амин

* * *

Актаныш төбәгендә археографик тикшеренүләр – гарәп язулы кулъязма һәм басма китапларны табу һәм өйрәнү – күләмле һәм системалы рәвештә алып барылмаса да, бу өлкәдә табышлар һәм казанышлар юк түгел. Район авылларында урта гасыр болгар-татар әдәбияты җәүһәре «Кыйссаи Йосыф»ның 19 кулъязма күчермәсе табылуы үзе генә ни тора!

1960–1970 елларда Казан дәүләт университеты археографик экспедициясе әгъзасы Альберт Фәтхи[1] районның күп кенә

[1] Тумышы белән Актаныш районының Такталачык авылыннан. Казан университетының Н. Лобачевский исемендәге гыйльми китапханәсендә сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге мөдире булып эшләгән.

авылларында йөреп, шактый санда кулъязма һәм басма китап табуга ирешә. Мәсәлән, ул Габделкадыйр Габделҗәлил углының мәшһүр «Рисаләи болгарийә» (1851) исемле сәяхәтнамәсенең 4 нөсхәсен таба[1]. 1972 елның җәендә А. Фәтхи Актаныш һәм Мөслим районнары авылларында XVIII–XIX гасырларда төзелгән кулъязмаларга, XX йөз башларына караган шәкерт дәфтәрләренә тап була. Актаныш төбәгеннән КДУ китапханәсенә ул алып кайткан китаплар тупламасы – нәфис әдәбият үрнәкләре, стилистика һәм грамматика буенча хезмәтләр, фәлсәфә һәм хокук фәненә багышланган рисаләләр, математика, җирле тарих һәм география дәреслекләре, тыйбби әсәрләр – барлыгы 120 гә якын археографик берәмлек тәшкил итә[2]. Атаклы археограф бу табышларга үзе төзегән тасвирламаларда һәм аерым мәкаләләрендә анализ бирә, Актаныш төбәге авылларында яшәгән яки эшләгән күренекле шәхесләр, җөмләдән Аеш авылында укыткан Әбүкәрәм Шакиров турында яза[3].

1969 елда оештырылган экспедиция вакытында районның Такталачык, Зөбәер, Куян авыллары тарихнамәләре табыла. Хәзерге көндә алар Идел буе (Казан) федераль университетының гыйльми китапханәсендә саклана. Әлеге эзләнүләр төрле сәбәпләр аркасында киң кулланылышка керми торды. 2009 елның җәендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Актаныш районына оештырылган фәнни экспедиция бу юнәлештә яңа эзләнүләр алып барып, күп нәрсәләргә ачыклык кертте.

Шунысын да искәртик: еллар үткән саен, борынгы кулъязмаларны табу кыенлаша бара. Моны төрлечә аңлатып булыр иде.

---

[1] *Фәтхи Альберт.* Мәкаләләр, истәлекләр. – Казан, 2007. – Б. 102.

[2] Шунда ук. – Б. 147–148.

[3] *Фәтхи А. С.* Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары. – Казан, 1986. – Б. 125–126.

Әбүкәрәм Шакиров (1885–1942), билгеле булганча, озак еллар буена Башкортстан хакимиятендә хезмәт иткән Мидхәт Закир улы Шакировның әтисе белән бертуган абыйсы; Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган; Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсендә эшләгән елларында (1935–1941) татар һәм көнчыгыш кулъязмаларын фәнни эшкәртү һәм системага салу белән шөгыльләнгән.

Кулъязмалар аз күләмдә табылуның иң җитди сәбәбе – иске китапларның начар шартларда сакланып, туза, таркала баруы һәм күп очракта кирәксез әйбер дип юкка чыгарылуы. Совет хакимияте чорында гарәп язуы бары тик дини язуга тиңләштерелгәнлектән, ул шрифтта язылган яки басылган китаплар, газеталар һәм журналларның «реакцион әдәбият» исемлегенә кереп, аларны саклауның җинаять саналуы (бигрәк тә 1930–1950 елларда) барыбызга да мәгълүм. Шуңа да карамастан укымышлы һәм милләт җанлы кешеләр ата-бабадан калган язма мирасны ничек тә саклап калырга тырышканнар. Сәяси-мәдәни «җепшеклек» шартларыннан файдаланып, 1963 елда Казан дәүләт университеты оештыра башлаган археографик экспедицияләрнең нәтиҗәле эшләвендә дә әлеге ватандарларның өлеше зур.

Яңа сәяси вазгыятькә бәйле рәвештә халкыбызның милли үзаңы уяну соңгы 20 ел эчендә гарәби язулы китапларга мөнәсәбәтне уңай якка үзгәртте. Әмма бу еллар эчендә сакланып калган китаплар сан ягыннан бик күпкә азаерга өлгергән иде инде.

Әлеге тискәре факторларны исәпкә алганда, 2009 елгы экспедиция дәвамында 10 көн эчендә Актаныш районында табылган басма һәм кулъязма китапларның (шулай ук китап фрагментларының) сан ягы канәгатьләнерлек булды, дип әйтергә мөмкин. Барлыгы 200 гә якын гарәп язулы берәмлек тупланды. Арада байтак кына кулъязма китаплар, кулъязма фрагментлар һәм өзекләр бар.

Кагыйдә буларак, археографик экспедицияләр вакытында иң күп табылган материал – мәгариф өлкәсенә караган китаплар. Бу бик табигый, чөнки мәдрәсәләр һәм мәктәпләрдә уку-укыту процессын тәэмин итү өчен, күп санда дәреслекләр таләп ителгән. Алар арасында гарәп, фарсы, төрки телләр буенча басма һәм кулъязма китаплар, уку ярдәмлекләре, гүзәл язу (хөсне хат), мантыйк, фикыһ, кәлам, география, тарих, арифметика дәреслекләре һ. б. бар. Атеизм пропагандасы куәтле булган совет чорында, «элекке мәдрәсәләрдәге дин укытуны чагылдырудан башкага ярамый» дип, мондый китапларга игътибар ителми иде диярлек. Хәзер исә алар да мәдәниятебезнең кадерле ядкярләре дип бәяләнә.

*КУШЫМТА*

## «Ревизская сказка» мәгълүматлары буенча XIX гасыр урталарында Мәчти авылында яшәгән кешеләр исемлеге

Шәйхелислам Мөхәммәтрәхим угылы Солтанов, отставкадагы сотник, дворян нәселеннән, 42 яшендә.

Шәйхизаман Шәйхелислам угылы Солтанов, 17 яшендә.

Әмир Тимер Шәйхелислам угылы Солтанов, 14 яшендә.

Шәйхелмәрдан Мөхәммәтрәхим угылы Солтанов, отставкадагы сотник, нәселдән дворян, 1858 елда вафат.

Мөхәммәдшәриф Бәязит угылы Солтанов, сотник, нәселдән дворян, 52 яшендә.

Арыслангали Мөхәммәтшәриф угылы Солтанов, сотник, 26 яшендә.

Мөхәммәдьяр Мөхәммәтшәриф угылы Солтанов, урядник, 20 яшендә.

Шаһиәхмәт Бәязит угылы Солтанов, хорунжий, нәселдән дворян, 1852 елда вафат.

Сәрвиҗиһан Габдессәлам кызы, Шәйхелислам Солтанов хатыны, дворян, 42 яшендә[1].

Мәрьям Шәйхелислам кызы, 9 яшендә.

Гайниҗамал Шәмсетдин кызы, Шәйхелмәрдан Солтанов хатыны, 39 яшендә.

Гайшә Шәйхелмәрдан кызы, 11 яшендә.

Фатыйма Шәйхелмәрдан кызы, 9 яшендә.

Бану (?) Габдеррәшит кызы, Мөхәммәтшәриф Солтанов хатыны, 50 яшендә.

Мәрхәба Мөхәммәтшәриф кызы, 13 яшендә.

Гайшә Сәедбаттал кызы, Арыслангали Солтанов хатыны, 24 яшендә.

Габдессаттар Габделҗәлил угылы Солтанов, 14 класс чиновнигы, 1852 елда вафат.

---

[1] Габдессәлам кызы Сәрвиҗиһанның кабер ташында аның үлем датасы 1842 ел дип куелган. Хәлбуки, «Ревизская сказка»да (халык санын алу документында) күрсәтелгәнчә, ул 1859 елда да әле исән булган. Моны ничек аңлатырга? Башка фактларны исәпкә алганда, соңгы дата дөресрәк күренә. Сәрвиҗиһан 1817 елда, ягъни, атасына чама белән 43 яшь булганда туган. Кабер ташына ышансаң, ул 25 яшендә үлгән булып чыга, бу исә мөмкин күрелми. Таштагы «илле яшендә үлде» дигәнне исәпкә алсаң, мөфти Габдессәлам кызы Сәрвиҗиһан 1867 елда вафат иткән булса кирәк.

Шаһихәйдәр Габдессаттар угылы, 38 яшендә.

Шаһимөхәммәт Шаһихәйдәр угылы, 11 яшендә.

Шаһимәрдән Шаһихәйдәр угылы, 2 яшендә.

Шәрәфетдин Габдессаттар угылы, 35 яшендә.

Фәридетдин Шәрәфетдин угылы, 2 яшендә.

Габделгаффар Габделҗәлил угылы Солтанов, 14 класс чиновнигы, 63 яшендә.

Мөхәммәтҗан Габделҗәлил угылы Солтанов, зауряд-есаул, 58 яшендә.

Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтҗан угылы, 35 яшендә.

Әхмәтшаһ Мөхәммәтҗан угылы, 1854 елда хәрби хезмәткә алынган, 29 яшендә.

Мөхәммәтгалим Мөхәммәтҗан угылы, 24 яшендә.

Сафура Габделвахит кызы, Габдессаттар Солтанов хатыны, 62 яшендә.

Җәмлиха Урманай кызы, Шаһихәйдәр Солтанов хатыны, 33 яшендә.

Гыйззелбанат Шаһихәйдәр кызы, 8 яшендә.

Хәйрелбанат Шаһихәйдәр кызы, 5 яшендә.

Шәмсиҗамал Кибәз кызы, Шәрәфетдин Солтанов хатыны, 30 яшендә.

Шәмсикамал Шәрәфетдин кызы, 6 яшендә.

Фатыйма Мөхәммәт кызы, Габделгаффар Солтанов хатыны, 58 яшендә.

Гөлҗамал Шаммаз кызы, Мөхәммәтҗан Солтанов хатыны, 58 яшендә.

Мөхәммәтгәрәй Габделҗәлил угылы Солтанов, зауряд-сотник, дворян исемен дәгъвалаучы, 55 яшендә.

Шаһисолтан Мөхәммәтгәрәй угылы, урядник, 21 яшендә.

Шаһимөхәммәт Мөхәммәтгәрәй угылы, 19 яшендә.

Габдеррәхим Габделҗәлил угылы Солтанов, 14 класс чиновнигы, 1857 елда вафат.

Габделвахит Габделҗәлил угылы Солтанов, 14 класс чиновнигы, 72 яшендә.

Мөхәммәтвәли Габделвахит угылы, сотник, 1857 елда вафат.

Дәүләтгәрәй Габденнасыйр угылы Солтанов, зауряд-есаул, 52 яшендә.

Батыргәрәй Дәүләтгәрәй угылы, 21 яшендә.

Солтангәрәй Дәүләтгәрәй угылы, 19 яшендә.

Шәйхелбостан Дәүләтгәрәй угылы, 14 яшендә.

Шәйхелгәрдән Дәүләтгәрәй угылы, 9 ярым яшендә.

Шаһимәрдан Дәүләтгәрәй угылы, 7 яшендә.

Шәмсиҗиһан Габдеррәшит кызы, Мөхәммәтгәрәй Солтанов хатыны, 44 яшендә.

Бибишәрифә Мөхәммәтгәрәй кызы, 13 яшендә.

Бибигазизә Мөхәммәтгәрәй кызы, 11 яшендә.

Бибисәгыйдә Мөхәммәтгәрәй кызы, 8 яшендә.

Бибифатыйха Мөхәммәтгәрәй кызы, 5 яшендә.

Гөлдәстан Нигъмәтулла кызы, Габдеррәхим Солтанов хатыны, 58 яшендә.

Әсхабҗамал Мөхәммәтшәриф кызы, Габделвахит Солтанов хатыны, 58 яшендә.

Маһитап Фәйзулла кызы, Мөхәммәтвәли Солтанов хатыны, 27 яшендә.

Зөләйха Мөхәммәтвәли кызы, 5 яшендә.

Бибифатыйма Мөхәммәтвәли кызы, 2 яшендә.

Бибифәхриҗиһан Дәүләтгәрәй кызы, 15 яшендә.

Бибифәрхибану Дәүләтгәрәй кызы, 12 яшендә.

Шәнгәрәй Габденнасыйр угылы Солтанов, зауряд-хорунжий, 1857 елда вафат.

Бәхтигәрәй Габденнасыйр угылы Солтанов, зауряд-сотник, 47 яшендә.

Әхмәтгәрәй Габденнасыйр угылы Солтанов, урядник, 36 яшендә.

Ибраһим Габделхаликъ угылы Солтанов, урядник, 38 яшендә.

[…] Ибраһим угылы, 8 яшендә.

Исмәгыйль Габделхалик угылы Солтанов, 34 яшендә.

Хөсниҗиһан Мөхәммәтгали кызы, Шәнгәрәй Солтановның хатыны, 38 яшендә.

Бибиҗиһан Шәнгәрәй кызы, 5 яшендә.

Бибигафифә Габидулла кызы, Бәхтигәрәй Солтановның хатыны, 40 яшендә.

Шәкәрбану Мөхәммәтрәхим кызы, Әхмәтгәрәй Солтановның әнисе, 70 яшендә.

[…], Әхмәтгәрәй Солтановның хатыны, 39 яшендә.

Бибигөлчәһрә Әхмәтгәрәй кызы, 9 яшендә.

Гөлҗиһан Ибраһим кызы, Ибраһим Солтановның хатыны, 39 яшендә.

Нәфисәҗиһан Ибраһим кызы, 11 яшендә.

Хөсниҗиһан Ибраһим кызы, 5 яшендә.

Гайниҗиһан Ибраһим кызы, 1 яшендә.

[…]гөл, Габделкаһир кызы, Исмәгыйль Габделхаликовның хатыны, 28 яшендә.

Газизәбану Исмәгыйль кызы, 7 яшендә.

Шәмсибану Исмәгыйль кызы, 4 яшендә.

Шәмсиҗамал (?) Исмәгыйль кызы, 1 яшендә.

# АКТАНЫШ РАЙОНЫ АВЫЛЛАРЫ

*Гөлфия Һадиева*

**АКТАНЫШ РАЙОНЫ** Татарстан Республикасының ерак көнчыгышында урнашкан, Башкортстан Республикасы белән чиктәш. 1930 елның 10 августында оештырыла. 1963 елның 1 февралендә таркатыла, биләмәсе Минзәлә районына бирелә. 1965 елның 12 гыйнварында яңадан торгызыла. Мәйданы 2037,8 км$^2$. Халкы – 1989 елда 33,5 мең кеше (96,4% – татарлар), 2019 елда 29,8 мең кеше. Үзәге – Актаныш авылы. Рельефы – калкулыклы тигезлек (биеклеге – Кама һәм Агыйдел үзәннәрендә 60 м чамасы, көньякта 160–235 м). Кама елгасы (Түбән Кама сусаклагычы), Агыйдел елгасы һәм кушылдыгы Сөн елгасы ага. Район күлләргә бай. Төньяк-көнбатышта – Күләгәш сазлыгы. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән, көлсуланган һәм кара туфраклы, районның үзәк өлешендә соры урман туфраклы. Территориясенең 9,6% ында урман. Торф, чуер-таш, ком ятмалары бар.

Борынгы заманнарда татарларда тормышка чыккач та озак вакыт бала тапмаган киленгә Акланыш исеме кушылган. *л~т* тартыклары көчеше нәтиҗәсендә, Актаныш формасына ия булып, Актаныш авылы һәм районы атамасында сакланган[1].

**АДАЙ** авылы район үзәгеннән 35 км көнбатыштарак, Түбән Кама сусаклагычы астында калган зона чигендә. 1747 елдан

[1] *Саттаров Г. Ф.* Татар антропонимикасы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1990. – Б. 94.

мәгълүм. 1989 елда 380 кеше (татарлар), 2000 елда 337 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Адай авылы атамасының нигезендә «Адай» дигән борынгы төрки кеше исеме ята. Бу авылга Адай дигән кеше нигез салган булырга тиеш. «Борынгы төрки сүзлектә adaj: 1) «птенец»; 2) перен. «дитя», «птенчик» мәгънәсендә кулланылуы күрсәтелгән[1]. «Кошчык» күчерелмә мәгънәсендә «бала» төшенчәсен белдергән adaj сүзе башта дөньяга яңа туган ир балага иркәләп эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзе буларак кулланылган, аннан соң кеше исеменә әверелеп киткән[2].

**АЕШ** авылы район үзәгеннән 11 км көньяктарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Биҗады суы буенда, Башкортостан Республикасы чигендә. 1745 елдан мәгълүм. 1989 елда 524 кеше (татарлар), 2000 елда 468 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, мөгезле эре терлек, сарык асрау.

Авыл атамасы борынгы төрки татар Аеш «ай иш, ай ише, айга иш (тиң) бала» кеше исеменә нисбәтле барлыкка килгән[3].

**АККҮЗ** авылы район үзәгеннән 27 км көньяктарак, Сөн елгасы буенда урнашкан. Авылга XVII йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1989 елда 354 кеше (татарлар), 2000 елда 303 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Татар антропонимиконында яңа туган баланың күз, бит, чәч, каш, керфек һ.б. әгъзасының төсенә нигезләнеп, байтак кына кеше исемнәре барлыкка килгән. Кеше әгъзасы атамасына ак сүзе кушылу юлы белән Аккүз дигән кеше исеме барлыкка килгән. Аккүз авылы атамасы Аккүз дигән кеше исеменә нисбәтле.

**АКТАНЫШ** авылы, Актаныш районы үзәге. Татарстанның көнчыгыш төбәгендә (Казаннан 381 км), Башкортстан Республикасы чигендә, Агыйдел елгасының түбән агымы буенда урнашкан. Казан – Екатеринбург тимер юлындагы Камбарка станциясеннән 66 км көньяктарак урнашкан. 1715 елдан мәгълүм.

---

[1] Древнетюркский словарь. – Л.: Наука, 1969. – С. 8.

[2] *Саттаров Г. Ф.* Татарстан АССРның антропонимнары: Татарстан авылларының исемнәре. – Казан: Казан ун-ты, 1973. – Б. 70.

[3] *Саттаров Г. Ф.* Татар топонимиясе. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1998. – Б. 39.

1930–1963 елларда һәм 1965 елдан – район үзәге, 1988–1991 елларда – шәһәр тибындагы посёлок. 1989 елда 6814 кеше (татарлар), 2000 елда 8367 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Карагыз: Актаныш районы.

**АКТАНЫШБАШ** авылы район үзәгеннән 3 км көнбатыштарак урнашкан. Авылга XVIII йөздә нигез салына. 1989 елда 224 кеше (татарлар), 2000 елда 311 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек. Авыл халкы сөйләвенчә, Актаныш Нөркә авылыннан аерылып чыга. Нөркә урманы урынында урнашкан була. Актаныш елгасы ярлар ясап, җирне ярып, Куян ягына күчә бара. Актанышбаш янында аның ярлары нык текәләнә. Хәзерге Нөркә урманына каршы як Иске йортка кадәр барган. Беренче тапкыр кый кешесе килеп урнашканга күрә, аны *Кый авылы чокыры* дип йөрткәннәр. Бу урыннарда ямьяшел чирәм булган, шул яшел чирәм өстеннән су җәйрәп аккан. Аның суы көмеш кебек саф, чиста, ап-ак булган. Бу елга ак та, таныш та, диләр авыл кешеләре. Авылның исеме шуннан Актанышбаш булган.

Карагыз: Актаныш районы.

**АПАЧ** авылы район үзәгеннән 37 км көньяк-көнбатыштарак, Агыйделнең сул кушылдыгы Шәбез суының югары агымы буенда урнашкан. 1731 елда нигез салына. 1989 елда 242 кеше (татарлар), 2000 елда 223 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек. XVIII гасыр башларында Әтәс һәм Апач авылына бер чорда нигез салынган дип барыла. Авылның беренче кешеләре Әтәс һәм Апач Әгерҗе районы Исәнбай авылыннан күчеп килгәннәр. Аларны кан кардәшләр булган дигән фараз бар. Патшага тугры хезмәте өчен генерал дәрәҗәсендәге Апачка күп кенә җир биләмәләре бүлеп бирелә. Ул шушында авылга нигез сала. Күп кенә атлар тота[1].

**АХУН** авылы, Актаныш районында, район үзәгеннән 28 км көньяктарак, Башкортстан Республикасы чигендә. XVIII йөздә

---

[1] *Закиров Ф. Х.* Апачмы әллә Апасмы?: авылым тарихыннан. – [Яр Чаллы]: Новости Мира, 2007.

нигез салына. 1989 елда 279 кеше (татарлар), 2000 елда 274 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Ойконим антропонимга нигезләнеп барлыкка килгән. *Ахун* – фарсы чыгышлы кеше исеме: «1) туры юлга күндерүче; 2) остаз, кардәш» мәгънәләренә ия.

**ӘҖӘКҮЛ** район үзәгеннән 5 км төньяк-көнбатыштарак. Агыйдел елгасы ярындагы пристань. 1722 елдан мәгълүм. 1989 елда 359 кеше (татарлар), 2000 елда 373 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек.

Галим М. И. Әхмәтҗанов фикеренчә, Әҗәкүл авылы исеме Әҗе күле исеменнән алына. Әҗәкүл авылыннан ерак түгел Агыйдел елгасы буендагы күлләрнең берсе хәзер дә Әҗекәй күле дип йөртелә. Әҗе күле буйлап килеп, көньяк ярга күчүче кешеләр – Әҗәкүл авылына нигез салучылар.

Ойконим фин-угор нигезле *аз (аза)* + төрки *күл* компонентларыннан тора. И.С. Галкин фикеренчә, *аз (ас)* компоненты елга атамасы булган: хант. «зур елга»; *я* элементы шулай ук «су», «елга» гидронимик мәгънәләрен белдергән. *Аз* топонигезле гидронимнарның таралыш ареалы киң. Мәсәлән, Мари Эл Республикасының Моркин һәм Идел буе районы территорияләрендә *Азъял, Кушыл Азъял, Улыл Азъял, Азъял кутыр* исемле авыллар, Казансу елгасы кушылдыгы *Аза аз* – елганың фин-угор телләрендәге исеме һәм *яр* мари телендә «авыл» мәгънәсен аңлата[1].

Н.И. Воробьёв фикеренчә, Әҗәкүл авылын Казан һәм Казан тирәсендә яшәүче кешеләр нигезләгән[2].

**ӘҖМӘТ** авылы район үзәгеннән 17 км төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдагы Шәбез суы буенда урнашкан. 1906 елда нигез салына. 1989 елда 137 кеше (татарлар), 2000 елда 134 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек. Авыл янында борынгы Әҗмәт каберлеге урыны саклана.

---

[1] *Галкин И. С.* Тайны марийской топономики. – Йошкар-Ола, 1985. – С. 30.

[2] *Рамазанова Д. Б.* К вопросу истории заселения Закамья татарами и формирования некоторых прикамских говоров татарского языка // Национальный вопрос в Татарии дооктябрьского периода. – Казань, 1990. – С. 6.

Әҗмәт каберлеге Чиялек культурасы истәлеге. 1971–1976 елларда Е. П. Казаков тарафыннан тикшерелә. XII–XV йөзләр мөселман каберлегендә мәҗүсилек йолалары элементлары сакланган (ут культы, күмгәндә кидерелә торган битлек кисәкләре, үрелмәле бизәкләр төшерелгән калку төпле савытлар, Үзбәк хан акчалары һ.б.). Кайбер тикшерүчеләр фаразынча, Әҗмәт каберлеге мөселманлашкан угор кабиләләреннән калган[1].

Борынгы төрки татарларда оҗе «өлкән ир туган, абый» мәгънәсен аңлата[2].

**ӘНӘК** авылы район үзәгеннән 49 км көньяк-көнбатыштарак, Казан-Уфа автомобиль юлы буенда урнашкан. XVII йөз ахыры – XVIII йөз башларында нигез салына. 1989 елда 80 кеше (татарлар), 2000 елда 106 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек; терлек азыгы җитештерү. Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиев туган авыл.

Болгар-татарларда эт культы, эт тотемына нисбәтле рәвештә һәм ир баланың талымсыз, авыруларга бирешми торган булсын дигән теләктән чыгып, «эт» мәгънәсенә ия булган сүзләрне кеше исеме итеп бирү йоласы булган. Шушы йоладан борынгы телебездә «эт» төшенчәсен белдерә торган *әнәк* сүзе кеше исеме булып йөргән.

**ӘТӘС** авылы, Актаныш районында, район үзәгеннән 36 км көньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез суының югары агымы буенда. XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 198 кеше (татарлар), 2000 елда 210 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты.

*Әтәс* атамасы башкорт теленнән, с ~ ч күзәтелә.

**БҮЛӘК** авылы район үзәгеннән 26 км көнбатыштарак, Түбән Кама сусаклагычы астында калган зона чигендә урнашкан. 1925 елда нигез салына. 1989 елда 196 кеше (татарлар), 2000 елда 158 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

---

[1] Татар энциклопедиясе. – Казан, 2002. – Б. 58.

[2] *Саттаров Г. Ф.* Татар топонимиясе. – Б. 39.

Авылга нигезне Иске Семиостров авылы кешеләре сала. Башта җиде гаилә килеп утыра, Өшәр халкы аларны Күчмә авыл дип атаса да, күченүчеләр Бүләк исеме бирәләр.

**БУАЗКҮЛ** авылы район үзәгеннән 27 км төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасы тамагы янында урнашкан. XVIII йөз урталарында нигез салына. 1989 елда 392 кеше (татарлар), 2000 елда 392 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Буазкүл авылы исеме турында мондый риваять бар. Авылдан төньяк-көнчыгышка таба урнашкан күлдә буаз сыер батып үлгән. Авылның исеме шуннан килеп чыккан, имеш. Статистик документларда русча атамасы Баскулево, Баскуль, Буаскулево, Буаз-Куль рәвешендә бирелә. Авыл халкы телендә Өске Буазкүл (Шүрәле), Аскы Буаз-күл.

**БУРСЫК** авылы район үзәгеннән 20 км төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасы тамагы буенда урнашкан. XVIII йөздә нигез салына. 1989 елда 231 кеше (татарлар), 2000 елда 210 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Зоонимик чыгышлы атама. Авыл тирәсендәге урманнарда, чокырларда бурсык җәнлекләре күп булган, авылның исеме шуннан алынган.

**ЗӨБӘЕР** авылы район үзәгеннән 41 км көньяк-көнбатыштарак, Ык елгасының уң кушылдыгы Бәҗәнә суы буенда урнашкан. Авылга XVIII йөз ахырларында нигез салына. 1989 елда 317 кеше (татарлар), 2000 елда 311 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Антропонимик чыгышлы атама. Авылга Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе, академик Диләвер Зөбәеровның бабасының бабасы нигез сала. Рус чыганакларында Зибаиров, Зубаиров, Зюбаиров рәвешендә күрсәтелә.

*Зөбәер* «көчле; акыллы» мәгънәсендәге гарәби чыгышлы кеше исеме[1].

**ИЛЧЕБАЙ** авылы район үзәгеннән 8 км төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 1747 елдан мәгълүм. 1989 елда 107 кеше

[1] *Саттаров Г. Ф.* Татар топонимиясе. – Б. 106.

(татарлар), 2000 елда 99 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек.

Авыл халкы сөйләвенчә, 600 – 800 еллар элек Агыйделнең уң ярындагы Җанҗегет авылыннан Илчегол дигән кеше елга аша йөзеп чыга. Бу ярдагылар, аны чыгармаска тырышып, аңа ташлар атканнар. Илчегол су астына чумып, шактый гына кызу аккан Агыйделне йөзеп чыга. Батырлыгы өчен аңа җир кишәрлеге бүләк итеп бирәләр. Авылның хәзерге урыны сазлык була. Илчегол бабай нигезне тау башына сала. Авылның беренче урыны – Куян белән Илчебай арасындагы Бүләк тау. Урмандагы агачларны кисеп төпләгәч, тау астындагы сазлык кибә. Халык тау астына күчеп утыра һәм Яңа Илчебай авылын төзи. Авылга нигезне алдынгы карашлы Илчебай атлы кеше сала дигән фикер бар.

*Илчебай* антропонимы борынгы төрки-татар чыгышлы *илче* + *бай* компонентларыннан тора.

**ИРМӘШ** авылы район үзәгеннән 2 км төньяк-көнбатыштарак утырган. XVIII йөзнең I яртысында нигез салына. 1989 елда 126 кеше (татарлар), 2000 елда 112 кеше яши. Халкының төп шөгыле – сарык асрау.

Гәрәй хан кабиләсеннән Җуар нәселенең XIII буын вәкиле – Ирмәш Ирмәк улы нигез сала. Антропонимик чыгышлы атама.

Кама буе ойконимиясе һәм гидронимиясендә фонетик яктан Ирмәш сүзенә якын атама Армезь (Кама елгасы кушылдыгы һәм Удмуртиянең Камбар районы торак пункт атамасы) бар[1].

М. Г. Атаманов фикеренчә, Армезь борынгы удмурт теленнән «томанлы сазлык, елга ярыннан агучы чишмә» дигән мәгънәне аңлата. Ирмәш авылында елгадан, томанлы сазлык ясап, чишмә чыга.

**ИСКЕ АЙМАН** авылы район үзәгеннән 54 км көньяк-көнбатыштарак, Ыкның уң кушылдыгы Бәҗәнә елгасының югары агымы буенда урнашкан. Авылга XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 400 кеше (татарлар), 2000 елда 376 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

---

[1] *Арсланов Л. Ш.* Финны, угры и самодийцы в Восточном Закамье / Л. Ш. Арсланов, Е. П. Казаков, К. И. Корепанов. – Елабуга, 1993. – С. 33.

Антропонимнан ясалган ойконим. 1631 елда авыл нигез ташы салучы Айдагол баба хөрмәтенә Айман дип атала. Аларның җире күп була, Матвеевка, Маҗын якларында биләмәләр тоталар. Ара ераклыгы аларны тиешенчә файдаланырга мөмкинчелек бирми, шуңа бер төркем халык, 1892 елда күчеп китеп, Яңа Айман, икенче төркем 1905 елда Мөслим ягының каенлы, сазлы урынында Каенсаз авылын нигезлиләр. Аларны башка чыгарган төп авыл Иске Айман дип йөртелә башлый.

**ИСКЕ ӘГЪБӘЗ** авыл район үзәгеннән 40 км төньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Калмыя суы буенда утырган. XVIII йөзнең I яртысында нигез салына. 1989 елда 349 кеше (татарлар), 2000 елда 282 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты.

Антропонимнан барлыкка килгән атама. Ойконим Бүләр волосте кешесе Агыйбәс (Әгыйбәс) Доскаев исеме белән бәйле.

**ИСКЕ ӘЛЕМ** авылы, Актаныш районында, район үзәгеннән 12 км көньяктарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Биҗады суы буенда. XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 274 кеше (татарлар), 2000 елда 221 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, сарык асрау.

Карагыз: Яңа Әлем.

**ИСКЕ БАЙСАР** авылы район үзәгеннән 30 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасы буенда урнашкан. Авыл 1713 елдан мәгълүм. 1989 елда 717 кеше (татарлар), 2000 елда 674 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Карагыз: Яңа Байсар.

Г. Ф. Саттаров фикеренчә, атамалар Байсары – Байсар антропонимы яисә байсарлар ыруы белән бәйле. *Байсар* атамасы ногай кабиләсе берлеге чорындагы төрки *байсар* этнонимына барып тоташа.

**ИСКЕ БАЛТАЧ** авылы район үзәгеннән 22 км көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез инеше буенда утырган. Авылга 1732 елда нигез салына. 1989 елда 146 кеше (татарлар), 2000 елда 130 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Батый хан гаскәрләре Болгар шәһәрен таптагач һәм талагач, 1237 елда Чуяр баба, каланы ташлап китеп, әлеге Балтачка нигез сала.

Авыл халкы *Балтач* атамасының барлыкка килүен биредә оста балтачылар яшәгәнлеге белән аңлатырга омтыла.

Карагыз: Яңа Балтач.

**ИСКЕ БИКЧӘНТӘЙ** авылы район үзәгеннән 31 км көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез инеше бассейнында урнашкан. Авылга 1715 елда нигез салына. 1989 елда 151 кеше (татарлар), 2000 елда 148 кеше яши. Халыкның төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Авылның атамасы антропонимга нигезләнеп барлыкка килгән. Борынгы төрки-татар-монгол чыгышлы *Бикчәнтәй* исеме: «1) төпчек бәк; иң кече ир бала; 2) нык һәм кечкенә» мәгънәләренә ия.

**ИСКЕ БОГАДЫ** авылы район үзәгеннән 18 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Биҗады суы буенда урнашкан. 1712 елдан мәгълүм. 1989 елда 698 кеше (татарлар), 2000 елда 675 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Карагыз: Югары Богады.

**ИСКЕ ҖИЯШ** авылы район үзәгеннән 18 км көнбатыштарак, Агыйделнең сул кушылдыгы Шәбез елгасы буенда утырган. Авыл 1738 елдан мәгълүм. 1989 елда 215 кеше (татарлар), 2000 елда 200 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

**ИСКЕ КАДЕРМӘТ** авылы район үзәгеннән 27 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Терпеле суы буенда урнашкан. Авылга XVII йөз ахырларында нигез салына. 1989 елда 180 кеше (татарлар), 2000 елда 172 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Карагыз: Яңа Кадермәт.

**ИСКЕ КОРМАШ** авылы район үзәгеннән 25 км көнбатыштарак, Агыйделнең сул кушылдыгы Шәбез елгасы буенда утырган. Авыл XVII йөздән мәгълүм. 1989 елда 491 кеше (татарлар), 2000 елда 448 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, умартачылык.

Карагыз: Яңа Кормаш.

**ИСКЕ СӘФӘР** авылы район үзәгеннән 30 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Терпеле суы буенда урнашкан. Авылга XVII йөз ахырларында нигез салына. 1989 елда 904 кеше (татарлар), 2000 елда 898 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Авыл антропонимга нигезләнеп барлыкка килгән. Гарәби чыгышлы *Сәфәр* исеменең мәгънәләре: 1) юл йөрү; сәфәр; 2) һиҗри елның икенче ае исеме. Сәфәр аенда туган балаларга кушылган исем[1].

**ИСКЕ СОЛТАНГОЛ** авылы район үзәгеннән 18 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Биҗады суы буенда утырган. Авыл 1712 елдан мәгълүм. 1989 елда 698 кеше (татарлар), 2000 елда 675 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Иске Солтангол авылы исеме антропонимга бәйле. *Солтангол* – кушма төзелешле гарәби төрки-татар чыгышлы исем. *Солтан* «патша, хөкемдар, дәүләт хуҗасы, монарх, император» + *гол/кол* «солтан колы, ярдәмчесе».

**ИСКЕ ТЕЛӘКӘЙ** авылы район үзәгеннән 15 км көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез инеше буенда урнашкан. 1729 елдан мәгълүм. 1989 елда 466 кеше (татарлар), 2000 елда 436 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Авылның исеме Теләкәй исемле кеше исеменә нигезләнеп барлыкка килгән. *Теләкәй* – баланың булуын, дөньяга килүен, тууын теләү исеме. Борынгы заманнарда төрки халыкларда гаиләдә, нәселдә озак бала булмый торса яки туган балалар үлеп барса, тәңредән бала сорау, баланың үлмәвен, яшәвен теләү, үтенү, ялвару йоласы башкарылган. Бу йола «Бала келәве» дип аталган. Бала келәве Келәү (Теләү) йоласының бер төрен тәшкил иткән[2].

**ИСКЕ УРЬЯДЫ** авылы район үзәгеннән 32 км көнбатыштарак, Ык елгасының уң кушылдыгы Бәҗәнә бассейнында урнашкан. Авылга XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 134 кеше (та-

---

[1] *Саттаров Г. Ф.* Татар топонимиясе. – Б. 224.

[2] *Саттаров Г. Ф.* Татар антропонимикасы. – Б. 106.

тарлар), 2000 елда 125 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, сарык асрау.

**КАЕНЛЫК** авылы район үзәгеннән 22 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Биҗады елгасының югары агымы буенда утырган. Авылга 1927 елда нигез салына. 1989 елда 26 кеше (татарлар), 2000 елда 20 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Авылның исеме *каен* һәм җыйма мәгънәне аңлата торган *-лык* кушымчасына нигезләнеп барлыкка килгән.

**КАЛМАШ** авылы район үзәгеннән 23 км көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез суы буенда урнашкан. XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 79 кеше (татарлар), 2000 елда 84 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек.

*Калмаш* ойконимы удмуртларның *Калмез* этнонимына нисбәтле. Бу авыл халкының һәм археологик истәлекләрнең удмурт этносы белән бәйлелеген белдерә. *Калмаш* топонимы Татарстан, Башкортстан, Удмуртия территорияләрендә киң таралган[1].

В. Ф. Генинг фикеренчә, Калмаш этнонимы ике составлы: *кал~кел* компоненты самодий телләре этнонимы «козгын; ала карга» мәгънәсен, *маш~мез* компоненты «кеше, халык» мәгънәсен аңлата[2].

М. Г. Атаманов фин-угор тамырлы *кал* «балык» мәгънәсенә бәйли. Чагыштырыгыз: мар. *кол*, морд. *кал*, фин. *кала*, хант. *kul*, венг. *hal*, ненец. *xale*[3].

**КАЧКЫН** авылы, район үзәгеннән 53 км төньяк-көнбатыштарак, Казан – Уфа автомобиль юлы буенда. XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 237 кеше (татарлар), 2000 елда 258 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Авыл халкы фикеренчә, Әреш бабай, Әгерҗе районы Салагыш авылыннан бер төркем кешеләр, Мөслим районы Каенсаз

---

[1] *Арсланов Л. Ш.* Финны, угры и самодийцы в Восточном Закамье / Л.Ш. Арсланов, Е.П. Казаков, К.И. Корепанов. – Елабуга, 1993. – С. 32.

[2] *Генинг В. Ф.* История населения удмуртского Прикамья в пьяноборскую эпоху // Вопросы археологии Урала. Вып. 10. – Свердловск; Ижевск, 1970. – С. 199.

[3] *Атаманов М. Г.* Удмуртская ономастика. – Ижевск, 1988. – С. 220.

авылыннан берничә нәсел качып килеп монда төпләнгәннәр, авыл *Качкын* исемен ала.

**КӘЗКӘЙ** авылы район үзәгеннән 11 км көньяк-көнчыгыштарак, Башкортстан Республикасы чигендә урнашкан. XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 351 кеше (татарлар), 2000 елда 311 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Революциягә кадәр Казыкай (Кадыпеево) дип йөртелә. Кадыкай (Казикәй) исемле кеше нигез салган булса кирәк.

**КИРОВ** исемендәге совхоз посёлогы район үзәгеннән 32 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Терпеле суы буенда утырган. 1989 елда 1112 кеше (татарлар), 2000 елда 1122 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек, умартачылык.

Авыл 1931 елда ТАССР Халык Комиссарлары Советы карары нигезендә 201 санлы Актаныш итчелек-сөтчелек совхозы буларак төзелә, төрле җирләрдән, күрше-тирә авыллардан кешеләр килеп төпләнә, 1935 елда Киров исеме бирелә.

**КОЛЫН** авылы район үзәгеннән 54 км көньяк-көнбатыштарак, Ык елгасының уң кушылдыгы Бәҗәнә суының югары агымы буенда урнашкан. Авыл 1747 елдан мәгълүм. 1989 елда 176 кеше (татарлар), 2000 елда 155 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Казан татарларының канкардәш бабалары болгарлар бик борынгы чорда үзләренең килеп чыгышлары турында, башка борынгы халыклар кебек кебек үк, бик примитив фикер йөрткәннәр. Алар уйлавынча, ыруг-кабилә башлангычында ниндидер тотем – хайван-баба торган. Борынгы заманнарда болгар татарларда, кыргый һәм йорт хайваннары балаларының атамалары булып йөри торган зоологик терминнарны, хайван балаларының кечкенә, яшь чагында сөйкемле, ягымлы, матур, уйнакчыл булуларын күздә тотып, ир балаларга исем итеп бирү гадәт-йоласы булган[1]. Шундый исемнәрнең берсе – Колын исеме.

Авыл халкы, XVI гасырда Мөшегедә яшәгән Бүләк баба Дускайның нәселен дәвам итүче Морзакай баба Юкачевның

---

[1] *Саттаров Г. Ф.* Татар антропонимикасы. – Б. 26.

балалары 1701 елда Колын авылына нигез сала. Шул хөрмәткә колын суеп, аш әзерлиләр, авылга әлеге атамасын бирәләр, дип сөйли.

**КҮҖӘКӘ** авылы, Актаныш районында, район үзәгеннән 35 км көнбатыштарак, Ык елгасының уң кушылдыгы Бәҗәнә бассейнында. XVIII йөз башларында нигез салына. 1989 елда 546 кеше (татарлар), 2000 елда 455 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек, кирпеч заводы. Урта мәктәп. Мәдәният йорты.

*Күҗәкә* атамасын профессор Г. Ф. Саттаров удмуртларның ыру исеме Кузямка (бүләк), ә икенче профессор Л. Ш. Арсланов географик урнашуына бәйле төстә аны шул ук халык телендәге чоңгыл, елга борыны төшенчәсенә бәйләп аңлаталар.

Ә Мари Суыксу авылы кешеләре бу авыл атамасы «калку урын»ны аңлатучы *Күкшәкә* сүзеннән барлыкка килгән дип әйтәләр. Андый атамалы авыллар һәм елга Киров өлкәсендә, Удмурт Республикасында бар. Минзәлә өязендә андый атамалы ике авыл булган, аларның берсе икенчесеннән өч км читтәрәк урнашкан булган. Авылга Варзидан (Удмурт Республикасы), Омга ыруыннан чыгучылар нигез салганнар.

*Күҗәкә* исеменең каян алынуы турында төрле риваятьләр, хикәятләр бар. Имеш, безнең төбәктә урманнар күп булган. Монда Әкә бай эшчеләр яллап урман кистергән. Эшчеләр байны *хуҗа әкә* диеп йөрткәннәр. Соңрак җайлаштырып *Күҗәкә* дия башлаганнар. Бу эшчеләр монда төпләнеп калганнар. Авылга *Күҗәкә* исеме бирелгән.

**КУЯН** авылы район үзәгеннән 5 км төньяк-көнбатыштарак урнашкан. XVII йөздән мәгълүм. 1989 елда 286 кеше (татарлар), 2000 елда 273 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Җирле тарихчы Мулланур Бәширов елъязмасында, Әҗәкүлдән дүрт гаилә, катнаш урман эчендә тау итәгендә уңайлы урын сайлап, биредә куыш коралар. Йосыф, Яманай, Бикбай, Солтанай аймакларыннан авыл барлыкка килә. Риваять буенча, бу урыннан куян йөгереп узып китә, шуннан торак урынын Куян дип атыйлар, ди.

**КЫР-КАЕНТҮБӘ** авылы район үзәгеннән 28 км көньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез инеше буенда. XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 121 кеше (татарлар), 2000 елда 115 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, умартачылык, сарык асрау. XIX йөздә киез итек, киез басу кәсепчелеге белән мәгълүм. Каеннар үскән калкулык – түбә авыл атамасы итеп алына.

Авыл каен урманы янында урнашкан. *Каентүбә* атамасы каен урманындагы агачлардан йортлар төзүгә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән. Каентүбәлеләрне Чүтертләр дип атыйлар. Бу кушамат күптәннән килә. *Чүтерт* дигән кушамат «аптырап калмаучан, мәзәкчән, шаян, мактанчык» мәгънәсен аңлата.

**МАРИ СУЫКСУЫ** авылы район үзәгеннән 29 км көнбатыштарак, Түбән Кама сусаклагычы астында калган җирләр чигендә утырган. 1707 елдан мәгълүм. 1989 елда 498 кеше (марилар), 2000 елда 571 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Колонизацияләү башлангач, Ямаш тау итәгендә яшәгән марилардан ике кеше авыл өчен яңа урын эзләргә чыгып китә. Тау башыннан караганда көньякта урман өстендә күренгән дымны эзләп юл тоталар. Берничә көннән дым күтәрелергә сәбәпче чишмәне эзләп табалар, аны Йушто Памаш (Салкын Чишмә) дип атыйлар. Бераздан шул тирәгә татарлар күченеп килә. Авылга *Суыксу* дип атама бирәләр.

**МӘСӘДЕ** авылы район үзәгеннән 23 км төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасы буенда урнашкан. Авылга 1927 елда нигез салына. 1989 елда 251 кеше (татарлар), 2000 елда 292 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек; нефть суырту станциясе.

Авыл Такталачык авылы кешеләре тарафыннан 1920–1930 елларда нигезләнгәнгә, ойконим гидронимнан барлыкка килгән булырга тиеш[1]. Авыл тирәсендә пьянобор эпохасына караган

---

[1] *Арсланов Л.Ш.* Финны, угры и самодийцы в Восточном Закамье / Л. Ш. Арсланов, Е. П. Казаков, К. И. Корепанов. – Елабуга, 1993. – С. 45.

истәлекләр табылган[1]. В. Ф. Генинг бу топонимны ыруг атамасы Массада белән бәйли[2]. Л. Ш. Арсланов атаманы угыр теле белән аңлата: манс. *mesiy,mesi, mesi, месыг, мэсей* «текә борылыш».

Мәсәде авылы Агыйдел елгасының текә борылыш ясаган җирендә, елга борылыш ясаган урынында урнашкан. Агыйделнең бу өлеше семафор дип аталган, елга суднолары таралыша алмыйча, башка судноның үткәнен көтеп торганнар. *Меси (месыг)* + *-ды* ия булу аффиксы[3].

**МЕРӘС** авылы район үзәгеннән 12 км көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез инеше буенда урнашкан. 1738 елдан мәгълүм. 1989 елда 138 кеше (татарлар), 2000 елда 90 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Авылга Гәрәй хан нәселеннән Төнләче улы Байтирәк малае Мерәс нигез сала.

**МИХАЙЛОВКА** авылы район үзәгеннән 21 км көньяктарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Терпеле суы буенда утырган. XIX йөздән бирле яшәп килә. 1989 елда 67 кеше (татарлар, руслар), 2000 елда 71 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, дуңгыз асрау.

Авылга Сембердән килгән руслар тарафыннан нигез салына.

**ОЛЫИМӘН** авылы район үзәгеннән 42 км көньяк-көнбатыштарак, Сөннең сул кушылдыгы Сикия елгасы бассейнында урнашкан. Авыл XVII йөздән мәгълүм. 1989 елда 417 кеше (татарлар), 2000 елда 384 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек. Олы Имән – фитоойконим. Агач исеменнән барлыкка килгән атама.

**ПУЧЫ** авылы район үзәгеннән 48 км көньяк-көнбатыштарак, Саралы елгасы, Казан – Уфа автомобиль юлы буенда утырган. Авылга XVIII йөз башларында нигез салына. 1935–1959 елларда ТАССРның Калинин районы үзәге була. 1989 елда

---

[1] *Генинг В.Ф.* История населения удмуртского Прикамья в пьяноборскую эпоху. – С. 16.

[2] *Генинг В. Ф.* Памятники мазунинской культуры // Вопросы археологии Урала. – Вып. 3. – Т. 3. – Свердловск-Ижевск, 1967. – С. 86.

[3] *Арсланов Л. Ш.* Финны, угры и самодийцы в Восточном Закамье / Л. Ш. Арсланов, Е. П. Казаков, К. И. Корепанов. – Елабуга, 1993. – С. 46.

1562 кеше (татарлар), 2000 елда 1550 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек. XIX йөздә чабата ясау кәсепчелеге белән мәгълүм.

Риваятьләргә караганда, Биткол елгасы буена Тучы (Туйчы) һәм Пучы атлы ике бертуган казык каккан. Бу урыннар Шәех Әхмәтнеке булып саналган. Рөхсәтсез килеп утырганга, Тучы һәм Пучыны куып җибәргәннәр. Шулай да берникадәр вакыттан соң Пучыга аръякка күчеп төпләнергә рөхсәт бирелгән. Авылның исеме шуннан калган, диләр.

*Пучы* атамасының асылында мари телендә «болан» мәгънәсен белдерә торган *пучы* сүзенә нигезләнеп ясалган *Пучы* «болан» кушаматы ята. Кешенең хәрәкәтен, холкын яки башка берәр ягын боланга охшату, чагыштыру җирлегендә метафорик-образлы *Пучы* кушаматы яки кушамат-исеме барлыкка килгән. Пучы авылына мәҗүси чирмеш-типтәрләр нигез салганнар. Бу авылда алар тора-бара тулысынча татарлашып беткәннәр. Актаныш районында Мари Суыксуы, Мари Ямалые, Терпеле, Мөслим районында (Пучы авылыннан 10–15 км ераклыкта) Мари Буләр, Усаклык, Бикмәс һ.б.ныкы кебек халкы хәзерге вакытта татарча сөйләшә һәм балалары мәктәптә татар телендә укый торган мари авылларының булуы әнә шуны раслый. Әлеге мари авылларының халкы элек-электән (алар мәҗүси булганнар) болгар-татар исем-фамилияләрен йөртә[1].

**ТАБАНЛЫКҮЛ** авылы район үзәгеннән 44 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Сикия суы буенда урнашкан. Авыл XVIII йөздән бирле яшәп килә. 1989 елда 154 кеше (татарлар), 2000 елда 176 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Авыл халкы сөйләвенчә, булачак авыл урынына хәзерге Башкортстанның Бакалы авылыннан ике бертуган Әлмәт белән Колмәт килеп чыгалар. Ул вакытта тирә-як калын урманнар белән капланган булган. Урман эченнән инеш аккан, янында матур гына күл дә булган. Күлдә табан балыгы күп үрчегән. Күлнең матурлыгына, табан балыгының күплегенә сокланып,

[1] *Саттаров Г.Ф.* Татарстан АССРның антропонимнары. – Б. 172.

аңа Табанлыкүл дигән исем куялар. Риваятьнең башкачарак варианты да бар. XIV гасыр башында Бүләр-Биләр шәһәреннән Бараҗ кабиләсе кешеләре Агыйделнең Чулманга койган һәм Ык елгасының түбәнге агымы янындагы җирләргә килеп утыралар. Соңыннан нәкъ шул урында Бүләр олысы барлыкка килә. Бүләрханның улы Җәдәшнең угылы Ихсанның Әлмөхәммәт белән Килмөхәммәт исемле малайлары күлләргә бай, киек-җәнлекле куе урманлы урында Табанлыкүл дигән авылга нигез салалар.

Тарихи чыганакларга күз салсак, Башкортстанның Бүздәк авылы да элек (1912 елларга кадәр) Табанлыкүл исемле мишәр авылы булып торган.

Гомумтатар телендә киң һәм актив кулланышка ия булган *күл* гидрографик терминына нигезләнеп, Татарстан топонимиясенең байтак кына гидронимнары, ойконимнары (башлыча авыл атамалары) һәм микротопонимнары ясалган.

Г. Ф. Саттаров болай дип яза: «Татар телендә ияргүче кисәге әйбернең булуын, табылуын белдерүче ясалма сыйфат булган исем (бу очракта географик термин) сүзтезмәләрдән гыйбарәт географик атамалар ифрат күп. Алар әйберне шул географик объектта булуын, табылуын ачыклыйлар». Автор фикеренчә, татар телендә әйбернең, билгенең булуын, табылуын белдерүче ясалма сыйфатлар *-лы, -ле* кушымчалары кушылып ясала. Галим теге яки бу әйбернең, билгенең табылуын яки табылмавын белдерүче сүзләрдән ясалган топонимнар һәм микротопонимнар рәтенә *Табанлы күл* гидронимын кертә.

**ТАКТАЛАЧЫК** авылы район үзәгеннән 14 км көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез суы бассейнында урнашкан. Авылга XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 1000 кеше (татарлар), 2000 елда 868 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Шагыйрь Гамил Афзал туган авыл.

**ТАТАР СУЫКСУЫ** авылы район үзәге Актаныш авылыннан 14 км көньяк-көнбатыштарак. XVII йөз урталарыннан мәгълүм. 1989 елда 120 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, сарык асрау. Мәчет. XIX йөздә киез итек-киез басу кәсепчелеге белән мәгълүм.

**ТАТАР ЯМАЛЫ** авылы район үзәгеннән 20 км төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасы буенда урнашкан. Авылга 1742 елда нигез салына. 1989 елда 422 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Ойконим ненец телендәге ям(а) «зур су, диңгез, зур елга» мәгънәсенә ия[1] + ненец телендәге *мал* «чыганак, су башы, елга башы»[2] + төрки телләрдә әйбернең, билгенең, сыйфатның булуын, табылуын белдерүче *-лы* кушымчасы[3].

**ТӘКМӘК** авылы район үзәгеннән 42 км көньяк-көнбатыштарак, Сөннең сул кушылдыгы Сикия суы бассейнында утырган. Авылга XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 153 кеше (татарлар), 2000 елда 117 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Авыл халкы сөйләвенчә, *Тәкмәк* атамасы турында төрле фаразлар йөри: 1) таба ашына бәйле, тәбикмәктән кыскартып алынган; 2) авылга рус кешесе урнашкан һәм ул гел «так,так» дип сөйләшкән; 3) руслар белән татарлар гел сугыша торган булганнар, шуннан *тукмарга* дигән сүздән *тукмак*, соңрак *Тәкмәк* исеме килеп чыккан.

*-мәк*/*-мак* топоформантлы ойконимнар Татарстанның Мөслим районында (Симәк, Иске Чамак, Олы Чамак), Удмуртиядә (Тойма елгасы бассейнындагы Колтымак, Челтымак елгалары, Калмыз елгасы бассейнындагы Чермак елгасы, Алнаш районында Колтымак авылы, Можга районында Сосмак авылы), Киров өлкәсендә (Сосмак авылы) очрыйлар.

Т. И. Тепляшина *-мак* топоформантлы топонимнарны болгар теле белән бәйли. М. Г. Атаманов бу фикерне кире кага. Аныңча, мондый топонимнар төрки телләр белән бәйле түгел. *-мак* сүз башында да килә ала: Макшур[4].

---

[1] *Афанасьев А. П.* Древние топономические пласты Помезенья // Материалы VI Международного конгресса финно-угроведов. – М., 1990. – С. 524; *Галкин И. С.* Основные типы топонимов на территории Марийской АССР // Вопросы финно-угорской ономастики. – Ижевск, 1989. – С. 40.

[2] *Галкин И. С.* Основные типы топонимов на территории Марийской АССР // Вопросы финно-угорской ономастики. – Ижевск, 1989. – С. 40.

[3] *Арсланов Л. Ш.* Финны, угры и самодийцы в Восточном Закамье / Л. Ш. Арсланов, Е. П. Казаков, К. И. Корепанов. – Елабуга, 1993. – С. 44–45.

[4] *Атаманов М.Г.* Удмуртская ономастика – Ижевск, 1988. – С. 77.

Л. Ш. Арсланов *-мак* компонентын угор-самодий теленнән дип исәпли[1].

**ТЕРПЕЛЕ** авылы район үзәгеннән 27 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Терпеле суы буенда урнашкан. Авыл 1742 елдан мәгълүм. 1989 елда 50 кеше (татарлар), 2000 елда 51 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

**ТҮБӘН ГӘРӘЙ** авылы, Актаныш районында, район үзәгеннән 18 км төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез суы буенда. XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 117 кеше (татарлар), 2000 елда 140 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Клуб.

Карагыз: Югары Гәрәй.

**ТҮБӘН КАРАЧ** авылы район үзәгеннән 27 км көнбатыштарак, Агыйделнең сул кушылдыгы Шәбез елгасы буенда урнашкан. Авыл XIX йөздән мәгълүм. 1989 һәм 2000 елларда даими яшәүчеләр (татарлар) саны 10 нан ким.

Авыл халкы, Казан ханлыгы бәйсезлеген югалткач, бабаларыбыз бирегә күчеп утырган, ди.

Карагыз: Югары Карач.

**ТҮБӘН ЯХШЫЙ** авылы район үзәгеннән 40 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Сикия инеше буенда утырган. Авылга XIX йөз урталарында нигез салына. 1989 елда 122 кеше (татарлар), 2000 елда 127 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Авыл атамасы Яхшыгол башкорт исеме белән бәйле. Ул хәзерге Түбән Яхшый урынына килеп нигез корган.

*Яхшый* атамасы борынгы төрки-татар кеше исеме *Яхшыгол* = *яхшы* «шәп, әйбәт, яхшы» + *кол* «кол, чура» компонентларыннан тора[2].

**ТҮКЕ** авылы район үзәгеннән 40 км көньяк-көнбатыштарак, Ык елгасының уң кушылдыгы Бәҗәнә суы буенда урнашкан. Авылга XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 428 кеше

[1] *Арсланов Л.Ш.* Финны, угры и самодийцы в Восточном Закамье / Л. Ш. Арсланов, Е. П. Казаков, К. И. Корепанов. – Елабуга, 1993. – С. 37.

[2] *Саттаров Г. Ф.* Татар топонимиясе. – Б. 139, 306.

(татарлар), 2000 елда 387 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Авыл атамасының килеп чыгышы башкорт кушаматына нисбәтле.

**ТЫҢЛАМАС** авылы район үзәгеннән 9 км көнбатыштарак, Башкортстан Республикасы чигендә урнашкан. 1722 елдан мәгълүм. 1989 елда 339 кеше (татарлар), 2000 елда 318 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Авылны тугыз гаилә килеп нигезләгән. Авыл исеме елга атамасыннан барлыкка килгән. Иң элек авыл исеме *Толнамас* буларак билгеле, чөнки Сөн елгасы буенда бик күп таллар үскән. 1467–1478 елларда идарә иткән Казан хакиме Ибраһим хан Тыңламас җирләрен Котлыгыш бигә ярлык нигезендә бүләк итеп тапшыра. Ә бу җирләр Сөн тамагының Агыйдел елгасына кушылган җәннәттәй җирләре санала. Билгеле, урын буш булмый, халыклар яши, көн күрә. Авыл тарихының яңа сәхифәсе шул вакыттан башлана.

Тыңламас авылын икегә бүлеп, Тыңламас елгасы ага. Риваятьләрдән күренгәнчә, электән ата-бабаларыбыз шушы елга буена су тегермәне ясаганнар, күпер төзегәннәр, яз килү белән су, ярларына сыеша алмыйча, күперне дә, тегермәнне дә агызып алып китә торган булган. Берничә тапкыр шулай эшләп карагач, елгага Тыңламас исеме биргәннәр. Авыл да шул вакыттан соң Тыңламас исеме белән атала башлаган.

**УРАЗАЙ** авылы район үзәгеннән 10 км төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасыннан 3 км читтә урнашкан. Авыл 1674 елдан мәгълүм. 1989 елда 511 кеше (татарлар), 2000 елда 473 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек, кирпеч заводы.

Болгар-татарларда кеше исемнәре аша, исемнәргә баланың бәхетле, мул ризыклы, мал-мөлкәтле булуын теләү «бәхет», «тәгам-ризык», «байлык», мал-мөлкәт» төшенчәсен белдерүче сүзләргә нигезләнеп ясалган исемнәрдә гәүдәләнеш тапкан. Иске татар телендә *ураз* «бәхет, бәхетле» мәгънәсенә ия. *Уразай* исеме *ураз* «бәхет» сүзенә *-ай* атау-эндәшү-боеру кушымчасы ялганып ясалган. «Бәхетле бул, бәхеткә ия бул» дигән мәгънә белдерә.

**ЧАЛМАНАРАТ** авылы район үзәгеннән 20 км көнбатыштарак, Агыйделнең сул кушылдыгы Шәбез суы буенда урнашкан. Авылга XVII йөз башларында нигез салына. 1989 елда 309 кеше (татарлар), 2000 елда 331 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

**ЧАТ** авылы район үзәгеннән 30 км көнбатыштарак, Агыйделнең сул кушылдыгы Шәбез елгасы бассейнында утырган. Авыл XVII йөздән мәгълүм. 1989 елда 162 кеше (татарлар), 2000 елда 159 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Авыл халкы сөйләвенчә, Көньяк Урал ягыннан Габдулла баба Бәк балалары белән 1200 еллар тирәсендә тирә-ягын урманнар әйләндереп алган җиде чатлы, җиде чатыннан җиде чишмә бәреп торган урында Чат авылына килеп төпләнгән.

**ЧӘЧЕР** авылы район үзәгеннән 44 км көнбатыштарак, Ык елгасы тамагы буенда урнашкан. Авылга XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 140 кеше (татарлар), 2000 елда 108 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек.

Бакалы якларыннан Шәйхечура исемле типтәр беренче булып нигезли. Авыл башта аның исеме белән атала. XVIII гасыр урталарында *Чәчер* исеме кушыла. Монда яшәүче руслар авылны Шайчурино дип йөртә.

Г. Ф. Саттаров фикеренчә, атама *Шаһичура* («шаһ колы») исеменең җирле диалекталь әйтелешкә яраклаштырылган *Чәчер* вариантыннан ясалган: *Шаһичура – Шаһичур – Шачур – Чәчүр – Чәчер.*

**ЧИРҮ** авылы район үзәгеннән 31 км көнбатыштарак, Агыйделнең сул кушылдыгы Шәбез суы буенда утырган. Авылга XVIII йөз башларында нигез салына. 1989 елда 122 кеше (татарлар), 2000 елда 101 кеше яши. Халкының төп шөгыле – сарык асрау, игенчелек.

**ЧИШМӘ** авылы район үзәгеннән 17 км көньяктарак, Башкортстан Республикасы чигендә урнашкан. Авыл XIX йөздән мәгълүм. 1989 елда 185 кеше (татарлар), 2000 елда 174 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек.

Авыл халкы сөйләвенчә, Тыңламас авылы кешеләренең эчәргә сулары булмаган. Тау асты тоташ урман булган, гел сазлыктан торган. Авыл кешесе Гыйздикамал тау буеннан чишмә эзләп тапкан, ул чишмәне бурап, улак куйганнар. Авыл башта *Арка* дип атала. Аннан *Яңа Тыңламас* була. 1924 елда *Чишмә* исеме бирелә.

**ЧИШМӘБАШ** авылы район үзәгеннән 31 км көньяктарак, Сөн елгасы буенда утырган. 1927 елда нигез салына. 1989 елда 168 кеше (татарлар), 2000 елда 184 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

**ЧИЯЛЕК** авылы район үзәгеннән 58 км көньяк-көнбатыштарак, Ыкның уң кушылдыгы Мөшек елгасы бассейнында урнашкан. 1930 елда мәгълүм. 1989 елда 69 кеше (татарлар), 2000 елда 67 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

*Чия* – фитоойконим. *Чия* + *-лек* (сүзьясагыч кушымча).

**ЧИЯЛЕК** авылы район үзәгеннән 35 км көньяктарак, Сөн елгасы буенда урнашкан. 1927 елда нигез салына. Авыл исеме археологик культура атамасы булып киткән.

Чиялек культурасы XIII йөз ахыры – XIV йөздә Чулман белән Урал алды аралыгында яшәүчеләргә нисбәтле археологик культура. Атамасы Чиялек янындагы авыллык табылгач бирелә. Беренче тапкыр 1969 елда Е. П. Казаков тарафыннан тасвирлана. Фараз ителүенчә, Урал төбәгенең угор кабиләләренә караган истәлек. Чиялек культурасы халкы терлекчелек, игенчелек, аучылык, балыкчылык белән көн күргән. Чиялек культурасына балчыктан ясалган түгәрәк төпле, үрелмәле орнаментлар белән бизәлгән савытлар хас. Мәетләр мөселман йоласы буенча җирләнгән; мәҗүсилек үзенчәлекләре булган каберләр дә очрый. Чиялек культурасы истәлекләре Татарстанда Актаныш районының Чиялек, Такталачык, Дербёшка, Әҗмәт авыллары, Мөслим районының Мәлләтамак авылы һ.б. урыннарда табыла[1].

1989 елда 77 кеше (татарлар), 2000 елда 67 кеше яши. Халкының төп шөгыле – сарык асрау, игенчелек.

---

[1] Татар энциклопедиясе. – Казан, 2002. – Б. 754.

**ЧУРАКАЙ** авылы район үзәгеннән 40 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Калмыя суы буенда урнашкан. Авылга XVIII йөздә нигез салына. 1989 елда 564 кеше (татарлар), 2000 елда 511 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

**ЧЫНЫК** авылы район үзәгеннән 29 км көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез суы буенда утырган. Авылга XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 45 кеше (татарлар), 2000 елда 37 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек.

М. Г. Атаманов фикеренчә, *Чынык* ойконимы асылында «чәшке» мәгънәсен белдергән удмурт зоонимы «сян-чан» ята[1].

**ШӘБЕЗ** авылы, Актаныш район үзәгеннән 22 км көнбатыштарак, Агыйделнең сул кушылдыгы Шәбез суы буенда. 1723 елдан мәгълүм. 1989 елда 191 кеше (татарлар), 2000 елда 195 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек. Башлангыч мәктәп.

**ШӘБЕЗБАШ** авылы Актаныш район үзәгеннән 31 км көньяк-көнбатыштарак, Агыйделнең сул кушылдыгы Шәбез суы буенда. 1740 елдан мәгълүм. 1989 елда 78 кеше (татарлар), 2000 елда 73 кеше яши. Халкының төп шөгыле – сарык асрау. Башлангыч мәктәп.

**ШӘРИП** авылы район үзәгеннән 11 км көнбатыштарак урнашкан. Авыл 1758 елдан мәгълүм. 1989 елда 244 кеше (татарлар), 2000 елда 221 кеше яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, игенчелек.

Авыл халкы сөйләвенчә, 1) Гәрәй хан ыруыннан Яхшыхуҗа углы Әҗәкнең җиденче буын вәкиле Шәриф баба нигез сала; 2) Урал тауларында аучылык белән шөгыльләнүче Габделмоталлап дигән кеше буйга җиткән Йосыф, Шәриф, Гәрәй исемле улларын Агыйдел буйларына җибәргән. Бу егетләр Шәрип, Гәрәй һәм Башкортстандагы Йосыф авылларына нигез салган.

*Шәрип/Шәриф* – гарәби чыгышлы кеше исеме: 1) «атаклы, хөрмәткә лаеклы»; 2) «мәрхәмәтле, изге»; 3) «зыялы, олы җанлы, бөек»[2].

---

[1] *Атаманов М.Г.* Удмуртская ономастика. – Ижевск, 1988. – Б. 37.

[2] *Саттаров Г.Ф.* Татар топонимиясе. – Б. 295.

**ЮГАРЫ БОГАДЫ** авылы район үзәгеннән 21 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Биҗады суының югары агымы буенда утырган. Авылга 1928 елда нигез салына. 1989 елда 134 кеше (татарлар), 2000 елда 140 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек.

Э. Ф. Ишбердин параллель топонимнарны тикшерә һәм Тәтешледәге *Богады* гидронимы, шулай ук Башкортстанның Бүздәк районындагы *Богады* ойконимы, Башкортстандагы еней кабиләсенең *Богады* этнонимыннан килеп чыккан дип уйлый[1].

Г. Ф. Саттаров *Богады* атамасын борынгы төрки телдәге *бога/буга* «үгез» + *-ды* («үгезле») кушымчасы нигезендә ясалуын әйтә. Республикабызның татар теленең урта диалектына карый торган минзәлә сөйләше таралган регион топонимиясендә әйбернең, билгенең, сыйфатның булуын, табылуын белдерүче *-лы* кушымчасы урынына, башкорт теле тәэсирендә булса кирәк, *-ды, -ты* кушымчалары килү – характерлы күренеш. И. Сафиуллин исә, Г. Ф. Саттаров фикерен куәтләп: «Богады халкы Җәнәй ыруыннан чыккан. «Богады», искечәдән тәрҗемә иткәндә, «бога», «үгез», «богалы», «үгезле» дигәнне аңлата. Богады дип телгә җайлаштырганнар. Элек үгезгә табынганнар. Авылның исеме дә шуннан килеп чыккан булырга тиеш», – дип исәпли.

В. И. Васильев һәм С. Н. Шитова уйлавынча, *Богады* этнонимының нигезендә *бог* форманты ята. М. Кастрен һәм П. Хайдунов фикеренә нигезләнеп, В. Ф. Генинг бу этнонимны урал халыкларының үз атамаларыннан килеп чыккан, ул «кеше» дигән төшенчәне белдерә, ди[2].

**ЮГАРЫ ГӘРӘЙ** авылы район үзәгеннән 18 км төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез суы буенда урнашкан. XVII йөздә нигез салына. 1989 елда 78 кеше (татарлар), 2000 елда 60 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, сарык асрау.

---

[1] *Ишбердин Э.Ф.* Этнонимы в топонимии Башкирии // Ономастика Поволжья. – Вып. 3. – Уфа, 1973. – С. 124.

[2] *Генинг В.Ф.* Памятники мазунинской культуры. – С. 68, 80–81.

Атама бу якка килеп төпләнгән Гәрәй тарханның варислары тарафыннан бирелә. Халык авылны Күркә Гәрәй дип йөртә.

Атама болгар-татар *гәрәй* этнонимына нисбәтле.

**ЮГАРЫ КАРАЧ** авылы район үзәгеннән 26 км көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез суы буенда утырган. XVIII йөздән мәгълүм. 1989 һәм 2000 елларда даими яшәүчеләр (татарлар) саны 10 нан кими.

**ЮГАРЫ ЯХШЫЙ** авылы район үзәгеннән 41 км төньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Сикия суы бассейнында урнашкан. XVIII йөздә нигез салына. 1989 елда 203 кеше (татарлар), 2000 елда 186 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

**ЯҢА ӘЛЕМ** авылы район үзәгеннән 6 км көньяк-көнбатыштарак утырган. XVIII йөздән мәгълүм. 1989 елда 1371 кеше (татарлар), 2000 елда 1241 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Авыл атамасы антропонимга нигезләнеп барлыкка килгән.

Һәрбер ата-ана баланы матур, якты өметләр белән дөньяга китерә, аның акыллы, тәүфыйклы булып үсүен, үскәчүзләренә таяныч, ярдәмче-киңәшче, картайган көннәрендә караучы-тәрбияләүче булуын тели. Шундый исемнәрдән борынгы төрки телдә «кул» төшенчәсен белдерү өчен йөргән *әл* сүзенә беренче зат берлек сандагы тартым кушымчасы *-ем* кушылу юлы белән Әлем дигән борынгы исем ясалган. Бу исем күчерелмә мәгънәдә «таянычым», ягъни «таянырдай кулым, ярдәмчем, ышанычым» мәгънәсен аңлата.

**ЯҢА БАЙСАР** авылы район үзәгеннән 34 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасы буенда урнашкан. Аңа XIX йөздә нигез салына. 1989 елда 104 кеше (татарлар), 2000 елда 105 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Байсар авылы атамасы антропонимга нигезләнеп ясалган. Борынгы төрки-татар чыгышлы *бай* «хуҗа; мал-мөлкәтле, куәтле бай кеше, әфәнде» + *сары*. Борынгы төрки халыкларда сары төс – затлы төс, алтын төсе итеп саналган. Табигатьнең сары төстәге әйберләре ихтирам ителгән. Атама Байсаров, Байсариев, Байзаров, Байсарин фамилияләрендә

сакланган. Байсар исеме һәм Байсаров фамилиясе удмуртларда да бар[1].

**ЯҢА БАЛТАЧ** авылы район үзәгеннән 21 км көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез инеше буенда утырган. Авылга XVIII йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1989 елда 143 кеше (татарлар), 2000 елда 118 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, умартачылык, сарык асрау.

Авыл атамасы кеше исеменә нисбәтле барлыкка килгән. Борынгы төрки-татар чыгышлы *Балтач* исеме ир бала балта кебек нык, үткен булсын дигән теләктән чыгып бирелгән. -*ч* иркәләү-кечерәйтүне белдерә.

**ЯҢА ҖИЯШ** авылы район үзәгеннән 19 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Биҗады суының югары агымы буенда урнашкан. 1732 елдан мәгълүм. 1989 елда 190 кеше (татарлар), 2000 елда 161 кеше яши. Халкының төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек.

Л. Ш. Арсланов фикеренчә, фин-угор халыкларында *җи/си* «су, елга» төшенчәсен белдерә, шуңа географик атамаларда еш очрый торган *–әш* кушымчасы ялганып, «сулы урын» мәгънәсен аңлата.

**ЯҢА КАДЕРМӘТ** авылы район үзәгеннән 23 км көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасының сул кушылдыгы Терпеле суы буенда урнашкан. Авылга XIX йөздә нигез салына. 1989 елда 42 кеше (татарлар), 2000 елда 31 кеше яши. Халкының төп шөгыле – сарык асрау.

Яңа Кадермәт авылы атамасы *Кадермөхәммәт* исеменең фонетик яктан кыскаруы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Гарәби чыгышлы кадер «дәрәҗә, хөрмәт; бәя, кадер» + гарәби чыгышлы Мөхәммәт 1) «макталган, мактаулы, данлыклы»; 2) ислам диненә нигез салучы Мөхәммәт пәйгамбәр исеме»[2].

**ЯҢА КОРМАШ** авылы район үзәгеннән 24 км көнбатыштарак, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы Шәбез суы буенда утырган. Авылга XIX йөздә нигез салына. 1989 елда 439 кеше

---

[1] *Саттаров Г. Ф.* Татар топонимиясе. – Б. 54, 212.
[2] *Саттаров Г. Ф.* Татар топонимиясе. – Б. 126, 183.

(татарлар), 2000 елда 393 кеше яши. Халыкның төп шөгыле – игенчелек, терлекчелек, умартачылык.

Куе урман белән капланган урынга Кормаш исемле кеше килеп урнаша. Агачларны кисеп, нигез корып җибәрә.

## Актаныш районының юкка чыккан авыллары[1]

**АБДУЛЛА** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында, Әзәкүл пристаненнан 25 км ераклыкта урнаша. 1930 елдан Актаныш районының Сәфәр, 1948 елдан Калинино районы Иске-Сәфәр, 1963 елдан Минзәлә районы Иске-Сәфәр авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 96 кеше (1930 ел, татарлар), 81 кеше (1963, татарлар). 1965 елда перспективасыз авыллар белән көрәш вакытында Актаныш районы Иске-Сәфәр авыл советына кертелә.

**АБРАМОВКА** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1963 елда Минзәлә районы Киров авыл советына керә. Халык саны – 141 кеше (1963, руслар). 1965 елда перспективасыз авыллар белән көрәш вакытында Актаныш районы Иске-Сәфәр авыл советына кертелә.

**АФАНАСЬЕВКА** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында, Әзәкүл пристаненнан 28 км ераклыкта урнаша. 1930 елдан Минзәлә районының Соранчаков, 1956 елдан Актаныш районының Иске-Богадин, 1963 елдан Минзәлә районы Иске-Богадин, 1966 елдан Актаныш районы Иске-Богадин авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 193 кеше (1930 ел, руслар), 74 кеше (1939, руслар), 96 кеше (1956, руслар), 85 кеше (1963, руслар). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**БАЙБУЛАТ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. Уфа губерниясе, Байлар волосте Калмаеш җирлеге составына керә. Белешмә басмаларда искәртелми.

[1] Исчезнувшие населѐнные пункты Республики Татарстан: справочник / под ред. Р. В. Шайдуллина. – Казань: Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, 2016. – 320 с.

**БИШКҮМӘЧ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Минзәлә районының Олыймән, 1956 елдан Калинино районы Олыймән, 1963 елдан Минзәлә районы Киров, 1966 елдан Актаныш районының Киров авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 286 кеше (1930 ел, татарлар), 187 кеше (1963, татарлар), 9 кеше (1979, татарлар). 1960 еллардагы перспективасыз авыллар белән көрәш вакытында җирлек юкка чыгарыла. Җирле халык Актаныш районының Олыимән авылына күченә.

**БУРАНЧЫ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Актаныш районының Күзәкин, 1963 елдан Минзәлә районы Күзәкин авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 94 кеше (1930, татарлар), 95 кеше (1939, татарлар), 43 кеше (1963, татарлар). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ДУГАЛЫ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. Халык саны – 191 кеше (1965). 1978 елда юкка чыгарыла.

**ЕЛАН** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында, Әзәкүл пристаненнан 46 км ераклыкта урнашкан. 1930 елдан Актаныш районының Чуракай, 1948 елдан Калинино районы Чуракай, 1963 елдан Минзәлә районы Чуракай, 1966 елдан Актаныш районының Чуракай авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 884 кеше (1930, татарлар). 1970 елда Елан авылы Актаныш районының Чуракай авылы составына кертелә.

**ЗИРЕКЛЕ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында булган, Яр Чаллы пристаненнән 88 км ераклыкта урнаша. 1930 елдан Акоязов, 1948 елдан Мөслим районы Варяш-Баш, 1963 елдан Сарман районы Мөслим, 1966 елдан Мөслим районы Мөслим авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 172 кеше (1930, татарлар). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ИЛТИМЕР** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Минзәлә районы Түкле, 1948 елдан Калинино районы Түкле, 1963 елдан Минзәлә районы, 1966 елдан Актаныш районы Түкле авыл советлары со-

ставларына кертелә. Халык саны – 90 кеше (1930, татарлар), 325 кеше (1939, татарлар), 238 кеше (1963, татарлар). 1992 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**КАЕНЛЫ ҖИЛӘК** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1963 елда Минзәлә районы Иске-Семиостров авыл советы составына кертелә. 1965 елда перспективасыз дип танылa.

**КАЛТАУ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. Халык саны – 195 кеше (1956, татарлар). Актаныш районы Яңа Кормаш авылы составына кертелә.

**КАРАҢГЫ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында Татар Ямалысы һәм Чалманарат авыллары арасында урнашкан. Белешмә басмаларда искәртелми.

**КИЧ-НАРАТ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында, Әгерҗе тимерьюл станциясеннән 137 км ераклыкта урнашкан. 1930 елдан Яңа Бикчәнтәй, 1956 елдан Минзәлә районы Дусай-Кичү, 1963 елдан Минзәлә районы Иске-Мелкен авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 167 кеше (1930, татарлар), 203 кеше (1939, татарлар), 152 кеше (1963, татарлар). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**КҮНТИ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Актаныш районы Яңа-Кормаш авыл советы составына кертелә. Халык саны – 149 кеше (1930, татарлар). 1930 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында, Әзәкүл пристаненнан 12 км ераклыкта урнашкан. 1948 елдан Актаныш районы Актаныш, 1963 елдан Минзәлә районы Актаныш авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 52 кеше (1956, татарлар). 1965 елда юкка чыгарыла.

**МАРИ-КАРАКҮЛ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. Белешмә басмаларда искәртелми.

**МАРИ ЯМАЛЫ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Актаныш районы Татар-Ямалысы, 1963 елдан Минзәлә районы Татар Ямалысы, 1966 елдан Актаныш районы Татар Ямалысы авыл советлары

составларына кертелә. Халык саны – 84 кеше (1930, марилар), 72 кеше (1963, марилар). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**МАРТЫНЛЫ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. Беренче тапкыр 1706 елда искә алына. Белешмә басмаларда искәртелми.

**НАРАТЛЫ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында, Әзәкүл пристаненнан 40 км ераклыкта урнашкан. 1930 елдан Актаныш районы Наратлы, 1935 елдан Калинино районы Өске Яхшеев, 1956 елдан Актаныш районы Өске Яхшеев авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 310 кеше (1939, татарлар), 206 кеше (1963, татарлар). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ОЗЫН КҮЛ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Актаныш районы Чогынлы авыл советы составына кертелә. Халык саны – 17 кеше (1930, татарлар). 1930 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ОМАНАЕВ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. Халык саны – 246 кеше (1963). 1966 елдан соң белешмә материалларда искәртелми. Җирле халык Актаныш районы Күзәке авылына күчерелә.

**ОРДАЛЫ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1948 елдан Актаныш районы Татар Әзибәе авыл советы составына кертелә. Халык саны – 146 кеше (1956). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ПИЧМӘН ЕЛГА** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. Белешмә басмаларда искәртелми.

**РУС ӘНӘБИЕ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Актаныш районы Рус Әнәби, 1963 елдан Минзәлә районы Татар Әнәби, 1966 елдан Актаныш районы Татар Әнәби авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 660 кеше (1930, руслар). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**САРМАК** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1752 елдан билгеле. Белешмә басмаларда искәртелми.

**СӘФӘР**, посёлок. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Актаныш районы Татар Ямалысы авыл советы составына кертелә. Халык саны – 135 кеше (1931, татарлар). 1940 елларның азагыннан белешмә басмаларда искәртелми.

**СОРАНЧЫК** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында, Әзәкүл пристаненнан 30 км ераклыкта урнашкан. 1930 елдан Соранчык, 1963 елдан Минзәлә районы Аккүз авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 286 кеше (1930, руслар). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми. 1963 елда перспективасыз авыллар белән көрәш вакытында юкка чыгарыла. Җирле халык Актаныш районы Михайловка авылына күчерелә.

**СЫРТЛАН** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1752 елдан билгеле. Белешмә басмаларда искәртелми.

**ТАЛДЕЕВ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1745 елдан билгеле. Белешмә басмаларда искәртелми.

**ТАРЫШ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Актаныш районы Акбәз авыл советы составына кертелә. Халык саны – 65 кеше (1930, татарлар). 1930 еллардан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ТАТАР ӘҖМӘТЕ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. Белешмә басмаларда искәртелми.

**ТАШЛЫЯР** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Ташлыяр, 1948 елдан Калинино районы Пучы, 1956 елдан Мөслим районы Ташлыяр, 1966 елдан Актаныш районы Пучы авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 757 кеше (1930, татарлар), 869 кеше (1939, татарлар), 99 кеше (1963, татарлар). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ТИМЕР КУЛ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында, Әзәкүл пристаненнан 17 км ераклыкта урнашкан. 1948 елдан Актаныш районы Яңа Әлем, 1963 елдан Минзәлә районы Яңа Әлем, 1966 елдан Актаныш районы Яңа

Әлем авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 101 кеше (1956, татарлар), 159 кеше (1939, татарлар), 144 кеше (1963, татарлар), 150 кеше (1965, татарлар). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми. 1965 елда перспективасыз авыллар белән көрәш вакытында юкка чыгарыла. Җирле халык Актаныш районы Яңа Әлем авылына күчерелә.

**ТОРБЫШКЫ**, шәһәр тибындагы бистә. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1948 елдан Торбышкы, 1963 елдан Минзәлә районы Торбышкы, 1966 елдан Актаныш районы Торбышкы авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 546 кеше (1938, нигездә татарлар һәм руслар), 2938 кеше (1949), 3470 кеше (1959), 2604 кеше (1970), 1110 кеше (1979), 800 кеше (1989). 1970 елда Түбән Кама сусаклагычы территориясенә эләгеп, су астында кала. 1998 елда торак пунктлар исемлегеннән төшерелә. 1990 елллар уртасыннан даими халык саны күзәтелми.

**ТҮБӘН АКБӘЗ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Актаныш районы Акбәз авыл советы составына кертелә. Халык саны – 193 кеше (1930, татарлар). 1930 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ТҮБӘН ПОКРОВКА** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Актаныш районы Акбәз авыл советы составына кертелә. Халык саны – 19 кеше (1930, руслар). 1930 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ТҮБӘН ТАКТАЛАЧЫК** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. Халык саны – 213 кеше (1963). Перспективасыз авыллар белән көрәш вакытында юкка чыгарыла. Җирле халык Актаныш районы Такталачык авылына күчерелә.

**ЧИРӘМ КОЛАК** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1976–1978 елларда авыл халкы күченә. Белешмә басмаларда искәртелми.

**ЧИШМӘ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Мөслим районы Исәнсоп, 1935 елдан Калинино районы Исәнсоп, 1956 елдан Актаныш

районы Чишмә, 1963 елдан Алабуга районы Наҗар, 1966 елдан Актаныш районы Чишмә авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 201 кеше (1930, татарлар), 200 кеше (1939, татарлар), 326 кеше (1956, татарлар). 2005 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ЧИЯЛЕК** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1948 елдан Калинино районы Чуракай, 1956 елдан Актаныш районы Соранчык, 1963 елдан Минзәлә районы Иске Байсар, 1966 елдан Аккүз, 1986 елдан Актаныш районы Байсар авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 63 кеше (1956, татарлар), 90 кеше (1963, татарлар). 2005 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ЫК**, посёлок. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1963 елдан Минзәлә районы Пучы, 1966 елдан Актаныш районы Пучы авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 146 кеше (1930, руслар). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ЯҢА БИКЧӘНТӘЙ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында, Әгерҗе тимерьюл станциясеннән 135 км ераклыкта урнашкан. 1930 елдан Актаныш районы Яңа Бикчәнтәй, 1948 елдан Яңа Бикчәнтәй, 1956 елдан Дусай Кичү, 1963 елдан Минзәлә районы Иске-Мелкен авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 157 кеше (1930, татарлар). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ЯҢА КӨЛӘГЕШ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. Белешмә басмаларда искәртелми.

**ЯҢА ПУЧЫ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1948 елдан Калинино районы Пучы, 1963 елдан Минзәлә районы Пучы авыл советлары составларына кертелә. 1963 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми. 1965 елда перспективасыз авыллар белән көрәш вакытында юкка чыгарыла. Җирле халык Актаныш районы Пучы авылына күчерелә.

**ЯҢА СОЛТАНГЫЛ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында, Әзәкүл пристаненнан 19 км ераклыкта урнашкан. 1948 елдан Актаныш районы Иске-

Солтангыл, 1963 елдан Минзәлә районы Иске-Богадин, 1966 елдан Актаныш районы Иске-Богадин авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 195 кеше (1939), 113 кеше (1963). 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ЯҢА ТЕЛӘКӘЙ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1930 елдан Актаныш районы Иске Теләкәй авыл советы составына кертелә. Халык саны – 111 кеше (1930, татарлар), 1956 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ЯҢА ЮЛ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында, Әзәкүл пристаненнан 20 км ераклыкта урнашкан. 1948 елдан Иске Әлем, 1956 елдан Актаныш районы Чишмәле, 1963 елдан Минзәлә районы Яңа Әлем, 1966 елдан Актаныш раоны Яңа Әлем авыл советлары составларына кертелә. 1966 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ЯКТЫ** авылы. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. 1948 елдан Татар Ямалысы, 1956 елдан Актаныш районы Татар Суыксуы, 1963 елдан Минзәлә районы Татар Суыксуы авыл советлары составларына кертелә. Халык саны – 50 кеше (1956, татарлар). 1963 елдан соң белешмә басмаларда искәртелми.

**ЯҢА АВЫЛ** («Победа» колхозы), авыл. Хәзерге Татарстан Республикасы Актаныш районында урнаша. Белешмә басмаларда искәртелми.

# АВЫЛ – МИЛЛӘТНЕҢ ТЕРӘГЕ

## Авыллар тарихыннан

*Фирдәвес Гарипова*

Актаныш ягында авыллар бик күркәм. Йортлары балкып тора, тәрәзә төпләре тулы гөл, халкы кунакчыл.

Халык әби-бабалары, аларның ничек яшәүләре, авыллар тарихы белән кызыксына. Шактый авылларның кыскача тарихы язылган. Анда колхоз төзү, сугыш еллары турында рәсем-документлар, сугышта һәлак булган авылдашларының исемнәре теркәп куелган. Кайберләрендә мәктәп-мәдрәсәләр турында да мәгълүмат саклана.

### Актаныш

Район үзәге булган Яңа Актаныш тау өстендә утыра. Актаныш бистәсе утырган тауның бер өлешен Ирмәш, икенче өлешен Текә тау дип йөртәләр. Агыйдел ягыннан караганда Актаныш очарга канат каккан аккошны хәтерләтә. Яшеллеккә төренгән күп катлы ак биналар менә-менә зәңгәр күккә ашар кебек.

Халык телендә Иске Актаныш дип йөртелә торган авыл белән Яңа Актанышны озын баскыч тоташтыра. Ул баскыч тау битендә булганлыктан, еректан караганда аеруча матур булып күренә.

Бүгенге Актаныш авылы урынына кешеләр моннан 300 ел элек күчеп утырганнар. Элек исә авыл хәзерге Нөркә урманының көньяк-көнчыгыш өлешенә урнашкан булган. Актаныш атамасының килеп чыгышына карата халыкта мондый риваять йөри.

Бер кешегә каяндыр кунак килә. Өй хуҗасының ындыр табагында ашлык суккан чагы була. Килгән кеше, хуҗаның кечкенә малаен капка төбендә очратып, әтисенең кайда икәнен сорый һәм аны чакырып килергә куша. «Миңа синең әтиең таныш бит», – дигән сүзне дә әйтә. Кунак ак чырайлы кеше булганлыктан, малай әтисенә барып:

– Ак танышың килгән, сине чакыра, – ди икән.

Шуннан хуҗа кеше, дусты янына килеп, исәнлек-саулык сорашкач:

– Минем малай сине «ак танышың» дип атады, – дип көлеп сөйләгән имеш.

Шуннан бу малайның үзенә «Ак таныш» кушаматы береккән. Ул вакытта авыл янындагы елгада су тегермәне өчен шактый тирән буа була. Су коенганда әлеге «Ак таныш» кушаматлы малай батып үлгәч, аны «Актаныш» буасы дип йөртә башлыйлар, тора-бара бу исем елгага күчә, аннары авыл да «Актаныш» дип атала башлый...

Икенче риваять буенча, Актаныш «аккошлар иле» булган. Ә аккошлар табигатьнең иң саф, изге һәм матур урыннарын сайлыйлар… Ихтимал, бу риваятьтә дә хаклык бардыр.

Актаныш Агыйдел һәм Иске Идел елгалары буена утырган. Авыл уртасыннан Актаныш елгасы ага. Аңа инеш кушыла. Авылны бизәгән Ак инешне һәрвакыт карап һәм чистартып торалар. Авылдан ерак түгел генә Озын күл, Чөгәнә күле, Бака күле, Үлек күле җәелеп ята. Авыл читендә Куян сазлыгы дип исемләнгән сазлык барлыгын да әйтик.

Актанышның ике ягында – Нөркә һәм Бүләк урманнары. Бүләк урманы янындагы чишмә матур агач корылма белән уратып алынган. Аны чистартып һәм корылмасын буяп торалар.

Авыл янында Олый басуы белән Нөркә яланы бар. Халык Әргәнеш, Ташком, Озын күл һ. б. урыннарда печән чаба.

Актаныш – республикабыз тарихына кdirectlyлек күренекле кешеләр, биш Советлар Союзы Герое, Социалистик Хезмәт Геройлары, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә танылган күп кенә шәхесләр биргән төбәк.

Инде Актаныш төбәгендәге кайбер авылларның кыскача тарихына тукталып үтик.

### Аккүз авылы

Элек Аккүзне Югары Ахун дип, ә күршедәге Ахун авылын Түбән Ахун дип йөрткәннәр.

Сөн буендагы Аккүз авылы янында археологлар бура культурасына мөнәсәбәтле торлак (стоянка) тапканнар[1].

1870 елгы мәгълүматларга караганда, Аккүздә 120 йорт булып, аларда 592 кеше яшәгән (306 сы ир-ат, 286 сы хатын-кыз). Авылда мәчет, мәдрәсә эшләгән[2].

Аксакаллар сөйләве буенча, авыл элекке заманнарда урман эчендә, хәзерге урыныннан бер чакрым чамасы ераклыкта булган. XIX гасырның 70 нче елларында Аккүз халкы элек марилар яшәгән урынга килеп утырган. Бабайлар фикеренчә, халык бирегә хәзерге Башкортстанның Җәнәй авылыннан күчеп килгән.

Элек авылда байларга ялланып хезмәт иткән җирсез крестьяннар яшәгән. Аларны типтәрләр дип йөрткәннәр. Ахун, Кәсәй, Төхфәй, Нури һәм Мөхәммәтҗан мулла зур байлардан саналган. Нури байның хәтта авыл хуҗалыгы машиналары да булган. Бу бай йортының аскы каты әлегә кадәр сакланып калган (элегрәк ул мәктәп хезмәтен дә үтәгән). Авыл Алексей Дедюхин дигән рус алпавыты кул астында булган. Аның тегермәннәре, күпсанлы машиналары булуы билгеле. Авыл халкының йорт нигезләренә салынган әлеге тегермән ташлары бүгенгә кадәр сакланган.

Дедюхин кызу канлы, каты куллы кеше булган дип сөйлиләр. Нәселле атлар асраган һәм алар белән горурланган алпавыт бервакыт үзенә килгән кунак белән: «Актаныштан Аккүзгә атта чабып 45 минутта кайтып җитәм», – дип бәхәсләшкән. Тик Алексейның аты бу вакыт эчендә кайтып җитә алмый. Шуннан соң ул атыннан төшә дә, кесәсеннән револьвер алып, аны атып үтерә.

---

[1] Археологические памятники Восточного Закамья. – Казань, 1989. № 681. Алга таба бу хезмәт «Археологические...» дип биреләчәк.

[2] Список населённых мест по сведениям 1870 года: XIV. Уфимская губерния. – СПб., 1877. – 112 б. (Алга таба – «Список...»).

Авылда Шәйхелислам Фәтхетдинов урамы бар. Бу кеше алда телгә алынган Нури байның улы. Ул 1905 елгы революциядә катнашып, революционер буларак таныла. Нури байның оныклары арасында сугышта катнашып майор, полковник дәрәҗәсенә җитүчеләр дә бар.

Аккүз авылы Актаныш районының бик матур җирендә урнашкан. Сөннең авыл яныннан агып үткән җирендә Кара мунча дип аталган урын бар. Бик күпләрнең фаҗигале үлеменә сәбәп булган урын ул. Аннан ерак түгел генә Сөнгә коя торган Боланай ерымы. Ул болынны икегә бүлә. Шушында ук Бурлы бүләк дип йөртелә торган куаклы һәм сулыклы җир бар. Авыл өстендәрәк Сөрәнчек басуы. Монда элек авыл булган, сугыштан соң ул юкка чыккан. Биредәге топонимнардан тагын Кыска күл, Карга куагы, Зәйди сазы, Мари зираты, Кызыл тау, Козгын әрәмәсе, урман ягында Чатра, Сулы куак, Кырыклы, Бакыр тавы, Полковник чокыры, Елкыч, Төхфәй күпере, Матур күл ягы, Үле Сөн һ. б. ны санарга мөмкин.

## Ирмәш авылы

1870 ел мәгълүматлары тупланган авыл атамалары исемлегендә «Чишмә инеше ярына утырган Ирмәш авылының 35 хуҗалыгында ислам динендәге 95 ир-ат һәм 97 хатын-кыз яши» дип теркәлгән (Список..., № 1974, 112).

Олы буын кешеләре сөйләвенә караганда, авылның оешуы болай булган. Агалы-энеле Ирмәш һәм Шәриф исемле ике туган, төпләнер өчен урын эзләп йөргәндә, бик матур җиргә килеп чыкканнар. Якында гына Агыйдел елгасы аккан. Бер ягында тау, икенче ягында күл җәелеп яткан. Ирмәш дигәненә бу урын бик ошаган һәм ул шунда төпләнеп калган. Шуннан бирле авыл аның исемен йөртә икән. (Ә Шәриф исемлесе Шәриф авылын нигезләгән.)

Авылга якын гына урында Иске Идел бар. Башта бу елга Агыйделгә тоташкан була, әмма, дамба төзелгәч, алар аерыла. Иске Идел тирән һәм киң булган, элек анда хәтта пароходлар йөзгән. Дамба төзелгәч су киткән, елга да тарайган, саеккан. Ул үзәндә урман үскән. Янында болын бар, аны Әргәнеш дип

йөртәләр. Авыл халкы, Идел аша көймәләргә утырып чыгып, бу болынга печән әзерләргә йөргән. Авылдан ерак түгел генә ике күл бар, аларның берсен – Озын күл, икенчесен Үлек күле, дип йөртәләр. Элегрәк бу күлдә үлгән кешеләрнең киемнәрен чайкаганнар. Ел саен яз көне, кар сулары эрегәч, зур гына тагын бер күл барлыкка килә һәм бер-ике айдан кибеп бетә икән. Аны авыл халкы Бака күле дип йөртә. Басуда Куян сазлыгы дип йөртелгән сазлык бар. Авылдан ерак түгел генә Бүләк урманы үсә. Монда Кәҗә баткагы, Кара тәкә, Ак тәкә дигән күлләр урнашкан. Авыл янында көтүлек җәелеп ята. Аны Олый (Алый) басуы дип йөртәләр.

### Иске Байсар һәм Яңа Байсар авыллары

Сөн суы җәелеп яткан матур урында Иске Байсар һәм Яңа Байсар авыллары урнашкан.

Иске Байсар авылы янында археологлар бура культурасына нисбәтле каберлек табалар. Байсар авылы тарихи җыентыкта да теркәлгән. Ул 1785 елның гыйнвар аенда граф А. К. Разумовскийга җир сату унае белән искә алына. 1870 елда Иске Байсар авылындагы 182 хуҗалыкта 419 ир-ат һәм 388 хатын-кыз яшәгән. Авылда волость идарәсе, ике мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, 16 кибет булган. Шимбә көн базар үткәрелгән. Авыл халкы чабата үреп саткан һәм тәгәрмәч ясаган (Список..., 107).

Безгә бу авылларның ничек оешуы хакында Хәйретдин абый белән Әхмәдулла абый сөйләде. Казаннан өч карт Идел буена килгәннәр. Картларның берсе – Байсар, икенчесе Чуракай исемле булган, алар шул исемдәге авылларны нигезләүчеләр икән. Өченче карт Идел буена урнашкан.

Иске Байсар авылы оешуга 600 еллап бар. Элек бу тирәләрдә кешеләр яшәмәгән, тоташ урман булган. Тора-бара авыл зурая, кешеләргә җир-су җитми башлый, һәм авыл халкының бер өлеше 1892 елда, бераз читкәрәк күчеп утырып, Яңа Байсар авылына нигез сала.

Минемчә, Байсар атамасы нугай кабиләләре берлеге чорындагы «байсар» этнонимына (ыру исеменә) нисбәтле. Башкортстанның Яңавыл районында Байсар исемле авыл, Казакъстанда

Байсар исемле күл булуы билгеле. Кыргыз-казакъларның ак-найман ыруында байсар төркемчәсе оешып калган. Шулай итеп, байсарларның бер өлеше казакъ һ. б. төрки халыкларны оештыруда катнашса, икенчеләре исә татар халкы этногенезына өлеш керткән. Моннан тыш, Удмурт республикасында Байсар исемле татар авылы булуы мәгълүм. Мари галимнәре фикеренчә, Байсар исеме мариларга татар теленнән кергән: Пайсар – мари кенәзе. Вятка губернасының Уржум өязендә Пайсарово пүчинкәсе булуы мәгълүм. Арзамас татарларындагы Янсар исеме дә игътибарга лаек.

Байсар авыллары яныннан Сөн суы агып уза һәм ул Агыйделгә барып кушыла. Сөн буйларында җырлы чишмәләр бик күп. Әрәмәләрендә балан, миләш, гөлҗимеш, кура, карлыган һ. б. агачлар, куаклар үсә. Авыл тирәләрендә зирек, каен агачлары да бик күп. Зирекле күл атамасы монда зирек үсүгә мөнәсәбәтле. Ә менә Чатра кәҗүнние атамасы каен агачлары үсү белән бәйләнешле. Алкаби тавы янында чия агачлары үскәнлектән, бу урын Чиялекләр дип атала.

Сөн суына кечкенә инеш-ермаклар (Комтамак, Асылтамак, Көҗекә, Чатра, Әҗекәш, Сәфәр суы, Шәүлегән, Исәмәт, Печмән, Бия суйган елгасы, Сикия, Калмия һ. б.) килеп кушыла. Завод күле, Чүкеч, Мунчала, Плат, Дуга, Зирекле һ. б. күлләр, Мүк сазы, Ачылы саз, Ачы арасы сазлары, Әүлия, Батрай, Әндрәй чишмәләре, Каравыл тавы, Карга, Чәүкә, Җимерек, Төкәй, Борынчык таулары – барысы да шушы як атамалары.

Иске Байсар авылы эстон язучысы Лилли Прометның «Деревня без мужчин» дип аталган романында искә алына. 1941 елның җәендә бер төркем эвакуацияләнгән эстонлылар татар авылына киләләр. Романда вакыйгалар Иске Тәкмәк атамасы белән бәйләп алып барыла. Ләкин халык сөйләвенә караганда, Иске Тәкмәк дип искә алынган авыл Иске Байсар, ә Яңа Тәкмәк – Яңа Байсар икән.

Язучы Иске Байсар авылын болай сурәтли:

«Картлар монда русча начар сөйләшәләр, ә хатын-кызлар кул хәрәкәтләре белән генә аңлашалар, шуңа да карамастан, безнең бөтен эшебез җайланды. Авылның һәр йортыннан безнең янга

кулына йә ләгән, йә керосин лампасы, йә чиләк, йә учактан күмер чүпләү өчен шепши (кыскыч) тоткан хатын-кызлар кердә. Алар сәке кырыена утырып, башларын селки-селки безне җәлләп үз телләрендә бик матур итеп нәрсәдер сөйләштеләр. Тильденең бу хәлгә исе китте. Еэвегә ул:

– Монда әйбәт кешеләр яши икән, – диде. – Йә, әйт, кемнәр генә тагын менә шулай эшләр иде икән?

Эстон качаклары башта үзләрен колхозның вакытлы кешеләре дип кенә исәплиләр, өйләренә кайту көннәрен көтеп яшиләр. Авыл Шайтан суы ярыннан башлана, аның беренче йортының бусагасы нәкъ су янына чыга, ә соңгысы тау өстендә, яшь имән урманы янында урнашкан.

Елга зур авылны икегә – Иске Тәкмәк һәм Яңа Тәкмәк авылларына бүлә. Җәй көне аның суы саега, урыны-урыны белән бөтенләй кибә һәм сары төбе генә күренеп кала. Димәк, бу вакытта авылларны бүлә торган чик тә юкка чыга. Иске Тәкмәк авылы тормышы каты режимга корылган. Иртә таңнан бригадир барлык халыкны тәрәзә кагып эшкә чакыра, амбар янында аларга тырма, сәнәк, чалгы бирәләр һәм эшкә яраклы бар кеше басуга китә, авыл балалар карамагында кала. Гөлҗимеш куаклары арасында бары тик бал кортлары гына гөжли.

Төш вакытында авылда җанлану башлана. Морҗалардан, нәкъ мәче койрыгы кебек туп-туры булып, төтен күтәрелә. Басудан балаларын ашату өчен йөгерә-чаба кайткан хатын-кызлар зур мискине ишек алдындагы чирәмгә куялар һәм барлык гаилә, зур агач кашыклар тотып, шулпа ашарга керешә.

Бу минутларда балаларны берни дә: чуар каурыйлы тавыклар да, йомшак песи балалары да кызыксындырмый, алар борыч яндырган авызларын ачып, сирәк-мирәк кенә күзләренә бәреп чыккан яшьләрен сөртеп алалар.

Төштән соңгы тынлык кичкә кадәр дәвам итә. Кич белән хатын-кызлар елга аша чыгып Яңа Тәкмәк авылының элемтә үзәге каршындагы эскәмиягә тезелешеп утыралар. Шул вакыт аларның кайберләренә „Бие!” дип әйтәләр һәм өчпочмаклы конверт биреп шатландыралар».

## Меңнәр авылы

Бу авыл тарихи чыганакларда шактый искә алына. 1870 ел мәгълүматларын туплаган белешмәлектән күренгәнчә, Меңнәр авылының 100 хуҗалыгында 250 ир-ат һәм 246 хатын-кыз көн иткән. Анда мәчет, мәдрәсә эшләгән. Халык умартачылык һәм итек тегү белән шөгыльләнгән (Список..., № 1977, 112).

Авыл исеме ничек барлыкка килгән соң? Халык телендә мондый легенда-риваять яши.

Моннан күп еллар элек берничә кеше үзләренә тормыш итәргә урын эзләп йөргәннәр. Кая гына барып урнашсалар да, аларны куып җибәрә торган булганнар. Йөри торгач, шушы урынга килеп чыгалар һәм бүтән беркая да китмәскә булалар. Аларны бу җирдән куарга теләүчеләргә: «Без бу урыннан китмибез, без аз булмабыз, бик күп, меңнәр булырбыз», – дигәннәр. Бу, әлбәттә, халык этимологиясе, Меңнәр исеменә яраклаштырып халык уйлап чыгарган матур легенда.

Меңнәр атамасы «мең» ыруына мөнәсәбәтле булса кирәк. Танылган галим Марсель Әхмәтҗанов бу фикерне тарихи яктан саллы итеп дәлилли. Шулай ук борынгы төркиләрдә дә «меңнәр» этнонимының булуын истә тотарга кирәк. Мең кабиләләре шушы урынга килеп утырган һәм авылны үз исемнәре белән тамгалап куйган.

Авыл кечкенә булса да, аның табигате бик бай. Авылга кергәндә, юлның бер ягында каеннар, ә икенче ягында күл кала. Авылга терәлеп үк Сөн елгасы ага. Елганың аръягында еракларга җәелеп киткән урман шаулый. Урман эчендә бик күп таулар, аланлыклар, печәнлек һәм чишмә-кизләүләр бар. Авыл янындагы Туры тауда бала-чага кышын шау-гөр килеп чана һәм чаңгы шуа. Кыпчак сибе, Өянкеле чишмә, Вак каенлык исемле җиләкле аланлыклар, Йомры күл, Якты күл, Чүкеч күле, Чәйле күлләр буенда хуш исле печәнлекләр бар. Авылга якын гына бик зур Балыклы күл җәелеп ята.

Авыл янында гына күңелдә шом уята торган Убыр күле урнашкан. Су коенырга кергән кешене төпкә суыра, диләр аның турында. Элеккеге байлар, колхозлашу чорында, барлык алтын-көмешләрен шул күл төбенә ташлаганнар, дигән сүзләр дә йөри.

## Пучы авылы

Пучы авылыннан Мәэлүфә Мирзаянова сөйләвенә караганда, 1553 еллар тирәсендә бу якларга Пучы һәм Тучы исемле кешеләр килеп чыккан. Тучы дигәне киткән, ә Пучы урман кисеп, агач төпләп, өй салган һәм монда яши башлаган. Авыл исеменең килеп чыгышын нәкъ менә шушы Пучы исеменә бәйләп аңлаталар да инде.

Пучы авылының уртасыннан Сарашлы елгасы ага. Тирәюньдә Мазар елгасы, Ык елгасы, Кара Яр сулыгы, Өч аеры күле, Килтекәй чокыры бар. Пучыда Кәлтә-елан чишмәсе, Салкын чишмә, Әнәк чишмәсе, Әхмәт чишмәсе челтерәп ага. Авылдан ике-өч чакрым ераклыкта Очлы сырт дип йөртелгән калкулык бар. Якын-тирәдәге урманнарны халык Әнәк урманы, Уразлы урманы, Бәләкәй урман, Бүләк урманы дип атап йөртә. Кайсы якта урнашуларына карап, басуларга түбәндәге исемнәр бирелгән: Кара Яр ягы, Килтекәй ягы, Бүләк урманы һ. б. Мәчет күпере, Тәкәрлек күперенең исемнәре дә урнашкан җирләренә карап кушылган.

## Табанлыкүл авылы

Авыл Табанлы күл суы буена урнашкан. 1877 елда басылып чыккан белешмәлектә күрсәтелгәнчә, ул вакытта авылда 49 хуҗалыкта 138 ир-ат һәм 125 хатын-кыз яшәгән (Список..., № 1895, 109).

Өлкәннәр сөйләвенә караганда, авылга 1820–1828 елларда хәзерге Башкортстанның Бакалы авылыннан килгән бертуган Әлмәт белән Колмәт нигез салган. Ул вакытта тирә-як калын урманнар белән капланган булган, урман эченнән инеш аккан, янында матур гына күл дә булган. Күлдә табан балыгы күп үрчегән. Күлнең матурлыгына, табан балыгының күплегенә сокланып, аңа «Табанлы күл» дигән исем биргәннәр. Хәзер инде бу күл кипкән...

Авылның көнчыгыш ягында Бия суйган, ә көньягында Имәнлек исеме алган урманнар бар. Бия суйган атамасын халык болай аңлата: көндез эшләп алҗыган атларны, кемнәрдер, төнлә шул урманда суя торган булганнар. Эш атлары бия булганга,

урман «Бия суйган» дип йөртелә башлаган. Имән агачлары үскән көньяктагы урманга «Имәнлек» дигән исем биргәннәр. Авылдан 3 чакрым арырак Кыр станы, 4 чакрым ераклыкта Әлмәт тау башы басулары урнашкан. Сугыш вакытында басуларда төн кунып эшләгән хатын-кыз һәм яшүсмерләр кыр станында йоклаганнар. Анда аларга, йоклар өчен, махсус йортлар да төзелгән булган.

Элек авылда тирә-якта дан тоткан зур мәдрәсә эшләгән. Анда атаклы Иж-Буби мәдрәсәсендә укып кайткан Хафиз хәзрәт мөгаллимлек иткән. Тирә-юньдәге зыялылар Табанлыкүл мәдрәсәсендә белем алганнар. Хафиз хәзрәтне яманаты чыккан 30 нчы елларда төнлә алып китәләр, һәм ул эзсез югала... Мәчет манарасын 1936 елда кисәләр.

Авылдан 8 чакрым ераклыкта Башкортстанның Төкәй авылы янындагы Төкәй тавы күренеп тора. Аннан Пугачев явы да үткән. Бу тау икенче төрле «Алып баба чабата каккан тау» дип йөртелә. Билгеле, мондый исемдәге таулар башка җирләрдә дә очрый...

## Яңа Балтач һәм Иске Балтач авыллары

1870 елдагы мәгълүматларны үз эченә алган белешмәлектә Яңа Балтач авылы болай сурәтләнә: «Шәбез суы ярына утырган Яңа Балтач авылының 24 йортында 99 ир-ат һәм 93 хатын-кыз көн күргән. Шәбез суында 2 су тегермәне эшләгән» (Список..., № 1958, 111).

Өлкәннәр фикеренчә, Яңа Балтач белән чагыштырганда, Иске Балтач борынгырак. Яңа Балтач авылына Иске Балтач кешеләре нигез салган. Иске Балтач авылының бер гаиләсеннән 3 егет өйләнәләр һәм булачак Яңа Балтач урынындагы урманнарны кисеп, Шәбез суының аръягына, тау башына килеп утыралар. Авылга «Яңа Балтач» дигән исем бирәләр.

Авылның тирә-юнен урманнар, таулар, чокырлар, кечкенә елгалар әйләндереп алган. Шәбез суы хәзер кечерәйгән, саеккан. Буып куйган елларны ул мул сулы буага әйләнә торган булган. Шәбез суыннан ерак түгел урнашкан күлне халык «станция» сүзеннән Станса күле дип йөртә. Бу сулыкта элек авылның

электр станциясе урнашкан булган. Авылга беренче электр утын да шул станция биргән.

Авылның икенче ягыннан кечкенә генә инеш – Почманкүл ага. Ул елганың ярлары биек булса да, суы аз. Ләкин ул кипми, һаман ага бирә. Еракларга сузылган Почманкүл ярларында каен урманы үсә. Халык ул урынны «Тау башы» дип атый. Ә Почманкүл елгасы башланган урындагы урманны халык «Почманкүл башы» дип йөртә. Тау башы, уңдырышлы кырлар аша үтеп, Мәчет рушасы дигән урманга тоташа. Урман янында сазлык бар. Сазлыкның аргы ягындагы урман Саз аръягы дип йөртелә. Бу урман җиләккә бик бай. Авыл халкы көнкүрештә кулланыла торган (әйтик, яшелчәгә сибү өчен) суны коедан ала, чәй һәм аш-су өчен тотыла торганын чишмәдән алып кайта. «Чәй суы» ала торган чишмә авылдан читтәрәк урнашкан ярдан ага. Чишмәгә төшә торган басма бик матур. Кызыл ярдан ага торган салкын, чиста сулы бу чишмәгә «Салкын чишмә» дигән исем биргәннәр. Авыл зур юлдан читтәрәк урнашкан, ул юлның авылга кереп китә торган борылышында ике имән үсә. Кайтучыларны каршы ала, китүчеләрне озатып кала торган ике имән янында тукталып, узган юлга, узган гомергә борылып карау мөмкинлеге туа сыман.

* * *

Республикабызның беренче Илбашы М. Ш. Шәймиев кебек зур шәхесне тәрбияләп үстергән район авыллары белән танышканда, менә шулай, тарихка да, ерак киләчәккә дә күз ташлыйсың, рухи башкалабыз булган Авылның милләт язмышында тоткан урыны турында тагын бер кат уйланасың.

Актаныш төбәгендә туган якларына тугры, милләтпәрвәр шәхесләр яшәвен күреп сөендек без. Алар арасында үз авылларының үткәне белән кызыксынучылар, аны җентекләп өйрәнеп, тарих битләренә теркәп калдырырга омтылучылар байтак. Туган як тарихының яңа сәхифәләрен нәкъ менә алар язар әле.

# АКТАНЫШ РАЙОНЫ МИКРОТОПОНИМИЯСЕ

*Олег Хисамов*

Тел белеменең иң актуаль мәсьәләләренең берсе булып ялгызлык атамаларын, аларның мәгънәсен, килеп чыгышларын, номинация принципларын, атау мотивларын өйрәнү тора. Әлеге эш белән лексикологиянең аерым бер өлкәсе – ономастика шөгыльләнә. Ономастиканың топонимика тармагы исә барлык төр географик атамаларны җентекләп тикшерә.

Географик атамалар иң мөһим мәдәният һәйкәлләреннән санала. Төрле телләрдә, төрле вакытта барлыкка килеп, алар кешелекнең күп гасырлык тарихын: табигый яшәү шартларын, матди, рухи һәм мәдәни тормышларын өзлексез үсештә чагылдыралар.

Топонимик лексика теге яки бу телнең сүзлек составының аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Шуңа күрә географик атамаларның мәгънәсен ачыклау, лингвистик һәм экстралингвистик факторларның атамалар сайлауга тәэсир итү дәрәҗәсен өйрәнү, атама сайлауның мотивларын тикшерү һ.б. хәзерге тел белеменең актуаль мәсьәләләреннән берсе санала.

Топонимика фәне нәтиҗәләре, тел белеменнән тыш, халык һәм тел тарихларын өйрәнүгә зур өлешен кертә, шулай ук тарих, археология, этнография, тарихи география һ.б. фән тармаклары өчен дә ярдәмче ролен башкара.

Топонимнарда теге яки бу төбәкнең һәм халыкның тарихы фотосурәткә төшергән төсле сакланып кала. Шул ук вакытта то-

понимнар, аеруча микротопонимнар – бик нәзберек атамалар. Зур топонимнар, бигрәк тә гидронимнар, борынгы вакытлардан безнең көннәргә кадәр ниндидер үзгәрешләр кичереп булса да килеп җитсәләр, микротопонимнар белән ситуация башкачарак. Аларның күбесе рәсми рәвештә бернинди базаларга да кертелмәгән. Рәсми документларда теркәлмәгән. Күбесенчә халыкның хәтерендә генә саклана. Кечкенә атамаларны белүче өлкәннәр китеп бетеп бара, ул атамаларны бик тиз алыштырып куярга да мөмкиннәр. Шулай ук кайбер атамаларның объектлары ук юкка чыгарга мөмкин. Шунлыктан микротопонимнарны җыю, өйрәнү һәм системага салу – бүгенге көндә бик тиз эшләнергә тиешле эш. Елгалар, күлләр, чишмәләр кибеп юкка чыга. Басуларны урманнар капларга, урманнар киселеп бетәргә мөмкин. Татарстан территориясендә су басуга бәйле рәвештә күпме урманлыклар, болын, басулар, хәтта ки зур-зур авыллар юкка чыкты. Бүгенге көндә аларның атамаларын белүче кешеләр дә инде кимеп бара.

Шушыларны истә тотып, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында 2014 елдан башлап Татарстан топонимнарының электрон каталогы эшләнә башлады. Әлеге каталог 2014–2022 елларда Татарстанның дәүләт телләрен һәм республикада яшәүче башка халыкларның телләрен саклау, үстерү дәүләт программасы кысаларында эшләнә һәм бүгенге көндә анда 7000 нән артык топоним бар. Ул https://toponym.antat.ru адресы буенча урнаштырылган.

Әлеге каталогка материалны институт хезмәткәрләре ел саен комплекслы экспедицияләрдә туплыйлар. Актаныш районына шундый экспедиция 2009 елда оештырылган иде инде. 2020 елда без, районга тагын бер экспедиция үткәрергә планлаштырылган иде. Кызганычка каршы, пандемия безнең планнарга үзенең төзәтүләрен кертте. Экспедиция оештырылмый калды. Шуңа да карамастан без район администрациясе ярдәме белән районның топонимик материалын анкета ысулын кулланып җыеп тупладык. Бу эшне башкаруда ярдәм иткән район администрациясенә, авылларда эшне башкарып чыккан хезмәткәрләргә һәм информантларга зур рәхмәтебезне белдерәбез. Җыелган

материал бик күләмле (1500 микротопоним). Анализлау эше шактый зур вакыт сорый. Әлеге мәкаләдә без беренчел анализ нәтиҗәләрен җиткерәбез. Соңыннан алар аерым эшләнеп чыгарылачак. Әлеге микротопонимнарның сүзлеге сезнең кулдагы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты әзерләгән Милли-мәдәни мирасыбыз сериясенең Актаныш районына багышланган китабында урын алды. Шулай ук тупланган атамалар Татарстан Республикасы топонимнарының электрон каталогына да кертеләчәк.

Татарстан Республикасының топонимнар системасы күп гасырлар дәвамында катлаулы географик, тарихи һәм лингвистик шартларда, көнчыгыш, көнбатыш, көньяк һәм төньякның төрле тугандаш һәм тугандаш булмаган халыкларының даими рәвештә кушылу, катнашу һәм бергә яшәү урыны булган территориядә формалашкан. Һәр миграцион дулкын үзеннән соң топонимик катламнар калдырган. Шуңа күрә һәр регионның топонимик системасын географик, тарихи һәм лингвистик яктан комплекслы итеп өйрәнү зарур.

Актаныш районы, – топонимика күзлегеннән караганда, шулай ук гаять кызык төбәк. Биредә төрле вакытларда төрле кабилә, халык вәкилләре булып узган, табигый ландшафты да бик үзенчәлекле, бай табигатьле регион.

Район Татарстан Республикасының көнчыгыш өлешендә, Түбән Кама аръягының төньяк-көнчыгышында урнашкан. Көнбатышта – Минзәлә, төньякта һәм көнчыгышта Кама, Агыйдел һәм Сөн елгалары ага. Аларның икенче ярларында ут күршеләребез Удмуртия һәм Башкортстан җирләре башлана. Көньякта Мөслим районы белән чиктәш.

Район үзәге булган Актаныш бистәсе Агыйдел елгасының түбән агымында урнашкан. Рәсми чыганакларда 1710 елдан билгеле.

Район 1930 елның 10 августында оештырыла. 1935 елда район икегә бүленеп ала – Калинин һәм Актаныш районнары. 1959 елда аларны яңадан берләштерәләр. 1963 елның 1 февраленнән Минзәлә составына кертелә, 1965 елның 12 гыйнварыннан яңадан Актаныш районы итеп оештырыла.

Тагын да тирәнрәк тарихка күз салсак, район территориясе генә түгел Татарстанның бөтен көнчыгышы һәм Башкортстанның төньяк-көнбатышы Идел Болгары вакытында әлеге дәүләтнең җирләре булган. XI–XII гасырларда инде Агыйдел һәм Ык елгалары арасында (Дербышки һәм Татар Әҗбие, Татар Ямалы авыллары) Идел буе болгарларының яшәве билгеле. Биредә болгар кабиләләре (юрмат, йәнәй, биләр, бүләр, гәйнә һ.б.) көн күргән. Соңыннан әлеге җирләр Алтын Урда һәм Казан ханлыгы составына керәләр[1]. 1552 елда Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, бирегә татарлар тагын да күбрәк күчеп киләләр. 1552–1580 елларда әлеге территория инде Казан өязе составына керә. Төрле елларда җирләр Уфа губернасына да, Оренбург губернасына да кереп ала. 1920 елдан – Актаныш территориясе Татарстан АССР составында.

Актаныш районында яшәүче татарларның сөйләме татар теленең минзәлә сөйләшенә керә.

Бүгенге көндә Актаныш районында 87 авыл бар. Аларның икесе, Мари Суыксуы белән Терпеле, мари авыллары. Михайловка – катнаш рус-татар авылы.

Инде югарыда әйтеп кителгәнчә, әлеге 87 авылдан анкета юлы белән 1500 микротопоним җыеп алынды.

«Микротопонимия» термины белән без зур булмаган географик объектларның (кечкенә елгалар, инешләр, күлләр, сазлыклар, чишмәләр, болыннар, урманнар һ.б.) атамаларының җыелмасын атыйбыз. Күп очракта әлеге атамалар зур булмаган территориядә яшәүче кешеләргә генә мәгълүм була. Рәсми рәвештә күбесе теркәлми. Мәсәлән, **Ак балчык чишмәсе** (Теләкәй авылы), **Алакаен** (Адай авылындагы агачлык), **Әпәкәй басуы** (Апач авылы). Әлеге территориядә яшәүчеләр күчеп китсә, алар онытыла, юкка чыга. Шул ук вакытта әлеге атамалар шул җирләрнең, анда яшәүчеләрнең тарихы, дөньяга карашлары, мәдәнияте турында гаять зур мәгълүмат бирә. Алар җирле халык өчен теге яки бу урынны конкрет билгеләү,

[1] *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – С. 16.

адрес функциясен башкаралар. Микротопонимнарга вариативлык хас. Бер үк урынны берничә төрле атама белән дә атарга мөмкиннәр яки бер үк атама берничә географик объектны да белдерү ихтималы бар. Мәсәлән, Олыимән авылындагы **Атнаш** атамасы зур чокырны да, анда урнашкан чишмәне дә аңлата.

Бер үк төрле атама төрле торак пунктларда очрарга мөмкин. Мәсәлән, Актаныш районында **Аккош күле** атамасы 5 авылда очрый. Татарстан буенча карасаң, бу атама тагын да күбрәк.

Микротопонимнар күмәклек исемнәргә тартым булалар, нигездә күмәклек исемнәрдән ясалалар: **Ак чишмә, Алаша тавы, Аргы саз, Аръяк** һ.б.

Географик объектның төренә карап, Актаныш микротопонимнарын түбәндәге төрләргә бүләбез. **Торак пунктларның өлешләре** (рәсми булмаган урам, тыкрык һ.б. атамалары): **Авыл башы** (Чөгәнә а.), **Алдакчылар урамы** (Ю. Яхшый а.), **Зират урамы** (Олыимән а.), **Алма бакчасы урамы** (Татар Ямалы а.); **оронимнар** (рельеф төренә карап чокыр, тау һ.б.): **Алкаби тавы** (Иске Байсар а.), **Әсәкәй чокыры** (Теләкәй а.), **Әткәрәй яры** (Иске Кормаш а.), **Әтмәнкүл чокыры** (Шәрип а.); **дримонимнар** (урман, әрәмә, бакча атамалары): **Башанак урманы** (Чиялек а.), **Биек тау әрәмәсе** (Татар Суыксу а.), **Биткен урманы** (Әнәк а.), **Алма бакчасы** (Апач а.); **гидронимнар** (су чыганаклары атамалары) үзләре берничә төргә бүленә. Елга атамалары: **Бия суйган елгасы** (Иске Байсар а.), **Бождады елгасы** (Кәзкәй а.); күл атамалары: **Бомбей күле** (Әнәк а.), **Витамин күле** (Тыңламас а.); сазлык атамалары: **Гыймакай сазы** (Чалманарат а.), **Зиярат сазы** (Иске Айман а.); чишмә атамалары: **Галләм чишмәсе** (Зөбәер а.), **Гариф чишмәсе** (Чалманарат а.); буа атамалары: **Габдулла буасы** (Иске Сәфәр а.), **Гали буасы** (Адай а.); кое атамалары: **Гайсә коесы** (Чалманарат а.), **Дәвем коесы** (Шәрип а.). **Агронимнар** (басу, кыр, болын, алан, ялан атамалары): **Зыя кыр станы** (Югары Яхшый а.), **Алтынчы** (Олыимән а.), **Ишмән болыны** (Күҗәкә а.), **Камышлык** (печәнлек атамасы Күҗәкә а.). Кеше тарафыннан төзелгән объект (күпер, мәчет һ.б.) белән бәйле атамалар: **Кушкүпер**

(Күҗәкә а.), **Кызлар басмасы** (Иске Балтач а.), **Кымыз цехы** (Меңнәр а.), **Кыргыз күпере** (Адай а.).

Актаныш районы микротопонимнары арасында иң зур күпчелекне су чыганаклары атамалары алып тора. Икенче урында – басу, болын, кыр атамалары, өченче урында – рельеф белән бәйле атамалар.

Лексик-семантик яктан караганда, Актаныш районы микротопонимнары күпчелек очракта теге яки бу географик объектның физик үзенчәлеген (размерын, урнашкан урынын, формасын, төсен, эчке үзенчәлекләрен) күрсәткән сүзләр ярдәмендә ясалганнар: **Ак инеш** (Актаныш б.), **Аркылы күл** (Табанлыкүл а.), **Аръяк** (Иске Айман а.), **Бәләкәй урман** (Пучы а.), **Биек тау** (Яңа Кормаш а.), **Җәенке күл** (Аеш а.), **Җимерек тау** (Иске Байсар а.), **Озын атау** (Күҗәкә а.), **Озын күл** (Кәзкәй а.), **Олы әрәмә** (Иске Байсар а., Иске Кормаш һ.б.), **Олы кое** (Иске Балтач а.) һ.б.

Икенче урында кеше исемнәре белән бәйле атамалар тора. Кеше исемнәре географик объектларга хуҗалык эшчәнлеге белән бәйле рәвештә кушылганнар. Теге яки бу болында, печәнлектә теге яки бу кеше печән чапкан, яки аның анда җир кишәрлеге булган. Коелар һәм чишмәләр шулай ук аларны карап, тәрбияләп торган кешеләрнең исемнәре белән йөртелә. Кайчакта әлеге тип атамаларга исемнәр авыл исеменнән бирелә, ә авыл атамасы үзе антропонимга нисбәтле ясалган була. Әлеге атамаларны фәндә антропотопонимнар дип атап йөртәләр: **Апач әрәмәсе** (Апач Тютеев – мулла) (Яңа Кормаш а.), **Афзал коесы** (Такталачык а.), **Әбүш коесы** (Зөбәер а.), **Әлмәкәй чишмәсе** (Шәрип а.), **Әндәрәй күле** (Чиялек а.), **Әпәт чокыры** (Иске Богады а.), **Әптерәйләр урамы** (Түбән Яхшый а.), **Әслах юлы** (Түмерҗә а.), **Әхәт чокыры** (Олыимән а.), **Әхмәй яры** (Түмерҗә а.) һ.б.

Теге яки бу халык яки кабиләнең атамасына нигезләнеп ясалган атамалар (этнотопонимнар) үзләре аерым бер урынны алып торалар. Алар аркылы без бу җирләрдә кемнәр яшәгәнлеген белә алабыз: **Асаба әрәмәсе** (Олыимән а.), **Бүләр түбә** (Чалманарат а.), **Җәнәй түбә** (Чалманарат а.), **Кыргыз күпере**

(Адай а.), **Мукшы биләме** (Чишмәбаш а.), **Рус буасы** (Иске Әлем а.), **Типтәр урамы** (Яңа Әлем а.), **Чирмеш чокыры** (Татар Суыксуы а.).

Тагын бер категория атамаларда үсемлек һәм хайван, кошкорт, су җанварлары атамалары чагылыш таба. Алар теге яки бу урында теге яки бу үсемлекнең үсүе, хайваннарның ул урында күп очравына бәйле рәвештә кушылалар: **Ак балык күле** (Күҗәкә а.), **Аю куагы** (Татар Суыксуы а.), **Бака елгасы** (Иске Җияш а.), **Баланлы куак** (Иске Әлем а.), **Бәрәңге урамы** (Күҗәкә а.), **Җиләк ерымы** (Кыр-Каентүбә а.), **Зирекле күл** (Иске Байсар а.), **Имәнле күл** (Усы а.) һ.б.

Теге яки бу вакыйга белән бәйле булган атамалар, гадәттә, артык күп булмыйлар: **Комгансызлар урамы** (Яңа Балтач а.), **Кымыз цехы** (Меңнәр а.), **Кылыч күле** (Тыңламас а.), **Пугач явы үткән басу** (Адай а.), **Туктар күле** (Татар Ямалы а.), **Бия суйган әрәмәсе** (Табанлыкүл а.) һ.б.

Йомгак ясап әйткәндә, микротопонимнарда халыкның дөньяга карашы, дөньяны аңлау, яшәү рәвеше, кайсы вакытта, кайсы яктан килүләре, тарихы һ.б. чагылыш таба.

Безнең анализ күрсәткәнчә, тупланган микротопонимнарның 90%тан артыгының мәгънәсе хәзерге татар теле белән аңлатыла. Мәгънәсе, этимологиясе аңлашылмаган сүзләр бик аз. **Аклай** (Күҗәкә а.), **Әргәнеш болыны** (Әҗәкүл а.), **Доха күле** (Әҗәкүл а.) һ.б. шундыйлардан. Ләкин боларның да этимологиясен татар теле һәм аның сөйләшләре аша табарга мөмкин.

Шул рәвешле җыелган микротопонимнарның 90% тан артыгы татар теле һәм, аерым алганда, аның минзәлә сөйләше нигезендә ясалган. Әлегә күрсәткеч бу җирләрдә борын-борынгыдан татарлар һәм аларның бабалары яшәгәнлекне тагын бер кат исбатлап торучы дәлил булып тора.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**

*Арсланов Л.Ш.* Следы пребывания марийцев в Актанышском районе Республики Татарстан // Филолого-краеведческий сборник: материалы III научно-краеведческой конференции. – Наб. Челны, 1996. – 80 с.

*Арсланов Л.Ш.* Топонимические параллели на территории Актанышского района Республики Татарстан и северо-западных районов Башкор-

тостана // Филолого-краеведческий сборник: материалы III научнокраеведческой конференции. – Наб. Челны, 1996. – 80 с.

*Арсланов Л.Ш.* Топонимы с формантом -ныш, -неш (наш) на территории Актанышского района Республики Татарстан // Ономастика Поволжья: тезисы докладов IX Междунар. конференции. – Волгоград: Перемена, 2002. – 228 с.

*Арсланов Л.Ш.* О происхождении некоторых названий озер на территории Актанышского района Республики Татарстан // Очерки по диалектологии и ономастике (избранные труды). – Елабуга, 2009. – 141 с.

*Әхмәтҗанов М.И.* Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 343 б.

*Гарипова Ф.Г.* Гидронимия Заказанья Татарской АССР (бассейн реки Ашит, Казанки, Меши, Шошмы): автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1975.

*Гарипова Ф.Г.* Татарстан гидронимнары сүзлеге. – Казан, 1984. – 141 б.

*Гарипова Ф.Г.* Исследования по гидронимии Татарстана. – М.: Наука, 1991. – 294 с.

*Саттаров Г.Ф.* Татарстан АССРның антропонимнары: Татарстан авылларының исемнәре. – Казан: Казан ун-ты, 1973. – 297 б.

*Саттаров Г.Ф.* Татар исемнәре сүзлеге. – Казан, 1981. – 256 б.

*Тимирова Л.Ф.* Ономастикон Актанышского ареала: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2012. – 199 с.

## МӘГЪЛҮМАТ БИРҮЧЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

Акмалова Ләйсән Рәфкать кызы, Күҗәкә авылы, Күҗәкә авылында туган, 1966 елгы, китапханәче.

Арсланова Зөлфирә Юныс кызы, Әҗмәт авылы, Әҗмәт авылында туган, 1980 елгы, мәдәният хезмәткәре.

Аухадеева Гөлнур Шәйхенур кызы, Олыимән авылы, Тәкмәк авылында туган, 1963 елгы, клуб мөдире.

Габидинова Гөлүсә Кәлимулла кызы, Зөбәер авылы, Тукай районы Мусабай авылында туган, 1971 елгы, мәдәният йорты директоры.

Гайнетдинов Фанзур Вәзүт улы, Түке авылы, Илтимер авылында туган, 1967 елгы, мәдәният йорты мөдире.

Гайсина Диләрия Шаехян кызы, Әҗмәт авылы, Әҗмәт авылында туган, 1964 елгы, китапханәче.

Гаязова Лилия Булат кызы, Чалманарат авылы (башка мәгълүмат юк).

Зиннурова Энҗе Камил кызы, Әтәс авылы, Әтәс авылында туган, 1983 елгы, мәдәният йорты директоры.

Магданова Мәйсәрә Рахимҗан кызы, Тыңламас авылы, Башкортстан Республикасы Илеш районы Уяндык авылында туган, 1966 елгы, мәдәният йорты мөдире.

Марданов Әфка Муллаян улы, Түмерҗә авылы, Түбән Гәрәй авылында туган, 1956 елгы, мәдәният хезмәткәре.

Муллаянова Элмира Рафкать кызы, Адай авылы, Күҗәкә авылында туган, 1969 елгы, китапханәче.

Мусина Лилия Фәрит кызы, Югары Яхшый авылы, Актаныш авылында туган, 1983 елгы, мәдәният йорты директоры.

Нәбиева Ләйсән Өлфәт кызы, Иске Балтач авылы, Адай авылында туган, 1964 елгы, клуб мөдире.

Нәгыймова Гөлсәрия Әхсән кызы, Иске Кормаш авылы, Чишмә авылында туган, 1971 елгы, китапханәче.

Нигъмәтуллина Фәйрузә Вәсим кызы, Әнәк авылы, Әнәк авылында туган, 1972 елгы, мәдәният йорты мөдире.

Нургалиева Гүзәлия Гакиф кызы, Татар Ямалы авылы, Татар Ямалы авылында туган, 1965 елгы, профессиясе?

Нуриева Рәзимә Әбүдәр кызы, Бүләк авылы, Татар Суыксуы авылында туган, 1967 елгы, укытучы.

Нурлыгаянова Гөлнара Флүс кызы, Чишмә авылы, Чишмә авылында туган, 1971 елгы, мәдәният йорты директоры.

Сәетова Кадрия Шаһидулла кызы, Иске Айман авылы, Иске Айман авылында туган, 1966 елгы, мәдәният йорты директоры.

Хафизова Әсфирә Миргалим кызы, Иске Богады авылы, Иске Богады авылында туган, 1973 елгы, мәдәният йорты директоры.

Хәбирова Ләйсән Дилфат кызы, Яңа Әлем авылы, Башкортстан Республикасы Нефтекамск шәһәрендә туган, 1987 елгы, мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе.

Хәертдинов Рәскать Әнвәретдин улы, Уръяды авылы, Үмәнәй авылында туган, 1954 елгы, икътисадчы.

Хөснетдинова Әнисә Назыйф кызы, Яңа Балтач авылы, Иске Балтач авылында туган, 1976 елгы, клуб мөдире.

Хуҗина Алсу Фасил кызы, Киров исемендәге совхоз, Киров авылында туган, 1981елгы, мәдәният йорты директоры.

Һарунов Илдус Һади улы, Иске Сәфәр авылы, Иске Сәфәр авылында туган, 1971 елгы, мәдәният йорты директоры.

Шәвәлиева Рания Рәсил кызы, Кыр-Каентүбә авылы, Иске Кормаш авылында туган, 1971 елгы, клуб мөдире.

Шәрипова Инсия Гафурҗан кызы, Чөгәнә авылы, Чөгәнә авылында туган, 1947 елгы, тегүче.

## АКТАНЫШ РАЙОНЫ ТОПОНИМНАРЫ СҮЗЛЕГЕ

**Абдуллин урманы** – Иске Сәфәр авылы, урман атамасы.
**Авангард урамы –** Олыимән авылы, урам атамасы.
**Авыл башы** – Чөгәнә авылы, урам атамасы.
**Агачлык –** Зөбәер авылы, агачлык атамасы.
**Агачныкылар күле –** Ахун авылы, күл атамасы.
**Агыйдел** – Актаныш, Тат. Ямалы авыллары, елга атамасы.
**Агышлы күл –** Аеш авылы, күл атамасы.
**Адай чишмәсе –** Адай авылы, чишмә атамасы.
**Адәм сөяге басуы** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, басу атамасы.
**Ает буе** – Яңа Әлем авылы, болынлык атамасы.
**Айман борынчыгы –** Иске Айман авылы, урын атамасы.
**Ак балык күле** – Күҗәкә авылы, күл атамасы.
**Акбалык күле –** Адай, Буаз-күл, Иске Богады, Куян, Татар Ямалы, Уразай авыллары, күл атамасы.
**Ак балчык чишмәсе –** Теләкәй авылы, чишмә атамасы.
**Ак егет яры –** Олыимән авылы, яр атамасы.
**Ак инеш** – Актаныш авылы, инеш атамасы.
**Аклай –** Аеш авылы, болын атамасы.
**Аклан** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Акма елгасы** – Актаныш авылы, елга атамасы.
**Акманай күле –** Адай авылы, күл атамасы.
**Акманай сырты** – Күҗәкә авылы, тау атамасы.
**Ак мәчет** – Иске Байсар авылы, мәчет атамасы.
**Ак такта –** Тат. Суыксуы авылы, күпер атамасы.
**Актаныш елгасы** – Актаныш авылы, елга атамасы.
**Актаныш капкасы** – Шәрип авылы, урын атамасы.
**Акташ чишмәсе** – Шәрип авылы, чишмә атамасы.
**Ак тәкә күле –** Ирмәш авылы, күл атамасы.
**Акхуҗа суы** – Чишмәбаш авылы, елга атамасы.
**Акчарлак сазлыгы** – Аккүз авылы, сазлык атамасы.
**Ак чишмә –** Мәсәде, Шәрип авыллары, чишмә атамасы.
**Алакаен –** Адай, Күҗәкә авыллары, агачлык атамасы.
**Албасты чокыры** – Кыр-Каентүбә авылы, чокыр атамасы.
**Алдакчылар урамы** – Түбән Яхшый авылы, урам атамасы.
**Алдырыш чокырлары –** Тат. Суыксуы авылы, чокыр атамасы.
**Алкаби тавы** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, тау атамасы.
**Алма-Ата буасы** – Киров авылы, буа атамасы.
**Алма бакчасы урамы –** Татар Ямалы авылы, урам атамасы.
**Алтынчы –** Олыимән авылы, кыр станы атамасы.
**Алтынъяр –** Такталачык авылы, яр атамасы.
**Амбар урамы** – Уразай авылы, урам атамасы.
**Апайыш күле –** Такталачык авылы, күл атамасы.
**Ар үлгән күл –** Аеш авылы, күл атамасы.
**Аргы саз –** Ахун авылы, саз атамасы.
**Аргы тугай** – Тыңламас авылы, тугай атамасы.
**Арка күл** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, күл атамасы.
**Аркылы күл –** Табанлыкүл авылы, күл атамасы.
**Аркылы саз** – Кәзкәй авылы, сазлык атамасы.
**Арт тыкрык** – Чишмә авылы, тыкрык атамасы.
**Арт урам** – Иске Богады, Тыңламас авыллары, урам атамасы.
**Аръяк –** Иске Айман, Иске Богады, Яңа Әлем авыллары, урам атамасы.
**Аръяк болыны** – Чөгәнә авылы, болын атамасы.
**Аръяк (Горький)** – Күҗәкә авылы, урам атамасы.
**Аръяк урамы** – Тыңламас авылы, урам атамасы.
**Аръяк чишмәләре –** Такталачык авылы, чишмә атамасы.
**Асаба әрәмәсе –** Олыимән авылы, әрәмәлек атамасы.
**Асаба ягы** – Аккүз авылы, урам атамасы.
**Аскы Актаныш** – Актаныш авылы, бистә атамасы.

**Асылтамак** – Иске Байсар авылы, сулык атамасы.
**Асылтамак елгасы** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, елга атамасы.
**Ат чишмәсе** – Иске Кормаш авылы, чишмә атамасы.
**Атау күле** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Атау** – Качкын авылы, чокыр атамасы.
**Атнагол кисәге** – Югары Богады авылы, урын атамасы.
**Атнагол төбәге** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Атнаш сызасы –** Адай авылы, сазлык атамасы.
**Атнаш чишмәсе –** Олыимән авылы, чишмә атамасы.
**Афанасовка зираты –** Терпеле авылы, зират атамасы.
**Афанасовка урманы** – Иске Сәфәр, Терпеле авыллары, урман атамасы.
**Афзал коесы –** Такталачык авылы, кое атамасы.
**Ахун өянкелеге** – Түмерҗә авылы, урын атамасы.
**Ачы –** Качкын авылы, ялан атамасы.
**Ачы арасы сазы** – Иске Байсар авылы, сазлык атамасы.
**Ачы басуы** – Күҗәкә авылы, басу атамасы.
**Ачы башы –** Зөбәер авылы, урын атамасы.
**Ачы болынлыгы** – Кәзкәй авылы, болын атамасы.
**Ачылы –** Аеш авылы, әрәмә атамасы.
**Ачылы саз** – Иске Байсар авылы, сазлык атамасы.
**Аю елгасы** – Түмерҗә авылы, елга атамасы.
**Аю куагы –** Тат. Суыксуы авылы, куаклык атамасы.
**Аю куак** – Чөгәнә авылы, куаклык атамасы.
**Аю үтергән әрәмә** – Уразай авылы, әрәмә атамасы.
**Аю яланы –** Әнәк авылы, ялан атамасы.
**Әби патша юлы** – Иске Сәфәр, Такталачык авыллары, юл атамасы.
**Әби чокыры** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, чокыр атамасы.
**Әбүгали сазлыгы –** Такталачык авылы, сазлык атамасы.
**Әбүш коесы –** Зөбәер авылы, кое атамасы.
**Әҗби урамы** – Иске Кормаш авылы, урам атамасы.
**Әҗе күле (Әҗәкүл) –** Әҗәкүл авылы, күл атамасы.
**Әҗекәш** – Иске Байсар авылы, сулык атамасы.
**Әҗмәт болыны –** Әҗмәт авылы, болын атамасы.
**Әҗмәт каберлеге –** Әҗмәт авылы, зиарат атамасы.
**Әҗмәт тегермәне –** Әҗмәт авылы, тегермән булган урын атамасы.
**Әлмәкәй чишмәсе (Майкамал чишмәсе)** – Шәрип авылы, чишмә атамасы.
**Әлмәт тау башы басуы –** Табанлыкүл авылы, басу атамасы.
**Әмә чишмәсе** – Уразай авылы, чишмә атамасы.
**Әмир тыкрыгы –** Апач авылы, тыкрык атамасы.
**Әнәк борынчыгы –** Иске Айман авылы, урын атамасы.
**Әнәк күпере –** Әнәк авылы, күпер атамасы.
**Әнәк урманы –** Әнәк, Пучы авыллары, урман атамасы.
**Әнәк чишмәсе –** Пучы авылы, чишмә атамасы.
**Әндәрәй күле** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, күл атамасы.
**Әндрәй чишмәсе** – Иске Байсар, Чишмәбаш авыллары, чишмә атамасы.
**Әндрәй бай кибетләре** – Иске Байсар авылы, урын атамасы.
**Әпәкәй басуы –** Апач, Әтәс авыллары, басу атамасы.
**Әпәт чокыры** – Иске Богады авылы, чокыр атамасы.
**Әптекәй –** Такталачык авылы, урын атамасы.
**Әптекәй печәнлеге –** Табанлыкүл авылы, болын атамасы.
**Әптекәй яланы** – Түбән Яхшый авылы, ялан атамасы.
**Әптекәй имәнлеге** – Иске Әгъбас авылы, урман атамасы.
**Әптерәйләр урамы** – Түбән Яхшый авылы, урам атамасы.
**Әрәкәй бабай култыгы –** Мерәс авылы, урын атамасы.
**Әргәнеш –** Әҗәкүл авылы, болын атамасы.
**Әргәнеш болыны** – Актаныш, Чөгәнә авыллары, болын атамасы.
**Әреш чишмәсе** – Качкын авылы, чишмә атамасы.
**Әрҗәвез басуы** – Күҗәкә авылы, басу атамасы.
**Әреш чишмәсе (Шифалы чишмә)** – Качкын авылы, чишмә атамасы.
**Әсәкәй чокыры –** Теләкәй авылы, чокыр атамасы.

**Әслах юлы** – Түмерҗә авылы, юл атамасы.
**Әсүән буасы** – Иске Сәфәр авылы, буа атамасы.
**Әтәс урамы (Гагарин)** – Күҗәкә авылы, урам атамасы.
**Әтәскан (Эт аскан)** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Әткәрәй яры** – Иске Кормаш авылы, яр атамасы.
**Әтмәнкүл чокыры** – Шәрип авылы, чокыр атамасы.
**Әүлия** – Иске Байсар авылы, сазлык атамасы.
**Әүлия кабере –** Әҗмәт, Тәкмәк авыллары, урын атамасы.
**Әүлия тавы –** Теләкәй авылы, тау атамасы.
**Әүлия чишмәсе** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, чишмә атамасы.
**Әхәт чокыры –** Олыимән авылы, чокыр атамасы.
**Әхәт чишмәсе –** Олыимән авылы, чишмә атамасы.
**Әхмәдулла чишмәсе** – Түбән Яхшый авылы, чишмә атамасы.
**Әхмәй яры** – Түмерҗә авылы, яр атамасы.
**Әхмәт күпере** – Иске Богады авылы, күпер атамасы.
**Әхмәт тавы** – Иске Богады авылы, тау атамасы.
**Әхмәт чишмәсе** – Иске Богады, Пучы авыллары, чишмә атамасы.
**Әхмәтша елгасы** – Чалманарат авылы, елга атамасы.
**Әхмәтша тавы** – Яңа Кормаш авылы, тау атамасы.
**Әхнәф чокыры –** Олыимән, Тыңламас авыллары, чокыр атамасы.
**Әюп почмагы** – Киров авылы, урын атамасы.
**Ә. Сәфәргалин урамы** – Иске Кормаш авылы, урам атамасы.
**Бабай урманы –** Иске Айман авылы, урман атамасы.
**Баҗана –** Иске Айман авылы, елга атамасы.
**Баҗана елгасы –** Адай, Әнәк, Зөбәер, Иске Уръяды, Түке, Качкын авыллары, елга атамасы.
**Баҗгыяд** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Базар тавы** – Түмерҗә авылы, тау атамасы.
**Байбак үре –** Пучы авылы, калкулык атамасы.
**Байбулат сырты** – Чат авылы, урын атамасы.
**Байлар урамы** – Яңа Балтач авылы, урам атамасы.
**Байсар күле** – Иске Байсар авылы, күл атамасы.
**Бака елгасы** – Иске Җияш авылы, елга атамасы.
**Бака күле –** Аеш, Актаныш, Әнәк авыллары, күл атамасы.
**Бакалы күл** – Яңа Балтач авылы, күл атамасы.
**Бакыр базы** – Иске Җияш авылы, чокыр атамасы.
**Бакыр коесы** – Иске Җияш авылы, кое атамасы.
**Бакыр тавы** – Аккүз, Түбән Гәрәй авыллары, тау атамасы.
**Бала кәрәкә атавы** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Бала кәрәкә күле** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Баланлы куак –** Иске Әлем авылы, куаклык атамасы.
**Баланлы куак тавы** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, тау атамасы.
**Баллы балак** – Иске Бикчәнтәй авылы, чокыр атамасы.
**Балтач тавы** – Иске Кормаш авылы, тау атамасы.
**Балтач урманы** – Иске Кормаш авылы, урман атамасы.
**Балчыклы тау** – Усы авылы, тау атамасы.
**Балык күле** – Аккүз, Иске Байсар авыллары, күл атамасы.
**Балыклы күл** – Иске Сәфәр, Меңнәр авыллары, күл атамасы.
**Баскүл –** Татар Ямалы авылы, күл атамасы.
**Батрай кулы** – Иске Байсар авылы, урын атамасы.
**Батрай чишмәсе** – Иске Байсар авылы, чишмә атамасы.
**Батыр чишмәсе –** Табанлыкүл авылы, чишмә атамасы.
**Батырай чишмәсе** – Чишмәбаш авылы, чишмә атамасы.
**Батырша дүмгәге –** Адай авылы, болын атамасы.
**Баһау тыкрыгы –** Әтәс авылы, тыкрык атамасы.
**Бачка** – Чөгәнә авылы, урын атамасы.
**Башанак урманы** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, урман атамасы.
**Башкорт очы** – Кәзкәй авылы, урам атамасы.
**Башкорт зираты** – Качкын авылы, зират атамасы.

**Башкорт чишмәсе** – Түке авылы, чишмә атамасы.
**Башлау –** Табанлыкүл авылы, урын атамасы.
**Бәдеш коесы –** Карт авылы, кое атамасы.
**Бәкилде күле** – Уразай авылы, күл атамасы.
**Бәкилде урамы** – Уразай авылы, урам атамасы.
**Бәләкәй борын** – Иске Җияш авылы, юл атамасы.
**Бәләкәй җәнтек яланы** – Иске Байсар авылы, ялан атамасы.
**Бәләкәй күпер –** Апач, Әтәс авыллары, күпер атамасы.
**Бәләкәй урам –** Татар Ямалы авылы, урам атамасы.
**Бәләкәй урман –** Әнәк, Пучы авыллары, урман атамасы.
**Бәләкәй Чарлак –** Аеш авылы, печәнлек атамасы.
**Бәләкәй чишмә** – Усы авылы, чишмә атамасы.
**Бәрәңге урамы (Куйбышев)** – Күҗәкә авылы, урам атамасы.
**Бәхтияр чокыры** – Уразай авылы, чокыр атамасы.
**Бәшәр бакчасы –** Адай, Күҗәкә авыллары, урын атамасы.
**Бәшәр тавы** – Күҗәкә авылы, тау атамасы.
**Бердәмлек мәчете** – Түке авылы, мәчет атамасы.
**Беренче таллык –** Такталачык авылы, таллык атамасы.
**Биҗады елгасы** – Яңа Әлем авылы, елга атамасы.
**Биҗады елгасы** – Иске Богады авылы, елга атамасы.
**Биек тау** – Яңа Кормаш авылы, тау атамасы.
**Биек җилән –** Тат. Суыксуы авылы, әрәмә атамасы.
**Бикә аланы** – Иске Кормаш авылы, алан атамасы.
**Бикә күле** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Бикә тавы** – Кыр-Каентүбә авылы, тау атамасы.
**Бикбай –** Мерәс авылы, урын атамасы.
**Бикбай сазы –** Татар Ямалы авылы, сазлык атамасы.
**Бикҗилән сырты** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Биккенә сукмагы –** Пучы авылы, сукмак атамасы.
**Биккенә урманы –** Пучы авылы, урман атамасы.
**Бикмәт басуы –** Апач, Әтәс авыллары, басу атамасы.
**Бикмәт буасы –** Апач, Әтәс авыллары, буа атамасы.
**Бикмәт чокыры –** Апач авылы, чокыр атамасы.
**Биктекәй** – Иске Җияш авылы, тау атамасы.
**Биктимер чишмәсе** – Шәрип авылы, чишмә атамасы.
**Бирге саз –** Ахун авылы, саз атамасы.
**Бирге тугай** – Тыңламас авылы, тугай атамасы.
**Биткен сукмагы –** Әнәк авылы, сукмак атамасы.
**Биткол каберлеге –** Пучы авылы, каберлек атамасы.
**Биткол чокыры –** Әнәк авылы, чокыр атамасы.
**Бишенче басу –** Адай, Әҗмәт, Такталачык авыллары, басу атамасы.
**Бишкүмәч әрәмәсе –** Олыимән авылы, әрәмәлек атамасы.
**Биясиган әрәмәсе** – Түбән Яхшый авылы, әрәмә атамасы.
**Бия суйган әрәмәсе –** Табанлыкүл авылы, әрәмә атамасы.
**Бия суйган елгасы** – Иске Байсар авылы, елга атамасы.
**Биясуйган чокыры** – Чуракай авылы, чокыр атамасы.
**Богады капкасы** – Шәрип авылы, урын атамасы.
**Бożады елгасы** – Кәзкәй авылы, елга атамасы.
**Бозау киртәсе –** Татар Ямалы авылы, ялан атамасы.
**Бозаулык –** Илчебай авылы, урын атамасы.
**Бойткол чокыры –** Пучы авылы, чокыр атамасы.
**Бойткол – Биткен урманы –** Әнәк авылы, урман атамасы.
**Боланай елгасы** – Аккүз авылы, елга атамасы.
**Болын –** Әнәк авылы, болын атамасы.
**Больница урамы**, хәзер **Медицина урамы (Ач очы) –** Такталачык авылы, урам атамасы.
**Больница юлы –** Әҗмәт авылы, юл атамасы.
**Бомбей күле –** Әнәк авылы, күл атамасы.
**Борнаш урманы –** Иске Әлем авылы, урман атамасы.
**Борнаш чокыры** – Яңа Әлем авылы, чокыр атамасы.

**Борын коесы** – Шәрип авылы, кое атамасы.
**Борын тау** – Чишмә авылы, тау атамасы.
**Борынчык тавы** – Иске Байсар авылы, тау атамасы.
**Бояр чишмәсе** – Чәчер авылы, чишмә атамасы.
**Бөгә** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Бөгә елгасы –** Адай авылы, елга атамасы.
**Бөят Бавы инеше** – Иске Сәфәр авылы, инеш атамасы.
**Бу оч** – Чөгәнә авылы, оч атамасы.
**Буклы балак чокыры** – Кыр-Каентүбә авылы, чокыр атамасы.
**Булат чишмәсе –** Табанлыкүл авылы, чишмә атамасы.
**Буранлы куыш** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, урын атамасы.
**Бурлар күпере** – Иске Богады авылы, күпер атамасы.
**Бурлы бүләк** – Аккүз авылы, ерым атамасы.
**Бурсык буасы** – Күҗәкә авылы, буа атамасы.
**Бурсык сырты –** Адай авылы, ялан атамасы.
**Бурсык чишмәсе** – Күҗәкә авылы, чишмә атамасы.
**Бүләк –** Адай авылы, әрәмә атамасы.
**Бүләк** – Күҗәкә авылы, куаклык атамасы.
**Бүләк –** Такталачык авылы, урын атамасы.
**Бүләк тау –** Илчебай авылы, тау атамасы.
**Бүләк урманы** – Актаныш, Әнәк, Пучы, Шәрип авыллары, болын атамасы.
**Бүләк чабыны –** Иске Әгъбәс авылы, печәнлек атамасы.
**Бүләр түбә** – Чалманарат авылы, урын атамасы.
**Бүлнис асты –** Такталачык авылы, урын атамасы.
**Бүлнис тавы –** Әҗмәт авылы, тау атамасы.
**Бүре тавы** – Түмерҗә авылы, тау атамасы.
**Бүре тыкрыгы** – Түмерҗә авылы, тыкрык атамасы.
**Бүрле бүләк суы** – Иске Байсар авылы, сулык атамасы.
**Варис коесы –** Әнәк авылы, кое атамасы.
**Вахит таллыгы** – Уразай авылы, урын атамасы.
**Ваһап коесы –** Иске Айман авылы, кое атамасы.
**Вәлкәй чишмәсе** – Чалманарат авылы, чишмә атамасы.
**Венера күле –** Тат. Суыксуы авылы, күл атамасы.
**Витамин күле** – Тыңламас авылы, күл атамасы.
**В. Маликов урамы (Тегермән урамы)** – Иске Кормаш авылы, урам атамасы.
**Войный урманы –** Бурсык авылы, урман атамасы.
**Ворошилов урамы –** Адай авылы, урам атамасы.
**Восход яланы –** Тат. Суыксуы авылы, ялан атамасы.
**Габделхәй Әхәтов урамы (Чүкеч урамы) –** Иске Айман авылы, урам атамасы.
**Габдулла буасы** – Иске Сәфәр авылы, буа атамасы.
**Гайни әрәмәсе** – Түмерҗә авылы, әрәмә атамасы.
**Гайсә коесы** – Чалманарат авылы, кое атамасы.
**Гайсә чокыры –** Теләкәй авылы, чокыр атамасы.
**Гайшә күпере** – Түмерҗә, Чалманарат авыллары, күпер атамасы.
**Гали болыны** – Уразай авылы, болын атамасы.
**Гали буасы –** Адай авылы, буа атамасы.
**Гали буасы** – Күҗәкә авылы, буа атамасы.
**Гали буасы –** Татар Ямалы авылы, буа атамасы.
**Гали тарлавы** – Чалманарат авылы, урын атамасы.
**Галим буасы** – Күҗәкә авылы, буа атамасы.
**Галим чокыры** – Иске Әгъбәс авылы, урам атамасы.
**Галләм чишмәсе –** Зөбәер авылы, чишмә атамасы.
**Гариф чишмәсе** – Чалманарат авылы, чишмә атамасы.
**Гарифә күле –** Адай, Күҗәкә авыллары, күл атамасы.
**Гарифуллин чишмәсе –** Ирмәш авылы, чишмә атамасы.
**Гаттар түбәтәе –** Иске Айман авылы, урын атамасы.
**Гашыйклар урамы (Гыйшык урамы)** – Иске Кормаш авылы, урам атамасы.
**Гәрәй болыны –** Татар Ямалы авылы, болын атамасы.
**Гәрәй тамак** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Гобәй күпере –** Табанлыкүл авылы, күпер атамасы.
**Гобәй күпере** – Түбән Яхшый авылы, күпер атамасы.
**Горький урамы –** Адай, Түбән Уръяды авыллары, урам атамасы.

**Госман тавы** – Иске Кадермәт авылы, тау атамасы.
**Госман ындыры** – Иске Сәфәр авылы, урын атамасы.
**Гөлчирә мәчете –** Иске Айман авылы, мәчет атамасы.
**Гөргөри чокыры –** Зөбәер, Түке авыллары, чокыр атамасы.
**Г. Сафиуллин урамы – Эт урамы** – Иске Сәфәр авылы, урам атамасы.
**Г. Тукай урамы** – Түбән Уръяды авылы, урам атамасы.
**Г. Тукай урамы – Абдуллин** – Иске Сәфәр авылы, урам атамасы.
**Гыйльмегали чишмәсе** – Чалманарат авылы, чишмә атамасы.
**Гыйльмегаян тыкрыгы** – Күҗәкә авылы, урам атамасы.
**Гыйльмесафа чишмәсе** – Яңа Балтач авылы, чишмә атамасы.
**Гыймакай сазы** – Чалманарат авылы, сазлык атамасы.
**Давай җиләне** – Тыңламас авылы, урын атамасы.
**Дәвем коесы** – Шәрип авылы, кое атамасы.
**Дәүләт чокыры** – Киров авылы, чокыр атамасы.
**Дегет базы –** Адай, Иске Кадермәт, Иске Айман авыллары, баз атамасы.
**Дегет күл чокыры –** Иске Әлем авылы, чокыр атамасы.
**Дегет / Нефтянниклар чокыры** – Иске Богады авылы, чокыр атамасы.
**Детдом коесы –** Такталачык авылы, кое атамасы.
**Дилфас чишмәсе** – Тыңламас авылы, чишмә атамасы.
**Динислам яры –** Илчебай авылы, яр атамасы.
**Динислам яры** – Уразай авылы, тау атамасы.
**Доха күле –** Әҗәкүл, Уразай авыллары, күл атамасы.
**Дөя куагы** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Дуга** – Иске Байсар авылы, күл атамасы.
**Дуга күле** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, күл атамасы.
**Дугай** – Чөгәнә авылы, урын атамасы.
**Дуңгыз күле –** Ирмәш авылы, күл атамасы.
**Дүмгәк авызы –** Адай авылы, урын атамасы.
**Дүмәк яланы** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, ялан атамасы.
**Дүмгәлек** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Еланлы күл –** Теләкәй авылы, күл атамасы.
**Елга** – Күҗәкә авылы, елга атамасы.
**Елга буе** – Тыңламас авылы, елга буе, урын атамасы.
**Елга чокыры** – Кыр-Каентүбә авылы, чокыр атамасы.
**Ерак Чишмә –** Иске Айман авылы, чишмә атамасы.
**Җамигъ мәчете –** Олыимән авылы, мәчет атамасы.
**Җанбай күле –** Илчебай, Уразай авыллары, күл атамасы.
**Җанбирде –** Аеш авылы, печәнлек атамасы.
**Җәенке күл –** Аеш авылы, күл атамасы.
**Җәйләү** – Качкын авылы, ялан атамасы.
**Җәймәт –** Әҗмәт авылы, урын атамасы.
**Җәлил мулла мәдрәсәсе –** Теләкәй авылы, урын атамасы.
**Җәмәй күле –** Зөбәер авылы, күл атамасы.
**Җәмәкәй –** Татар Ямалы авылы, елга атамасы.
**Җәмәкәй елгасы –** Буаз-күл, Татар Ямалы авыллары, елга атамасы.
**Җәнәй түбә** – Чалманарат авылы, урын атамасы.
**Җәнәй чишмәсе –** Ахун авылы, чишмә атамасы.
**Җәнтек аланы** – Иске Байсар авылы, алан атамасы.
**Җәрәкә чишмәсе** – Куян авылы, чишмә атамасы.
**Җәүбүре –** Теләкәй авылы, урын атамасы.
**Ждан зираты** – Чалманарат авылы, зират атамасы.
**Җиде наратлык** – Чалманарат авылы, урман атамасы.
**Җидегән чишмә** – Актаныш авылы, чишмә атамасы.
**Җиделе күл** – Уразай авылы, күл атамасы.
**Җиделе күле –** Илчебай авылы, күл атамасы.
**Җиз комган чокыры** – Иске Кормаш авылы, чокыр атамасы.
**Җизмыек зираты** – Чат авылы, зират атамасы.
**Җиләк ерымы** – Шәбезбаш авылы, чокыр атамасы.
**Җимерек асты чишмәсе** – Иске Байсар авылы, чишмә атамасы.
**Җимерек тау** – Иске Байсар авылы, тау атамасы.
**Җинан коесы –** Карт авылы, кое атамасы.
**Җиңү урамы –** Олыимән авылы, урам атамасы.

**Җир җимереге** – Чишмәбаш авылы, урын атамасы.
**Җирән бүләге –** Иске Әлем авылы, аланлык атамасы.
**Җирев урамы** – Куян авылы, урам атамасы.
**Җирек –** Татар Ямалы авылы, агачлык атамасы.
**Җирек буе** – Чишмә авылы, урын атамасы. Агачлык янындагы урын.
**Җирекле күл** – Чуракай авылы, күл атамасы.
**Җиреклек** – Күҗәкә авылы, агачлык атамасы.
**Җитен тарлавы** – Иске Җияш авылы, кыр атамасы.
**Җылан зираты** – Чуракай авылы, зират атамасы.
**Җылкыйа суы** – Иске Байсар авылы, елга атамасы.
**Җырлы чишмә** – Иске Кормаш авылы, чишмә атамасы.
**Завод күле** – Иске Байсар авылы, күл атамасы.
**Зариф тавы –** Тат. Суыксуы авылы, тау атамасы.
**Затон** – Чөгәнә авылы, урын атамасы.
**Зәет Мәҗитов урамы –** Иске Айман авылы, урам атамасы.
**Зәйди сазы** – Аккүз авылы, күл атамасы.
**Зәйтүнә урман полосасы –** Бүләк авылы, урман атамасы.
**Зәңгәр күл –** Тат. Суыксуы авылы, күл атамасы.
**Земской коесы –** Иске Әлем авылы, кое атамасы.
**Зиарат чишмәсе –** Әҗмәт авылы, чишмә атамасы.
**Зирекле күл** – Иске Байсар, Уразай авыллары, күл атамасы.
**Зиреклек (Урта саз) –** Иске Айман авылы, урман атамасы.
**Зират тавы –** Теләкәй авылы, тау атамасы.
**Зират тыкрыгы –** Апач, Әтәс авыллары, тыкрык атамасы.
**Зират урамы –** Олыимән авылы, урам атамасы.
**Зират чишмәсе –** Такталачык авылы, чишмә атамасы.
**Зират чокыры** – Шәрип авылы, чокыр атамасы.
**Зөһрә коесы** – Усы авылы, кое атамасы.
**Зөһрә тавы** – Чишмәбаш, Чиялек (Иске Байсар) авыллары, тау атамасы.
**Зур урман** – Аккүз авылы, урман атамасы.
**Зыя кыр станы** – Түбән Яхшый авылы, кыр атамасы.
**Зыярат сазы –** Иске Айман авылы, сазлык атамасы.
**Идарә чишмәсе –** Такталачык авылы, чишмә атамасы.
**Идел –** Әҗмәт, Такталачык авыллары, елга атамасы.
**Изгеләр чишмәсе** – Актаныш авылы, чишмә атамасы.
**Изһам чишмәсе** – Иске Кормаш авылы, чишмә атамасы.
**Ике имәнлек** – Шәрип авылы, урын атамасы.
**Ике камыш –** Адай авылы, чабулык атамасы.
**Икенче тау –** Теләкәй авылы, тау атамасы.
**Илбакты чокыры –** Такталачык авылы, чокыр атамасы.
**Илек тавы –** Теләкәй авылы, тау атамасы.
**Ильяс чишмәсе** – Иске Солтангол авылы, чишмә атамасы.
**Иманай күле** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Имәнле күл** – Усы авылы, күл атамасы.
**Имәнлек** – Уразай авылы, урын атамасы.
**Имәнлек урманы –** Табанлыкүл авылы, урман атамасы.
**Индус, Митҗан, Муллахан, Хатыйп посадкалары** – Иске Балтач авылы, посадка атамалары.
**Ипи тавы** – Кыр-Каентүбә авылы, тау атамасы.
**Иркә күл** – Чуракай авылы, күл атамасы.
**Ирмәш күле –** Ирмәш авылы, күл атамасы.
**Исәмәт** – Иске Байсар авылы, инеш атамасы.
**Исәмәт юлы** – Аккүз авылы, юл атамасы.
**Иске авыл коесы –** Адай авылы, кыр атамасы.
**Иске авыл күле** – Уразай авылы, күл атамасы.
**Иске авыл чокыры –** Адай авылы, чокыр атамасы.
**Иске Идел** – Актаныш авылы, елга атамасы.
**Иске Идел елгасы –** Ирмәш авылы, елга атамасы.
**Иске Шәбез** – Чалманарат авылы, елга атамасы.
**Исмай полосасы** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, урман атамасы.
**Ишан зираты –** Карач авылы, зират атамасы.
**Ишәле коесы –** Бурсык авылы, кое атамасы.
**Ишмән болыны** – Күҗәкә авылы, болын атамасы.
**Ишмән буе** – Чишмәбаш авылы, урын атамасы.

**Ишти куагы күле –** Әнәк авылы, күл атамасы.
**Йахшый суы** – Иске Байсар авылы, сулык атамасы.
**Йомран очы –** Әнәк авылы, урам атамасы.
**Йомры күл –** Меңнәр авылы, күл атамасы.
**Йомры тал –** Буаз-күл авылы, урын атамасы.
**Йөзнарат урманы** – Чәчер авылы, урман атамасы.
**Кабак күле** – Кәзкәй, Тыңламас авыллары, күл атамасы.
**Кабак тау башы** – Тыңламас авылы, тау атамасы.
**Кабыклы күпер –** Иске Айман авылы, күпер атамасы.
**Кави мәчете –** Аеш авылы, мәчет атамасы.
**Кадермәт басуы** – Иске Кадермәт авылы, басу атамасы.
**Каен бакчасы** – Кәзкәй авылы, бакча атамасы.
**Каен күпер** – Иске Байсар авылы, күпер атамасы.
**Каен сыза сырты** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Каенлы кул** – Чишмә авылы, урын атамасы.
**Каенлы күл –** Аеш авылы, күл атамасы.
**Каенлыкүл –** Табанлыкүл авылы, күл атамасы.
**Каенлы кул чокыры** – Кыр-Каентүбә авылы, чокыр атамасы.
**Каенлык** – Чөгәнә авылы, агачлык атамасы.
**Каенлык урамы** – Шәрип авылы, урам атамасы.
**Каенлык урамы коесы** – Шәрип авылы, кое атамасы.
**Каенлык урманы** – Иске Богады авылы, урман атамасы.
**Каенсаз(ы)** – Иске Богады авылы, сазлык атамасы.
**Каз күле –** Аеш, Кәзкәй авыллары, күл атамасы.
**Каз тәкие** – Уразай авылы, урын атамасы.
**Казан күле** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Казна тавы –** Мерәс авылы, тау атамасы.
**Кайна тау –** Ахун авылы, тау атамасы.
**Калмаш тавы** – Иске Кормаш авылы, тау атамасы.
**Калмаш Тарлау** – Мари Суыксуы авылы, урын атамасы.
**Калмыя** – Иске Байсар авылы, елга атамасы.
**Калмыя елгасы –** Табанлыкүл, Чуракай авыллары, елга атамасы.
**Кама тамагы –** Адай авылы, урын атамасы.
**Камчау** – Яңа Әлем авылы, әрәмәлек атамасы.
**Камырлык чокыры** – Иске Җияш авылы, чокыр атамасы.
**Камышлык** – Күҗәкә авылы, печәнлек атамасы.
**Камышлы күл** – Куян, Чуракай авыллары, күл атамасы.
**Канау буе –** Адай авылы, печәнлек атамасы.
**Кантон наратлары** – Чалманарат авылы, урын атамасы.
**Кап юлы** – Күҗәкә авылы, юл атамасы.
**Карабай чишмәсе –** Бурсык авылы, чишмә атамасы.
**Карабаш имәнлеге –** Иске Әгъбас авылы, урман атамасы
**Карабия тавы –** Иске Айман авылы, тау атамасы.
**Каравыл тавы** – Иске Байсар авылы, тау атамасы.
**Караҗирек –** Адай авылы, агачлык атамасы.
**Караҗирек әрәмәсе** – Чөгәнә авылы, әрәмә атамасы.
**Кара күл –** Адай, Кәзкәй авыллары, күл атамасы.
**Карамалы куак –** Адай авылы, куаклык атамасы.
**Карамулла коесы** – Киров авылы, кое атамасы.
**Карамулла тыкрыгы** – Киров авылы, тыкрык атамасы.
**Караңгы авыл чокыры –** Татар Ямалы авылы, чокыр атамасы.
**Караңгылык урманы** – Түбән Яхшый авылы, урман атамасы.
**Кара саз** – Күҗәкә авылы, сазлык атамасы.
**Кара сыер елгасы –** Зөбәер авылы, елга атамасы.
**Кара тәкә күле –** Ирмәш авылы, күл атамасы.
**Кара тәкә чокыры** – Иске Кормаш авылы, чокыр атамасы.
**Карачәч елгасы** – Аккүз авылы, елга атамасы.
**Кара чокыр** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, чокыр атамасы.
**Кара яр –** Качкын авылы, чокырлы ялан атамасы.
**Караяр күле** – Уразай авылы, күл атамасы.
**Караяр сулыгы –** Әнәк авылы, яр атамасы.

**Кара яр күле –** Пучы авылы, күл атамасы.
**Карга очы** – Иске Балтач авылы, оч атамасы.
**Карга тавы** – Иске Байсар авылы, тау атамасы.
**Карга урамы** – Чуракай авылы, урам атамасы.
**Каргалы куак** – Иске Сәфәр авылы, алан атамасы.
**Кар ерымы** – Шәбезбаш авылы, чокыр атамасы.
**Карт авыл очы –** Тат. Суыксуы авылы, урам атамасы.
**Карт инеше** – Карт авылы, инеш атамасы.
**Каршы әрәмә –** Татар Ямалы авылы, әрәмә атамасы.
**Каршы әрәмә күле –** Татар Ямалы авылы, күл атамасы.
**Каршы тау** – Кыр-Каентүбә авылы, тау атамасы.
**Каһарман коесы** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Каһир чишмәсе** – Чөгәнә авылы, чишмә атамасы.
**Качкын очы коесы –** Зөбәер авылы, кое атамасы.
**Качкын урамы –** Олыимән авылы, урам атамасы.
**Кашка тау –** Зөбәер авылы, тау атамасы.
**Каюм тыкрыгы –** Ирмәш авылы, тыкрык атамасы.
**Кәбиб чокыры** – Уразай авылы, чокыр атамасы.
**Кәҗә баткагы (Бака күле) –** Ирмәш авылы, күл атамасы.
**Кәҗә буасы** – Яңа Әлем авылы, буа атамасы.
**Кәҗә куаклыгы** – Чуракай авылы, куаклык атамасы.
**Кәҗә күпере күле** – Иске Кормаш авылы, күл атамасы.
**Кәҗә тавы** – Яңа Балтач, Иске Уръяды авыллары, тау атамасы.
**Кәкре күл –** Аеш авылы, күл атамасы.
**Кәлтә елан чишмәсе –** Пучы авылы, чишмә атамасы.
**Кәлтәү** – Иске Кормаш авылы, урын атамасы.
**Кәлтәү күпер сызасы** – Чат авылы, урын атамасы.
**Кәпәй елгасы –** Тат. Суыксуы, Яңа Кормаш авыллары, елга атамасы.
**Кәпәй куагы** – Чат авылы, куаклык атамасы.
**Кәрәкә** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Кәрәкә күле** – Тыңламас авылы, күл атамасы.
**Кәрге күле –** Такталачык авылы, күл атамасы.
**Кәрим чокыры –** Тат. Суыксуы авылы, чокыр атамасы.
**Кәшәй тавы** – Тыңламас авылы, тау атамасы.
**Кече бүләк –** Зөбәер авылы, әрәмәлек атамасы.
**Кече бүләк** – Каенлык авылы, алан атамасы.
**Кече Бүләк –** Терпеле авылы, урын атамасы.
**Кече Бүләк әрәмәсе** – Иске Богады авылы, ялан атамасы.
**Кече нарат –** Мерәс авылы, наратлык атамасы.
**Кече урман** – Яңа Әлем авылы, урман атамасы.
**Киек сазы –** Иске Айман авылы, сазлык атамасы.
**Киек сырты** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Килтекәй чокыры –** Әнәк, Пучы авыллары, чокыр атамасы.
**Киндер күле –** Адай, Бурсык, Бүләк, Кәзкәй авыллары, күл атамасы.
**Киндерле күл –** Илчебай авылы, күл атамасы.
**Кирәмәт тавы –** Буаз-күл, Илчебай, Татар Ямалы, Уразай авыллары, тау атамасы.
**Кирмәнчек –** Тат. Суыксуы авылы, урын атамасы.
**Кирмәнчек тавы –** Татар Ямалы авылы, тау атамасы.
**Коелы чокыр** – Иске Кадермәт авылы, чокыр атамасы.
**Козгын әрәмәсе** – Аккүз авылы, әрәмә атамасы.
**Кой бүләге урманы –** Әнәк авылы, урман атамасы.
**Колхоз урамы** – Чөгәнә авылы, урам атамасы.
**Колхоз урамы (Купшылар урамы) –** Такталачык авылы, урам атамасы.
**Комгансызлар урамы** – Яңа Балтач авылы, урам атамасы.
**Комтамак суы** – Иске Байсар авылы, сулык атамасы.
**Кондыз** – Уразай авылы, урын атамасы.
**Кондызлы күле –** Татар Ямалы авылы, күл атамасы.
**Коркылан** – Чишмә авылы, урман атамасы.
**Кормаш басуы –** Иске Әгъбәс, Чуракай авыллары, басу атамасы.

**Кортлык –** Тат. Суыксуы авылы, урын атамасы.
**Коры каен сазы** – Яңа Әлем авылы, сазлык атамасы.
**Корыч чокыр –** Тат. Суыксуы, Яңа Кормаш авыллары, чокыр атамасы.
**Котлыяммәт чыбынлыгы –** Адай авылы, урын атамасы.
**Котый** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Котый сызасы –** Адай авылы, сазлык атамасы.
**Котыш күле** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Көҗекә суы** – Иске Байсар авылы, елга атамасы.
**Көймә түше** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, урын атамасы.
**Көләгеш күле –** Тат. Суыксуы авылы, күл атамасы.
**Көнтәй күле –** Әҗәкүл авылы, күл атамасы.
**Көньяк урамы** – Чөгәнә авылы, урам атамасы.
**Көтес күле** – Аккүз авылы, күл атамасы.
**Көтүче коесы** – Иске Җияш авылы, кое атамасы.
**Кугалы күле –** Татар Ямалы авылы, күл атамасы.
**Куйбышев урамы** – Иске Уръяды авылы, урам атамасы.
**Кул арасы** – Уразай авылы, урын атамасы.
**Кушай чокыры –** Табанлыкүл, Түбән Яхшый авыллары, чокыр атамасы.
**Кушкүпер** – Күҗәкә авылы, күпер атамасы.
**Куштан чокыры –** Тат. Суыксуы, Яңа Кормаш авыллары, чокыр атамасы.
**Куян борылмасы –** Буаз-күл, Татар Ямалы авыллары, юл борылмасы атамасы.
**Куян сазлыгы –** Ирмәш авылы, сазлык атамасы.
**Куян сазы** – Түмерҗә авылы, сазлык атамасы.
**Куян яланы** – Киров авылы, ялан атамасы.
**Күбәнлек** – Яңа Әлем авылы, аланлык атамасы.
**Күгәнлек** – Күҗәкә авылы, агачлык атамасы.
**Күгәннек –** Адай авылы, агачлык атамасы.
**Күҗәкә башы** – Иске Уръяды авылы, урын атамасы.
**Күл** – Чәчер, Чишмә авыллары, күл атамасы.
**Күл буе урамы** – Чөгәнә авылы, урам атамасы.
**Күлләвек** – Актанышбаш авылы, урын атамасы.
**Күмер базы** – Түмерҗә авылы, урын атамасы.
**Күмерсау** – Чалманарат авылы, урын атамасы.
**Күперле саз** – Иске Җияш, Иске Сәфәр авыллары, сазлык атамасы.
**Күперле саз чишмәсе** – Иске Җияш, Теләкәй авыллары, чишмә атамасы.
**Күперлесадә** – Иске Кормаш авылы, чокыр атамасы.
**Күрәнле күл** – Кыр-Каентүбә авылы, күл атамасы.
**Күрәнлек** – Яңа Әлем авылы, урын атамасы.
**Күрән сазы** – Иске Байсар авылы, сазлык атамасы.
**Күркә кулы –** Апач, Әтәс авыллары, чокыр атамасы.
**Күркә очы** – Иске Балтач авылы, оч атамасы.
**Күркә яры –** Апач авылы, яр атамасы.
**Күч елгасы –** Иске Айман авылы, елга атамасы.
**Кыдай талы күле** – Уразай авылы, күл атамасы.
**Кыйбла урамы** – Тыңламас авылы, урам атамасы.
**Кыйбла чишмәсе –** Зөбәер, Иске Кормаш, Түке авыллары, чишмә атамасы.
**Кыйтката тавы** – Яңа Балтач авылы, тау атамасы.
**Кызлар басмасы** – Иске Балтач авылы, күпер атамасы.
**Кызлар тавы –** Мерәс, Чалманарат авыллары, тау атамасы.
**Кызыл саз** – Күҗәкә авылы, сазлык атамасы.
**Кызыл тау** – Аккүз, Ахун авыллары, тау атамасы.
**Кызылтау –** Әнәк авылы, тау атамасы.
**Кызыл төбәк –** Иске Айман авылы, урын атамасы.
**Кызылъяр чишмәсе** – Күҗәкә авылы, чишмә атамасы.
**Кызыл яр** – Аккүз, Апач, Такталачык, Чалманарат авыллары, яр атамасы.
**Кылчыбай –** Бүләк авылы, урын атамасы.
**Кылы буе –** Адай авылы, ялан атамасы.
**Кылы күле** – Уразай авылы, күл атамасы.
**Кылыч күле** – Тыңламас авылы, күл атамасы.
**Кымыз цехы –** Меңнәр авылы, урын атамасы.
**Кыр станы басуы –** Табанлыкүл авылы, басу атамасы.

**Кыргыз күпере –** Адай авылы, күпер атамасы.
**Кыргыз түре –** Апач авылы, басудагы калкулык-сырт атамасы.
**Кыргын сырты** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Кыркүл –** Иске Айман авылы, күл атамасы.
**Кыска күл** – Аккүз, Иске Бикчәнтәй авыллары, күл атамасы.
**Кыска күл елгасы** – Чөгәнә авылы, елга атамасы.
**Кыска күл чокыры –** Тат. Суыксуы, Чөгәнә, Яңа Кормаш авыллары, чокыр атамасы.
**Кытай урамы (Татарстан)** – Күҗәкә авылы, урам атамасы.
**Кытыл әрәмәлеге** – Актаныш авылы, әрәмә атамасы.
**Кытыл әрәмәсе** – Чөгәнә авылы, әрәмә атамасы.
**Кытыл болыны –** Әҗәкүл авылы, болын атамасы.
**Кытыл буе –** Ирмәш авылы, әрәмә атамасы.
**Кышкы күл –** Адай авылы, күл атамасы.
**Кыяклы күл** – Кыр-Каентүбә авылы, күл атамасы.
**Кыяклык** – Күҗәкә авылы, печәнлек атамасы.
**Кюнних басуы** – Иске Кадермәт авылы, басу атамасы.
**К.Якубов урамы** – Иске Кадермәт авылы, урам атамасы.
**Лавка чокыры** – Күҗәкә авылы, чокыр атамасы.
**Ләфкә чокыры –** Тат. Суыксуы, Адай авыллары, чокыр атамасы.
**Локман тыкрыгы –** Иске Айман авылы, тыкрык атамасы.
**Лыпыды** – Актаныш авылы, күл һәм болын атамасы.
**Мадарат күле** – Аккүз авылы, күл атамасы.
**Мадарат күпере** – Күҗәкә авылы, күпер атамасы.
**Мазар арты күле –** Ахун авылы, күл атамасы.
**Мазар елгасы –** Пучы авылы, елга атамасы.
**Мазарка –** Әнәк авылы, елга атамасы.
**Мал сулау –** Аеш авылы, күл атамасы.
**Мамыкай чишмәсе (Йушто Памаш)** – Мари Суыксуы авылы, чишмә атамасы.
**Манара басуы** – Иске Бикчәнтәй авылы, басу атамасы.
**Мансур лапасы** – Киров авылы, урын атамасы.
**Мансур полосасы** – Кыр-Каентүбә авылы, агачлык атамасы.
**Мансур чишмәсе** – Кыр-Каентүбә авылы, чишмә атамасы.
**Марҗа зираты** – Куян авылы, зиарат атамасы.
**Марҗа чокыры** – Түбән Яхшый авылы, чокыр атамасы.
**Мари зираты** – Аккүз, Ахун, Тат. Суыксуы авыллары, урын атамасы.
**Мари таллыгы –** Буаз-күл, Татар Ямалы авыллары, агачлык атамасы.
**Маслопром күпере** – Пучы авылы, күпер атамасы.
**Мастерской урамы** – Киров авылы, урам атамасы.
**Мәгәҗәй тавы –** Бурсык авылы, тау атамасы.
**Мәгъҗи әрәмәсе** – Иске Кормаш авылы, әрәмә атамасы.
**Мәгъҗи елгасы** – Яңа Кормаш авылы, елга атамасы.
**Мәгъҗи чишмәсе –** Яңа Кормаш авылы, чишмә атамасы.
**Мәктәп урамы** – Түбән Яхшый, Чөгәнә авыллары, урам атамасы.
**Мәктәп урамы (Качкын очы) –** Зөбәер авылы, урам атамасы.
**Мәликә чишмәсе** – Актаныш авылы, чишмә атамасы.
**Мәлкән чокыры** – Иске Балтач авылы, чокыр атамасы.
**Мәнәй тавы** – Чалманарат авылы, тау атамасы.
**Мәннан күле** – Кыр-Каентүбә авылы, күл атамасы.
**Мәннан чишмәсе** – Кыр-Каентүбә авылы, чишмә атамасы.
**Мәннәф карамасы –** Олыимән авылы, агачлык атамасы.
**Мәртен** – Күҗәкә авылы, күл атамасы.
**Мәртен күле –** Адай авылы, күл атамасы.
**Мәрфуга күпере** – Иске Сәфәр авылы, күпер атамасы.
**Мәрьям коесы –** Иске Айман авылы, кое атамасы.
**Мәсәде күле –** Мәсәде авылы, күл атамасы.
**Мәтеч кул чокыры** – Шәбезбаш авылы, чокыр атамасы.
**Мәчет елгасы –** Түбән Гәрәй авылы, елга атамасы.

**Мәчет каен асты** – Усы авылы, агачлык атамасы.
**Мәчет күпере –** Пучы авылы, күпер атамасы.
**Мәчет оршасы –** Мерәс, Шәрип авыллары, агачлык атамасы.
**Мәчет саклавы –** Аеш, Кәзкәй авыллары, утрау атамасы.
**Мәчет тавы** – Күҗәкә авылы, урам атамасы.
**Мәчет тыкрыгы –** Апач, Чалманарат, Иске Богады авыллары, тыкрык атамасы.
**Мәчет урамы –** Адай, Иске Кадермәт, Иске Кормаш, Куян, Шәрип авыллары, урам атамасы.
**Мәчет чокыры** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, чокыр атамасы.
**Мәчти әрәмәсе** – Яңа Кормаш авылы, әрәмә атамасы.
**Минеш яры** – Иске Кадермәт авылы, тау атамасы.
**Минсалих чишмәсе** – Чалманарат авылы, чишмә атамасы.
**Миргай чабыны –** Адай авылы, печәнлек атамасы.
**Мирзасаях коесы –** Табанлыкүл авылы, кое атамасы.
**Мирзаһит тавы** – Шәрип авылы, тау атамасы.
**Мирсәет күле** – Чишмә авылы, күл атамасы.
**Мишәр кабак асты** – Иске Байсар авылы, урын атамасы.
**Мишәр очы** – Яңа Әлем авылы, оч атамасы.
**Морза күле** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Мортыш күле –** Адай авылы, күл атамасы.
**Мосаллия мәчете** – Иске Байсар авылы, мәчет атамасы.
**Мостафа аланы** – Чалманарат авылы, алан атамасы.
**Моташ коесы** – Иске Кормаш авылы, кое атамасы.
**Мөстәкыйм коесы** – Усы авылы, кое атамасы.
**Мөхсинә чишмәсе** – Иске Солтангол авылы, чишмә атамасы.
**Мөшек елгасы** – Чиялек (Иске Айман) авылы, елга атамасы.
**Мукшы биләме** – Чишмәбаш авылы, урын атамасы.
**Мулла бакчасы** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Мулла басуы –** Әнәк авылы, басу атамасы.
**Мулла җиләне –** Татар Ямалы авылы, ялан атамасы.
**Мулла коесы** – Чалманарат авылы, кое атамасы.
**Мулла тавы** – Усы авылы, тау атамасы.
**Муллахмәт чокыры –** Такталачык авылы, чокыр атамасы.
**Мунча җиреклеге –** Адай авылы, агачлык атамасы.
**Мунчала** – Иске Байсар авылы, күл атамасы.
**Мунчала куагы –** Тат. Суыксуы авылы, урын атамасы.
**Мунчалы күл** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, күл атамасы.
**Мурзин әрәмәсе** – Киров, Олыимән авыллары, әрәмәлек атамасы.
**Муса тегермәне –** Тат. Суыксуы авылы, урын атамасы.
**Мутин чишмәсе –** Ирмәш авылы, чишмә атамасы.
**Мүк сазы –** Апач авылы, сазлык атамасы.
**Мүкле күл** – Кыр-Каентүбә авылы, күл атамасы.
**Мүкле саз** – Усы, Чөгәнә авыллары, сазлык атамасы.
**Мүксаз** – Аккүз авылы, сазлык атамасы.
**Мыртыш күле** – Күҗәкә авылы, күл атамасы.
**М. Вахитов урамы – Үзәк урам** – Иске Сәфәр авылы, урам атамасы.
**М. Җәлил урамы – Озын урам** – Иске Сәфәр авылы, урам атамасы.
**М. Мутин урамы (Ары киртә) –** Такталачык авылы, урам атамасы.
**Наратлы басу –** Адай авылы, басу атамасы.
**Наратлык –** Әнәк, Пучы авыллары, агачлык атамасы.
**Наратлы күл** – Түмерҗә авылы, күл атамасы.
**Нарат сырты** – Иске Уръяды авылы, басу атамасы.
**Нарат тавы –** Буаз-күл, Татар Ямалы авыллары, тау атамасы.
**Нардом тавы –** Такталачык авылы, тау атамасы.
**Нәби җиләне** – Күҗәкә авылы, болын атамасы.
**Нәвап мәчете** – Чишмә авылы, мәчет атамасы.
**Нәгыйм мәчете –** Иске Айман авылы, мәчет атамасы.
**Нәҗип чишмәсе** – Түбән Яхшый авылы, чишмә атамасы.

**Нэзкәй ерганагы** – Иске Богады авылы, чокыр атамасы.
**Нәкый сушилкасы** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Нәфыйк мәдрәсәсе –** Карт авылы, мәдрәсә атамасы.
**Нечкә җилән –** Тат. Суыксуы авылы, урын атамасы.
**Нечкә кул** – Чишмәбаш авылы, урын атамасы.
**Нечкә күл –** Бурсык авылы, күл атамасы.
**Нечкә саз–** Аеш, Кәзкәй авыллары, сазлык атамасы.
**Нечкә саз –** Тат. Суыксуы авылы, урын атамасы.
**Нигъмәй аланы** – Шәрип авылы, алан атамасы.
**Никкилдем урамы** – Тат. Суыксуы авылы, урам атамасы.
**Ниргез** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Нөркә урманы** – Актаныш авылы, урман атамасы.
**Нугашай –** Әҗмәт авылы, урын атамасы.
**Нугаш тавы –** Мерәс авылы, тау атамасы.
**Нукрат урамы –** Яңа Кормаш авылы, урам атамасы.
**Нургай урамы** – Түбән Яхшый авылы, урам атамасы.
**Нурҗиян тыкрыгы** – Күҗәкә авылы, тыкрык атамасы.
**Нури күпере –** Тат. Суыксуы авылы, күпер атамасы.
**Нурлый тавы –** Әҗмәт авылы, тау атамасы.
**Нурлый чишмәсе** – Иске Богады авылы, чишмә атамасы.
**Нур мәчете** – Киров авылы, мәчет атамасы.
**Нурый күпере** – Яңа Кормаш авылы, күпер атамасы.
**Озын атау** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Озын куак –** Качкын авылы, яр атамасы.
**Озынкул елгасы** – Чөгәнә авылы, елга атамасы.
**Озынкул чокыры** – Чөгәнә авылы, чокыр атамасы.
**Озынкул юлы** – Тыңламас авылы, юл атамасы.
**Озын күл –** Әҗәкүл, Ирмәш авыллары, күл атамасы.
**Озынкүл** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Озын күпер –** Бүләк авылы, күпер атамасы.
**Озын тал** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Озынтал –** Адай авылы, болын атамасы.
**Олачы (Олы ачыклык)** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Олы аклан** – Иске Байсар авылы, алан атамасы.
**Олы әрәмә** – Иске Кормаш, Яңа Кормаш, Тат. Суыксуы авыллары, әрәмә атамасы.
**Олы әрәмә** – Күҗәкә авылы, печәнлек атамасы.
**Олы бүләк –** Зөбәер авылы, алан атамасы.
**Олы Бүләк –** Терпеле авылы, урын атамасы.
**Олы Бүләк аланы** – Иске Богады авылы, алан атамасы.
**Олы елга –** Яңа Кормаш авылы, елга атамасы.
**Олы җәнтек** – Иске Байсар авылы, алан атамасы.
**Олыимән елгасы –** Олыимән авылы, елга атамасы.
**Олыимән инеше –** Тәкмәк авылы, инеш атамасы.
**Олы кое** – Иске Балтач, Иске Кормаш авыллары, кое атамасы.
**Олы куак –** Аеш, Табанлыкүл авыллары, куаклык атамасы.
**Олы куак яланы** – Түбән Яхшый авылы, ялан атамасы.
**Олы кул** – Чалманарат, Иске Байсар, Уразай, Чөгәнә авыллары, күл атамасы.
**Олы күл тау асты** – Иске Байсар авылы, урын атамасы.
**Олы тау күле** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Олы урам** – Куян авылы, урам атамасы.
**Олы урман** – Яңа Әлем авылы, урман атамасы.
**Олы чишмә** – Түмерҗә авылы, чишмә атамасы.
**Олы юл** – Кыр-Каентүбә, Такталачык авыллары, юл атамасы.
**Олы кое** – Шәрип авылы, кое атамасы.
**Олы күпер –** Апач, Әтәс авыллары, күпер атамасы.
**Олы нарат –** Мерәс авылы, урын атамасы.
**Олы урам** – Шәрип авылы, урам атамасы.
**Олы Чарлак –** Аеш авылы, печәнлек атамасы.
**Олы чишмә –** Олыимән авылы, чишмә атамасы.
**Олы юл тавы** – Иске Байсар авылы, тау атамасы.
**Офицер ерымы** – Шәбезбаш авылы, чокыр атамасы.
**Очлыкай** – Актаныш авылы, урын атамасы.

**Очлыкай печәнлеге** – Чөгәнә авылы, печәнлек атамасы.
**Очлы сырт –** Әнәк, Пучы авыллары, урын атамасы.
**Очтүбә –** Тат. Суыксуы авылы, урын атамасы.
**Өзек күл –** Аеш авылы, күл атамасы.
**Өлкәр тавы –** Әҗмәт, Такталачык авыллары, тау атамасы.
**Өлкәр тау –** Югары Гәрәй авылы, тау атамасы.
**Өмә тавы** – Яңа Кормаш авылы, тау атамасы.
**Өмет мәчете –** Теләкәй авылы, мәчет атамасы.
**Өммегөлсем мәчете** – Иске Богады авылы, мәчет атамасы.
**Өске Актаныш** – Актаныш авылы, бистә атамасы.
**Өчаер күле** – Чәчер авылы, күл атамасы.
**Өч аеры күле –** Әнәк, Пучы авыллары, күл атамасы.
**Өчимән буасы** – Киров авылы, буа атамасы.
**Өчкүл** – Кыр-Каентүбә авылы, күл атамасы.
**Өчтөтен тыкрыгы** – Иске Уръяды авылы, тыкрык атамасы.
**Өчтөтен урамы –** Адай авылы, урам атамасы.
**Өчтөтен чишмәсе –** Адай авылы, чишмә атамасы.
**Өчтүбә** – Яңа Кормаш авылы, урын атамасы.
**Өч чишмә** – Чишмә авылы, чишмә атамасы.
**Өшәр елгасы** – Чәчер авылы, елга атамасы.
**Өшәр күле –** Әнәк авылы, күл атамасы.
**Өянке сазы** – Югары Богады авылы, сазлык атамасы.
**Өянкеле чишмә –** Меңнәр авылы, чишмә атамасы.
**Пар чишмә** – Иске Богады авылы, чишмә атамасы.
**Парк урамы –** Олыимән, Уразай авыллары, урам атамасы.
**Пәри яры** – Кыр-Каентүбә, Иске Балтач авыллары, ерым атамасы.
**Песи күле** – Күҗәкә авылы, күл атамасы.
**Петел канаты** – Иске Байсар авылы, урын атамасы.
**Петр тау** – Тыңламас авылы, тау атамасы.
**Печмән басуы** – Чалманарат авылы, басу атамасы.
**Печмән елгасы –** Әҗмәт, Иске Байсар авыллары, елга атамасы.
**Печмән күпере** – Чалманарат авылы, күпер атамасы.
**Плат кулы** – Иске Байсар авылы, урын атамасы.
**Плат күле** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, күл атамасы.
**Почманкүл** – Яңа Балтач авылы, күл атамасы.
**Почырман күпере** – Тыңламас авылы, күпер атамасы.
**Поши чокыры** – Шәбезбаш авылы, чокыр атамасы.
**Прис буе –** Адай авылы, болын атамасы.
**Прис буе** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Приют басуы** – Иске Кадермәт, Иске Сәфәр авыллары, басу атамасы.
**Пугач тавы –** Адай, Иске Кормаш авыллары, тау атамасы.
**Пугач явы үткән басу –** Адай авылы, басу атамасы.
**Пучинка** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Пучы юлы –** Зөбәер авылы, юл атамасы.
**Пыршый күле –** Тат. Суыксуы авылы, күл атамасы.
**Равил аланы** – Чөгәнә авылы, алан атамасы.
**Рамазан мәчете** – Тыңламас авылы, мәчет атамасы.
**Рафаэль коесы** – Күҗәкә ,Такталачык авыллары, кое атамасы.
**Рәгатъ елгасы –** Зөбәер авылы, елга атамасы.
**Рәгать сазлыгы** – Чәчер авылы, сазлык атамасы.
**Рәдис буасы** – Уразай авылы, буа атамасы.
**Рәсил чишмәсе** – Кыр-Каентүбә авылы, чишмә атамасы.
**Рәфәр чишмәсе** – Качкын авылы, чишмә атамасы.
**Рудник чокыры –** Иске Әгъбәс авылы, чокыр атамасы.
**Рус буасы –** Иске Әлем авылы, буа атамасы.
**Рус елгасы –** Мерәс авылы, елга атамасы.
**Р. Фәрдиев исемендәге урам (Яңа урам) –** Зөбәер авылы, урам атамасы.
**Сабанай урамы –** Адай авылы, урам атамасы.
**Сабира мәчете** – Түбән Яхшый авылы, мәчет атамасы.
**Сабыр елгасы** – Иске Кадермәт авылы, елга атамасы.

**Сабыр чишмәсе** – Иске Сәфәр авылы, чишмә атамасы.
**Садак күле –** Татар Ямалы авылы, күл атамасы.
**Сада тавы (Яңа басу)** – Шәрип авылы, тау атамасы.
**Сазлык урманы** – Чалманарат авылы, урман атамасы.
**Саз урамы** – Яңа Әлем авылы, урам атамасы.
**Салавыз сырты** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Салам урамы** – Яңа Әлем авылы, урам атамасы.
**Салкын чишмә –** Адай, Әнәк, Иске Уръяды, Күҗәкә, Пучы, Усы авыллары, чишмә атамасы.
**Сания күле –** Иске Айман авылы, күл атамасы.
**Сапуш коесы –** Такталачык авылы, кое атамасы.
**Сарашлы елга** – Уразай авылы, елга атамасы.
**Сарашлы елгасы –** Әнәк, Пучы авыллары, елга атамасы.
**Сарашлы инеше –** Зөбәер авылы, инеш атамасы.
**Сарсаз** – Яңа Кормаш авылы, урын атамасы.
**Сарсаз болыны** – Чат авылы, болын атамасы.
**Сары кое чишмәсе** – Тыңламас авылы, чишмә атамасы.
**Сары мәчет** – Иске Байсар авылы, мәчет атамасы.
**Сәвәнәй чокыры** – Чат авылы, чокыр атамасы.
**Сәгъди күпере** – Иске Сәфәр авылы, күпер атамасы.
**Сәгъди чокыры** – Иске Сәфәр авылы, чокыр атамасы.
**Сәет күле** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, күл атамасы.
**Сәет чокыры** – Аеш авылы, чокыр атамасы.
**Сәйфи тарлавы –** Теләкәй авылы, калкулык атамасы.
**Сәмига мәчете –** Адай авылы, мәчет атамасы.
**Сәппи тыкрыгы –** Әтәс авылы, тыкрык атамасы.
**Сәптем тавы –** Татар Ямалы авылы, тау атамасы.
**Сәфәр суы** – Иске Сәфәр авылы, елга атамасы.
**Сәфәр урманы** – Киров авылы, урман атамасы.
**Сәхил коесы –** Әҗмәт, Такталачык авыллары, кое атамасы.
**Сибәт чокыры** – Чалманарат авылы, чокыр атамасы.
**Сигезлекәй тавы –** Такталачык авылы, тау атамасы.
**Сикия** – Иске Байсар авылы, елга атамасы.
**Сикия елгасы –** Табанлыкүл, Тәкмәк, Түбән Яхшый авыллары, елга атамасы.
**Сирай күле** – Усы авылы, күл атамасы.
**Совет урамы** – Иске Уръяды авылы, урам атамасы.
**Солтан Шәрипов урамы –** Иске Айман авылы, урам атамасы.
**Солтан юлы** – Күҗәкә авылы, кыр атамасы.
**Сөләйман күпере** – Уразай авылы, күпер атамасы.
**Сөлекле күл –** Аеш авылы, күл атамасы.
**Сөнгәл күле –** Әҗәкүл авылы, күл атамасы.
**Сөн елгасы** – Тыңламас авылы, елга атамасы.
**Сөтлә күле –** Мәсәде авылы, күл атамасы.
**Сөтлә(е) күл(е) –** Татар Ямалы авылы, күл атамасы.
**Сөтлә тавы –** Татар Ямалы авылы, тау атамасы.
**Стан-бай** – Кыр-Каентүбә авылы, тау итәге атамасы.
**Станса күле** – Яңа Балтач авылы, күл атамасы.
**Су буе урамы** – Иске Богады авылы, урам атамасы.
**Суыксу борылмасы –** Татар Ямалы авылы, юл борылмасы атамасы.
**Сулау чокыры** – Шәрип авылы, чокыр атамасы.
**Сулы куак –** Апач, Әтәс, Түмерҗә, Чишмә, Актанышбаш авыллары, куаклык атамасы.
**Су тегермәне** – Иске Байсар авылы, урын атамасы.
**Суфи тавы** – Иске Кадермәт авылы, тау атамасы.
**Сушилка чокыры –** Такталачык авылы, чокыр атамасы.
**Суыксу борылмасы –** Буаз-күл авылы, борылма атамасы.
**Суыксу-Кужәкә юлы** – Иске Уръяды авылы, юл атамасы.
**Суыксу очы** – Иске Уръяды авылы, оч атамасы.

**Суык чишмә** – Яңа Балтач авылы, чишмә атамасы.
**Сүнәле –** Татар Ямалы авылы, басу атамасы.
**Сыер җәйләве** – Иске Байсар авылы, урын атамасы.
**Сыерчык күле** – Тыңламас авылы, күл атамасы.
**Сыза болыны** – Чат авылы, болын атамасы.
**Сыза буе –** Тат. Суыксуы авылы, урын атамасы.
**Сылу куак чокыры** – Иске Кормаш авылы, чокыр атамасы.
**С. Сәйдәшев урамы** – Иске Кадермәт авылы, урам атамасы.
**Табанлы күл –** Бурсык, Мәсәде авылы, күл атамасы.
**Табанлы күле –** Табанлыкүл авылы, күл атамасы.
**Таз урамы** – Чуракай авылы, урам атамасы.
**Тайлар яланы** – Иске Сәфәр авылы, ялан атамасы.
**Такталачык капкасы** – Чалманарат авылы, урын атамасы.
**Таллык** – Иске Кормаш, Олыимән авыллары, агачлык атамасы.
**Таллык елгасы** – Иске Байсар авылы, елга атамасы.
**Таллы кое** – Иске Кормаш авылы, кое атамасы.
**Талпанкүл** – Иске Байсар авылы, күл атамасы.
**Талсыза аланы** – Түбән Яхшый авылы, алан атамасы.
**Тана кулы –** Әтәс авылы, чокыр атамасы.
**Тарлау** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Тарлау –** Качкын авылы, ялан атамасы.
**Тарлау җире** – Иске Богады авылы, урын атамасы.
**Тарлау чокыры –** Иске Кормаш, Тат. Суыксуы, Яңа Кормаш авыллары, чокыр атамасы.
**Тартамак** – Чөгәнә авылы, урын атамасы.
**Татый болыны** – Кәзкәй авылы, болын атамасы.
**Тау асты бүләге** – Усы авылы, чокыр атамасы.
**Тау асты чишмәсе –** Зөбәер, Күҗәкә авыллары, чишмә атамасы.
**Тау башы** – Иске Кормаш, Такталачык авыллары, урын атамасы.
**Тау буе** – Уразай авылы, урын атамасы.
**Тау буе урамы** – Куян авылы, урам атамасы.
**Тау урамы** – Иске Кормаш авылы, урам атамасы.
**Тау чишмәсе –** Теләкәй авылы, чишмә атамасы.
**Таһир күле** – Чуракай авылы, күл атамасы.
**Таш кое –** Апач, Әтәс авыллары, кое атамасы.
**Таш тау** – Киров, Олыимән авыллары, тау атамасы.
**Ташкичү –** Такталачык авылы, урын атамасы.
**Ташком –** Әҗәкүл авылы, урын атамасы.
**Ташлы елга –** Әҗмәт, Иске Кормаш, Яңа Балтач авыллары, елга атамасы.
**Ташлыкул култыгы** – Түбән Яхшый авылы, урын атамасы.
**Ташлыкул чокыры** – Түбән Яхшый авылы, чокыр атамасы.
**Ташлыяр очы** – Түке авылы, урам атамасы.
**Тәкә кулы** – Чишмәбаш авылы, урын атамасы.
**Тәкәрлек күле –** Әнәк авылы, күл атамасы.
**Тәкәрлек күпере –** Пучы авылы, күпер атамасы.
**Тәкәрлек урамы –** Теләкәй авылы, урам атамасы.
**Тәкәрлек чишмәсе** – Чалманарат авылы, чишмә атамасы.
**Тәләй елгасы –** Яңа Кормаш авылы, елга атамасы.
**Тәмле елга чишмәсе –** Теләкәй авылы, чишмә атамасы.
**Тәмле чишмә** – Түмерҗә авылы, чишмә атамасы.
**Тәтәй авыл –** Татар Ямалы авылы, авыл атамасы.
**Тәтәй оршасы –** Татар Ямалы авылы, агачлык атамасы.
**Т. Гыйззәт урамы – Төпле урам** – Иске Сәфәр авылы, урам атамасы.
**Теге оч** – Чөгәнә авылы, оч атамасы.
**Тегермән буасы** – Шәрип авылы, буа атамасы.
**Тегермән колагы аланы** – Иске Байсар авылы, алан атамасы.
**Тегермән чокыры** – Иске Богады авылы, чокыр атамасы.
**Теләүле сазы –** Ахун авылы, сазлык атамасы.
**Телле тау** – Куян авылы, тау атамасы.
**Терпеле елгасы** – Аккүз, Иске Кадермәт, Иске Сәфәр, Терпеле авыллары, елга атамасы.



Э.Н. Фәттахов, Актаныш муниципаль районы башлыгы



Актаныш районы хакимияте бинасы



Актаныш күренеше



Актаныштагы ял паркы



Тыл ветераннарына һәйкәл



Минтимер Шәймиевкә бронза бюст ачылу тантанасы. Әнәк авылы



М.Ш. Шәймиевнең музей-йорты. Әнәк авылы



Яр буйлары. Актаныш



Мәдәният сарае. Актаныш



«Гамбәрия» мәчете. МТС бистәсе







Абышева Гөлҗиһан һәм аның эшләнмәләре. Татар Суыксуы



Хуҗина Миләүшә Хәләф кызы әнисе белән. Чалманарат



Бәдертдинова Исхания Шәйхелгали кызы. Әтәс





Зәкиева Рина Закир кызы чигүләре. Әтәс





Баянова Мәдәния Гайнәм кызы чигүләре. Олы Имән

Әмирова Вәсилә Мөхәммәтҗан кызы чигүләре. Киров исемендәге совхоз





Арысланова Алсу Илфәр кызы, чигүче. Чөгәнә



Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү үзәгендә эшләүчеләр.
Х.М. Шәрипова, З.М. Билалова, С.В. Рәхимова, Л.Ш. Нургалиева,
Ә.М. Фәтхетдинов, Ф.Г. Димиев, М.Ш. Шәйдәүләтов. 1980 еллар. Бурсык





Мирсәетова Гөлсинә Муллагали кызы чигүләре. Чәчер





Ильясова Факия Галимәрдан кызының эшләнмәләре. 2018 елгы. Мерәс

Җәмилова Гөлчирә Гани кызы эшләнмәләре. Олы Имән









Солтанова Ләлә Илфәр кызы чигүләре. Чөгәнә



Хәкимова Илиза Әфтах кызы, чигүче. Актаныш





Шәйхина Раушания Әнвәр кызы. Югары Яхшый



Рәхимова Рәфия Исмәгыйль кызы эшләнмәләре. Чынык



Нәбиева Фәния, чигүче, бәйләү остасы. Әгъбәз



Шириева Нәзиха Камал кызы эшләнмәләре. Өтәс







Габдрахманова Эльмира, бәйләү остасы. Татар Суыксуы



Бәдыйкова Мәрьям Зәбир кызы. Чуракай





Баянова Мәулия Шәрифулла кызы эшләре. Киров исемендәге совхоз



Муллагалиева Венера Вәли кызы эшләре. Чәчер



Хаҗиева Миннефаза Фатыйх кызы эшләнмәләре. Аккүз



Шәрипова Илсөяр Заһит кызы. Актаныш районы Балалар иҗаты үзәгенең өстәмә белем бирүче педагогы





Әхмәтов Камил Сабирҗан улы эшләнмәләре. Чалманарат

Галимов Исхак Ибраһим улы эшләнмәләре. Олы Имән





Иксанов Данил Марат улы эшләре. Аккүз





Локманов Роберт Сәүбән улы.
Уразай



Дәүләтов Дилшат Әбелмәних улы.
Әҗәкүл

Хәертдинов Сәйдәр Сәлах улы. Иске Теләкәй





Мосавиров Мирсаяф
Мосавир улы. Пучы



1960 елларда төзелгән йорт. Тәрәзә йөзлекләрен, киртәләрне ясаучы, йортны тышлаучы – М.М. Мосавиров. Пучы





Ганиев Артур Альберт улы эшләнмәләре.
Иске Байсар










Исламов Динар Дилфат улы эшләре. Михайловка




Кашапов Нурсил Хәмит улы. Әтәс





Экспедиция әгъзалары Н. Фәттахов, Шәһидә Максудова һәм Х. Гатина колхозчы белән әңгәмә вакытында. Актаныш авылы. Х. Ярми фотосы. 1948 ел



Х. Ярми информант белән әңгәмә вакытында. Иске Кормаш авылы. 1948 ел



Юлда: Халидә Гатина, Шәһидә Максудова, Н. Фәттах. Х. Ярми фотосы. 1948 ел



Әкиятче И. Фәррахов. Актаныш районы Иске Кормаш. 1948 ел



Яшь әкиятче Шәриф Закиров. Актаныш районы Т. Әҗби. 1948 ел



Х. Гатина информант (Шәфикъ Хөснуллин булырга мөмкин!) белән әңгәмә вакытында. Калинин районы Әмәкәй авылы. 1948 ел

Актаныш районы Иске Кормаш авылы яшьләре Х. Гатина белән. 1948 ел



**Терпеле сызасы** – Киров, Терпеле авыллары, урын атамасы.
**Тимерҗан күпере –** Тат. Суыксуы авылы, күпер атамасы.
**Тимер куагы** – Кәзкәй авылы, куаклык атамасы.
**Тимеркүл** – Яңа Әлем авылы, бетерелгән авыл атамасы. Бүгенге көндә Яңа Әлемдә урам атамасы.
**Тимер тырнагы сазы** – Иске Байсар авылы, сазлык атамасы.
**Тимер тырнак** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, урын атамасы.
**Тимер тырнак сырты** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Тимерче күл** – Уразай авылы, күл атамасы.
**Тимерчелек –** Илчебай авылы, урын атамасы.
**Тимершәех мәчете** – Иске Уръяды авылы, мәчет атамасы.
**Типтәрләр урамы –** Тат. Суыксуы авылы, урам атамасы.
**Типтәр урамы** – Яңа Әлем авылы, урам атамасы.
**Типтәр чишмәсе –** Иске Айман авылы, чишмә атамасы.
**Тирәнкул башы –** Апач авылы, чокыр атамасы.
**Тирән күл –** Буаз-күл, Татар Ямалы авыллары, күл атамасы.
**Тирән тоба –** Татар Ямалы авылы, елга атамасы.
**Тирән чокыр –** Иске Айман авылы, чокыр атамасы.
**Тиреслек асты –** Такталачык авылы, урын атамасы.
**Токым –** Качкын авылы, чокыр атамасы.
**Томбай** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Торалы урамы –** Тат. Суыксуы авылы, урам атамасы.
**Торна коесы** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, кое атамасы.
**Торна сазы –** Әнәк авылы, урман атамасы.
**Торна сазы –** Иске Айман, Иске Уръяды, Яңа Кормаш авыллары, сазлык атамасы.
**Торна сазы –** Тат. Суыксуы авылы, куаклык атамасы.
**Торна тавы –** Татар Ямалы авылы, тау атамасы.
**Төбәк –** Бурсык авылы, урын атамасы.
**Төбәк урманы** – Иске Богады авылы, урман атамасы.
**Төкәй тавы** – Иске Байсар, Табанлыкүл авыллары, тау атамасы.
**Төпле тыкрык –** Әнәк авылы, чат атамасы.
**Төпсез кое** – Иске Сәфәр авылы, кое атамасы.
**Төхфәй күпере** – Аккүз авылы, күпер атамасы.
**Төхфәт чишмәсе** – Чөгәнә авылы, чишмә атамасы.
**Трубкә урамы** – Тыңламас авылы, урам атамасы.
**Тубалас (Түбәләс)** – Иске Сәфәр авылы, тау атамасы.
**Тубылгы төбәк** – Аеш авылы, урын атамасы.
**Тугыз имән –** Апач авылы, урын атамасы.
**Тукай сызасы** – Киров авылы, урын атамасы.
**Тукмай** – Иске Балтач авылы, урын атамасы.
**Туктар күле (Пугачев явы) –** Татар Ямалы авылы, күл атамасы.
**Туплама –** Табанлыкүл авылы, көтүлек атамасы.
**Туры кое** – Усы авылы, кое атамасы.
**Түбәләй** – Шәбезбаш авылы, калкулык атамасы.
**Түбәләс тавы** – Киров авылы, тау атамасы.
**Түбән авыл чишмәсе –** Бурсык авылы, чишмә атамасы.
**Түбән басу** – Чөгәнә авылы, басу атамасы.
**Түбән елга –** Табанлыкүл авылы, буа атамасы.
**Түбән оч –** Апач, Әтәс, Кыр-Каентүбә, Иске Богады авыллары, урам атамасы.
**Түбән оч –** Иске Айман авылы, оч атамасы.
**Түбән урам –** Адай авылы, урам атамасы.
**Түбәрәскә** – Иске Җияш авылы, кыр атамасы.
**Түбә саз** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, саз атамасы.
**Түбәтәй** – Күҗәкә авылы, тау атамасы.
**Түбәтәй тау –** Зөбәер, Иске Сәфәр авыллары, тау атамасы.
**Түгәрәк ачы** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Түгәрәк куак** – Иске Бикчәнтәй авылы, куаклык атамасы.
**Түгәрәк күл** – Чөгәнә авылы, күл атамасы.
**Түгәрәк ялан –** Адай авылы, ялан атамасы.
**Түке юлы –** Зөбәер авылы, юл атамасы.
**Түке ягы** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Түмерҗә юлы** – Түмерҗә авылы, юл атамасы.

**Тыңламас елгасы** – Тыңламас авылы, елга атамасы.
**Тыңнамас елгасы** – Кәзкәй авылы, елга атамасы.
**Тырачы елгасы** – Аккүз авылы, елга атамасы.
**Убыр күл –** Меңнәр авылы, күл атамасы.
**Убыр күле –** Аеш авылы, күл атамасы.
**Убыр сызасы** – Аеш авылы, күл атамасы.
**Удык –** Буаз-күл, Татар Ямалы авыллары, әрәмәлек атамасы.
**Умарта бакчасы** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Умарталык –** Апач, Әтәс, Шәрип авыллары, умарталык атамасы.
**Умбо чокыры** – Иске Кадермәт авылы, чокыр атамасы.
**Умбы буасы** – Чат авылы, буа атамасы.
**Умбылык –** Татар Ямалы авылы, чокыр атамасы.
**Уразбай чишмәләре –** Мари Суыксуы авылы, чишмә атамасы.
**Уразлы урман –** Пучы авылы, урман атамасы**.**
**Уразлы (Урзалы) урманы –** Әнәк авылы, урман атамасы.
**Урдалы чокыры** – Шәрип авылы, чокыр атамасы.
**Урта бүләк –** Мерәс авылы, урын атамасы.
**Урта кое** – Качкын, Такталачык авыллары, кое атамасы.
**Урта күл –** Табанлыкүл авылы, күл атамасы.
**Уртанчы оч** – Кыр-Каентүбә авылы, урам атамасы.
**Урта тау –** Әнәк авылы, тау атамасы.
**Урта тыкрыгы** – Чишмә авылы, тыкрык атамасы.
**Урта урам** – Шәрип авылы, урам атамасы.
**Уръяды инеше** – Иске Уръяды авылы, инеш атамасы.
**Уръяды тамагы** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Уръяды юлы** – Күҗәкә авылы, юл атамасы.
**Урыс базы –** Илчебай авылы, чокыр атамасы.
**Урыс базы** – Түмерҗә авылы, урын, баз атамасы.
**Урыс базы юлы** – Аккүз авылы, юл атамасы.
**Урыс зираты** – Яңа Кормаш, Тат. Суыксуы авыллары, урын атамасы.
**Урыс куышы күләне** – Уразай авылы, урын атамасы.
**Урыс күпере** – Яңа Кормаш авылы, күпер атамасы.
**Урыс полосасы** – Иске Кадермәт авылы, урын атамасы.
**Урыс чишмәсе** – Иске Кадермәт авылы, чишмә атамасы.
**Урыс юлы** – Күҗәкә авылы, юл атамасы.
**Усак асты** – Чөгәнә авылы, урын атамасы.
**Усаклы куак** – Иске Уръяды авылы, басу атамасы.
**Үзәк суы** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Үзәк урам** – Иске Богады, Иске Кормаш, Уразай, Чөгәнә авыллары, урам атамасы.
**Үзәк урам (Көллек урамы) –** Зөбәер авылы, урам атамасы.
**Үзәк урам (Советская)** – Күҗәкә авылы, урам атамасы.
**Үләт чокыры** – Иске Җияш, Шәрип, Иске Әгъбас авыллары, чокыр атамасы.
**Үлек күле –** Ирмәш авылы, күл атамасы.
**Үле Сөн –** Аеш, Кәзкәй, Тыңламас авыллары, күл атамасы.
**Үрдәк күле** – Аккүз, Табанлыкүл авыллары, күл атамасы.
**Үрдәк күле коесы** – Түбән Яхшый авылы, кое атамасы.
**Үрдәкле күл** – Кыр-Каентүбә авылы, күл атамасы.
**Фаел коесы –** Иске Айман авылы, кое атамасы.
**Фазыл коесы** – Киров авылы, кое атамасы.
**Фазыл тавы –** Такталачык авылы, тау атамасы.
**Фазыл чишмәсе** – Аккүз, Такталачык авыллары, чишмә атамасы.
**Фарсый тыкрыгы** – Чөгәнә авылы, тыкрык атамасы.
**Фатих коесы** – Уразай авылы, кое атамасы.
**Фаягол яланы** – Киров авылы, ялан атамасы.
**Фәвәдис коесы –** Әҗмәт авылы, кое атамасы.
**Фәй җыены** – Иске Сәфәр авылы, урын атамасы.
**Фәрхетдин коесы** – Иске Уръяды авылы, кое атамасы.
**Фәссах тавы** – Иске Кадермәт авылы, тау атамасы.
**Фәттах бай мәчете һәм мәдрәсәсе** – Чуракай авылы, урын атамасы.
**Фәттах бай тегермәне** – Чуракай авылы, урын атамасы.

**Фәхертдин акмасы** – Уразай авылы, урын атамасы.
**Ферма буе чишмәсе** – Куян авылы, чишмә атамасы.
**Ф. Кәрим урамы – Төннек урамы** – Иске Сәфәр авылы, урам атамасы.
**Фруза** чишмәсе – Олыимән авылы, чишмә атамасы.
**Хазна чокыры** – Иске Богады авылы, чокыр атамасы.
**Халидә мәчете** – Күҗәкә авылы, мәчет атамасы.
**Халик усагы** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Хаммат коесы** – Иске Кормаш авылы, кое атамасы.
**Хан тавы** – Меңнәр авылы, тау атамасы.
**Хафиз бакчасы** – Иске Кормаш авылы, печәнлек атамасы.
**Хәдичә мәчете** – Качкын авылы, мәчет атамасы
**Хәзрәт таллыгы** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, агачлык атамасы.
**Хәзрәт чишмәсе –** Такталачык авылы, чишмә атамасы.
**Хәйдәр күле** – Иске Кадермәт авылы, күл атамасы.
**Хәйдәр сазы –** Апач авылы, сазлык атамасы.
**Хәким күле** – Кыр-Каентүбә авылы, күл атамасы.
**Хәләф коесы –** Такталачык авылы, кое атамасы.
**Хәләф чишмәсе** – Качкын авылы, чишмә атамасы.
**Хәлил күле** – Кыр-Каентүбә авылы, күл атамасы.
**Хәми тавы** – Югары Богады авылы, тау атамасы.
**Хәмит чишмәсе** – Актаныш авылы, елга атамасы.
**Х. Вахит урамы** – Иске Кадермәт авылы, урам атамасы.
**Хисмәт зираты** – Уразай авылы, зират атамасы.
**Хөҗҗәт күпере –** Адай, Күҗәкә авыллары, күпер атамасы.
**Хөсәй чокыры** – Чат авылы, чокыр атамасы.
**Х. Ямашев урамы – Сәлкәй** – Иске Сәфәр авылы, урам атамасы.
**Һ. Такташ урамы – Бакча урамы** – Иске Сәфәр авылы, урам атамасы.
**Чабаталы колхоз очы –** Апач авылы, урам атамасы.
**Чавай** – Мари Суыксуы авылы, чишмә атамасы.
**Чагыл тавы** – Иске Байсар авылы, тау атамасы.
**Чалка чокыры** – Иске Бикчәнтәй авылы, чокыр атамасы.
**Чапкын күпере –** Пучы авылы, күпер атамасы.
**Чапкын очы –** Пучы авылы, урам атамасы.
**Чат әрәмәсе** – Иске Кормаш авылы, әрәмә атамасы.
**Чатлыкай юлы** – Иске Богады авылы, юл атамасы.
**Чатлы күл** – Уразай авылы, күл атамасы.
**Чатра** – Иске Балтач авылы, ешлык атамасы.
**Чатра елгасы** – Иске Байсар авылы, елга атамасы.
**Чатра кәҗүнние урманы** – Иске Байсар авылы, урман атамасы.
**Чатра тарлавыгы** – Чалманарат авылы, урын атамасы.
**Чатра чишмәсе** – Иске Байсар авылы, чишмә атамасы.
**Чытырлы куак** – Иске Байсар авылы, куаклык атамасы.
**Чәбе –** Әҗмәт авылы, су буе атамасы.
**Чәбе суы –** Такталачык авылы, су буе атамасы.
**Чәйле күл –** Меңнәр, Уразай авыллары, күл атамасы.
**Чәйле күле –** Аеш авылы, күл атамасы.
**Чәй суы** – Иске Балтач авылы, чишмә атамасы.
**Чәмәк тавы** – Шәрип авылы, тау атамасы.
**Чәтертән –** Адай, Күҗәкә авыллары, әрәмәлек атамасы.
**Чәтертән аланы –** Тат. Суыксуы авылы, алан атамасы.
**Чәүкә тавы** – Иске Байсар авылы, тау атамасы.
**Чигер әрәмәсе** – Тыңламас авылы, әрәмә атамасы.
**Чигер күле** – Тыңламас авылы, күл атамасы.
**Чигер тамагы** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Чигер ягы юлы**– Тыңламас авылы, юл атамасы.
**Чиркәш болыны** – Күҗәкә авылы, болын атамасы.
**Чирмеш чокыры –** Тат. Суыксуы авылы, чокыр атамасы.
**Чирү юлы** – Иске Сәфәр, Күҗәкә авыллары, юл атамасы.

**Чиста –** Качкын авылы, кул-буа атамасы.
**Чишмә** – Чәчер авылы, чишмә атамасы.
**Чишмәле кул –** Апач, Әтәс авыллары, чокыр атамасы.
**Чишмә тавы** – Түке авылы, тау атамасы.
**Чишмә тау асты** – Аеш авылы, урман, умарталык, алан, тау бите атамасы.
**Чишмә урамы (Чүкеч урамы)** – Иске Кормаш авылы, урам атамасы.
**Чияле җилән –** Татар Ямалы авылы, болын атамасы.
**Чиялек** – Уразай авылы, урын атамасы.
**Чиялек күле –** Буаз-күл, Татар Ямалы авыллары, күл атамасы.
**Чиялек күпере –** Буаз-күл авылы, күпер атамасы.
**Чиялек сырты** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Чиялек тавы –** Теләкәй авылы, тау атамасы.
**Чиялек тау** – Кәзкәй авылы, тау атамасы.
**Чиялек тау башы** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Чөгәнә күле** – Чөгәнә авылы, күл атамасы.
**Чубар ягы басуы –** Әнәк авылы, басу атамасы.
**Чураш күле** – Чөгәнә авылы, күл атамасы.
**Чуккаен әрәмәсе** – Кәзкәй авылы, әрәмә атамасы.
**Чучка күле** – Иске Богады авылы, күл атамасы.
**Чүкә күле –** Ирмәш авылы, күлләвек атамасы.
**Чүкеч күл –** Меңнәр, Чиялек (Иске Байсар) авыллары, күл атамасы.
**Чүкеч күл** – авылы, күл атамасы.
**Чүк каен күле** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Чүмгәл –** Ирмәш, Уразай авыллары, урын атамасы.
**Чүмгәл тавы –** Бурсык авылы, тау атамасы.
**Чыҗым –** Әнәк авылы, урам атамасы.
**Чыпчык буасы** – Яңа Әлем авылы, буа атамасы.
**Шадрин урамы (Ворошилов)** – Күҗәкә авылы, урам атамасы.
**Шалкана тавы** – Күҗәкә авылы, кыр атамасы.
**Шарлавык чокыры** – Иске Байсар авылы, чокыр атамасы.
**Шарлама** – Иске Сәфәр, Уразай авыллары, сулык атамасы.
**Шарлама күл** – Куян, Апач, Әҗмәт, Иске Бикчәнтәй, Кыр-Каентүбә, Яңа Балтач, Уразай, Шәбез авыллары, күл атамасы.
**Шәбез инеше** – Иске Кормаш авылы, инеш атамасы.
**Шәбез күпере** – Чалманарат авылы, күпер атамасы.
**Шәбез суы** – Чалманарат авылы, елга атамасы.
**Шәех чишмәсе** – Кыр-Каентүбә авылы, чишмә атамасы.
**Шәйморат тавы** – Шәрип авылы, тау атамасы.
**Шәйхел бакчасы** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Шәйхел куагы** – Чат авылы, куаклык атамасы.
**Шәкертләр зираты** – Усы авылы, зират атамасы.
**Шәкүр кирәме тыкрыгы (Мәчет тыкрыгы) –** Әтәс авылы, тыкрык атамасы.
**Шәмәй чокыры –** Татар Ямалы авылы, чокыр атамасы.
**Шәмси чишмәсе** – Кыр-Каентүбә авылы, чишмә атамасы.
**Шәрәй күле –** Илчебай авылы, күл атамасы.
**Шәрәп чишмәсе** – Чөгәнә авылы, чишмә атамасы.
**Шәрә тау** – Чиялек (Иске Байсар) авылы, тау атамасы.
**Шәрәфи** – Шәрип авылы, урын атамасы.
**Шәрип буасы** – Уразай авылы, буа атамасы.
**Шәрип тарлавы** – Шәрип авылы, урын атамасы.
**Шәүлегән** – Иске Байсар авылы, сулык атамасы.
**Шәһимөхәммәт мәчете –** Әнәк авылы, мәчет атамасы.
**Шелекле** – Иске Балтач авылы, урын атамасы.
**Шифа чишмәсе** – Иске Кормаш авылы, чишмә атамасы.
**Шишара тыкрыгы** – Иске Уръяды авылы, тыкрык атамасы.
**Ш. Камал урамы – Мәчкә очы** – Иске Сәфәр авылы, урам атамасы.
**Шомырт күле –** Иске Айман авылы, күл атамасы.
**Шомыртлы куак** – Иске Сәфәр авылы, куаклык атамасы.

**Шүрәле сазы –** Әнәк авылы, сазлык атамасы.
**Шүрәле чокыры** – Иске Җияш авылы, чокыр атамасы.
**Шырлык әрәмәсе** – Кәзкәй авылы, әрәмә атамасы.
**Ык елгасы –** Әнәк авылы, елга атамасы.
**Ырша әрәмәлеге** – Чат авылы, әрәмә атамасы.
**Ыштан балагы** – Киров авылы, урын атамасы.
**Эт урамы** – Киров, Кыр-Каентүбә, Чуракай авыллары, урам атамасы.
**Эт үлгән күл –** Аеш авылы, күл атамасы.
**Югары оч –** Апач, Әтәс, Иске Айман, Киров, Кыр-Каентүбә авыллары, урам атамасы.
**Югары оч Мәчет тыкрыгы** – Иске Богады авылы, тыкрык атамасы.
**Югары оч сазы –** Әтәс авылы, сазлык атамасы.
**Югары оч урамы (Җәбрәйләр урамы)** – Иске Богады авылы, урам атамасы.
**Югары урман** – Иске Богады авылы, урман атамасы.
**Юкәле җилән** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Юкәле куак –** Иске Айман авылы, куаклык атамасы.
**Юкәле күл** – Иске Җияш авылы, күл атамасы.
**Юкәле күл суы** – Иске Балтач авылы, сулык атамасы.
**Юлдаш тегермәне** – Кәзкәй авылы, урын атамасы.
**Юныс тамагы** – Кәзкәй авылы, күл атамасы.
**Ябир чишмәсе** – Шәбезбаш авылы, чишмә атамасы.
**Якты күл –** Аеш, Меңнәр авыллары, күл атамасы.
**Якты күл –** Апач авылы, оч атамасы.
**Якуп чокыры** – Иске Балтач авылы, чокыр атамасы.
**Ялан** – Иске Кормаш авылы, алан атамасы.
**Яланкүл** – Чөгәнә авылы, күл атамасы.
**Яланъяр** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Ялгалы капкасы** – Чалманарат авылы, урын атамасы.
**Ялкау кул чокыры** – Иске Кадермәт авылы, чокыр атамасы.
**Ялпы кул** – Чөгәнә авылы, тау атамасы.
**Ялпы чокыры –** Апач авылы, чокыр атамасы.
**Ямалы күле –** Татар Ямалы авылы, күл атамасы.
**Яман саз** – Иске Байсар авылы, сазлык атамасы.
**Ямаш тавы (Ямаша курыкшо)** – Мари Суыксуы авылы, тау атамасы.
**Янган саз** – Иске Сәфәр авылы, сазлык атамасы.
**Янтек яланы –** Әнәк авылы, ялан атамасы.
**Яңа типтәрләр урамы –** Тат. Суыксуы авылы, урам атамасы.
**Яңа урам –** Иске Айман авылы, урам атамасы.
**Ярлыкул чишмәсе –** Такталачык авылы, чишмә атамасы.
**Яр чишмәсе** – Түке авылы, чишмә атамасы.
**Яу басты** – Күҗәкә авылы, урын атамасы.
**Яшел мәчет** – Иске Байсар авылы, мәчет атамасы.
**Яшел таш күпере** – Киров авылы, күпер атамасы.
**Яшел урам** – Кыр-Каентүбә авылы, урам атамасы.
**Яшелчә бакчасы –** Такталачык авылы, бакча атамасы.
**Яшелчә сызасы –** Олыимән авылы, әрәмә атамасы.
**Яшьләр урамы** – Иске Кормаш, Олыимән авыллары, урам атамасы.
**1 Май урамы – Аръяк** – Иске Сәфәр авылы, урам атамасы.
**1 Май урамы –** Олыимән авылы, урам атамасы.

# ЙӨЗЛӘРЕ ЯКТЫ, ТЕЛЛӘРЕ ТАТЛЫ

## Актаныш төбәгенең сөйләү үзенчәлекләре

*Дария Рамазанова*

Телебезнең җирле сөйләшләре галимнәр тарафыннан даими рәвештә тикшерелеп килә.

Аерым төбәкләрдәге җанлы сөйләм телен диалектология фәне өйрәнә. Диалектология фәне, җирле телне территориаль аспектта тикшереп, аның диалектларга, сөйләшләргә, урынчылыкларга бүленешен ачыклый.

Сөйләш, диалект дигәндә төбәкләрдә яшәп килә торган җанлы сөйләм теле күздә тотыла. Телебездә, кайбер сүзләрнең әйтелешенә, төрләнешенә хас аерымлыклар белән бер үк вакытта, аерым җирлектә генә кулланыла торган сүзләр дә күп. Алар теге яки бу сәбәпләр аркасында әдәби телгә керми калганнар, әмма төбәкләрдә актив кулланылуларын дәвам итәләр. Бу аерымлыкларның кайберләре зур ареалда таралганнар һәм телнең «диалект» дигән берәмлеген аерып чыгару өчен нигез булып торалар.

Билгеле булганча, кайбер аерымлыклар кечкенәрәк территорияләрдә дә күзәтелә. Мәсәлән, Татарстанның көнчыгыш, Башкортстанның көнбатыш районнарындагы татар авылларында *з* авазы урынына аның сакау варианты кулланыла: *dәңгәр, бed, қыdыл* һ. б. Әмма ул урта диалектның бер өлешенә генә хас. Мондый очракларда теге яки бу диалект сөйләшләргә бүленә. Сакау *d* авазы Татарстанның Тау ягындагы сөйләшләрдәге аерым сүзләрдә һәм мамадыш сөйләшендә дә очрый. Әмма

Минзәлә өязе территориясендә электән үк системалы рәвештә кулланылганлыктан, әлеге әйтелеш минзәлә сөйләшенең төп үзенчәлеге булып санала.

Диалект гомумхалык теле белән сөйләшләр арасында тора һәм уртак үзенчәлекләре булган берничә сөйләшне берләштерә. Сөйләшләр, – диалект белән чагыштырганда, ваграк тел берәмлеге. Алар, күренешләре буенча беркадәр аерымланган булсалар да, бер төркем әһәмиятле уртак диалекталь үзенчәлекләре белән үзара берләшәләр.

Урынчылыклар кайбер диалекталь күренешләрнең таррак күләмдә таралган булуы яки икенчел дәрәҗәдәге күренешләр сакланып килү белән аерылып чыгалар. Кайбер үзенчәлекләр күрше сөйләшләр йогынтысы астында һәм сөйләш таралган территориянең аерым бер төбәгендә генә дә барлыкка килергә мөмкин.

«Диалект», «сөйләш», «урынчылык» төшенчәләре турында фикер йөрткәндә бер нәрсә игътибар үзәгендә булырга тиеш: мөстәкыйль диалект, сөйләш яки урынчылыкларны аерым берәмлек итеп бүлеп чыгару өчен, аларга хас диалекталь күренешләр аерым, шушы берәмлек өчен генә характерлы системаны тәшкил итәргә тиешләр, бу системага һәм фонетик, һәм грамматик, һәм лексик күренешләр кергән булуы шарт. Әлеге система билгеле бер территория белән дә бәйле була. Фәндә ул территориаль-лингвистик принцип дип йөртелә.

Территориаль-лингвистик принциптан чыгып, татар телендә түбәндәге биш диалект билгеләнгән: урта, көнбатыш (мишәр), тобол-иртыш, бараба, том.

Болгар бабаларыбызның дәвамчылары булып саналган урта диалект вәкилләре «казан татарлары» дип йөртелсәләр, көнбатыш диалектта сөйләшүчеләрне «мишәрләр» дип атау гадәткә кергән.

Тобол-иртыш (Төмән, Омск өлкәләре), бараба (Новосибирск өлкәсе), том (Томск һәм Кемерово өлкәләре) диалектлары[1] вәкилләре исә Себердә яшиләр һәм «себер татарлары»

[1] Аларны икенче төрле көнчыгыш диалект дип тә йөртәләр. Әлеге өч диалектны себер диалектлары буенча белгеч Д. Г. Тумашева аерып чыгара. Аның нәтиҗәләрен безнең тикшеренүләр һәм атлас материаллары да раслады.

дип йөртеләләр. Бараба диалекты вәкилләре көнчыгыш төрки халыклардан (шор, хакас, алтай һ. б.) аерылып чыккан кабиләләр нигезендә формалашкан. Том диалекты вәкилләре, нигездә, татарлашкан телеутлардан тора.

Диалектлар (бараба диалектыннан кала) түбәндәге сөйләшләргә бүленәләр.

Көнбатыш диалект: темников, ләмбрә, кузнецк, карсун, хвалын, волгоград, сергач, чүпрәле, чистай, мәләкәс, шарлык, байкыбаш, стәрлетамак, подберезье, мордва-каратай һ. б.

Урта диалект: казан арты сөйләшләре төркеме (дөбьяз, мамадыш, балтач, лаеш; бәрәңге); тау ягы сөйләшләре төркеме (норлат, кама тамагы, тархан); керәшен сөйләшләре төркеме (казан арты керәшеннәре сөйләше, түбән кама керәшеннәре сөйләше, нагайбәк керәшеннәре сөйләше), әстерхан, касыйм, бастан, минзәлә, бөре, пермь, нократ, красноуфим, златоуст, эчкен, сафакүл, тепекәй, богырыслан, каргалы, камышлы һ. б.

Тобол-иртыш диалекты: түмән, тобол, саз ягы, тара, тевриз.

Том диалекты: яуштә-чат, калмак.

Актаныш төбәге халкы урта диалектның минзәлә сөйләшендә аралаша.

Минзәлә сөйләше Татарстанның Әгерҗе, Зәй, Минзәлә, Актаныш, Мөслим, Азнакай, Ютазы, Сарман, Бөгелмә, Башкортстанның Яңавыл, Краснокама, Тәтешле, Борай, Дүртөйле, Илеш, Чакмагыш, Шаран, Туймазы, Миякә, Фёдоровка, Стәрлебаш, Бишбүләк районнарында таралган. Кайбер районнарда (мәсәлән, Татарстанның Әлмәт, Баулы, Лениногорск, Башкортстанның Кушнаренко, Бәләбәй, Әлшәй, Благовар, Чишмә, Стәрлетамак, Аургазы, Кырмыскалы, Мәләвез, Күмертау районнарында) ул мишәр сөйләшләре белән аралашкан.

Минзәлә сөйләшен өйрәнүнең 130 еллык бай тарихы бар. Ул төрле галимнәр тарафыннан (А. Г. Бессонов, Л. Җ. Җәләй, А. А. Юлдашев, Л. Т. Мәхмүтова, Д. Б. Рамазанова, Ф. С. Баязитова, Җ. Алмаз, Ә. Ш. Әфләтунов һ. б.) һәм төрле методлар белән тикшерелгән. Сөйләш турында тулы тасвирлама бу юллар авторының «Татары Восточного Закамья: их распространение, формирование говора» дигән хезмәтендә (Казан, 2000) бирелгән.

Әлеге сөйләшне тикшерүче галимнәр аның әдәби телгә якын булуын ассызыклый. Бу фикерләр татар теленең диалектологик атласы материаллары белән дә раслана.

Зур территориягә таралган минзәлә сөйләше төп үзенчәлекләре ягыннан, нигездә, бер төсле. Шул ук вакытта күрше сөйләшләр белән үзара тәэсир итешү, төрле тарихи-мәдәни вакыйгалар кичерү, аерым чорларда төрле административ үзәкләргә карау, күчеп килүчеләрнең төрле яклардан булуы яки аерым төбәктә үзгә сөйләш һәм диалект вәкилләренең өстенлек алуы кебек сәбәпләр аркасында аңарда төрле урынчылыклар да барлыкка килгән.

*Төп урынчылык* Татарстанның Кама аръягы көнчыгышын һәм Башкортстанның Ык бассейны көнчыгышындагы тар гына полосаны үз эченә ала. Бу урынчылыкта минзәлә сөйләшенә хас төп билгеләр эзлекле рәвештә күзәтелә (*изән* – идән, *boday* – бозау, *белмәй* – белми, *ниндәй* – нинди һ. б.).

*Әгерҗе* урынчылыгы хәзерге Әгерҗе районында һәм Удмуртиядәге чиктәш районнарда таралган. Бу төбәккә XVI–XVII гасырларда нократ (элеккечә: Карийно < Карино) татарлары, ә XVIII гасырда Казан арты татарлары күчеп утырганнар. Төбәкнең төньягында алдынгы укыту ысуллары белән танылган Иж-Бубый мәдрәсәсе, көчле мәдәни учак буларак, әгерҗе урынчылыгының формалашуында зур роль уйнаган. Нәтиҗәдә бу урынчылыкта иске татар язма әдәби теленә хас үзенчәлекләр күбрәк сакланган (*бармаққа*/*килмәккә*, *бармаға*/*килмәгә*, *бармақлы*/*килмәкле* формалары һ. б.), ә минзәлә сөйләше үзенчәлекләре көчсезләнгән. Әлеге иске язма әдәби тел формалары Актаныш төбәгендә дә очрый.

*Яңавыл* урынчылыгы Башкортстанның Яңавыл, өлешчә Краснокама, Тәтешле районнарында, күрше Пермь краеның Куеда районында таралган. Пермь сөйләшенә хас күренешләрнең табылуы бу урынчылыкка үзенчәлекле яңгыраш бирә.

*Бәләбәй* урынчылыгы Башкортстанның көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнарында таралган. Күчеп килүчеләр белән җирле төрки халыкларның тыгыз аралашуы нәтиҗәсендә минзәлә сөйләшенә хас төп үзенчәлекләрнең системалылыгы берни-

кадәр дәрәҗәдә югалып, бу урынчылыкта кайбер аерымлыклар барлыкка килгән.

Әлбәттә, моның тарихи җирлеге бар. Хәзерге Татарстанның Кама аръягы өлешендә элек-электән безнең бабаларыбыз яшәгән. Әлеге төбәкләр, шул исәптән Актаныш җирлеге дә Идел буе дәүләтләре (Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Казан приказы, Казан губернасы) составына кергән булган. Бу фикерләр танылган археологларыбызның, тарихчыларыбызның (Р. Г. Фәхретдинов, Е. И. Чернышев, В. П. Смирнов) тикшеренүләрендә ачыкланган һәм объектив расланган. Башкорт тарихчысы һәм этнографы Р. Г. Кузеев, көньяк-көнбатыш Башкортстан җирләре, Рус дәүләтенә кушылганчы күп еллар элек үк, болгарлар тарафыннан колонизацияләнгән булган, дип яза (1957). Ык бассейнында болгарларның угор халыклары белән катнашып яшәгәнлеге турында (Е. П. Казаков, М. И. Әхмәтҗанов, Д. М. Исхаков) мәгълүматлар бар. Болгар дәүләте җимерелгәч, аның составындагы *кече, кәлчер, юмран, бүләр, йәнәй, юрми, гәйнә-тархан* һ. б. күп кенә кабиләләр төньякка һәм көнчыгышка таба күчеп утыралар. Аларның дәвамчылары булган халыкның бүгенге көндәге сөйләшләре татар теленә бик якын.

Казан ханлыгы җимерелгәч, Идел–Агыйдел халыкларының бердәйлеген ныгыта торган вакыйгалар тагын да арта. Идел буендагы татарлар бик күпләп Урал якларына агыла башлыйлар.

Актаныш төбәгендәге Идел буеннан, Казан артыннан күчеп килгән татарлар нигез салган авылларда булырга туры килде. Ул авылларның тарихы архив документларында чагыла, топонимик материаллар, шәҗәрәләрдәге фактлар белән раслана һәм халык хәтерендәге риваятьләрдә саклана. Актаныш төбәгенә хәзерге Әгерҗе районы аша нократ татарларының күчеп килүләре турында да мәгълүматлар бар. 1522–1523 елларда Казан ханы Адназы Сахиб-Гәрәй Ык бассейны Ирәкте волостеннан Шигахмет һәм аның иптәшләренә тарханлык грамотасы тапшырган[1]. Сарали авылыннан Toктамышко һәм тагын берничә кешегә 1595 (?) елда Каманың бу ягы һәм аръягындагы елгалар буендагы җирләр бирелгән. Ә XVIII гасыр азагында исә хәзерге Азнакай, Мөс-

[1] Архив документларындагы исемнәр чыганактагыча рус телендә бирелә.

лим, Сарман, Минзәлә районнарындагы авылларның күпчелеге үзләрен әлеге Токтамышко һәм аның иптәшләренең оныклары, варислары итеп санаганлыклары ачыклана (РГАДА, 1324 фонд, I тасвирлама, 1249 саклау берәмлеге, 55–56 битләр).

Актаныш төбәге авыллары турындагы архив мәгълүматлары моның белән генә чикләнми әле. Мәсәлән, элекке Уфа өязе Казан даругасыннан (хәзерге Актаныш районы) Тайламас (< Тыңламас) авылы татары Кутлумет Кутлушев дигән кеше, Ибраһим хан (1467–1478 елларда хакимлек иткән) биргән грамота нигезендә, тарханлыгым бар иде, дип яза (РГАДА, 1173 ф., 1 тасв., 196 сакл. бер.).

1688 елга карый торган документтан хәзерге Агыйдел елгасының түбән агымында (Уран волосте) татар, мари һәм удмурт авыллары (барысы 50 ләп) булуы ачыклана, аларның 37 се – 1662 елга кадәр, 13 е 1662 елдан соң барлыкка килгән (РГАДА, 1173 ф., 1 тасв., 980 сакл. бер.). 1701 елга караган документ Ирехты волосте Мушуга (хәзерге Мөшеге, Минзәлә районы) авылы татарларының вотчинасында 20 авыл барлыкка килүен раслый. Әлеге авылларны тикшерү барышында, аларның кайберләренең 50–70, хәтта аннан да артык еллар шушы җирләрдә яшәгәнлекләре билгеле була (Мөшеге елгасы хәзерге Актаныш районыннан көньяк-көнбатышта ага). Китерелгән саннар Идел буе халыкларының, аеруча татарларның, безне кызыксындыра торган төбәккә бик интенсив рәвештә күчүен күрсәтә. Архив документларында Мөшеге елгасының югары агымында Симәк (1679 ел) авылы булуы, Талламаз (< Тыңламас) авылы бобыльләренең Казанга да, Уфага да ясак түләп торулары (1691 ел) турында мәгълүматлар бар. Челобитная язучылар бу җирләрнең борынгы заманнардан бирле аларныкы булуын һәм борынгы бабаларыннан калуын кат-кат ассызыклаганнар. Мәсәлән, Талламаз (< Тыңламас) авылыннан Котайко һәм аның иптәшләре 1658 елда оклад ясагына күчерүләрен сорап мөрәҗәгать иткәннәр (РГАДА, 1173 ф., 1 тасв., 476 сакл. бер., 1–7 битләр), һәм аларның үтенече канәгатьләндерелгән.

Алда китерелгән мәгълүматлар Актаныш төбәге татарларының этник тарихы бик борынгы чорларга барып тоташуын

күрсәтә. Аларның сөйләм теленең әдәби телгә якын булуы да тарих белән бәйле. Шунысын да ассызыклап үтик: актанышлылар бүген дә әлеге традицияләргә тугры калып, ана телебезгә аеруча сак мөнәсәбәтләре белән сокландыралар.

Минзәлә сөйләше таралган территориянең аерым төбәкләрендә яшәүче төркемнәрнең сөйләшендә, төрле (тарихи, мәдәни, географик һ. б.) факторлар йогынтысы астында, үзләренә генә хас үзлекләре барлыкка килгән, дидек. Биредә әлеге тел үзенчәлекләрен күрсәтеп китәрбез һәм минзәлә сөйләше белән әдәби тел арасындагы аерымлыкларга тукталырбыз.

* * *

Актаныш төбәгендә минзәлә сөйләшенең төп билгеләре булган *-ай/-әй* кушык авазын (*бармайынчы – әд.* бармыйча, *башлай* – башлый), *з* авазының сакау вариантын (*беләбеd* – беләбез, *сеdнең* – сезнең, *dәңгәр* – зәңгәр) кулланып сөйләшәләр. Бу күренеш, нигездә, өлкәннәр телендә саклана. Урта диалектның күпчелек сөйләшләренә хас булган *-ай/-әй* кушык авазы борынгы татар әдәби телендә даими кулланылган. Фәндә аның татар һәм башкорт телләре өчен уртак күренеш булуы расланган.

Актаныш төбәгендә урта диалектка хас *җ*-ләштерү (*арҗаҡ – арйак* (аръяк), *җул – йул* (юл), *җаулыҡ – йаулык* (яулык) үзен көчле сиздерә. Бу үзенчәлек Актаныш төбәге сөйләү телен *җ* авазы бөтенләй әйтелмәгән башкорт теленнән катгый аерып тора. Шул ук вакытта, әдәби телдәге *җ* урынына *з* куллану очраклары да күзәтелә: *зиде – җиде, залварам – җалварам* (ялварам), *зеп – җеп, зегерме – җегерме* (егерме) һ. б. Мондый күренеш тагын лаеш, мамадыш, керәшен сөйләшләрендә очрый.

Аерым сүзләрдә генә очрый торган кайбер аваз тәңгәллекләре Актаныш төбәге сөйләү теленә берникадәр үзенчәлек өсти. Сузык авазларда бу күчеш түбәндәгечә чагыла:

э~и: *эпи* – ипи, *эми* – ими;

ы~у: *была* – була;

ә~е: *бәрхәт* – бәрхет, *кәлҗәмә – диал.* кәлҗемә;

ә~и: *әпекәй* – ипекәй, *кәтмәннәү* – йомшарту (бәрәңге бакчасын), *диал.* китмәннәү;

и~э: *мәчит* – мәчет;

и~ә: *җийәү* – җәйәү (җәяү), *пирештә* – фәрештә;

у~а: *уралышу* – аралашу;

о~у: *сом* – сум (акча), *җоқа* – йука (юка);

у~о: *сурау* – сорау;

ү~ө: *җүгерү* – йөгерү.

Дифтонгларда: *үрәтү* – өйрәтү, *сүрәү* – сөйрәү, *сүләү/сөләү/сөйләү* – сөйләү.

Тартыкларның берсе урынына икенчесен куллану түбәндәгечә:

м~б: *мәндә* – бәндә;

н~м: *барнақ* – бармак, *шауқын* – шаукым, *берәнтекләп* – бердәмтекләп;

х~к: *тырахтыр* – трактор; *пылсухна* – полусукно;

с~ч: *посмақ* – почмак; *сыға* – чыга, *бетергәс* – бетергәч;

г~к: *гөпшә* – көпшә (үлән исеме);

ч~с: *читса* – ситсы;

р~н: *үткер* – үткен;

й~ж: *йер* – җир, *йетә* – җитә;

з~җ: *кәзә* – кәҗә;

ш~н: *тәбәшәк* – тәбәнәк.

Сүз башында яисә уртасында *л, к, и* авазлары өстәлергә мөмкин: *тәгерләү* – тәгәрәү, *аклан* – алан, *ичереп* – череп һ. б. Традицион сөйләштә сүз башында *һ* авазы даими рәвештә төшеп кала: *аман* – һаман, *ушы китү* – һушы китү, *аwа* – һава, *өнәрчелек* – һөнәрчелек, *ичбер* – һичбер, *әрбер* – һәрбер, *зинне* – зиһенне, *Майрә* – Маһирә, *Тайра* – Таһира һ. б.

Сүзләрне нечкәртү очраклары бар. Алар сөйләү теленә күпмедер дәрәҗәдә йомшаклык өстиләр: *мөрҗә* – морҗа, *идә* – иза (чигү), *миңә* – миңа, *әңгерә* – аңгыра, *әрзән* – арзан, *әрмийә* – армия, *беләлмәйем* – белә алмыйм һ. б.

Кайбер алынма сүзләр, җирле сөйләш үзенчәлекләренә яраклашып, түбәндәгечә кулланылалар: *ағус* – август, *пиннек* – веник, *кырандил* – крендель, *җилән//зилән* – делянка, *кандул/кәндүл* – камзул һ. б.

* * *

Минзәлә сөйләшенә хас морфологик үзенчәлекләргә күзәтү ясыйк.

Биредә сүз төркемнәре һәм аларга хас төп грамматик категорияләр (зат, сан, тартым һ. б.) әдәби телдәгеләрдән күпкә аерылмый. Сөйләшнең төп үзенчәлеге шунда: *-кай/-кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы абстракт мәгънәле яки җансыз әйберләрне белдерә торган исемнәргә, сыйфатларга һәм, хәтта ымлыкларга да ялганып килә: *Абзыкай* суғыштан қайтмады. *Аллақай* таdалық бирсен. *Чабатақайны* баdардан алыш ийе. *Әпекәйне* мич төбөндә пешерәдер ийек элгәре. Арыш *онқайы* үdенә бертөрлө тәмне бит ул *эпекәй* пешерергә. Қартайғач *кешекәй* берни түгел икән. Чапқан *печәнкәйләр* бар бит, йауса алама инде. *Күлмәққәйләр* бетте, җаулық бетте. *Қартлыққайларны* нәмәшәтәсең?

Тартымлы исемнәрнең һәм исем функциясендәге башка сүз төркемнәренең төшем килеше -*ы*/-*е* кушымчалары белән ясалуы күзәтелә: *үdеме* – үземне, *битләреме* – битләремне, *эштән қалғаныңы* (калганыңны) белсә, бергаҗир эзләп килә торған ийе.

Актаныш төбәгендә *-лар/-ләр* күплек кушымчасының мәгънә төсмере киңрәк: *Ничекләр* килдегез? Бүсер булса бүсер сүрәтләре йасап *чайқатыплар* эчерәләр ийе. Рәсемгә *төшөрөпләр* киттеләр.

Алмашлыкларны куллануга бәйле кайбер аерымлыкларга игътибарыгызны юнәлтик. Мисал өчен, *үз* алмашлыгын *үзе* формасында куллану очрый: *Үзе* җортын үзе қарый. *Үdе* бақчасын да, қыdынықын да утап чыққан. Әдәби телдәге *нәрсә* сорау алмашлыгы урынына Актаныш халкы даими рәвештә *нәмә*/*нәмәкәй* алмашлыгын куллана: Кемнең *нәмәгә* көчө йетә, шуны әdерләй туйға. *Кайбер* алмашлыгы *қай* рәвешендә әйтелергә мөмкин (Тал балын қай (кайбер) кеше суwыртыб ала). *Қайсы* алмашлыгы, әдәби телдән аермалы буларак, икеләтелгән тартым кушымчасы ала: *Қайсысы* бидрә белән апменеп сибә суны.

*Бу* алмашлыгын *бул* дип әйтү очрагы теркәлгән: *Бул* төштә дә болын булған.

Әдәби телдәге *әллә нәрсә* алмашлыгы *әлләмә/әлләнәмә/әлнмә/әлнәмәкәй* вариантларында еш кулланыла: *Әлләмә* әйтте,

ишетәлмәйенче қалдым. *Әлнәмәкәй* эшләсәң дә булмай икән булмағачтын.

Актаныш төбәге сөйләү теленең фигыль формаларына бай булуы игътибарны җәлеп итә. Әдәби тел белән чагыштырганда, аларны куллануда берникадәр аерымлыклар бар.

Хәл фигыльләрнең *-гачтын/-гәчтен* (*уқып чыққачтын*, *тырышып эшләгәчтен* һ. б.), *-майынчы/-мәйенче* (*белмәйенче* йөрмә, су *сипмәйенче* (сипмичә) бер нәмә дә үсмәй), *-мас борын* (*барып җитмәс борын* – барып җиткәнче) кебек формалары актив кулланыла.

Теләк фигыльнең *-айық/-әйек, -айым/-әйем* (*әд. -ыйк/-ик, -ыйм/-им*) кушымчалары белән ясалуы үзенчәлекле: Тифрәк *бетерәйек* урақны, дип, җал итмәйенче эшләдек. Сезгә қайнар эпекәй *кисәйем* әле, мөсафир қунақларға.

Әдәби телдәгечә, *-у/-ү* кушымчалары белән ясалганнарыннан тыш, исем фигыльнең *-ыш/-еш* формасы еш кулланыла. Мәсәлән: Абитқа монда *қайтыш*. Таллыққа қачырып *өйөш* ийе ул печәнне. Элек кандуллар (камзул) *кийеш* ийе. Шундый ук мәгънә төсмерләре татар теленең тау ягы сөйләшләрендә дә чагылыш таба.

*-Мак/-мәк* формасы, минзәлә сөйләшенә хас булганча, сорау алмашлыклары белән үзенчәлекле төзелмә оештыра һәм җөмләгә хис-кичерешле мәгънә төсмере бирә: Ничег итеп *җатламаққа кирәк* боларны. Җитмеш мең ақчаны *қайан алмақ кирәк*. Анда зиләк йуқтыр, *қайан болмақ кирәк*. Бу борынгы форма иске татар язма әдәби әсәрләрендә еш очрый.

*-Малы/-мәле* формасы тау ягы сөйләшләрендә аеруча актив, ул минзәлә сөйләшенең барлык урынчылыкларында да күзәтелә һәм эшне башкарып булуны, *түгел* сүзе белән килгәндә исә башкарып булмауны белдерә: Машиналарны шул урынға *қыймалы*. Эшләгәндә *йәшәмәле* әле. Қарлыған җийып *бетермәле түгел* ийе әрәмәлектә.

Актаныш төбәге сөйләү телендә башка сөйләшләрдә сирәк кулланыла торган бәйлекләр очрый. Мәсәлән: *Ул табатын* (шунда таба) бер бабай тора. *Сиксәнгә табатындыр* ул, оло ул. Кил *бу таба* (монда таба).

Кайбер бәйлекләрнең кулланылышында кызыклы үзенчәлекләр бар: *күрә* бәйлек сүзе *өчен* бәйлеге урынына кулланыла: Қарама қайырысыннан чабата җасайлар, су *үтмәскә күрә* (үтмәсен өчен) төбөнә қайын тузы салалар.

*Өчөңгә, сымаҡ/сыман, күүк/кебек* бәйлекләре дә әдәби телдәге тәңгәлләреннән берникадәр аерылалар: Тел *белмәгән өчөңгә* йазып сөйләшә икән. *Уҡытҡан өчөңгә* түләмәгәннәр. *Шуның күүк* қура җиләкләре буладыр ыйы анда. Тормошлар *хәдерге сымаҡ* түгел ийе. *Илдар сыман* тийә исеме.

*Исә* теркәгече билгеле үткән заман хикәя фигыльгә кушылып килә һәм шартны белдерә: Ақчаң *булдисә* (булса) аласың. Ашағыd, *йараттығыd исә* (яратсагыз). Доға уқып алырға диләр суны беренче алғанда, *шикләнмәдисәң* (шикләнмәсәң) су тотмай.

Актаныш төбәгендә *нық, dәхәр* (*әд.* бик) кебек көчәйткеч кисәкчәләр, *бәй* гаҗәпләнү ымлыгы һ. б. кулланыла: *Бәй*, сеd әле шулай зур қунақмыни?

* * *

Лексик үзенчәлекләргә озаклабрак тукталырбыз. Гәрчә минзәлә сөйләшенең бай лексикасы фәнгә инде күптән кертелгән булса да, Актаныш төбәгенә хас матур да, тикшеренүләр өчен әһәмиятле дә булган яңа сүзләр әле дә табыла тора. Әлбәттә, аларның барысын да бу язмада китереп булмас, шуңа күрә туганлык, аш-су, кием-салым, үсемлек атамалары һ. б. белән бәйле үзенчәлекләргә киңрәк тукталып, әлеге төбәккә хас диалекталь сүзләрнең характеры һәм төркемчәләре турында гомуми мәгълүмат бирү белән чикләнербез. Безнең тарафтан язып алынган сүзләр киләчәктә төзеләчәк диалектологик сүзлекләрдә яисә һәртөрле тикшеренүләрдә, һичшиксез, чагылыш табар.

**Актаныш төбәгенә хас туганлык атамалары белән бәйле үзенчәлекләр.** Әлеге лексик төркемгә мөрәҗәгать итүебез очраклы түгел. Билгеле булганча, туганлык-кардәшлекне белдерә торган сүзләр телгә хас сүзлек составының иң борынгы катламын тәшкил итәләр һәм тарихи юнәлештә алып барыла торган тикшеренүләрдә ышанычлы чыганак булып торалар.

Бик борынгы чорларда барлыкка килгән һәм тотрыклылык күрсәтеп, безнең көннәргә кадәр сакланып килгән туганлык атамалары 2 төркемгә бүлеп карала.

**Кан туганлыкны белдерә торган атамалар** үзләренең әйтелешләре белән әдәби телдәгедән беркадәр аерылалар: *әтә (ата)*, *инә (әни)*. *Әткәй* һәм *әңкәй/инәкәй* – хөрмәтләп, яратып эндәшү формалары. *Әни, ана* атамаларының нигезендә яткан *ән/ин* тамыры бөтен Идел – Урал – Себер регионындагы халыклар өчен уртак. Бу исә аның бик борынгы чорларда барлыкка килүен күрсәтә һәм матриархатның беренчел булуы турында фаразларга мөмкинлек бирә. Ата сүзе чагыштырмача соңрак барлыкка килгән булырга мөмкин.

*Абзый-абый* – әнисенең яки әтисенең энесен белдерә торган туганлык атамасы, *абзыкай* – аларга мөрәҗәгать итү формасы; *түтәй/түткәй/түткей/апа* – бертуган апа, әнисенең яки әтисенең сеңлесе. Бу туганнар берничәшәр дә булырга мөмкин, ул вакытта аларны аеру өчен төрле сыйфатлау сүзләре кулланалар: *алмапай* < *алма* + *апай*, *чибәрттәй* < *чибәр* + *түтәй*, *актүтәй, моллаттәй* < *мулла* + *түтәй* һ. б.; *абз(d)ыкай, бәләкәбdыкай* < *бәләкәй* + *абdыкай, бәләкәбкай* < *бәләкәй* + *абыкай, чибәр абdый, моллабdый* һ. б. ш. *Түтәй, апа* сүзләре үзеннән олырак булган чит кешеләргә карата да кулланыла. Әлеге атамаларның мәгънәләре киң булу элек аларның үзеннән олырак булган барлык хатын-кызлар яки ирләр өчен уртак атама булганлыгын күрсәтә, аларның борынгы ырулык чорында ук (ягъни кабилә яки нәсел-ыруга керә торган затлар әле индивидуальләшмәгән чорларда) барлыкка килүен аңлата.

Актаныш төбәгенә дә *эне, сеңел* атамалары белән беррәттән, аларга эндәшү өчен уртак *апайым (-ым, -ың, -ы)* сүзен куллану хас.

Төрки телләрдә киң таралган *түтәй/түти* атамасын *тута* атамасы белән бергә дә карыйлар. Үзебезнең тикшеренүләрдән чыгып, *түтәй/тәтәй* атамасының борынгы санскрит теленнән үк билгеле булуын ассызыклап үтәсе килә. *Абый, түтәй* атамалары әнидән, *каената* һәм *каенанадан* олырак туганнарны белдерү өчен дә кулланылырга мөмкин, тик бу вакытта алар ти-

ешле ачыклау сүзләре белән әйтеләләр: *дур түтәй, ак түтәй, шәкерт абай, мулләттәй* һ. б.

Урал алды төбәгенә хас булганча, Актаныш төбәгендә дә атаның олырак туганнарын һәм ананың олырак туганнарын аерып атау күзәтелә. Җәмгыятьнең борынгы чорында алар бер үк атама белән белдерелсәләр, вакытлар үтү белән бу ике төркемне – этинең абыйларын, апаларын һәм әнинең абыйларын, апаларын индивидуальләштерү хаҗәте туган. Мондый бүленеш төрле төрки халыкларда төрле чаралар ярдәмендә белдерелә.

Актанышлылар, мәсәлән, әни ягыннан булган туганнарны *җырак/йырак* сүзе белән аерып атыйлар: *җыраг әби, җыраг абдай, җырак бабай*. Мондый күренеш Татарстанда, Удмуртиядә, Уралда, Оренбург өлкәсендә һәм Себердә таралган татар сөйләшләренә хас. Агыйдел–Ык бассейннарындагы сөйләшләрдә этинең абыйсын *дур әтәй/әткәй* дип, ә аның хатынын *дур инәй* дип атыйлар. Шул ук вакытта этинең апасын *дур инәй*, ә аның ирен *дур әтәй/әткәй* диләр. Димәк, материаллардан күренгәнчә, өйләнешү нәтиҗәсендә барлыкка килгән туганлык һәм кан туганлык терминологиясе, Көнчыгыш Татарстан һәм Көнбатыш Башкортстандагы кебек, Актаныш төбәгендә дә ахырынача аерылып җитмәгән әле. Фәндә бу ике туганлыкны чагыштырмача соңрак аера башлаганнар дип санала. Җизнәнең балдызга өйләнүе һәм җиңгәнең каенегә кияүгә бирелүе дә әлеге ике туганлык «аерылмаган» чорлардан сакланып калган гадәт калдыгы. Бу – без сүз алып бара торган төбәктә борынгылык, тарихилыкның чагылышы.

Әдәби телдәге *бабай, әби* атамаларына туры килгән *картәти, картәни* Актаныш төбәгендә бик сирәк кулланыла. «Татар халык сөйләшләре атласы» күрсәтүенчә, әлеге атамаларның таралышы Ык елгасының һәм Түбән Агыйделнең көнчыгыш бассейннарыннан башлана. Бу җирлектән көнчыгышка таба урнашкан өлкәләрдә *әби, бабай* атамалары эти-әнинең абыйсын һәм апасын белдерәләр. Ык һәм Түбән Агыйдел елгаларының көнбатышында исә *әби, бабай* атамаларын әдәби телдәгечә куллану өстенлек итә.

*Әби-бабай* һәм *картәни-картәти* атамаларының бер-берсен алыштырулары Актаныш төбәгендә дә очрый. Әлеге күренеш,

бөтен төрки халыклардагы кебек, буыннарның күчеш закончалыгы, ягъни әби-бабайларның, *картәни-картатай*ларның бер буынга – *бабалар* буынына керүләре белән аңлатыла. Мисал өчен, әтисе, аның энеләре, сөйләүченең бертуган абыйсы белән бер буын – *аталар* буыны булып санала, ә әтисенең абыйсы, сөйләүченең бабасы, бабасының бертуган энеләре *бабайлар* буынына керә. Шуңа күрә, бабайны һәм әтинең абыйсын белдерә торган атамалар бер-берсен алмаштырып килә алалар. Хатын-кызларның буын күчеш закончалыгы да шулай ук.

Шунысы кызык, татар телендә дәү әни (әти), зур әни (әти), карт әни (әти), оло инә (әтә) атамаларының ясалу калыбы төрки телләрдән тыш, һинд-европа һ. б. телләрдә дә яшәп килә икән: *әти → зур + әти (бабай), әни → зур + әни (әби)* һ. б.

Кан туганлыкны белдерә торган атамалардан Актаныш төбәгенә хас *баш бала* (беренче бала), *бәбәй*, *туган балалары* (туганнан туган), *әби-апай* (әнисенең апасы) һ. б. ны күрсәтеп үтәргә кирәк.

Туганлык, кардәшлекне белдерә торган *нәсел, туган, қәрендәш, туған-тумача, ағайны* (< *ага-эне*) кебек барлык татар халкына хас сүзләр аеруча актив кулланыла.

Актаныш төбәгендә рус телендәге *правнук* төшенчәсе *оныкчык* атамасы белән белдерелә (бу күренеш соңгы елларда әдәби телебездә дә очрый башлады). Мәсәлән: *уналты оныҡ, биш оныҡчыҡ бар минем*. Ягъни, ике буынга караган туганнар, бөтен төрки халыклардан аермалы буларак, кушымча ярдәмендә генә аерып атала.

Билгеле булганча, туган тиешле кешеләрне үзара аерып атау өчен кушымчалар куллану, һинд-европа телләре белән чагыштырганда, төрки телләрдә сирәгрәк очрый. Мәсәлән, татар теленең Киров өлкәсендә һәм Удмуртиядә таралган нократ сөйләшендә иренең олы һәм кече кыз туганнарын аеру өчен *-ч* иркәләүкечерәйтү кушымчасын куллану күзәтелә: *бикәм* (хатын-кыз өчен иренең апасы), *бикәчем* (хатын-кыз өчен иренең сеңлесе; каенсеңел), *бабач/бабача* (бабайның энесе). Бу очракта Актаныш төбәге сөйләше белән борынгылыкны аеруча нык саклап килә торган нократ сөйләше арасында уртаклык саклануы сизелеп тора.

**Никах туганлыгы атамалары** дип йөртелгән төркемгә никахлашу нәтиҗәсендә барлыкка килгән туганнарны белдерә торган сүзләр керә. Махсус тикшеренүләр әлеге төркем атамаларының төрле юллар һәм төрле чаралар ярдәмендә формалашкан булуын күрсәтте. Туганнарга эндәшүнең бу формалары чагыштырмача соңрак ясалган, һәм аларның нигезендә кан туганлык атамалары ята: *әңкәй* – әнисенә һәм каенанасына*, әткәй* – каенатасына*, абзыкай (*түткәй*)* – иренең яки каенана-каенатасының абыйларына (апаларына) эндәшү сүзе һ. б.

Никах туганлыгы атамалары формалашуда социаль атамалар зур роль уйнаган. Бер төркем никах туганлыгы атамалары *бий* сүзенә нигезләнеп ясалган: *бийем* (< бий + -ем) – иренең әнисе, *бийата* (< бий + ата) – иренең әтисе, *бийагай* (< бий + агай) – иренең абыйсы. Мондый күренеш башкорт, чуваш, өлешчә казакъ, якут телләренә дә хас. *Бий* сүзе мең еллар элек язылган төрки язма ядкярләрдә дә очрый һәм ул *бәк, кенәз, хуҗа, ир* мәгънәләрен белдергән. Билгеле булганча, кыз кеше яңа гаиләгә килен булып төшкәч, андагы өлкәннәргә баш иеп, түбәнчелек, итәгатьлелек саклап яшәргә тиеш булган. Атамаларның мәгънәләре дә шуны күрсәтә: *бием*, ягъни хуҗам, бәгем*, биатай* – хуҗа ата, бәк ата, *бийана* – хуҗа ана, бәк ана һ. б. Вакытлар үткән саен бу сүзләрнең чын мәгънәсе югала, томанлана төшкән. Мәсәлән, еш кулланыла торган *бийемем* сүзендә беренче *-ем* кушымчасының функциясе онытылганлыктан, каенанам мәгънәсен белдерү өчен тагын бер *-ем* кушымчасы өстәлгән: *бийем* + *ем*. Килен кеше иренең әти-әнисенә *әткәй* (әти + иркәләүне белдерә торган *-кәй* кушымчасы), *әңкәй* (< әни + -кәй) дип эндәшергә тиеш. Ир-ат өчен исә хатынының әти-әниләре *бабай, әби* була.

Иренең яки хатынының бертуган абыйларына, апаларына карата да хөрмәт итү, буйсынуны чагылдырган атамалар барлыкка килгән (*туташ/түтәй/түткей*, *абзыкай/агай)*. Чит кешеләр сөйләмендә әлеге атамалар болай яңгырый: *тутасы, абыйы/агайы*. *Тута* сүзе борынгы *тоота* сүзенә барып тоташа. XVII–XVIII йөзләргә караган борынгы язма чыганакларда югары катлам вәкилләреннән булган хатын-кызларга карата *тутай* сүзе кулланылган.

Килен кеше алда күрсәтелгән олылау атамаларын кулланганда, аларга иркәләү кушымчалары (мәсәлән, *тутақай, туташ, абдықай*) яисә матур эпитетлар өстәргә тиеш булган. Гадәттә, каенананың апаларына яки сеңелләренә *ақ туташ, моллаттәй, молла туташ,* сеңлесенә *иркә туташ* кебек сүзләр белән мөрәҗәгать иткәннәр.

*Абзый* атамасын фәндә *абыз* тамырыннан дип аңлату бар. Ул өлкән, хөрмәтле мәгънәсендә актив кулланыла: *абыз ага* (өлкән абый), *абыз тумачи* (өлкән туган) һ. б. *Абыз* тамырын Коръәнне яттан белүче мәгънәсендәге хафиз сүзеннән килә дип санийлар. Татарларда киң таралган *абыстай* (абыз + тутай) сүзенең беренче өлешендә әлеге мәгънә бик ачык чагыла, ә *тутай* өлешендә югары катлам вәкиле дигән мәгънә тоемлана.

Иренең яки хатынының кече туганнарын билгеләү буенча актанышлыларда татар халкына хас атамалар кулланыла: *балдыз* (борынгы төрки телдә *балдыр* яшь, иртәнге мәгънәләрендә йөргән)*, каенсеңел, кайнеш, бажҫа, килендәш* һ. б. Биредә татар теленең минзәлә, нократ, норлат һәм барлык керәшен сөйләшләренә хас булган *җанағай* атамасы кулланыла. Ул тагын чулым төрекләре телендә бар, ә башка төрки телләрдә бик сирәк очрый. Борынгы төрки телдә принц мәгънәсендә йөргән *бикәч* сүзе актив кулланыла.

Мисаллардан күренгәнчә, Актаныш төбәгенә хас туганлык атамалары, нигездә, әдәби телдәгечә, әмма, шул ук вакытта, кайбер үзенчәлекле күренешләр дә бар. Инде актанышлылар сөйләменең башка тармакларына караган лексик үзенчәлекләренә, ягъни аларга гына хас булган диалекталь сүзләргә игътибар итик.

**Тормыш-көнкүрешне чагылдырган атамалар.** Билгеле булганча, диалекталь сүзләр халыкның тормыш-көнкүрешен, нәрсә җитештерүен, ничек дөнья көтүен һәм башка бик күп өлкәдәге үзенчәлекләрне чагылдырулары белән әһәмиятле. Мәсәлән: *ҫушма* 1) юан агачның эчен чокып-юнып ясалган, 2–3 центнер ашлык сыешлы савыт; 2) чишмәнең тамагына су тирәнәйсен һәм чиста булып тонып торсын өчен куела торган зур агач кисмәк. *Тырыс* (кырга су алып бару өчен каен тузыннан эшлән-

гән чиләк, туз чиләк), *зәрәкә* (зур көймә), *сәлмән кирпече* (саман кирпече), *кәнсә* (< канцелярия) *бурычы* (һәртөрле түләүләр), *милек* (йорт урыны), *сике арасы* (киндер сугу станы).

Актанышлылар сөйләменә хас булган йорт-җир, хуҗалык белән бәйле сүзләрдә метафорик мәгънә күчешләре, үзенчәлекле номинация принциплары чагылыш таба. Мәсәлән, *тастымал* – сөлге (бу сүз шушы мәгънәдә Урал төбәге татар сөйләшләрендә таралган), *җомро* – чынаяк чокыры, *җамыйаķ* (*фарсы* җам – пыяла + *төрки* айаķ – савыт) – зур булмаган савыт, *эткеч* – юшкәне этеп яба торган калак, *өй әйләндермәсе* – стена буйлап элеп чыккан кашага.

Сөйләшкә яраклаштырылган рус алынмалары да очрый: *бидрә* – чиләк, *ләwешкә* – юка тактадан (гадәттә, туздан) ясалган капкачлы чиләк; әбәт чиләге һ. б.

Халыкның бай рухи тормышын чагылдырган күркәм йолалары, гореф-гадәтләре белән танышу безнең өчен аеруча кызыклы булды, яңа диалекталь сүзләр бирде: *мәйдан* – сабантуй, *тәсбих* – теләк яисә ырым сүзләре, *өшкөрөк* – өшкерү (*аның өшкөрөгө йаķшы дип киләләр*).

Татар халкының гүзәллеккә омтылышы, нәфислекне яратуы **бизәнү әйберләрен белдерә торган атамалар**да ачык чагылган. Бу якларда бизәнү әйберләре үзенчәлекле һәм төрле-төрле: *ķалпаķ/ķалфаķ, энҗеле ķалпаķ, бәләкәй ķалпаķ, тәңкәле беләзек, алтын зүгертелгән беләзек, ишмә беләзек, ķулбау мәрҗәннән* һ. б., *җөдөк / зөзөк / ташлы* (кашлы) *җөзөк, тәңкәле зөзөк, алтын зөзөк* һ. б.

Хатын-кызлар өчен аеруча *чулпы*ларның әһәмияте зур булган, аның кашлысы да, такта кебек эшләнгәне дә, көянтәлесе дә яратып кулланылган. Суга барганда чулпыларның чылтыр-чылтыр итүен олылар әле яхшы хәтерлидер. Кайбер хатын-кызлар *чәчķап* йөртсә, икенчеләре чәч толымы очына *тәнкә (тәңкә; оло тәңкә)* яки бер-бер артлы тезеп берничә тәнкә (аны *чулпы* дип атау очраклары да бар) такканнар. Тәнкәләр тегеп эшләнгән *дәwәт* дигән бизәнү әйбере дә булган. *Дәwәт*не кыйгач итеп кигәннәр (бу очракта ул хәситәгә туры килә). Шул ук вакытта аны дүртпочмаклы рәвештә дип тасвирлаучылар да бар.

Һәрхәлдә, ул тукыма кисәгеннән аска бөтен тәнкәләр, ә өскә таба 20 лек, 10 лык тәнкәләр тезеп ясалган. Мондый бизәнү әйберсен кунакка барганда кигәннәр.

Актаныш яклары өчен үзенчәлекле бизәнү әйберләреннән *сырға* (*тәңкәләр тедгән чылбыр*), *сөрмә җәләм* (*сөрмә тарта торган, карандаш пурмылы*) һ. б.ны атарга мөмкин.

Татар халкы элек-электән кием-салымга бай булган, аларны урынлы һәм килешле итеп кия белгән һәм күп кенә киемнәрне үзе җитештергән, ягъни, теккән, бәйләгән, чиккән. Моны Актаныш якларындагы кием үрнәкләре һәм аларны белдерә торган атамалар да дәлилли.

**Кием-салым белән бәйле диалекталь атамалар**ның күпчелегенең төрки чыгышлы булуы күзгә ташлана: *сырма* – мамыктан сырылган кыска өс киеме, *чоба* – сүс белән йон жептән яисә җитен сүсеннән сугылган өс киеме, *түштий* – күкрәкчә (*түштийне күлмәг эченнән, күкрәкне каплап кийәдер ийек, җен соҗланмасын дигән булып, имедгәндә җаплап имедәсең*), *кийес җата/ җыйсҗата* – киез итек, *әби итеге* // *к(г)әлүш итек* // *калуш җыйскатасы* – киезката, *җилем итек* – резин итек, *айаҗ саwыты* – аяк киеме, *шәкәртмә* – чабата асты күтәртмәсе, *чөлкә* – оекбаш һ. б. *Кәндүл* – камзул, *кәлүш* – галош кебек алынмалар да очрый.

Үзләренең күптөрлелеге һәм җирле ясалмаларның активлыгы белән Актаныш төбәгендәге **аш-су исемнәре** дә игътибарны җәлеп итә. Төп төшенчәләр, әлбәттә, әдәби телдәгедән әллә ни аерылмый: *аш, итлаш, бәлеш, чәкчәк, җыстыбый, көлчә, сөт өстө, сары май, шурпа, пилмән, тоҗмач, умач, чумар* һ. б. Үз җирлекләренә генә хас диалекталь сүзләр, нигездә, камыр ашлары, шулпалы ашлар һ. б. белән бәйле. Мисал өчен, бу төбәктә *шәнгә (шәңгә)* сүзе бик актив (*Шәңгә дә җасап җуйам, бәрәңге җағып өстөнә).* Шәңгәне ватрушканың Урал төре дип атыйлар.

Актаныш төбәгендә *угыз сөте* ритуаль ашамлыкларның берсе булып санала. Мәсәлән: *Уғыd эремчеген Аллаһы тәғәләгә, аның ыризалығы өчөн җуwадан тәкә пешерәләр ийе, шуңа уғыd эремчеген кисеп-кисеп җамырға тығып пешерә торғаннар ийе. Йортта иң оло кешегә пирwай җаптыра торғаннар ийе уwызны, иң оло кеше йортта бийата бит инде.*

Көндәлек камыр ашларыннан саналган *көлчәне* ипи камырыннан таба зурлыгында итеп пешерәләр: *оло көлчә // эре көлчә, wақ көлчә* (шул ук, тик аны табага берничәне салып пешерәләр): *Эпи салғанда берәр таба пешереб алам әле дип, wақ көлчә пешерә торған ийек. Қазан көлчәсе қазанда майда пешерелә торған қабартма ул.*

Камыр ашларының төрләре бик бай, шулардан *бәлеш, сумса, пилмән* аеруча киң таралган. Затлы камыр ашлары: *чәкчәк, күзикмәк/күдикмәк*. Соңгысы шул ук чәкчәк камырыннан юка гына итеп җәеп, майга салып казанда пешерелә, шуңа аны *қазан ашы* дип тә йөртәләр.

*Кәтеркәй* – юка төче күмәч: *Қашықлап он бирерләр ийе, кәтеркәй қатырып шул арыш ононнан, шулай итеп үстердек балаларны.*

*Тәкә* – бөккән, аның бер башына камырын ике мөгезгә охшашлы итеп бөреп куялар *(Бәрәңге тәкәләре сала торған ийек мичкә. Орлоқ тәкәсе, қабақ тәкәсе пешерәдер ийе инәй).*

*Төплөкәй* – өстенә төйгән киндер орлыгы җәелгән камыр ашы: *Киндер орлоғын төйәләр, иләйләр, онон қысып сығалар да, барнақ башы чақлы чәкчәк була, аны сөткә туғыйлар да қашық белән җәйәләр қамыр өстөнә, шул төплөкәй була, аның тәмнелекләрен күрсәң син! Төплөкәйне эремчек белән дә пешерәләсен.*

*Тод пирүге*: *Йуқа ғына итеп җәйгән қамырны, өстөнә тод сибеп урталай бөкләп пешерәсең, балаларға алдап, шайартып пешерәсең анысын.*

*Кәлҗәмә* – күздән алынмыйча калып, өшегән бәрәңгедән пешерелгән күмәч, өшемкә.

*Шишәрә* – төче камыр ашы: *Сарықлар күп бәрәннәсен дип, төчөгә пешереп, балаларға ашаталар, шишәрәне кырандил да диләр аны.*

Кош-кортка болгатып ясаган азыкны *туғым*, аш ашауны *аш эчү*, тутырган тавыкны *таwық тутырмасы*, аш бүлүне *аш төшөрү* дип сөйләү әлеге өлкәгә хас үзенчәлекләр.

*Ачы //күwәс ачысы* (камыр башы), *тәбикмәк* (белен), *әнәләү* (ипине әвәләү), *бәчмәчә* (ашка төче камырны рож-

ки кебек итеп ваклап салып пешерелгән азык) һ. б. диалектальь сүзләр Актаныш төбәге сөйләмен баеталар һәм фән өчен кызыклы итәләр.

**Кеше әгъзаларын атый торган сүзләр** телнең сүзлек составында иң борынгы катламны тәшкил итәләр, аларның зур күпчелеге төрки, тунгус-маньчжур, монгол телләре белән уртак. Димәк, әгъза атамалары берничә мең еллар элек, күрсәтелгән телләрдә сөйләшүче халыклар кавемнәргә аерылганчы барлыкка килгәннәр булып чыга. *Аяк, баш, маңгай, буй, кул, җилкә* һ. б. сүзләр шундыйлардан.

Тормыш-көнкүреш үсә һәм үзгәрә барган саен әгъзаларның төрле өлешләрен аерып атау мохтаҗлыгы туган, аларның функцияләре арткан.

Актаныш төбәгендәге әгъза атамалары, нигездә, әдәби телдәге атамалардан аерылмый диярлек. Шулай да кайбер үзенчәлекләр очрый. Мәсәлән, әдәби телдәге «тубык сөяге» мәгънәсендә актанышлылар тагын *бәкәл, ор, орчоқ сөйәге, чәкән, чәпи* сүзләрен дә куллана. Тубык сөягенең диалекталь синонимнары саны егермедән артып китә, аларның кайберләре башка сөйләшләрдә аякның башка өлешләрен дә белдерергә мөмкиннәр, мәсәлән, *бәкәл* сыйракның нечкә җирен белдерсә, *тубық* сүзе тез мәгънәсендә актив кулланыла. Актаныш төбәгендә тубык сөяген белдергән *чәкән* сүзе Иске Әгъбәз авылында «сыйрак сөяге» мәгънәсендә йөри.

Әгъза атамалары төркеменә керә торган диалектизмнардан тагын *қорсақ ачу – әд.* тамак ачу, *қан чире* – кар астында кышлаган игеннән әзерләнгән ризык ашагач була торган авыру, *әпә* – телсез (*Бийанам унөч йыл йатты, ике йылын әпә булды*), *саңгырау* – чукрак, *этенеп сөйләү* – тотлыгу һ. б. ш. ларны күрсәтергә мөмкин.

Кешене төрле яклап сыйфатлый, аның физик һәм рухи халәтен, эчке дөньясын тасвирлый торган лексика игътибарга лаек: *матур, чибәр, ақыллы, булдыклы, оста, тырыш, илтимаслы, сөйкемле, дийенне/дӣнне* – зиһенле, *дирәк* – зирәк, *җүнчел* – булдыклы, тапкыр *(Алар нәселләре беләр җүнчел, болар җүнчел түгел); шәпле* – көчле, егәрле *(Бәләкәй генә булсам да шәплемен);*

*алҗану* – бик нык бетеренү, хәлсезләнү, алҗу *(Ачлық җылны алҗанып, бүлнискә салғаннар аның әтәсен); әсир итү* – исне китәрү, *җараулы* – яхшы һ. б.

Актаныш төбәге өч зур су юлы (Чулман Иделе, Агыйдел, Ык) кушылган җирдә урнашкан. Мондагы табигатьнең байлыгына, ямьлелегенә сокланып туймыйсың. Елгалары балыкка бай. Шуңадырмы, биредә әдәби телдәге **балык исемнәре**нең барысы да диярлек кулланыла. Шулар арасында төгәл тәрҗемәсен табуы авыр булган мондый атамалар очрады: *алдау* – вак балык төре, *қара қанат* – корбан балыкның бер төре (?)[1], *күгәмә* (?), *түбән awыd* (?), *ақ опто* (*русча* жерех), *сыла* (*русча* судак) һ. б.

Балык тоту җайланмаларыннан *қармақ, йәтмә, мурда* (чыбыктан үргән), *җылым, питил (ике қанатлы, салып қына қуйалар), көймә, қайық* һ. б. кулланыла: «*Қайық ағач көймә инде ул, чоқоп эшләйләр. Чоқой да, пешереп, ағачны җәйә. Өйәңкә тирәк йақшы аңа, бөртөрлө җомошақ ағач ул, усақ та түгел, тупыл' да түгел, җиңел ул, су буйларында үсә ул*».

Кайсы гына төбәккә барса да, җирле тел материаллары җыючы белгеч өчен үзенчәлекле **үсемлек атамалары** табылмый калмый. Бу теге яки бу үләнгә атаманың төрле төбәктә төрле үзенчәлектән чыгып бирелүе белән аңлатыла. Димәк, җирле фитонимнарда үсемлеккә хас нинди дә булса үзенчәлек чагылган булырга мөмкин. Бу исә әлеге җирле атамаларны өйрәнүнең ботаника фәне өчен дә зур әһәмияте булуын күрсәтә.

Материаллардан күренгәнчә, ашарга ярый торган үлән исемнәре халык күңелендә яхшырак сакланган: *кәзәкәй // кәзә сақалы* – кәҗә сакалы (*русча* дикий пастернак): *Кәзәкәй басуда была торған ийе, ирнеңе бода, тигедмәй генә ашайсың, сақланыб ашамадисә иренне бода.*

*Қуқы* – какы: *Қуқы әчкөлтөм, әрчеб-әрчеп ашайсың, қатса сары чәчкә ата.*

*Җөннөкәй // җонно қуқы // җөннө бәрәңге* – йонлы бәрәңге (*русча* бутень клубненосный): *Җөннөкәй бик тәмне, төбөндә*

---

[1] Әдәби телдәге төгәл вариантын билгеләп булмаган диалекталь ихтионимнар янына сорау билгесе куелды.

*кукәйе була тәмне генә, әрчеб ашайсың. Җонно қуқы була, аның кукәйен бүре кукәйе ди торған ийек.*

*Мөтләк* – бөтнек: *Мөтләк dәп-dәңгәр чәчкә ата, киптереп төйгәчтән, ашқа dәхәр инде ул.*

*Қурай гөпшә*: *Қурай гөпшә бар, шома гөпшә түгел ул, қурай кебек таwыш чығарып тора ул.*

*Күке башы*: *Күке башы диләр, dәңгәр чәчкәле, ул да ашай торған, бик тәмне.*

*Саранча* – сарана: *Саранча урманда була, имәннек тиләр ул урманны бәлекәйрәк булғанға, шунда күп буладырыйы ул саранча.*

Дәвага ярый торган үләннәрдән, әрем, мәтрүшкә, гөлбадран кебек атамалардан тыш, әдәби телдә очрамый торганнары да бар. Мәсәлән: *сәрдәр*: *Сәрдәр дигән гөпшә бар, ашағанда бик тәмне, ашағач баш аwырта* (*түндербаш үләне* булырга мөмкин, русчасы *болиголов*). *Қырғый анис* (әнис): *Қырғый анисны ашқа саласың, тамырын да.*

Үсемлекләр дөньясы белән бәйле диалекталь сүзләрдән тагын *қарағат* – қара карлыган, *қамырлық* – дүләнә, *қаwық* – кылчык (*Арпа бит қаwықлы, ничег ашайсың аны*), *қурпылау* – агач яки үсемлекләрнең урынына яшь үрентеләр үсеп чыгу *(утап чығам, курпылай да чыға бақчада, қурпылай да чыға)* һ. б. билгеле.

Йомгак ясап шуны әйтергә мөмкин: лексик, грамматик һ. б. үзенчәлекләрне фәнни анализлау күрсәткәнчә, актанышлыларның сөйләү теле минзәлә сөйләшенең әгерҗе һәм төп урынчылыклары арасында тора. Аларның сөйләү теле әдәби телгә бик якын. Иң мөһиме, Актаныш якларында матур итеп үз телебездә сөйләшәләр, туган телебезне сакларга, үстерергә тырышалар.

## Җирле халыктан язып алган материаллар

### *Авыл тарихлары, риваятьләр*

Күҗәкә авылы. Әүлийә қәбере дигән урын бар Үмәнәй таwында. Хәdер дә бар, тик ул үdгәрде. Су баса, дип dийәрәтләрне эттерделәр. Аның валы да бар ыйы. Ул валның өdөк җире бар ыйы, йап тибеd, тәбәнәг урын. Шул йақтан кереп китә торған җире бар ыйы, чоқор шикелле. Сөргәндә, шуның белән

эрәттә, җирдә кеше башы чыкkан. Башында уk бар ыйы, дигән. Аны бабай малай чағында алып kайткан. Биdгәк белән чирләй башлаган. Күршедәге муллага шул сөйәкне биргән, беdнең әткәйдә чир беткән, теге мулла чирли башлаган хәdер. Мулла бик уkымышлы кеше ийе. Ул әйткән: син моно kайан алдың, алган урынына итеп kуй. Әткәй итеп kуйган. Шуннан әткәйдә дә беткән теге чир, муллада да. Әүлийә kәбере йанындагы сөрүлектән чыkkан булган ул баш сөйәге. Үмәнәй күчеб утырган җирне, йорт урны, дигәннәр. Kырында күл булган, шул тау буйына күчкәннәр Үмәнәй булып. Бер өлеше Сөн буйына Йаkты күл дигән җиргә күчкән, әле дә бар ул аwыл. Черкигә түdәлмәйенче күчкәннәр алар. Бабkайлар сүләй торган ийе. Үмәнәй kырында йуwан тирәк булган. Берәү беdнең аwылныкыннан теге Үмәнәйдән күчкән кешеләрнең берсе теге тирәк исәмме, дип сораша икән. Бер олло имән бар ыйы, икегә йарылып аwарга тора. Лоkман мулла әйтә торган ийе, шул имән ауғач Үмәнәй дә бетә ди торган ийе. Ул Лоkман мулла шул Үмәнәйдә үлеп kалды. Үмәнәй чыннан да бетте, анда үткән җыл аwылдашлар җийылып истәлек ташы kуйдылар.

Адай авылы. Элеке dаман урман булган. Kаdанны тар-мар иткәчтен, чуkындырудан kачып килеб утырганнар монда. Агач төпләп, бакча йасап, әdерәк иген басуwы йасап көн күргәннәр. Күрше Мари Суkсуның җире күп булган. Кукмара районыннан килгәннәр. Бездә Өч төтөн дигән чишмә бар. Зиреклек дигән урман бар. Беd нифет өстөндә утырабыd, бу төштә генә нифет чыга. Адай дигән аwылдан килеп, монда утырганнар, гөмөр итеп үлгәннәр. Әүлийә kәбере шуларныкы. Алар әүлийә булган. Бу җаkта Әрҗәwed дигән басуда да әүлийә kәбере. Әрҗәwedнең беренче кергән почмагында әүлийә kәберенең икенчесе, дийарәт kылганнар шул төштә. Бик бай беdнең аwыл, кәбестәне бөтөн районга бирәләр ийе, андагы үскән помидурны Мәскәүгә җибәрделәр бер җылны. Уңа торган ийе йәшелчәсе. Соңраk чәчсәк тә тиз уңа торган ийе. Гөпшәләре, kуdгалагы, җуwасы, җикәне, kамыш ул, тамырын ашайсың, көнө буйы тамагың ачмай. Kошлар килә торган ийе бу йаkkа. Бөрлөгәне булыр ийе, kарасы, kызылы, kайын җиләге, җир җиләге. Kара бөрлөгәннең

берсе-берсе җарты җомор чақлы. Алар бетте хәdер. Оҗмақ шикелле җир булған. Ул беdдәге қош-қортлар, аққошлар килә, акчарлақ та килә, селәүчен ашап җөриләр җир сөрдөргәндә. Ачлық чағындә бидрәләп (чиләкләп) җийдық күкәйләрен, ачқа үлмәйче қалдық. Торналар килә торған ийе, тәкәрлекләр, қыр үрдәкләре, қыр қаdлары, исәбе йуқ аларның. Тартай дигән қош бар, тар-тар, дип қычқырып йата, бүдәнәсе бар, симеd. Сарықтан җөн алғачтын әйтә торған тәсбих (теләк сүзе) бар:

Бүдәнәдән май җый,
Йабалақтан җөн җый, –

дип, торғозоп җибәрәләр, шуны тәсбих диләр.

Үмәнәйне менгәндә, кисәк борола торған җир бар, Бәшәр бабай бақчасы, диләр, чикләwеклег ийе ул, Бәшәр таwы, диләр. Аннан ни чыққанын белмәйләр, магниты бармы шунда. Болот килә, шунда җиткәч күтәрелеп китә болот, магнитмы бар, җаумай җаңғыр. Таш чоқор чишмәсе, диләр, чоқорында шунда бик тәмне сулы чишмә бар. Бәшәр таwында умарталығы да булған, ул умарта асыраған күп итеп. Бөгә йылғасы беdнең аwылнықы, Ыққа җақын җирендә балық бик шәп.

Әүлийә қәберен дүртәү диләр ийе, берсе Үмәнәйдә, беdнекен җаdдығыd, Әрҗәwеd дигән төштә, дип. Элек Әрҗәwеd ур (канау) белән әйләндереп алыңңан булған, хәdер җуғ, белмәйләр дә, уры булған аның шулай (тирәнлектә). Нарат басуwы тау өстендә, Чатлы бағана басуwы, элек Нарат басуwы, хәdер Чатлы бағана басуwы диләр. Адайдан җуғарырақ, Тачын тарлаwығы, диләр ийе, ул Урйады басуwы белән чиктәш, бәйк уңдырышлы басу ул. Қуdғалақ, җуwа, шома гөпшә (русчасы дягил), балтырған. Күҗәкәләр қыр җағы бит, болар урманда үсә, сәрдәр дигән гөпшә бар, ашағанда бик тәмне, ашағач баш аwырта. Қурай гөпшә бар, шома гөпшә түгел ул, қурай кебек таwыш чығарып тора ул. Қыdыл шоморт үсә. Алақайын дигән урманда сийәләр, күгәннәр бар, қура җиләкләре. Хәdер майлы қуwыш дигән урманда бик қаты (шәп) қура җиләге. Қарлыған җыйып бетермәле түгел ийе. Ике генә йыл ГЭС суwы килде дә, барысы да череп бетте. Шалқан атаwы Бөгә (болын ис.) буйлап барған чақта ул, күперләрне чыққачтын да.

Чиркәш тигән урман бар, Зиреклекне үткәч. Беdнең Шифа шишмәсе бар, чәй чишмәсе, қыблаға қаршы аққанны, шифа чишмәсе, диләр. Көмөш кебег ул, салқын ул. Беdнең қойорықтан аға йылға, исемне түгел, үdе таштан чыға, таш, қом төбө, шуннан чығып аға.

Адайларны, мишәр, диб әйтәләр ийе, Урйады аwылын, типтәрләр дип йөртәләр ийе.

Тачын тарлаwының асқы йағы беdнең аwылның беренче утырған урыны булған, Искаwыл. Искаwыл чоқоры дигән чоқоры да бар бик тәмне чишмәле. Марилар киткәч, монда килеб утырғаннар бабайлар. Искаwыл чоқоро бик шәпләнгән, дип сөйләйләр, қушмасы да бар. Қушма, жуwан ағачның эчен алып, чишмә чыққан урыңға қуйалар, ташлар жыйып сала торған ыйық, суwы тоноқ торсон, дип. Қырға суны тырыс белән апарғаннар, анан жылы үтмәй, чишмәдән суны қайын тырыс белән апара торған булғаннар. Беdдә жуwан жүкәдән қорт җийа торған тубал йасайлар, аның бит исе әйбәт, қорт китмей. Қарамадан да җасайлар ул тубалны, қайырысыннан – чабата, су үтмәскә күрә қайын тузын салалар. Арғы Бөгә (басу) бар, қырыйында чикләwеклек. Күгәннек тигән җирдә йе печәннегебеd, дүрт-биш чақрым.

Татар Суыксуы авылы. Қартаwылны «типтәрләр» дип, «арлар» дип җөрткәннәр, дип ишеткәнем бар.

Карт авылы. Ташқом, Сырт, Ике малай суқмағы – болар болыннар. Көләгешкә (әрәмәлек) барғаннар да адашқаннар болонда.

Киндер күле ул батқач чықмай торған җир. Элеке байлар шунда киндер салғаннар, шунда киндер талқып җатқаннар. Талқығачтан җегерләгәннәр, киндер суққаннар. Шул киндер күленең бу җағында Гәрәчке җиләне (< делянка, болын), анда Васкут дигән урыс аwылы бар ыйы. Аннан болайрақ Майур җиләне бар ийе, көтү җөридер ийе. Суғыш булған, шунда майурны күмгәннәр. Ул җиләннәр аман да исән. Киндер күленең төбө йуқ, өстө ләпек, батқак, төшә дә йуғалалар. Бер йылны тырактыр төштө анда бирталутлар килеп тартыб алды. Киндер күленең теге йағында Зәңгәр күл, Урыс Әзби аwылы күле,

Өшәр (Семистрау) күле. Иске Идел Кама алдында Ағидел белән қушыла, анда Чирәм қолағы (авыл исеме), Луговой дигәннәр.

Уразай авылы. Беdнең аwыл күл буйында булған, өч километыр Иске Уразай. Бер мең сигеd йөd сиксән икенче йылны монда күчкәннәр су басқанға. Дамба булғанчы, гел су килде монда. Сабан туй беdдә икмәк чәчелеп беткәч булған элек-электән. Ат чабышлары була, көрәш, кешеләр йөгөреш, қапчық суғышы, бөртөкләп әйтеп бетереп булмай. Уразай кеше исеме булған. Иске Қормашта Уразайыфлар күп. Башқорт түгел беd, беd чын татар. Беdдән башлап Краснокамыски, Дүртиле, Қараиделгә тикле татар, берәү дә башқорт телен белмәй, башқорт аwыллары да йуқ. Чын башқортларның теле үзгә, бөтөнләй бүтән, бу тирәләрдә йуқ алар.

Куян авылы. Аwыл тарихын белә торған қартлар үлеп беттеләр инде. Идел аржағыннан, Кама аржағыннан өч балықчы чығыб утырған монда. Аларны, өчилеләр дип дә атайлар. Жаннарыннан қуйан үтеп бара икән, шуннан Куйан аwылы булып қалған бу аwыл. Урамнарын Жирек дип, Тау буйы, Мәчет урамы дип жөртәбеd. Оло урамнарында алпаwыт Хәлфин мәчет ачқан.

Илчебай авылы. Жәнжегет аwылыннан Илчеғол дигән кешегә жир бүләк итәләр. Идел арйағында Жаңа Илчебай дигән аwылға нигеd салғаннар беdнең аwылдан. Беdдә таулар күп кенә: Бүләк тау, Кирәмәт таwы... Урыс баdы бар, ике урыс анда чүлмәк йасағаннар. Шәрәй күле, анда Шәрәй бабай балық тотқан. Динислам жары дигән төш бар.

Чуракай авылы. Типтәрләр дә булған, беd үdебеd торалы булғамбыd, Торалы дигән басу булған. Чалманараттан (авыл исеме) мулла килгән дә шуннан үрчегәмбеd беd. Эт урамы, Торалы урамының жартысы торалылар. Жире дә айыры булған. Торалы басуын билгеләп урлар (тирән канау) қаdығаннар ыйы. Жаланда да урлар бар ыйы мин белгәндә дә.

Мишәрләр Сәлкәй урамнарында таралалар, Мәчкә очо да шуңа керәдер ийе. Хәdер болғанғаннар бит. Төплө урам жарға барып төртөләдер ийе. Аның башында Артурам, Қайынның урам. Арқылы урамнар дүртәү: Мәкәрләр урамы, дидек, арқылы урам алар. Сәлкәй урамының башын да Мәчкә очо диделәр.

Керипитләр (кушамат) Қәдерматтән күчеп килгәннәр. Җирләре шунда булған, айыры калхуз ийе ул, персийәтеле бар ийе, айыры икмәк җийалар ийе.

– Беdнең аwыл Чурағолдан чыққан, кеше исеме ул Чурақай. 1730 йылларны ойошқан. Башта Қалмийаның уң йағында булғаннар. Чуқындыру башланғач теге йаққа қысрықлағаннар, Илекне, Үмерне (ав. ис.) чуқындырғаннар, башта аларда да татарлар булған. Чуқынмағаннары монда қалғаннар. Чурағол, Қадырғол шулар нәселеннән башланып киткән. Қадырғолов фамилийәсе әле дә бар. Қадырғолның малайы Ибраһим мөқтәсиб, улы Шәйәхмәт, оныгы Фелүн абdый сиксән йәштә. Типтәр дип җөрткәннәр беdнең аwылны. Қалмийаның теге йағы урман булған ул. Төпләп шул урманнарны иген игә башлағаннар. Ақма дигән җирне төпләгәннәр. Сөннөң теге йағында Султан таwы, Алқаби таwы. Алқаби таwы, диләр, Пугачевның ыштабы шунда булған. Аны түбәсенә урнашқан Чийәлек аwылы. Алқаби түбәсеннән Җыланға (урам исеме) атқаннар, шушы урамның җартысы. Ихаталарға эснәрәт төшкән. Сөннөң иске йулларында күлләр күп: Таһир күле, Иркә күле. Таһир йуғалған, аны тапмағаннар, шуннан Таһир күле дигәннәр. Яңа Байсар (авыл исеме) йанында Чүкеч күле, чүкечкә ошаған ул, Қамышлы күл, җәйен қорай ул түлкә. Сөн Уралға таба күчә барды, урманға җиткәч туқтады, хәdер беdнең йақны җимерә. Қоро йылларны, мондый қоры йылларны көтүлек ул Қамышлы күл. Иркә күлендә гел балық тоталар анда. Асылтамақ күле Байсар белән Чурақай арасында.

Қоролық булса, соңғы күмелгән мәйет қаберенә су салығыd, диләр. Туры килә ул, йаңғыр йаwа башлай. Суйылған ат башы салалар ыйы. Чулпан аwылында су сибешә торғаннар ийе, суға ат башы салалар. Персидәтел, йаңғырға китә башласа, қайсығыd салды ат башы, алығыd тиdрәк, дип радийодан қычқыра торған ийе.

## *Җир-сулар*

Күҗәкә авылы. Беdнең Ақлан басуwы, аның таллықлары бар, җылгасы бар, чишмә җылғасы ғына. Түбән басу, аның

теге йағында әрәмәсе булған. Бурсық җары, Бурсық чишмәсе, қайчан булған, беркем белми. Бурсық басуwы да шунда. Элек бурсық бик-бик күп булған. Солтан җулы басу булған ансы да. Солтан җулында арыш уралар, борчақ бүлеп бирә дибеd, Бурсық җылғасына әйләнгән ул. Қалморза қутыры, җул чаты ул. Шунда беdнең Минсалих исемне бабай адашқан. Ат белә қайтып киткәч, адашқан шунда. Барып җитәм, ди, гел (бөтенләй) башқа җир икән. Сүгенеп тә қарайым, уқынып та қарайым, барыбер җулны тапмадым, ди. Ахырында кире қайтып, монда қунды. Аннан иртәнчәк қайтып китте. Йапарай чоқоры бар. Йапарай дигән кеше адашып үлгән шунда. Бүләг арты дибеd. Бүләк тигән урманмы булған шунда. Ачы басуwы, җире ачы булғанға шулай әйткәннәр, Айу болоны бар. Үмәнәйдә Бажана йылғасы, Ықка қойа. Көләгеш саdлығы ғөмөр-ғөмөргә булған саdлық ул. Су баса, дип, Қалморза аwылын Минdәлә районына Аликсандровкаға күчергәннәр, анда бер генә урыс булған. Бикчәнтәй, Кече Нарат аwыллары бетте. Сарсаd тыралы, бик күп урыс аwыллары да беткәннәр. Дусай Кичү (авыл) бетеп бара.

Ирмәш авылы. Элекке dийәрәт тау башында булған, ул бетте инде. Монсо – Текә тау, аннан болай теге таба Сәлим җары, тау итәгендә Шәрәп койосы. Анысын Илдус бик қарады, хәdер, Илдус қойосы, дип тә әйтәбеd. Тағын Урта қойо бар. Өскә таба – Олый басуwы, өстәгесе – Җақын басу, Басу қапқасы басуwы, Әргәнәш – әрәмәлек ул. Шуның эчендә Печмән, Тәкә күлләре бар, Озон күл. Қаd қомо болоны су астында калды. Тәкә күле буйында сарығ апчығып суйып, шуннан Тәкә күле булып қалған, имеш.

Иске Әгъбәз авылы. Бақыр тау, туп-турыға менәсең. Бөйә суйған чоқор, бер байлар бөйә суйғаннар икән анда. Қормаш (авыл исеме) басуwы, шул басуға қормашлар килеп урағ урғаннар. Бүләк чабуwы – Бүләк үdе генә йәшәгән, ир кеше, берәү белән дә аралашмаған. Әүлийә қәбере бар ийе, бетте бит инде, әүлийә кеше булған. Қарабаш урманы. Қаршимәннек җақынырақ. Җаңа йақ тиләр, имәннекнең бер урыны. Башқортстан йағында күп беdдән күчеп киткән татар аwыллары: Җаңа Әғбәс, Җаңа Әлмәт, Җаңа Әмәкәй.

### *Рухи мәдәният (сабантуйлар, җыеннар, йолалар)*

Күҗәкә авылы. Йаdғы чәчү беткәчтен, җуwалар үсә бит. Үмәнәйдә бөтөн аwыл тау буйында җийылып утырған. Иң беренче җийын шушыннан башлана. Аннан болай Йамалы җийыны булыр ыйы. Җуwа җийынын нық сүләй торғаннар ийе. Үмәнәйдән ике аwыл аерылып чыққан, Йақты күл, Үмәнәй дигән кеше 1742 нче йылда утырып қала. Үмәнәй аша эпи ташай торғаннар ыйы, Чурақайдан (ав. ис.), бөтен җирдән. Үмәнәй кеше исеме ул. Аwылда қушаматлар бар ул. Сөйәк нәселе дип җөртәләр ийе, йабық кешене. Қорбанғалий абзый, оdон буйлы, оло бороннойы. Зөбәйер қуwықлары диләр, мақтанырға, шапырынырға йараталар. Адайлар (*Адай авылында яшәүчеләр.* – Авт.) қарабодайда су кергәннәр дигән сүd бар, күб ул аwылда мәdәкләр.

– Җомро эпеки алып бара торған ийек. Мин үdем дә җомро эпекәй алып бардым ашйаулыққа төрөп. Суққан киндер ашйаулық була торған ийе. Оло табаққа салып бара торған ийем, туйға күп йөрдөк. Dур әтәй, dур инәйләр беd, Суқсуда да энесе бар бабайның (иремнең), Азнақайда да бер энесе бар. Аларның оноқлары беdне «dур әтәй бабақай», «dур инәй әбекәй», дип җөриләр. Бер абзыйсына «сылу абзықай» димен. Қайссы dур абdықай, тәтәй (< тәти – әйбәт) абdықай, бәләкәй абdықай, дип үрәнәләр.

Мин 1958 йылны бардым, беd аның белән сүләшмәдек. Иң беренче төшкәч «Исәммесез, эткәй» диб әйткән ийем, бийанай «Килен, дейде, бийатаң белән сүләшмәйсең җаңадан» дейде. Аның җанда җаулық салып булмады, билдә алҗапқыч булды. Аdақ сулуда чәй эчердем, мә, эч, дип мин әйтмәдем. Ул эчкәч, «килен, эрәхмәт» тиде. Менә шул dакун. Иремнең энеләре ике булды, исемнәре белән эндәшелгәндер инде, җанағай (каене) булалар. Кайынсеңнеләр игезләр ийе, икесе дә исән, Ғәйшә, Фатима. Хәлидә белән Хәлимә ике йәштә йе, ачуwы килсә, а-ай апа, әйбәт чақта тәтәй апа, диделәр. Анан, үскәч, ападан җиңгәчәйгә күчте. Сәке инде ул чағында, олосы туф та туф, ти. Мич қаршысында ызбутта тоз тора, шуны әйтә икән ул. Бабай әйтеп җибәрде, балам, диде, ишле симйаға барасың, артыңа кем

типсә дә, әйләнеп қарамайсың, диде. Артқа типсәләр дә әйләнеп қараш булмады. Миннән соң қалған ике килен җалан айақ та җөрдөләр, икесе дә уқытучылар иде, без инде қара кеше. Мин үdемә үdем хаҗәйен түгел, алар нәмәкәй әйтсә, шуңа ыриза, дидем. Фәлән көннө никийахқа киләбеd, дип, сүләштеләр дә қайтып киттеләр. Никийахны қыd артында (ягында) уқыйлар, аш пешерәләр дә бәлеш пешерәләр, эпекәй белән чәйдер инде өстәлдә. Әткәй белән әнкәй генә килгән ийе никийахқа. Кийәү буласы кичтән килде дә, иртәнчәк dакс (загс) кәнсәсендә (канцеляриясендә) йаdылып қына чықтық та, пар ат җигеп килеп, моннан күчтәнәч арбасы, диделәр, оdата барған атны. Урамны әйләндереп алып китте. Тегендә (егет ягында) алып барған күчтәнәчең белән «килен чәйе» дип чәй эчерәләр, әdме-күпме, чәкчәк әdерләп, ашын да пешереп, бәлешен дә салдылар. Ишектән кергәндә «әйдә, килен, төклө айағың белән», дип әйтте бийанай. Хәdер мендәргә бастыралар, элек жуғыйы. Эпи башлаталар, бал-май қаптыралар хәdер, тәмне телле булсын дип. Қыңғыраулар тағып китәсең, туған-тумачасы җийылып көтөп торалар ийе. Тупсадан уң айағың белән атлап кер, дип, үрәтеп җибәрәләр. Бийанай қаршы ала, шишенеп чәйгә утыралар. Әпкилгән тәрdә фәрдәләрме, эләләр. Бүләгең булса, бирәсең, қайсына җаулық. Қапқа ачқан кешегә чиккән қулҗаулығы. Ат белән утыртып килгәнгә дә чиккән қулҗаулық. Ачйаулықлар (ашъяулыклар) да чиктем. Түрләмәм (өлеңге, стена кашагасы) дә чигүле йе. Намаdлыққа да чиктем, кийәүгә барасы қызларға да чиктем мин! Алҗапқычым үdемнеке дә чигүле йе, бийанама да чиктем алҗапқыч, анықы қара сатин ыйы, үdемнең әңкәйнеке белән бергә чиккән ийем. Ирләр алҗапқычын да күргәнем бар, кийештерделәр, минем бабай (ирем) аны кийез итек басқанда кийә торған ийе. Йөнөн теттереб апқайта торған ийе. Мал эчәгесеннән йасап җебен, үdебеd дә тетә торған ыйық, дырыңдырың тетә торған ийек. Минең әңкәй (бианай) үdе дә (каенатасы белән) сүләшмәгән, нәселендә булғанмы шундый.

Китапта җазған, имеш, берәү урыс печәнен таптаған. Зачим печән таптамыш, дигән. Шуннан безнең нәсел Таптамыш булып қалған.

Бикә җийынына барғаннар, сабан туйның алдында булған ул, сабан туйына чақлы булған, қыdыл билле перәннекләр алып қайтқаннар Бикә җийыныннан, кырандилләр (крендель).

– Аулағыйлар була торған ийе. Арқа суғышлы уйнай торғаннар ийе. Килен төшөреш, ди торған ийек, элек ишектән кергәчтән баd була торған ийе. Сайғақны алып, өстенә бер нәмә йабып қуйалар. Килеп кергән кеше баdға төшөп киткән. Аулағыйда тақмақ буладырыйы. Тақмақны берсенә берсе атап, бер күрше (янәшәдәге) малайына җырлай торғаннар ийе.

Қөтдүс килә тақырдан,
Төрөпкәсе бақырдан;
Көтдүс килмәс ийе тақырдан,
Гөләндәмкәйе чақырған.

Аулағыйда аулағаш пешерә торғаннар ийе. Идә бәрәңге қыстыбыйы пешерәләр ийе. Қайсысы-берсе йалында (өйалдында) қачып қалып, пешереб ашар wахыт җиткәч кенә җегетләр кереп ашап шунда. Беdнең үdебеdдә дә шулай қылғаннар ыйы.

Қаd ашлары була торған ыйы. Қаd йуwып қайтуға тәбикмәк (белен) пешерә торғаннар ийе. Ашына қаdын да салып, ит тә салып пешерә торғаннар ийе. Көйәнтәләп су буйына төшөп йуwыш ийе.

Әҗәкүл авылы. Киленне алырға элеккеге кебек ат белән баралар, алдан ат белән баралар, машина арттан килә. Биdәлгән ат, тырантаслар була, қыңғыраулар, бик күңелле була ул. Урамны урап чығалар, һәйкәлгә чәчкәләр қуйалар. Хәdер байлық бит инде, өстәлне бик мул әdерләйләр. Қыd оdатқанда ақча сибеп чығып китәләр. Қапқаны балалар ача қыd төшөргәндә. Камфитләр, ақчалар сибәләр. Қыd оdатқанда бигрәк күп сибәләр ақчаны. Килен аттан төшөп мендәргә басқачтан, балмай қаптырыш. Кереб утыралар. Бийанаға килен, килен бийанаға җаулық бирешәләр, бабайға – түбәтәй. Килен чәй эчергәчтән сондоқ саталар, мендәрләр – барысы да сатыла. Бүләг итеп ақча бирелә, ул ақча туйға салына шунда. Киленгә су йулы күрсәтеш. Аңа тағы җийылып барып, бийеп-җырлап, калуңкамы, чишмәме, аңа берәр әйбер тағып қуйа килен. Туғаннары беләν баралар, әкрен генә барыш, әкрен генә қайтыш. Қайтқач,

қапқада, кем қыйурақ, шул килен суwы сатыб утыра. Шайан сүзләре, уйын-көлкесе, күңелле инде. Шул суны сатыб алып қына қунақ кеше қапқадан керә. Миннән килен қоймағы пешерттеләр. Нәмә пешерәсе булса, үdем пешердем, нәмә әdерләсе булса, үdем йөрдөм. Туй қунақларын да муча кертәсең, кийәү мучасы йағасың да башта үdең керешле инде кийәү белән, аннан суң килен қоймағы пешерә башлайсың. Жақын кешеләрең дә килен қоймағы пешереп китерә. Туйға килгән қунақларны да килен қоймагы белән сыйлап, мучалар кертеп оdатышлы.

– Онтоп бетергәмен инде. Сақ уйыны була торған ийе беd жәш чақта. Парлап басалар. Тақ алға чыға да арты белән баса. Арттағы пар алға килә дә, «сақ» дип қычқырып, икесе ике йаққа жүгереп китеш. Тақ шуларның берсен тотарға тийеш, алар парлашып алға баса.

Қарға ботқасында қатнашқаным да бар. Алдан бер қортқаны билгеләп қуйа торғаннар ийе. Ул бөтөн бала-чағаны жийып алып чығып китә. Иң әwәл әйбер жийалар. Кем нәмә бирә, күкәйме, маймы, қайссы йарма бирә. Бөтенесен алып барып бер билгеле урында ботқа пешерәләр. Ул ботқаға нәмә бар барын да салалар, тәмне булып пешә ул. Нәмәшләп шулай тәмне булғандыр ул ботқа. Андары су сибешә башлайлар, йаңғыры да йаwып китә шунда.

Иске Әгъбәз авылы. Элек қаd ийе ул. Сорап барғанда да қаd бирдек. Мин, улым бардық сорап. Ике қыdы бар, бирмим, ди. Инәсе, кыdым, нигә шул чақлы қаршы торасың. Жаңадан, жалына-жалына ыриза булды. Никийахқа беdдә чәкчәк аппаралар, өстөнә жаулық сала. Хәйерлек (хәергә өләшергә акча яки әйбер) аппарасың. Малай белә инәй бара инде, әтәсе булмаса. Қода-қодағый булышайық, тип, қыd сорарға килдек, тиб әйтәсең. Қодағый буласы кеше дә малайы белән. Мәһәрең нәмә, диде мулла. Алтын алқа, диде кийәү, аптырамады, алқа бүләк иткән булған икән. Алжапқыч қына бәйләдек тә, шәл бәйләдек тә киттек, чигүле булсын түлке. Анан кийәүнең күлмәге әбәзәтелни чигүле булсын, кийәү пирчәткәсе анан (тагын) кийәүгә. Гармунчыға, кучерға пирчәткә була. Элек бирнә биреш ийе,

хәдер эрәтең булса ғына. Туған-тумачасына бирнә бирә, теге йақлар да сала. Элек күп пиреш ийе бирнә.

Төшөргәндә (киленне) бийанай мендәр сала да килен бийанайға жаулық бәйләй. Бийанай бал белән май қаптыра. Элек киленне җитәкләп кереш ийе. Киленнең бидрәсе-көйәнтәсе була, су жулы күрсәтәләр, туғаннары, дус қыdлары жыйылышып, уйнап-бийеп, барып қайталар шунда, суwын қуйып қунақларға чәй эчерәсең.

Адай авылы. Қарға ботқасына чығалар беdдә қоролыққа китсә. Ботқаны пешерәләр. Аның бер кешесе була башлап җөри торған, ботқасын пешерә торған. Бер түтәй бар ийе, бийатамның түтәсе, шул пешерә торған ийе. Қаdаннардан алып талларға, чирәмнәргә ботқаларны салып қуйалар қошлар ашасын дип. Ашағач су сибешәләр ийе.

Су килгәндә көймәгә утырып эрәхәтләнеп күңел ачып қайталар.

Уғызны пешерәләр, пешергәчтен кисеп-кисеп бөтөн туғаннарын аwыз иттерәләр. Қайсысы уғыз шәңгәсе пешерә шунда. Уғыз эремчеген, аллаһы тәғәлә ыриdалығы өчен дип, өләшәләр дә.

– Ырымнар дип, бақа қычқырғачтан су жылына, диләр, су қойонорға жарый, диләр. Күке бийыл бик күп қычқырмады, сақаулана ул, китә ул. Тупсаға утырырға йарамай, диләр, dәхмәт қағыла. Сарык бәрәннәре чирләгәчтен, мари кирәмәте, ди торғаннар ийе, шуннан әйләндерәләр.

Карт авылы. Әүлийә қәбере Назифлар айағ очонда, бақча артында. Шунда җомро чоқор қазып, қул белән қазып, сенаж йасайлар. Шул җомро чоқорно қазығанда чыққан аның сөйәге, бото ғына да бер митыр бар ийе ди. Тиз генә күмдертеп қуйғаннар ул чоқорны. Хәdер билгеле түгел. Җул салып, күтәртеп ул төшнө әлләмәләр эшләделәр.

Аннан бер пошины күмделәр җаңғор жаумағач. Лайға батыб үлгән дә бер поши, бала-чаға қайтып әйтеп, җийылып күрегә бардылар, су сибә-сибә күмделәр қортқа-сартқалар, ату җаңғыр жаумай бит.

Бер қатын айағ очондағы батқақлы таллықта адашып җөрдө. Оло йаланда печән чабалар икән, бу қайтып киткән. Өйөнә

қайтқан ул көннө, түтәсе беләторадырыйы. Бу тағын төшөп киткән печән чабарға. Алты көн қайтмады. Көтүчеләр «җардәм итегеd» дип қычқырғанны ишетеп, төшөп алып менгәннәр. Йанымда гармуннар уйнап җөрдөләр, гел җәш қыdлар анда, дип сөйләгән. Тырнақлары җебеп беткән иде бич. Җеннәр булғандырмы. Моғҗизасымақ тойолдо. Ул төштә беd дә адашып җөрдөк, Гыйләчтин абdыйның әбисе, Самат абdый қортқасы да адашып бер кич қунып қайтты. Урман ул, жышқынныќ, таллық, гел адашырлық.

Татар Суыксуы авылы. Бикә җийыны иң аdақы җийын ул. Бикә җийынын үткәрәләр дә, урақка төшәләр дә. Бикә җийыныннан бер атна алда Элбәк җийыны ди торғаннар ийе, ул кем булғандыр инде, белгән кеше җуқ.

Уйынны боd аққачтан күл буйында уйнай торған ыйық. Сақ-қа йөгөрә торған ыйық, җегетләр беләъ. Бии торған ыйық, қара-бай бийүwе ди торған ыйық, күмәк бийү, қара-қаршы басалар да бер-берсен алып әйләнәсең. Өчлө бийү, бишле бийү диде-рийек, парлап бийиләр. Аулағыйларда тычқан салыш дибеd, берәү салып чыға, тычқан кемдә, уртаға чық дип әйтә. Чығар ыйы қайсы, қайсысын қырындағылар (янындагылар) тотоп қала, үткере сыразу сикереп чыға.

Уразай авылы. Атна сайын җийын булған бит элек. Ик-мәк чәчеп бетергәч, Ағыйделнең тийағында байлар йөргән-нәр. Тағын беdнең ураdа бәйрәме, қорбан бәйрәмнәре бәк оло булған. Күкәйне, әйбер утыртқанда, җиргә чәчеп җибәргәннәр, уңыш булсын дип. Халық төрлөчә қыланған инде, тормош имин булсын дип. Өй күтәргәндә, беренче нирәгне салғанда, көмөш ақча қыстыралар. Башлар сыdламаска да көмөш тәңкәләр қуй-ғаннар, артқа чәч өстөнә қуйғаннар, чәчқап, тиб ишеткәнем бар.

Кирәмәт бар беddә, тау башында ике қайын үсеп утыра, ма-риларныкы ул. Архийологлар қаdып киттеләр. 1870 йылғы қә-бер ташлары бар. Уразайда чақта ук китереп монда күмә баш-лағаннар. Мин үdем дийарәт өчөн җаwаплы кеше. Ирләрне җуғанда қатнашам.

Башта монда марилар йәшәгән. Җамбай, Бәкилде күлләре исемнәре шулардан қалған. Кирәмәт таwы да марича dийарәт

дигән сүз. Марилар күчеп киткән. Уразай аwылы Иске аwыл дигән урыннан 1882 җылны Уразайыв дигән кеше килеб утырған, балықчы булған. Аwыл исеме дә шуннан қалған.

Чуракай авылы. Җийын диделәр элек. Иң башта үdebedнең (Сәет ав.) аwылда, аннан – күршаwылларда: Чурақайда, Сәфәрдә. Хәdер сабантуй дибеd, уйыннары бер үк. Ат җигәргә кичтән үк билгеләп қуйыш, парлы атлар алар. Кем атның хуҗасы, кемнәр утыра. Иртән җийылып, утырып китәләр. Атларны бидәш инде тастымаллар (сөлгеләр) белән. Ат чабышы буладыр ийе, йөгөрөш буладырыйы. Йәшрәк чақта йөгөрөштә қатнашқаным булды. Сумка биргәннәр ийе. Җаланда була инде. Хәdер иртә йасайлар, элек бит ул ийүн ахырларында буладыр ыйы. Кичен сабантуйдан қайтқачтан, урам ураш шул уқ атлар белән, қартлар көтөп торалар қарарға, қапқа төбөнә чығып. Сабантуй көннө, йә икенче көнөндә кичке сабантуй булыр ыйы қалған бүләкләр белән. Әйберне өй рәтеннән җыйып, бүген әйбер җийарға чығалар дип, көтәләр ийе. Майдан шул уқ җийын ул.

– Ул бит йәшен суққан ийәле ағач. Бер генә баламын. Башқа чығардай җиргә барсам ийе, үdем қарасам ийе инәйне, дип теләйем. Намаз уқу Аллаһы тәғәлә тарафыннан бирелгән бүләк ул. Қалмийәгә (елга исеме) су керергә бара торған ийем. Чық, Рауза, (судан) зәхмәт қағыла, дип ишетәм. Күd керфегем җомолмай. Мәрткә киткән әбигә өшкөртөргә килдем урлашып қына. Өч көн рәттән килмәсәң шауқыны қалыр, диде. Үd-үdеңе дә өшкөрәсең, укыйсың да менә монда (изүгә) төкөрәсең.

Күd тийүнекен җибәрү аwыррақ, башқа кешедән өшкөртергә кирәк. Күd тигән булса, шайтан зәхмәтләре, су зәхмәтләре тигән булса, дип, доғаны ихластан уқырға кирәк. Җоқларға җатқач dур су күрдем, батам, димен, нидер этеп йарға чығарды мине. Мине әсир итте шул.

Моно боdғаннар ат башы белән, дигән. Төшемдә күккә менгеdделәр өч бабай. Сиңа иртә әле, дип төшөрделәр. Аңыма килдем. Тағын менеп киттем. Икенче бер җөнчүрәк әбигә бирдем сәдәқәсен. Ат башын, доғалықны уқып, моноң җулына җә ихатаға ташлайлар. Синдә сихер бар, алам, диде. Алды. Синдә

бозом бар, гел җибәреп торалар, ди. Қайбер ашлардан чирләп қайта, күd тийә дә, матур, чибәр кеше бәк. Кеше үdенең қәлебен әdерләргә тийеш, қәлебең чиста булсын, пирештәләр йаdып тора. Қәдер кичендә берәнтекләп теләб утырам. Аппақ кийенгән бер кеше аш белә үтеп китте.

Ирмәш авылы. Мин үскән чағында Қуйан (авыл исеме) белән икарада, Элбәк җийыны, ди торғаннар ийе. Әҗәкүл, Қуйан, Ирмәш – 3 аwыл көтөп тора торғаннар ийе Элбәк җийынын. Ақтанышта тау башында, майдан, ди торғаннар ийе, сабан беткәчтән җаd көнө иң алдан майдан буладырыйы. Андары Тақталачықта җийын буладыр ыйы. Элбәк җийыны беdнеке, ул өчөнче җийын. Аннан сун Бикә җийыны була: Боғады, Солтаңғул җақларында була торған ийе, қыр җағында. Беdне, урман җағы, диләр. Дүрт атна уdа, җийын бетә, эш башлана.

Аwылның исеме шуннан қалған, башлап Ирмәш бабай утырған, өстәге dийәрәттә борынғы урында.

– Әүлийә dийәрәте, иdгеләр dийәрәте, ди торғаннар ийе. Мәчет турында, урман эчендә, ағач арасында ул, үd алдына түгәрәк тау иде ул, иdгеләр dийәрәте, дип җөртә торғаннар ийе.

Килен кешегә су җулы күрсәтәләр. Ике қыdны, күрше қыdларынмы ийәртеп җибәрәләр. Бидрә-көйәнтәсен алып баралар. Килен җә җаулық бәйләй, қулҗаулықмы, сабынмы-маdар қалдыра. Су тотқан, тийеп, қуллары чабыртқан, тийеп ишеткәнем бар. Уқып алырға, тиләр суны, шикләнмәдисә су тотмай. Аwылның бу баштағысын Шәрәп қойысы, теге башнықын Қаhир шишмәсе тиләр ийе. Урта қойно Тухфат қойосы, дип йөрдөләр. Қартәтәйнең бакчасы артқылы (агып) төшөп киткән. Шишмә була инде ул, беdдә койо, диләр, теге башнықын чишмә, диләр.

Чөгәнә авылы. Күл буйында кичен уйнап-җырлап қайтадырыйық шунда. Җырлайлар ийе тотоноп, түгәрәк җасап:

Су буйлары, су буйлары,
Су буйлары әрәшә (яр карлыгачы);
Сөйгән җарларың қайларда,
Ыскажи, пажалуста.

Йә:

Сөйәсеңме Тимербайыңы,
Ыскажи, пажалысты.

Уртада берәү басып тора бит инде. Ул җырлай:

Су буйлары, су буйлары,
Су буйлары әрәшә;
Сөйгән йарым әрмийәдә,
Wатан өчөн көрәшә.

Аулағ өй булса күгәрчен очорошлы уйнай торған ыйык. Җегет белән кыd чығып сүләшәләр дә, кергәч қыd икенче кеше белән китә. Сақлы дидер ийек, ике кеше җитәкләшәләр дә түгәрәк буйлап қуышып китеп берәрсенең алдына кереп баса, арттағы үткеррәк булса тиdрәк тороп җүгерә шунда.

Бed, сабан туйы, димәйбed, җийын дибed. Ачы җийыны, диделәр инәйләр, бedнең заманда булмады инде ул. Айышта булмады микән ул. Бикә җийынын сүләп кенә ишеткәнем бар. Җийын алдыннан әйбер җийалар. Кеше сайын керәләр. Қолғаға тастымаллар бәйләп, бала-чағаны ийәртеп җөрәйләр. Күберәк читса бирәләр хәdер.

Бала-чаға чирләсә, қайссы әбидән өшкөрткәннәр. Бүсер булса, бүсер сүрәтләрен йасап чайқатыплар эчерәләр ийе.

Иске Ағыйдел буйында Әргәнәш урманы бар.

Куян авылы. Питырау уникесендә. Питыраудан соң әйбер үсмәй башлай, қошлар сайрамай башлай. Кәкүк таwышын әdрәк ишетеб алдым, кәкүк тә қычқырмай башлай.

– Аулағөйләрдә уйыны да була. Тычқан салалар, уйнайлар. Җегетләр ақыллыйы. Қулҗаулықмы, нәмә йөрөтәләр теdелеп утыралар да, салып чығалар. Аннан болай тычқан батыр, сикереп тор, дип. Бииләр матур итеп. Җәшләр бар ийе, үлеп беттеләр бик күп суғышта. Әтәң-инәңнән сорап чығасың, фәлән кешеләрдә аулағый, диләр. Түлке ипле җөр, дип тешәтеп (кисәтеп) җибәрәләр.

Әнәк авылы. Ийәле өйләр бар ул, хәdер дә сөйләйләр ул ийәле җортларны. Бed андайларны күрмәдек, шөкөр ходайға, балаларым арқасында бик нық эрәхәт җәшәдем. Аd аwыру, асат үлем бирсен ходай. Моннан түбән тәүфиқлы булсыннар.

## *Аш-су*

Күҗәкә авылы. Киндер орлоғыннан тәкә (бөккән) җасай торғаннар ийе, тәкә пешерәбеd, дип. Көйлөдә төйөш ийе орлоқны. Қаdанда қыdдырып, ағач қөйлөдә төйөп орлоғын. Мәк тәкәсе пешерә торғаннар ийе, қамырны җәйеп, җартысына орлоқно сибеп, қара-қаршы йабып қамырны, мичтә пешерәсең, dәхәр тәмне була ул. Мичнең төбенә салып пешерсәң дә йарай. Элек эпине әнәләп (әвәләп) мич төбөнә сала торған ийек. Беdдә, бәчмәчә, дип пешерәләр тағын мондайны: тәгерләтеп-тәгерләтеп җибәрәләр, нәзек кенә итеп қамырны. Шуны барнақ белән басып қына өdәсең дә атасың ашқа. Аны магазинда да саталар, рашки инде ул.

## *Кием-салым*

Күҗәкә авылы. Озон ычқырлы ыштан төп қуйып, төпле итеп, киндерне қайнатып тегә торғаннар ийе. Бөрмәсенә бау үреп, хатын-қыdнықы да шулай була торған ийе. Бауны айыры үрә торғаннар ийе ыштан киндерәсе дип.

Тула йоқно җөннән җасай торғаннар ийе. Җөннө җәйеп җоқа ғына итеп, кере бетсен дип қайнар суда қайната торғаннар ийе. Оdон ойоқ теdдән җуғары, бәйләйләр, балағы оdон. Балдағы дип тә әйтә қайссы.

Тәңкәдән, көмөштән, чулпы булған өчәр тәңкә, берсе аста, икесе ике җақта, шылтыр-шылтыр килеп җөридер ийе. Дәwәтләр (дүрт почмаклы, тәңкәләр тезгән, муенга бәйләп алга киелә торган бизәнү әйбере) дип сөйләгәнне беләм.

Адай авылы. Киндернең кәүсәсеннән сүс йасап бишмәтлекләр дә, җәймәне дә суқтылар. Беdдә кийеd дә суқтылар чите қара итеп. Түшәп тигеd генә иттереп, басалар, аннан болай оло қаdанға салып қайнаталар.

Куян авылы. Талқы талқыта торғаннар ийе, киндерне муча сайын бирәләр. Беренче җегерләгән җепне хәйергә бирәдер ийек. Сүсне бәк күп җегерләдек. Чоба теккәннәр сүсне җөн белән қушып суғып, оло йақалы, чикмән күүк. Чобасы халат кебек, пылащ кебек. Чобаны ирләр кийәләр ийе. Аппақ чоба була торған ийе җитеннән. Тулайоқны басалар аны. Беd бик күрмәдек инде аны. Җырақ җулларға җөргәндә, оло шәл җабы-

налар, чана шәле була ул. Җуғалттым чана шәлемне. Эй эчем ачыта шул шәлгә, dур ул, дүрт шәл чыға бүлсәк. Шул шәлемне алып чығып киттеләр теге сөргән җылларны. Кешмир шәл була торған ийе, кешмир шәл әл дә бар, бәйләп бийегәндә әртислар күрәбеd. Җибәк шәле дә бар, wәле дә бар, хәdер аларны бәйләгән кеше дә жуқ.

Кийем-салым хәdер үdгәрде бит ул. Гәрәбә төймә ди торған ийек. Анан болай әбиләрдән чулпылар ала торған ийек эспиктакыллар қуйғанда. Уң күdем гел (бөтенләй) суқыр. Чәчқапны да күргәнем бар, толомно эченә төшөрәсең, өстөндә тәңкә теdгән, очонда йә чулпы, йә оло тәңкә (бөтен тәңкә). Күлмәкләрне турыға ғына тегеш. Йақасы утыртма җақа, җә түгәрәк җақа, җә очло җақа йы. Эләктермәле күлмәк булған. Элегерәк сәдәф кебек йасағаннар ағачтан, түгәрәк итеп. Күлмәкнең түшен сәдәфләп қуйа торған булғаннар, түше ачық күлмәкләр булмаған да. Җиң оdон инде, җиң очо болай ғына да була, бәбәйтәк тә. Бәбәйтәкле күлмәк әммесендә, балайтәкле дип тә әйтә қайссы. Икешәр-өчәр, дүртәр, бишәр балайтәк була торған ийе. Күлмәкнең биле өdөк түгел ийе. Алҗапқыч моннан кимәле, түшле алҗапқыч инде ул. Соңрақ билдән буwа торғаны да чықты. Килен булып төшкәндә, аш-суға йәрдәм итүчеләргә алҗапқыч тегеб алып килеш ийе. Җиңгәчәйләр, түткәйләр – үdеңнең туғаннарың була бит инде анда.

Иске Әгъбәз авылы. Муйын төймәсе (муенса), чын гәрәбә төймәләр була торған ийе, чулпы тағырлар ыйы, челтер-челтер килеп җөри торған ийе. Беләdекнең күзлеләре дә була торған ийе, балдақларның төрлөсе бар ийе. Алқа, қашлысы да, қашсыdы да була. Дуғайлы алқа киде минең инәкәй. Сырға булыр ийе, муйынса иде ул, оdонырақ, көмөштән, тәңкә теdгәннәре дә буладыр ыйы, ул тәңкәләрне тишеп-тишеп тақтылар микән суң. Оло (бөтен) тәңкәне чәч толомоның очона тағарлар ыйы. Қалпақны беләсеңме? Энже-сәйләннәр теdгән, байырақларда әлнәмәдәйләре бар ыйы аның, тәқыйалар кийеп җөргәннәр.

Әнәк авылы. Җидесе җиде төрлө, җидешәр бәбәйтәкле күлмәгем бар ыйы, ничә күлмәгем бар, күлмәк сайын бер алҗапқыч, ди торған ийе инәй.

МӘГЪЛҮМАТ БИРҮЧЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

***Адай авылы:*** Газизова Ханә Хәсән кызы, 1929 елгы.

***Әҗәкүл авылы:*** Ахпарова Кифая Сәләхетдин кызы, 1925 елгы; Әдиятуллина Зәмзәмия Зәки кызы, 1928 елгы.

***Әнәк авылы:*** Хамурзина Гөлсинә Мөхәммәтдин кызы, 1934 елгы.

***Ирмәш авылы:*** Мөхәмәтшакирова Мосаяра, 1923 елгы.

***Иске Әгъбәз авылы:*** Рәшитова Гөлҗәннәт Хөҗҗәт кызы, 1932 елгы.

***Карт авылы:*** Зарипова Нәгыймә Латыйп кызы, 1932 елгы; Фәтхетдинова Дәнә Фәхертдин кызы, 1946 елгы.

***Куян авылы:*** Әхмәдуллина Җәннәт Нәҗметдин кызы, 1927 елгы; Галләмова Мәрзия Мирзаян кызы, 1927 елгы.

***Күҗәкә авылы:*** Мөхәммәтсалихова Рәхимә Мөхәммәтсалих кызы, 1928 елгы; Хәйбиева Дунийә Мирзанур кызы, 1937 елгы; Хәйбиев Зәки, 1934 елгы.

***Татар Суыксуы авылы:*** Арсланова Гөләйнә Садертдин кызы, 1936 елгы; Бикмөхәммәтов Шайгалим Шайдәүләт улы, 1929 елгы; Галиуллина Зәйтүнә, 1927 елгы.

***Уразай авылы:*** Шәйхелимамова Хөдәймә Әбелмәгъриф кызы, 1931 елгы.

***Чөгәнә авылы:*** Салихова Халидә Шагали кызы; Хөсәенова Әнүзә Мәгъдәнур кызы.

***Чуракай авылы:*** Зиязетдинова Нәҗибә Сәлмәнфарсый кызы, 1927 елгы; Хафизов Мөдәрис Хафиз улы, 1930 елгы; Хафизова Альбина Хәйдәр кызы, 1937 елгы.

# МИНЗӘЛӘ СӨЙЛӘШЕНЕҢ ФОНЕТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Фәрит Йосыпов*

## Сузык авазлар системасы

Сузык авазлар системасы буенча минзәлә сөйләше татар әдәби теленә иң якын сөйләшләрдән санала. Авазларның артикуляцион, акустик сыйфатлары ягыннан да ул татар теленең орфоэпик нормаларына якын тора. Алай гына да түгел, минзәлә сөйләше үзенең төп билгеләре буенча татар теленең сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә. Бу якынлык бигрәк тә формалашу тарихлары уртак булган казан арты һәм тау ягы сөйләшләре арасында күзәтелә. Минзәлә сөйләшенең көнчыгыш өлкәләрдә таралган урта диалект сөйләшләре белән булган уртаклыгы да бу төбәктәге башка татар төркемнәренең XVI гасырдан башлап бергәләп кичергән тарихи сәбәпләр белән аңлатыла. Шулай да сөйләштә кулланыла торган сузык авазлар, кайбер очракларда төрле позицияләрдә килеп, әдәби телдән аерыла торган фонетик күренешләр барлыкка китерәләр. Ләкин аларның күпчелеге минзәлә сөйләше таралган территория белән генә чикләнеп калмый, бәлки Казан ханлыгы заманында формалашкан татар теленең нигез сөйләшләре өчен дә үзенчәлекле билгеләреннән санала.

Минзәлә сөйләшендә кулланыла торган сузык авазларны, татар тел белемендә кабул ителгән бүленеш буенча, түбәндәгечә төркемнәргә аерырга мөмкин.

**Телнең горизонталь хәрәкәтенә карап:**
алгы рәт сузыклар: **[и], [ә], [е], [ү], [ө]**
арткы рәт сузыклар: **[а], [у], [о], [ы]**

**Телнең вертикаль хәрәкәтенә карап:**
югары күтәрелешле сузыклар: **[и], [у], [ү]**
урта күтәрелешле сузыклар: **[о], [ө], [ы], [е]**
түбән күтәрелешле сузыклар: **[а], [ә]**.

**[а] фонемасы.** Билгеле булганча, татар сөйләшләрен төркемләгәндә, [а] сузыгының сыйфаты зур әһәмияткә ия. Сөйләштә кулланыла торган **[а]** сузыгы – алгы рәт, түбән күтәрелешле аваз. Татар әдәби телендә һәм казан арты, тау ягы сөйләшләрендәге кебек үк, бу аваз минзәлә сөйләшендә дә ирен төсмере белән әйтелә. Иренләшү дәрәҗәсе авазның кайсы позициядә килүе белән бәйле. [а] авазы беренче, икенче, өченче иҗекләрдә көчле ирен төсмере белән әйтелсә, дүртенче һәм аннан соңгы иҗекләрдә ирен төсмере кими бара, шулай да дүртенче һәм бишенче иҗекләрдә килүенә карамастан, башка төрки телләрдәге кебек ачык итеп әйтелми: *а$^{о}$қ, а$^{о}$л, а$^{о}$ш, а$^{о}$т, а$^{о}$й; са$^{о}$л, та$^{о}$ш, қа$^{о}$р; қа$^{о}$рға$^{о}$, та$^{о}$ба$^{о}$, ба$^{о}$ра$^{о}$ а$^{о}$ға$^{о}$, та$^{о}$dа$^{о}$, ба$^{о}$ла$^{о}$, а$^{о}$ча$^{о}$, қа$^{о}$йа$^{о}$; а$^{о}$ла$^{о}$р, та$^{о}$ла$^{о}$, а$^{о}$шлық, Қа$^{о}$за$^{о}$н, а$^{о}$лда$^{о}$у, қа$^{о}$йда$^{о}$, йа$^{о}$ ққа$^{о}$нчы* һ.б.

Ирен-ирен [б], [w], [п], [м] тартыклары һәм ирен-ирен [о], [у] сузыкларыннан соң килгән [а] сузыгының иренләшү дәрәҗәсе әдәби телдәге варианттан да артып китә: *ба$^{о}$р, ба$^{о}$л, ба$^{о}$ш, ба$^{о}$й; ма$^{о}$л, ма$^{о}$й; wа$^{о}$қ, wа$^{о}$т, wа$^{о}$лчық; wа$^{о}$қыт, бора$^{о}$, бота$^{о}$, тора$^{о}$, қора$^{о}$, бута$^{о}$, буша$^{о}$, сура$^{о}$ – сора$^{о}$, боdай – боdа$^{о}$й, боdа$^{о}$у – боза$^{о}$у* һ.б. Минзәлә сөйләшенең бу үзенчәлеге турында беренчеләрдән булып, А.Г. Бессонов (1881), Н.Ф. Катанов (1900) ассызымлап әйтеп узалар. Аларның әйтүенчә, Башкортстанның көньяк-көнбатыш өлешендә яшәүче татарлар сөйләше бу үзенчәлеге белән башкорт теленнән нык аерылып тора. Күренекле башкорт телчесе Җ.Г. Киекбаев та иренләшкән [а] авазы башкорт сөйләшләре өчен хас түгел, аның кайбер сөйләшләрендә күзәтелүе күрше татар сөйләшләре тәэсирендә генә барлыкка килгән дигән фикерне әйтә[1].

[1] *Киекбаев Ж. Ғ.* Башкорт теленең фонетикаһы. – Өфө, 1958. – Б. 27.

Билгеле булганча, татар әдәби теленә аеруча якын торган урта диалект сөйләшләре, бу авазның иренләшүе-иренләшмәвенә карап, ике зур төркемгә бүленәләр: беренче иҗекләрдә иренләшкән [а°] авазы татар теленең болгар теле һәм фин-угор кавемнәре катнашында формалашкан сөйләшләре өчен хас. Иренләшмәгән [а] авазы исә нугай теле катнашкан сөйләшләрдә кулланыла.

Татар әдәби телендә һәм урта диалект сөйләшләрен иренләшкән [а] фонемасының булуын тирән тел арты [қ] [ғ] тартыкларына бәйләп аңлатырга тырышучылар да бар. Ләкин бу фикер белән килешү шактый кыен, чөнки әлеге тартык авазлар бик сирәк төрки телләрдә генә кулланылалар. Шулай булуга карамастан [а] авазының иренләшкән варианты бары тик татар һәм үзбәк телләренең генә үзенчәлекле билгеләреннән санала. Бу авазның татар телендә тагын бер үзенчәлегенә дә игътибар итеп китик: башка төрки телләрдән аермалы буларак, ул сүз башында хәмзә төсмере белән әйтелә, ләкин ул авазга фонемалык мәгънәсе алып килми.

[а] авазын иренләштереп әйтү ягыннан минзәлә сөйләше, башка татар сөйләшләре белән чагыштырганда беренче чиратта урта диалектның казан арты сөйләшләре төркеме белән зур уртаклык күрсәтә. Шул ук диалектның тау ягы, бәрәңге сөйләшләре, шулай ук эчкен, богырслан сөйләшләренең аерым урынчылыклары исә бу күренешнең кайбер искәрмәләре булуы белән характерлана.

Минзәлә һәм казан артты сөйләшләренең [а] авазын беренче, икенче, өченче иҗекләрдә шактый иренләштереп әйтү аларның уртак тарихлары белән аңлатыла. Билгеле булганча, казан арты сөйләшләре татар теленең Казан ханлыгы чорында ук формалашып җиткән борынгы сөйләшләреннән санала. Бу дәвердә татар теленең сөйләшләрендә җирле этнолингвистик сәбәпләр нәтиҗәсендә кайбер сузык һәм тартык авазлар өлкәсендә аерымланулар башлана. Шундый билгеләрнең берсе итеп, казан арты сөйләшләрендә җирле фин-угор кабиләләре субстраты тәэсирендә [а] авазын иренләштереп әйтү үзенчәлеген билгеләп үтәргә кирәк. Мәгълүм булганча, Идел-Кама

бассейнында таралган телләрдә (татар, мари, чуваш телләрендә беренче иҗектә килә торган [а] сузыгы иренләшеп әйтелә: чуваш теленең тау (верховой) диалектында ул бөтенләй [о] булып үзгәргән (*пос* – баш, *хора* – кара, *хор* – каз һ.б.), болын (низовой) чувашларында исә [о] дан [у] га күчкән (*пус* – баш, *хура* – кара, *хур* – каз һ.б.), мари телендә борынгы фин-угор [а] сы [о] тәңгәллеген барлыкка китергән: *тошто* – иске, карт, *поро* – яхшы һ.б.[1]. Чуваш телендә дә, татар телендәге кебек үк, «о»лаштырып сөйләү бигәк тә мари теле белән чиктәш сөйләшләр өчен хас. Мари теле сөйләшләре, борынгы мари телендәге [а] урынына [о] яки [а] авазларын кулланyга карап, ике төркемгә бүленәләр: болын һәм көнчыгыш сөйләшләр төркемендә бу позициядә, кагыйдә буларак, ирен-ирен [о] сузыгы кулланыла[2]. Шулай итеп, мари теленең субстраты нигезендә болгар телендәге иренләшмәгән [а] сузыгы беренче иҗекләрдә ирен төсмере белән әйтелә башлаган. Тора-бара икътисади, мәдәни яктан өстен булган болгарлар тәэсире нәтиҗәсендә Казан арты территориясендә, аерым алганда, хәзерге Арча, Балтач, Кукмара, Саба, Мамадыш районнарында яшәгән болгарлар белән тыгыз мөнәсәбәттә булган «о»лаштыручы мариларның бер өлеше ассимиляциягә бирелгән[3]. 1552 елда, Казан руслар тарафыннан басып алынганнан соң, [а] авазын иренләштереп сөйләүче Казан арты татарларының бик күп өлеше Кама аръягы аша рус администрациясе ераграк булган Агыйдел буйларына, соңрак Башкортстанның көньяк-көнбатыш, көньяк-көнчыгыш өлешләренә качып китә. Минзәлә сөйләшенең формалашу тарихыннан күренгәнчә, татарларның Идел һәм Казансу тирәләреннән көнчыгыш төбәкләргә күчеп утырулары берничә гасыр буенча зур темплар белән дәвам итә. Димәк, минзәлә сөйләшендә [а] сузыгын «о»лаштырып, ирен төсмере белән әйтү Казан ханлыгы җи-

[1] *Хабибуллина М.Р.* Характеристика изоглосс вариантов фонемы [а] в татарском лингвистическом пространстве: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2002. – С. 15.

[2] *Грузов Л.П.* Фонетика диалектов марийского языка в историческом освещении. – Йошкар-Ола, 1965. – С. 45

[3] *Хабибуллина М.Р.* Характеристика изоглосс вариантов фонемы [а] в татарском лингвистическом пространстве. – С. 16.

мерелгәннән соң бу якларга күчеп килгән, сан ягыннан җирле татар-төрки кабиләләреннән артып киткән Казан татарларының сөйләш үзенчәлекләренә бәйле рәвештә барлыкка килгән. Казан татарлары кимрәк булган төбәкләрдә [а] авазының иренләшү дәрәҗәсе шактый кими төшә.

Татар диалектологиясендә [а] авазын иренләштереп әйтү минзәлә сөйләше таралган барлык территорияләрдә дә бер үк дәрәҗәдә күзәтелә, дигән фикер хөкем сөрсә дә, безнең материаллар күрсәтүенә караганда, сөйләшнең көнчыгыш чикләрендә иренләшү дәрәҗәсе, Татарстанның көнчыгыш районнары, шулай ук Агыйдел, Ык, Сөн елгалары бассейнында таралган урынчылыклар белән чагыштырганда, бераз кими төшә. Кайбер урынчылыкларда [а] авазының [о] төсмере белән әйтелеше әдәби телдә кабул ителгән орфоэпик нормаларда артып китә. Кызганычка каршы, татар теленең диалектологик атласында бу төсмерләр махсус билгеләр белән күрсәтелмәгәннәр. Урта диалектның кайбер сөйләшләрендә [а] авазының төрле дәрәҗәдә иренләшкән вариантлары булуы бу сөйләшләрнең формалашуында катнашкан мари субстратының интинсивлыгы яки иренләшмәгән [а] авазы кулланылган сөйләшләрнең тәэсире белән аңлатылырга тиеш.

Татар әдәби теле һәм күпчелек сөйләшләрдә кулланыла торган арткы рәт, калын [а] авазы, кайбер очракта палатальләшеп, алгы рәт, нечкә [ә] авазына күчә, бу күренеш нигездә түбәндәге мисалларда чагыла: *сиңә* – сиңа, *миңә* – миңа, *әләйсә* // *әлсә* – алайса, *мәтәшеү* – маташу, *әңгерә* – аңгыра, *нәчәрлек* – начарлык, *сәленеү* – салыну, *кәкшәү* – какшау, *йәбешеү* – йабышу, *сәйескән* – саескан, *җәр* – йар, *чәк* – чак, *кечерткән* – қычытқан. Бу күренеш тә асылында минзәлә сөйләшенең борынгы төрки тел традицияләрен саклавы белән аңлатыла. Югарыда әйтеп киткәнебезчә, татар телендә борынгы төрки телдәге кайбер сүзләрдә әйтелә торган арткы рәт [а] авазы минзәлә сәйләшендә алгы рәт [ә] сузыгына туры килә. Л. Т. Мәхмүтова бу күренешне күбрәк алынма сүзләрдә чагылыш таба дип күрсәтә[1]: *пәлтә* –

[1] *Махмутова Л.Т.* О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР // Материалы по татарской диалектологии. – Казань, 1962. – С. 64.

пальто, *ләфкә* – лавка, *кәртә* – карта, *гәдит* – газета, *эчтәкән* – стакан, *тәпечкә* – тапочка, *тәрликә* – тарелка, *кәртинкә* – картина, *мәтрешкә* – матрешка, *эшкәп* – шкаф, *күфәйкә* – куфайка, *дәмәнә* – замана, *тәрих* – тарих һ.б.

Шуның белән беррәттән, бер төркем сүзләрдә татар телендәге киң әйтелешле [а] авазына кайбер төрки телләрдә тар [ы] сузыгы яки тар [ы] сузыгына киң әйтелешле [а] авазы туры килү минзәлә сөйләшендә күзәтелә торган мисаллар белән дә раслана: *соңадын* – соңыннан, *чаңға* – чаңгы, *йаңғы* – йаңа, *алҗадым* – алҗыдым, *җасмақ* – җасмык, *батқылық* – баткаклык, *уңдару* – уңдыру, *чыйқау* – чайкау, *қалыға* – калага, *балыма* – балама, *қапқысы* – капкасы. Шулай ук чагыштыр: тув. *чыт, тырт, тып, шып – тат. ят, тарт, тап, яп;* якут. *сыт, ыт, ый, ыл* – тат. *ят, ат, ай, ал* һ.б. (Исхаков, 1956, 233). Бу күренеш буенча да минзәлә сөйләшенең борынгы төрки тел өчен уртак күренешләрне күбрәк саклап калган Уралда һәм Көнбатыш Себердә таралган татар сөйләшләре белән уртаклыгы күренә.

Татар әдәби телендәге киң [а] авазын тар [ы] белән алмаштыру яки, киресенчә, тар [ы] урынына киң [а] әйтү күренеше тамыр сүзләрдән тыш кушымчалар өчен дә хас:

а) *-ыр, -ер; -ырга, -ергә* кушымчаларына беткән кайбер фигыльләрдә: *киләр, киләргә* – килер, килергә; *сатар, сатарға* – сатыр, сатырга; *бирәр, бирәргә* – бирер, бирергә; *төзәтәр, төзәтәргә* – төзәтер, төзәтергә һ.б.

Диалектологларның әйтүенә караганда, бу күренеш бигрәк тә сөйләшнең бәләбәй урынчылыгы өчен хас, дип санала[1]. Бу яктан да минзәлә сөйләшенең Урал һәм Көнбатыш Себер территориясендә таралган татар сөйләшләренә якынлыгы күренә.

ә) *-ганчы, -гәнче* формалы хәл фигыльләрдә: *атқынчы* – атканчы, *алғынчы* – алганчы, *қайтқынчы* – кайтканчы, *ашағынчы* – ашаганчы, *барғынчы* – барганчы, *туйғынчы* – туйганчы, *бозолғончы* – бозылганчы; *килгенче* – килгәнче, *җиткенче* – җиткәнче, *әйткенче* – әйткәнче, *эшлегенче* – эшләгәнче, *пешкенче* – пешкәнче һ.б.;

[1] *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – С. 85.

б) *-ғыла, -гелә* кушымчалы фигыльләрдә: *алғылай* – алгалый, *барғылай* – баргалый, *қайтқылай* – кайткалый, *килгеләй* – килгәли, *киткеләй* – киткәли һ.б.

Кабатлаулы фигыль кушымчаларындагы киң [а] сузыгын тар [ы] авазы белән алмаштыру үзенчәлеге буенча минзәлә сөйләше Урал һәм Көнбатыш Себер иңкүлегендә таралган татар сөйләшләре белән берлектә уртак изоглосса барлыкка китерә. Бу изоглоссаның үзәге булып Себер татарлары диалектлары санала. Бу яктан без өйрәнә торган сөйләш аеруча пермь[1], красноуфим, эчкен, сафакүл[2] сөйләшләренә якын тора. Златоуст татарлар сөйләше бу изоглоссаның тирбәлеш зонасын тәшкил итә[3]. Татар диалектлар системасыннан тыш, бу изоглосса күрше башкорт теле һәм аның сөйләшләре[4], шулай ук Көнбатыш Себердә таралган алтай, шор[5] телләрен дә үз эченә ала. Бу күренеш кыпчык һәм карлук телләренә хас үзенчәлек, дип санала.

**[ә]** сузыгы үзенең артикуляцион, акустик сыйфатлары белән урта диалектның Казан ханлыгы чикләрендә формалашкан нигез сөйләшләреннән аерылмый. Билгеле булганча, бу сөйләшләрдә ул татар әдәби теле орфоэпик нормаларына туры килә. Минзәлә сөйләшендә дә бу аваз алгы рәт, түбән күтәрелешле, ачык (киң) әйтелешле аваз булып санала.Татар әдәби телендә һәм татар сөйләшләрендә бик актив кулланыла торган бу сузык аваз үзенең киң әйтелеше белән мишәр һәм Казан ханлыгы чикләреннән тыш формалашкан сөйләшләрендәге тар [ә] вариантыннан аерылып тора. Татар теленең үзенчәлеге булып саналган бу сузык аваз, сүзнең тамыры һәм кушымчаларында килеп, барлык иҗекләрендә дә актив кулланыла: *әd* – аз, *әйт, тәм, тән, бәр,*

---

[1] *Рамазанова Д.Б.* К истории формирования говора пермских татар. – Казань, 1996. – С. 105.

[2] *Юсупов Ф.Ю.* Татар теленең диалектлары. Урал сөйләшләре. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 103, 273, 326.

[3] *Хайрутдинова Т.Х.* Златоустовский говор татарского языка. – Казань, 1985. – С. 90.

[4] *Дмитриев Н.К.* Грамматика башкирского языка. – М.; Л., 1948. – С. 185.

[5] *Дыренкова Н.П.* Грамматика шорского языка. – М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1941. – С. 47.

*җәм* – ямь, *җәш* – яшь, *килә, китә, тибә, сирәк, җиләк, иркә, сәнәк, бәләк, кәләш, кешеләргә, җиләклектә, чебешләрдән* һ.б.

Урта диалектның [ө] сузыгы булган күпчелек сөйләшләрендәге кебек, минзәлә сөйләшендә дә [ә] авазының иренләшкән варианты кулланыла. Бу авазның әлеге варианты, экстралингвистик сәбәпләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән иренләшкән [а$^{о}$] дан аермалы буларак, бары тик фонетик позицияләр өчен ген хас. Шушы сәбәпләр аркасында [ә] авазының иренләшкән варианты беркайчан да сүзнең беренче иҗегендә күзәтелми. Иренләшмәгән [ә] сузыгы, иренләшкән [ө] авазынан соң килеп, аның көчле тәэсире нәтиҗәсендә иреннәрнең актив эшчәнлеге белән әйтелә: *бөрә$^{ө}$, төрә$^{ө}$, көлә$^{ө}$ сөрә$^{ө}$, сөрә$^{ө}$ләр, төзә$^{ө}$тә$^{ө}$ләр, көрә$^{ө}$шә$^{ө}$ләр, сөдөшә$^{ө}$лә$^{ө}$р* – сөзешәләр һ.б.

Татар әдәби теле өчен дә күпмедер дәрәҗәдә күзәтелә торган бу күренеш беренче чиратта татар теленең Урал, Көнбатыш Себер киңлекләрендә таралган сөйләшләре өчен үзенчәлекле. Әйтергә кирәк, борынгы төрки һәм хәзерге төрки телләрдән аермалы буларак, татар әдәби телендә [ө] авазының иренләштерү дәрәҗәсе шактый ким. Иренләшкән [ө] сузыгының Уралда таралган татар сөйләшләрендә, аерым алганда, минзәлә сөйләшендә иренсез сузыкларны иренләштереп әйттерү табигатен борынгыдан ук Урал төбәкләләрендә яшәп килгән, [ө] авазының көчле иренләштерү үзенчәлегенә ия булган төрки кабилә теленең субстраты буларак аңлатырга мөмкин.

Ә. Ш. Әфләтүнов фикеренчә, сүзләрнең беренче иҗегендә килгән [ә] сузыгы, җиңелчә иренләштерелеп, [ө] авзы төсмере белән әйтелергә мөмкин[1]. Ләкин мондый очраклар безнең һәм башка тикшеренүчеләрнең күзәтүләре белән расланмады.

Билгеле булганча, борынгы, шулай ук хәзерге төрки телләрнең күпчелегендә кулланыла торган киң әйтелешле [ә] авазы татар телендәге тар [и], [е] сузыкларына туры килә: борынгы төрки, уйг., үзб. *мән* – мин, *сән* – син, *кәс* – кис, *кәл* – кил, *тәр* –

[1] *Әфләтүнов Ә.Ш.* БАССРның көньяк-көнбатыш өлешендә яшәүче татар сөйләшләренең тел үзенчәлекләре: филол. фән. канд. ... дис. – Казан, 1960. – Б. 45.

тир; *әдик* – ничә, *чик, кишер, итек;* азәрб. *кәпәк, әр, кәс, әлли* – кибәк, ир, илле, кис, илле һ.б.

Сөйләштә бер төркем сүзләрдә шушы борынгы әйтелешне саклап сөйләү очраклары бар. Бу күренеш татар теленең күпчелек сөйләшләрендә күзәтелсә дә, сүзнең тамырында әдәби телдәге тар [и] урынына киң [ә] сузыгын әйтү аеруча Урал һәм Көнбатыш Себердә таралган татар сөйләшләре өчен, аерым алганда, минзәлә сөйләше өчен үзенчәлекле: *бәк* – бик, *кәм* – ким, *кәм* – кем, *кәбәк* – кебек, *мәләш* – миләш, *кәләп* – киләп, *кәбәк* – кибәк, *кәрәк* – кирәк, *тәрән* – тирән, *кәтмән* – китмән, *кәбән* – кибән, *кәштә* – киштә, *кәртә* – киртә, *кәмә* – көймә//кимә, *бәзмән* – бизмән, *сәрмәү* – сирмәү, *тәкле* – тикле, *кәмсетү* – кимсетү, *кәметү* – киметү, *кәгәwен* – кигәвен, *әлләмәшләп* – әллә нишләп.

И. Насипов, югарыда китерелгәннәргә өстәп, минзәлә сөйләше өчен генә хас булган түбәндәге сүзләрне дә китерә[1]: *әреш* – иреш (тукыма сугу станогының бер детале), *әгәрче* – игәрче (ачыган камыр оеткысы), *кәсәртке* – кисәртке, *кәршән* – киршән (кечкенә тагарак), *кәпрән* – кипрән (мендәр тышы), *кәрмән* – кирмән (ныгытма), *мәчкәү* – хайваннар тоту өчен элмәк.

Шуның белән беррәттән, Идел буе төрки телләр өчен хас булганча, XVI гасырдан башлап, борынгы киң [ә] авазын тарайту процессы барса, икенчедән, шул ук борынгы төрки телдә тамырында [и] булган сүзләр дә булырга мөмкин. Сөйләш таралган территориядә бу күренешнең активлыгы төрле дәрәҗәдә. Өлкән буын вәкилләренең әйтүенә караганда, XX гасыр башларында да мондый сүзләрнең саны бүгенге көнгә караганда шактый артык булган.

**[у]** сузык авазының ясалышы һәм әйтелеше ягыннан минзәлә сөйләше урта һәм себер татарлары диалектлары сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә. Бу аваз, мишәр сөйләшләреннән аермалы буларак, өстәмә төсмерләр белән әйтелми. Ул барлык фонетик шартларда да татар теленең орфоэпик нормаларына туры килә. Бу аваз югары күтәрелешле, арткы рәт,

[1] *Насипов И.С.* Древнетюркский лексический пласт диалектной лексики мензелинского говора татарского языка: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1994. – С. 113–114.

иренләшкән сузык аваз булып әйтелә. Ул сүзнең башында, уртасында, азагында очрарга мөмкин. Татар әдәби теле һәм башка татар сөйләшләрендәге кебек, бу аваздан соң гадәттә [а], [ы] авазлары килә: *ун, ул, урт, була, бутау, турау қурай* һ.б.

Минзәлә сөйләшендә тамырның беренче иҗегендә кулланыла торган төрки чыганаклы [у] авазына башка төрки телләрдә [о] сузыгына туры килә: тат. *учак* – якут. *оһох,* чуртан – якут. *сордоң,* ун – үзб., уйг. *он,* тун – үзб., уйг. *тон* һ.б.

Бу күренешнең кайбер очраклары сөйләштә түбәндәге сүзләрдә генә сакланып калган: *чобалу* – чуwалу, *чобан* – чуwан, *җобану* – йуwану, *боғаз* – бугаз, *җоқа* – йука, *ақбор* – акбур, *оңғай* – уңгай, *сосар* –сусар, *олом* – улым, *қол* – кул, *қолйаулық* – кульъяулык, *йомарт* – йумарт, орф. юмарт, *монча* – мунча, *мончала* – мунчала, *молла* – мулла, *олақ* – улак, *топса* – тупса, *бота* – бута, *боталған* – буталган, *орлау* – урлау, *шолай* – шулай, *шошо* – шушы, *шонда* – шунда. Алынма сүзләрдә: *сохари* – рус. сухари, *торба* – труба, *қоча* – рус куча һ.б. Югарыда китерелгән мисаллардан бу төбәкләрдә Казан татарлары килгәнче яшәгән төрки кабиләләр борынгы һәм хәзерге төрки телләргә хас булган сузыклар системасын саклап сөйләгәннәр дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Тамырның беренче иҗегендә, татар әдәби теленнән аермалы буларак, [у] урынына борынгы төрки телдәге [о] сузыгын куллану төрле сүзләрдә төрле дәрәҗәдә татар теленең күпчелек сөйләшләрендә чагылыш таба. Шулай да бу күренеш бигрәк тә урта диалектның Урал һәм Урал артында таралган татар сәйләшләре өчен хас. Шундый сөйләшләрдән беренче чиратта пермь[1], красноуфим, эчкен, сафакүл[2], златоуст[3] сөйләшләре өчен үзенчәлекле. Бу яктан минзәлә сәйләшенең борынгы һәм хәзерге төрки телләр белән якынлыгы күренә.

---

[1] *Рамазанова Д.Б.* К истории формирования говора пермских татар. – Казань, 1996. – С. 42.

[2] *Юсупов Ф.Ю.* Татар теленең диалектлары. Урал сөйләшләре. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 28, 240, 296.

[3] *Хайрутдинова Т.Х.* Златоустовский говор татарского языка. – Казань, 1985. – С. 20.

Минзәлә сөйләшендәге борынгы төрки телдәге иренләшкән [о] сузыгын [у] белән алмаштыру тора-бара бу авазларның иренсезләшүенә, ягъни бу авазларның [ы], [и] авазлары белән алмаштырып әйтүгә китергән дип санарга мөмкин. Сөйләштә күзәтелә торган түбәндәге очраклар шул турыда сөйли булса кирәк: *бы* – бу, *сым* – сум, *был* – бул, *была* – була, *былган* – булган, *былыр* – булыр, *былышыу* – булышу, *быйау*// *бийау* – бую, *ыҡлау* –уклау, *тыплау* – туплау, *ҡыйарға* – куярга, *тыйдым* – туйдым, *былай* – болай, *сыйу*//*суйу* – сую, *мынча* – мунча, *мынчалы* – мунчала, *тыплыу* – туплау, *мылла* – мулла, *чылпан* – чулпан, *намыс* – намус, *мыйын* – муйын, *Тимазы* – Туймазы, *су бийында* – су буйында, *бийаҡ* – бу як, *бийыл* – бу ел һ.б.

Җ. Алмаз Башкортстанның Илеш һәм Дүртиле районнарында яшәүчеләрнең сөйләшендәге бу үзгәрешләрне [о] хәрефе өстенә ы куеп аңлата: оы [о] һәм [у], [ы] авазлары арасындагы мөнәсәбәтләрнең бер этабы булган бу күренешне иренсезләшү процессының башлангыч этабы итеп карарга кирәк.

**[ү]** авазы, әдәби тел һәм урта диалектның нигез сөйләшләрендәге кебек, югары күтәрелешле, алгы рәт, иренләшкән сузык аваз булып әйтелә. Мишәр сөйләшләреннән аермалы буларак, ул башка сузык авазлар төсмере белән катлауландырылмый. Ул тамыр сүзнең беренче иҗегеннән тыш бары тик кушымчаларда гына кулланыла. [ү] авазыннан соң, гадәттә, [ү], [ә], [е] авазлары килә: *үт, үтеш, үрә, үбеү, түгә, түбә, сүгә, сүтә, күрә, бүтән, бүрек, күбек* һ.б.

Минзәлә сөйләшендә кулланыла торган [ү] авазына борынгы һәм хәзерге төрки телләрдә [ө] авазы туры килә: *күл* – башка төрки телләрдә – көл, *сүд* – сөз, *күз* – көз һ.б. Бу күренешнең кайбер очраклары сөйләштә түбәндәге сүзләрдә сакланып калганнар: *шөрләү* – шүрләү, *төбә* – түбә, *чөмәлә* – чүмәлә, *бөгөн* – бүген, *өрмәкүч* – үрмәкүч, *көңөл* – күңел, *көркә* – күркә, *чөпрәк* – чүпрәк, *төбән* – түбән, *көпчек* – күпчек (кечкенә мендәр), *бөре* – бүре, *көзәтү* – күзәтү һ.б.

Сузык авазлар өлкәсендәге башка тәңгәллекләр кебек [ө], [ү] авазлары арасындагы тәңгәллек тә барлык террриториядә бер

үк дәрәҗәдә, бер үк сүзләрдә күзәтелми, китерелгән очраклар гомумиләштереп бирелде.

Әйтергә кирәк, ирен [ө], [ү] сузыкларының тарихи күчешен чагылдырган бу очракларны татар теленең күпчелек сөйләшләрендә табарга мөмкин, ләкин әлеге сүзләрнең саны ягыннан минзәлә сөйләше Уралда таралган, татар әдәби теле йогынтысыннан ераграк торган пермь, красноуфим, златоуст, эчкен, сафакүл сөйләшләренә якын тора.

**[о]** татар әдәби теле, татар теленең нигез сөйләшләрендәге кебек үк, сөйләмдә бик актив кулланыла торган сузыклардан санала. Бу аваз урта күтәрелешле, арткы рәт иренләшкән авазлар төркеменә керә. Сөйләштә бу авазны куллану хосусияте тулысы белән татар әдәби теле нормаларына туры килә. Урта диалектның нигез сөйләшләрендәге кебек, бу аваз сүзнең барлык иҗекләрендә дә кулланыла ала. Бу беренче чиратта аның үзеннән соң килгән иренләшмәгән [ы] авазын иренләштерү табигатеннән килә. Шунлыктан [о] авазы сүзнең дүртенче иҗекләрендә дә саф килеш ишетелә: *тормошобод* – тормышыбыз, *боролошо* – борылышы, *тотошо* – тотышы, *солосо* – солысы һ.б.

Татар әдәби теле һәм татар сөйләшләрендә кулланыла торган арткы рәт, урта күтәрелешле, иренләшкән кыска [о] сузыгына борынгы төрки, башка төрки телләрдә, кагыйдә буларак, югары күтәрелешле [у] авазы туры килә: тат., минз. *болот* – аз., алт., кырг., тув., уйг., үзб. – *булут,* шор. –*пулут*; *борон* – аз., төркм., уйг., үзб. – *бурун,* к. калп. – *мурун* һ.б.

Борынгы әйтелешне саклап әйтү түбәндәге сүзләрдә сакланган: *туқмач* – токмач, *бутқа* – ботка, *бурчақ* – борчак, *ғумер* – гомер.

**[ө]** сузыгын куллану буенча да минзәлә сөйләше татар әдәби теле һәм урта диалектның нигез сөйләшләреннән аерылмый. Бу аваз минзәлә сөйләшендә дә урта күтәрелешле, алгы рәт, иренләшкән сузык аваз булып әйтелә. Сүзнең беренче иҗегендә килеп, икенче, өченче, дүртенче иҗекләрдә дә кулланыла. Безнең күзәтүләргә караганда, бу авазның иренләшү үзенчәлеге бары тик дүртенче иҗектән соң гына кими башлый: *бөрө* – тат. орф. бөре, *төрлө* – төрле, *бөйөр* – бөер, *бөтөнөсө* – бөтенесе, *төрлөсө* – төрлесе, *көлкөсө* – көлкесе һ.б.

Югарыда күреп үткәнебезчә, бу аваздан соң килгән иренсез [ә] авазы ирен төсмере белән әйтелә: *сөрә^ө^, көрә^ө^, төрә^ө^, көлә^ө^* һ.б.

Уралда таралган татар теленең башка сөйләшләрендәге кебек, кайбер сүзләрнең беренче иҗегендә иренләшкән [ө] авазының иренләшмәгән [е] урынына куллану очраклары билгеле: *мөң* – әд. мең, *бөрәй* – берәр, *бөтү* – бетү, *дөбәт* – дебет.

**[и]** – алгы рәт, югары күтәрелешле, иренләшмәгән сузык аваз. Кагыйдә буларак, сүз һәм иҗек башында, сүз уртасында кулланыла. Бу аваздан соң тартыклар аша [и], [е], [ә] сузыклары килә: *ит, ис, бит, бик , ич, ике, иртә, тимер, ирек, итек, шикәр, кишер, сирәк* һ.б. Сүз азагында килгән позицияләрдә [әй] дифтонгына күчә: *инәй* – әни, *әтәй* – әти, *тирләй* – тирли, *сүләй* – сөйли, *бирмәй* – бирми һ.б.

Сөйләштә бу күренешнең киресе, ягъни киң [ә] авазын тар [и] сузыгы белән алмаштырып сөйләү очраклары да күзәтелә: *чичкә* – чәчкә, *сике* – сәке, *тирәдә* – тәрәзә, *әлбиттә* – әлбәттә.

Билгеле булганча, Идел буенда таралган төрки телләрдә XVI гасырдан башлап борынгы төрки телдәге киң [ә] авазын тарайту процессы барса, икенчедән, шул ук борынгы төрки телдә тамырында [и] булган сүзләр дә кулланылган. Югарыда китерелгән очраклар моның дәлиле булып торалар.

**[ы]** – урта күтәрелешле, арткы рәт, иренләшмәгән сузык аваз. Татар әдәби теле һәм татар сөйләшләренең үзенчәлеге булып исәпләнгән бу авазның кулланышы минзәлә сөйләшендә дә билгеле позицияләр белән чикләнмәгән, ул сүзнең теләсә кайсы иҗегендә, тамыр яки кушымчалар составында кулланыла ала: *ырғақ, ырмау, ындыр, тырнақ, тастымал, тартына, барасы, табасы, тырышлыгы* һ.б.

**[е]** – татар әдәби теле һәм татар сөйләшләрендәге кебек үк, алгы рәт, урта күтәрелештәге, иренләшмәгән сузык аваз. Кулланылышы ягыннан аерым позицияләр белән чикләнмәгән, [ы] авазы кебек, тамыр яки кушымчалар составында килеп, сүзнең барлык иҗекләрендә дә кулланыла ала: *бер, сер, кер, беренчесе, бишенчесенеке* һ.б. Бу аваздан соң, гадәттә, [е], [ә], [и] сузыклары килә.

Төрле төрки телләрдә бу авазның тагын да таррак яки бераз киңрәк вариантлары билгеле (Исхаков, 1956, 96). Төрки телләр арасында күзәтелә торган [е] ~ [и] ~[е] тәңгәллеге борынгы төрки һәм башка язма истәлекләрдә күзәтелә: *кәм,* чув. *кам,* тув. *кым,* күпчелек төрки телләрдә *ким,* тат., башк., алт., хак., шор., казах., нугай *кем* һ.б.

Әлеге тарихи тәңгәллек **кам>кым>//кәм>ким> кем** юнәлешендә барган *а>ы//а>ә>е>и* тарихи күчеш процессы буларак каралырга тиеш (Исхаков, 1956, 97). Минзәлә сөйләшендә моны дәлилли торган түбәндәге сүзләр сакланып калган: *инәй* – әни, *тирәзә* – тәрәзә, *пирәмәч* – пәрәмәч, *сике* – сәке, *пике* – пәке, *ирлән* – әрлән, *әлбиттә* – әлбәттә; *ичкыну* – ычкыну, *пичкы//пычкы, ич* – эч, *ичке* – эчке, *ичү* – эчү, *пичән* – печән, *чиршы//чыршы, чиллә* – челлә, *чиргән* – черегән, *җигерләү* – җегерләү, эрләү, *инә* – энә, *тиге* – теге, *кичкенә* – кечкенә, *җигерме* – егерме, *мәчит* – мәчет. Шулай ук чагыштыр: *әпекәй//эпекәй//ипикәй*. Шушы күзлектән караганда, түбәндәге сүзләр дә әлеге тарихи күчешнең бер этабын тәшкил иткән дип санарга мөмкин (Исхаков, 1956, 96), ягъни минзәлә сөйләшендә дә артикуляцияләре ягыннан берберләренә якын булган [и], [е] сузыклары генетик яктан бер чыганактан булган [и] сузыгы белән чиратлашып килергә мөмкин.

Югарыда күреп үткәнебезчә, сузык авазларның саны, аларның артикуляцион, акустик хосусиятләре ягыннан минзәлә сөйләше татар әдәби теленә, шулай ук урта диалектның нигез сөйләшләренә бик якын тора. Сөйләшнең урта диалект сөйләшләре белән охшашлыгы аларның генетик уртаклыгын аңлата.

## Сузыклар гармониясе

**Рәт гармониясе.** Сузык авазлар гармониясе яки сингармонизм законы буенча да минзәлә сөйләше татар әдәби теле һәм татар сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә. Бу закон буенча беренче иҗектә килгән сузык аваз тәэсирендә анннан соңгы килгән авазлар калынлыкта, яки нечкәлектә ярашып киләләр. Сөйләштә бу закончалык, татар әдәби телендәге кебек үк, эзлекле рәвештә тормышка ашырыла. Рәт гармониясе буенча, беренче иҗектә килгән сузыкка карап, башка иҗекләрдә я алгы рәт, я арткы рәт

сузыклар гына килә: *қартнәй* – дәү әни, *қарттәй* – дәү әти, *дурнәй* – дәү әни, *билмау* – билбау, *бертен* –аз гына, бераз һ.б.

Бу закончалыкны бозу күренешләре башка система телләрдән кергән алынма һәм кушма сүзләргә карый. Алынма сүзләрнең иң зур төркемен гарәп, фарсы, рус һәм Европа телләренннән кергән сүзләр тәшкил итә: *ишан, иман, сират, сәдәқа, шәйтан; кило//кила, киламитыр, сипаратыр, силус* һ.б.

Югарыда китерелгән очраклар белән беррәттән сузык гармониясен бозу очраклары сөйләшнең үз сүзләрендә дә очрый: *арчи* – туйда кыз ягыннан килгән кунаклар, *ихата* – йорт, кура, *чинакай* – юк-барга тавыш чыгаручы кеше, *миканаю* – симерү.

Алынма сүзләрдә, югарыда күрсәтеп үтелгән очраклар белән беррәттән, арткы рәт сузыкларны алгы рәт сузыклары белән алмаштырып әйтү киң таралган:

Рус сүзләрендә: *сәwит* – совет, *әдрис* – адрес, *ләфкә, ләүкә* – лафка, *пәлтә* – пальто, *бәтинкә* – ботинка, *тәпечкә* – тапочки, *кәрт* – карта, *кәстүм, бүчкә* – бочка, *бүлнис* – больница һ.б.

Гарәп-фарсы телләреннән кергән сүзләрдә: *бәлә* – бәла, *җәфа* – җәфа, *хәләқ* – һәлак һ.б.

Сөйләштә сингармоник парларны куллану да шактый киң таралган: *кечерткән//кычырткан, сәленү//салыну, йәбешү//йабышу, сармашу//сәрмәшү, зар//зәр, мәк//мак, шешә//шыйша// әчкеч//ачкыч, әрзән//арзан* һ.б.

**Ирен гармониясе.** Татар әдәби телендәге кебек үк, минзәлә сөйләшендә дә беренче иҗектә килгән [о], [ө] сузыклары үзләреннән соң килгән иренсез [ы], [е] авазларын иренләштереп киләләр. Урта диалектның нигез сөйләшләренә хас булганча, бу авазларның иренләштерү тәэсире сүзнең тамырында гына түгел, бәлки кушымчаларда да дәвам итә. [о], [ө] ирен сузыкларының иренләштерү көче ягыннан минзәлә сөйләше Урал төбәгендә таралган башка татар сөйләшләренә, аерым алганда, красноуфим, златоус, эчкен, сафакүл, богырыслан сөйләшләренә якын тора. Бу сузыкларның көчле иренләштерү табигате Көнбатыш Себер татарлары диалектлары өчен дә хас.

[о] сузыгының тамыр сүзләрдә кулланышы: *болон* – орф. болын, *болот* – орф. болыт, *борон* – орф. борын, *қолон* –

орф. колын, *толом* – орф. толым, *тоқом* – орф. токым, *шошо* – шушы.

[о] сузыгының кушымчаларда кулланылышы: *солосо* – орф. солысы, *боролош* – борылыш, *тормошобоз* – тормышыбыз һ.б.

[ө] сузыгының тамыр сүзләрдә кулланылышы: *өрөк* – орф. өрек, *төлкө* – төлке, *көлкө* – көлке, *бөтөн* – бөтен, *төзөлөш* – төзелеш һ.б.

[ө] сузыгының кушымчаларда кулланылуы: бөгөнгөсө – орф. бүгенгесе, бөтөнөсө – бөтенесе, төрлөсөнөкө – төрлесенеке һ.б.

Югарыда күреп үткәнебезчә, иренләшкән [о], [ө] сузыклары үзләреннән соң килгән иренләшмәгән [а], [ә] сузыкларын иренләштереп, [о], [ө] төсмере белән әйтүне таләп итәләр: *тома$^{о}$ан, тора$^{о}$м, бора$^{о}$, сора$^{о}$у; көрәк, төбәү, сөрән* һ.б. Кайбер урынчылыкларда [о], [ө] авазлары үзләреннән соң килгән [ы], [е] сузыкларын гына иренләштереп калмыйча, бәлки алдагы сүзнең иренсез авазларына да тәсир итә алу көченә ия булу очраклары да теркәлде: *бөр көннө* – бер көнне, *бөрсөкөн* – берсекөн, *қошқоно* – кыш көне, *тоноч тора* – тыныч тора һ.б.

## Дифтонглар

Дифтонгларның саны, аларның табигатьләре буенча сөйләш татар әдәби теле, урта диалектның казан арты, тау ягы сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә. Сөйләштә гомуми тел белемендә чын дифтонглар дип аталып йөртелгән фонетик берәмлек урынына сузык авазлар белән бергә килгән, үзләренең сыйфатлары белән сузык авазларга бик якын булган [w], [й] сонантларыннан торган тезмәләр генә кулланыла. Төрки тел белемендә мондый тезмәләрне ялган дифтонглар дип атап йөртәләр. Аларның саны татар диалектларында төрлечә. Иң күп дифтонглар урта һәм көнчыгыш (себер татарлары) диалектында кулланыла дигән фикер урнашкан. Мишәр диалектында, төрле фонетик шартларга карап, дифтонгларны монофтонглаштыру киң таралган. Бу тезмәнең башында әлеге сонантларның берсе, сузык авазлардан соң килеп, күтәрелмә тон белән әйтелсәләр, мондый тезмәләрне **күтәрелмә дифтонглар** дип атыйлар. Сөйләштә түбәндәге күтәрелмә дифтонглар файдаланыла: [йа], [йә], [йу], [йү], [йы], [йе], [йо], [йө], [wa], [wә], [wы], [we].

Татар әдәби теленнән аермалы буларак, [й] сонантына башланган күтәрелмә дифтонгларны, сөйләшкә җеләштерү хас булганлыктан, сүз башында куллану шактый чикләнгән. Бу дифтонглар сөйләшнең көнчыгыш чикләрендә, [ж], [й] тартыкларын параллель кулланган яки [й] сонанты өстенлек иткән урынчылыкларда, аулаут позицияләрдә генә кулланыла башлый.

[йа]: *бa°йa°* – орф. бая, *қa°йa°* – орф. кая, *тa°йa°* – орф. тая, *буйa°* – орф. буя, *туйa°* – орф. туя, *суйa°* – орф. суя, *қуйa°* – орф. куя, *тойa°* – орф, тоя, *қыйa°* – орф. кыя һ.б.

[йә]: *тийә* – орф. тия, *төйә* – орф. төя, *бийә* – орф. бия, *сөйә* – орф. сөя, *сөйән* – орф. сөян (юкә агачы) һ.б.

[йу] дифтонгы, нигездә, исем фигыль кушымчаларында очрый: *байу* – орф. баю, *туйу* – орф. тую, *қуйу* – кую, *тойу* – тою, *масайу* – масаю, *қартайу* – орф. картаю һ.б.

[йү] дифтонгын да, [йу] дифтонгы кебек үк, татар-төрки чыганаклы сүзләрдә нигездә исем фигыль кушымчаларында кулланыла: *тийү* – орф. тию, *бийү* – орф. бию, *көйү* – орф. көю, *сөйү* – орф. сөю һ.б.

[йы]: *байы* – орф. бае, *сайы* – сае (бәйлек), *тайы* – орф. тае, *тыйыл* – орф. тыел, *қайыш* – орф. каеш, *қайын* – орф. каен, *муйын* – орф. муен, *сыйығы* – орф. сыегы һ.б.

[йе]: *тийен* – орф. тиен, *кийек* – орф. киек, *бийек* – орф. биек, *тийеш* – орф. тиеш, *кийенү* – орф. киенү, *мийе* – орф. мие.

[йо]: *тойом* – орф. тоем, *қойо* – орф. кое.

[йө]: *көйө* – орф. көе, *бөйөк* – орф. бөек, *көйөгө* – орф. көеге һ.б.

[wa]: *wат* – орф. ват, *wақ* – орф. вак, *wалчық* – орф. валчык, *аwаз* – орф. аваз, *саwа* – орф. сава, *туwа* – орф. туа, *буwа* – орф. буа һ.б.

[wә]: *күwәс* – икмәк салу өчен әзерләнгән оеткы – камыр һ.б.

[wы]: *қуwық* – орф. куык, *суwық* – орф. суык, *таwыш* – орф. тавыш, *саwыт* – орф. савыт.

[we]: *җүwеш* – орф. юеш, *кәwеш* – орф. кәвеш, *белүwе* – орф. белүе, *китүwе* – орф. китүе һ.б.

Урта диалектның казан арты һәм тау ягы сөйләшләрендәге кебек үк, беренче элементы [а], [ә], [ы], [е], [о], [ө] сузык

авазлардан башланып, икенче авазы [й], [w] сонантларына тәмамланган [ай], [әй], [уй], [ой], [өй], [ый], [aw], [әw], [ow], [өw] төшерелмә дифтонглар актив кулланыла, [ий], [үй] дифтонглары минзәлә сәйләшендә дә бик сирәк очрый: [ай]: *а$^{о}$й, җа$^{о}$й, та$^{о}$й, са$^{о}$й, ма$^{о}$й, ҡа$^{о}$йсы, ба$^{о}$йтаҡ, а$^{о}$га$^{о}$й, уйна$^{о}$й* – уйный, *а$^{о}$ша$^{о}$й* – ашый, *ҡа$^{о}$ра$^{о}$й* – карый һ.б.

Минзәлә сөйләше, татар әдәби теле, урта диалектның нигез сөйләшләре булып саналган казан арты, тау ягы сөйләшләре, мишәр диалектыннан аермалы буларак, кайбер туганлык терминнары, күрсәтү алмашлыкларында, хәзерге заман хикәя, теләк фигыльләрдә, шулай ук *-п, -а* формалы хәл фигыльләрнең юклыгында кулланыла торган тар сузыклар белән әйтелә торган [ый], [ий] дифтонглары киң сузыклар белән [ай], [әй] итеп әйтеләләр: а) туганлык терминнарында һәм кайбер тамыр сүзләрдә: *инәй* – әд. әни, *әтәй* – әти, *җа$^{о}$на$^{о}$й* – җаный, *җизнәй* – җизни, *түтәй* – түти; *әпәй* – ипи, *бәбәй* – бәби, *үгәй* – үги; ә) сорау һәм күрсәтү алмашлыкларында: *ниндәй* – нинди, *шунда$^{о}$й* – шундый, *а$^{о}$нда$^{о}$й* – андый, *монда$^{о}$й* – мондый, *тегендәй* – тегенди; б) хәзерге заман хикәя фигыльләрдә: *а$^{о}$ша$^{о}$й* – ашый, *уйна$^{о}$й* – уйный, *туҡта$^{о}$й* – туктый, *эшләй* – эшли, *сүләй* – сөйли, *бидәй* – бизи; шулай ук: *эшләйем, эшләйсең* – эшлим, эшлисең, *са$^{о}$йла$^{о}$йым, са$^{о}$йла$^{о}$йсың* – са$^{о}$йлыйм, са$^{о}$йлыйсың; в) теләк фигыльләрдә: *ба$^{о}$ра$^{о}$йым* – барыйм, *а$^{о}$ла$^{о}$йым* – алыйм, *та$^{о}$ба$^{о}$йым* – табыйм, *әйтәйем* – әйтим, *эшләйем* – эшлим, *беләйем* – белим, *ҡа$^{о}$ра$^{о}$йыҡ* – карыйк, *ҡа$^{о}$йта$^{о}$йыҡ* – кайтыйк, *күтәрәйек* – күтәрик, *күрешәйек* – күрешик, *белешәйек* – белешик; г) *-ып, -а* формалы хәл фигыльләрнең юклыгында: *ба$^{о}$рма$^{о}$й* – бармый, *онотма$^{о}$й* – онытмый, *са$^{о}$гымма$^{о}$й* – сагынмый, *белмәй* – белмәй, *сидмәй* – сизми һ.б.

Татар диалектологиясендә бу күренеш, нигездә, минзәлә сөйләшенең үзенчәлекле билгеләреннән саналып килде[1]. Минзәлә сөйләшенең Татарстанның көнчыгыш, Башкортстанның

[1] *Җәләй Л.* Татар диалектологиясе. – Казан, 1947. – Б. 37; *Махмутова Л.Т.* О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР // Материалы по татарской диалектологии. – Казань, 1962. – С. 65; *Баязитова Ф.С.* Мензелинский говор татарского языка // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 7.– Казань, 1989. – С. 69.

көнбатыш районнарында таралган өлешендә бу үзенчәлек хәзерге көннәрдә дә тотрыклы үзенчәлекләрнең берсе булып тора. Бу төбәкне махсус өйрәнгән галимнәр әлеге күренешнең Башкортстан Республикасының көньяк-көнбатышында анда-санда гына күзәтелүен билгеләп үтәләр. Күрсәтелгән шартларда [ай], [әй] дифтонгларын фигыль формаларында куллану бәләбәй урынчылыгының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш өлешендә бөтенләй күзәтелми[1].

[ай], [әй] дифтонгларын шушы рәвешчә куллану белән минзәлә сөйләше беренче чиратта татар теленең Уралда таралган сөйләшләре, аерым алганда бөре[2], красноуфим, нократ-кистем, эчкен, сафакүл[3], златоуст[4] сөйләшләренә зур уртаклык күрсәтә. [ай], [әй] дифтонгларын түбәндәге позицияләрдә куллану себер татарлары диалектларының да үзенчәлекле билгеләреннән санала. Урал һәм Көнбатыш Себер лингвистик киңлекләрендә бу күренешнең шактый зур изоглосса зонасы барлыкка килә. Татар диалектлары системасында бу изоглоссаның үзәге булып себер татарларының тобол-иртыш диалекты тора. Ул үз эченә башкорт теленең күрше сөйләшләрен дә алып, бер ареал хасил итә. Моннан тыш, әлеге күренеш касыйм[5], кайбер керәшен сөйләшләре өчен дә характерлы.

[ай], [әй] дифтонглары иске татар теле һәм аның язма истәлекләре өчен дә хас булган. Соңрак татар теленең күпчелек сөйләшләрендә әдәби тел тәэсире нәтиҗәсендә әлеге дифтонглар составындагы киң [а], [ә] авазларының тараеп, [ы], [е]

---

[1] *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – С. 86–87.

[2] *Махмутова Л.Т.* О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР // Материалы по татарской диалектологии. – Казань, 1962. – С. 68.

[3] *Юсупов Ф. Ю.* Татар теленең диалектлары. Урал сөйләшләре. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 21, 116, 234, 292.

[4] *Хайрутдинова Т.Х.* Златоустовский говор татарского языка. – Казань, 1985. – С. 26.

[5] *Махмутова Л.Т.* Описание грамматических особенностей касимовского говора татарского языка // Изв. КФАН СССР. Вып. 1. – Казань, 1955. – С. 77–84.

сузыкларына күчүе нәтиҗәсендә, бу дифтонглар [ый], [ий>и] рәвешендә әйтелә башлый.

Сөйләштә югарыда карап узган күренеш белән беррәттән, татар әдәби теле һәм урта диалектның күпчелек сөйләшләреннән аермалы буларак, [ай], [әй] дифтонгларын тарайтып, [ый], [ий] рәвешендә әйтүнең түбәндәге очраклары бар: а) кайбер туганлык терминнарына иркәләү-кечерәйтү кушымчалары ялганганда: *инәкәй//инәкий, әткәй//әткий, әнкәй//әнкий, түтәкәй// түткәй//түтекий//түтий;* ә) *-лай, -ләй* кушымчалы рәвешләрдә: *икенчелий* – икечеләй, *бүтәнчәлий* – бүтәнчәләй; б) охшатучагыштыру рәвешләренең кушымчаларында: *айудый* – айюдай, *бүредий* – бүредәй, *күрмәгәндий* – күрмәгәндәй һ.б.; в) *бийәлий* – бийәләй.

Әйтергә кирәк, бер төркем сүзләрдә киң [ә] авазын тарайтып, [и] белән алмаштыру татар теленең күпчелек сөйләшләрендә күзәтелә. Бу күренеш [ә]< [е]<[и] авазлары арасындагы үзара тәңгәллекләрнең аерым этапларын тәшкил итә.

[әй]: *бәй* – ымлык, *җәй, җәй, инәй* – эни, *теләй* – тели, *күрмәй* – күрми, *ишетмәй* – ишетми һ.б.

[ый]: *тый, җый, сый* һ.б.

[уй]: *уй, буй, қуй, суй, туй* һ.б.

[ой]: *қой, той, тойғо – тойгы.*

[өй]: *өй, сөй, көй, җөй, чөй, төй, төймә, сөйрә, көймә, көйрә өйрә, сөйлә* һ.б.

Дифтонгар өлкәсендәге югарыда карап үтелгән күренешләр белән беррәттән, Уралда таралган башка татар сөйләшләрендәге кебек[1], әлеге дифтонгларны монофтонглаштыру, ягъни аны [ү] (сирәк кенә [ө]) сузыгы белән алмаштыру да киң таралган. Ул нигездә түбәндәге сүзләрне эченә ала: *үрәнү//өрәнү* – әд. өйрәнү, *үләнү// эләнү* – өйләнү, *үрә* – өйрә, *сүрәү* – сөйрәү, *сөйли//сүләй//сийли* – сөйли, *түмә//төмә – төймә, күләй* – көйли. Сузык авазлар алдында бу дифтонг [үw] белән алмаштырыла: *бүwә* – башка сөйләшләрдә *бөйә* – әд. буа, *wақ-түwәк* – вак-

[1] *Юсупов Ф.Ю.* Сафакүл татарлары: тарих, тел, халык иҗаты. – Казан, 2006. – Б. 64.

төяк. Башка очракларда, татар әдәби телендәге кебек, [өй] дифтонгы кулланыла.

Кайбер урынчылыкларда [ый], [ий] ~ [ай], [әй] тәңгәллеге кеше исемнәрендә дә күзәтелә: *Сәрбәй* – Сәрби, *Шәмсәй* – Шәмси.

[aw]: *caw* – орф. сау, *baw* – орф. бау, *taw* – орф. тау, *шaw* – орф. шау, *ҡайнaw* – орф. кайнау һ.б.

[әw]: *әw* – ымлык, орф. әү, *дәw* – орф. дәү, *берәw* – орф. бирәү, *эшләw* – орф. эшләү һ.б.

[ow]: *тотow* – орф. тоту, *борow* – орф. бору, *ҡорow* – орф. кору һ.б.

[өw]: *өтөw* – орф. өтү, *бөрөw* – орф. бөрү, *йөрөw* – орф. йөрү, *төтөw* – орф. төтү һ.б.

Минзәлә сөйләшендә татар әдәби телендге [йай], [йәй], [йaw], [йәw], йый], [йыw], [йуй] трифтонглары бары тик [җ], [й] сонантлары параллель кулланылган урынчылыкларда гына күзәтелә: *йаулыҡ* – орф. яулык, *йауды* – яуды, *йуйма* – башка сөйләшләрдә *җуйма* – әд. югалтма, *йый* – орф. җый, *йыйнаҡ* – орф. җыйнак.

## Сузык авазларның позицион үзгәрешләре

**Протеза.** Минзәлә сөйләшендә [р], [с], [т], [ш] тартык авазлары белән башланган сүзләр алдына өстәмә сузык аваз өстәп әйтү, татар әдәби теле һәм татар сөйләшләрендәге кебек үк, нигездә алынма сүзләр өчен хас: *эрәхмәт* – рәхмәт, *ыризык* – ризык, *эшәл* – шәл, *эрәт* – ряд, *эскәтер* – скатерть, *эчтәкән* – стакан, *эскәмбия* – скамья, *ыстанса* – станция һ.б.

**Эпентеза** – сүз уртасына аваз өстәү очраклары: а) татар теленең үз сүзләрендә: *ҡарышы* – каршы, *җөрөмәй* – йөрми, *михәнәт* – михнәт, *күреше* – күрше. Бу төркемгә татар диалектологиясендә редукциянең бер төре итеп аңлатыла торган *урны* – урын, *борно* – борын, *килне* – килен, *сеңле* – сеңел сүзләрен дә кертеп карарга була. Әлеге формалар үзләренең әйтелешләрен тартым һәм килешләр белән төрләнгәндә дә саклыйлар: *урнысы* – урыны, *килнесе* – килене, *бороносо* – борыны; *урнының* – урынның, *урныдан* – урындан, *урныға* – урынга һ.б.; б) рус һәм Европа телләреннән кергән сүзләрдә: *белен* – блин, *жирәбә* –

жребий, *пыраулкы* – проволока, *пырадукты* – продукт, *перәме* – прямо, *зерә* – зря, *бериме* – время, *безәтке* – взятка һ.б.

**Элизия.** Сөйләштә сузык авазларга тәмамланган ике сүз чигендәге беренче сузыкның төшеп калуы да киң таралган. Бу очракта рәт гармониясе беренче сүз тәэсирендә барлыкка килә: *киләлмәде* – килә алмады, *ишетәлмәде* – ишетә алмады, *алалмады* – ала алмады, *баралмады* – бара алмады һ.б.

**Аваз төшү** күренешенең түбәндәге очраклары теркәлгән: *ләккән* – эләккән, *ләшмәйләр* – өләшмиләр, *дәшмәй* – эндәшми, *шану* – ышану, *йәңке* – иянке, *тирәз* – тәрәзә, *бөтәс түгел* – бөтәсе түгел. Традицион сөйләштә сузык авазларга тәмамланган рус сүзләрендә соңгы аваз гадәттә төшеп кала: *рам* – рама, *эрәкит* – ракета, *кәмфит* – конфета, *кәрт* – карта, *быригат* – бригада, *пихут* – пехота һ.б.

## Тартык авазлар системасы

Минзәлә сөйләшендә түбәндәге тартык авазлар кулланыла:

1, Ирен-ирен тартыклары: [б], [п], [м], [ф],[w].

2. Тел очы тартыклары: [т], [д], [с],[з], [d], [ш], [ж],[ч], [л], [р], [н].

3. Тел уртасы тартыгы: [й].

4. Тел арты тартыклары: [к], [г], [х], [ң].

5. Тирән тел арты (увуляр) тартыклары: [қ], [ғ], [х], [ң].

Тартык авазларның саны, сыйфаты ягыннан минзәлә сөйләше татар әдәби теле һәм урта диалектның нигез сөйләшләре булып саналган казан арты һәм тау ягы сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә. Сөйләшнең бу өлкәдәге аермалыгы итеп түбәндәге күренешләрне күрсәтеп китәргә мөмкин.

1. Татар әдәби теленә рус теле аша кергән [в], [ц], [щ] тартыклары сөйләшнең артикуляцион яктан бер-берләренә якын булган үз авазлары белән алмаштырылып әйтеләләр.

2. Гарәп алынмаларында гына әйтелә торган [h] тартыгы да әйтелми, системалы рәвештә төшереп калдырыла: *әр* – һәр, *әркем* – һәркем, *ичкем* – һичкем, *әwәс* – һәвәс, *өнәр* – һөнәр һ.б.

3. Минзәлә сөйләшенең тартык авазлар өлкәсендәге үзенчәлекле билгесе булып татар әдәби телендщге тел очы [з] тартыгының тел очы, йомык [d] тартыгы белән алмаштырылуын

әйтергә кирәк. Бу аваз артикуляцион һәм акустик сыйфатлары белән татар әдәби теленә бик якын, киресенчә, башкорт телендәге тел очы ярым йомык, өрелмәле [з] тартыгыннан аерылып тора. Төбәкне өйрәнгән галимнәрнең фикеренчә, сөйләшнең Татарстанның көнчыгыш, Башкортстанның көнбатыш өлешендә бу күренеш системалы төс ала[1]. Бу фикер безнең тарафтан 1968–1985, 1995–1999 елларда бу ике күрше республика районнарына оештырылган диалектологик экспедицияләр барышында тупланган материаллар белән дә раслана. Тел очы, йомык [d] тартыгы сүзнең башы, азагы, уртасында килә ала: *dур* – зур, *diрек* – зирек, *dәңгәр* – зәңгәр, *dифа* – зифа, *қаd* – каз, *баd* – баз, *сеd* – сез, *қыdыл* – кызыл, *боdоқ* – бозык һ.б.

Шуның белән бергә, кайбер очракларда тел очы, йомык [d] тартыгы сүз башында сузыклар алдында яки сузыклар һәм сонор тартыклар уртасындагы позициядә йомык, шартлаулы [д] урынына да кулланыла: *иdән* – идән, *боdай* – бодай, *йоdороқ* – йодырык, *барdың* – бардың, *туйdы* – туйды, *dару* – дару, *dәүләт* – дәүләт, *қаdай* – кадый, *қаdақ* – кадак, *наdан* – надан, *қоdағай* – кодагый, *өйdә* – өйдә, *йәрdәм* – ярдәм, *буйdақ* – буйдак. *Идел//Иdел//Изел, Фәриdә* – Фәридә, *Мәdинә* – Мәдинә һ.б. Рус алынмаларында: *суdйа* – судья, *миdал* – медаль, *аdиал* – одеало, *dайым* – заем, *dапас* – запас, *параwыd* – паровоз, *партиdан* – партизан һ.б.

Бу үзенчәлекнең изоглоссасы, [d] изоглоссасы белән тәңгәл килеп, әлеге территориядә изоглосса бәйләме барлыкка китерә. Ул, [d], тартыгыгы кебек, Татарстан һәм Башкортстан республикаларының чикләреннән үтеп, Әгерҗе, Мамадыш, тау ягы сөйләшләре аша Казан артына кадәр барып җитә.

Татар диалектлары системасында караганда, бу аваз минзәлә сөйләшенең генә үзенчәлеге түгел. Чөнки, татар диалектологиясе фәненә нигез салган күренекле галим Л. Җәләйнең әйтүенә караганда, тел очы [з] тартыгын [d] белән алмаштыру урта диалектның нигез сөйләше булган казан арты сөйләшләренең дә төп билгеләреннән саналган. Берничә гасыр татар әдәби теленең

[1] *Җәләй Л.* Татар диалектологиясе. – Казан, 1947. – Б. 38; *Баязитова Ф.С.* Мензелинский говор татарского языка // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 7. – Казань, 1989.– С. 69.

көчле тәэсирендә торган казан арты сөйләшләрендә әлеге тартык аваз үзенең элеккеге активлыгын югалта төшкән. Хәзерге вакытта ул өлкән буын сөйләмендә элеккегечә дип әйтергә була. Галимнең әйтүенчә, бу күренешнең изоглоссасы, Татарстанның минзәлә сөйләше таралган районнарның чигеннән чыгып, иске административ бүленеш буенча Красный Бор, Әгерҗе районнары аша Мамадыш, Теләче тирәләрен кичеп, Казан артының үзәге булган Арча һәм Әтнә районнарын үз эченә ала. Казан арты сөйләшләре төркемен узган гасырның икенче яртысында махсус өйрәнгән Н. Б. Борһанованың күзәтүләренә караганда, татар әдәби телендәге тел очы өрелмәле [з] тартыгын тел очы, йомык [d] авазы белән алмаштырып сөйләү бүгенге көннәрдә Казан арты төбәгенең көньяк-көнчыгыш өлешендә, бигрәк тә Мишә, Кама, Вятка елгалары тирәсендә урнашкан татар авылларында киң таралган[1]. Татар әдәби теленең көчле йогынтысына карамастан, татар халкы яши торган җирләрнең үзәге саналган Казан артында бу үзенчәлек иң тотрыклы диалекталь билгеләрнең берсе буларак кала бирә[2]. Мәктәп укучылары, авыл интеллигенциясе, хәтта Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты факультеты студентларының сөйләмендә бу авазның кулланылуы шул турыда сөйли. Димәк, бу үзенчәлек Татарстанның көнбатыш һәм көнчыгыш өлешләрен тоташтыра торган лингвистик билге булып тора. Моннан тыш, әлеге күренеш тау ягы сөйләшләре төркеменең норлат-кайбыч урынчылыгында да таралган[3]. Бу үз чиратында әлеге үзенчәлекнең татар халкы өчен тарихи яктан да уртак билге булуы турында сөйли. Н. Б. Борһанова Казан арты территориясендә [d] тартыгын куллануны бу якларга күчеп утырган болгарларга бәйләп аңлата[4].

---

[1] *Бурганова Н.Б.* О формировании татарских говоров Заказанья // К формированию языка татар Поволжья и Приуралья. – Казань, 1985. – С. 3.

[2] Шунда ук. – Б. 3–4.

[3] *Бурганова Н.Б.* Особенности говора татар Нагорной стороны ТАССР // Материалы по диалектологии. – Казань, 1955. – С. 47.

[4] *Бурганова Н.Б.* Из истории формирования фонетических особенностей татарских говоров Заказанья // Источниковедение и история тюркских языков. – Казань, 1978. – С. 84.

Минзәлә сөйләшендә кулланыла торган тел очы, йомык [d] тартыгын башкорт теленең йогынтысы нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип караучылар да булды. Ләкин аларның күпчелеге шул ук вакытта бу авазның артикуляцион һәм акустик яктан башкорт телендәге вариантыннан нык аерылып тора дип күрсәтеп узалар[1]. Күп кенә тикшеренүчеләрнең әйтүенчә, минзәлә сөйләшендәге [d] авазында йомыклык өстенлек итә. Ул үзенең әйтелеше белән тел очы йомык [д] тартыгына якын тора. Бу безнең күзәтүләр белән дә раслана. Шунлыктан булса кирәк, бу төбәктә яшәүче татарларның сөйләшен беренче булып өйрәнгән рус галимнәре А. Г. Бессонов һәм Н. Ф. Катанов бу авазның әлеге территориядә яшәүче татарлар сөйләшендә кулланылуы турында бер сүз дә әйтмиләр. Ләкин шул ук вакытта сөйләшнең төп билгеләренең берсе итеп [д], [з] авазлары арасындагы тәңгәллекләрне күрсәтеп узалар. Бу, безнең фикеребезчә, өрелмәле [з] тартыгының йомык [d] тартыгы белән алмашынуыннан килеп чыккан булырга тиеш.

И. С. Насипов исә бу аваз һәм аңа бәйле тәңгәллекләрне иран теле тәэсирендәге борынгы угыз диалектларыннан калган тарихи күренеш дип саный (Насипов, 1993, 56). Безнең фикеребезчә, минзәлә һәм казан арты сөйләшләрендә кулланыла торган тел очы, йомык [d] тартыгының барлыкка килү сәбәпләре уртак булырга мөмкин. Бу аваз, татар диалекты системасында беренче буларак, казан арты сөйләшләрендә болгар яки борынгы кыпчак телләренең тәэсирендә барлыкка килгән. Үз чиратында Идел болгарларына IX – X гасырларда килеп кушылган кыпчаклар бу чорларга кадәр шактый гына вакыт Уралда һәм Урал итәкләрендә яшәгәннәр. Тел очы [d] тартыгы белән сөйләшә торган кыпчак кабиләләренең бер өлеше башкорт халкының формалашуында да катнашкан дип санарга урын бар. Татар лингвистик территориясендә бу авазның Татарстан һәм Башкортстан республикаларының чик буйларыннан башлап, Казан артына кадәр тоташ массив булып баруы бу җирләрдә барган

[1] *Әфләтүнов Ә.Ш.* БАССРның көньяк-көнбатыш өлешендә яшәүче татар сөйләшләренең тел үзенчәлекләре: филол. фән. канд. ... дис. – Казан, 1960.

миграцион процессларның юнәлешен күрсәтеп тора. Казан ханлыгы чорында формалашып җиткән татар сөйләшләрендә бу үзенчәлек аларның төп билгеләренең берсе санала башлый. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, төрле эзәрлекләүләргә түзә алмаган татар халкының бик күп өлеше Казан артыннан көнчыгыш өлкәләргә кача. Татар халкының иң күп өлеше Казан ханлыгының көнчыгыш чикләре булып исәпләнгән Агыйдел, Ык, Сөн елгалары бассейннарына күчеп утыралар. Казан ханлыгы территориясендә формалашкан сөйләшләр бер-берләренә якын булганга, бирегә күчеп килүчеләрнең сөйләшләре дә нигездә зур үзгәрешләргә дучар ителми. Шулай итеп, яңа җирләргә килгәннән соң да, казан арты татарларының [а] авазын иренләштереп әйтү, татар әдәби телдәге тел очы, өрелмәле [з] тартыгы урынына тел очы йомык [d] тартыгын куллану үзенчәлекләре саклanып кала. Идел буйларында яшәүче болгарлар сөйләшенә Урал итәкләреннән күчеп килгән төрки кабиләләр теленнән кергән [d] авазы бик күп гасырлардан соң яңадан әлеге халыкларның тарихи ватаннарына әйләнеп кайта. Минзәлә сөйләшендә тел очы, йомык [d] тартыгының тотрыклы кулланылуын югарыда китерелгән тарихи сәбәпләр белән аңлатып була.

Шулай да татар әдәби теленең соңгы еллардагы көчле тәэсире нәтиҗәсендә тел очы [d] тартыгын куллануның активлыгы шактый кимегәнлеге турында әйтеп китәргә кирәк. Кайбер белгечләрнең әлеге күренешне күрше башкорт теле йогынтысы дип исәпләүләренә карамастан, Башкортстан территориясенә эчкәрәк кергән саен, тел очы, йомык [d] тартыгын куллану азайганнан-азая бара[1] (Рамазанова; Насипов, 1993, 56). Сөйләшнең бәләбәй урынчылыгында исә бу үзенчәлекле тартык аваз сирәк-мирәк кенә күзәтелә башлый.

Югарыда күрсәтелеп узган үзенчәлекләр белән бергә сөйләштә тел очы, йомык, шартлаулы [д] тартыгын тел очы өрелмәле [з] авазы белән әйтеп сөйләү дә киң таралган, Минзәлә сөйләшен өйрәнүчеләр бу күренешне сөйләшнең төп билгелә-

[1] *Рамазанова Д. Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – С. 88.

реннән саныйлар[1]. Л. Т. Махмутова ни өчендер бу күренеш турында сөйләми[2]. Д. Б. Рамазанова да аңа махсус тукталмый. Татарстан һәм Башкортстан республикаларының күрше районнары әлеге изоглоссаның үзәге булып санала. Биредә бу тәңгәллек чагыштырмача күп сүзләрне үз эченә ала: *назан* – надан, *бозай* – бодай, *изән* – идән, *қазақ* – кадак, *киләлмәзе* – килә алмады, *бирзе* – бирде, *изе* – иде, *Ағыйзел* – Агидел, *Ғазилә* – Гадилә, *Замирә* – Дамира, *Мизхәт* – Мидхәт һ.б.; рус теленнән кергән алынмаларда: *бизрә* – рус. ведро, *разийу* – радио, *азийал* – одеало, *зайаркы* – доярка, *узарник* – ударник, *запрус* – допрос, *быригазир* – бригадир һ.б.

Бәләбәй урынчылыгы бу изоглоссаның тирбәлеш зонасын тәшкил итә. Д. Б. Рамазанова хезмәтендә бу күренешнең махсус чагылмавы шушы сәбәпләр белән аңлатыла. Гадәттә, изоглоссаның тирбәлеш зонасында бер үк күренеш төрле вариантларда булуын күзәтергә мөмкин. Сөйләшнең күп кенә урынчылыкларында тел очы [d], [д], [з] тартыкларының тәңгәллеген чагылдырган фонетик вариантларның параллель кулланышы да очрый: *қаdақ//қадақ//қазақ, идән//изән//иdән, Мәдинә//Мәзинә//Мәdинә, Фәридә//Фәризә//Фәриdә* һ.б.

Тел очы, йомык, шартлаулы [д] тартыгын өрелмәле [з] авазы белән алмаштырып әйтү ягыннан да минзәлә сөйләшенең урта диалектның нигез сөйләшләре белән генетик уртаклыгы күренә. Бу изоглосса Казан арты, Мамадыш тирәләре аша Урал итәкләренә кадәр барып җитә. Димәк, [д], [з] тәңгәллеген дә татар телендә борынгыдан ук яшәп килгән, Казан ханлыгы

---

[1] *Бессонов А. Г.* О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам // Журнал Министерства народного просвещения : Ч. CCXVI. СПб., 1881. – С. 58–74; *Катанов Н. Ф.* Отчет о поездке, совершенной с 20 мая по 20 августа 1898 г. в Белебеевский уезд Уфимской губернии // Уч. зап. имп. Казан-го Унта. Кн. 7, 8. – Казань, 1900. – С. 1–30; *Җәләй Л.* Татар диалектологиясе. – Казан, 1947. – Б. 38–39; *Баязитова Ф.С.* Мензелинский говор татарского языка // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 7.– Казань, 1989. – С. 69.

[2] *Махмутова Л. Т.* О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР (по материалам экспедиции 1954–57 гг.) // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. – Казань, 1962. – С. 57–85.

җимерелгәннән соң кабаттан шул ук территориядә активлашып киткән тарихи күренеш итеп карарга тулы нигезебез бар.

**[ч] һәм [җ] тартыкларының әйтелеше** буенча да минзәлә сөйләше татар әдәби теле һәм Казан ханлыгы чикләрендә формалашкан казан арты, тау ягы сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә. Тел очында ясала торган саңгырау [ч], яңгырау [җ] тартыклары татар әдәби телендәге кебек бер фокуслы, өрелмәле (аффрикат түгел!) итеп әйтеләләр. Сөйләштә бер генә сүздә тел очы өрелмәле [ч] тартыгын [с] белән алмаштырып әйтү бар: *әтәс.* Бу күренеш бер генә сүз белән чикләнсә дә, ул сөйләшнең төп билгеләреннән саналып килә. Әлеге изоглоссаның үзәге булып Татарстан һәм Башкортстан республикалары очрашкан районнар санала. Көнчыгыш тарафка киткән саен әлеге күренешнең активлыгы кими бара. Туймазы, Ярмәкәй, Бәләбәй районнарындагы татар авыллары югарыда күрсәтелгән изоглосаның сүнү зонасын тәшкил итәләр. Шунысы кызыклы: *әтәч* сүзен *әтәс* рәвешендә әйтү бу яктагы кайбер мишәр авылларына кадәр үтеп кергән. Бу үзенчәлеге белән минзәлә сөйләше татар сөйләшләре арасында аерым урын тота. Татар диалект системасында бу күренеш билгеле төркем сүзләрне эченә ала яки системалы күзәтелә торган сөйләшләр барлыкка китерә. Мәсәлән, казан арты-дөбьяз сөйләшендә ул билгеле сүзләрдә һәм грамматик формаларда гына күзәтелә, златоуст, сафакүл сөйләшләрендә, шулай ук красноуфим сөйләшенең аерым урынчылыгында исә ул системалы төс ала. Бү күренеш башкорт теле чолганышында булган сөйләшләргә хас, шунлыктан башкорт теленең йогынтысында барлыкка килгән дип санала. Минзәлә сөйләшендә бары тик бер сүздә генә теркәлгән [ч]~[с] тәңгәллегенең сәбәбе хәзергә көндә әле ачыкланмаган.

Рус теленнән кергән сүзләрдә, киресенчә [с]~ [ч] тәңгәллеге күзәтелә: *читса* – ситса (ситец), *чилсәwит* – сельсовет, *чичтра*// *чистра* – сестра, *чимийа* – семья, *чиннек* – сенник, *чүченкә* – чесанки, *бич* – весь, *чилом* – силом, *Чучи* – Сочи һ.б.

**Җеләштерү күренеше.** Тел очы, өрелмәле, бер фокуслы [җ] тартыгын сүз башында актив куллануга яки бу тартыкны тел уртасы палаталь [й] сонанты белән алмаштыруга карап,

татар диалекларын һәм сөйләшләрен *җеләтерүче* яки *йеләтерүче* сөйләшләргә бүлеп карыйлар. Урта диалектның нигез сөйләшләрендә сүз башы позициясендә [й] тартыгын системалы рәвештә [ж] авазы белән алмаштырып сөйләгәнгә күрә, бу диалектны *җеләштерүче* диалект дип тә атап йөртәләр. Минзәлә сөйләше бу яктан да беренче чиратта казан арты һәм тау ягы сөйләшләре төркеменә бик якын: *җил, җиз, җиләк, җәшел* – орф. яшел, *җәтим* – ятим, *җорт* – йорт, *җәрдәм* – ярдәм, *җылан* – елан, *җырақ* – ерак, *җылақ* – елак, *җар* – яр, *җақа* – яка, *җақшы* – якшы, *җасаған* – ясаган, *җаңғыр* – яңгыр, *җафрақ* – яфрак, *җаман* – яман, *җаңғыз* – ялгыз, *җарату* – ярату, *җаwыз* – явыз, *җарма* – ярма, *җаман* – йаман, *җомшақ* – йомшак, *җомочқа* – йомочка, *җоморқа* – йомырка һ.б. Ләкин бу үзенчәлек минзәлә сөйләше таралган территориянең барлык өлешендә дә бер үк дәрәҗәдә күзәтелми.

Сүз уртасында: *берҗулы* – берьюлы, *алҗапкыч* – алъяпкыч, *арҗақ* – аръяк һ.б.

Алынма сүзләрдә: *җан, җафа, җаwап* – җавап, *җанwар* – җанвар, *мөрҗә* – моржа, *дөнҗа* – дөнья, *симҗә*//*семҗә* – семья, *сабранҗа* – собрание, *фамилҗә* – фамилия, *wаринҗа* – варенье, *направлинҗа* – направление, *назбанҗа* – название, *личинҗә* – лечение, *заданҗа* – задание, *пичинҗә* – печенье һ. б.

Җеләштерү аеруча Татарстан һәм Башкортстан республикаларының чик буе районнарында урнашкан татар авыллары өчен хас. Әлеге төбәктә яшәүчеләрнең сөйләмендә [й] тартыгын [ж] авазы белән әйтү алынма сүзләрдә, сүз уртасындагы позицияләрдә дә киң таралган: Биредә [ж]//[й] билгеле төркем сүзләрдә генә күзәтелсә, сөйләшнең көнчыгыш чикләрендә [ж] һәм [й] тартыкларын параллель куллану тотрыклы төс ала: *җә*//*йә* – ымлык, *җеп*//*йеп* – җеп, *җитен*//*йитен* – җитен, *җақын*//*йақын* – якын, *җақты*//*җақты* – якты, *җул*//*йул* – юл, *җәшел*//*йәшел* – яшел, *җибәрү*//*йибәрү* – җибәрү, *җиләс*//*йиләс* – җиләс, *җимеш*//*йимеш* – җимеш, *йан*//*җан* – ян, *җаwап*//*йаwап* – җавап, *мәлҗерәү*//*мәлйерәү* – мәлҗерәү, *җуwаш*//*йуwаш* – юаш, *фамилийә*//*фамилҗә* – фамилия һ.б.

Бу яктан минзәлә сөйләшенең Уралда таралган красноуфим, пермь, златоуст сөйләшләре белән уртаклыгы булуын да әйтеп китәргә кирәк.

Әлеге тартык авазларны бер үк шартларда параллель куллануның сәбәбе итеп Д. Б. Рамазанова бу төбәктә урта һәм мишәр диалектларының күп гасырлар буенча үзара тәэсир итешеп яшәүләрен исәпли. Күп кенә авылларда бүгенге көнгә кадәр мишәр очлары яшәп килә. Билгеле булганча, 1845 елга кадәр бередә яшәүче татарлар һәм мишәрләр бер үк административ үзәкләргә – мишәр кантонына караганнар. Д. Б. Рамазванова бу күренешнең башкорт теленең йогынтысында барлыкка килүен дә инкяр итми[1].

Безнең фикеребезчә, татар лингвистик киңлекләрендә [җ] һәм [й] тартыкларын параллель куллануның сәбәбе итеп *җеләштереп* сөйли торган төбәкнең *йеләштереп* сөйли торган лингвистик ареалның (Себер татарлары диалекты, башкорт теле) көнбатыш чикләрендә таралуы белән аңлатыла. Кайчандыр бу җирләр Себер ханлыгының Казан ханлыгы белән очрашкан көнчыгыш чикләре булып саналган. Билгеле булганча, Себер татарларының тобол-иртыш диалекты татар теленең *йеләштереп* сөйли торган диалектлар төркеменә карый. Моннан тыш, минзәлә сөйләшендә себер татарлары белән уртак булган башка үзенчәлекләр дә күзәтелә.

Кайбер урынчылыкларда, аерым алганда Илеш һәм Дүртиле районнарында, берничә сүздә генә булса да [җ] тартыгы [з] авазы белән алмаштырып әйтелә: *кәзә* – орф. кәҗә, *Зәләй*//*Зәләли* – Җәләлетдин, *Тәзәй* – Таҗи (авыл исеме).

[л] тартыгының әйтелеше. Минзәлә сөйләше [л] тартыгын артык нечкәртеп (палатальләштереп) әйтү ягыннан урта диалект сөйләшләре арасында аерым урын алып тора. Бу үзенчәлек сөйләшнең Башкорстан белән чиктәш булган Сарман, Мөслим, Актаныш районнарының кайбер авылларында күзәтелә. Сөйләштә кулланыла торган калын һәм нечкә [л] вариантларыннан аерма-

---

[1] *Рамазанова Д. Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – С. 89.

лы буларак, бу вариант, аерым сүзләрдә генә кулланылып, арткы рәт сузык авазлар уртасында палаталь (артык нечкә әйтелешле) тартык аваз итеп әйтелә: *мал'ай* – малай, *бал'а* – бала.

Шунысы гаҗәп: минзәлә сөйләшен шактый җентекле өйрәнгән тикшеренүчеләр хезмәтләрендә бу күренеш ни өчендер чагылыш тапмый.

Күпчелек татар сөйләшләрендәге кебек үк, минзәлә сөйләше өчен дә гарәп, фарсы телләреннән кергән фарингаль [һ] тартыгы хас түгел, күп кенә очракларда, аеруча өлкән буын кешеләрнең сөйләмендә ул гомумән әйтелми яки сөйләшнең үз авазы булган [х] тартыгы белән алмаштырыла: *әм* – һәм, *әр* – һәр, *уш* – һуш, *әммә* – һәммә, *өнәр* – һөнәр, *ич* – һич, *аман* – һаман, *аwа* – һава, *әwәс* – һәвәс, шәхәр – шәһәр, *Шәйдә* – Шәһидә, *Шийап* – Шиһап, *Фәймә* – Фәһимә, *Шәwәли* – Шаһвәли, *Миннеша* – Миңнешаһ, *Әдийә* – Һәдия, *Хажҗирә* – Һаҗирә һ.б.

Сөйләштә рус һәм Европа телләреннән кергән ирен-теш [в] тартыгы шулай ук традицион сөйләш вәкилләре тарафыннан кулланылмый, артикуляциясе якын булган башка тартыклар белән алмаштырылып әйтелә: *сәwит* – совет, *wәйәннәй* – военный, *wылас* – власть, *wагун* – вагон, *wиннек*//*биннек* – веник, *браш* – врач, *бур* – вор, *бич* – весь, *бидрә* – ведро, *әтбит* – ответ, *кәмбирт* – конверт, *бинтофка* – винтовка, *мирмишил* – вермишель һ.б.

Татар теленең үз сүзләрендә әйтелә торган ирен-ирен өрелмәле [ф], рус теле аша кергән сүзләрдә кулланыла торган иренteш [ф] тартыклары да сөйләш өчен хас түгел, өлкән буын вәкилләре тарафыннан нигездә ирен-ирен йомык, шартлаулы саңгырау [п] тартыгы белән алмаштырыла. Шуның белән беррәттән алынма сүзләрдәге ирен-ирен [п] тартыгын, киресенчә, ирен-теш [ф] тартыгы белән алмаштырып сөйләү сөйләш вәкилләренең [ф] тартыгын фонема буларак аермаулары турында сөйли: *йапраķ* – яфрак, *тупраķ* – туфрак, *керпек* – керфек, *пәйда* – файда, *панар* – фонарь, *кәмпит* – конфет, *Нәписә* – Нәфисә; *фәрдә* – пәрдә, *сифаратыр* – сепаратор, *фарты* – парта, *фатнус* – поднос, *фартфил* – портфель, *фамидур* – помидор һ.б.

Югарыда сөйләп үтелгән күренешләрдән тыш, минзәлә сөйләшен татар теленең башка, аерым алганда, урта диалект сөйләшләре белән якынайта торган түбәндәге тәңгәллекләр булуын да күрсәтеп китәргә кирәк. Алда санап узылган үзенчәлекләрдән аермалы буларак, бу тәңгәллекләр, мәҗбүри булмаган хәлдә, чикләнгән күләм сүзләрдә генә күзәтелә. Аларның сөйләштә таралышы да төрлечә, урынчылыкларга карап, аларның саны да төрлечә булырга мөмкин:

а) татар әдәби теле һәм татар сөйләшләрендәге кебек, [б] тартыгы ирен-ирен, йомык, шартлаулы, яңгырау тартык булып әйтелә. Ул сүзнең барлык позицияләрендә килә. Ләкин, татар теленең орфоэпик нормаларыннан аермалы буларак, бу тартык авазның, ике сузык аваз уртасында килгәндә, шартлау көче шактый кими. Нәтиҗәдә ул ике фокуслы авазга якын, ягъни шартлаулы [б] һәм өрелмәле [w] авазларына якын торган тартык аваз итеп әйтелә: *таб*$^{w}$*а* – таба, *каб*$^{w}$*а* – қаба, *киб*$^{w}$*ә* – кибә, сиб$^{w}$ә – сибә һ.б.

Ирен-ирен йомык, шартлаулы [б] тартыгын, күпмедер дәрәҗәдә спирантлаштырып әйтү ягыннан минзәлә сөйләше Көнбатыш Себер татарлары диалектлары белән уртаклык күрсәтә. Билгеле булганча, Себер татарлары сөйләмендә [б] тартыгы югарыда күрсәтелгән шартларда системалы рәвештә өрелмәлелек төсмере белән әйтелә[1];

ә) татар әдәби теле һәм урта диалектның нигез сөйләшләрендәге кебек, [б] тартыгына тәмамланган тамыр сүзләргә *-ып, -еп* формалы хәл фигыль кушымчалары ялганганда: [w] тартыгы белән чиратлаша: *таwып* – табып, *қаwып* – кабып, *чаwып* – чабып һ.б.

Чикләнгән күләм сүзләрдә генә ирен-ирен, йомык, шартлаулы [б] сөйләштә түбәндәге авазлар белән тәңгәлләшеп килергә мөмкин: ирен-ирен йомык, шартлаулы [б] һәм ирен-ирен, йомык сонант [м] тәңгәллеге: *мәке* – бәке, *мөрө* – бөре, *малан* – балан, *майтақ* – байтак, *қорман* – корбан, *мөкөрө* – бөкере, *мышый* –

---

[1] *Тумашева Д.Г.* Көнбатыш Себер татарлары теле (грамматик очерк һәм сүзлек). – Казан, 1961. – 240 б.

пошый. [б]~[м] тәңгәллеге Бәләбәй урынчылыгы таралган барлык территориядә дә кулланыла. Башлангыч [б] тартыгы белән әйтелә торган вариант (*бөрө, бәке*) Туймазы һәм Бәләбәй районнары өчен хас. Шунысына да игътибар итәргә кирәк: бу вариантның таралышы «әтәс» әйтелешенең изоглоссасына туры килә, көньяк-көнчыгыш тарафка киткән саен, [м] варианты активлаша бара[1].

Татар диалектологиясендә [б] ~ [м] тәңгәллеге нигездә мишәр диалекты өчен хас дигән фикер урнашкан[2]. Бу яктан минзәлә сөйләше аеруча урта диалектның Уралда таралган сөйләшләре, аерым алганда красноуфим, нагайбәк, сафакүл, пермь сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә[3]. Бу үзенчәлек санап үтелгән сөйләшләрдә, шул исәптән минзәлә сөйләшендә дә, мишәр субстраты нигезендә барлыкка килергә мөмкин, чөнки бу төркемнәрнең күпчелеге күпмедер дәрәҗәдә мишәр этносы катнашуында формалашалар. Икенчедән, әлеге сөйләшләрдә озак гасырлар буе Себер татарлары белән аралашып яшәү нәтиҗәсендә көнчыгыш диалект белән уртак билгеләр дә барлыкка килгән. Билгеле булганча, Себер татарлары сөйләшләрендә [б] ~ [м] тәңгәллеге күбрәк сүзләрне үз эченә ала.

Сирәк кенә булса да аерым кешеләрнең сөйләмендә яңгырау [б] һәм саңгырау [п] тартыклары арасындагы тәңгәллекләр күзәтелә: а) *пер* – бер, *пот* – бот, *пел* – бел, *пара* – бара, *путқа* – ботка, *потақ* – ботак, *пөтөн* – бөтен, *пулыш* – булыш; сүз уртасында: *Ғаптул*//*Ғаптулла* – Габдулла, *кәпестә* – кәбестә, *сеперү* – себерү, *түпәләм* – түбәләм һ.б.

---

[1] *Рамазанова Д. Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – С. 90.

[2] *Борһанова Н. Б.* Татарларның Мордва АССР территориясендә таралган сөйләшләре турында // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. – Казань, 1962. – С. 99; *Махмутова Л. Т.* Основные характерные черты мишарских говорах на террритории Пензенской области // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. – Казань, 1962. – С. 130; *Арсланов Л. Ш.* Татарские говоры правобережных районов Татарской и Чувашской АССР: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1966. – С. 57.

[3] *Юсупов Ф. Ю.* Татар теленең диалектлары. Урал сөйләшләре. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 34, 204, 246, 303.

Татар әдәби телендәге ирен-ирен, өрелмәле [w] тартыгын бер төркем сүзләрдә генә ике сузык аваз уртасында ирен-ирен, йомык, шартлауды [б] авазы белән әйтү бар: тамыр сүзләрдә: *чобар* – орфэп. чуwар, *чобан* – чуwан, *чобалу* – чуwалу, *җобат* – орфоэп. йуwат, *батылды* – орфоэп. wатылды.

**[б]~[w]:** *кеwек* – кебек.

**[т]~[д]**: *Маматыш* – Мамадыш, *тары//дары* – тары, *ти* – ди, *тулқын* – дулкын, *төбөрти* – дөберди, *пытыртау* – бытырдау; шулай ук: *дүшәм* – түшәм, *дигәнәк* – тигәнәк, *сандый* – сантый, *дүңгәк* – түмгәк һ.б. [т] һәм [д] тартыкларының саңгыраулашу һәм яңгыраулашу ягыннан тәңгәллеге – чикләнгән күләм сүзләрдә татар теленең күп кенә сөйләшләрендә очрый торган күренеш.

**[г]~[к]:** *гөпшә* – көпшә, *чикә* – чигә, *чигерткә* – чикерткә, *тәлкәш* – тәлгәш, *сеңкер* – сеңгер, *сискер* – сизгер, *чикерү* – чигерү; *катырқы* – катыргы.

**[н] һәм [м]** сонор тартыклары арасындагы тәңгәллекләр түбәндәге сүзләрдә күзәтелә: *үләм* – үлән, *чормау* – чорнау, *йаwын//йаwын* – явым, *агым//агын* – агым, *падмус* – поднос, *кәмпит* – конфет; шулай ук: *барнақ* – бармак.

**[л]~[н]:** *тешнәү* – тешләү, *җондоз* – йолдыз, *нәзәтле* – ләззәтле, *қатнау* – катлау.

**[н]~[к]:** *искәү* – иснәү.

**[к]~[х]:** *йақшы* – яхшы, *қатын* – хатын, *эрәқмәт* – рәхмәт, *Қапис* – Хафиз; *хәдәр* – кадәр, *wахыт* – орфоэп. wакыт, *хәрендәш* – каренләш, *хәләмфер* – канәфер, *кутор* – хутор.

**[т]~[к]:** *җикмеш* – җитмеш; *читләwек//читлаwық* – чикләвек, *итмәк* – икмәк, *өстөйақ* – өске як.

**[ш]~[ч]:** *ачаулық* – ашъяулык.

**[н]~[р]:** *үткер* – үткен.

**[л]~[ң]:** *суң йақ* – сул як.

**[ң]~[й]:** *мийа* – миңа, *сийа* – сиңа.

**[р]~[з]:** *йатқыз//йатқыр* – яткыр, *җапқыз//җапқыр* – яптыр, *менгер//менгез* – менгер, *үткәр//үткәз* һ.б.

## Тартык авазлар өлкәсендәге комбинатор үзгәрешләр. Ассимиляция күренешләре

1.Урта диалектның күпчелек сөйләшләрендәге кебек үк, сүз һәм иҗек азагында килгән тел очы [н] сонанты ирен-ирен [м], [б] сонантлары алдында килгәндә, тулы кире ассимиляциягә дучар була, ягъни [м] авазына әйләнә: а) ике сүз янәшәлегендә: *көмбағыш*//*гөмбагыш* – көнбагыш, *җамбашы* – янбашы, *хаммәчете* – хан мәчете, *умбер* – унбер, *умбиш* – унбиш, *сиксәмбер* – сиксәнбер, *ум бала* – ун бала, *тум бар* – тун бар, *болом буйлап* – болын буйлап, *ишеткәм бар* – ишеткән бар, *беткәммикән* – беткән микән, *көм буйы* – көн буе, *қайтқам бер кеше* – кайткан бер кеше, *моннам былай* – моннан болай, һ.б.; ә) билгесез үткән заманның беренче зат берлек санында, шулай ук бу форманың сорау һәм юклык формаларында: *барғаммы* – барганмы, *барғаммын* – барганмын, *алғаммы* – алганмы, *алғаммын* – алганмын, *барғамбыз* – барганбыз, *җатқамбыз* – ятканбыз, *килгәмме* – килгәнме, *килгәммен* – килгәнмен; *ышамай* – ышанмый, *қымшаммай* – кымшанмый, *суwыммай* – суынмый, *күреммәй* – күренми, *белеммәй* – беленми һ.б.; б) боерык фигыльнең юклык формасында: *шатламма* – шатланма, *болғамма* – болганма, *ышамма* – ышанма, *сызламма* – сызланма, қыламма – кыланма, *сүреммә* – сүренмә, *күреммә* – күренмә, *тибеммә* – тибенмә һ.б.

2. Тамыр яки нигез азагындагы [м], [н], [ң] сонантлары *-лы, -ле; -ла, -лә, -лык, -лек* кушымчаларындагы [л] сонантын [н] итеп охшашландыралар: *йәмне*//*җәмн*е – ямьле, *тәмне* – тәмле, *күнне* – көнле, *җүнне* – юньле, *җәннек* – җәнлек, *көннәшә* – көнләшә, *аңнаша* – аңлаша, *печәннек* – печәнлек, *урманнық* – урманлык, *тийеннек* – тиенлек һ.б.

3. Түбәндәге сүзләрдә саңгырау [ч], [с] тартыклары, [ш] авазы алдында килеп, тулы регрессив ассимиляциягә бирелләләр: *шаршау* – чаршау, *шуғыш* – сугыш, *шыршы* – чыршы, *шебеш* – чебеш, *шишмә* – чишмә, *шәшке* – чашка һ.б.

Ассимиляциянең югарыда күрсәтелеп үтелгән төрләре урта диалекның сөйләшләрендә еш очрый торган күренешләрдән санала. Бу яктан да минзәлә сөйләшенең казан арты, тау ягы, бәрәңге сөйләшләре белән генетик якынлыгы күренә.

4. Сирәк кенә булса да бер төркем сүзләрдә тел очы, йомык [d] авазы үзеннән соң килгән йомык, шартлаулы [д], шулай ук ярым-йомык [л] сонантын тулысынча охшашландыра. Моңа бу авазларның артикуляцион яктан якын булулары сәбәп була: *сыddай* – сызлый, *тоddай* – тозлай, *боddай* – боздай, *қыddа* – кызда, *туғыddа* – тугызда, *қыddан* – кыздан, *йырлайсығыd da* – җырлыйсыз да, *күd тиgeddем* – күз тидердем, *йатқыddым* – яткырдым, *йаddым* – яздым, *барыбыd da* – барыбыз да, *биddерde* – биздерде, *беddә* – бездә, *беddән* – бездән һ.б.

б) тел очы [л], [н] сонантлары тирән тел арты [қ],[ғ], тел арты [к], [г] тартыклары алдында килгәндә, аларга ясалу урыннары буенча охшашланалар: *җаңғыз* – ялгыз, *җаңғыш*//*җаңыш* – ялгыш, *салқыңға* – салкынга, *булғаңға* – булганга, *болоңға* – болынга, *қачаңға* – кайчанга, *қачаңғы* – кайчангы ,*күтәреңке* – күтәренке, *чөңки* – чөнки, *әңки* – әнки (кайнана), *күргәңгә* – күргәнгә, *белгәңгә* – белгәнгә һ.б.

**Аваз төшереп калдыру**

1. Интервокаль позициядә яңгырау [ғ], [г] тартыклар еш кына төшеп калалар, нәтиҗәдә күршедәш бер төрле сузыклар, берләшеп, озын итеп әйтеләләр: *чып*//*чыып китте* – чыгып китте, *ти* –теге, *теп*//*теeп пир* – тегеп бир, *нийә* – нигә, *түwел* – түгел, *йуwалу* – йугалу һ.б.

2. Бертөрле ике сузык аваз арасында (интервокаль) шартларда тел уртасы, палаталь [й] сонанты үзеннән соң килгән сузык аваз белән бергә төшеп кала: *тин* – тийен (тиен), *тип қалды* – (тийеп) тиеп калды, *җип алды* – (җыйып алды) җыеп алды, *сирчеқ*//*сирчық* – (сыйырчык) сыерчык.

3. Тел очы [л] сонантының төшеп калуы: *ниши* – ни эшли, *нишәтә* – ни (нәрсә) эшләтә, *көчәп* – көчләп, *итә* – илтә; *алып* фигыле белән ясалган тезмә фигыльләрдә *-лы* иҗеге төшеп кала: *апқуй* – алып куй, *апчық* – алып чык, *апкил* – алып кил, *аптөш* – алып төш, *апмен* – алып мен һ.б.

4. Түбәндәге очракларда тел уртасы палаталь [й] сонанты төшеп кала: *қасы* – кайсы, *қачан* – кайчан, *қачаңғы* – кайчангы,

*кан* – кайан – каян, *қасы* – кайсы, *бик түбә* – бийек түбә, *қачы* – кайчы, *қанап чықты* – кайнап чыкты һ.б.

5. Тел очы [н] сонантын төшереп калдыру түбәндәге сүзләр өчен хас: *қачқы* – качкын, *асат* – ансат, *мунча//муча* – мунча, *мучала* – мунчала, *оттом* – оныттым, *тағы* – тагын, *нидәй* – нинди, *әлләйчә* – әллә ничә, *белә* – белән, *микә* – микән.

6. Калтыраулы [р] сонантын киләчәк заман хикәя фигыльнең беренче зат берлек һәм күплек формаларында еш кына төшереп калдыру киң таралган: төшеп калган тартыктан соң килгән сузык аваз, гадәттә, озын итеп әйтелә: *барым* – барырмын, *барыс* – барырсыз, *торымын* – торырмын, *бором* – борырмын, *боробыс* – борырбыз, *торобыс* – торырбыз, *керем* – керермен, *биремен* – бирермен, *себерем* – себерермен һ.б.

7. Икеләтелгән тартыкларның кыскаруы күзәтелә: нн > н: *төнә* – төннә, *анары* – аннары, *анан* – аннан, *кигәнәр* – кигәннәр, *тигәнәр* – дигәннәр, *биргәнәр* – биргәннәр; тт > т: *қайты* – қайтты, *бетеме* – беттеме; кк > к: *чықан* – чыккан, *җикән* – җиккән; мм > м: *әмәсе* – һәммәсе; лл > л: *теләнү* – телләнү[1].

8. Иҗекләр төшеп калу очраклары: *иләшү* – ийәләшү (ияләшү), әлсә – алайса.

## Аваз өстәү күренешләре

1. Урта диалектның Урал төбәгендә таралган башка сөйләшләрендәге кебек үк, борынгы [рт] тезмәсе түбәндәге сүзләрдә сакланган: *қычыртқан//кечерткән* – кычыткан, *шартлану* – шатлану, *қортлау* – котлау, *себертке* – себерке, *йомортқа* – йомырка, *чыбыртқы* – чыбыркы, *кәбәрткә* – кәбәркә.

2. [ғ], [г] тартыкларын өстәп сөйләү: *шуңғынчы//шуңынчы* – шуңа кадәр, *оңғай//ыңғай* – уңай, *җиңгү* – җиңү, *җиңгел* – җиңел.

[1] *Әфләтүнов Ә.Ш.* БАССРның көньяк-көнбатыш өлешендә яшәүче татар сөйләшләренең тел үзенчәлекләре: филол. фән. канд. ... дис. – Казан, 1960. – Б. 91.

## АТА-БАБАДАН КАЛГАН

### **Йолалар һәм көнкүреш үзенчәлекләре: этнолингвистик аспект**

*Флера Баязитова*

Халык йолаларын, йола терминологиясен өйрәнү-тикшерүдә төп таяныч – халык хәтере, халык теле. Ә татар халкы һәм аның тарихи хәтере дигәндә, без беренче чиратта телне һәм гореф-гадәтләрне саклауда иң зур тотка булган авылны һәм авыл халкының телен күз алдында тотабыз. Авыл – шәһәрнең анасы диләр, чөнки ул шәһәрне матди яктан гына түгел, рухи яктан да туендырып тора. Авыл хәтере безгә халыкның үзенә генә хас булган аң-күңел тарихын, кабатланмас тормыш чынбарлыгын, гасырлар тирәнлегеннән килгән борынгы сүз һәм йолаларын китереп җиткерә.

Йола терминологиясе, гадәттә, ике төркемгә аерып өйрәнелә: *гаилә йолалары* һәм *ел фасыллары белән бәйле йолалар, бәйрәмнәр терминологиясе.* Билгеле, бу бүленеш шартлы, чөнки халык йолалары берсенә берсе керешеп, бер-берсен тулыландырып «яшиләр».

Гаилә йолалары, үз чиратында кеше тормышындагы әһәмиятле борылышларга бәйләп, түбәндәгечә төркемләнә: *туй йолалары; бала туу белән бәйле йолалар; адәм баласын соңгы юлга озату, искә алу йолалары.*

Халкыбыз элек-электән гаилә төзүгә, гаилә абруен, әхлакны саклауга зур җаваплылык белән караган. Шул рәвешле, аның ил, җәмгыять каршында үтәлергә тиешле әдәп-әхлак нормалары, гадәт-йолалары барлыкка килгән.

Ел фасыллары белән бәйле йолалар, борынгы ышанулар (мифология) һәм аларга караган сүзләр тематик яктан берләштереп өйрәнелә: *кышкы, язгы-җәйге йолалар һәм бәйрәмнәр, өмәләр, аулак өйләр, утырмалар; мифология, борынгы ышанулар; ырымнар һәм им-томнар.*

Ел фасылларына караган йолалар табигатькә, ел тәүлегенең үзгәрешенә бәйле. Игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнгән авыл кешеләренең бергәләп үткәрелә торган бәйрәмнәре һәм йолалары да кояш нурларына һәм көн җылынуга, үләннәр, агачлар яшәрүгә, табигатьнең яңаруына шатлану тойгысы белән тулы.

Йола терминологиясе бер яктан тел хәзинәсе булса, икенче яктан аны халыкның рухи көзгесе, борынгылыкның хәзерге көннәргә килеп җиткән тамырлары дип әйтергә мөмкин. Дөрес, бүгенге авылларда, иҗтимагый һәм сәяси сәбәпләр аркасында, халык йолалары чылбырының кайбер буыннары җуелган. Шуның өчен безнең алда рухи культураның борынгы катламын – югалып бетү алдындагы тел һәм йола байлыгын, мөмкин булганча, яңадан торгызу бурычы тора.

Җәмгыятебездә соңгы елларда бара торган үзгәрешләр (халкыбызның милли үзаңы уяну, татар теленең республикабызда дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелүе һ. б.) мәктәпләр һәм укытучылар алдына халык йолаларын, гаилә этикасын яшь буынга кече яшьтән үк төшендереп, балаларны буыннар бәйләнеше өзелмәслек итеп тәрбияләү бурычын күтәрде.

Йолалар халык тарихы белән тыгыз бәйләнештә яши. Телсөйләм кебек үк, халыкның рухи культурасы да җирле үзенчәлекләр белән байый. Шуңа да ул әлеге төбәктә яшәгән халыкның җанына якын, кадерле һәм изге.

Актаныш төбәге авылларындагы җирле сөйләшләрдә йолаларга караган сүз-төшенчәләр гаҗәп бай һәм кызыклы. Аларны халыкның үзеннән – йола һәм тел осталарыннан язып алынган мисаллар нигезендә өйрәнү шушы хәзинәне тулырак күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Бигрәк тә апа-әбиләрне бергә җыеп сөйләштерүнең нәтиҗәләре уңышлы. Алар, берсе онытканны икенчесе искә төшереп, борынгыдан килгән йолалар турында шактый тулы мәгълүмат бирәләр. Ул истәлек-сөйләмнәр халык

йолаларын, терминнарын өйрәнү өчен фәнни материал гына түгел, киләчәк буыннарга әманәт-мирас булып та калачак.

Бу китапта Актаныш төбәге авылларында тел осталары һәм йола белгечләреннән язып алынган сөйләм үрнәкләре, халык хәтерендә сакланып калган борынгы йолалар, гореф-гадәтләр, аларга бәйле истәлекләр, җирле сөйләштә ничек булса, шул килеш, ягъни үзгәртелмичә бирелә.

Сөйләш үзенчәлекләрен чагылдыру өчен, гадиләштереп төзелгән тамгалар кулланыла: йа – я, йу – ю, w – ирен-ирен өрелмәле яңгырау тартык; d – интердентал тартык; қ, ғ – тирән тел арты тартыклары.

Һәр мәгълүмат бирүченең чыгышы яңа юлдан (сызык аша) бирелә.

Бер үк йола, гадәтне төрлерәк төсмерләр белән аңлату яки, киресенчә, мәгълүмат кабатлану очраклары бар. Без аларны укучылар игътибарына кабатлауларын кыскартмыйча тәкъдим итәбез. Җирле тел материалларының кыйммәте һәм кирәклеге дә шунда.

## Гаилә йолалары һәм йола сүзләре

### *Кыз димләү, ярәшү, никах*

**Җаучы, димче килү.** Әдәби телдәге кебек үк, кыз димләргә, кыз сорарга килгән кеше *йаучы, җаучы, димче* дип атала.

– Җаучы җөридерийе башта, җаучылыйлары ыйы. – Җаучыға бара бер кеше. Җегетнең ата-инәсе дә бара җаучыға. Мин үземнең абыстама җаучы килгәнне беләм, безнең заманға ул инде қалмады. – Димче килгән қыз сорап. Инәйләргә ошаса биргән, ошамаса йуқ (Күҗәкә).

**Ақлашу.** Урта диалектның кайбер сөйләшләренә хас булганча, *ақлашу* сүзе кызны ярәшү мәгънәсендә кулланыла.

– Қызны алдан ақлашқаннар. Ақлашу дигән нәстәкәй булған инде әwәле. Җегетнең атасы белән анасы қызның атасы белән анасына сорарға киләләр. Қызын бирергә риза булса, никах көнен билгеләп қайтқаннар.

*Ақлашу бүләге* (кыз ярәшкәндә ике гаилә арасында каракаршы бирелә торган бүләк).

– Ақлашқан чағында қыd анасы *айақ сөрткече, бит җаулық, намаdлық* биреп җибәрә *ақлашу бүләгенә.* Анысы *ақлашу бүләге* була.

– *Ақлашқанны, қыd ақлашқанны* белгертер өчөнгә қыdның бер битҗаулығын тәрdә башына элеп қуйалар ыйы.

– «Бәрәкәт, малай өйләндерәсезмени, *қыd тастымалы* алып қайтқансыз», – диләр ийе. Ул инде инәйләр dаманында булған. Ул чүпләп суққан киндер тастымал булған инде *қыd тастымалы* (Чуракай).

**Йабышып чығу.** Ата-ана ризалыгыннан башка гына качып кияүгә чыгу. Халык фикеренчә, күмәкләшү, колхозлашу елларында башланып киткән йола.

– Безнең чорда йабышып чығу дигән сүз булды инде. Йегет белән қыз килешсә – китәләр дә баралар, ата-аналары белми дә. Мин үзем шушылай килдем, җегет белән сүләшеп, җөрешеп бардым. Икебез сүләштек тә, җегет ат белән килде дә, утырдым да киттем.

«Қыdығыdны йуғалтмадығыdмы, қыdығыd веddә», – дип қайнатам барды. Йоласы шул, дәwере шул булғач орышмадылар (Күҗәкә).

**Киңәш.** Никах алдыннан һәр ике якның ата-аналары, туганнары кыз өендә җыелышып, киңәш ясап, уртага салып сөйләшәләр, чәй мәҗлесе ясыйлар, никах көнен билгелиләр.

– Әwәле йақын-тирәләре, күршеләре-туғаннарын чақырып, киңәш йасап, уртаға салып сөйләшкәннәр никах алдыннан. Ни көнне никах булырға (Уразай).

**Никах.** Никах мәҗлесе гадәттә кыз өендә уздырыла, ләкин кыз ябышып чыккан очракларда егет өендә ясала.

– Әwәле җаучыға барғаннар, ақлашқаннар. Риза булсалар, фәлән көнгә никахлашырға дип көн билгеләп киткәннәр. Қыз йағына килгәннәр никахқа.

– Никахны уқыттылар қыз өйендә. Инәй табын йасады. Никахқа килгәндә чәкчәк, пар қаз алып килделәр қодалар.

– Мин җабышып чықтым. Җегет ат белән килде, утырдым да киттем. Аннан соң әткәйләрне, әнкәйләрне алып килделәр, муллаларны алып килделәр, никах уқыттылар. Бик әйбәт тордық.

– Никах уқытқанда кийәү килә. Мунча йағалар ыйы. Ул мунчаға кийәү ақча салып чығадыр ыйы мунча йағучыларға. Шуннан соң қыԁ белән кийәүнең үԁләрен генә қундыралар ыйы (Адай).

**Қыз бикләү.** Никахтан соң егет белән кызны кавыштыру.

– Ақ чыбылдық ийе шулай өйдә. Алты почмақлы өйнең түрендә кийәү белән қызны бикләгәннәр (Әнәк).

**Қыз қуйнына керү.** Кияүнең үзенең кәләше белән беренче кич бергә кунуы.

– Кийәүне пар атлар, қыңғыраулар белән килеп алалар. Җиңгә урынны җәйеп қуйа әйбәтләп. Аннан соң кичке йақта кийәү керә қыз қуйнына. Ул дүрт кич қуна қыз қуйынында. Кийәү булған кеше шулай бик қадерле булған.

**Кийәү күрегә килү.** – Кийәү күрегә килгәндә туған-тумачалар қоймақ пешереп алып киләләр ийе. Кийәү аларға бүләк биреп җибәргән, сабын, көԁге, кершән, иннек (Күҗәкә).

**Кийәү мунчасы.** Кыз белән кияү кавышкач, махсус алар өчен ягып әзерләнгән мунча.

– *Кийәү мунчасын* қыз белән кийәү қаwышқачтын йағалар. Таң беленңгәнче қараңғыда тороп, қараңғыда кертеп чығаралар ыйы иртән. Қыԁ йағыннан кийәүне қыңғыраулы атлар белән барып алалар ыйы.

Алар *мунчадан қайтуға* қоймақ инде. «Кем кадерле – кийәү қадерле», – диләр ийе. Башта қыз белән кийәү, аннан қода белән қодағый, килгән қунақлар *мунча керә*.

Қайын пиннекләре* белән чабынып, зур қызыл башлы тастымалларға сөртенеп, қодалар чығарлар ыйы *кийәү мунчасыннан* күңелле иттереп.

Туйның да, қунақның да иң зур сыйы – мунча белән тәбикмәк.

**Кийәү бүләге, мунча бүләге.** Кияүнең мунчада мунча ягучыга дип куеп калдырган бүләге.

– Мунчада кийәү белән қыз чығып киткәннән соң, *мунча җаққан кеше* җәтрәк мунчаға барып қарый. Аңарға бүләк салып қалдыра кийәү. Йә ақча, йә ислемай, йә күлмәклек қалдыра.

---

* *Пиннек* – мунча себеркесе.

– Қараңғыдан уқ таң белән *кийәү мунчасына* баралар. Кийәү инде арурақ булса, *кийәү мунчасына* бүләк салып қалдыра: сабын, көdге, исле май, ақча да қуйа мунча йағучыға, хезмәтен олылый инде.

– *Мунча тәрәзә төбенә*, җә *мунча йалдысы* тәрәзә төбенә қуйып қалдыра бүләкне.

**Мунчада кийәүне киендерү.** Йола буенча беренче мунчадан чыкканда кияү булган кеше кыз әзерләгән киемнәрне киенеп чыгарга тиеш булган.

– Беренче мунчадан чыққанда кийәүне қыз кийендерәдер ийе. Кийәү мунчасыннан чыққанда кийәүгә кийәсе кийемнәрне қыd йағы әdерләп қуйадыр ыйы. *Кийәү күлмәге, кийәү ыштаны* әdерләп қуйадыр ыйы.

**Кийәү қоймағы.** Мунчадан чыккач чәй эчәргә дип, кияү хөрмәтенә пешерелгән коймак (гадәттә ул төче камырдан булган).

– Кийәүгә мунча жақтық, қайтуwына қоймақ инде. Төче қоймақ ару була. Төчедән пешерәләр ийе *кийәү қоймағын* мунчадан чығып чәй эчәргә (Әнәк).

**Кийәүләп йөрү**. Никахтан соң кияүнең кыз өенә кунакка килеп-китеп йөрүе.

– Кийәүләр атна сайын килеп *кийәүләп йөргән*. Ул кийәүне бик нық сыйлыйлар.

– Менә малай өйләнсә, киленне икенче көdгә алып қайтқаннар. Кийәү атна сайын бара икән, *кийәүләп йөри* икән, икешәрне-өчәрне қунып қайта икән.

**Йыллап бирү.** Кияүне бер ел кияүләтеп, кызны биреп җибәрү.

– *Кийәүләп йөри* бер йыл. Қыз өйенә килеп йөри кийәү, бер йылға хәтлегә килә. Бер йылдан соң қыңғыраулар белән алып китә. Менә шуны *йыллап бирү* диләр. Ата-анасы тигезләр шундый булды. Бик зур йасыйлар ыйы туйларны қалхуз булғанчы.

– Қайбер кийәүләр берәр жыл *кийәүләп* җөргәннәр, бала белән төшкән қайбер киленнәр. Минем әбийем килен булып төшкәндә баланы алдына утыртып төшкән, бала бер йәшлек булған. Бер йыл *кийәүләп йөргән* бабам, Мөхәммәтдинне алдына утыртып төшкән әбийем.

– Никах уқығаннан соң кийәү килеп-нитеп кенә йөргән, қыd бер жыл утырған. Бәбәй белән төшкән қайсы киленнәр.

**Җәйләтеп бирү**. Кияүне җәй буе кияүләтеп йөртеп, кызны җәй үткәч кенә биреп җибәрү.

– Әwәле, қыdны җәйләтеп бирәбеd, дип оdағрақ торғыdалар ыйы қайсы кеше, кийәү килеп-китеп йөрер ийе җәйли. Аннары қыdны кийәү алып китәр ийе (Уразай).

***Туйда катнашучылар***

**Җиңгә**. Туйда кызга һәм кияүгә хезмәт күрсәтүче, алар тирәсендә йөрүче хатын-кыз.

– Кийәү жағыннан берәү, қыd жағыннан берәү җиңгә була.

**Қыd җиңгәсе**. Туйда кыз ягыннан куелган, кызга хезмәт күрсәтүче хатын-кыз.

– Қыd җиңгәсе була, қыd җиңгәсе қыd җанында утырды.

**Урын җәйгән кеше, урын жыйған кеше.** Туйда кызга һәм кияүгә хезмәт күрсәтүче хатын-кыз.

– Килен булып төшкәчтен урын җәйгән кешегә дә, урын жыйған кешегә дә бүләк қуйдым, ислемай, тастымаллар қуйдым (Әнәк).

**Қода, төп қода.** Кияү яки киленнең әтисе.

– Төп қода қадерле инде, өстәл башында утыра, һәр көнне мунча йағып кертәләр төп қоданы.

– Қоdаларны ашқа алалар, ашқа йөртәләр.

**Қодағай, қодағый.** Кияү яки киленнең әнисе.

– Қодағайым бик уңған булды, ике зур бәлеш, ике зур қаз белән килде. Қодағайым белән тату йәшәдек.

– Қодалар, қодағыйлар иң беренче жоқоларыннан торалар да мунчаға китәләр. Мунчадан қайтышқа тәбикмәк белән чәй аларға. Қызыл башлы тастымалларға сөртенеп, қодалар мунчадан чығарлар ыйы, чәй эчәсебез килде дип (Әнәк).

**Ийәрчен.** Төп кодага ияреп туйга килүче.

– Икене, җә дүртне ийәрчен алып баралар, аларға да бүләк қуйалар қыd жағыннан.

– Күмәчләр алып килгәннәр, дүртәр-бишәр қалач белән килгәннәр қодағыйлар. Ийәрченнәре дә шулай килгәннәр дип мақтап сөйләрләр ийе.

**Ийәрчен күчтәнәче.** Төп кодага ияреп килгән туй кунакларының күчтәнәче.

– Ийәрчен күчтәнәче җә күdикмәк, җә қош теле була. Күdикмәк менә жуқа ғына итеп пешереп алып киләләр, күкәйгә генә басып. Ийәрченнеке үdалдына була (Күҗәкә).

**Арчи, әрчи.** Кыз ягыннан аны озатып кияү йортына килүче туганнары, дуслары.

– Арчи әнә шул ийәрчен инде ул, төп қодаға ийәреп туйға килүче қызлар, туғаннары, күршеләре, туй қунақлары була.

– Әрчи булып қыd йағындағы йақын туғаннары бара, қыd оdата баралар. Аларны хөрмәтләп, өчәр-дүртәр кич қундыралар.

– Әрчи белән бара торғаннары да чанаға палас асылындырырлар ыйы. Шулай итеп өчәр-дүртәр ат белән килеп төшәрләр ийе. Мин әрчи булып килгәндә җиdнәй буласы қаршы алды, туйда ғына күрдем җиdнәй буласыны (Күҗәкә).

**Арчи қызы.** Кыз ягыннан аны озатып килүче туганы яки күршесе.

– Килен йағыннан сеңлесеме, қәрдәшеме, күрше қызымы, арчи қызы булып килә.

– Арчи қызлары, йәш киленне уртаға алып суға төшәләр, чишмәгә.

– Арчи қызлары қурчак кебек кийенәләр ийе, башларына тақийалар кийәләр, шәлләр бөркәнәләр, бәбәй итәкле күлмәкләр, ағ алҗапқычлар җабалар. Ағ алҗапқычның түше чигүле. Арчи қызын җегетләр күреп қала да хәзер җаучы килә башлый.

**Арчилап төшү.** Туйлап, үзен озатып килүчеләр белән кияү өенә төшү.

– Байырақ қызлар арчилап төшәләр ийе, безгә инде арчилап төшүләр бик эләкмәде.

**Арчиға килүчеләр.** Кызны озатып килүчеләр.

– Арчиға килүчеләр аш-су белән киләләр җегет җортона. Алар қызны озата киләләр дә қалдырып китәләр инде кунақ булып. Қыш көне булса, чанада киләләр атлар белән, җәй көне булса арбада киләләр инде, қыңғыраулы атлар белән киләләр. Йәмле буладыр ыйы.

**Туй атлары.** *Туй атларын* матур итеп, кыңгыраулар, яулыклар белән бизәү булган.

– Килен алырға килгәндә пирбуй килгән атта *қыңғыраулы дуғалар* була. *Битжәаулықлар урап* төшерәләр дуғаларға жақ-жағыннан асылындырып, *қулжәаулықлар* тағалар.

– Туйға жақшы атларны ғына жигеп, пар атларны бизәп, дуғаларға қулжәаулықлар, сөлгеләр элеп киләләр ийе матур иттереп. Минем кече қыdым шулай биdәлгән қыңғыраулы атлар белән китте.

– Әwәле туйға өчәр ат жигәләр ийе, труйка дип әйтерләр ийе. Әти труйка жигеп барыр ыйы.

– Атлы-тунлы кеше ат белән килер ийе туйға. Һәрбер хужаның икешәр дә өчәр аты булыр ыйы.

– Дуғаларда қыңғыраулар, уникешәр ат тезелешеп килерләр ийе. Дуғасына сөлгеләр урарлар ыйы атларның. Туй қодалары безгә атларын қуйарлар ыйы. Атқа башақ бирә торған улағыбыз бар ыйы. Озын сарайның буйыннан-буйына биш митырлы улақ. Шул улақта башақ бирә торған ыйық атларға. Шул өч ат ашар ыйы башақны.

*Алдан ат, пар ат.* – Туйға өч ат жигәләр. Пар атның алдында бер ат була, аны «алдан ат» дип әйтәләр.

**Ат башы** (кучер). – Ат башы атны тотып бара, кучер була. Аңа пирчәткә бәйләп биреш ийе ат тотып барған өчен. Үdебеdнең күрше ат башында булды, шул алып китте беdне. Шулай итеп килен булып төштем.

*Ат тотучы* (кучер). – Алдағы атта кийәү белән қыз, ат тотучы утырадыр ыйы, шундый матур буладыр ыйы.

**Аш арбасы.** Туйда күчтәнәч ашамлыклар куелган арба.

– Аш арбасы белән киләләр жегет жағыннан. Аш арбасында күчтәнәче, баwырсағы қуйған була.

**Аш чанасы, күчтәнәч чанасы**. Туйда күчтәнәч ашамлыклар куелган чана.

– Без менә биш ат жиктек. Аш чанасы да китте. Аш чанасында әйбер күп. «Таудан әкерен генә мен, аш чанасының жөгө аwыр», – диде кийәүнең абзыйсы (Әгъбәз).

**Килен төшерү.** – Бакчи, киленне бик матур итеп, жақшы атларны бизәп, қыңғыраулар белән төшергәннәр, ә хәзер унар

машина белән төшә туйлар. Атлар белән төшергәчтен матур була килен төшергәндә. Ат белән, кашувка белән төшерделәр.

– Чанаға кийәү белән қыз утырған, аның артыннан матур итеп суққан палас асылындырырлар ыйы, ул чуқлы булыр ыйы. Аның йастығы да матур булыр ыйы, аны күрсәтебрәк утырырлар ыйы.

– Килен булып төшкәндә бийанам, бийатам, җанағам бар ыйы, қайын сеңлем бар ыйы.

– Мин килен булып төшкәндә Шәех абый гармунчы булды, атта утырды, аның қырында кучер булды (Әнәк).

– Мине шушы урамны уратып күпердән алып чығып, килен итеп төшерделәр. Ул гармун тawышы, қыңғыраулар.

– Қыңғыраулар тағып киләләр қыз алырға килгәндә, гармуннар белән. Киткәндә урам әйләнеп китәләр атлар белән. Сине җыйылып қаршы алалар.

– Бу минем туған диңгеdем генә, минем өйем тегендә.

– Теге диңгеdдән бу диңгеdгә килен булып төшкән ийем. – Ат белән, айғыр белән барыш ыйы.

Шушы *милектә** бәләкәй генә өй ике тирәdәле. Шунда килен булып төштем. Қыш көне йурғанға төренеп ат белән төшеш булды бит инде, ашқа утырып. Җәй көне кырандас, қыш көне кашаwай, башқа мамық шәлләр урап.

Хәdер дә матур итеп кийәүгә баралар да бик тиd айырылалар. Беdнең dаманда айырылу булмады.

**Баwырсақ, чикләwек чәчү.** – Килен чанаға утырғач та чикләwек чәчәрләр ийе. Без шуны җыйар ыйық балалар. Киленне алып киткәндә дә чәчәрләр ийе, төшкәч тә чәчәрләр ийе. Чикләwек тә, баwырсақ та чәчә қайсы кеше.

**Килен қаршылау, бал-май қаптыру**. Килен төшкәндә айақ астына мендәр салып бастыралар. Бийанай кеше бал-май қаптыра. «Теле балдай татлы, Май кебек җомшақ булсын», – дип. Бийанай кешегә җаулық бәйләтә килен. Бийатасына түбәтәй алып килә.

Килен төшкәч тә бийанай булған кеше әпекәй қаптыра, бал қаптыра башта. Эпи тешләткәндә теләк тели: «Әйбәт-тигез

---

* *Милек* – нигез.

торығыз, тәүфиқле-бәхетле булығыз, күп балалар үстерегез». Бийатай-бийанайлар шулай теләк телиләр.

**Мендәргә бастыру.** – Киленне җиргә бастырмыйы, мендәргә бастырып алып кереп китәләр.

**Танаға тайандыру.** – Әти тананы тотып тора, килен танаға тайанды (Әнәк).

**Килен тоқмачы.** – Киленгә беренче эш итеп тоқмач басарға қушалар. Килен тоқмачына күрше-күкертләрне, бөтен туғаннарны җыйып аш ашаталар. Килен үзенең алып килгән бүләкләрен өләшә килен тоқмачына килгән қунақларға.

**Су җулы күрсәтү.** – Киленне көйәнтә-чиләге күтәртеп алып китәләр су җулына. Килеп кереп чәй эчкәч тә алып китәләр. Килен артыннан бала-чаға килә. Қыdлар киленгә су җулы күрсәтеп, су алып қайтып, чәй қуйалар. Аның көйәнтә-чиләге үdенеке була киленнең, үdе килгәндә алып килә.

– Беренче чәй эчкәчтән үк җегетләр-қыdлар җыйылып, киленгә су йулы күрсәтү булды. Соңыннан шайарып килен суы сатабыз диләр. Кем күпмедер ақча сала *килен суына.*

**Чишмә янында бүләк элеп қалдыру.** – Килен суға барғачтан чишмә талына йаулық бәйләп қалдыра, пар йаулық қалдыра. Чишмә қаплаулы, шунда бәйләп қуйыш ыйы. Аны алып китә инде кемдер килеп. Болай атап қына биреш түгел ийе. Суға кем килә, шул алып китә.

– Су қырына, су алған җиргә қулҗаулық, җә тастымал, җә баш җаулығы бәйләп китә. Анда бит ағачлар үсеп утыра инде. Бер агачқа бәйләп қуйа сөлге, йә йаулық, йә сабын қалдыра ағач төбендә. Тора ул шунда җилфердәп, бер узучы алып китә торғандыр аны (Күҗәкә).

**Тел йәшерү.** – Бийатай-бийанайға хөрмәт булған. Бийатасы белән җаңғышып та сүләшмәделәр. Кирәк әйбере булса, кеше арқылы әйттерә. Килен җалан айақ җөрмәгән. Җалан айақ җөрсә, никахы бозыла, дигәннәр.

– Қайнатама тел ачмадым, бийағама да тел ачмадым, сүләшмәдем, җегерме җиде җыл җәшәдек.

– Киленнәр тел йәшергән, битләренә йаулықларын қаплап йөргәннәр, идәнгә йалан айақ басмағаннар, түшләр йабық.

– Олы ағасы белән бер-бер кәлимә сүз дә сүләшә алмаған, үзеннән-үзе ойалып, тартынып торған киленнәр.

– Бийанай нәмә ҡушса, шуны эшләп йөреш ийе. Элек бийанадан ҡурҡыш ыйы. Ҡурҡыш та түгел, намус саҡлаш ыйы (Уразай).

### *Туй чыгымнары һәм үзара бүләкләшү*

**Мәһәр.** Гарәп теленнән кергән әлеге сүз кияү ягыннан кыз өчен бирелә торган кием-салым, акчаны белдерә. Элекке вакытта мулла аны дәфтәргә яза торган булган, һәм, килен аерылып китә калса, ул мәһәрне кияүдән түләтә торган булганнар. – *Мәһәр җаздыралар* ыйы. Ҡызға сондоҡ, бишмәт, күлмәк, шәл, ҡалын шәл, йуҡа шәл, йурған, түшәк. Кийәү китерергә тийеш булған шуларны. Аҡчалата да биргән кийәү.

– Кийәү йағыннан ҡызга *күпчекләрен, йурғаннарын* алып барадыр ыйы. Әwәлдә ҡызга кийендерегә бер ҡат *кийем* алып киләләр ийе. Күлмәген, йаулығын, ҡалын шәлен шулай алып киләләр ийе ҡызға.

– Мәһәргә менә минем түтигә йастыҡ, йурған, дүртәр тотҡалы сандыҡ, аның өстенә одон җилән, ҡандул, кийед итек, күн ҡалуш, тула ойоғын, эрдиңкә-читеген, берсе йаҡшыдан, берсе прастуйдан күлмәк, ике төрле шәл – берсе йуҡа шәл, берсе ҡалын шәл. Менә шулай иттереп, бер ат йөге әйбер төйәп китерәләр ийе мәһәргә (Такталачык).

**Мәһәр сандыгы.** Кияү ягыннан кызга китерелгән сандык, элек аны мәһәргә язып, никах алдыннан китерә торган булганнар.

– Мәһәр сандығы дип дүртәр тотҡалы сандыҡлар буладыр ыйы, йегет йағыннан мәһәргә китерелгән сандыҡтан мәһәр әйберләрен алып, ҡыз үзе әзерләгән ҡул өшәнчекләрен шул сандыҡҡа тутырып барған.

– Мәһәр салалар ыйы. Аҡча салалар ыйы, бер ҡат йаҡшы кийем-салым салалар ыйы мәһәргә. Йаҡшы күлмәк, йаҡшы шәл. «И-и, шундый мәһәрләр салған», – дип сүләрләр ийе.

– Мәһәр сандығы диләр ийе. Бар әйбере сандыҡ эчендә булыр ыйы. «И-и, мәһәр сандыҡларына хәтлек килгән», – дийерләр ийе.

– Кийәү йағы бирә мәһәр сандығын. Йахшы затлы әйберләрен қуйалар мәһәр сандығына. Мәһәр сандығы кийәү йағыннан килә дә анда килен әйберләрен тутырып, килен килгәндә алып китәрләр ийе (Такталачык).

**Мал**. Кияү ягыннан мәһәргә язылган әйберләр; кыз өенә биреләсе кием-салымнар һ. б.

– Мал китерделәр туйға, түтигә сандық китерделәр. Сандыққа салып, күп әйберләр китергән җегет җақ: *бишмәтлекләр, күлмәклекләр* китергән.

– Малны китерә, мәһәргә җазган әйберләрне китерә кийәү. Мал китергәчтен, қыԁ җегетнеке була инде, мин белгәнеме сүлим.

– Элгәре кийәүгә китәсе қызга сондоқ китерәләр ийе кийәү йақтан, йурған китерәләр ийе *мал итеп.*

**Қыз малы.** Кыз ягыннан кияү өенә биреләсе әйберләр.

– Қыз малы инде киҗеле киндер ыштан булыр ыйы буй-буй киндердән, киндердән күлмәк, түбәтәй, қолақчын бүрек, қайнатасы-қайнанасы булса, шул күлмәк, йаулық, сөлге әзерләгән қыз.

**Мал әйтү.** Кияү өенә төшкәннән соң килен исеменә атап тере хайван әйтү.

– Килен булып төшкәчтен, киленгә мал әйтеп мал биргәннәр. Инәй сүлидер ийе, килен булып төшкәчтен мал әйткәннәр ийе, танамы, сыйырмы. Шуннан үрчеп китте малларым дип.

– Беԁнең инәкәйгә тана әйткәннәр килен булып төшкәчтән (Уразай).

**Терлек**. Кияүгә барасы кызның кулдан әзерләнгән әйберләре: өйгә элү әйберләре, бүләк итеп биреләсе сөлге-тастымаллар, кием-салымнар һ. б.

– Бер җыл буйы терлек әзерли инде қыз төрле-төрле җепләр белән (Әгъбәз).

**Қыз бүләге.** Туйда катнашучыларга кыз ягыннан бирелә торган бүләк.

– Қыз биргән кеше табында бүләк өләшә. Бүләк алған кеше шул бүләккә ақча қыстыра да кире бирә хуҗага. Қызның бөтен нәрсәсе ақчалыйы.

– Килен булып төшкән җирнең сеңнесе буламы, бийанасы, бийатасы буламы, ир туғаннары буламы, килен үd қулы белән бүләк бирә.

**Бүләк өләшеш.** – Туй була. Туйдан соң өләшеш ийе бүләкләрне. Кийәү йортындағы бөтен қардәш-ыруларына алҗапқыч, күлмәк, кулҗаулық әdерләп бара торған ыйық. Килен төшкәчтен шуны өләшеш ийе. Бийатай-бийанайларға тастымал, күлмәклек булды.

**Тастымал.** – Бийанай белән бийатаға иң зур бүләк тастымал булды. Бүләк бирү тастымалдан башлана. *Килен тастымаллары, килен ашйаулықлары* була.

**Кийәү ыштаны, билбуғычлы күлмәк.** – Кийәүгә кийәү ыштаннары, киҗеле ыштаннар алып килә, билбуғычлы күлмәкләр була. Җиң очлары, җақалары қайулы.

– *Җанчық* өләшерләр ийе бүләккә. Матур сатинны читләп тегәрләр ийе. Мин җөй теккәч, үзем алып килдем җанчықлар. Уртасы қанwа белән чигелгән җанчық, тәмәке җанчығы инде. Ике йағы чигелгән булса, *йәш қодаларға, кийәү җегетләргә* бирерләр ийе җанчықны.

– *Күлмәклек таwарлар* бирәләр туйда хәзер дә, тийешле кешегә, олы қунақларға.

– *Чигешле күкрәкчәләр* бирәләр олырақ хатын-қызларға.

– Килен булып төшкәч әбиләрне җыйадырыйық килен чәйенә. Килен күкрәкчә өләшә әбиләргә. Күкрәкчә кигәннәр элеке қортқалар. Киленнәр шулай күкрәкчә тегеп алып барыш ыйы өләшеп бирергә. Кийәүгә барасы қыd – һәркем күкрәкчә әdерләдек килен булып төшкәч өләшергә.

Күкрәкчәләр тектек, алйапқычлар, тастымаллар чиктек. Шуларны бүләк итеп өләшер ийек туйда. Қулйаулығы да бүләк булды.

*Пирчәткәләр* бәйлиләр ийе қызлар бүләккә. Нечкә итеп эрләп, ақ җоннан пирчәткә бәйлиләр ийе қызлар. Кийәүгә, кийәү җегетләргә, қара җоннан да бәйләрләр ийе.

*Намазлық, чүпләп суққан сөлгеләр* белән килдем мин. *Намазлықны қайнана* булғанға, чүпләп суққан сөлгене қайната булғанға бирдем.

**Элү, элү элеп керү.** Кияү өенә төшкәч, киленне кунакка, ашка йөртәләр. Ул беренче кергән өйләргә бүләк итеп сөлге алып бара, шуны *элү* дип әйтәләр.

– Ашқа әйтәләр килен төшкәч. Дүрт-биш өйгә барсаң, дүртбиш бит җаулығы алып барасың эләргә. Мин үзем күп элдем.

– Керәсең, исәнләшәсең, чөйгә эләсең бит җаулығы.

– Килен булып мунчаға барғанда да сөлге алып барасың. Элеп қайтасың, алып қайтмыйсың сөлгеңе. Килен сөлгесе дип арурақ булса сақлап қына тоталар ыйы (Күҗәкә).

**Кийәү бүләге.** Кияүнең кыз ягында өләшү өчен алып килгән вак-төяк бүләкләре: иннек, кершән, хушбуй, көзге, сабын, пәке, тарак һ. б.

– Бәләкәй генә ағач сандыққа салып алып киләләр кийәү бүләген.

– Кийәү булған кеше бүләкләр алып килә торған ыйы элгәре. Исле майлар, көԁгеләр, пәкеләр малайларға, қоԁаларға. Кийәү бүләге дийеп исле сабыннар да тараталар.

– Кийәү беләп қыԁға күрше-тирә, йақыннары қоймақ пешереп кертәләр. Анарға да сабынмы, иннекме, кершәнме, көԁгеме, шуның ишене қоймақ тәлинкәсенә салып биреп чығаралар ыйы кийәү бүләге дип.

– Кийәү бүләгенә *иннеген, кершәнен, хушбуйын, көԁгеләрен, сабыннарын* алып килә торған ыйы. Кийәү қоймағы керткән кешегә салып чығаралар ыйы *кийәү бүләген.*

– *Җиԁнәй* килде, *тутәй* белән бер өйдә қалдылар. Иртән алар торуға мунча йақтылар, қоймақ пешерделәр. Инәй әйтте: «Бар, тутаң белән җиԁнәңә кийәү қоймағы кертеп чық», – диде. Мин қоштабақ белән қоймақ керткән ийем, җиԁнәй шул савытыма шушының хәтле бер сабын салып чығарды. Менә кийәү бүләге миңа эләкте (Уразай).

**Қуйнына салу.** Беренче кичне, кавышкач, кийәүнең үзенең кәләшенә бүләк бирү йоласы.

– Кийәү инде қызға да бүләк алып килә қуйнына салырға. Беренче кичне бергә җоқлағач, кийәү үзенең бүләген бирә. Җә күлмәклек, җә матур җефәк җаулық, җә җөзөк, алқа алып

килә торған ыйы. Минем үземә фирүзә қашлы җөзөк бүләк итте кийәwем, қуйныма салды. Қыз булмаса, җарып та чығып китәләр ийе кийәүләр (Югары Уръяды).

**Сондоқ (сандық). Сандық китерү**. Кияү ягыннан кызга һәртөрле кием-салымнар, бизәнү әйберләре салып сандык китерү йоласы.

– Түтигә сандық китерделәр. Шул сандықта ике төрле сатиннан, йәшел сатин, қызыл сатиннан *күлмәклек, қалын шәл, кешмир шәл, кешмир йаулық, чулпы, беләзек, гәрәбәсе* бар ыйы, ике әйбәт камзул ыйы. Күп китерде кийәү.

– Сондоқны йегет йағыннан илтеп қуйғаннар. Килен булған кеше кийәү йағыннан килгән әйберләрне бушатып үзенең әйберләрен тутырып қуйған шул сондоққа. Ул сондоқны арбағамы, чанағамы салып, үзенең чиләк-көйәнтәләрен салып, таз-қомғаннарын салып төшәдер ийе килен.

**Килен сандығы.** Киленнең әйберләре тутырылган сандык.

– Сандығы булған, сандығы булмаса буқчасы булған. Шунда тутырылған қызның бөтен әйбере. Ул килен сандығын ачып әйбер эләләр, шуны қарарға барабыз бит инде.

– Сандық тулы әйбер була, қыз әйберләре. Әллә күрсәтәйем микән сезгә. Тастымаллар, түрләмәләр, челтәрләр, қулйаулықлар, чигүле ақ җәймәләр.

**Мәһәр сандығы**. Кияү ягыннан кызга биреләсе киемнәр һ. б. салып китерелгән сандык.

– Мәһәр сандығы зур сандық, дүртәр тотқалы сандық булыр ыйы. Дүрт кеше күтәреп кертерләр ийе.

– Мәһәр сандығы диләр ийе. Бар әйбере сандық эчендә булыр ыйы. «И-и, мәһәр сандықларына хәтлек килгән», – дийерләр ийе. Кийәү йағы бирә мәһәр сандығын. Йахшы-затлы әйберләрен қуйалар мәһәр сандығына.

Мәһәр сандығы кийәү йағыннан килә дә анда килен әйберләрен тутырып, килен төшкәндә алып китәрләр ийе.

**Сондоқ арбасы**. Килен булып төшкәндә кызның әйберләре тутырылган сандык куелган арба.

– Сондоқ арбасы була җәй көне төшсә. Иң өскә алйапқычын сала, үзенә тиз генә ачып бәйләп қуйарға.

**Сондоқ чанасы**. Кыш көне килен булып төшкәндә кызның әйберләре тутырылган сандык куелган чана.

– Чанаға сондоқны қуйа, сондоқ өстенә ике матур мендәр, аның өстенә журған қуйалар. Теге матур паласны җәйер ийе өстән сондоқ чанасында. Кийәү җегете шул сондоқның өстенә утырып килер ийе.

– Сындық *сындық чанасында* килә. Сындықта бүләкләр, тирәдә фәрдәсе, челтәрләр, тастымаллар, чаршаулар. Сындық өстендә ике мендәр, бер йастық. Сындықта йегермеләп тастымал булды (Чуракай).

**Сондоқ сатулашу.** – Сондоқны кертмиләр ийе. «Менә сондоқ қыйбат, түләп алығыз, бирмибез», – диләр ийе кийәү җегетләре. Кийәү җегетенә бирәләр ийе бүләк. Қулҗаулығы, пирчәткә, җә җанчық. Аруръағы күлмәк тә бирер ийе.

– Айырым ат белән *сандықны* китерәләр. *Сандық* китерүче сандық өстендә утыра. «Сандықны сатабыз», – ди. Бәһәсен бәһәләп тора, шайартып инде. Өйдәге хуҗалар чыққачтын сүләшәләр, сандықны кертәләр. Әйбер арбасы айыры, қыd белән кийәүнеке айыры (Уразай).

**Чумадан (чемодан) китерү.** – Чумаданны кырандас артына бәйләш. Анда ашйаулық, тәрәdәгә челтәр, сарфиткә, чаршау, әдийәл, қулҗаулықлар чигеп қуйыш. Ике күлмәк чигеп қуйыш кийәүгә. Бийанаға күлмәк, йаулық (Күҗәкә).

**Бирнә**. Кияү ягыннан бирелә торган әйберләр: кием-салым, ашамлыклар һ. б.

– Қызны үзенең ишенә биргәннәр. Ул қызға торошлымы бу малай, исәпкә алғаннар ата-аналары. Бирнәсе начар булса бирмәгәннәр. Йегет йағы бөтен нәрсәкәйен дә биргән.

– Бирнәгә күлмәкләр, йарты потмы, бер потмы – балын, майын, ағ он, дөге йармалары бирәләр. Қызны кийендерәләр (Такталачык).

**Буқча**. Кыз әйберләрен салып кияү ягына алып бару өчен өчпочмаклап тегелә. Элеккерәк вакытта кулдан сугып әзерләнгән буқчалар да булган. Буқчаны кыз киткәнче үк никах мәҗлесеннән соң егет ягына биреп җибәргәннәр.

– Киндердән эшләнгән зур буқча булған, чүперәктән тегелгән буқчалар да булған. Чәчәкләп йасап эшләнгән буқча булған.

– Элгәре буқча әдерлиләр ийе. Буқчаға кодағыйға, қодаға бүләк салалар. Битҗаулық суғалар ыйы элгәре, нәрсәкәй. Киндер әйберсе булды бит инде.

– Менә өчпочмақ итеп тегәсең дә буқча була. Буқчаға сала қыз әйберләрен.

*Буқча баwы.* Букчага тагып, аны бәйләп кую өчен махсус сугып яки тегеп матурлап эшләнгән бау.

– Олы буқча булған, аның урый торған *баwы* булған. Баwын озын итеп йасағаннар, ул бик матур була, аны киҗеле җептән суғалар. Буқчаны кийәү өйендә элеп қуйалар баwыннан.

– Буқча бар ыйы. Инәйнең буқчасын гомер буйы сақлаган ыйым, былтыр ғына сүтеп, тастымал итеп тоттым. Ул шулай өчпочмақлап тегеп, бау тағып бәйләп куйыладыр ыйы.

*Буқча бирү.* Никах мәҗлесендә кызның букчасын егет ягына тапшыру.

– Буқча алдан бирелә. Никах мәҗлесендә бирелә ул.

– Буқчаның эчендә төрле *тастымаллар, намазлықлар, айақ чолғаулары, қызның әйберләре* була. Шуларны алдан җибәрәләр. *Буқча китә,* дип. Никах булғачтын шул буқча алдан киткән. Никахка килгән бабайлар алып киткәннәр буқчаны.

– Буқчаны киндердән матур итеп бизәкләп, *чәкәннәр* төшереп суққан киндердән теккәннәр.

– Түтинең буқчасы бар ыйы. Аны бик матур киҗеле җептән суғалар, аның баwын озын итеп йасағаннар. Кийәү йағыннан сандық китермәсә, әйберләрен шул буқчаға тутырып қуйа қызлар. Ул бик матур була, киҗеле шақмақлы итеп суғылған була. Мулла никах уқығач та биреп җибәрәләр буқчаны кийәү өйенә.

*Буқчага тәңкә қадау.* Егет өендә букчаны күрсәтеп мәҗлес ясыйлар, килгән кунаклар букчага «тәңкә кадый» яки акчалата бирә.

– Қыдыл буқча булыр ыйы, аның чигешлесе дә булыр ыйы. Аны қыз йағы бирер ийе. Шуннан «қыз ақлашып қайттық менә фәлән җирдән қыз ақлашып қайттық», – дип, ашқа җийалар ыйы җегет өйендә. Һәрбер ашқа килгән кеше шул буқчага *тәңкә қадыйдыр ыйы, көмеш тәңкә.* Шул буқча менә өчпочмақлы була инде.

– Буқчада қызның кийемнәре, қул өшәнчекләре, тотмастайырағы буладыр ыйы. Ул буқчаны матурлап, чәкәннәп суққан

буладыр ыйы, ул букчаны кыз үзе килгәч ачарлар ыйы. Көмеш тәңкәләр кызга була.

**Өшәнчек**. Кияүгә чыга торган кыз тарафыннан әзерләнгән сөлге-тастымаллар, чаршаулар һ. б.

– Кыз йагыннан өшәнчекләр, чүпрәк-чапраклар алып килгән. Йегет инде өйләрен, урын-җирләрен әзерләгән. Кыз сандык белән өшәнчек, йату-тору урыннары, өйне җиһазларга алып килә. Эләргә инде *чаршаулар, ашйаулыклар, сөлгеләр* әзерләгән, кәтүк җебеннән челтәрләр бәйләгән.

– «Суккан әйберләре, өшәнчекләре бармы суң?» – диләр. Мин кыdларымның кыdларына да суктым *паласлар,* уртасына *парча* төшереп.

– Өшәнчекләр инде йортны бизәргә элә торган әйберләр, чиккән намазлыклар, битҗаулыклары.

*Кул өшәнчеге.* Кызның үзе сугып яки тегеп әзерләгән әйберләре: кияүгә кийем-салымнар, кайнана-кайнатага биреләсе бүләкләр, сөлге-тастымаллар һ. б.

– Кул өшәнчеге кызның үзе белән бара сандыкта.

– Кул өшәнчеге алып килә кызлар, кижеледән әзерләгән әйберләр, кийәүгә күлмәк-ыштан, *урawыч,* айагына урамага. Битйаулыклары, *айак сөрткече* була (Күҗәкә).

*Җапкыч: бawырсак җапкычы, чынийак җапкычы* чиктек кийәүгә барырга. Кул өшәнчегендә була бар да.

Килен сандыгында күпләгән *сарфиткә* һәм тастымаллар булган.

– Киндер тастымаллар суктык. «Калган җебеңе бир әле, апайым», – дип алып киттеләр сорап. – Менә, кыdыкайым, бу тастымалны жырак әбекәй суккан. Бу – *чүпләмле сугу* белән суккан тастымал. Берәннәп кертеп барганнар җепләрне. Ныгытып карасагыd менә күрерсеd. Менә болары – атып кына суккан тастымал. *Асалап суккан* тастымал моносы, тегеләре чүпләп суккан тастымал. Тастымал башларын *чуптарлап* суккан (Чуракай).

**Өй бизәү, өй киендерү.** – Кул өшәнчеге – ансы өй жыйыштыра, өйгә элә торган әйберләр, ансы кодагыйларның бүләксанагына керми. Килен өйгә элә шуларны.

**Түр ашаулығы (ашъяулыгы).** – Өйне бизиләр, түр ашаулығы эләләр матурлап.

**Түр буйы.** – Түр буйы диләр, өйгә буйдан-буйға эләләр. Түр буйлары чигәләр ийе менә. Кич утырып чигәләр ийе. Түргә элеп қуйалар ыйы буйдан-буйға. Тастымаллар асып, түр буйлары белән өйне төреп қуйалар.

**Түр қашағасы.** – Аннары түр қашағасы диләр ийе, минем үземнеке дә бар ыйы.

– Аннан соң түр қашағалары элеп қуйа бәбәй итәкле, ойа-ойа итеп чиктем мин, чәчәкләп.

**Түр элмәсе.** – Түр элмәсе була булған кешенеке. Түр элмәсен дә чигеп йасыйлар, иңеннән-иңенә түргә эләләр.

**Түр җәймәсе.** – Ашйаулықны җәйгәч, түр җәймәләрен салып қуйа, идәнгә утырырға йомошақ була. Идәнгә утырғаннар элеке халық.

**Түрләмә.** – Чигүле чуқлы түрләмәләр элдек, түрләмәләрне қызыл басмаға чигеп эшләдек. Матчаларға түрләмәләр қуйалар. Түрләмә йә чуар ситсыдан, йә уйдықлап-уйдықлап чиктек.

– Өйгә буйдан-буйға түрләмәләр қордылар. Түрләмәләр чигеп утырдық қыш буйы.

**Өй әйләндермәсе.** – Өй әйләндермәсе чигәдерийек. Өйнең дүрт почмағы өстеннән шул чигүле әйберне беркетеп чыға торғаннар ыйы. Ничә митер булғандыр ул. Бер сигеđ-ун митер булғандыр.

– Өй әйләндермәсе менә моноң киңлеге була, өйне әйләндереп алыш. Аның уртасын чигәсең, қырыйына челтәр тотасың. Бик матур була ул.

– Кийәүгә барасы қыđлар, эшкә барғачтын, чүмәлә төбендә җал иткәндә челтәр бәйләп утырыш ыйы. Шул өй әйләндермәләренә тағар өчен.

**Қашаға, матча кашағалары.** – Матча қашағалары бар ыйы, минем үземнең чачақлыйы шулай.

– Матча қашағаларын әзерләгәннәр чигеп, бәбәй итәк тотып. Матча қашағасын матур чуар ситсыдан җасыйдыр ыйық, аққа да чиктек.

**Чаршау.** – Килен белән кийәүнең сәкесенә чаршау қоралар ыйы, ишеккә дә чаршау қуйалар ыйы.

*Чәкәнне чаршау.* Бизәкләр төшереп суккан чаршау.

– Чаршауларны чәкәннәп суғалар ыйы, бизәкле чәкәнне чаршау диләр ийе, өйгә килен төшкәч, чәкәнне чаршау коралар ыйы.

– Чәкәннәп суққан төрле җептән, бизәкләр төшереп суққан була. Чәкәннәп суғу инде бер шакмағы сайын чәкән төшергәннәр, ул чәкән чәйнек қапқачы хәтле була. Ул остабикәләр, бай қызларында ғына булған. Төрле буйаулы җепләр белән чәкәннәп суққаннар.

– Чаршау булыр ыйы. Элгәре бит бүлмә-бүлмә өй жугыйы. Чаршауны инәйләр икене-өчне йасағаннар, бүлмә урынына чаршау короп йатқаннар. Йатқырма итеп теккәннәр чаршауны. Чәкәннәп суққан чаршаwы бар ыйы безнең инәйнең. Безнең инәйнең қызыл белән қарайы, шуның шақмағын чәкәннәп, йолдызсыман итеп суққан ыйы. Тегендә-монда йөртелә торған чаршауны атып қына да суғалар ыйы. *Сөрмәле чаршау* җеп аткан чаршау була.

*Чаршау суғу.* – Киҗе-мамықтан чаршаулар суқтылар. Көрөләрдән, қылычлардан алып утырғанны беләм.

**Битҗаулык, сөлге.** – Битҗаулықларын киҗе-мамық җебеннән суғып та әзерләгәннәр. Битҗаулықны ап-ак итеп суғарға кирәк, ағартырға кирәк.

Битҗаулыклар төренә, ничек эшләнешенә карап, *башлы битҗаулығы, қызыл башлы битҗаулығы, чигешле битҗаулығы, чүпләмле битҗаулығы, парчалы битҗаулығы* дип исемләнгәннәр.

– Тәрзә өстенә башлы битҗаулығы эләләр ийе ике җақтан асылындырып. Озын, дүртәр митырлы битҗаулығы булыр ыйы. Безнең заманда башлы битҗаулықлары бетте инде, чигешлеләре генә қалды.

– Битҗаулықлар эләләр тәрзә арасы сайын, көзгеләргә эләләр. Алар шул әләр өчен генә. Матур итеп чүпләмләп-чүпләмләп суққан, қызыл башлы, уртасы ақ. Инәйләр аны қолаққа туғып торалар ыйы, кийәүгә барасығыз бар дип. Мунчаға барса, мунча битҗаулығы эләләр ийе киленнәр.

– Қызыл башлы, чәкәннәп суққан битҗаулықларым бар ыйы. Абыстайлар суғып бирде аны, миңа эләкмәде алары.

Битҗаулыкларын почмаклар сайын элеп төшерәләр ийе, чөйгә кызыл башлы сөлгеләрне элеп куйалар ыйы.

– *Парчалы битҗаулыкларым* әле дә бар. Аны инәйләр чүпләп суғалар ыйы без бәләкәй чакта. Оло битҗаулығы, уртасы ак, ике башы кызыл булыр ыйы.

*Кызыл башлы сөлге.* – Килен бөтен өйгә кызыл башлы сөлгеләр элеп тутыра. Менә биш тәрәзә була икән, биш тәрәзәгә дә биш кызыл башлы сөлге элә. Асылындырып куйа тәрәзәнең ике йағына.

*Чөй җаулығы*. Өйгә элү өчен матурлап сугылган сөлге.

– Өйгә соң менә чөй җаулыклары чүпләп суғадыр ыйык. Җаулыкның уртасына ак куйып, башына кызыл куйып, шулай иттереп суға торған ыйык. Чөй җаулыкларын әнкәй төсе итеп саклыйм.

Ашйаулыкларның *түр ашйаулығы, табын ашйаулығы* дигәннәре киң таралган. – Өйнең түренә, стенага элү өчен чигеп әзерләнгән ашйаулык. – Түр ашйаулығын чигеп әзерлидер ийек. Безнең инәйләр, идәнгә утырып, ыргаклы инә белән чигәләр ийе. Инәй мине дә бик үрәтергә тырышкан ыйы, мин үрәнә алмадым.

– Табын ашйаулығын сәкегә җәйеп, сәкедә ашыйдыр ыйык. Зурлар *йөзлек* кырыйына бүкән куйып утыра, хәзерге шикелле урындыклар жук. *Түмәргә такта* кадаклап эскәмийә итеп утырыр ыйык.

**Алйапма**. Табында кунаклар алдына салына торган озын тастымал.

– Алйапма буладыр ыйы бөтен табынга әйләндереп салышлы.

Актаныш халкы паласларга *мунча паласы, түр паласы, эскәмбийә паласы* дигән исемнәр биргән.

– Мунчаның эчке йағына да җәйәдер ийек палас, йалдысына да җәйү ийе.

– Ашка җыйғанда кеше астына саласың паласны, анысы *түр паласы* була.

– *Эскәмбийә паласы* була бер иңне палас. Эскәмбийә паласы жуллы-жуллы була, озын була.

**Палас суғу.** – Кызларға эскәмбийә паласлары суғып бирдем каwирсыман итеп. Мин чүпләп сукмадым, атып кына суктым. Суккан паласым әле дә исән.

– Ничәшәр паласны суқтым бер очтан. Бер кешедән күреп қайтам икән, шуның төсле иттереп утырдым да суқтым палас.

– Мулла абыстай китәргә булғач, чәчкәләп җон җебеннән палас суқтық, қырыйларын чуқлап. Үзеңнеке, үз хезмәтең буладыр ыйы, озаққа чыдашлы буладыр ыйы үзең суққан әйберләр.

**Чыбылдық, кийәү чыбылдығы.** – Чыбылдықны тегеп қуйалар ыйы, кийәү чыбылдығын. Кийәү шуның эчендә була.

**Элмә**. Өйгә элү өчен әзерләнгән әйберләр.

*Элмә элү.* – Өйгә шул суққан, чиккән әйберләрне элү бар ыйы, элмәләр элү бар ыйы. Мин үзем киндерне бик күп суқтым суғуын, алай элмәләр суқмадым. Зәңгәр белән озатқан, қара белән читләгән элмәләр булыр ыйы. Ару кеше шулай элмәләр алып бара. Киштәләргә матур қызыл җитеннән сугылган ашйаулықларны элеп қуйалар ыйы.

**Фәрдә**. Пәрдә, тәрәзә пәрдәсе.

– Килен булып төшкәч иң беренче фәрдәләр қорош ыйы тәрәзәләргә. Өйгә эләргә барлығына қарап фәрдәләрне ақтан чигеп, челтәрләрне қулдан бәйләп қуйдық.

– Элек *тәрәзә челтәрләре* җуғыйы. Үзебез бәйлидерийек унлы кәтүк җептән. Килен төшкәч элеп қуйадырыйы тәрәзәләргә.

**Мендәр җапмалары, караwат итәкләре.** – Мендәр җапмалары, караwат итәкләре әзерләдек унлы кәтүктән бәйләп. Өйгә нәмәкәй кирәк инде. Қорордай әйберләреңе қорасың инде. Йақын туған-тумачалары өйгә эләләр килен төшкән көнне.

**Изән җәймәләре.** – Изән җәймәләре дә, сәке җәймәләре дә суғарлар ыйы қулдан.

**Чигүле ақ җәймә.** – Чигүле ақ җәймәләр әзерләдек килен булып төшкәч җәйәргә, ақ ситсы пәрдәләрне дә чиктек.

**Киштә.** – Иртән тороп, урыннарны җыйып, киштәгә күтәреп қуйалар ыйы, мендәр йастықларны матурлап қуйалар ыйы.

– Киштәләргә матур қызыл җитеннән суғылған ашйаулықларны элеп куйалар ыйы.

**Өй күрегә керү.** – Килен әйберләрен элгәч, өйне бизәгәч, күршеләр, туганнары өй күрегә керәләр.

– Өшәнчеге бармы, йукмы, өйгә элгән әйберләрен күрегә керәләр ийе, өй күрегә керәләр ийе.

– Бит җаулыкларын, матча қашағаларын элгәчтен ул өй шундый матур буладыр ыйы, гөл кебек, идәннәре ақ. Сәкегә паласын җәйә, киштәгә мендәр-йастығын күтәреп қуйа (Күҗәкә).

### *Туй мәҗлесләре (туй кучтәнәчләре, туй ашлары)*

Мәҗлесләргә бәйле үзенчәлекләргә тукталганчы, элек табынның өстәлләрдә түгел, ә идәндә яисә сәкедә корылганлыгын искә төшерик.

**Идәнгә табын җәйү.** – *Идәнгә* ашаулық җәйеп, идәнгә утырып ашау ыйы әwәле, өстәлдә түгел.

– Идәнгә башта паласын җәйә, палас өстенә ашйаулық, ашйаулық өстенә оло паднус қуйып, шунда тезелеп утырып ашау ыйы.

– Ашаулық қырыйына кеше астына утырыға җурғанмы, паласмы, шулай әйләнәләй салалар. Кеше алдына капларға озон сарфиткә сузалар.

**Сәкегә табын җәйү.** – Элгәре сәкегә утырып ашағаннар, сәке қырыйына *букән* қуйып утырғаннар.

**Туй күтәрү**. Кияү ягыннан кыз ягына туй үткәрү өчен ашамлыклар китерү.

– Туй күтәрегә китерәләр ийе кийәү йақтан. Инәй сүлидер ийе, қодаларға туй үткәрегә сарық суйып илттек, дип, май китердек, он, ит, бал китердек, дип. Кийәү йағы шулай китерегә тийеш булған. Беднең дәwергә беткән ийе инде алар (Уразай).

*Бал китеру.* – Туйға тәпән белән *бал* китерде безнең әти абзый өйләнгәндә, қыз йағына илтеп бирде.

**Туй кертү.** Туй кунакларын һәм кодаларны мәҗлескә чакыру.

– Қода-қодагыйларны, килгән ийәрченнәрне арчилары белән қунаққа чақыралар, очтан-очқа җөриләр атлар белән.

**Ашқа алу, ашқа җөртү**. Туй кунакларын һәм кодаларны мәҗлескә чакыру.

– *Ашқа алу* бар қода белән қодагыйларны, уникешәр ашқа алалар ыйы туй узғач та.

– Ашқа җөртәләр ийе, башқаwылга да килеп алып китәләр ийе атлар белән. Мончасын җағу инде, бәлешен салу.

– Көн сайын муча йағыш, тәбикмәк пешереш. Қодаларны, қунақларны муча кертеш. Тәбикмәк белән чәй эчкәннән соң ашқа китеш инде. Өйдә утырып торош йуқ. Ирләр үзалдына, қатыннар үзалдына җөрделәр ашқа. – Ул қодалар хәзерге сыман ашап-эчеп кенә китмәделәр, дүртәрне қуна торғаннар ыйы. Аларны инде аwыл кешесе әзерләнеп көтеп торды. Қодаларны чиратлап *ашқа алу* булды. Өй борончa ашқа җөрттеләр. Дүртәрне қуналар ыйы қодалар. Менә беdнең бәләкәй генә аwыл ыйы, теге өйдән бу өйгә дә ат белән алып керделәр, ат җигеп. Җигүле ат көтеп тора инде тегеләрнең аштан чыққанын. Безнекеләр унике өйгә ашқа кердек дип қайтырлар ыйы.

– Кодағыйлар ат белән килделәр. Кучеры да, гармунчысы да қайтып китмәделәр. Бер өйдән чығалар, икенче өйгә ашқа керәләр.

– Туй wақытында өйгә қайтып кермәле түгел. Ашқа-чәйгә чақыралар. Әллә ни сыйы булмаса да барыбер чақыралар.

*Қода төшерү.* – Килен йағында да қода төшерәләр ийе, малай йағына да. Дүрт кич қунып қайтыш ыйы. Хәзер менә туйлар үтә дә китә, қайтып китә, күреп дә қалмыйсың. Берне генә қунмадылар элеке, тақ була дип. Җеп кирәк, җә икеле, җә дүртне қундылар.

– Берсендә қода төшердек қызнықын. Тотынды буран, бер җиргә дә барыш түгел. Қыш көне бит, җулны қар басты. Безнең қодалар бишне қундылар китәлмәйенчә. Без әйттек: «Биш белән генә булмый ул, тақ була». Алтынчы кичне дә қундылар. Шулай итеп аларны аwылларында көтеп утырғаннар.

– Доға қылып, қода-қодағыйларны қаршылап торалар. Бәләкәй өйдә дүрт кич қуналар қодалар. Күршеләр чиратлап ашқа алалар қодаларны. Сәғәт қуйып, фәлән wақытқа без дип көн буйы ашқа йөреш булды. Мин үскәндә дә шулай булды әле (Уразай).

*Қода зату,* дип, қода китәсе көнне дә табын җыйалар ыйы (Әнәк).

**Күчтәнәч чанасы.** – Туйға зурлап килеш ийе. Күчтәнәч чанасы үзенә айырым булыр ыйы.

**Пар қаз.** – Туйға килгәндә пар қаз белән киләләр «пар булсыннар», – дип.

– Пар қаз апкиләләр ийе. Қазны қарындыққа төреп, ашаулыққа төйнәрләр ийе.

**Бодай күмәче.** – Бодай күмәче ике, йә дүрт булыр ыйы. Қабарып пешә, қыԁықайым. Дүрт күмәч булса, дүртәр кич қуну ыйы элгәре.

Қодалар-кодағыйлар дүрт кич қуналар, дүрт кичкә дүрт күмәч алып киләләр. Үзләре пешергән күмәч, чәкчәк, пар қаз, пар қазы булмаса сарықның бер санын пешереп алып килә. Пичинйә-мазар ғына алып килеш түгел ийе ул ԁаманда. Күмәчен дә дүртне алып килеш ийе.

**Базар қалачы.** – Қайсы кеше базар қалачы да алып киләдер ийе.

**Ипекәй.** – Ағач күәстә ипекәйне күб итеп басар ыйық. Аны әwәләп йастық өстенә қуйасың җәймә җәйеп. Шулай җәймә өстенә ипекәйләрне әwәләп қуйасың, алар қабара матур итеп.

– Мичкә йағып пешерәбез, ипекәйнең йөзе килсенгә қатық сөртәбез өстөнә.

**Қош теле.** – Қайсыберләре қош телләре пешереп алып килерләр ийе туйға. Қош теле булса, казанда пешерү ийе. Өч литыр майны саласың, қайнатасың, хәзер саласың, хәзер аласың, бик тиз пешеп чыға. Майны күп салсаң, майы да кимеми, кош теле дә тиз пешә. Туйға қайсы баwырсақ, қайсы қош теле пешерер ийе.

**Килен чәйе, килен күчтәнәче**. Туйда килен төшкәч үткәрелә торган мәҗлес.

– Килен чәйенә, килен күчтәнәченә җыйдылар әбиләрне, қортқаларны. Килен инде чәкчәкләр алып килә, чәкчәк пешерергә оннар алып килә.

– Бер көнне мин килеп төштем килен булып, килен чәйе үткәрдек. Икенче көнне қайын сеңлем китте күрше аwылға килен булып. «Килен, син *җөԁ иттең* инде, Орқыйаға биреп җибәрәйек күчтәнәчләрне. Ул да җөԁ итсен», – ди бийәнәй қортқам (Әгъбәз).

**Туй балы.** – Кийәү бал китергән биш пот, туй алдыннан китергән.

– Балны тәпәнгә салалар ыйы *умарта менгәндә.* Чәкчәк баллау өченгә бал булыр ыйы. Қышлау умарталар күп булған, бағана умарталар. Ағач қуышыннан була қышлау умарталар.

**Бал койу.** Бал әчетү.

– Туйларға бал қойош ыйы. Идел буйыннан қолмақ алып кайтыр ыйық жыйып. Бодайны қайнатып, қолмақ суы, шикәр салып йасыйдырыйық. Балны чәйнүккә салып, чәйнүктән алып эчеш ийе.

– Туй йасыйсы булса бал қойалар ыйы. «И, балы зәһәр дә булған», – дип сүлиләр ийе. Ағач бичкә булыр ыйы, бичкәсенә хәтле әйбәт, диләр.

– Туған-тумачалар бучкы белән бал қойоп алып килеш ийе. Туй қунақларын хөрмәтләү булды ул (Уразай).

**Баwырсақ.** Актаныш төбәгендә *баwырсақ* сүзе дә, *чәкчәк* сүзе дә кулланыла.

– Бик әйбәт иттереп, оло иттереп баwырсақ пешереп алып киләләр йегет йағыннан да, қыз йағыннан да. Туйда аларның икесе дә чыға инде.

– Баwырсақны баллап қатырып, төреп алып киләләр. Зур ашйаулыққа төреп алып киләләр. Зур ашйаулыққамы, битжаулыққамы төрәләр. Туйға баwырсағын пешерәләр. Жиңгәйдән сора менә. Күкәйне тугисың-тугисың да қамыр басасың қаты итмичә генә. *Әнәчәлибез,* кисәбез дә майға салабыз. Баwырсақ бик *онны сайлый,* йақшы он, *ару он* кирәк. Баwырсақ та, чәкчәк тә – безнең мөселман халқының *табын күрке.* Таwық күкәйенең сарысыннан чақ қына бәләкәйрәк итеп, түгәрәк итеп пешердек без баwырсақны. Элгәре пичтә пешерү ийе, икешәр таба белән пешерәдер ийек. Хәзер пелитә йанында тәпи өсте тороп пешерәбез. Пичтә бит ул табағачыңы тығасың да аласың ғына. Элгәре баwырсақны икешәр кеше күтәрәдер ийе патнусын, оло итеп пешерәләр ийе, сиксәннәп, йөзәр күкәйлек баwырсақ пешерәләр ийе. Мин үзем дә баwырсақ пешерергә күп йөрдем. Баwырсақны балға шикәр қушып қайнатып бутыйсың аны.

– Туйға баwырсақ пешергәндә кешенең уңар белән уңмасы беренче табақны пешергәндә үк билгеле буладыр ыйы. Баwырсақ жә шиңә, жә жарыла. Пешерүчеләр белән әз генә ыһым-

ыһым сөйләшәдер ийек тә аны җәүнәмидер ийек инде. Әз генә булса да бозылышып алалар ыйы шулар.

**Баwырсақ бизәү.** – Баwырсақ өстенә қақлар, қамфитлар, wақ *җимешләр* тезәләр. *Алма ақлары, җиләк ақлары* белән бизиләр (Уразай).

**Кийәү баwырсағы.** – Кийәү баwырсағын қыз йағы ата-инәсе әзерләп бара, қода булып барғанда.

**Қыз баwырсағы.** – Қыз баwырсағын ата-инә қыз йағына барғанда әзерләп бара. Қыз баwырсағы зур итеп йасалған була. Зур паднусқа қуйып, төйнәп киләләр баwырсақны, аны элекерәк ашаулыққа төйниләр ийе. «Қыз уңарға булса, баwырсақ та уңа», – диләр. Әйтем шундый. Майы күп, йомырқасы күп, пешереп кенә торабыз туйларға.

**Табын баwырсағы.** – Табын баwырсағы wақ-wақ итеп йасалған була. Қунаққа килгән һәр кеше баwырсақ белән килә зурлап, хөрмәтләп. Паднусқа баwырсақны қуйып, өстенә чигүле ашаулық йабалар, шулай алып киләләр. Баwырсақ өстенә *қақ* та йабалар.

**Баwырсаққа чақыру.** – Кийәүне қыз йортына алып килер алдыннан йегетләрне баwырсаққа чақыралар кийәү йортында. Йегетләр сыйлана. Аларны озаталар да кийәү әзерләнә қыз өйенә никахқа барырға.

**Баwырсаққа бүләк салу.** – Қыз баwырсағын башта wатмыйлар. Аны күрсәтәләр ачып табында. Қыз атасы аңа туй бүләкләре әйтә. Аңарға нәрсәкәй бирәселәре килә зурлап, хөрмәтләп, зур-зур әйберләр әйткәннәр. Саwыт қуйалар, теләгән кеше бүләк сала. Қыз баwырсағын ачқанда бөтен туган-тумача күчтәнәчләр, бүләкләр салалар. Ақчалата, баллата, әйберләтә салалар. Қайсысы ат бирәм, қайсысы сыйыр бирәм, ди. Хәзер инде думнар алып бирүчеләр дә бар, диләр. Туйда баwырсақ ачқан чағында дүрт почмағын дүрт кеше ача, теđелеп басып. Бүләк әйтәләр ийе. Қайсы кеше бүләкне әйтә дә wақытында бирми. Әйтәләр ийе, менә туйда баwырсақ ачып бүләк әйтте, бирмәде, дип. Туйда башта йегет баwырсағын ачалар, аннары қыз баwырсағын ачалар. Бүләк саласың қыз баwырсағына. Башта бер почмағын бер қода ача, бүләк әйтә, икенче почмағын икенче қода ача, бүләк әйтә. Аннары қалган кешеләр ачалар, бүләк әйтәләр.

*Баwырсаķ ачу.* – Туйда баwырсаķ чыға. Ķода-ķодағый йегет йағыннан бер почмағын ача, ķыз йағыннан төп ķода-ķодағый ķалған ике почмағын да ача бисмиллаларын әйтеп.

*Баwырсаķ ачучыға бүләк.* – Баwырсаķны беренче ачķан кешегә йаулыķ була, чәй була өстә, күчтәнәч була. *Йә табын алып баручы* ала инде аны (Әнәк).

**Чәкчәк.** *Чәкчәк пешерүче.* – Мин үdем чәкчәк пешерүче ийем. Уңса бик йараталар, күчтәнәч-бүләкне дә күберәк бирәләр. Уңмаса – йуķ. Күкәйне уннымы, умбернеме сытып саласың бер коштабағына. Әdерәк уķырға да кирәк, уķымыйча аны пешерәм димә. Шул көйгә аны туķыйбыd, ķабарса бик шәп инде. Ķыdған майда пешерәбеd. Аны оло паднусķа өйәләр. «Әллә уңа, әллә туңа», – дисең чәкчәкне.

*Чәкчәк остасы.* – Элгәре чәкчәкне билгеле кеше генә, аwылда бер кеше генә пешерәдерийе. Чәкчәк остасы буладырыйы. Оны да ķәдерле, майы да ķәдерле булған. Чәкчәгең уңмаса нәмә эшләргә кирәк.

Әсмабикә ķортķа оста пешерә торған ыйы чәкчәкне. Май артыķ ķызу булса, чәкчәкне йарып җибәрә. – Йомырķаны суытķычта тундырабыз, эретәбез дә үзенең күперткече белән күпертәбез. Ун йомырķаға бер ķашыķ ғомбағыш майы, әз генә суды салабыз. Күпертәбез-күпертәбез дә он салабыз, басабыз, җәйәбез, кисәбез. Олейна майы әйбәт чәкчәккә. Элек туңмайда пешерәдерийек. Майны артыķ ķыздырырға йарамый, артыķ ķызса, чәкчәк йарыла.

**Чәкчәкне җомочķа йағып пешерү.** – Элек чәкчәкне җомочķа йағып ķаdанда пешереш ийе. Хәdерге кебек газда пешерү, келтерәтеп кенә алыш түгел ийе. Җомочķа йағалар ыйы ķаdан астына. «Күп йаķма» дип торалар. Чәк кенә күпкә китсә, су сибеп җибәрәләр пырлатып.

**Чәкчәкне салам йағып пешерү.** – Чәкчәкне ķаdан астына салам йағып та пешерделәр. Саламны бөгәрләп-бөгәрләп ķаdан астына тығып тордылар. Ул бик тиd йанып бетә. Майны да, чәкчәкне дә көйдермә дә, йандырма да. Элек сары май белән пешерделәр. Хәdер ғомбағыш майы белән пешерәләр.

**Чәкчәкне зур итеп йасап ķуйу.** – Чәкчәкне зур итеп йасаш ыйы, менә шушы өстәл буйы булды. Ике кеше күтәреп

кертерләр ийе. Wақ-wақ қына иттереп кисеш, бал белән қатырыш ыйы, борчақ-борчақ қына булыр ыйы чәкчәк. Хәdер эре итәләр, барнақ чақлы чәкчәк. Паднусқа қатырыш чәкчәкне.

**Чәкчәк өстенә қақ қойу.** – Чәкчәк өстенә қақ қойыш булды. Қақ қойоп чәкчәкнең өстенә қапладылар. Җиләк қағы, алма қағы, балан қагы булды. «Қақлы чәкчәк – хақлы чәкчәк». Аңа инде бөтен кеше ақчамы, бүләкме сала.

**Чәкчәк төйөнчеге.** – Чәкчәк төйөнчегенең башына йақшы чәйләр, затлы йаулықлар қуйыш ыйы. Кем башлый чәкчәкне, шул ала ул бүләкне (Чуракай).

**Кодағый чәкчәге.** – «Кодағыйның чәкчәге җөd күкәйдән җасалған» дип әйтерләр ийе. Җүне булған қодағыйлар dур чәкчәкләр белән киләләр ийе.

**Йегет чәкчәге.** – Йегет чәкчәген пешереп, йегет қыз йанына барғанчы, йегетнең дусларын чақырып, туғаннарын чақырып аш үткәрә торған булғаннар. Шул чәкчәккә туған-тумачалар ақча сала торған булғаннар. Қардәшләре, нәсел-нәсәпләре чәкчәк ашарға килеп ашны үткәргәннән соң қыз йағыннан йегетне килеп алалар атлар белән.

**Қыз чәкчәге, килен чәкчәге.** – Қыз чәкчәген бер қызыл ашаулыққа төреп чығаралар ыйы. Кем ача, шул бүләк әйтә. Чәкчәк өстенә *җиләк қағы* йаба, камфитлар тезгән була. Чәкчәкне элеке қаdанда пешерделәр, табада пешерделәр пичтә. – Ике оло чәкчәк алып барыш ыйы. Бер оло чәкчәк – ансы туйға чығарырға, икенче килен чәкчәк, чәй эчәргә, килен чәйенә. Туйға чақлы оло әбиләрне җыйып чәй эчерерләр ийе.

**Қыз чәкчәген қотлау**. – Қыз чәкчәген қотлыйлар туйда. Табында чәкчәкне беренче қызның әтисе белән әнисе, аннан җегетнең әтисе белән әнисе, аннан туғаннары қотлый. Тәрилкәгә ақча салалар. Қыз чәкчәгенә туйда бүләк салалар, ақчалатамы, әйберләтәме. *Туй қотлау* була.

*Чәкчәккә бүләк әйтү.* – Чәкчәкне ашйаулық белән қапланған була. Җегет җағыннан туғаннары ача да миннән сарық, ди. Икенче туғаннары ача да, йә умарта, йә қаз, ди.

– Алтмыш-житмеш күкәйлек чәкчәк була. Чәкчәкне ақчачтын чәкчәк қотлау була. Дүрт почмағыннан дүрт кеше ақчачтын

бүләк әйтәләр дүртесе дә. Җә мал әйтәләр, җә акча әйтәләр. Мин үзем әйтеп ачтым мал бирәм, дип.

*Чәкчәк бүләге.* – Чәкчәккә бүләк салырлар ыйы, чәкчәк бүләге булыр ыйы. Ќайсы салыр ыйы җаулыќ, ќайсы салыр ыйы ойоќ, ќайсы – күлмәклек, ќайсы акча салыр ыйы.

*Чәкчәкне ќушлап алу, ќуш чәкчәк.* – Ќыз йағыннан да, малай йағыннан да зур-зур паднуслар белән туй чәкчәге пешерерләр ийе. Табынға ќуйғач, туй чәкчәген бер дә берәмләп кенә алу жуғыйы, ќушлап алалар ыйы, ќуш чәкчәк алырлар ыйы.

«Ишле-ќушлы булып,
Бала-чағалы булып
Ғомер итсеннәр».

*Чәкчәк ачучы.* – Чәкчәк ачучыға иң өскә шәлҗаулыќ салған да чәй салған. Туйда ќодалар ача чәкчәкне. Икесе ике йаќтан баса да бүләген әйтеп ачалар. Башта берсе, аннары икенчесе, ќыз йағы ќода беренче ача чәкчәкне. «Миннән ќызыма, кийәwемә бер ќышлау тана», – ди. Шулай мал әйтеп ачќан. Беренче ачќан ќодаға була өстәге бүләк.

**Туйда чәкчәк кертү.** – Паднус-паднус чәкчәк булыр ыйы. «Күтәреп булмый, ишектән сыймый», – дип торған булырлар ыйы шулай. Бүләк сорыйлар.

– «Ишек борысын ачмыйчы булмас, сыймый», – диләр. Бүләк сорыйлар. Бүләк биргәч сыйа инде чәкчәк. Ќыdығ инде үзенә күрә. – Чәкчәкне алып кереп күрсәтәләр дә: «И-и, ќодағый зурлап килгән икән», – дип, кисәләр дә тәлинкәгә салып чығаралар ќунаќларға. Чәкчәкнең җартысын үdләренә биреп җибәрәләр.

**Шоморт чәкчәге**. Шомыртны киптереп ясала.

– Шоморт чәкчәге йасарлар ыйы. Шомортны җыйып, киптереп, тегермәндә тарттырып шоморт оно җасадылар. Аны писүкләп чәкчәк итеп ќуйарлар ыйы (Әнәк).

**Төш.** – Беdнең dаманда утыd-ќырыќ күкәйдән төш пешердек. Чәкчәк тә диләр.

– Элек wағ итеп пешерәләр ийе төшне. Күкәй туғыланып беткәч, онны саласың да әнәчәлисең, табаға җылыраќ ќына майға саласың. Төшен салғач, ул үзе күпереп ќайный.

– Төшкә миләш кағы қаплый, өстенә җаба. Төшкә қапларға дип миләш қагын үзем җасыйм. Миләшне чемнисең, әзрәк су салып пешерәсең, ул суны түгәсең дә төйәсең, аннары иләктән чығарасың да киптерәсең.

*Төш пешерүче.* – Минем инәй авылда оста төш пешерүче ийе (Күҗәкә).

**Қоймақ, кийәү қоймағы.** – Қыз җиңгәсе кийәү килгәчтен wақ қына итеп, матур ғына итеп пешереп, кетертәп торырлык булсын, кийәү қоймагын қыз белән кийәү бүлмәсенә кертәләр. Алар кийәү қоймағын керткәчтен, кийәү сиздермичә генә ақча сала торған булған.

– Төче қоймақ пешерәләр кийәүгә, кийәү қоймағы дип. Җиңгә генә қарый кийәүне.

– Беđнең инәй килен булып төшкән җылны күđенә қамыл төртелгән, суқыр булып қалған. Шулай булса да кийәүләргә бер көн дә қалмыйча, қоймақ пешерә торған ыйы инәй. Қоймақсыз, мунчасыз йуқ инде. Қоймақ җанына дөге үрәсе, дөге бәлеше дә пешерерләр ийе.

– Кийәүгә мунчадан чығуға төче қоймақ, баллы қоймақлар инде. Әйтешле дә түгел. Беđнең инәй оло түтине биргәчтен, *баллы май* белән майлыйдыр ыйы қоймақларны.

*Қоймақның уртасын тишү.* – Қоймақ пешергәннәр кийәүгә, төче қоймақ. Әгәр дә қыđ булмаса, кийәү қоймақның уртасын тишкән дә чығарып җибәргән, уртасын қабып тишеп қуйган. «Кийәү, ник қоймақны алай иттең, кирәкмәс ийе», – дисәләр: «Қыđыңнан сора, әби», – дигәннәр кийәүләр.

**Җарма қоймагы**. Камырга бүрттерелгән тары ярмасы кушып пешерелгән коймак. – Қайсы кеше җарма қоймағы да пешергән. Тарыны оннап, бодай қамырына қушқаннар (Татар Суыксуы).

**Бәлеш.** – Туйда пар бәлеше, ите, пар қаđы чығадыр ыйы өстәлгә.

– *Бәрәңгеле-итле бәлешкә* әнис орлыгы салып пешерәбез, тәмле, хуш исле була.

– Бәлешне ачып җибәрделәр, ашамыйчы утыра қызым. «Аша, аша», – дигәч, – «Мин чүп қойылган дип белдем», – ди, әнис орлығы салғанны белмәгән теге.

*Бәлешне бүлү.* – Табын қараучы бәлешне үзе ачып бүлә. *Бәлеш қапқачын* кисә дә алып қуйа. *Бәлеш ирнәwен* wақлап салып бирә кеше сайын.

– Қайсы кеше әз генә сал дийә, қайсы кеше эндәшми бер дә. Әз ашала ул бәлеш (Күҗәкә).

*Wақ бәлеш.* – Wақ бәлеш пешерделәр қодағыйларға иртәнге чәйгә.

**Тукмачлы аш, пилмин.** – Туйда *туқмачлы аш,* қатық, чәй тәмнәре була. – Туйда *пилмингә* хәдәре булды дип әйтерләр ийе, *дары үрәсенә* пилмин салып пешергәннәр (Әнәк).

### *Төрле ашлар*

**Төплекәй**. – Төче қамырны басып, йуқа ғына итеп җәйеп, өстенә эремчек җә бәрәңге төйөп йағалар. Мич төбенә салып пешерәләр. Ул төплекәй була. Бәрәңге төплекәйе, эремчек төплекәйе була (Уразай).

**Қыстыбый.** – Қыстыбыйны да мин үзем пешерәм бик тәмне итеп. Қыстыбыйны мин майға, сөткә басам, җә қатыққа басам. Қамырын җәйәбез дә түгәрәкләп табада пешерәбез. Бәрәңгене пешереп төйәбез дә йомырқа сытабыз, каймақ йә сөт салабыз да ике қыстыбыйны йәнәшә итеп майлап өйөп қуйабыз табаққа (Татар Суыксуы).

**Күзикмәк.** – Күзикмәкне күкәйгә генә басып җәйәбез дә майда пешерәбез. Қаз майы белән майлаған күзикмәк тәмле булыр ыйы, қаз өмәләренә пешерер ийе инәй (Әгъбәз).

**Қалын таба.** – Қалын таба, дип, менә он белән судан қамыр басып табада пешерәбез мичкә қуйып. Менә түткәй белән қалын таба салдық (Уразай).

**Кәлҗемә.** Өшегән бәрәңге күмәче. – Кәлҗемәгә өшегән бәрәңгене қазып алып қайта торған ыйық. Аны чистартып, бәләк белән табақта төйөп, табаға күмәч кебек түгәрәкләп тезеп қуйар ыйық, аны бала сайын санап бүләр ийек (Уразай).

**Шишара** (шишәрә). Кечкенә ипи, аны гадәттә хәер итеп биргәннәр. – Күәстә ипи басабыз. Бер кечкенә ипи итеп әwәлисең дә қуна тақтасында шишара дип пешерәсең. Ул озынча була. Икене саласың шишара. Берсен хәйергә бирә, берсен қайнар

көйе өстәл өстендә турый, чәй эчәләр. «Шишара пешкән, чәй эчәбез», – дидер ийе инәй.

– Ипиләрне мичкә тығабыз. Озынрақ итеп шишара сала ипи арасына мичкә. Ул тизерәк пешә.

– Күәстә ипи қабарып менсә, тизерәк шишәрә әвәлисең, ипийең беткән булса. Шишәрәнең пешүен көтеп торасың. Күәс төбендә камырың қалса, тағын мич қырыйына тығасың инде сыйса.

– *Бийем қарчығым* әйтәдер ийе без қырға шишара алып киткәчтен: «Сезнең қайтқач ашар җирегез дә қалмыйдыр инде, бер шишара ашап қайтқансыз», – дип. Аны җыйылып ашыйсың бит инде. Бер чүлмәк қатықны ашыйдыр ыйық шишара белән.

*Шишара «саваплы ипи»* дип йөртеләә. – Шишараны самый пич аwызына ғына қуйа да пешкән ынғайына қайнар шишара белән чәй эчәләр ийе.

– Қайнар шишара белән күршеңне чәй эчәргә чақырырға қушқан, аның бик күп саwабы. Йаңа йазған май, қайнар шишара белән чәй эчертсә күршең – иң зур саwап.

– Алтышар түгәрәк ипи пешерә дә шишараны бер йәтим карчыкка бирә.

– Пич төбенә ике йақ қырыйына өчәр ипи салабыз, шуның уртасына ике шишара салабыз. Хәзерге батун төсле була шишара.

Бер шишараны хәйер итеп күрше әбигә кертер ийе инәй. Әтей әйтер ийе: «Қыdым, ипи салған көнне кеше керсә, чәй эчерми чығарма. Қорбан ите белән бер булыр ди ул җылы ипей белән чәй эчерү», – диләр ийе. Шулай үрәттеләр беdне.

**Тәбикмәк, тәйекмәк.** – Коймақ қамырыннан оло итеп табаға салып пешерәсең. Қоймаққа қарый шуны җараталар. Табаны *сөрткеч* белән сөртәләр дә пешерәләр, пешкәч кенә майлыйлар. Тәбикмәк киндер майы белән тәмле була.

– Тары төйөп, җарма җасап, тары оны белән тәйекмәк пешереш. Чәк кенә бер эстәкән белән тары йармасы бүрттереп салабыз. Күп салсаң әйбәт булмый. Олы күәс белән пешерәбез бит. Көлчә булды да тәйекмәк булды элгәре.

– Тәбикмәк пешерү менә болай була. Он белән баш йасап қуйасың да кичтән, ипи ачысы белән қатыштырып. Бер нәмә дә салмыйсың әле, ипи ачысына шул он белән су ғына. Кичтән

қаплап қуйасың. Иртән торғачтын, бодай онын да, үзең тартқан дары онын да саласың, әз генә дары йармасын бүрттереп тә саласың. Аннан ары төйерләнмәсен өчен болғатасың, тоз саласың. Қуйы иттереп кенә болғатасың да аннары сыйықлайсың. Чүмеч белән табаға салғачтын җәйелеп китәрлек булсын ул. Шулай итеп, пешерәм дигәндә генә әз генә чәйни суды җибәрәм. Җитешкән, күпереп менгән қамырға шул судыны салам. Болғатасың да пешерә башлыйсың (Татар Суыксуы).

**Көлчә.** – Тәбикмәк ул қалса, суынса әйбәт булмый, көлчә ул суынса да әйбәт булыр ыйы. Күб итеп қызартып пешереп қуйар ыйық. Аны инде урып ашап чығып китәрләр ийе сабан туйға килгән кешеләр (Әнәк).

**Тәкә.** – Шоморттан, бөрлегәннән, баланнан тәкә пешерделәр.

– Баланны пичкә қуйарлар ыйы. Кичтән қуйар ыйы, икенче көнне иртән алыр ыйы әни. Әз генә өстенә он саладырыйы баланға. Төбенә әз генә су саладырыйы да әкерен генә парланып пешәдерийе.

– Шул тәүлек буйы төчеләндергән баланнан балан тәкәсе пешерер ийе әни. Элек «тәкә» диләр ийе, «пирук» дип әйтмиләр ийе (Күҗәкә).

**Әлбә.** – Әлбәне әwәле менә қунақ килеп керде, тиз генә чәйгә пешереп алыр ыйы инәй. Әйбәт ақ майны эретеп сала, писуқ сала, он сала, болгап-болгап пешерәләр. Ул кетертәп тора, чәй эчәргә бик тәмле, туқлықлы була (Әнәк).

**Қызыл билле перәннек** (инкыйлабка хәтле чорларда сатуда булган үзенә бер төрле формалы перәннек). Г. Тукай әсәрләрендә дә телгә алынган: *Кызыл билле ал перәннек қызыктыра қызларны.*

– Қыdыл билле перәннекне әwәле җул җөргән чағында алып қайтырлар ыйы, җыйыннарға барсалар алып қайтырлар ыйы. Ул ал була, биле нәзек була. Әле беdнең dаманда да булды ул. Уртасыннан билбау белән буган кеwек булыр ыйы, шулай қыdыл сыdық буладыр ыйы. Аны сабан туйларына, әрәпәгә дип, балаларға өләшергә дип алып қайталар ыйы (Чуракай).

**Башлы шикәр.** – Башлы шикәр булыр ыйы әwәле, менә шушылай очлайып килгән шикәр. Күк алашаға да башлы шикәр

қаптырып қарадық без сабан туйында. Башлы шикәр чүмәлә кебек итеп йасаған булыр ыйы, байларда булыр ыйы күберәк (Татар Суыксуы).

**Чөгендер суы.** – Аш, бәлеш, ит чығаралар. Аш артыннан қыdыл чөгендер суы чығаралар. Чөгендерне олы чүлмәкләрдә пешереп, шуның суын қуйу ыйы. Чәй эчертү дә жуғыйы әwәле. «Чәй куймадым инде», – дийәрләр ийе (Әгъбәз).

Авылларда киндер үстерү, киндер сугу гына түгел, киндер орлыгыннан төрле ашамлыклар әзерләү турында да күп истәлекләр калган.

– Үзебез бақчаға чәчәдер ийек киндерне, киндер орлығы күп булыр ыйы.

**Орлық (орлоқ) майы.** – Киндер орлығын төйөп, башта майын чығаралар ыйы. Киндер орлығыннан чығарған май, киндер майы йәм-йәшел, бик тәмле буладыр ыйы, *тәбикмәк* ашарға, *пирәмәч* ашарға бик тәмле орлық майы.

– Орлық майын қыздыра да пешкән жиренә сөртә, бик тиз төзәтә.

**Орлық ойырчысы.** – Башлы көйлеләр була. Орлықны төйәсең дә бер кәнди ойырчысын алып қайтабыз *кәнди* белән. Ул шул көйе ашарға бик тәмле була.

**Орлық ыйырчығы.** – Орлықны нығытып төйгәч, қул белән баса-баса үзләндереп майын чығарадыр ыйық.

– Шул *орлықның ыйырчығын* әd генә писүк салып, түгәрәкләп, чәй эчәргә өстәлгә қуйадыр ыйық, *баллаған орлық була,* чәй эчәргә бик тәмле буладыр ыйы.

**Орлық әнәчәсе.** – Киндер орлығын төйөп, майын чығаралар ыйы. *Әнәчә* дип атыйлар ыйы шул майы чыққан орлықны. Таwық йомырқасы кебек йомарлап қуйалар ыйы майын сыққачтан. Шуны орлық әнәчәсе дип атыйлар. Бәрәңге белән дә ашыйдыр ыйық киндер орлығы әнәчәсен (Күҗәкә).

**Орлық чәкчәге.** Киндер орлыгын төеп ясала.

– Орлық чәкчәге диләр, бик тәмне була. Орлықны төйөп, майлап пешерделәр. Аны төйгәндә тимер көйледә төйәсең. Писук беләն болғатып, wақ-wақ қына қына иттереп җомарлап қуйасың табынға.

**Орлық дурочмағы.** – Орлық дурочмағы түгәрәк була. Орлықны төйөп сыйықлый да ачы қамырға йаға, *қабартма* өстенә йаға. Ачы қамырдан қабартма итеп, өстенә орлықны төйөп йақсақ, шундайын тәмле ризық буладыр ыйы.

**Орлық қыстыбыйы.** – Қыстыбый тышына шул орлықны төйөп йағадыр ыйық. Орлыққа сөт, йомырқа саласың. Орлық қыстыбыйы була.

**Орлық пирәмәче.** – Орлықны көйледә төйөп, орлықның пирәмәчен пешерәдер ийек. Орлық пирәмәче дидер ийек. Орлықны төйөп йағадыр ыйық қабартма өстенә.

**Орлық тәкәсе**. – Орлық тәкәсе пешерәбез, орлықны йарма белән қушып салабыз.

**Орлық белән бәрәңге тәкәсе.** – Орлықны төйөп, бәрәңгегә қушып, орлық белән бәрәңге тәкәсе пешердек майлап.

**Орлық белән бәрәңге ботқасы.** – Орлық белән бәрәңге ботқасы пешердем әле диләр, бик тәмле була, майлы була.

**Чуар тәкә.** – Орлық тәкәсен «чуар тәкә» дип йөридер ийек. Тары йармасы белән орлықны кушып пешердек. Тары йармасына орлықны қушқач чуар була, қаралы-ақлы була бит инде, «чуар тәкә» дип әйтәләр ийе шуны. Шулай орлықны йарма белән бутап, тәкәсен саладыр ыйық.

**Қазан тәкәсе.** – Қазан тәкәсе дип wақ қына итеп пешерәләр ийе киндер орлығы салып. Қазан тәкәсе дип wақ қына итеп йасап, шулпада пешерәдер ийек пилмин шикелле итеп (Әнәк).

**Мүгез.** – Мүгезләрен пешерәдер ийек орлықның, орлық мүгезе дип, бәрәңге белән дә кушып пешерәдер ийек. Мүгез, диләр бездә, тәкә, димиләр. Шул төйгән киндер орлығын, қабақны турап мүгез пешерәдер ийек. *Җарма мүгезенә* дә орлық қушадыр ыйық.

**Төш өсте.** – Қамырны жуқа итеп җәйәсең дә, шуны табада пешереп аласың майда, күзикмәк була. Шуның өстенә төйгән орлықны әнәчәләп йағалар. Аны «төш өсте» диләр. Шушылай иттереп өйөп қуйарлар ыйы. Аны сындырғалап, кисеп чәй эчү ийе (Татар Суыксуы).

Актаныш ягында тары үстергәннәр һәм аңардан төрле камыр ризыклары әзерли торган булганнар. Мисал өчен:

**Тары қыстыбыйы.** – Тарының қыстыбыйын пешерәдер ийек.

**Тары өйрәсе.** – Тары өйрәсе, дип, исләре китеп сөйли торганнар ыйы. Wак-wак қаз ите турап пешерерләр ийе.

**Тары тәбикмәге.** – Тары тәбикмәге пешерәдер ийек өмәләргә булышқан қатыннарға.

– Тәбикмәкне бодай оны белән изәсең. *Җарма онный* торган ыйым берәр *бидерә*. Тары җармасын онныйбыз, *көйледә* төйәбез инде. Җарма оны белән җаңартып пешерәсең. Пешерә башлар алдыннан ғына, бәләкәй генә чәйни суды салсаң, бик тәмле була, қабарып пешә торган ыйы.

– Тәбикмәкне бодай оны белән кичтән изәсең икән, ул иртәнгә ачый. Шуңарға ачығач иртәнчәк су саласың, сыйықлыйсың да теге җарма онын салып туғылыйсың, пешерер алдыннан ғына теге чәйни судыны саласың күәсеңә. Алдан салсаң ташуы бар. Бик тәмне була тәбикмәк. *Тары* йармасын да кушалар нық қына пешереп (Татар Суыксуы).

*Тары йарғычы.* – Тарының йарғычы бар ыйы.

Актаныш авылларында **солы онынннан пешерелгән ашамлыкларны** да искә төшерделәр:

– *Солы оны* бөтен нәрсәкәйгә дә әйбәт булыр ыйы. *Солы умачы, солы чумары* пешерәдер ийек солы онынннан. *Қашық чумары* пешерәдер ийек. Онны туғылап күкәй белән суға, қашық белән өзеп-өзеп кенә саладыр ыйық. *Солы қоймағы* үзенә бер тәмле, исләре урамға чығар ыйы. *Соло кесәле* пешерер ийек. Соло онон иләктән или торган ыйық та, шул қалған кибәклесен, қылчықлысын җылымса суға салып қуйадыр ыйық, сөтен чыгарадыр ыйық, сөзәдер ийек. Шул сөте чыққан суны қайнатасың инде, ә теге қабығын таwықларға саласың. Шул сөте чыққан соло суын әкерен генә утта пешерәсең, *соло кесәле* була. Соло кесәлен пешереп суынырға қуйсақ, дерелдәп торошлы булыр ийы.

**Талқан. Талқаннық, талқан оны.** Талқан пешерү өчен махсус әзерләнгән он.

– Солоны қайнатып төйә торған ыйық, тарыны қайнатып төйә торған ыйық, арышны да пешереп төйөп қуйадыр ыйық. Тары қушсаң, талқан таралып қына тора торған тәмле буладыр ыйы. Тегермәнгә барып тартадыр ыйық та шуларны пешереп

киптергәч, қайнаған суға ғына болғатып ашыйдыр ыйық. Сәхәрләрдә шуны ашау ыйы. Солоны нык қына күзисең кипкәч, төйәсең, тарының да қабықлары қуба пешкәч. Қыdy киптереп тегермәндә тартасың, туқлықлы була ул.

– Талқан пешерәдер ийек. Тары, бодай қушып тарттырасың.

– Бодайны, арышны жуып киптерәсең дә бергә қушып тартасың, талқаннық дип. Шул талқан онын қайнап торған суға салып болғата қашық белән. Ул сыйық булмасқа тийеш, таралып тора, тәмле була. Аның айырым бер тегермән ташы булған, wақ итеп тартмағаннар (Адай).

**Қолмақ. Қолмақ белән ипи пешерү.** – Әрәмәдә қолмақ күп булыр ыйы, қолмақ жыйып қайттық. Қолмақ белән ипи пешердем *жыл* тәүлеге буйына.

**Қолмақ суы**. Колмакны салып кайнаткан су.

– Қолмақны су салып қайнатасың, қолмағын сөзеп аласың. Қолмақ қайнатып, шуның суы белән ачытып саладыр ыйық ипине.

**Ипи башы йасау**. Ипи пешерү өчен, колмак суы белән камыр изеп кую.

– Қолмақ суына қайнар көйе он сала, туғылый, ул ачый. Бер ыстакан он житә ипи башы жасарға.

**Қолмақ башы**. Колмак суына изеп, ипи пешерү өчен әзерләнгән сыек камыр.

– Қолмақ башы биреп тор әле, дип, үзеңдә бетсә күршеләрдән әжәткә алып та пешерәдер ийек. Ул ипи искерми, озақ тора, тәмле, хуш исле була (Күҗәкә).

### *Сугым сую, ит*

**Суғым**. Суяр өчен ашатып симертелгән эре мал: тана, ат яки сыер.

– Суғым суйған көнне ашқа жыйа, олы бәйрәм инде. Бөтен урамы белән ашқа чақыра. Һәр суғымда ит ашатабыз оло табақ белән табында турап. Итне табаққа өйөп кенә чығару ыйы табынға. Күп пешерәдер ийек итне.

**Ат ите.** – Ат итен күп ашадық. Уртақ суйадыр ыйық. Үзебез *қышлау** да суйабыз, ат та суйабыз. Аны ничек ашағанбыздыр

---

* *Қышлау* – тана сыер.

инде. Элек җул җөриләр ийе. Әти җулға ат ите алып чығадыр ыйы, җомошақ бит, қатмый, дип. Ашатып суйған мал, үзен-нән-үзе майы сығылып торадыр ыйы (Әнәк).

**Қазылық.** – Менә ат суйабыз бит. Атның туры эчәгесен алып қаладыр ыйық, аны әйләндереп йуып, ат итен телемләп турап, тозға манча-манча тутырадыр ыйық. Ул ат қамытындагы бөйәт шикелле буладыр ыйы. Шул тутырған қазылықны қайнап торған суға тығып чығаралар ыйы да элеп қуйалар ыйы өй түбәсенә. Ул шунда кибәдер ийе. Печәнгә китсәләр дә, урақка китсәләр дә, шул қазылықны алып китәләр ийе җәйнең қызу көнендә.

– Қазылық тутыралар ат итеннән. Итне борычлап, тозлап тутыралар, ат ите қойашта кибә. Менә ашап туйғысыз былтырғы қазылықны.

– Ат суйадыр ыйық, ит күп буладыр ыйы. Қазылықны эчәгегә тутырасың да элеп қуйасың, ағып тора инде майлары. Җәй көне кисеп-кисеп кенә ашыйсың. Қазылық менә қойашта қызарып кибә.

– Эчәгене җармыйсың, әйләндереп кенә җуасың. Итне ықлау белән төртеп-төртеп кертәсең, тутырасың.

– Шушылай өйнең тышқы йағына киртә қуйадыр ыйы әтей қойаш йағына. Шунда тезеп эләләр ийе қазылықны.

– Җуан эчәгегә итне телеп-телеп тутыралар ыйы майы белән бергә. Ул йуан колбаса шикелле буладыр ыйы. Инәй бик күп җасыйдыр ыйы. Атлар, сыйырлар суйадыр ыйық. Башта *тәпәнгә* тозлыйлар ыйы да аннан берқадәр торғачтын, қазылык тутырып, өй түбәсенә эләләр ийе. Ул *қақлана,* исе урамнарға чығар ыйы тәмне булып.

– Ат итен йуwан эчәккә тутыралар, бик майлы җирләрен тутыралар иплэп кенә. Ул қазылық була. Аны инде йаздан тутыра, җәй буйы чарлақта тора, караңғы җирдә тора. Ул шунда тозланып, кибеп пешә, өлгерә. Бик озақ йыллар сақлана ди қазылық. Җәйгелектә, печән өсләрендә, болын өсләрендә рәхәтләнеп ашыйсың қазылықны (Әнәк).

**Тутырма.** – Мин тутырма тутырам эчәгегә. Итне wақ қына итеп турыйм, дөге белән, суған белән бутыйм да сыйырның йуwан эчәгесенә, йә нечкә эчәгесенә тутырам. Бер башын бәйлим

дә икенче башыннан тутырам. Кәстрүлгә тезеп пешерәм. Тутырма ул шундый шулпалы, тәмле була (Уразай).

### *Как*

**Қақ қойу.** – Әрәмә қуйы йы. Қара бөрлегәнгә керәдерийек, қарлығаннар, шомортлар, баланнар жыйып чығадырыйық. Қара бөрлегән күп буладырыйы. Әрәмәләрне бер дә сақламадылар.

– Элгәргеләр қақ қойа торған булғаннар. Сирәк кешедә генә буладырыйы қақ, олы кешеләр генә қойадырыйы. Көз көне баланға барып балан қағы қойарлар ыйы.

– Ашқа барсалар да әнкәйләр қайтып сөйлиләр ийе: «И-и, менә қақ та қойғаннар, җиләк қағы да бар, балан қағы да бар», – дип.

– Әрәмәләребездә төрледән-төрле җиләкләр күп булыр ыйы, тауларыбызда да җир җиләкләре бидерәләп жыйышлы булыр ыйы. Қақны күп қойадыр ыйық, хәзердә дә қойабыз әле. Җиләктән, баланнан, миләштән қойадыр ыйық. Пешереп төйәдер ийек, аның сөзгече булыр ыйы. Ул чағында сәке тақтасына нық қына итеп май ышқыйлар ыйы да қақны йағалар ыйы, қойашқа чығарып қуйалар ыйы. Көн қойашлы булса, кичкә кибеп тә чығадыр ыйы. Йә икенче көнгә қубадыр ыйы ул.

– Туйға барса-нитсә дип, инәй шулай қақны жыйып қуйадыр ыйы, чәкчәк өстенә қаплау өчен дип. Ул қақны шулай чәкчәк өстенә қапларлар ыйы.

– Икебезгә ике бидерә алып чығып китәдер ийек тә, җиләк белән тутырып қайтадыр ыйык. Жыйып қайтқан оңғай белән инәй шушылай төйәдер ийе, шул арада сығып қағын да қойоп қуйадыр ыйық. Әwәле эре буладыр ыйы *җиләк.* Җәштән үк җимеш жыйарға дәртле булдым. Қайда нәрсәкәй үсә, нинди ағач, нинди үлән қай төштә бар, барын да беләдер ийем, хәзердә дә беләм (Күҗәкә).

### *Сөт, май ашамлыклары*

**Қатық.** – Җиңгәй ойотқан қатық бик тәмле була. Сөтне қайнатабыз да бармақ пешми башлағач қына ойотқы салып, қатық салып болғатабыз, қатық ойый.

**Чөгендерле қатық.** – Чөгендерле қатық қуйалар ыйы аш артыннан, бик тәмле буладырыйы. Қаймақлар салалар ыйы

чөгендерле қатыққа. Өчәр-дүртәр җиргә қуйарлар ыйы чөгендерле қатықны.

– Сөтне қайнатқанда турап салалар чөгендерне. Қайсыбер кеше сөтне чөгендерсез генә қайната да чөгендерне пешереп турап сала. Ну менә чөгендерне турап сөткә қушып қайнатып пешереп йасаса тәмлерәк була (Чуракай).

**Сөзмә.** – Қатықны марлыдан сөзәләр, сөзмә була, қуйы тәмлесе генә қала инде қатықның, әче суы чығып бетә.

**Қыdыл эремчек.** – Сөтне-қатықны қыdарғанчы қайната, қыdыл эремчек була. Баллап қуйа, гөбәдийә пешерә.

**Эремчек эретү.** – Сабан туйы, җыйын җитә башласа, бик күп итеп эремчек эретер ийек. Безнең бөтен сый шул булды. Зур ағач табақ бар ыйы безнең, шул табаққа салыр ыйық та қаймақтан йасаған майны җоморолап уртасына ғына қуйар ыйық. Иң беренче сый шул булды, эремчек булды, қатық булды, май булды.

**Уғыз.** Сыер бозаулагач беренче көннәрдә савыла торган сөт.

– Уғызны қазан белән пешерә, тозын да сала. Йаңадан туғылашлы булмый, китеп-китеп алышлы була. Ашқа салырға да йарый, пирашки эченә салырға да йарый уғызны. Уғызны күршеләргә дә керткәннәр, ул йылға бер генә була бит.

– Сыйыр бозауласа, уғызны кешеләргә аwыз иттермиче қалдырмыйдыр ыйы.

– *Тана бозау* булса – *алты мәртәбә, үгез бозау* булса, *җиде мәртәбә* уғызны ашамыйча җыйасың, шуны қазанға саласың. Ул олы кисәкле булып пешә. Суынғач кисеп-кисеп ашыйсың.

– *Уғыз ашы,* дип кисәк-кисәк итеп бүлгәләп, ашқа сала торғаннар ыйы сыйыр бозаулағач.

**Май, май әйрәне.** – Икешәр сыйыр асырыйбыз, гөбедә май йазабыз. Майын салқын сулар белән йуwасың, май әйрәнен эчәсең.

**Май йазу.** – Гөбедә май йазарлар ыйы. Май йазған көнне ботқа пешерү булыр ыйы, тары йармасы белән ботқа. Қыстыбый пешерерләр ийе май йазған көнне.

**Туралы май.** Киптереп төйгән эремчек, сары май һәм шикәр белән ясалган ашамлык.

– Туралы майлар йасый торған ыйық сабан туйларына, жыйыннарға. Қунақ киләсе булса да туралы майлар қуйыш булды.

– *Эремчекне* киптерәсең, ақ эремчекне. Шуны киптергәчтен нығытып төйәсең, төйөп иләйсең. Ул *эремчек оно* була. Аны сары май белән қазанда қайнатасың, писук белән болғатасың. Аннан да тәмне әйбер жуқ. Аны мин аwыз ачтырғанда паднусқа тезеп, шақмақлап-шақмақлап қуйа торған ыйым. Бик нық тәмле була. Аwыз ачтыра торған ыйым жыл да.

**Эремчек белән май.** – Қунақ киләсе булса да эремчек белән май әзерләделәр.

– Эремчек йасап, сары май қушып қуйалар ыйы. Сыйыр майы да қуйалар ыйы туралы май дип.

**Алмалы май, бөрлегәнле май, чийәле май.** – Инәй май йазадырыйы да wақ алманы, қара бөрлегәнне, чийәне дә май белән бутап қышқылыққа әзерләп қуйадырыйы, қунақ-төшем булғанда чәйгә әзер торды, тәм-том булды.

**Туң май сызғыру.** – *Қоштабақта* туңмайны қыздыра, төтеннәре чығып тора, шуны ашқа сызғыра (Әнәк).

### *Савыт-саба*

**Бидерә.** Чиләк.

– Әwәле ағач бидерә, тақта бидерәләр ийе. Сыйырны да ағач бидерәгә саwар ыйы инәй.

**Чиләк, әбәт чиләге.** Кырга сөт-катык, әйрән салып йөри торган чиләк.

– Әбәт чиләге ағачтан ыйы. Җимеш жыйарға да жайлы булыр ыйы ул әбәт чиләге.

**Гөбе, аталаwыч.** Май язу әйберләре.

– Җүкә ағачының эче қуыш була. Шуны чоқып гөбе йасый, гөбегә аталаwыч йасый. Гөбедә май йазалар ыйы. Гөбе йазу – җан чықмақ, дигәннәр. Аны саран кешеләр бирмиләр гөбене.

**Кәнди.** Аш бүлеп ашый торган савыт, аяк.

– Сөйән ағачыннан йасаған ағач кәндиләр ийе, беd бәләкәй чағында. Балчық кәндиләр дә була торған ыйы. Кәндигә бүлеп ашыйдыр ыйық ашны.

**Қапламыш.** Өсте капкачлы кечкенә кисмәк.

– Ағач қапламышның йартысында май, йартысында мәк булыр ыйы безнең инәйнең. Ғомбағыш, киндер майларын салып қуйарлар ыйы қапламышқа.

**Ағач табақ.** – Сәкегә тезелеп утырып, йөзлек қырыйына эскәмийәгә йә бүкәнгә утырып, зур ағач табақтан ун кеше буламы, җиде кеше буламы, шулай ашыйлар ыйы қашық белән.

**Қоштабақ.** – Балчық қоштабақлар була торған ыйы.

– Қоштабақның зуры жуқ, ана шул ағач кәнди. Шул ағач кәндигә бүлеп ашыйлар ыйы. Таш тәрилкәләр байларда ғына булды.

**Қалақ** дип тимер қашықны әйтәләр.

– Қашық (агач кашык) белән аш эчәләр ийе, қалақ жуғыйы әwәле.

**Тәпән.** Эчен куышлап ясалган кисмәк.

– Имән тәпән, сөйән тәпән буладыр ыйы. Икмәк басамы, қыйар тозлыймы.

– Тәпән утыртқан чүмечле қойо булды, аннан бик күп су эчтек. *Бал тәпәне* буладыр ыйы. Иптәш қызым тәпәннән бал алып, ипигә йағып алып чығар ыйы. Балны тәпәнгә салып алып қайталар ыйы *умарта менгән* чағында. *Ипи тәпәне* зурырақ була.

**Лағун.** – Ул ағачтан була. Аны бөкесен ачып қына ағыза. Әйрәнне су белән йасап, салқын су белән, шунда салып алып бара қырга. Урманда – ағач төбенә, ураққа барса, чүмәлә төбенә утырта. Көне буйы салқын тора әйрән. Қалай булса қыза бит.

**Лақан.** – Қомғаннан су қойып йуwынған суны саладыр ыйық.

**Ләңгәч.** – Ағач саwыт, қапқачлы. Әйрән аппаралар ыйы қырға, қатық әйрәне җасап алып барған.

**Лар.** – Лар ул бүленгән. Берсендә йарма, берсендә он. Өсте қапқачлы була ларның, келәттә тора. Олы келәт эчендә лар буладыр ыйы. Лар ул қапқачлы сандық кебек, бер йағында борчақ оны, бер йағында бодай оны торыр ыйы (Чуракай).

### *Бала туу белән бәйле йолалар*

**Кендек әбисе.** – Кендек әбисе булған аwыл сайын. Бәбәй туғанда аwылда бер атақлы кендек әби булыр ыйы. Минем үземнең кендек әбийем Бәдиғолҗамал исемнейе, бөтен аwылға бер

ийе. Әле мин үскәндә, мин кийәүгә киткәндә дә һаман шул кендек әби булып йөрде.

– Кендек әби белгәнен уқып керә, баланың қолағына салаwатлар әйтә.

«Тигезлек белән карап үстерегез,

Бәхетле, тәүфикле, изге сабый булсын», – дип әйтәләр кендек әбиләр.

Кендек әби күп бала таптырса, имеш, аны җеннәр алып китә.

– Кендек әби җөздән артық бала таптырса, кендек әбине җеннәр алып китә үdләренә бәбәй таптырырға, дип әйтә торғаннар ыйы. «Курқам, бармыйм», дип әйтер ийе қайсы-берсе (Күҗәкә).

**Кендек әбинең вазифалары.**

**Мунча кертү.** – Кендек әби олан тудырган ананы мунча кертә. Бөтен тәнен, табан асларын сылап-сылап җуындырып ананы да, баланы да қадерли. «Бәхетле бул, таза бул», – ди.

– Кендек әбиләрем күршедә генә ийе, әби кулына төште балаларым. Кендек әбиләрен бер дә доғадан қалдырмыйбыз.

Баланы муча керткәндә *кендек әбисе пиннек белән чабар* ыйы:

Ата сарылы булсын,
Инә сарылы булсын,
Туганнары сарылы булсын.
Аталы-инәле булсын,
Алтын қанатлы булсын,
Олыларны олы итсен,
Кечеләрне кече итсен,
Бәхетле булсын,
Тәүфикле булсын,
Тигез қарағыd балағыdны, –

дип әйтеп чабар ыйы (Әнәк).

– Муча ташы,
Бүрәнә башы,
Аллаға қол булсын,
Мөхәммәткә өммәт булсын, –

дип әйтеп чапқаннар бәбәйне мучада.

**Кендеген кисү.** – Кендек әби белән тудырдым баланы. Кендеген кисә кендек әби.

– Кендеген *җитен тәгәрҗебе* белән бәйләп қуйа кендек әбиләр. Мунчалар кергәч, йуғач, ул кендек төшәдер ийе.

– Кендекне дөрес кисә белергә тийеш. Кендекне қысқа итеп киссәләр, бала үлә, ди. Астына сийүчән дә була, ди, бала.

**Кендекне җыеп кую.** – Кендек әбисе кендекне, киптереп төреп, *китап арасына* сала, *әфтийәк арасына* қуйадыр ыйы.

– Кендекне киптереп, бер *доғалық* эченә салып қуйа торған булғаннар.

– Кендеге теләсә қайда җөрсә, баланың эче аwыртучан була, диләр.

– Кендекне *сондоқ төбенә, кендек қыймылтамый торған* җиргә салырға кирәк. Кендек қыймылтап торса, баланың эче аwыртучан була, диләр.

– Қороп төшкән кендеген, беренче чәчен Коръән эченә тығыш ыйы. Шулай исемен җазып Коръән эченә қуйыш ыйы.

**Соңғылықны, «бәбәй иптәше»н күмү.** – Кендек әбиләре баланы җуа, соңғылықны күмә, бисмилла әйтеп, чиста урынға.

– *Бәбәй иптәше,* дип бер эт алмастай ғына җиргә, ару җиргә чоқыр қазып күмә торғаннар ыйы, җуып, чайқап, чүперәккә төреп күмәләр ийе.

– Бәбәй иптәшен җирне чоқоп җиргә күмгәннәр, кеше йөрмәй торған җиргә. Қош-қорт ашаса да бала чирләшкә була ди. Пычрақ җиргә дә күммиләр, ару җиргә, ағач төбенә күмәләр.

**Бала йатқылығын, соңғылықны күмү.** – Бала йатқылығын чиста җиргә күмәләр, айақ асты булмасын, қош-қорт ашамасын.

– Иске чабатаға салып күмгәннәр элек, хәдер белмәйем.

**Йөзлек белән туған баланың йөзлеген җыеп қую.** – Йөзлек белән туған баланың йөзлеген дә киптереп, китап арасына салып қуйғаннар, қайсы кеше сындықта сақлаған. «Йөзлек белән туған бала бәхетле була», – диләр. Йөзлекне алып урлаучылар буладыр ыйы кеше күзенә мәхәббәтле күренер өченгә.

**Аwызландыру.** Бәбинең авызына бал-май тидереп алу.

– Кендек әби бал белән, май белән аwызландыра, салаwатлар әйтеп.

– Кендек әби баланы аwызландыра, аwызына бал-май тигерә.

Пар қанатлы булсын,
Алтын қанатлы булсын,
Ата-инәле булсын,
Бәхетле-тәүфиқле булсын,
Тәмле телле булсын, – дип (Әнәк).

**Кендек әбисен хөрмәтләү.** – Кендек әбисен алып килдем әле баланы мунча кертергә, диләр. Кендек әбисенә сый әзерләп қуйғаннар, қадерле ул кендек әби. Им-том да итә кендек әби.

– «Минем кендек әбийем бит ул», диләр, хәdер дә. Шуңа кендек әбийемә доға қылығыd, диләр. Кендек әбисе – бик оло кеше ул.

– Кендек әбисенә қоймақ белән чәй эчерәләр. Кендек әбигә чәй җасап биргәннәр икән, ул чәйне үзе эчмәгән, бәбәй тапқан хатынға эчергән. «Кибеккән ул», – дип.

Кендек әби өйгә кергәндә матчалар сығылып торор, дигәннәр. Бик хөрмәтле кеше булған кендек әбисе.

– Шәмшенур қортқа кендек әбисе булған безнең Күҗәкәдә.

Кендек әби булсаң әгәр,
Алырсың син бик күп саwап.
Үлеп қаберләргә кергәч,
Күрмәссең син ичбер азап.
И ходайым, сақла безне
Шайтан wәсwәсәләреннән.
Зекер-тәсбих, тәһлилләрне
Чығармайық күңлебездән (Күҗәкә).

**Кендек әбисен бүләкләү.** – Кендек әбисенә *күлмәклек* алып бирерләр ийе, митырлы *ситсы*, йә йақшы *кешмир йаулық* бирерләр ийе. *Пелиш камзул* бирерләр ийе *кызыл бәрхеттән.*

**Кендек ипийе.** Кендек әбисенә бирү өчен пешерелгән кечкенә ипи.

– Кендек кискән кешегә, кендек әбисенә ипий бирү иде. Ипине түгәрәкләп җасап, уртасына бармақ белән чоқырлатып уйым йасап, кендек ипийе дип, кендек әбисенә бирерләр ийе.

– Менә җылак балалар булса әйтерләр иде: «Әй, кендек ипийе бирмәдегезме әллә, нишләп җылый бу бала?» – дийерләр ийе.

– Кендек ипийе бирәләр ийе кендек әбигә, түгәрәк ипи салып, уртасына болай чоқыр йасап бирерләр иде.

– Элек бит жук ԁаман. Ипекәй пешердег исә ипи салғанда төртеп қуйар ыйық кендек әбийенә бирергә (Әнәк).

**Бәбәй туған өй.** – Бәбәй туған өйгә бер дә керергә wақытың булмаса, әғузе-бисмилла әйтеп, өй почмағына қарап булса да китәргә қушқаннар.

– Бер дә кереп күрә алмасаң, өй почмағына айағыңны тигезеп булса да китәргә қушқаннар бәбәй туған өйгә.

**Бәбәйләгән хатынға чәй, шулпа бирү.** – Бәбәй туғач ана кешегә тәмле итеп чәй, шулпа бирәләр, сөте булсын, дип.

**Бәбәйләгән хатынға аш кертеш.** – Бәбәй туғач, күршеләр аш кертеш булды. Кендек әби бәбәй туғанда булыша, қулына алуға, күрше-күкерт аш керткән. Умач пешерепме анда, тоқмач кисепме, шулпа керткәннәр бәбәйләгән хатынға.

**Бәбәй ашы, бәбәй қоймағы кертү.** – Элек өйдә бәбәйләү булды. Бәбәйләгәнеңне белсәләр, ашын, қоймағын, бәлешен пешереп кертәләр күршеләр. Бәбәй тапқан кешегә шулай бәбәй ашын, бәбәй қоймағын пешереп кертәләр.

**Бәбәй туйы.** – Бәбәй туйы ул үзенә атақлы инде. Қайсы чәкчәк, қайсы бәлешләр алып килерләр ийе, паштитлар алып килерләр ийе. Буш килмиләр ийе бер дә. Йә йаулығын, йә ситсасын алып килерләр ийе.

**Бәбәй күрергә килү.** – Бәбәй күрергә киләләр. Бүләкләрен, күчтәнәчләрен тотып ана қырына киләләр.

**Бәбәй бүләге.** – *Бәбәй тапқан кеше* бийанаға, бийатаға да *бәбәй бүләге* бирде, күлмәкме, алҗапқычмы. Мәгънәле кеше шулай бирә. Мин үԁем биш бала таптым, бишесендә дә бийанаға күлмәклек бирдем.

**Бәбәйнең айағын атасына күрсәтү.** – Бәбәйнең, иң беренче, айағын ғына күрсәткәннәр атасына, йөԁен күрсәтмәгәннәр бәбәйнең. Йаңа туған бала матур булмый, кемгә ошағанын да белеп булмый (Чуракай).

**Баланы төрү.** – Атасының иске күлмәге, анасының иске кийеме булған балаға.

– «Ата сарылы булсын», – дип, ата күлмәгенә төрдек балабызны (Кужәкә).

**Бәбәй мучасы.** Бала тугач та ягып әзерләнә торган мунча. Ананы да, бәбәйне дә мунчада юындырганнар. Бу эшне, гадәттә, кендек әби башкарган.

– Бәбәй туу белән муча кирәк. Бәбәй мучасын элек өч көн рәттән җақтылар. Хәдер инде қырығар көн җағалар.

– Бәбәй тапқан кешенең қырық тамыры өзелер, дигәннәр. Бөтен җирен сылый кендек әби. Бармақ очыннан башлап, буыннардан башлап, бөтен тәнен сылар ыйы. Бер атна муча йағып кертер ийе, бөтен җиреме сабын белән сылар ыйы (Әнәк).

**Исем қушу.** – Бабайлардан қалған ғадәт инде ул *азан белән исем* қушу.

– Исем қушқанда изге теләкләр теләргә қушабыз.

– Аллаһы Тәғаләгә қол булсын, Пәйғамбәребезгә өммәт булсын, – дип исем қушабыз. Өч мәртәбә қолағына *салаwат* әйтәбез.

– Баланың миңе булса, җүшкәдән қашық төшереп исем қушалар ыйы. *Миннегөл, Миннебай, Миннеқамал* исемнәре *қушалар* ыйы баланың миңе булса.

– Бала *исеменә ийә* булырға тийеш, *исем* алу тийеш. Менә туғанымның баласы туды да үлде, туды да үлде. Шуңа күрә, нықлы булсын, торсон, дип, *Тимерғали* исеме қуйалар. Менә Фатыйма апаныкына да Тимершәйех қуйдылар. Йәшәп киттеләр балалар.

– Нықлы була инде Тимер исеме қушсалар.

**Аdаннап исем адату.** – *Аdаннап исем ататырға* кирәк балаға. «Аdан ататтырдығыdмы бәләкәчәйегеdгә? Бәләкәчәйегеd әйбәт кенә үсәме?» (Әнәк).

**Бишек, бәллү сиртмә, арба.** – *Ағач бишектә* айақ белән тирбәтеп үстердек баланы.

– *Қабық* бишек тә бар ыйы.

– *Сиртмә* ағачтан ыйы, қайын ағачыннан. Қайын сиртмәгә асадыр ыйық бишекне. Пыржина булған кеше пыржина қуйадыр ыйы.

– *Бәләкәй арбаны* матур итеп йасады. Қабықтан йасаған бәләкәй арбаға салып тартып йөрү ийе.

– *Қабық* арба буладырыйы. Ағач қабығын төшереп бәбәй арбасы йасағаннар. Шулай қабықтан арба йасап, аны йәшелгә буйап қуйарлар ыйы.

**Тал бишек.** – Сыйық тал чыбығын бөгеп бишек үрәләр. Тал бит монда ғына, күп үсә. Беđ ике баланы да тал *бишектә* үстердек. *Тал бишек үрүчеләр* күп булды. Менә Иманғали абđый бишек үрүче булды. И матур итеп үрерләр ийе тал бишекне. Тал чыбыгының беразын кайызларлар ыйы, беразын қайызламаслар ыйы. Ансы җәм-җәшел булып торор ыйы, и матур булып торыр ыйы ул.

**Тал бишек чаршаwы.** – Тал бишеккә *чаршау* йасадылар *бәбәй итәкләп.* Шулай бишек чаршаwы булыр ыйы чебен тимәскә.

**Бәллү, киндердән теккән бәллү.** – *Бәллүгә салғаннар* баланы. Киндердән тегеп йасағаннар, рамға қуйғаннар, шунда салып селкегәннәр (Чуракай).

**Баланың кырыгы тулу.** Борынгыдан килгән ышанулар буенча, кырык саны – тылсымлы, ырымлы сан. Балага кырык көн тулганчы аның үзен генә калдырырга кушмаганнар, җен, шайтан алмаштырудан һ. б. дан саклану өчен, төрле ырымнар кулланылган.

– Қырығы тулмайынчы бер үđен қалдырмыйлар баланы, қалдырыш түгел ийе берүđен (Адай).

### *Язгы, җәйге бәйрәмнәр һәм йолалар*

**Қарға ботқасы.** Олылар һәм балалар катнашында язгы чәчүгә чыкканчы үткәрелә торган бәйрәм.

– Қарға ботқасын көтеп ала торған ыйық. Әđ генә чирәм чыға, шатланабыđ қарға ботқасына чығабыđ дип. Беđнең Аđайда тау башында пешерделәр. Қайсы нәмәкәй алып бара (Адай).

– *Қарға ботқасы* алдыннан сөрәнгә чығалар. Кеше саен ашамлықлар җыялар.

– Қарға ботқасы дип җегетләр чығарлар ыйы сөрәнгә. Сөрән суқтылар җегетләр. Аның тақмағы бар ыйы. Күкәй, сөт, җарма сорап, сөрән суғып, урам буйы җөрөрләр ийе. Кем нәрсә бирә.

– Қарға ботқасына бер бидерә сөт илтәбеd, *таwық күкәйләре* алып барабыd, *қазылық* алып барабыd.

*Дары ботқасы пешереш.* – Олы қаdанда дары ботқасы пешереш ийе. Аwылда бер кеше дә қалмаған, ботқа ашарға барған. Ындыр артындағы чокырға қаdан утыртып, қаdанда қарға ботқасы пешереп бирә торған ыйым.

– Күкәйләрне бийар ыйық қарға ботқасына чыққанда. Аның бийаwы шул инде: суған қабығын салып, су қайнатып, шуңа салып пешерер ийек.

*Қарға ботқасында балалар таудан тәгәрлиләр* (тәгәриләр). Балаларга, – Таудан тәгәрләгез, «йыл әйбәт килер», дигәннәр олылар. Беd, балалар, беребеdдән-беребеd уdдырып, рәхәтләнеп тәгәрлибеd. Тау бите кипкән була бит.

*Карға ботқасында күкәй тәгәрләтү (тәгәрәтү).* – Балалар тау башыннан күкәй тәгәрәтеп уйныйлар. Кемнең күкәйләре йырағырақ тәгәрли. Wатылған күкәйләрне қарғаларға ырғытып қалдыралар.

*Қарға ботқасында қарғаларға күчтәнәч қалдыру.* – Мин үdем қарға ботқасын пешерүче булдым күп йыллар. Олы қаdан ботқа. Ул ботқаны балаларға да, олыларға да ашатабыd. Қалған ботқаны бөтен җалан тутырып қарғаларға салып чығабыd. Қарғалар күп булып төшеп ашай торғаннар ыйы ботқаны. Бағана башларына салып чығар ыйық ботқаны. «Карға ботқасы булғач, Қарғалар ботқа ашарға тийеш», – дип.

*Қарға күчтәнәче алып қайту.* – Қарға ботқасында балалар уйныйлар тауда, утырып күкәй ашыйлар. Ашап бетермәгән күкәйләрне: Қарға сеdгә күчтәнәч җибәрде, – дип өйгә картларға, кечкенә балаларға алып қайтабыз (Күҗәкә).

**Су сибешеп җаңғыр теләү.** – Җәшләр бидерә белән су сибешерләр ийе, берсен-берсе қойондырырлар ыйы, җаңғыр җаусын, дип.

*Җаңғыр теләге әйтү.* – Аwыл буйынча су сибешеп тә җаңғыр теләгәннәр, җаңғыр теләге әйткәннәр:

Җаңғырқайым, җау-җау,  
Илдә ачлық булмасын,  
Ачтан халық үлмәсен,

Төрле-төрле чирләрдән
Ичбер азап күрмәсен.

Урамнан кем үтеп бара, әйбәт кейемлеме ул, әшәке кейемлеме, дәррәү су сиптеләр, жаңғыр жаусын, дип (Әнәк).

*Қорымлы қазан йуу.* – Жаңғыр жаумый, қорылықлар башланса, инәйләр менә болай итәрләр ийе. Қорымлы қаdанны, аш пешерә торған dур қаdанны ишегалдына алып чығып қуйарлар ыйы да ипләп кенә қаdан төбе жуарлар ыйы.

**Боз жаwа башласа пумала, кисәү агачы ырғыту.** – Боз жаwа башласа, бисмиллаңны әйтеп, тәрәзәңне ачасың да пумалаңны, кисәү ағачын ырғытасың. Боз туқтый шуларны ырғытқач.

– Жил-даwыллар килгәндә дә пумала, кисәү ағачларын чығарып ишек алдына ырғытырлар ыйы инәйләр (Чуракай).

## ***Жыйыннар***

**Жыйынға бару.** – Чытыр арбаларға утырып, гармуннар белән киләләр ийе жыйынға. Кибетләр күп киләдерийе.

– Атлар белән киләләр ийе. Безнең урамнан, тықырықтан жырлап килерләр ийе, йөгереп чығып қарыйдырыйық.

*Жуа жыйыны.* – Беdнең әнкәйләр, *жуа жыйыны, жүкә жыйыны,* дип барырлар ыйы. Жөрүчән булды беdнең әнкәйләр жөрөрлек рәтләре булғач. Жыйынға барабыd, дип ат белән чығып китәрләр ийе. Әйбәт кенә торығыd, ишегегеdне бикләп утырығыd, – дип әйтерләр ийе. Апкайтырлар ыйы жуалар, қуdғалақлар.

– Печәнгә төшкәнче жуа жыйыны, Үмәнәйдә булды ул. Шунда жыйылып килгәннәр, көрәшүләр, уйыннар булған.

– Үмәнәйгә, шушы жуа жыйынына қунақлар күп килгән. Ул килгән қунақлар үdләренә жуа жыйғаннар. Ул жуаның пирукларын, ботқаларын пешергәннәр. Ул аwылға исемнәнгән инде. Ық буйы, жуа күп.

– Беd үскәндә әле Үмәнәйдә *жуа жыйыны* булды. Жегетләр-кыdлар килерләр ийе тау буйына, уйнарлар ыйы, жырларлар ыйы, бийерләр ийе. Шулай тау буйында жыйылып уйнарлар ыйы.

*Бикә жыйыны.* – Икмәк житкәндә булды *Бикә жыйыны.* Бикә жыйыны Қормашта булды. Пирwай оло жыйын, *Жамалы*

*җыйыны* арты Бикә җыйыны. Бикә җыйыны безнең Боғадыныкы булған.

*Җамалы җыйыны.* – Иң adaқы җыйын булыр ыйы Җамалыда. Җамалы җыйынына чақырып алырлар ыйы. Миңа бер буқча белән қыdыл билле перәннек бирә торған ыйы җиdнәй булған кеше. Инәй белән бертуғанның ире җиdнәй була. Җыйында dур әтәй ул әтәйнең абdыйсы була, беdгә қыdыл билле перәннек бирде. Җыйын күчтәнәче итеп алып қайта торған ыйық тәм-томнарны (Күҗәкә).

***Кызлар уены, кич утырулар,***
***аулак өйләр***

**Кичқуйын.** – Йуғарочта су буйында буладыр ыйы кичқуйын, төне буйы җегетләр ғармун уйнап утырырлар ыйы. Атап җырлар җырлыйлар ыйы, сигезле, өчле уйныйлар ыйы.

– Кичқуйын буладыр ыйы сабан туйында. *Җегет җөгертү* диләр ийе. Ике җақта ике қыз, уртада җегет, китәләр җөгереп. Қайтқан waхытта ипләп кенә сөйләшеп киләләр. Қараңғы төшкәнче кичқуйынға чыға торғаннар ыйы. Җырлау, бийү анда. Ақ ойоқ-чабата кийеп төшү ийе тауға.

Бийүченең күлмәгенә
Гөлҗимешләр җабышқан.
Бийүчегә сүз әйтмәгез
Җаңа бийергә төшкән.

– Кичқуйынға менә торған ыйық. Чурақай белән икарада булды ул майдан, ындыр артында ғына. Кичқуйында бийепләр, кырук әйләнепләр, җырлаплар йөри торған ыйық.

– Җир чыққачтын да уйынға чыға башлый торған ыйық. Ындыр артында бик тиd қар эреп бетә торған ыйы, шунда уйынға чыға торған ыйық. Йақын җир, айақ очо ғына бит. Башта ололарға ийәреп җөрдек, аннан үdебеd җөри башладық. Түгәрәкләнеп уйный торған ыйық. – Бөтен кеше шул ындыр артына җыйыла торған ыйы элек беd җәш чағында (Әгъбәз).

*Түгәрәк уйын, калхуз түгәрәге.* – Бийеш, җырлаш булды кичке уйында. Калхуз түгәрәге, диделәр. Түгәрәк уйында, калхуз түгәрәгендә җырладык.

Қыйбыладан искән җилгә
Мамық шәлләр җабынам.
Аwадағы йолдозларның
Саннарынча сағынам.

Қулымдағы җөзөгемнең
Исемнәре Сафуан.
Қулларыма чәчәк җыйдым
Сиңа ошатып басудан.

Калхуd түгәрәге бичердә булды. Кылуптағы уйын, түгәрәкләнеп уйныйбыз. Уртада бер җегет белән қыd утыра. Бер-ике җыр җырлағачтын алар чыға да икенчесен кертеп утырталар. Бичырлар шул калхуd түгәрәге белән башланып китә торған ыйы.

Кылупқа бара торған ыйық, кылуп тулы кеше була торған ыйы. Калхуd түгәрәкләре уйнап, алҗап, алҗағачтын тышқа чығып қағынып кереп, тағын тотона торған ыйық бийергә.

Хәdердәдә бийү көйен ишетсәм бийеп китәм. Қартайған сыман түгел ул күңел дигән нәстәкәй. Менә җырлап та күрсәтим әле.

Алсу-кыdыл гөлләр булса,
Сулар сибәрләр иде.
Сабый чақларымда үлсәм,
Сағнып сөйләрләр иде.

Сары матур, сары матур,
Сары матур сайласаң.
Таwышларығыздан танырмын,
Қошлар булып сайрасаң.

Су сибегеd гөлләремә,
Гөлләрем шиңмәсеннәр.
Гөле шиңгән, күңеле күптән
Сүнгәндер, димәсеннәр (Әгъбәз).

**Боз зату, ташу қарау.** – Беdнең Үмәнәйдә боз зату бар ыйы, боз затырға төшәрләр ийе җәшләр. Боз өстендә учақлар җаға-җаға барырлар ыйы, җазғы бозлар бик қалын булыр ыйы.

Күпергә җитәм-җитәм, дип киләдерийе йазға бозлар. Элек бозлар қалын, нықлы була торған ыйы.

Гармуннар, җырлар, бийүләр белән ташу карауға төшеп, қарап қайта торған ыйық. Әллә қайан ишетелеп торор ыйы таwышлары (Үмәнәй).

**Аулағи.** – Әтисе-әнисе қунаққа китсә, аулағига қызлар җыйыладыр ыйы. – Аулағиларға бик ышанычлы кешеләргә җибәрәләр ийе, қарчықлар сақлап утырыр ыйы қызларны.

– Аулағида җегетләр-қыdлар җыйылалар ыйы да қул суғышлы уйныйлар ыйы, қайыш суғышлы уйныйлар ыйы.

– Аулағиға әнкәйдән сорап қына барабыd. «Ydeгedне ydeгed сақлап йөртегеd, тәртипле булығыd», – дип қала инде әниләр. Андағы уйыннарны сүләп бетермәле түгел, күб ул.

– Без үскәндә күпчелек аулағи булды. Кемнең ата-инәсе қунаққа китә, қыdлар җыйылып утыра торған ыйық. Қул эшләрен алып килә торған ыйық. Чигүләр чигеп, бәйләмнәр бәйләп, челтәрләр бәйләп утыра торған ыйық. Қоймақ пешереш ийе.

– Аулағида пичкә йағарға утын йуқ бит, йегетләр утын китерәләр кешеләрнең читәннәрен, қоймаларын сүтеп. Қачан пешереп бетерәсеd, ашыйсы килә, – дип өй артында йөри торғаннар ыйы алар, беd аларны кертмәйбеd. Қоймақ пешкәч кенә аларны кертеп, бергә ашап, уйнап утыралар: арқа суғыш, хат ташучы, пучталы уйнап.

Иртәнге сәғәт икегә, өчкә чақлы шулай уйнап утыра торған ыйық җоқламайчы. Шул хәdәрле җәмне була торғаныйы ул аулағилар.

Берсендә аулағида уйнағанда мичне җимерделәр. Менә җегетләр тотондылар тиd-тиd мич чығарырға. Иртәгә инәләре қайтасы бит. Тәки мичне чығарып қуйдылар.

Урам буйлап җырлый-җырлый қайтып китәрләр ийе гармуннар белән (Уразай).

**Аулағаш.** Аулағида пешерелә торган ашамлык.

– Қызлар аулағиларда *аулағашлар* пешерә торған ыйы. Йәшләрне кертмиләр ийе. Қайсыбер йәшләр, өйгә кереп, қызларның бәлешләрен урлап та чығарлар ыйы, шулай итеп күңел ачқаннар. Анда орчоғ эрләү, сүс эрләү, бәйләү, чигү инде. Шундый қул эшләре эшләдек.

– *Чөлкә бәйләргә, орчоғ* эрләргә алып киләләр қызлар. Кич утырғачтын *аулағ ашы* пешереп ашыйбыз. *Он боламығы* болғатып, уртаға күз йасап майын салып ашыйбыз. Безнең *әртилебез* бик әйбәт, дусларыбыз күп.

– Аулағида аулағашлар пешердек, *дары ботқасы* пешердек, *бәрәңге қыстыбыйы* пешердек. Бер wақыт йегетләрне кертмәдек аулағиға. Қыш көне йе. Бер өй арқылы ғына йегетләр. Алар өй түбәсенә менеп китеп су салдылар мөрҗәдән, аулағига кертмәгән өчен үпкәләп. Ағып төште изәнгә қорымлы су, пич алды тулды. Йудық инде көлешә-көлешә. Шулай бик йәмне булды ул чағында. Хәdер йәм йуқ.

– Шулай йәмне булыр ыйы, кыdлар-йегетләр сәкедә теdелеп йатырлар ыйы парлап-парлап. Беd мич башында утырыр ыйық балалар. – Әтәй-әнәй өйдә булмаса, қызларны, җегетләрне жыйа торғаннар ыйы «аулағи» дип. Аулағида аулағашлар пешерә торғаннар ыйы, бәрәңге қыстыбыйлары пешерерләр ийе. Берсе бәрәңге, берсе он алып килер ийе. Җәшләр таралғач қына ашыйлар ыйы. Йалды ишеген бикләп қуйарлар ыйы.

– Менә берwақыт йегетләрне қуып чығардық та йалды ишеген бикләп қуйдық, үзебез чәй эчәргә утырдық. Ә бер йегет йалдында қачып қалған, ул ишекне ачып йегетләрне керткән. Болар җыйылышып, көлешә-көлешә безнең белән қыстыбый ашарға утырдылар. Үзебезгә тимәде дә инде. Шундый қызықлар була торған ыйы.

– Аулағашны мичкә қуйып тора торған ыйық, мич жылы була торған ыйы.

– Аулағида аулағашлар пешерә торған ыйық. Аулағашта боламық болғата торған ыйық. Қайсы он, қайсы сөт, қайсы май алып килә торған ыйы (Татар Суыксуы).

**Пичтән бәлеш урлау.** – Аулағиларда бәлеш пешереп ашыйдыр ыйық. Аны қайсыбер кешеләрнең мичennән, мичен қаплап қуймаса, урлап та апчығып китәләр ийе. Пич алдында утын тутырып қуйсаң да барып қарыйлар ыйы аны бәлешне. Исе чыға бит аның. Алай минем урлатқан булмады.

– Аулағиларда қыdлар бәлешләр пешерәләр. Ә йәшләр, аулағиға кергәч, бәлеш исен сизәләр дә бәлешне пичтән шыпырт қына алалар. Берсе әйтә:

И пешә лә, пешә лә,
Идәннәргә төшә лә.
– Төшә бирсә, қыса бир, ди.
– Қыссам суы чыға, ди.
– Суы чықса, сыза бир, ди.

Урлыйлар бәлешне. Пешәр булса, тышқа чық, ди икән. Йәшләр чығып киткәч пичтән бәлешне қарасалар, йуқ бәлеш. Қыdлар қолқынып қалалар икән. Менә шундый дәwерләр дә булды.

– Аулағида бәлеш пешергәннәр дә малайлар бәлешне урлағаннар.

Аулағида утырғанда,
Қыdлар пешерде бәлеш.
Қыdығып қарап утырма,
Тот та бәлешкә җәбеш, –

дип җырлар чығарғаннар җегетләр.

Қулымдағы җөdөгемнең
Исемнәре Гөлҗәннәт.
Қайа қуйдың бер бәлешне,
Теләсәң қайдан җүнәт.

Қулымдағы җөdөгемнең
Исемнәре Гөлҗәннәт.
Кеше җәренә қыdықма,
Үdеңә-үdең җүнәт (Әгъбәз).

**Урнаш.** Урын+аш, ягъни аулак, яшерен аш.

– Беd бер эстәкән тары йармасы алып килеп, қырдан салам ташып, сөт алып килеп урнаш ботқа пешерә торған ыйық Мәрҗәмнәрдә. Асқа да салам, мендәр урынына да салам.

– Әнкәйләр қунаққа киткәчтән урнаш булды инде ул. Қыdлар қайсы жарма, қайсы он әпкиләдерийе, қайсы май әпкиләдерийе. Шулай итеп, үdебеd әdерләп қоймақлар пешерә торған ыйық. Әле ул мичкә саламнар җақмалыйы. Ул чағында утын да җуғыйы.

– Шәңгә сала торған ыйық урнашта. Майладық та тәрәdә буйға қуйдық. Дәки белән Харис бар ыйы. Икесе килгәннәр дә

тәрәdәдән шәңгәне алғаннар да ашап торалар басып. Шулай қыdық булды, әрләшмәдек.

– *Урнашта* ботқа пешерәбез, дары ботқасы. Қызлар қул эше эшли, бәйләм бәйли, челтәр бәйли, чигү чигә. Урнаш пешерәбеd дип қыстыбый пешерәдерийек. Бик җәмне булыр ыйы (Чуракай).

### *Сугыштан соңгы еллар истәлеге*

– Беd қул белән урдық урақны. Бу сугыштан соң булды. Персидәтелебез Шәрип абый булды.

Ашарға йуқ йыллар, бер қушуч бодай алып қайтыр ыйық. Өстән күлмәгебеdне салабыd да бодайны суғабыd тайақ белән. Кесәгә салыр ыйық. И, бер қушуч бодай инде ул. Шуны балаларға қурып бирер ийек.

– «Сақ булығыd, айғыр таwышын ишетсәгеd йәшерегеd. Мин сеdгә усаллық эшләмәм, башқа кешеләр күрмәсен», дип әйтер ийе Шәрип абый. Шәрип абыйлар белән күрше булып гомер иттек, бер ишеғалдында тордық. Аның усаллықлары булмады халыққа, бик йақшы кеше булды. Урыны җәннәттә булсын (Әнәк).

## МӘГЪЛҮМАТ БИРГӘН ТЕЛ ОСТАЛАРЫ ҺӘМ ЙОЛА БЕЛГЕЧЛӘРЕНЕҢ ИСЕМНӘРЕ

***Адай авылы:*** Нәфыйков Миңтимер, Фәтхетдинова Нурдидә, Гарипова Мәүҗидә, Шәехова Гөлчирә, Вәлиева Тәрзимә.

***Әгъбәз авылы:*** Рәшитова Гөлҗәннәт, Багабиева Галия, Хөҗҗәтова Наилә, Фәхрәзиева Мөнирә, Галәветдинова Мәймүнә, Хәмидуллина Фәнүзә.

***Әҗмәт авылы:*** Гыйльметдинова Хәбибә, Мәрдәнов Хаҗимәрдән, Майрунова Йомадия.

***Әнәк авылы:*** Бәдертдинова Фәния, Нуретдинова Рәйсә, Хәлиуллин Зиннәтулла.

***Кадермәт авылы:*** Хисамова Фәһимә, Сәйфетдинов Әрдәүс, Заманова Икълимә, Гыйниятуллин Галимҗан, Гыйльфанова Нәзлия, Әхмәтова Газдәвия, Суфиев Әбүзәр.

***Күҗәкә авылы:*** Фатыйхова Тәхия, Габдуллина Нурфика, Мирзанурова Халидә, Шакирова Мөзәйнә, Шәрәфетдинов Инсаф, Гәрәева Мөзәккирә, Шәйгәрдәнова Рәйсә, Шәрипова Рәшидә, Миясәрова Мөзәйнә, Миясәров Мөхтәсәр, Миясәрова Фәния.

***Мари Суыксуы авылы:*** Яманова Зәкия, Басыйрова Ләйлә, Әхмәрова Минзифа, Галиев Эдуард.

***Такталачык авылы:*** Акмаева Зәйнә, Мансурова Асия, Сәлимгәрәева Венера, Мутина Рифа, Насыйрова Фәридә, Майлунова Рауза, Гайсина Гөлҗәннәт, Гайсина Диләрия, Раянова Венера, Газетдинова Люция.

***Татар Суыксуы авылы:*** Шакиров Вазих, Солтанова Рәшидә, Хафизова Мәхрәмә, Басыйрова Хөллия.

***Терпеле авылы:*** Илекбаева Бүләкәй, Шәйхаттарова Майтинә, Тимеркәев Миңнегол, Солтанов Ислам, Абдулова Минҗамал, Курманова Солбикә, Солтанова Аля.

***Уразай авылы:*** Зәгыртдинова Гөләндәм, Саматова Кадрия, Халикова Зәкия, Ялалов Мөхәммәт, Сафина Миңнегамбәрия, Сафина Дилбәр, Нуриева Тутыя, Солтанова Сания, Солтанов Шәрип, Фарисов Миңнис, Фарисова Флёра.

***Чуракай авылы:*** Гаптауллина Рәүфә, Шәехов Назыйм, Шәехов Зөфәрит, Суфиева Сәвия, Вәлиәхмәтова Рәкыя, Суфиев Әхәт, Халитова Кифая.

***Югары Уръяды авылы:*** Асламова Мәрҗәм, Дәүләтханова Бибисара.

***Яңа Әлем авылы:*** Әнвәрева Дилбәр, Фәйзуллина Фәния, Әхмәдуллина Фелүсә, Нәгыймова Һава, Усманова Тәхия.

***Яңа Байсар авылы:*** Җиһангирова Мәдинә.

# ОСТАЛАР ЯГЫ

## Традицион һөнәрчелек һәм халык сәнгате

*Рауза Солтанова*

Галимнәр Актаныш районын тарихи һәм мәдәни традицияләре ягыннан Казан татарларының көнчыгыш этнографик төркеменә кертеп карыйлар[1]. Бу төбәктә халык көнкүрешенең милли-мәдәни йөзен формалаштыруга актив йогынты ясаган этноүзгәрешләр күзәтелә. Актанышның җирле халкы электән татар традицион матди культурасы һәм халык декоратив сәнгате үсешенең үзенчәлеген билгеләгән[2].

Районның җирлеге, тарихы археологлар А. П. Шокуров, Р. С. Габәшев, В. Ф. Генинг, Е. П. Казаков тарафыннан чагыштырмача тулы тикшерелгән һәм анализланган. Тарихчы Д. М. Исхаков үзенең хезмәтләрендә этник мәсьәләләргә туктала, этнографлар Н. А. Халиков, Ю. Г. Мөхәммәтшин, Ф. Ш. Сафина вак һөнәрчелек һәм матди мәдәният тарихын тикшерә. Ә менә декоратив сәнгать һәм матди мәдәниятнең бүгенге торышы бөтенләй өйрәнелмәгән иде диярлек.

---

[1] *Исхаков Д. М.* К этнической и этнокультурной дифференциации татар Волго-Уральского региона (историографический обзор и постановка проблемы). Этнокультурное районирование татар Среднего Поволжья. – Казань, 1991. – С. 3–52.

[2] *Исхаков Д. М.* Из этнической истории татар восточных районов Татарской АССР до начала XX века // К вопросу этнической истории татарского народа. – Казань, 1985. – С. 36–59.

Актаныш халкының декоратив сәнгатен гомуммилли мәдәниятнең шундый ук формалары белән чагыштырып карау безгә бу төбәккә хас җирле үзенчәлекләрне билгеләргә һәм халык сәнгатенең тарихи дәвамчанлыгын ачыкларга мөмкинлек бирде. Биредә Актаныш төбәгендә гомер кичерүче татарларның традицион мәдәнияте һәм халык декоратив-гамәли сәнгате төрләренә тукталырбыз. Аларны 2004 һәм 2009 елларда Күҗәкә, Татар Суыксуы, Түке, Зөбәер, Такталачык, Пучы авылларына ясалган комплекслы экспедицияләр вакытында барладык. Тикшерүгә, җирле материаллар белән беррәттән, район һәм мәктәп музейлары тупламалары да җәлеп ителде. Сәнгать үрнәкләрен өйрәнү-анализлау (1500 ләп предмет һәм объект сурәткә төшерелде һәм теркәлде) информаторлар биргән мәгълүматлар белән баетылды.

Актаныш халкы гомер-гомергә игенчелек һәм терлекчелек белән көн күргән. Мондый тормыш рәвеше үз чиратында үсемлекчелек һәм терлекчелек продуктларын эшкәртү белән бәйле һөнәр һәм кәсепләрнең үсешенә этәргеч биргән. Уфа губернасындагы вак һөнәрләр үсешен чагылдырган мәгълүматларга караганда, XX гасыр башында биредә йорт җиһазлары, савыт-саба ясау, кылыч кәсебе (рус телендә «бердо» исеме белән билгеле, тәрәшле таракка охшаш махсус җайланма ярдәмендә кулдан туку), чабата үрү, тупас киндердән капчык һәм башка хуҗалык кирәк-яраклары туку, бау-аркан ишү, тимерчелек, арба-тарантас ясау, итек тегү, тире эшкәртү, киез басу, йон тетү, кием-салым тегү таралган була (кушымтаны карагыз).

Актаныш халкы, нигездә, үзендә җитештерелгән арзан чималдан файдаланган. Терлекчелек продуктларын эшкәртү белән бәйле вак һөнәрчелек төрләреннән тегү, киез басу, йон язу аеруча киң таралган булган. Авыл халкы гади һәм шул ук вакытта бик чыдам аяк киеме – *кәлүш катысы* теккән. Әмма XX гасырның 40 нчы елларына кадәр көнкүрештә чабата беренчелекне тоткан әле. Зөбәер авылында яшәүче Нәкыя Муса кызы Шәвәлиева (1918 елда туган) сүзләренә караганда, кәлүш катысын сарык тиресен без ярдәмендә тишеп, җитен һәм киндер җепләр белән теккәннәр. Итекчеләрнең эш кораллары – аяк киеме калыплары, без, пычак, кыстыргыч, чүкеч һ. б. Актанышның

туган якны өйрәнү музеенда саклана. Кайбер авылларда өлкән буын әлегә кадәр тире иләү белән шөгыльләнә[1]. Ата-бабалардан мирас булып калган әлеге һөнәр алымнары бүгенге көндә төлке, куян, ондатра тиреләрен эшкәртүдә, баш киемнәре тегүдә кулланыла[2]. Йон эшкәртү үзәкләре элек Пучы, Такталачык волостьларында урнашкан була. Анда киез баш киемнәре, киез аяк киемнәре эшләнелгән. Йонны сугыш елларында да иске гадәт буенча эшкәрткәннәр. *«Халык тула өмәсенә җыелгач, иң башта киндер нигезгә йонны җәеп салалар, аннары аны таяк тирәли әйләндерәләр һәм су белән юешли-юешли, тәгәрәтәләр иде», –* дип тасвирлап бирде киез басуны Түке авылында яшәүче Рифкать Бәхтигәрәй улы Солтанов (1934 елда туган). *«Оекларны кейледә бастырдылар», –* дип, эшләү рәвешен тәгаенли төште Нәкыя Шәвәлиева. Уръяды авылында тула оек һәм эшләпәләр өчен киез әзерләүче махсус осталар да булган. Авыл халкы, мәсәлән, Шәйморат бабайны (туган елы билгеле түгел) һәм Талип Газизовны (1890 –1959) хәтерли. Осталарның теге яки бу һөнәрдәге күнекмәләре балаларына да күчкән. Уръяды авылында гомере буе киез аяк киемнәре баскан Мирзанур Закировның кызы, мәсәлән, бүгенге көндә бу һөнәрне Адай авылында дәвам иттерә[3]. Түке авылында исә киез аяк киемнәрен Галләм Минһаҗетдин улы Низамов (1925–2001) эшләгән.

Бурсык авылында Көнкүреш хезмәте күрсәтү үзәгендә (1930 елда оешкан, 1992 елга кадәр эшләгән)[4] киез басу белән Ф. Г. Димиев (1938–2010), Ф. М. Муллахмәтов (1941), А. Н. Насриев, А. М. Фәтхетдинов (1932– ), М. Ш. Шәйдәүләтов шөгыльләнгәннәр. Алар җирле чималдан кышын – киез аяк киемнәре, җәен сандыклар эшләгәннәр. Бүгенгесе көндә әтисенең һөнәрен Димиевның улы Флүн (1966) дәвам итә.

---

[1] *Халиков Н. А.* Хозяйство татар Поволжья и Урала (середина XIX – начало XX в.). – Казань, 1995. – С. 176–177.

[2] Мәгълүмат бирүче – Рифкать Бәхтигәрәй улы Солтанов (1934), Түке авылы.

[3] Мәгълүмат бирүче – Саяф Гариф улы Хаҗиев (1930), Күҗәкә авылы (чыгышы белән Уръядыдан).

[4] Мәгълүмат бирүче – Ләлә Шәрип кызы Нургалиева.

Киез басу ысулларына балаларны Актаныш районы Балалар иҗаты үзәгендә 2015 елдан бирле өйрәтәләр. Өстәмә белем бирү педагогы Илсөяр Заһит кызы Шәрипова (1974) мастер-класслар күрсәтә, күргәзмәләр оештыра. Сәнгать белгече Р. Р. Солтанова[1] инициативасы белән 2014 елда биредә Казан рәссамы М. Королёва коры ысул белән киез басу буенча мастер-класс үткәргән. Монда, әлеге ысулны кулланып, төрле уенчыклар, шарфлар, брошкалар һ. б. эшләнә.

Юкә һәм карама кабыгыннан чабата үрү нык таралган була. Ярлы гаиләләр чабатаны сату өчен дә үргән. Минем әнием Гөлрәйхан Солтанова (1936 елда туган) әнисе белән көненә 50 шәр пар чабата үрә торган булган. Чабаталарны Пучы, Минзәлә базарларында сатканнар. Авыл кешесенең көнкүрешендә кәрзин, сумка, сандык, балык тоту өчен махсус җайланмалар, бишекләр, йорт җиһазлары һәм өянке, карама, шомырт кабыгыннан үрелгән башка әйберләр киң кулланылган. Күҗәкә авылыннан Хатыйп Зарипов (1918–1997) каз оялары, бишекләр, тарантас үрәчәсе һәм хәтта чаналар да[2] үргән. Зөбәер авылыннан Эльмира Шәрифуллина (1947 елда туган) сүзләренә караганда, Илтимер авылы халкы кәрзиннәр, каз оялары, ипи савытларын күрше авыллар өчен дә эшләгән. Түгәрәк кәрзиннәрне эчтән һәм тыштан тукыма белән төреп ясый торган булганнар. Түке авылында Аҗип Әмиров (1932–1998) халык соравы буенча бишекләр ясаган. Такталачык авылының мәктәп музеенда Бурсык авылыннан Әзһәм Фәтхетдиновның (1935–2007) 1961 елда үргән чытыр бала урындыгы саклана (7 рәс.). Галимнәр, урындык үрү кәсебе бирегә 1890 елларда күчеп килгән латышлардан кергән, дип билгели[3]. Әзһәм Фәтхетдинов өстәл, этажерка кебек көнкүреш җиһазлары

---

[1] Солтанова Рауза Рифкать кызы (1958), сәнгать фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИнең тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире. Чыгышы белән Актаныш районы Түке авылыннан.

[2] Мәгълүмат бирүче – Халидә Әбрар кызы Гомәрова (1955), Күҗәкә авылы.

[3] *Халиков Н. А.* Промыслы и ремесла татар Поволжья и Урала. – Казань, 1998. – С. 43.

да үргән. Бурсык авылында 1990 елларга кадәр аның җитәкчелегендә йорт җиһазлары ясау буенча артель эшләгән.

1960 елларга кадәр бу авылда Л. Я. Карпов исемендәге Менделеевск химия заводы белән килешү нигезендә кислота шешәләре өчен махсус кәрзиннәр үргәннәр. Чималны (тал чыбыгы) җирле халыктан данәсен 7 тиенгә сатып алганнар[1]. Артель янганнан соң, анда сандык эшли башлыйлар. Аларны Зеленодольскида эшләнгән фанер тактадан ясаганнар.Тирә-як авылларның соравы буенча елына йөзләрчә сандык эшләгәннәр, хәтта Башкортстаннан да сораучылар күп булган. Сандыкның берсен 45 сумнан сатканнар.

Бүгенге көндә Актаныштта йорт җиһазлары ясау буенча җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять эшли. Биредә бу якның символы саналган аккош сурәте төшерелгән бирнә сандыклары эшләнә (11 рәс.).

Күҗәкә авылында электән үк йорт җиһазлары ясаучы осталар (Н. М. Мусин, Н. Г. Галимҗанов, Ә. С. Солтанов) булган. Пыяла шкафлар ясап танылган Әбелгас абый Солтановны халыкта «пыялачы Әбелгас» дип йөрткәннәр. Бу авыл шулай ук балта осталары (Х. Ш. Шәйхелмәрданов, З. М. Хәйбиев, Н. Ә. Әнвәров) белән дә дан тоткан. Сугыш вакытында хәтта хатын-кызларның да балта остасы булып эшләве мәгълүм. Зөбәер авылыннан Шәмсениса Нәбиева (1880–1966) шундыйлардан. Ул арба, камыт, дуга, тырма ише әйберләр ясаган (шагыйрә Эльмира Шәрифуллина истәлекләреннән).

Агач савыт-саба ясау Идел буе татарларының борынгыдан килгән традицион һөнәрләреннән санала[2]. Актаныш районы музейларында агач савыт-сабаның күп булуы биредә бу кәсепнең киң таралганлыгын күрсәтә. Актаныштта *кашык, чынаяк, тәлинкә, тагарак, кисмәк, мичкә, гөбе, чиләк, җилпүч, орчык* ясаганнар. Аларны нарат, юкә, усактан эшләгәннәр. Осталар, савыт-саба белән беррәттән, агач тараклар да ясаган. Актаныш музеенда, мәсәлән, Иске Сәфәр авылыннан алынган тарак ясау

[1] Мәгълүмат бирүче – Ләлә Шәрип кызы Нургалиева.

[2] *Халиков Н. А.* Промыслы и ремесла татар Поволжья и Урала. – Казань, 1998. – С. 184.

станогы саклана. Музейларда җирле һөнәрчеләр тарафыннан эшләнгән эреле-ваклы иләкләр, орчыклар, кылычлар да еш очрый.

Арба-тарантас ясау – шулай ук борынгы чорлардан ук тамыр җәйгән кәсепләрнең берсе. Игенчелек белән тыгыз бәйләнгән һөнәр төре буларак, Актанышта ул XIX гасырның икенче яртысында киң тарала. Осталар җәй көне йөрергә тарантас, арба, кышкы юллар өчен чана (утын чаналары, чыптадан үрелгән кәрзин сыман биек артлы, тирән һәм киң чаналар һ. б.) эшләгәннәр. Такталачык авылы халкы бүген дә әле бу һөнәрне дәвам иттерә. Сабан туе үткәрергә тарантас һәм арбаларны алардан ясаталар. Уръяды авылыннан Зөфак Шәвәлиев (1936 елда туган) матур тарантаслары белән тирә-юньдә дан тота. Ул хәтта атаклы әби-патша тарантасының күчермәсен ясаган. Түке авылыннан Тимершәех Гариф улы Салиховның (1925–1986) арбалары пөхтә, җыйнак булулары белән аерылып торган (ул аларны 1980 елларга кадәр эшләгән).

Күзкәй, Байсар волостьларында тимерчелек киң таралган. Остакулларның хезмәт җимешләре – балта, дага, пычак, урак, сәнәк, ухват һ. б. Әнәктә, Актаныш авылында һәм районның башка музейларында саклана. Такталачык авылыннан Сәмәрә Мирзаян кызы Әхмәтшина (1926 елда туган) әйтүенчә, аның этисе Мирзаян Ашим улы Ашимов (1883–1975), тимер-томыр ремонтлау белән генә чикләнмичә, авылдашларының соравы буенча чиләкләр, тимер мичләр, комганнар, соскылар ясый торган булган[1].

Бүгенгесе көндә металл эшкәртү (тимерчелек эше) Михайловка (Д. Д. Исламов, 1994), Иске Байсар (А. А. Галиев, 1990); Чалманарат (Х. Г. Камалетдинов, 1970 ), Яңа Әлем (А. Сәрвәров), Иске Җияш, Әтәс (Р. Х. Кашапов), Түке (И. М. Тимеров, 1974), Югары Яхшый (Р. С. Хәсәнов, 1959), Иске Бикчәнтәй (Р. Ш. Гатин, 1957) һ. б. авылларда киң таралган. Тимерчелек белән яшь осталарның шөгыльләнүе тагын да куанычлы. Иске Байсар авылыннан Галиев Артурның тимердән ясаган эшләнмәләре (капкалар, кәрнизләр, тарантаслар, ландшафт дизайны өчен композицияләр), Михайловка авылы егете Исламов

---

[1] Күмәкләштерү елларында Мирзаян Ашимов пекарня да оештырган. Аңа күрше авыллардан, мәктәпләрдән, хастаханәләрдән, хәтта район үзәгеннән заказлар килгән.

Динарның челтәрләп эшләнгән эскәмияләре, чәчәкләр өчен аскуймалары үзләренең нәфислеге һәм матурлыгы белән аерылып торалар. Борынгы чорларда зур үсеш алган һөнәрләр – сөяктән әйберләр ясау һәм керәч кәсебе бүгенге көндә юкка чыга бара, онытыла. Бу төр һөнәрләрнең Актаныш төбәгендә таралган булуын биредәге туган якны өйрәнүчеләр тарафыннан тупланган уникаль экспонатлар дәлилли. Такталачык авылы музеенда, мәсәлән, сөяк саплы борынгы кылыч саклана. Кылыч сабына чокылган истәлек язуын галимнәр әлегә кадәр укый алмаган (17 рәс.).

1950–1970 елларда археологлар Актаныш төбәгендә дистәләгән тарихи-археологик һәйкәлләр тапканнар (Такталачык, Әҗмәт каберлекләре). 1964 елда Иске Семиостров авылында, мәсәлән, П. Н. Старостин тарафыннан тәрәшле тарак яисә үргән баусыман бизәк төшерелгән, балчыктан әвәләп ясалган юка кырлы керәч ватыклары табылган[1]. 1975 елда Татар Ямалы авылында монгол явына кадәрге чорга караган болгар чүлмәкләре очраган. 1957 елгы экспедиция вакытында А. П. Шокуров неолит чорына караган, сырлап ясалган бизәкле керәч әйберләр, X–XII гасырларга караган кабырчык яисә тальк катнаштырылган измәдән эшләнгән аркан-тәрәшсыман бизәкләр төшерелгән яссы төпле савыт-саба, болгар савыт-сабасы ватыклары тапкан[2].

Татар Ямалы, Мәсәде, Уразай, Актаныш, Түбән Гәрәй, Бурсык авылларында пьянобор культурасына караган керәч сәнгате калдыклары очрый. Е. П. Казаков Әҗмәт каберлегендә уздырылган казу эшләре вакытында түгәрәк төпле шома, ялтыравыклы савытлар, балчыктан әвәләп ясалган юка кырлы бизәксез керәч әйбер ватыклары таба. Такталачык авылында исә аркан-тәрәшсыман, түгәрәк төпле савытлар, кушнаренко культурасына караган мул бизәкле чүлмәк ватыклары табылган[3]. Е. П. Казаков, башлыча, Такталачык һәм Әҗмәт каберлекләре материаллары нигезендә болгар чорының постпетрогром һәм чиялек

[1] Археологические памятники Восточного Закамья. – Казань, 1989. – С. 70–80.

[2] Шунда ук. – Б. 71.

[3] Шунда ук. – Б. 89.

культураларын бүлеп чыгара. Аның фикере буенча, бу археологик табылдыкларның килеп чыгышы, Идел Болгары чорында төркиләшкән һәм Ислам дине кабул иткән, Урал буе угырлары белән бәйле[1].

2000 еллар башында Түке авылыннан Нәсих Солтанов (1973 елда туган) Илтимер авылы янындагы карьерда тагын бер борынгы каберлек таба. Аннан, балчык савытлар белән бергә, үлгән кешеләрнең баш сөякләре дә чыга. Атрибуция үткәргәннән соң, археолог Е. П. Казаков, бу истәлекле әйберләр бура культурасына карый, дигән фикергә килде (б. э. к. II меңьеллык уртасы) (3, 13, 14 рәс.). Чүлмәкләрнең берсе банка формасында һәм яссы төпле итеп соргылт-сары төсле балчыктан эшләнгән. Икенчесе дә банка формасын хәтерләтә. Киңәеп киткән өлешенең өске ягында асма сырлар төшерелгән (14 рәс.). Чүлмәккә охшаш өченче савыт алдагыларга караганда мулрак бизәлгән: муены һәм киңәеп киткән өлешләренең өске ягында бөжрасыман штамп оттисклары, савытның авызы турысында исә өчпочмаклар рәвешендәге тарак тәрәше сыман штамплар бар (13 рәс.)[2].

Экспедиция вакытында без музейларда һәм актанышлыларның өйләрендә соңрак чорларга караган (XVII–XVIII гасырлар) бүтән артефактлар да таптык. С. М. Әхмәтшина гаиләсендә (Такталачык авылы), мәсәлән, өстенә ялтыравык эретмә (глазурь) йөгертелгән чүлмәк формасындагы савыт саклана (авызының диаметры – 19 см, төбенеке – 13 см, биеклеге – 23 см). Киңәеп киткән өлешенә «6» лы санын хәтерләтүче билге сырланган (ул останың нәсел тамгасы, яисә исеменең баш хәрефе булырга мөмкин), аның янәшәсендә «М» хәрефе дә бар. Пучы авылы мәктәбендәге чүлмәк формалы, тар төпле, саргылт көрән төсле, өске өлешенә соргылт сары төстәге ялтыравыклы эретмәдән коеп эшләнгән савыт та шундыйлардан (16 рәс.).

---

[1] *Казаков Е. П.* Памятники болгарского времени в Восточных районах Татарии. – М.: Наука, 1978; *Казаков Е. П.* Чиялекская культура: территория, время, истоки // Материалы VI Сибирского симпозиума. – Тобольск, 2003. – С. 79–87; *Казаков Е. П.* Угры Восточного Закамья Улуса Джучи // История татар. – Казань, 2009. – С. 284–285.

[2] Нәсих Солтанов бу экспонатларны 2003 елда Зөбәер авылы мәктәбенә тапшырган.

Актаныш авылының туган якны өйрәнү музеенда саклана торган станок-рамнар бу төбәктә кирпеч ясауның киң таралган булуы турында сөйли. Күпчелек авылларда тирә-юньгә йөреп мич чыгаручылар булган. Түке авылында, мәсәлән, 1960–1980 елларда бу һөнәр белән Гыйльмегали Ганиев (1930 елда туган) шөгыльләнгән.

Актаныш районында 1960 елларга кадәр ягулык өчен тирес сугу кәсебе киң таралган булган. Моның өчен ике һәм аннан да күбрәк бүлемле төрле зурлыктагы агач калыплар ясаганнар. Тирес «кирпеч»ләрне, киптерер өчен, ачык һавага (ишегалдына, елга буена һ. б.) печән чүмәләсе формасында өйгәннәр. Бу «архитектур» корылмалардан бала-чага актив файдалана иде. Әле дә хәтерлим, бәләкәй чакта без шунда концерт-тамаша оештыра, качышлы уйный идек. Зөбәер авылы халкы Кашкатау янындагы сазлыктан *«умра тирес»* (торф) чыгара торган булган. Аны, утын урынына файдаланып, мичкә якканнар, самавыр куйганда күмер урынына кулланганнар.

Бик үк киң таралмаган һөнәрләр рәтенә бура тишек-ярыкларын томалау өчен мүк, сүс җыюны кертергә мөмкин. Гадәттә, бу кәсеп белән сазлык җирләрдә урнашкан авыл халкы шөгыльләнгән (Адай, Күҗәкә, Зөбәер, Чәчер, Илтимер, Түке авыллары һ. б.). Зөбәер авылы халкы Гөргөри күле янында кондырак җыя торган булган. Адай авылы халкы бүгенге көндә дә бу һөнәрне дәвам иттерә. Алар мүк, кондырак сату турында район газетасында еш кына игълан бирәләр.

Сәнгатьчә нәфис әйберләр тукып эшләү – өй шартларында башкарыла торган һәм гаилә йолалары белән тыгыз бәйләнгән кәсеп[1]. Яшь кәләшләрнең бирнәсен элек кулдан эшләнгән бизәкле сөлгеләр, ашъяулык, чаршау, кашага, җәймә, мич япмалары, алъяпмалардан башка күз алдына да китереп булмаган. Алар үзләре тукыган әйберләр белән кияү йортын бизәгәннәр. Йола сөлгеләре туй, никахларда, балага исем кушу ашларында, гает, корбан һ. б. дини бәйрәмнәр уздырганда әле дә кулланыла.

---

[1] *Суслова С. В.* Татарское народное декоративно-прикладное искусство // Этнография татарского народа. – Казань: Магариф, 2004 . – С. 216.

Татар Суыксуы авылыннан Л. А. Исхакова (1885 елда туган), Х. Г. Латыйпова (1926 елда туган), Адай авылыннан Ш. М. Мөхәммәтшина (1887 елда туган), Зөбәер авылыннан Н. М. Шәвәлиева (1918 елда туган), З. Ш. Сабирова (1914 елда туган), Күҗәкә авылыннан С. С. Сәхапова (1931 елда туган), С. Х. Гыйләҗева (1934 елда туган), Такталачык авылыннан К. Г. Габдрахманова (1919 елда туган), М. Г. Гыйльфанованың (1915 елда туган) кул эшләре музейларда һәм шәхси тупламаларында саклана. Бу китапта, безнең карашка, аеруча игътибарга лаек осталарның кайбер иҗат үрнәкләре китерелде (төсле кушымтаны карагыз).

Алтын куллы ханымнар гадәти бизәкләү ысулларын белү белән генә чикләнмичә, төрледән-төрле композицияләр уйлап чыгарганнар. Аларның кайберләре этнограф Ф. Ш. Сафина китабына да кертелгән. Әлеге китапта шулай ук, Куян, Такталачык, Кәзкәй авыллары осталарының гаять үзенчәлекле чаршау, төксез келәм һәм сөлгеләренең рәсемнәре урнаштырыла[1]. Экспедиция материалларыннан күренгәнчә, бу төбәк осталары тукучылык сәнгатенә хас барлык алымнарны белгәннәр һәм эш барышында кулланганнар (әйтик, *«чүпләм»*, *«төсле чүпләм»*, *«асалап сугу»* һ. б.).

Актанышта безгә төрле төсләр катнаштырып, шакмаклап яисә аркылы бизәкләр төшереп тукылган киндер *алачалар* һәм нәкышьләп (бизәкләп) сугылган тукымалар очратырга туры килде. Җитен алачалар тонык зәңгәр, соры, көрән-кызгылт, лимон төсендәге сары катыш кара һ. б. салкын төсләрдән эшләнеп, бик нәфис колоритлары белән аерылып торалар. Туку осталары төсләрне төрлечә аралаштыру, бер-берсенә яраштыру нәтиҗәсендә үз иҗатларында гармониягә ирешкән, төсләр палитрасын баеткан (20–24 рәс. Ашъяулык, алъяпма, букча (сумка) үрнәкләре). Актанышта шулай ук кызыл-зәңгәр, кызыл-кара төсләрне катнаштырып тукылган шакмак бизәкле, җете ачык төсле алачалар да очрый. Алар арасында иң киң таралганы – шакмак бизәкле, аклы-кызыллы алачалар. Ашъяулык һәм алъяпмалар өчен буйлап яисә шакмаклап сугылган алача файдаланылган. Өс

[1] *Сафина Ф. Ш.* Ткачество татар Поволжья и Урала. – Казань, 1996. – С. 88, 160, 139, 140, 150, 153, 156, 158, 176.

киемнәрендә туры, дөрес шакмаклы алачаларга өстенлек бирелсә, ыштаннарны төрле төстәге буйлар белән тукылган алачадан теккәннәр (28 рәс.).

Өй эчен бизәү һәм хатын-кыз ягын кунак бүлмәсеннән аерып тору өчен, чаршау киң кулланылган. Төсләре һәм үзәк өлешкә, каймага бүленеп бизәкләр төшерелүе буенча чаршаулар ашъяулыкларны хәтерләтә[1]. Бүгенге заман интерьерында чаршау урынына фабрикада эшләнгән вак яисә эре чәчәкле төрле төстәге тукымалар кулланыла.

Экспедиция вакытында чүпләм бизәкле һәм алача чаршауларның киң таралган булуы ачыкланды. Алар нәкышьләре, композицияләре, күләмнәре һәм төрле төстә булулары белән аерылып торган. Зөбәер авылы музеенда кызыл, зәңгәрсу, куе кызыл, сары төсләрдән гаять нәфис итеп эшләнгән алача чаршау (19 рәс.) һәм *чүпләм* туку элементлары белән җылырак төсле җепләрдән тукылган чаршаулар саклана. Актаныш авылы музеенда тукучылыкның төрле ысуллары *(алача сугу, түшәп туку)* белән башкарылган үзенчәлекле чаршау бар (18 рәс.). Аның бизәлеше борынгы башкорт чаршауларыныкына тартым. Композицияне тәшкил итүче бизәк белән эре орнамент мотивлары нәкъ менә төс ярдәмендә «бәйләнгән»[2].

Декоратив тукымалар турында сүз алып барганда, йола бәйрәмнәрендә, өй эчен бизәүдә һәм көнкүрештә киң кулланыла торган сөлгеләрнең төрлелегенә игътибар итми мөмкин түгел. Аларның очларына *чүпләм, төсле чүпләм, асалап сугу* һәм катнаш ысуллар белән сугылган бизәкләр төшерелгән. Аркылы бизәкле сөлгеләр дә киң таралган. Музейларда җете зәңгәр, яшел, сары кул эшләре еш очрый. Алар башлыча кызыл төсле орнаментлар белән бизәлгән (25 рәс.). Кайберләренең колориты тагын да баерак (кызыл фонда – ак, аксыл шәмәхә, сары, зәңгәрсу, ачык яшел, куе караңгы зәңгәр, горчица төсендәге бизәкләр; кара: 27 рәс.). Арада тоныграк, ягъни тыныч төсле (алсу, ком төсе, сыек яшел, соры катыш зәңгәрсу) җепләрдән тукылган кул эшләре дә очрый

[1] Шунда ук. – Б. 89.

[2] *Янбухтина А. Г.* Декоративное искусство Башкортостана. XX век: от тамги до авангарда. – Уфа: Китап, 2006. – С. 102.

(29 рәс.). Актанышның туган якны өйрәнү музеенда һәм Такталачык, Зөбәер авылларында *күп аркаулы (төсле чүпләм, түшәп туку)* ысул белән башкарылган бизәкле кул эшләре *(кырык шырпылы тукымалар)* саклана. Аларда һәр бизәк аерым башкарылган. Өч яки биш *аркылы бизәктән* торган композициядә урта буй сызык төп сәнгати-эстетик мәгънәгә ия. Күләме һәм рәсем формасы белән ул башкалардан аерылып тора (33 рәс.).

Төрле геометрик бизәкләрдән тыгыз итеп тукылган композицияләрдә (анда ромб, өчпочмак, шакмак, күппочмаклыклар, авыш хачлар, ыргаклар, спиральсыман формалар, тәкә мөгезенә, йолдызга охшаган бөтеркә бизәкләр дә булырга мөмкин) төп бизәк мотивы калку итеп күрсәтелми.

*Түшәп туку* техникасы нигезендә эшләнгән, *асалап сугу, түшәп туку* ысулларын берләштереп тукылган кул эшләрен аерым төркемдә карарга мөмкин (32 рәс.). Адай авылыннан Ш. Мөхәммәтшинаның сөлгеләре нәфис һәм шул ук вакытта гаять үзенчәлекле булулары белән аерылып тора. Мәсәлән, аларның берсендә ул тыныч төсләргә (сорыга тартым зәңгәрсу, сыек яшел, ачык фирүзә, нәфис сары, алсу, тонык сирень төсе) кара төс кушып, бик килешле, нечкә, нәфис композиция тудыра алган (30 рәс.).

*Асалап сугу* техникасы шәрык халыкларында борынгы чорлардан ук таралган төксез келәм җитештерүнең нигезен тәшкил итә[1]. Татар йортларының интерьерында еш кулланылган палас, идән җәймәләрен, бүтән төр тукымалар белән бергә, бер үк төрле туку станында җитештергәннәр. Бүгенге көндә палас туку технологиясендә, аның бизәлешендә электән килгән традицияләрнең саклануы күзәтелә. Актаныш районында киндердән сугылган паласлардан тыш, буй җебе киндер булып, аркау җеп урынына буй-буй итеп ертылган, бер-берсе белән тоташтырылган һәм җиңелчә боргычланган иске тукыма кисәкләре кулланылып эшләнгән паласлар (киңлеге – 40–75 см) да очрый. Төсле җепләр һәм тукыма кисәкләре кушылмасы гаҗәеп матур төсләр балкышы барлыкка китерә. Күҗәкә авылында тулаем сарык йоныннан тукылган бизәкле паласларны күрергә мөмкин (35 рәс.).

---

[1] *Валеев Ф. А.* Татарский народный орнамент. – Казань, 2002. – С. 35.

Паласларның аркылы сызыклылары да, геометрик бизәкләре дә киң таралган. Геометрик бизәкле паласларда башлыча төрле зурлыктагы һәм төрле төстәге ромблар игътибарны җәлеп итә. Элек зур ромбларның эченә кечкенәрәк ромб, шакмак, хач сыман фигура һ. б. тукыганнар. Тикшеренүчеләр фикеренчә, ромб кайда, ничек урнашуына һәм нинди билгеләр белән кушылуына карап, җирне, йортны, хатын-кыз затын, гомумән, җимеш бирүче башлангычны чагылдырырга мөмкин икән. Амброз фикеренчә, гади ромб хатын-кыз башлангычын, ягъни җир билгесен белдерә. Шашка тактасына охшатып эшләнгән ромб җир билгесен, ыргакчыклар белән катнаштырып сурәтләнгән ромб җимеш бирүче Җир-Ананы символлаштыра. Ромблар чылбыр булып тезелеп килсә, аларны «тормыш агачы» дип аңларга кирәк. Урта Азия келәмнәрендәге ике ыргакчыклы ромб тәкә мөгезен, дүрт ыргакчыклы ромб парлы тәкә мөгезен аңлата. 12 ыргакчыклы ромб ел циклы белән бәйле, ул 12 айны белдерә[1].

Композицияләрдә Идел һәм Урал буеның татар-типтәр компонентлы көньяк районнары өчен хас булган бер төсле фонда күзгә бәрелеп торган монументаль бизәкләрне дә, киртләч-киртләч контурлы гомумиләштерелеп сурәтләнгән геометрик формаларны да күрергә мөмкин[2]. Бу паласларның күбесендә тар кайма юк, ә кайберләре караңгырак төсле тукыма белән әйләндереп алынган. Бүгенге көндә тыныч төсле җепләрдән тукылган, буялмаган сарык йоны (ак, кара, соры) кушылып эшләнгән паласлардан тыш, җете төсле (караңгы зәңгәрсу, ачык алсу, сары, шәмәхә, яшел, ачык яшел) идән җәймәләрен дә очратырга мөмкин. Мондый паласлар диварга эленгән ачык, якты төстәге чигүләр һәм эре чәчәкләр төшерелгән бизәкле чаршаулар белән аеруча килешле, матур тора.

Соңгырак елларда тукылган паласларның кайберләрендә элек сирәк очрый торган үсемлек бизәкләре төшерелгән. Мәсә-

---

[1] *Алиева К.* Безворсовые ковры Азербайджана. – Баку, 1988. – С. 32.

[2] *Валеева-Сулейманова Г. Ф.* К вопросу об исторической преемственности традиционного искусства населения аулов Альметьевского района (опыт типологии и районирования) // Проблемы изучения истории населения и образования населенных пунктов Альметьевского района. Материалы симпозиума. – Казань: Матбугат йорты, 2000. – С. 117.

лән, шундыйларның берсендә бик матур роза чәчәге сурәтләнгән. Рәсемнең ал чәчәк төшерелгән өлеше бөрчек-бөрчек сыман итеп куе кызыл төстәге вак шакмаклар, ә яшел яфраклы нигезе сары төстәге вак шакмаклар белән бизәлгән. Җете төсле, бәйрәмчә матур һәм үзенә бер төрле купшы үзенчәлеккә ия булулары белән аерылып торган мондый паласлар «батмус» дип аталган башкорт идән җәймәләренә охшаган[1]. «Батмус»лар рәсем төшерелгән подносларны хәтерләтә. Бу төр паласлар интерьерга бәйрәм рухы өсти (34 рәс.).

Палас туку эше Актаныш районында үткән гасырның 80 нче елларына кадәр дәвам иткән. Күҗәкә авылыннан Г. Н. Нуруллина (1914–2005) гомеренең соңгы көннәренә кадәр бу эшне кулыннан төшермәгән. Үзе тукыган паласлар белән ул йортын бизәп кенә калмыйча, аларны туганнарына бүләк иткән һәм хәтта сату өчен дә җитештергән. «Суккан паласларымның озынлыгы Мәскәүгә җитәр иде», – дия торган булган ул балаларына.

«Ул суккан идән җәймәләре, алъяпмалар шундый нәфис, матур, буен буйга, шакмагын шакмакка туры китереп эшләнгән иде ки, кибетләрдә сатылган келәм, ашъяулыклар бер якта торсын», – дип искә ала шагыйрә Эльмира Шәрифуллина әбисе З. Ш. Сабированың (Зөбәер авылыннан) уңганлыгын. Кызганыч, бүген туку станнарында эшләүчеләр юк. Шуңа күрә алар чорма, сарайларда тузан җыеп ята (кайберләрен музейларда күрергә мөмкин). Күп кенә осталарның эшләре – дөньяда тиңе булмаган бәһасез ядкярләр. Моны яхшы аңлаган актанышлылар әниләренең, әбиләренең хезмәте кергән кул эшләрен күз карасыдай кадерләп саклыйлар.

Шунысы сөендерә: халыкта өйдә тукылган палас, келәмнәргә мәхәббәт сүнмәгән әле. Һәр авылда диярлек тукыма кисәкләреннән, сарык йонынннан ыргакчык белән түгәрәк идән паласлары һәм урындык япмалары бәйлиләр. Әзер бизәкле тукыма өстеннән шома чигү ысулы белән чигелгән һәм төкле келәмгә охшаш идән җәймәсе эшләүче осталар да бар (36–38 рәс.).

Татар хатын-кызлары элек-электән чигәргә яраткан. Фабрикада эшләнгән тукымалар барлыкка килү белән үзеннән-үзе ки-

[1] *Янбухтина А. Г.* Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 102.

рәксезгә чыккан тукучылык шөгыленнән аермалы буларак, чигү һөнәренең гомере озынрак. Ул өй эчен бизәүдә (пәрдә, сөлге, алъяпмалар), урын-җир кирәк-яракларын матурлауда (урын-җир җәймәсе, кайма, мендәр тышы, мендәр япмасы), дини йолалар үтәгәндә кулланыла торган әйберләрдә (намазлыклар, китаплар өчен тышлык-футлярлар), милли костюмнарда (аеруча хатын-кыз күлмәкләрендә) киң кулланыла.

Татарларда (бигрәк тә Идел буе – Урал төбәгендә яшәгәннәрендә) тамбурлы, күп төсле чигү киң таралган була. Тамбур белән бизәкнең контур сызыгын һәм аның эчке ягын чиккәннәр. Чигүнең «элмә» (тамбур) һәм «күперткән элмә» төрләре киң кулланылган. Безгә һәр ике төргә караган чигү үрнәкләрен очратырга туры килде. Төрле стильдә башкарылган чигү үрнәкләренең кайберләрендә борынгы чигү белән уртаклыклар тоемлана. Алар ак, кызыл, сары, кара төсле нигезләргә үсемлек бизәкләре, хайван рәсемнәре, кеше сурәтләре (антропоморф орнамент) төшерүдән гыйбарәт. Орнаментларның төп бизәкләре шундый оста яшерелгән, аларны хәтта аеру да кыен. Арада «тормыш агачы» (39 рәс.), тәкә мөгезе, кояш билгеләре (40 рәс.), бөтеркә бизәкләр кебек архаик мотивлар очрый. Зөбәер авылында яшәүче Гөлчирә апа Ямалетдинова (1931 елда туган) өендә 1953 елдан бирле саклана торган бирнә сөлгеләре аерым игътибарга лаек. Бу ике сөлгенең (берсе – кызыл, икенчесе сары төсле) башлары элмә чигү белән бизәлгән (42 рәс.). Композициясе ачык бүленгән өч өлештән тора. Иң өстә зәңгәр төсле җептән чылбырсыман бизәк чигелгән. Аңа параллель итеп «М» рәвешендәге зәңгәрле-аклы орнамент урнаштырылган. Шунда ук тамыр өлешеннән тасма белән матурлап бәйләнгән кара төсле «тормыш агачы» күренә. «М» хәрефенә охшаш бизәк өстә һәм аста урнаштырылган; абстракт композициянең аскы өлешендә, нәкъ өстәге кебек, зәңгәр төсле бизәк чигелгән. Сөлгенең башларына телле-телле өчпочмаклар тезелгән. Галимнәр фикеренчә, өчпочмак мотивы символик мәгънәгә һәм тылсымлы көчкә ия. Халыкта «өчпочмак бизәге явыз көчләрдән, күз тиюдән саклый» дигән ышану яшәгән. Өчпочмак мотивы келәмнәрдә, чигүләрдә очрый. Аны шулай ук «бөти» рәвешендә дә очратырга

мөмкин[1]. Өчпочмак мотивы Зөбәер мәктәбе музеенда саклана торган сөлгедә дә чагыла (39 рәс.). Анда кызыл төсле нигезгә үсемлек бизәкләрен һәм хайван рәсемнәрен хәтерләтүче орнаментлар чигелгән. Үзәктәге күләмле композициядә «тормыш агачы», агачның ике ягында эре куаклыклар, ә горизонталь җирлеккә үсемлек бизәкләре чигелгән. Рәсемнәрнең эче бүтән төсле җеп белән (кара, шәмәхә, яшел, зәңгәрсу, сары) сырлап бизәлгәнгә күрә, композиция нәфис һәм җиңел челтәрне хәтерләтә. Үзәк композициянең өске һәм аскы өлешләрендә ике компоненттан торган бер үк төрле рәсемнәр төшерелгән. Аларның өстәгесе кеше сурәтенә охшаган. «Тормыш агачы»ның һәм уртадагы бизәкләрнең кара төс белән аерып күрсәтелүе аны үзенчәлекле итә.

Кашага һәм намазлыкларда борынгылык чалымнары тагын да ныграк сизелә. Тәрәзә кашагалары башлыча ачык төсле тукымалардан (күбрәк ак һәм кызыл) тегелгән һәм йорт эчен бизәп, матурлап, аңа бәйрәмчә төс биреп торган. Татар өйләренең матчасына да кашагалар эленгән. Моннан тыш, кашагаларның «түрләмә» дип аталучы төрен дә очратырга туры килде. Түрләмәләр кыска гына пәрдә рәвешендә тәрәзә өсләренә эленгән (Түке, Татар Суыксуы, Зөбәер авыллары). Еш кына осталар, рәсемнәр белән чикләнмичә, тукымага өстәп, ак һәм кара төсләрдән кулдан бәйләнгән челтәрләр дә тегеп куя торган булганнар. Орнаментлы композицияләрнең нигезен, гадәттә, мул уңыш, байлыкны белдерүче «тормыш агачы» һәм әлеге символиканы дәвам итүче чәчәк бәйләме мотивы тәшкил итә. Кайбер композицияләрдә бер үк чәчәк бәйләме кабатланып чигелә. Чигүче осталар, еш кына рәсемнәрдәге тормышчанлыкны декоратив шартлылык белән берләштереп, гаҗәеп матур, әкияти, фантастик формалы бизәкләр уйлап чыгарганнар. Агач кәүсәләре, үсемлек сабаклары, чәчәк-яфрак мотивларыннан гыйбарәт катлаулы конфигурацияләрдә бер үк вакытта хайван рәсемнәре элементларын да (аяк, койрык, канат һ. б.) күрергә мөмкин. Асимметрия һәм чә-

---

[1] *Алиева К.* Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 33.

Өлкән буын хатын-кызлар әле бүген дә ике чәч толымы арасында Коръән аятьләре язылган өчпочмак формасындагы бөти йөртәләр һәм аның хәвеф-хәтәрдән саклавына чын күңелдән ышаналар.

чәк бәйләмнәрен төрле чәчәкләрдән төзү композициягә шундый үзенчәлек өсти – анда тормыш, хәрәкәт бар сыман тоела.

Татар Суыксуы авылындагы кашага үрнәге югарыда тасвирланганнардан гадирәк күренсә дә, болын һәм дала чәчәкләре (акчәчәк, күгәрчен күзе) һәм лотоссыман мотивларның оста үрелеп бирелүе белән үзенчәлекле.

Түке авылыннан Р. Нәсыйпованың (1926–1999) сатиннан (50 гә 240 см үлчәмдә) тегелгән кашагасы бизәкләргә аеруча бай (41 рәс.). Ул бер чәчәк бәйләмендә шәмәхә, сары, яшел, алсу, кара, ак, зәңгәр, зәңгәрсу, ультрамарин төсләрен берләштереп, гаҗәеп килешле, төгәл композиция төзүгә ирешкән. Кайма буенча урнашкан үсемлек бизәкләренең һәм хайван рәсемнәренең катлаулы кушылмасыннан гыйбарәт орнаментлар бер төрле стильдә чигелгән. Намазлыклар исә, киресенчә, тыйнак, гади итеп бизәкләнә. Дисбе белән бергә иң түргә куелса да, алар күзгә ташланып торырга тиеш түгел, ди халык[1]. Намазлыкларның традицион бизәлеше аларның функциясе белән тыгыз бәйләнгән: урта өлеше буш калдырыла, ике кырыйлап бер-берсенә симметрик рәвештә бизәкләр чигелә, гыйбадәт кылучының күз карашы беренче чиратта төшәчәк алгы өлеш шулай ук рәсемнәр белән нәкышьләнә[2]. Намазлыкларның бркага (михрабка) охшап торган урта өлеше бүтән төр яссылыкка, оҗмахка күчү концепциясен билгели – бу намазлык символикасында иң мөһимнәрдән санала. «Тормыш агачы», бакча, чәчәк мотивлары оҗмах идеясе белән бәйләнгән. Кайбер очракларда чәчәк бизәкләре тонык төсле җепләр белән (аксыл көрән, сирень төсе, караңгы кызыл, соры) чигелә. Ике кырыйлап чигелгән «тормыш агачы» мотивын гәүдәләндерүче бизәкләр (лалә, чалма чәчәк, ачылган чәчәк бөресе) композициянең үзәген – Мәккә тарафын күрсәтеп, тагын да баетылып, намазлыкның өске өлешенә күчә. Намазлыкларның җете төсле, мул, тыгыз бизәкле, тормышчанрак сюжетлы төре дә бар (43, 44 рәс.). Йон җеп белән чигелгәнлектән, аларның өсте кабарынкы булып тора. Ботак, яфрак бизәкләре

[1] Мәгълүмат бирүче – Рәвидә Гыйльметдинова (1937), Түке авылы.

[2] *Валеева-Сулейманова Г. Ф.* Мусульманское искусство в Волго-Уральском регионе. – Казань: Магариф, 2008. – 117 с.

белән баетылган чәчәк, җиләк-җимеш рәсемнәре җете төсләр белән чигелә. Намазлык кырыйларын тулысынча диярлек тутырган бу рәсемнәр күңелләрдә оҗмах бакчасы образын тудыра. Бөдрәләнеп үскән гөл үрентесе бизәген һәм чәчәкләрнең эчен кара төсле җеп, тышын кызыл җеп белән каймалау композицияне тулы һәм бөтен итә. Халык осталары эшләгән намазлыклар, нигездә, ак төстә. Моны күп халыкларда ак төснең «изге» булып саналуы һәм гыйбадәт кылганда күбесенчә ак төстәге киемнәргә өстенлек бирелү белән дә аңлатып була.

Актаныш районы авылларындагы өлкән яшьтәге хатын-кызларның барысы да диярлек «шома чигү», «тутырып чигү», «бастырып чигү», «басма чигү» ысулларын яхшы белә. Канва ярдәмендә чигелгән һәм шома чигүдә сабак сыман җөйнең бергә кушылуыннан гыйбарәт булган катлаулы техник алымнар кулланып эшләнгән әйберләр дә күп бирелә. Кайбер хатын-кызлар туй бирнәләрен һәм кияүгә дип әзерләнгән бүләкләрен бүгенгә кадәр кадерләп саклыйлар. Мәсәлән, Күҗәкә авылыннан З. Т. Мөхәммәтова 1950 елларда канва белән чигелгән, челтәр белән бизәлгән карават башы, сөлге, кияү кулъяулыклары кебек кул эшләрен әле дә истәлек итеп тота.

Сөлге башлары, мендәр тышлары, карават башлары, мендәр япмалары, чынаяк япмалары кебек көнкүреш кирәк-яракларының төрләре бихисап. Күкрәкчә, аяк чолгавы, баш яулыгы, калфак, түбәтәйләргә матур бизәкләр чигелгән. Элек йорт кирәк-яракларын, урын-җир әйберләрен өйдә тукылган тукымалардан гына тексәләр, тора-бара сатып алынган материаллар (бәз, сатин, штапель, атлас, парча, бәрхет, вельвет) файдаланыла башлаган. Алар арасында ак, аксыл көрән, алсу, зәңгәрсу, кызгылт сары төсле тукымалар өстенлек иткән. Бизәкләрне мулинә, йон җеп, сирәк очракларда алтын җеп, ука белән чиккәннәр.

Кайбер авылларда кара тукымага төрле төстәге җепләр белән чигелгән киемнәр, йорт кирәк-яраклары очратырга мөмкин. Бу төр бизәлешне районның җирле үзенчәлеге дияргә була.

Усы авылында туып үскән, бүгенге көндә Түке авылында гомер кичерүче Рәвидә апа Гыйльметдинованың сүзләренә

караганда, ак төстәге чаршау элсәләр, диварны да ачык төстәге чигүләр белән бизәгәннәр, чаршавы кызыл төсле булса, дивар чигүенең нигезе кара булган. Кешелеккә – ак, көндәлеккә кара күлмәк кигәннәр. «Минем кара сатиннан бизәкле алъяпкычым да бар иде», – дип сөйли ул. Кара кием турында хәтта мәҗлесләрдә җырлана торган җырлар да булган:

...Парлап костюм тектердек
Икебез дә карадан.
Дошман сүзе йөрмәсен
Икебезнең арадан...

С. В. Суслова һәм Р. Г. Мөхәммәтова билгеләп үткәнчә, татарларда күп төсләр белән чигү киң таралыш алган[1]. Ә менә кара төстәге чигүле күлмәкләр күбрәк типтәрләргә хас.

Диварлардагы чигү үрнәкләре үзләренең композицияләре, бизәкләре, төсләрнең төрлелеге белән аерылып тора. Аларның озынлыгы, гадәттә, 40–150 см, киңлеге 20–70 см. Чигүләр диварга рамсыз беркетелә. Зигзаглап яисә бизәкләп чигелгән каймалары рамга охшап торганлыктан, һәр татар йортында диярлек эленгән мондый чигүләр үзенчәлекле картина сыман кабул ителгәннәр. Шул ук вакытта алар декоратив натюрмортларны да хәтерләтәләр. Чүлмәк савыттан үсеп чыккан яисә сабакларының аскы өлеше тасма белән матурлап бәйләнгән чәчәк бәйләмнәре – чигүләрдә иң еш очрый торган сюжетларның берсе. Бу паннолардагы сурәтләргә тормышчанлык, төгәл ритм хас. Чигүләрдә бакча гөлләреннән роза, дәлия, кашкарый, алтынчәчәк, кыр, урман үсемлекләреннән күкчәчәк, акчәчәк, кыңгырау чәчәк, күгәрчен күзе еш тасвирлана. Арада катлаулы катнаш ысул белән башкарылган (шома чигү һәм сабаксыман җөй), кызгылт сары нигезгә күкчәчәкләр һәм калгансыман чәчәкләр төшерелгән үзенчәлекле карават башлары, уртасы – аксыл кызыл, ак төстәге канәферләр, кырыйлары күкчәчәкләр һәм яфраклар белән бизәлгән мендәр тышлары да очрый (51, 53 рәс.). Чынаяк япмаларында, чәчәкләрдән тыш, җиләк-җимешләрне дә (мәсә-

[1] *Суслова С. В., Мухаммедова Р. Г.* Народный костюм татар Поволжья и Урала (середина XIX – начало XX в.). – Казань, 2000. – С. 106.

лән, җир җиләге рәсемен) күрергә мөмкин. Рәсемнәрдә хыял байлыгы да юк түгел: чәчәк һәм яфраклардан төрледән-төрле бөтеркәләр, үсентеләр, җиләкләр үсеп чыккан. Костюм (ир-ат һәм хатын-кыз күлмәкләре, билбаулар) бизәлешендәге чиккән бизәкләр ярдәмендә киемнең конструкциясе билгеләнгән: мәсәлән, яка, җиң, итәк, күкрәк өлеше, кесә (79, 82, 84 рәс.).

Экспедиция вакытында татар, рус телләрендә (сирәк очракларда – гарәп хәрефләре белән) истәлек язуы чигелгән кул эшләрен очратырга туры килде. Кайбер үрнәкләрнең чигелгән көне күрсәтелгән. Бу язуларны кул остасының шәхси тамгасы дип кабул итәргә мөмкин (мисал өчен, «С добрым утром. 1959»; «Моя любовь. 1965», «Хәерле иртә», «Хәерле көн» язулары чигелгән паннолар һ. б.; 55, 57 рәс.). Үсемлек бизәкләре һәм хайван рәсемнәре сюжетлы композициядә бергә дә очрый. Моңа мисал итеп үбешеп торучы күгәрченнәр, җеп йомгагы белән уйнаучы мәче балалары һәм гөлләр сурәтләнгән чигү үрнәген китерергә мөмкин.

Кайбер чигүчеләрнең кул эшләре аеруча матур, зәвыклы булуы белән аерылып тора. Бу өлкәдә Зөбәер авылынан Г. Г. Ямалетдинова, Пучы авылыннан Ш. Ә. Шәйхеразиева, Түке авылыннан Г. Ә. Солтанова һәм Р. Ә. Гыйльметдиновага тиңнәр юктыр. Рәвидә апа Гыйльметдинованың бер үк ысуллар һәм бер үк стильдә (шома чигү, канва) чигелгән бирнә әйберләре (ишек һәм караватчаршаулары, кашага, мендәр тышлары, урын-җир япмалары, туй күлмәге) искиткеч әйбәт сакланган (47–57, 77–78 рәс.). Шунысы кызык: Рәвидә апа 1960 елда кияүгә чыгып, Усы авылыннан Түкегә күчеп килгәч, авыл халкы аның кул эшләренә охшатып чигә башлаган. Рәвидә апа исә осталыгын һаман саен камилләштереп тора. Бүген ул яшәгән йортның верандасы күз явын алырлык чигү үрнәкләре белән бизәлгән. Әлеге үрнәкләр этнография музейларында лаеклы урыннарын алырлар әле.

Экспедиция вакытында җирле халыкның милли костюмнары җентекләп өйрәнелде. Алар, нигездә, үткән гасырда Казан тирәсендә гомер кичергән татарларның киенү рәвешенә тәңгәл килә. Шул ук вакытта, баш киемнәренең тегелешендә, костюмнарның вак детальләрендә, бизәлешендә һәм төсендә аерымлыклар да бар.

Бурсык авылыннан хатын-кызлар өске кием тегү белән шөгыльләнгәннәр. Биредә 1930 елда промартель оештырылган (алга таба Көнкүреш хезмәте күрсәтү үзәге), монда 1950 еллар уртасында тегү цехы ачыла (1992 елда янып бетә). Әлеге цехта күлмәкләр, колакчан бүрекләр, туннар тегәләр. 1972–1992 елларда Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү үзәге җитәкчесе Ләлә Шәрип кызы Нургалиева (1939) сөйләгәнчә, хезмәткәрләр арасында белгечлектә төгәл бүленү булган: Фәния Шәйгәҗанова (1930–) кисүче вазифаларын башкарган, Сания Рәхимова (1936), нигездә, сырмалап теккән.

Костюмнар, аларның тегелеше һ.б. турында Пучы авылында 32 ел кием тегүче булып эшләгән (үзе Зөбәер авылыннан) Хәниф Сәетгәрәй улы Гәрәев (1914–2010) бик күп кызыклы мәгълүматлар бирде. Аның үзенә беренче костюмын 1920 еллар ахырында Миршәриф исемле мулла тегеп биргән булган.

Ир-атларның гадәти киеме күлмәк һәм ыштаннан торган. Күлмәкләр ике төрле итеп: «утыртма яка» һәм «урыс якасы» яки «әйләнмәле яка» белән, бер-ике төймә беркетеп, җиңел тукымадан тегелгән (81, 84 рәс.). Җиңнең башын һәм очларын, гадәттә, чигеп бизәкләгәннәр. Хәниф Гәрәев сөйләвенә караганда, бай кешеләрнең күлмәк итәге дә чигүле булган (гадәттә, үсемлек бизәкләре чиккәннәр). Кешелеккә күлмәкләрне атластан тегә торган булганнар. Баерак кешеләр күлмәкләрен зәңгәрсу, кызыл, зәңгәр сатин һәм бәздән тектергән. Өлкән буын буйлы бизәклене үз итсә, яшьләр күп төймәле күлмәк кигән. Татарлар барысы да ак һәм кара түбәтәйләрдән йөргән. Өлкән буын ир-атлар – бизәксез ак түбәтәй, яшь кияүләр кара түбәтәй кия торган булган (87 рәс.).

Бу якларда, бүтән төбәкләрдән аермалы буларак, кырлы киез эшләпә кигәннәр. Өлкән буын кешеләренең эшләпәләре ак киездән булган. Актаныш халкы, бүтән төбәкләрдәге кебек үк, күлмәкләрен билбау белән бәйләгән. Өлкән буын эссе көннәрдә дә билбаусыз йөрмәгән. Билбауны, нигездә, 2,5 м озынлыкта, 30–40 см киңлектә теккәннәр. Яшь кәләшләр кияүләренә, башка бүләкләр белән бергә, чигүле чолгаулар бүләк иткән (81 рәс.). «Аяк чолгавы әнкәйнең үз кулы белән әткәйгә дип чиккән туй бүләге булган. Ул ак төсле җирлеккә яшел җепләр белән чигеп

бизәкләнгән иде. Балаларында бик озак еллар истәлек булып сакланды», – дип искә ала Э. Шәрифуллина.

Актанышлылар киеменең этник үзенчәлеге аларның төсендә һәм күлмәк итәкләренең тәңкәләп бизәлүендә чагыла. Тәңкәләрнең һәм итәк бөрмәләренең санына карап, кызның баймы, ярлымы булуы турында фикер йөрткәннәр. Күлмәк итәкләрендәге 3–4 рәт бөрмә билгә кадәр менгән. Күлмәк җиңнәрен шулай ук 1–2 рәт бөрмә (шләпер) белән бизәп теккәннәр[1]. Күлмәкләрне башлыча бер генә төсле итеп – яшел, алсу яисә көрән тукымалардан тегә торган булганнар. Ак төскә зур өстенлек бирелгән (74–78, 80, 86, 88 рәс.). Байбичәләр итәк бөрмәләрен зәңгәр һәм кара төстәге кулдан бәйләнгән челтәрләр белән бизәгән. Кара төсле тукымадан кием сирәк тегелгән.

Хатын-кыз баш киемнәреннән 15 см киңлектәге тукымага тәңкәләр тезеп эшләнгән чәчкаплар бик үзенчәлекле. Чәчкабы булган кәләш акчалы, бай саналган. Шуңа күрә яшь киленнең чәчкабы булу-булмау (яисә аның ничә булуы) халыкны бик кызыксындырган. Тәңкәләр, алтын җепләр белән чигелгән бизәкләр һәм калфак өстен ямьләндереп торучы сәйлән бөртекләре хатын-кызның бай, дәрәҗәле булуын күрсәткән. Ә менә чәчләрне Казан татарларында еш кулланылган тезмә белән бизәү Актаныш якларында очрамады.

Экспедиция вакытында муенсаларның берничә төре теркәлде: а) *төймә* (бусы); б) берничә рәт сәйләннән ясалган *муенса* (ожерелье); в) *муен тәңкәләре,* ягъни тукымага тегелгән тәңкәләр (гадәттә, 7 рәт тегелгән була). Шулай ук *дәват* дип аталган Казан татарларының *хәситәсенә* охшаш бизәнү әйберен очратырга туры килде. Хәниф абый Гәрәевнең истәлекләренә караганда, *дәватларны* тукыма кисәкләренә төрле зурлыктагы тәңкәләр тегеп ясаганнар. Бу бизәнү әйберен, гадәттә, олы яшьтәге ханымнар кия торган булган. Х. Гәрәев безгә авыр сугыш елларында, ачлыктан исән калу өчен, әнисенең дәватын сатып, он алуы турында сөйләде. Шулай итеп, чәчкап, киез эшләпә, дәват,

[1] Мәгълүмат бирүчеләр – Зөбәер авылыннан Сафия Нәбиева һәм Хәниф Гәрәев.

муенса кебек киемнәр һәм бизәнү әйберләре Актаныш районында Урал төбәгенең татар-мишәр компонентлы традицион мәдәнияте өстенлек итүе турында сөйли.

Элек-электән күлмәк эченнән киелә торган, *күкрәкчә* яисә *түшти* дип аталучы күкрәк бизәмәсе тегә торган булганнар (мәҗүсиләрдә, күкрәкчә хатын-кызны, бигрәк тә бала имезүче хатын-кызны күз тиюдән саклый, дигән ышану яшәгән)[1]. Безгә бер төрле күкрәкчә генә очратырга туры килде: ул 25×40 см зурлыкта булган турыпочмаклык формасындагы йомшак тукымадан тегелгән, өске өлеше трапеция формасында эшләнгән. Биредә, Урал арты татарларында һәм аларның күршеләре булган башкортлардагы кебек үк, киҗе-мамык яисә ефәк тукыма кисәкләреннән аппликация рәвешендә бизәлгән күкрәкчәләр өстенлек итә[2]. «Күкрәкчәне вак-төяк йөз ялгаудан ясыйлар иде», – дип сөйләделәр безгә. Информантлар әйтүенчә, күкрәкчәнең нигезе тамбурлы яисә шома чигү ысуллары белән эшләнә торган булган, әмма безгә андыйлары очрамады. Актаныш якларында яшь кәләшләр күкрәкчәләрне туй бүләге итеп тә әзерли торган булганнар[3] (67–73 рәс.).

Актаныш районында торак коруның төп конструктив һәм этнографик үзенчәлекләре Казан татарларының төзүчелек мәдәнияте кысаларында үсеш алган[4]. Мәгълүм булганча, XX гасыр ахырында (илдә икътисади хәл кискенләшү сәбәпле) авылларның төс-кыяфәте нык үзгәрде. Элек авылларда урам башларында *кыр капкалары* ясап куя торган булганнар. Ул, гадәттә, 4 тактадан торган. Утарларны тоташ койма белән уратып алганнар. *Читән, такта коймалар* киң таралган. Түке авылында арткы яктагы бакчаларны аерып тора торган читәннәргә игътибар иттек. Бу авылда читән үрүдә Дәүләтгәрәй Солтановка (1901 елгы) тиңнәр булмаган, диләр.

Түбәсез урам капкасы Актаныш төбәгендә торак кору мәдәниятенең үзенчәлеге санала. *Урыс капкасы* дип аталучы, ике кы-

[1] *Суслова С. В.* Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 107.
[2] Суслова С. В. Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 107.
[3] Мәгълүмат бирүче – Светлана Хәбибуллина, Зөбәер авылы.
[4] *Халиков Н. А.* Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 237.

егы булган түбәле капкалар биредә бик сирәк очрый. Аның каравы, кече капка белән зур капкадан торган, ике якка ачылмалы капкалар киң таралыш алган. Элек капка һәм койма баганалары буларак агач бүрәнәләре файдаланылса, бүгенге көндә алар урынына төрле юанлыктагы торбалар кулланыла.

Йортларны капламасын өчен, капка һәм коймалар тәбәнәк итеп эшләнә. Түр бакча коймасы, капка кебек үк, җете төсләргә буяла һәм матур итеп бизәлә.

Йортларны элек-электән усак, нарат агачларыннан төзегәннәр. Халыкта, каен агачы йортка бәхетсезлек китерә, дигән ышану яшәгән, шуңа күрә төзелештә аны кулланмаска тырышканнар[1].

Бура ярыкларын кызыл балчык белән сылау – Актаныш төбәге төзүчелек мәдәниятенең тагын бер үзенчәлеге. Соңгы елларда төзелештә кирпеч киң кулланыла (101 рәс.). Кирпечтән салынган йортларның эчке диварларын еш кына эшкәртелгән такта белән каплыйлар һәм лак белән буйыйлар. Кайбер йортларның эче ДСП белән берничәгә бүленгән. Мондый диварларга обой ябыштырылырга яисә келәм эленергә мөмкин.

Өй түбәләрен күбесенчә ике кыеклы итеп эшлиләр, аны шифер яки калай белән ябалар һәм төрле төсләргә (капка, койма төсенә) буйыйлар. Арада җете түбәле йортлар да очрый (мәсәлән, Түке авылында кызыл түбәле йортлар бар).

Йортларны такта белән тышлау, өй почмакларын, фронтоннарны, капка баганаларын буйлы-буйлы итеп буяу – шулай ук Актаныш төбәге төзүчелек мәдәниятенең үзенчәлекле ягы. Йортларны бизәүдә ялганма, контурлы, челтәрле, колонналы һәм уеп ясалган бизәкләр кулланыла (99, 100, 102 рәс.). Күҗәкә һәм Түбән Гәрәй авылларында агачны сәнгатьчә эшкәртү белән шөгыльләнүчеләр бар.

Мосавиров Мирсаяф Мосавир улы (1925–2004) – Пучы авылыннан, Бөек Ватан сугышы ветераны (Пучы татар сигезьеллык мәктәбендә завуч булып эшләгән, математика, физика, астрономия фәннәрен укыткан), үз эшенең остасы. Эштән соң кичен һәм төннәрен үз остаханәсендә агачтан бизәкләп

---

[1] Мәгълүмат бирүче – Рифкать Солтанов, Түке авылы.

тәрәзә йөзлекләре, рамнар ясаган. Ял көннәрендә, җәйге ялда Пучыда һәм күрше авылларда йортлар, верандалар төзегән, тәрәзә йөзлекләре ясаган. Аны өйләр тышларга, бизәкле коймалар ясарга чакыра торган булганнар. (Соңрак Минзәлә районы Тауасты Байлар авылында бизәкле коймалар эшләгән.) М. М. Мосавиров салган йорт (1966) әле дә сакланган. Өй, веранда, койма останың башка эшләренә хас булган бизәкләр белән башкарылган: «тавис койрыгы» орнаменты, үзәк нокталы дискка охшаган түгәрәк бизәкләр (диаметры 1–4 см), чәчәк һәм таҗ яфракчыгының төрле формалары. Ул, орнаментны тутык белән бозмас өчен, яссы агач өслеккә үзе ясаган агач кадаклар белән пөхтә итеп бизәкләр беркеткән.

Элек Актаныш якларында йортлар тоташ фронтонлы булган. Хәзер исә, Казан татарларының этномәдәни традицияләре тәэсире аркасында, анда да фронтон куышлары куллану тарала бара. Еш кына ихаталарда, аерым алганда, капка, веранда, келәт, гаражларның тышкы стеналарында буяулы рәсемнәр очратырга була.

Актанышта да, Казан татарларындагы кебек үк, йортның төп атрибуты мич булган. Авылларга газ кергәч, мичнең кирәге калмаса да, алар элеккеге урыннарында кала бирәләр (мичләрне ишектән кергәч тә дивардан бераз ара калдырып ясаганнар). Элек-электән мичләр *мич чаршавы* яисә *мич әйләнмәсе* дип аталучы пәрдәләр белән бизәлгән. Бу традиция бүген дә дәвам итә. Элек *мич чаршаулары* тукылган яки эре бизәкләр төшереп чигелгән булса, хәзер аларны фабрикаларда җитештерелгән тукымалар алмаштырды. Ул чаршауларны һаман да бөрмәле-бөрмәле итеп, матурлап элəләр (89 рәс.).

Бүгенге көндә күп йортларда мич ягылмый, шуңа күрә мич алдын пәрдә белән каплап куялар. Түке авылында безгә матур чигүле мич алды пәрдәләре очрады. Мич һәрвакытта да ак төстә булган. Ә менә Күҗәкә авылында Әнисә апа Сәлахова (1940 елда туган) мичләрен акшарлы нигезгә бизәк төшереп матурлаган, Түке авылыннан Саһира апа Газизуллина (1929 елда туган) миченә майлы буяу белән эре-эре чәчәк, яфрак рәсемнәре ясаган (95 рәс.).

Актаныш районында өй эчен эшләү үзенчәлекләреннән урын-җир кирәк-яракларын җыеп кую өчен файдаланылган

киштә, савыт-саба саклау өчен хезмәт иткән шүрлек һәм татарларда 1965–1970 елларга кадәр киң таралган сәкеләр турында әйтеп үтәргә мөмкин.

Актаныш якларында өй эчен, аерым алганда, ишек, тәрәзә, диварларны һәм урын-җир өсләрен тукыма белән бизәү гадәте бүген дә яши әле (89–94 рәс.). Һәрбер йортта диярлек кысага куелган шәмаил очрый (112–116 рәс.). Шәмаилләрнең күпчелеге читтән кайтартылган. Шәмаил сүзе үзе биредә кулланылмый, аны «аятел-көрси» һәм «дога сүзләре» дип йөртәләр. Элек Аятел-көрсине муллалар, остабикәләр үзләре яза торган булган. Доганы керә торган ишек өстенә яисә өй түренә эләләр. Зөбәер авылыннан Сафия Нәбиева фикеренчә, халыкта, «“Аятел-көрси”не укысаң, өрәк кайтмый», дигән ышану яши икән.

Җирле муллалар тарафыннан язылган каллиграфик текстлар да очрый. Аларда гарәп язуы шартлы рәвештә башкарылган мәчет рәсемнәре, үсемлек бизәкләре белән баетылган. Кайвакыт юка металл кәгазь (фольга) урынына көмеш төсендәге буяу файдаланыла (мәсәлән, Түке авылында «Бәкарә» сүрәсен шундый җирлеккә язганнар). Һәвәскәр рәссамнардан без яңа исем – Зөбәер авылыннан Рифкать Мирзафатыйх улы Фатыйховны ачтык. Ул, эчтән яктылык, төс биреп торсын өчен, юка металл кәгазь кулланып, пыялага классик шәмаилләр ясаган. Аның шәмаилләре авылдашларының йортларында да очрады. 1951 елда Рифкать әфәнде Ижевск шәһәреннән бер шәмаил күчермәсен алып кайта. 1954 елда үзлегеннән гарәпчә укырга һәм язарга өйрәнә. Шәмаилләрне ул үзе өчен һәм дусларының, танышларының соравы буенча эшли (112 рәс.).

Кызганыч, кул эшләре көндәлек тормыштан әкренләп китә, онытыла бара. Аның каравы йортлар салганда кирпечләрдән бизәкләр тезү киң таралган. Кирпечләрне, гадәттә, келәм бизәкләренә охшаш бер тәртиптә тезәләр. Кечкенә ромблар, хач сыман фигуралар аеруча еш очрый. Композиция өч өлештән – кәрниз астына агачтан кисеп ясалган үсемлек бизәкләреннән, йортның үзәк өлешендәге геометрик орнаментлардан һәм астагы сызык-бордюрлардан тора. Бизәлештә төп элемент булган кечкенә ромблар буяу белән коймага да ясала.

Татар халкы элек-электән ачык матур төсләрне яраткан. Түке авылыннан Саһира Газизуллина, мәсәлән, бөтен йортын сары төскә буяган, тәрәзә йөзлекләрен, капканы матур итеп бизәгән. Капкага контурлары кисеп ясалган үсемлек орнаментлары төшергән, йортны, йорт яны корылмаларын (умарта оялары, эт оясы, капка төбендәге утыргычларны) тагын да матуррак декоратив бизәкләр белән баеткан (96 рәс.).

Актанышлыларда яшәүнең ямен тою, үзләре яшәгән тирәлекне бизәргә омтылу чагыла. Бу исә милли культурабыз тамырларының тирәнлегеннән, дөньяны образлы күзаллый белүдән килә.

Тәкъдим ителгән анализ – 2004–2009 елларда ясалган фәнни экспедиция материаллары нәтиҗәсендә Актаныш районындагы традицион һөнәрчелекне өйрәнүнең беренче тәҗрибәсе. Тикшерү нәтиҗәләре бүгенге көндә күп кенә һөнәр төрләренең югала баруын күрсәтә. Бу үз чиратында көндәлек тормышта чагылып килгән традицион сәнгать системасының бөтенлеге югалуга китерә. Мисал өчен, йон эшкәртү (киез басу, йон язу) бөтенләй яшәүдән туктаган. Аны элеккеге хәленә кайтару, кабат торгызу мөмкин дә түгел, чөнки авыл халкының яшәү рәвеше узган чорлар белән чагыштырганда нык үзгәрә, ауропалаша бара.

Шулай да кайбер һөнәр төрләре, бигрәк тә агач, металл эшкәтү белән бәйле булганнары (балта эше, агач эше, арба-тарантас ясау, токарьлык, тимерчелек һ.б.) бүген дә гамәлдә әле.Иң киң таралган кәсеп – йорт җиһазлары, көянтә ясау, тал чыбыгыннан кәрзин үрү. Туку эше һәм челтәр бәйләү дә онытылып бетмәгән (Табанлыкүл авылында бүген дә сарык йоныннан палас сугалар). Безнең карашка, ата-бабаларыбызның бай мирасыннан саналган киез һәм күнне сәнгатьчә эшкәртү традицияләре яңадан торгызылырга мөмкин әле. Чөнки алар профессиональ рәссамнарның иҗатларында даими рәвештә үстерелә килә. Һөнәр-кәсепләрне торгызырлык, тәҗрибәләрен яшь буын белән уртаклашырлык осталарыбыз да юк түгел. Иң мөһиме – соңга калмау, коммерция нигезенә корылып барган мәдәният һәм сәнгать өлкәләрендә этник традицияләрен үстерү перспективасын вакытында күреп алу.

*1 нче кушымта*

## Актаныш районында элеккеге вак һөнәрчелек кәсепләре*

| № | Кәсепләр | Волостьлар |
|---|---|---|
| 1. | Итек тегү (төзәтү) | Пучы, Семиостров, Шәрип |
| 2. | Тире иләү | Күзкәй |
| 3. | Йон тетү, итек басу, бәйләү | Пучы, Нөркәй, Такталачык |
| 4. | Агачтан өй җиһазлары эшләү | Нөркәй, Пучы |
| 5. | Токарьлык, савыт-саба эшләү | Пучы |
| 6. | Корал ясау | Актаныш |
| 7. | Чабата туку (үрү) | Күзкәй, Пучы, Семиостров |
| 8. | Бау ишү | Семиостров |
| 9. | Балык тоту ятьмәсе бәйләү | Такталачык |
| 10. | Тимерчелек | Күзкәй |
| 11. | Тимерчелек-слесарьлык эшләре | Байсар |
| 12. | Арба ясау: | |
| | а) тарантаслар | Пучы, Нөркәй |
| | ә) чаналар | Күзкәй, Пучы |
| | б) арба тәгәрмәчләре | Пучы |
| 13. | Авыл хуҗалыгы кораллары һәм машиналары җитештерү | Шәрип |
| 14. | Тукымаларны катнаштырып эшкәртү (тегүчелек) | Актаныш, Пучы |

* Мәгълүматлар 1912 елда Уфада басылып чыккан «Кустарные промыслы Уфимской губернии» китабының «Мензелинский уезд» бүлегеннән алынды.

*2 нче кушымта*

## Музейлар турында кыскача белешмә

### *Актаныш районы туган якны өйрәнү музее*

Музей 1960 елда КПССның Актаныш райкомы карары буенча оештырыла. 1970 елларда, төбәкнең тарихын өйрәнү белән бергә, борынгы акчалар, язма истәлекләр, этнографик материаллар туплана башлый. Иң башта музей район мәдәният йортында урнаша. Аның штаттан тыш директоры Ибраһим Гариф улы Гарипов (1910–1987) була. Аның вафатыннан соң музей ябыла. 1994 елдан, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы карары белән, ул кабат торгызыла һәм дәүләт статусы ала. Директорлары: Фәкыйль Госман улы Сабитов (1993–1997), Азия Мөхәммәтша кызы Гәрәева (1997–2000). Лилия Гыйльмегали кызы Шәйгарданова музейны 2000–2012 елларда җитәкли. 2013 елдан музей директоры – Әгълетдинов Мирсил Магис улы.

1977–1987 елларда музей район мәдәният йортында, соңрак «Сельхозтехника» мәдәният йортында урнаша, 2000 елның 5 маеннан район кулланучылар берлеге бинасында эшләп килә. 1993 елда ул Татарстан Республикасы Берләштерелгән дәүләт музее филиалына әйләнә. 2003 елда «Татарстан Республикасы Актаныш районы туган якны өйрәнү музее» дәүләт учреждениесе итеп оештырыла. Реконструкциядән соң музейның мәйданы 502 м$^2$ тәшкил итә.

Бүгенге көндә музей фондында 13 меңнән артык экспонат бар, шуларның 7617 се төп фондныкы, 5398 экспонат гыйльми ярдәм фондыныкы. 3000 гә якын экспонат даими экспозициядә урын ала. Биредә район тарихына, һөнәр төрләренә (декоратив-гамәли һ. б. сәнгатьләргә) багышланган экспозицияләр бар.

### *Аеш авылы мәктәбенең туган якны өйрәнү музее*

Җитәкчесе – Әхмәтдинова Ландыш Рәдис кызы.

### *Аккүз авылы мәктәбенең туган якны өйрәнү музее*

Җитәкчесе – Шәвәлиев Дилүс Мирзасалих улы.

### *Актанышбаш авылы Мәдәният йорты каршындагы музей*

Җитәкчесе – Аскарова Алена Дамир кызы (1987 елгы).

### *Әнәк авылында Шәрип Шаһимөхәммәт улы Шәймиевнең музей-йорты*

2005 елның 11 июлендә оештырылган. Директоры – Гөлназ Фаил кызы Гыйбадуллина (1978 елгы). Музейда 250 экспонат – 23 чигү үрнәге, 12 эш коралы, 55 фотосурәт, 2 палас бар.

### *Зөбәер авылы мәктәбенең туган якны өйрәнү музее*

Музей мәктәп директоры Ринат Фәтхи улы Фәтхиев (1942–2020) инициативасы белән 1990 елда оештырылган.

### *Иске Богады авылы мәктәбенең туган якны өйрәнү музее*

Җитәкчесе – Зәйнуллин Рафаэль Нәҗип улы.

### *Иске Сәфәр авылының М.Ф. Шәвәлиев исемендәге туган якны өйрәнү музее*

Җитәкчесе – Һарунов Илдус Һади улы.

### *Иске Теләкәй авылы мәктәбенең туган якны өйрәнү музее*

Җитәкчесе – Газетдинов Илнар Флүн улы.

### *Кәзкәй авылы китапханәсенең туган якны өйрәнү музее*

Җитәкчесе – Әхмәдишина Гөлназ Рафис кызы.

### *Күҗәкә авылы мәктәбенең туган якны өйрәнү музее*

Музейга 1970 елларда Әбүбәк Шәех улы Шәехов (1925–1994) нигез сала. Ул Бөек Ватан сугышында катнашкан, мәктәптә математика укыткан. 2000–2015 елларда музейны тарих укытучысы Халидә Әбрар кызы Гомәрова (1955 елгы) җитәкли. Ул Минзәлә педагогия училищесын һәм Казан педагогия институтының география факультетын тәмамлаган.

Хәзерге вакытта музейны тарих һәм география укытучысы Шәйхетдинова Лилия Хәниф кызы җитәкли.

Музейда 1146 экспонат бар, шуларның 892 се матди мәдәнияткә карый.

### *Мари Суыксуы авылы мәктәбенең туган якны өйрәнү музее*

Җитәкчесе – мари теле һәм әдәбияты укытучысы Ирина Александровна Галиева.

### *Пучы авылы мәктәбенең туган якны өйрәнү музее*

Музей 2001 елда оештырыла. Аны башта рус теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлназ Әмирхан кызы Зарипова (1981 елгы) җитәкли. Хәзерге вакытта музей белән рус теле укытучысы Вәсимә Дәүләт кызы Хөрмәтуллина (1947 елгы) җитәкчелек итә. Мәктәп директоры – Нургалиева Ландыш Саяп кызы.

Биредә 400 экспонат – 4 картина, 3 портрет, бюст, 11 археологик табылдык, 7 чигү үрнәге, балалар тарафыннан иҗат ителгән 52 әйбер һ. б. бар.

### *Такталачык авылы мәктәбенең туган якны өйрәнү музее*

1990 елда рус теле һәм әдәбияты укытучылары Рәшит Фоат улы Ахунов (1956 елгы) һәм Сәкинә Харрас кызы Ахунова (1955 елгы) оештыра. 1993 елдан музейны татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әлфия Гавис кызы Нуриева (1959 елгы) җитәкли. Музей фондында 700ләп экспонат бар.

### *Татар Суыксуы авылы мәктәбенең туган якны өйрәнү музее*

Җитәкчесе – тарих укытучысы Зөлфирә Хикмәтелгаян кызы Латыйпова.

### *Уразай авылының туган якны өйрәнү музее*

Мәдәният йорты директоры – Шәрипова Римма Дамир кызы (1963 елгы).

### *Уразай авылы мәктәбенең Риза Ишморатка багышланган музее*

1983 елда Рафаэль Ишморатов катнашында төзелгән (мәктәп директоры – Исламов Рузил Мөхәммәтнур улы). Бүгенге көндә музей белән татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сәлахова Венера Халит кызы җитәкчелек итә.

### *Чәчер авылының туган якны өйрәнү музее*

Җитәкчесе – Муллагалиева Гөлназ Кашаф кызы.

### *Чөгәнә авылы клубы каршындагы «Совет авылы көнкүреше» исемле музей почмагы*

Җитәкчесе – Арысланова Алсу Илфар кызы.

### *Яңа Әлем авылы мәктәбенең туган якны өйрәнү музее*

Җитәкчесе – Сәлимянова Лилия Әхтәм кызы.

*3 нче кушымта*

## Декоратив-гамәли сәнгать осталары, һөнәрчеләр

### *Аеш авылы*

Гобәева Ирина Ришат кызы (1978 елгы), челтәр бәйләү остасы.

Закиров Радик Тимершәех улы (1965 елгы), металл эшкәртү остасы.

Шәйхуллина Рәзилә Дусмөхәммәт кызы (1946 елгы), чигүче.

### *Аккүз авылы*

Иксанов Данил Марат улы (2004 елгы), кәрзин үрү остасы.

Мөхәммәтҗанова Миләүшә ( ...), бәйләү остасы.

Хаҗиева Миннефаза Фатыйх кызы (1937 елгы), бәйләү, корама остасы.

### *Актаныш авылы*

Ибраһимова Эльвира Рафинат кызы (1980 елгы), шәмаил остасы. Тумышы белән Колын авылыннан.

Ризванова Халидә Мәгънәви кызы (1952 елгы), чигүче. Тумышы белән Уразай авылыннан.

Саматова Кадрия Шәрип кызы (1939 елгы), чигүче, келәмнәр ясау остасы. Тумышы белән Уразай авылыннан.

Хәкимова Илизә Әфтах кызы (1946 елгы), чигүче.

Шәрипова Илсөяр Заһит кызы(1974 ), чигүче, киез басу остасы. Актаныш районы Балалар иҗаты үзәгенең өстәмә белем бирүче педагогы.

### *Әгъбәз авылы*

Гыйздәтов Халитҗан (1966 елгы), агачны кисеп-уеп бизәү остасы

Нәбиева Фәния (1930 елгы), чигүче.

### *Әҗәкүл авылы*

Дәүләтов Дилшат Әбелмәних улы, кәрзин үрү остасы.

### *Әтәс авылы*

Бәдертдинова Исхания Шәйхелгали кызы (1955 елгы), бәйләү остасы.

Зәкиева Рина Закир кызы (1951 елгы), чигүче.

Кашапов Нурсил Хәмит улы (1968 елгы), металл эшкәртү остасы.

Кашапов Нурсил Хәмит улы (1968 елгы), металл эшкәртү остасы.

Шириева Нәзиха Камал кызы (1952 елгы) , бәйләү остасы.

### *Бурсык авылы*

Билалова Зөхәдия Морзахан кызы (1934–2017), тегүче.

Гайсина Резеда Гали кызы (1967 елгы), бәйләү остасы.

Димиев Фәвис Гали улы (1938–2010), агачны кисеп-уеп бизәү остасы, киез итек басучы.

Димиев Флүн Фәвис улы (1966 елгы), агачны кисеп-уеп бизәү остасы, киез итек басучы.

Исхакова Сәмәрә Мансур кызы (1924 елгы), челтәр бәйләү остасы.

Муллахмәтов Флүр Муллахмәт улы (1941елгы), киез итек басучы.

Насрыев Әнвәр Насрый улы (1929–1998), итек басучы.

Нургалиева Ләлә Шәрип кызы (1938 елгы), тегүче, бәйләү остасы. Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү үзәге җитәкчесе (1972–1992).

Нурлыгаянова Дифинә Миңнеразый кызы (1942 елгы), бәйләү остасы.

Рәхимова Сания Вәҗетдин кызы (1936 елгы), тегүче.

Фәтхетдинов Әзһәм Мәгъфүрҗан улы (1932–2007), өй җиһазлары ясаучы балта остасы, 1990 елларга кадәр мебель эшләү һәм киез аяк киемнәре басу артелен җитәкләгән.

Шәйгәҗанова Фәния Шәйгәҗан кызы (1930 елгы) – кисүчетегүче.

Шәйдәүләтов Мәгъдәнур Шәйдәүләт улы (1932–), итек басучы.

### *Зөбәер авылы*

Гәрәев Хәниф Сәетгәрәй улы (1914–2010), тегүче. 32 ел буе Пучы авылы ательесында кием кисүче булып эшләгән.

Гыйделбанат, Н. М. Шәвәлиеваның әбисе, тукучы.

Зәйнетдинова Рауза Акмалетдин кызы (1934 елгы), чигүче. Мәсрүрә Хәсәнованың килене.

Мөхәммәтханова Латыйфа Мөхәммәтхан кызы (1910–2006), тукучы.

Нәбиева Шәмсениса Солтангәрәй кызы (1880–1966), балта остасы, тегүче. Тумышы белән Сәфәр авылыннан.

Сабирова Закирә Шәйхетдин кызы (1914 – 1998), тегүче, тукучы, чигүче.

Фатыйхов Рифкать Мирзафатыйх улы (1940 –2016), һәвәскәр шәмаил остасы.

Харисова Кафия Шәһримулла кызы (1894–?), тукучы, Н. М. Шәвәлиеваның әнисе.

Хаҗиәхмәтова Назыйфә Хаҗиәхмәт кызы (1905–1997), тукучы. 1990 елларга кадәр сөлгеләр, паласлар, җәймәләр тукыган.

Хәсәнова Мәсрүрә Ямалетдин кызы (1905–1989), тукучы. Мәктәп музеенда саклана торган барлык сөлгеләрне дә ул тукыган.

Шәвәлиева Нәкыя Муса кызы (1918–2017), тукучы.

Шәйхетдинова Фәрхебану, тукучы, чигүче.

Ямалетдинова Гөлчирә Госман кызы (1931–???), чигүче.

*Балта осталары династиясе:*

Вилданов Мирхәт Вилдан улы (1930–2020). Киез аяк киемнәре басу белән дә шөгыльләнгән.

Вилданов Мохтар Вилдан улы (1939–1984).

Исламов Вилдан Ислам улы (1894–1974).

Исламов Хәлил Мохтар улы (1963 елгы).

### *Илтимер авылы*

Әмируллина Рисала Әмирулла кызы (1923–2015), чигүче.

Гаязов Гаязетдин Насретдин улы (1885–1965), кәрзин үрүче, умартачы.

Гаязова Зөләйха Җәлил кызы (1897–1995), тукучы, тегүче.

### *Иске Байсар авылы*

Ганиев Артур Альберт улы (1990 елгы) – чүкеп ясау остасы (2011 елдан). Остазы – Ганиев Альберт Афзалтдим улы. Урта һөнәри белемгә ия.

### *Иске Бикчәнтәй авылы*

Борһанова Дәнифә Гыйздулла кызы (1942 елгы), бәйләү остасы.

Гатин Ринат Шамил улы (1957 елгы), металл эшкәртү остасы.

Шәрипова Галия Әбүдәр кызы (1943 елгы), чигүче.

### *Иске Җияш авылы*

Минһаҗев Р.Ш., металл эшкәртү остасы.

Хуҗина Э.Л., бәйләү остасы.

### *Иске Кадермәт авылы*

Гыйлфанова Инзилә Булат кызы (2005 елгы), бәйләү остасы.

Шәйсолтанова Галия Фоат кызы (1966 елгы), бәйләү остасы.

### *Иске Кормаш авылы*

Бариев Илгизәр Бәшир улы (1964 елгы), агачны кисеп ясаучы.

### *Иске Сәфәр авылы*

Кыямова Флүза Кыям кызы (1953 елгы), чигүче.

Некрасова Гүзәлия Шәрипҗан кыэы (1956 елгы ), кәрзин үрү остасы.

Нуруллин Рушат Фирдәвес улы (1977 елгы) , агачны кисеп-уеп бизәү остасы

### *Иске Теләкәй авылы*

Вәгыйзова Резеда Вәсил кызы (1978 елгы), чигүче.

Хәертдинов Сәйдәр Сәлах улы (1965 елгы), кәрзин үрү остасы.

### *Кәзкәй авылы*

Гарипова Дифина Муллаян кызы (1953 елгы, тумышы белән Актаныш районы Иске Үрьяды авылыннан), бәйләү остасы.

Нәбиева Гөлүзә Гыймадилислам кызы (1955 елгы, тумышы белән Актаныш районы Бикчәнтәй авылыннан), челтәр бәйләү остасы.

Ялалов Рәлиф Тимерҗан улы (1966 елгы), агачка уеп рәсем ясаучы, кәрзин үрү остасы.

Ялалова Илсөяр Хәмдил кызы (1970 елгы, тумышы белән Актаныш районы Иске Әгъбәз авылыннан), бәйләү остасы.

### *Киров исемендәге совхоз*

Әмирова Вәсилә Мөхәммәтҗан кызы (1937 елгы), чигүче.

Баянова Мәүлия Шәрифулла кызы (1947 елгы), бәйләү остасы.

Гайнетдинова Гөлназ Навадир кызы (1985елгы), бәйләү остасы.

Гыйздуллин Илнар Мирдариф улы (1974 елгы), агачны кисеп-уеп бизәү остасы.

Давыдова Наилә Назиф кызы (1962 елгы), бәйләү остасы.

Латыйпова Сафия Тимер кызы (1943 елгы), чигүче.

Хәсәнова Гөлсинә Мирзасалих кызы (1937), бәйләү остасы.

### *Күҗәкә авылы*

Акмалова Гөлфия Гавис кызы (1949 елгы), чигүче.

Акмалова Нәзифә Шәйхелгали кызы (1937 елгы), чигүче.

Акмалова Шамилә Камал кызы (1958 елгы), чигүче.

Әнвәров Назыймбәк Әнвәр улы (1937 елгы), балта остасы, агачтан кисеп ясаучы.

Әшрапов Дилшат Кәшби улы (1948–1994), агачтан кисеп ясаучы.

Галимҗанов Нәһерлегаян Гыйльмигаян улы (1956 – 2019), умартачы, агачтан кисеп ясаучы, өй җиһазлары ясаучы.

Ганиева Гөлчира Шаһинур кызы (1952 елгы), бәйләү остасы.Тумышы белән Иске Әлем авылыннан



1 рәс. Аучы сумкасы. Юкә кабыгы. Кулдан үрү. Татар Суксуы



2 рәс. Киле. Агач. Зөбәер.



3 рәс. Кулдан эшләнгән тимер әйберләр. Пучы



4 рәс. Тегермән ташы. Актаныш



5 рәс. Тарткы.
Хатыйп Нәфыйков эше. Түке



6 рәс. Чалма савыты.
Такталачык



7 рәс. Балалар өчен чытыр урындык. Такталачык



8 рәс. Кулдан ясалган гармун. И.Ялалов эше. Илчебай



9 рәс. Чана. Актаныш



10 рәс. Сандык. Әнәк

11 рәс. Сандык. Актаныш




12 рәс. Бала арбасы. Такталачык





13 рәс. Балчык чүлмәк. Түке.



14 рәс. Балчык чүлмәк.
Б.э.к. 2 меңенче ел урталары. Түке



15 рәс. Балчык чүлмәк.
Такталачык



16 рәс. Балчык чүлмәк.
XVIII–XIX гасырлар. Пучы

17 рәс. Кылыч. Тимер, сөяк. Такталачык





18 рәс. Чаршау. Чәмчәләп (чуптарлап) тукылган. Кафия Фатыйхова эше. Актаныш



19 рәс. Чаршау. Төрле төсле җепләрдән тукылган. Зөбәер



20 рәс. Өстәл җәймәсе. Төрле төсле җепләрдән тукылган. Зөбәер



21 рәс. Мәҗлесләрдә алга җәелә торган тастымал фрагменты. Татар Суксуы

22 рәс. Сәке җәймәсе. Сания Гафурова эше. Күҗәкә



23 рәс. Тастымал. Төрле төсле җепләрдән тукылган. Зөбәер





24 рәс. Букча.
Чуарлап тукылган. Актаныш



25 рәс. Сөлге. Җитен, мамык.
Чуптарлап тукылган. Зөбәер



26 рәс. Акча янчыгы. Такталачык

27 рәс. Сөлге. Җитен, мамык, йон.
Чуптарлап тукылган. Зөбәер



28 рәс. Ыштан. Җитен. Такталачык





29 рәс. Сөлге. Чуптарлап тукылган. Такталачык



30 рәс. Сөлге башы. Шәмсебану Мөхәммәтшина эше. Күҗәкә

31 рәс. Сөлге башы. К. Х. Ганиева эше. Түке



32 рәс. Сөлге башы. Ялганмалы һәм түшәлмә ысул. Зөбәер



33 рәс. Сөлге. Чуптарлап тукылган. Пучы





34 рәс. Палас. Актаныш.



35 рәс. Палас. Йон.
Хәерниса Хуҗина эше. Күҗәкә



36 рәс. Келәм. Тоташтан чигелгән.
Зөбәер

37 рәс. Келәм (чүпләмле гобелен).
Зәмфирә Мөхәммәтова эше. Күҗәкә



38 рәс. Келәм. Тоташтан чигелгән.
Зөбәер





39 рәс. Сөлге. Киҗе-мамык тукыма. Тамбурлы чигү, аппликация, мулинә. Зөбәер



40 рәс. Сөлге. Киҗе-мамык тукыма. Тамбурлы чигү, аппликация, мулинә. Зөбәер

41 рәс. Кашага фрагменты. Сатин. Тамбурлы чигү. Ракыя Нәсыйпова эше. Түке



42 рәс. Сөлге башы. Сатин. Тамбурлы чигү. Зөбәер






43–44 рәс. Намазлык һәм намазлык фрагменты. Ике иңле киҗе-мамык тукыма. Йон җепләр белән тамбурлы чигү. Актаныш

45 рәс. Сөлге башы. Гөлчирә Ямалетдинова эше. Зөбәер

46 рәс. Сөлге башы. Тамбурлы чигү, йон һәм киҗе-мамык җепләр. Зөбәер






47 рәс. Ишек пәрдәсе һәм аның фрагменты. Тоташлап чигелгән



48 рәс. Панно. Мулинә белән тоташтан чигелгән



50 рәс. Карават чаршавы. Тапкырлап чигү



49 рәс. Карават япмасы

51 рәс. Мендәр тышлары



Рәвидә Гыйльметдинова эшләре. Түке



52 рәс. Диван япмасы. Хөллия Локманова эше. Түке

53 рәс.
Мендәр тышлары.
Тоташ чигү.
Гакифә
Габделзәкиева эше.
Түке



54 рәс. Диван япмасы. Тоташ чигү.
Рауза Зәйнетдинова эше. Зөбәер





55 рәс. Панно. Сабаксыман ысул белән тоташ чигү. Әнисә Сәлахова эше. Күҗәкә



56 рәс. Карават өчен чигүле җәймә фрагменты. Сатин. Шома, сабаксыман чигү. Зөбәер
.



57 рәс. Панно.
Хөллия Локманова эше. Түке



58 рәс. Өстәл өчен чигүле җәймә. Киҗе-мамык тукыма, мулинә. Шома, сабаксыман чигү. Гөлрәйхан Солтанова эше. Түке

59 рәс. Кулъяулык.
Сабаксыман ысул белән тоташ чигү.
Зәмфира Мөхәммәтова эше. Күҗәкә



60 рәс. Өстәл өчен челтәрле җәймә фрагменты. Шома, сабаксыман чигү. Гөлрәйхан Солтанова эше. Түке





61 рәс. Сөлге башы. Тапкырлап чигү. Нәфисә Кәримова эше. Түке



62 рәс. Сөлге башы. Тапкырлап чигү. Хөллия Локманова эше. Түке



63 рәс. Сөлге башы. Тапкырлап чигү. Нәфисә Кәримова эше. Түке



64 рәс. Сөлге башы. Тапкырлап чигү. Нәфисә Кәримова эше. Түке



65 рәс. Сөлге башы. Тапкырлап чигү. Хөллия Локманова эше. Түке



66 рәс. Сөлге башы. Тапкырлап чигү. Мәрзия Ганиева эше. Зөбәер



67 рәс. Күкрәкчә. Киҗе-мамык тукымадан. Зөбәер



68 рәс. Күкрәкчә. Киҗе-мамык тукымадан. Зөбәер



69 рәс. Күкрәкчә. Киҗе-мамык тукымадан. Зөбәер



70 рәс. Күкрәкчә. Киҗе-мамык тукымадан. Зөбәер



71 рәс. Күкрәкчә. Тамбурлы чигү. Нәфисә Кәримова эше. Түке



72 рәс. Күкрәкчә. Киҗе-мамык. Тоташ, тамбурлы чигү. Актаныш

73 рәс. Күкрәкчә. Тамбурлы чигү. Татар Суксуы авылы



74 рәс. Хатын-кыз күлмәге. Сәһира Газизуллина эше. Түке





75 рәс. Кулдан тегелгән күлмәк һәм чигүле алъяпкыч кигән ханым. Зөбәер



а

76 а, б, в рәс. Розалия Хамматуллина әнисе теккән күлмәкләрдән һәм чигүле алъяпкычтан. Штапель, киҗе-мамык (1950 нче еллар)

б



в





77 рәс. Рәвидә Гыйльметдинова теккән туй күлмәге. Штапель, тамбурлы чигү. (1960 ел). Түке



78 рәс.  Алъяпкыч. Сатин. Тамбурлы чигү. Рәвидә Гыйльметдинова эше. Түке



79 рәс. Ирләр күлмәгенең бизәлеш фрагменты. 1950 нче еллар





80 рәс. Кара алъяпкыч һәм аның фрагменты. Сатин. Тамбурлы чигү



81 рәс. Милли кием кигән ир-ат. Аяк чолгавы – тамбурлы чигүле. Актаныш музее



82 рәс. Кесә чигелеше фрагменты. Тапкырлап чигү



83 рәс. Камзул. Бәрхет. Велюр кайма белән. Актаныш

84 рәс. Ирләр күлмәге. Сатин. Тапкырлап чигү. Актаныш



85 рәс. Камзул. Бәрхет. Тамбурлы чигү. Зөбәер







87 рәс. Түбәтәй. Бәрхет.
Укалап чигелгән. Зөбәер

86 рәс. Хатын-кыз костюмы: күлмәк, камзул, калфак. Сәйлән белән тамбурлы чигү. Актаныш



88 рәс. Кызлар өчен күлмәк, алъяпкыч, яулык. Алъяпкыч фрагменты. Тапкырлап чигү





89 рәс. Татар өе бизәлеше.
Шәрип Шәймиев йорты. Әнәк



90 рәс. Татар өе бизәлеше.
Рифкать Солтанов йорты. Түке

91 рәс. Татар өе бизәлеше.
Шәрип Шәймиев йорты. Әнәк





92 рәс. Ракыя Нәсыйпова өе бизәлеше. Түке



94 рәс. Чигүле җәймә.
Хөллия Локманова йорты. Түке

96 рәс. Сәһира Газизуллина йорты. Түке





93 рәс. Хөллия Локманова өе бизәлеше. Түке

95 рәс. Бизәлгән мич.
Сәһира Газизуллина йорты. Түке





97 рәс. Шәрип Шәймиев йорты. Әнәк



98 рәс. Мөгылтдин бабай йорты. XX гасыр башы



99 рәс. Тәрәзә рамы



100 рәс. Тәрәзә рамы. Зөбәер.

101 рәс. Нәсих Солтанов йорты. Түке



102 рәс. Тәрәзә рамы. Пучы





103 рәс. Локманова Хөллия Локман кызы. Түке

104 рәс. Шәйхеразыева Шәргыя Әүхәди кызы. Пучы



105 рәс. Солтанов Рифкать Бәхтигәрәй улы. Түке





106 рәс. Мәвлиева Хәдичә Салих кызы. Түке

107 рәс. Гомәрова Халидә Әбрар кызы. Күҗәкә



108 рәс. Мөхәмматова Зәмфира Тимершәех кызы. Күҗәкә







110 рәс. Газизуллина Саһира Тимершәех кызы. Түке

109 рәс. Әхмәтшина Сәмәрә Мирзаян кызы. Такталачык

111 рәс. Гыйләҗева Сәхия Ханнан кызы (Күҗәкә) һәм Солтанова Гөлрәйхан Әгъләм кызы (Түке)





112 рәс. Шәмаил. Пыяла, буяу, тушь, фольга. 51×33 см. 1960 ел. Рифкать Фатыйхов эше



113 рәс. Шәмаил. Пыяла, буяу, тушь, фольга, 40×30 см. Нәкыя Шәймиева эше. Зөбәер



114 рәс. Шәмаил. Пыяла, буяу, тушь, фольга, 24×34 см. Х.Т. Тимеров йортыннан. Түке



115 рәс. Шәмаил. Пыяла, буяу, тушь, фольга, 45×45 см. Галиәсгар Солтанов өендә. Мәчти



116 рәс. Шәмаил. Пыяла, буяу, тушь, фольга, 27×38 см. Зөбәер



117 рәс. Чәмчәләп һәм сайланма нәкышләр белән тукылган сөлге (ош вынереш нолтен куымо). 1950 нче еллар



118 рәс. Җитен сүсеннән тукылган сөлге (шурго шовычо). Шәмсебанат Мөхәммәтшина эше



119 рәс. Алъяпкыч (ончыласакыш)

117–134 рәсемнәрдә: Мари Суксуы авылы осталарының кул эшләре



а

б





в

120 рәс.
а, б – чәмчәләп һәм бизәкләп тукылган сөлге.
Балкыя Абдуллина эше.
в – сөлге.
Гөлдихан Абышева эше



121 рәс. Хатын-кыз киемнәре (күлмәк, алъяпкыч, баш яулыгы). XX гасыр уртасы



122 рәс. Кыз балалар өчен концерт күлмәге (йоча тувыр). XX гасыр ахыры



123 рәс. Гадәти тегелешле ирләр күлмәге (поръен тувыр). XX гасыр ахыры



124 рәс. Кыз балалар өчен концерт күлмәге (йоча тувыр).
XX гасыр ахыры



125 рәс. Концерт костюмы (удырамаш тувыр)



126 рәс. Киҗе-мамык тукымадан тегелгән гадәти күлмәк



а



в



г



б



д

127 рәс. Кулдан сугылган чуар тукымалар.
а – төрле төстәге җепләрдән буй-буй итеп (корман вынер);
б, в – шакмаклар белән (шакмакла вынер);
г, д – чәмчәләп туку (нолтымо вынер) техникасы



128 рәс. Сөлге фрагменты



129 рәс. Чәмчәләп һәм сайланма нәкышләр белән тукылган сөлге (ош вынереш нолтен куымо). Гөлшикәр Әхмәрова эше. 1950 еллар

130 рәс. Җитен сүсеннән тукылган сөлге (шурго шовычо)





131 рәс. Палас. Бизәкләп сугылган



132 рәс. Идән җәймәсе

133 рәс. Палас



134 рәс. Идән җәймәсе



Гафурова Сания Гафур кызы (1918–2002), чигүче.

Гафурова Дифинә Мостафа кызы (1940 елгы), чигүче.

Гомәрова Ләлә Фатыйх кызы (1941 елгы), чигүче.

Гомәрова Халидә Әбрар кызы (1955 елгы), чигүче. Тумышы белән Яңа Кормаш авылыннан

Гыйләҗева Сәхия Ханнан кызы (1934 елгы), тукучы, чигүче.

Гыйльметдинова Вафия Әзһәм кызы (1953 елгы), чигүче.

Гыйльметдинова Гөлнаҗия Мөнәвәр кызы (1973 елгы), чигүче.

Зарипов Хатыйп Зарип улы (1918–1997), кәрзин үрү остасы.

Ихсанова Латыйфа Әшрафҗан кызы (1885–1987), тукучы, Х. Ә. Гомәрованың әбисе, тумышы белән Татар Суыксуы авылыннан.

Кашбразиева Сания Габидулла кызы (1925–2015), чигүче.

Маликова Фәндәлия Нургали кызы (1953 елгы), чигүче.

Мөхәммәтова Гыйльмиҗамал Габделкәрим кызы (1908–1987), тукучы, З. Т. Мөхәммәтованың әнисе.

Мөхәммәтова Зәмфирә Тимершәех кызы (1937 елгы), чигүче. Тумышы белән Үръяды авылыннан.

Мөхәммәтшина Шәмсебану Мөхәммәтша кызы (1887–1982), тукучы. Тумышы белән Адай авылыннан.

Мусин Назыйф Муса улы (1933–1999), өй җиһазлары ясаучы.

Нурлыгаянова Әкълимә Муллахмәт кызы (1940 елгы), чигүче.

Нуруллина Газизҗамал Нурулла кызы (1914–2005), тукучы.

Сәлахова Әнисә Мирзашәрип кызы (1940 елгы), чигүче, челтәр бәйләү остасы.

Сәрвәрова Рисалә Сәрвәретдин кызы (1932 елгы), чигүче. Тумышы белән Күҗәкә авылыннан.

Сәхапова Сәвия Сәхап кызы (1931 елгы), тукучы.

Солтанов Әбелгас Солтанмәхмүт улы (1936 – 2011), балта остасы, агачтан кисеп ясаучы, балыкчы.

Ханнанова Шәмсемаһи Нәфыйк кызы (1898–1972), тукучы, С. Х. Гыйләҗеваның әнисе, тумышы белән Мөслим районының Исәнсеф авылыннан.

Хаҗиева Кадрия Әхмәтсафа кызы (1949 елгы), чигүче.

Хәйбиев Зәки Мөхәммммәтгазиз улы (1934 елгы), балта остасы, балыкчы, балык тоту өчен ятьмәләр һ. б. җайланмалар үрә.

Хәйретдинова Әлфия Абелгас кызы (1968 елгы), бәйләү остасы.

Фатыйхова Тахия Газиз кызы (1942 елгы), чигүче.

Шакиров Флүс Нурлыгаян улы (1964 елгы), балта остасы, агачтан кисеп ясаучы.

Шакирова Нәсимә Мулланур кызы (1966 елгы ), агачка, металлга, фарфорга бизәк төшерүче.

Шәйхелмәрданов Хөснулла Шәйхелмәрдан улы (1926–1994), балта остасы, калайчы (комганнар, хуҗалык кирәк-яраклары ясаган).

### *Мари Суыксуы авылы*

Абдуллина Балкыя Миңлебай кызы (1929 елгы), тукучы, чигүче һәм челтәр бәйләү остасы.

Абышева Гөлдихан Миңлебай кызы (1940 елгы), тукучы. Туку станогы аңа әнисе Дәүләтбикә Морзагали кызыннан (1911–1970) калган.

Айбашева Дәүләтбикә Морзагали кызы (1911–1970), тукучы.

Әхмәрова Гөлшикәр Ишембай кызы (1921–2003), тукучы.

### *Меңнәр авылы*

Галиева Илмира Авзалетдин кызы (1961 елгы), чигүче.

Мотавилова Рушания (1962 елгы), бәйләү остасы.

Шәрипова Рузалия Әгъләм кызы (1961), бәйләү остасы.

### *Мерәс авылы*

Ильясова Факия Галимәрдан кызы (1939 елгы), чигүче.

### *Михайловка авылы*

Исламов Динар Дилфат улы (1994 елгы), металл эшкәртү остасы.

### *Олы Имән авылы*

Баянова Мәдәния Гайнәм кызы (1943 елгы), бәйләү остасы.

Галимов Исхак Ибраһим улы (1975 елгы), агач эшкәртү остасы.

Җәмилова Гөлчира Гани кызы (1943 елгы) , бәйләү остасы.

Сабирова Нурия Фәрди кызы (1955 елгы), чигүче.

Сәлахова Рәмзия Габделхак кызы (1940 елгы), чигүче.

### *Пучы авылы*

Әгъләмов Фәнтимер Мирзахан улы (1961 елгы), балта остасы, агачтан кисеп ясаучы.

Галләмова Рузалия Муллахмәт кызы (1941 елгы), чигүче.

Исламова Зөлфирә Шәфыйк кызы (1941 елгы), чигүче.

Исхакова Зөлфирә Фазлетдин кызы (1969 елгы), чигүче, бәйләү остасы.

Камалов Фәнтимер Тимергали улы (1963 елгы), балта остасы.

Мөхетдинов Илфат Әнвәр улы (1967 елгы), балта остасы.

Мосавиров Мирсаяф (Мирсәй) Мосавир улы (1925–2004), балта остасы.

Разова Рәйсә Әмирхан кызы (1947 елгы), чигүче, бәйләү остасы, тегүче.

Шәйхеразиева Шәргыя Әүхәди кызы (1936 елгы), чигүче, бәйләү остасы.

Юнысова Эльмира Мажи кызы (1959 елгы), чигүче.

### *Табанлы Күл авылы*

Исламова Илүсә Мөдәррис кызы (1973 елгы), бәйләү остасы.

### *Такталачык авылы*

Ашимов Мирзаян Ашим улы (1883–1975), тимерче.

Әхмәтшина (Ашимова) Сәмәрә Мирзаян кызы (1926 елгы), чигүче, бәйләү остасы.

Габдрахманова Кифая Габдрахман кызы (1919–2009), тукучы.

Лотфуллина Кәримә Лотфулла кызы (1910–1993), тукучы.

Гыйльфанова Мәэмүнә Гыйльфанетдин кызы (1915–2000), чигүче.

### *Татар Суыксуы авылы*

Абышева Гөлҗиһан (1941 елгы), тукучы.

Габдрахманова Эльмира Г. (1974 елгы), челтәр үрү, бәйләү остасы.

Гайнетдинов Рушат Фәнил улы (1972 елгы), металл эшкәртү остасы.

Гыйльманова Закирә Әгълилулла кызы (1923–2007), тукучы.

Латыйпова Халисә Габдрахман кызы (1926 елгы), тукучы, чигүче.

Мөлекова Финҗия Шәмсемөхәммәт кызы (1923 елгы), челтәр бәйләүче, Р. В. Хуҗинаның әнисе.

Хафизетдинова Рәсимә Гайнетдин кызы (1933 елгы), тукучы, чигүче, челтәр бәйләү остасы.

Хәлиуллин Илмар Рәфис улы (1965 елгы), агачны кисеп-уеп бизәү остасы.

Хәсәнова Альбина Рифкать кызы (1951 елгы), чигүче.

Хуҗина Рәйханә Вәҗи кызы (1945 елгы), чигүче.

### *Түбән Гәрәй авылы*

Зарипов Айрат Гариф улы (1959 елгы), балта остасы, агачтан кисеп ясаучы.

### *Түке авылы*

Арысланова Миһерзадә Арыслангали кызы (1901–1970), тегүче. Тумышы белән Адай авылыннан.

Әмиров Аҗип Әмирулла улы (1932–1998), хуҗалык кирәк-яраклары үрүче.

Бәхтиев Газдалый Бәхтигәрәй улы (1930–1989), йорт җиһазлары ясау остасы.

Вәлиева Гөлнәһирә Габделвәли кызы (1930 –197 ).

Габделзәкиева Гакифә Габделзәки кызы (1927 елгы), чигүче.

Ганиев Гыйльмегали Габделгазиз улы (1930–1996), мич чыгару остасы.

Газизуллина Саһира Тимершәех кызы (1929 –2019), чигүче, умартачы.

Ганиева Кәримә Хуҗагали кызы (1903–1978), тукучы.

Ганиева Нәҗибә Мөнәвәртдин кызы (1940 елгы), чигүче.

Гыйльметдинова Рәвидә Әбелгасан кызы (1937 елгы), чигүче. Гильметдинова Бәния Сәлах кызы (10.01.1948) , бәйләү остасы. Тумышы белән Зөбәер авылыннан.

Дәүләтшина Оркыя Шәйхелислам кызы (1902–1985), тукучы, чигүче.

Кәримова Канифә Кәрим кызы (1947 елгы), чигүче. Тумышы белән Чәчер авылыннан.

Кәримова Нәфисә Кәрим кызы (1929–1974), чигүче, челтәр бәйләү остасы.

Локманова Хөллия Локман кызы (1941 елгы), чигүче. Тумышы белән Зөбәер авылыннан.

Мәвлиева Хәдичә Салих кызы (1936 елгы), киез итек басучы.

Миннәхмәтова (Ганиева) Мәрзия Вәгыйз кызы (1939 елгы), чигүче, челтәр бәйләү остасы.

Нәгыймова Хәмидә Нәгыйм кызы (1925–2010), чигүче.

Нәсыйпова Рабига Насыйфулла кызы (1925–1954), чигүче.

Нәсыйпова Ракыя Насыйфулла кызы (1926–1999), чигүче.

Нәфыйков Данил Хатыйп улы (1972 елгы), агачны кисеп бизәүче.

Нәфыйков Фәнис Хатыйп улы (1966 елгы), агачны кисеп бизәүче. Хәзерге көндә Чиләбе өлкәсенең Оша шәһәрендә яши.

Нәфыйков Хатыйп Нәфыйк улы (1937–2015), мебель ясаучы.

Нәфыйкова Равзалия Мәрдислам кызы (1947–2008), чигүче.

Низамов Галләм Минһаҗетдин улы (1925–2001), киез аяк киемнәре басу остасы.

Сабирова (Хәбибуллина) Зәнфирә Хайбрахман кызы (1965 елгы), чигүче, бәйләүче оста. Тумышы беләң Киров авылыннан.

Салихов Тимершәех Гариф улы (1925–1986), арбалар һәм чаналар ясау остасы.

Солтанов Рифкать Бәхтегәрәй улы (1934–2015), кәрзин үрү остасы, тире эшкәртүче, умартачы, аучы.

Солтанова Гөлрәйхан Әгъләм кызы (1936 елгы), чигүче, бәйләү остасы, тегүче.

Солтанова Мәмдүдә Фәйрүшә кызы (1904–1996), чигүче.

Тимеров Илназ Мирзагали улы (1974 елгы) – металл эшкәртү остасы.

Фазлыева Мөшәрәфә Фазлытдин кызы (1890–1979), тукучы.

Шәйхелисламова Гадимә Мөгылтдин кызы, тукучы.

Шәйхетдинова Сара Дәүләтбай кызы (1914–1994), тукучы. Гомере буе паласлар һәм сәке җәймәләре тукыган.

### *Уразай авылы*

Локманов Роберт Сәүбән улы (1939 елгы), кәрзин үрү остасы.

Саматова Кадрия Шәрип кызы (1938 елгы),чигүче, челтәр бәйләүче, бәйләү остасы.

### *Чалманарат авылы*

Әхмәтов Камил Сабирҗан улы (1963 елгы), агач эшкәртү остасы.

Камалетдинов Хәлил Гыйлфан улы (1970 елгы), тимерче.

Хуҗина Миләүшә Хәләф кызы (1974 елгы) , чигүче.

### *Чәчер авылы*

Мирсәетова Гөлсинә Муллагали кызы (1943 елгы), чигүче.

Муллагалиева Венера Вәли кызы (1950 елгы, Түкәй авылында туган), бәйләү остасы.

### *Чиру авылы*

Гыйлфанов Әкрам Гыйлфан улы (1930 елгы), агачны кисеп-уеп бизәү остасы.

Насыйрова Мәрфуга Абызгәрәй кызы (1913–1979), тукучы.

Хәйдәров Фәнил Хәйдәр улы (1942–2019), тире эшкәртү остасы.

Хәйдәрова Нәзира Фәүзетдин кызы (1945 елгы), чигүче.

### *Чөгәнә авылы*

Арысланова Алсу Илфәр кызы (1971 елгы), чигүче.

Солтанова Ләлә Илфәр кызы (1979 елгы), чигүче.

### *Чуракай авылы*

Бәдыйкова Мәрьям Зәбир кызы (1988 елгы), чигүче, бәйләү остасы.

Галимәрданова Зөмәрә Вәсим кызы (1964 елгы), челтәр бәйләү остасы.

Гаязов Зәйнгетдин Гаяз улы (1924 –1999), балта остасы, агачны кисеп-уеп бизәү остасы.

Зарипов Фәнис Зарип улы (1952 елгы), агачны кисеп-уеп бизәү остасы, тимерче.

Мөхәммәтдинова Фәния Биктимер кызы (1946 елгы), шәл бәйләүче.

Нәбиев Нәгыйм Әхмәтгали улы (1930 елгы), тимерче.

Шәйгарданова Нажия Шәйхелмәрдан кызы (1930–1998), шәл бәйләүче.

Шәймәрданов Мансур Шәймәрдан улы (1924–?), тимерче, тире иләү остасы, бүрек тегүче.

### *Чынык авылы*

Рәхимова Рәфия Исмәгыйль кызы (1936 елгы), чигүче, бәйләү остасы.

### *Шәрип авылы*

Сираева Зөбәрҗәт Вәсим кызы (1959 елгы), бәйләү остасы.

### *Югары Яхшый авылы*

Мусина Гөлчәчәк Ришат кызы (1977 елгы), тукучы.

Харрасов Әлфис Даут улы (1965 елгы), агачны кисеп-уеп бизәү остасы.

Хәсәнов Рәиф Сөләйман улы (1959 елгы), металл эшкәртү остасы.

Шәйхина Раушания Әнвәр кызы (1956 елгы), бәйләү остасы.

### *Яңа Әлем авылы*

Миннегалиев Марат Галинур улы (1976 елгы), металл эшкәртү остасы.

Сәрвәров Азат Рәшит улы (1973 елгы), металл эшкәртү остасы.

Шәрипов Хәлил Әсләх улы (1955 елгы), агачны кисеп-уеп бизәү остасы.

### *Яңа Җияш авылы*

Исламова Раилә Тимеркәй кызы, бәйләү остасы.

Шулбаева Роза Айдар кызы, чигүче.

### *Яңа Кормаш авылы*

Кашбразиев Азамат Әбрар улы (1965 елгы), агачтан кисеп ясаучы.

# МАРИ БИЗӘКЛӘРЕ

## Актаныш ягында яшәүче мариларның декоратив-гамәли сәнгате

*Лариса Илтубаева*

Этник тарихында катлаулы чорлар, вакыйгалар кичергән мари халкының еллар дәвамында үзенә генә хас мәдәнияте формалашкан. Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче мариларның декоратив-гамәли сәнгатен стиль һәм башкару алымнары ягыннан анализлау халык иҗатының үзенчәлекле йөзен ачыкларга ярдәм итә.

2009 елның июлендә Актаныш районына оештырылган фәнни экспедиция вакытында көнчыгыш төркемгә кергән марилар яши торган Мари Суыксуы (җирле халык аны *Йушта Памаш* дип йөртә) авылында шактый кызыклы материалларга юлыктык. Алар мәктәп музеенда һәм осталарның үзләрендә саклана. Музей экспонатлары белән танышудан тыш, җирле туку осталары Балкыя Миңлебай кызы Абдуллина (1929 елгы) һәм Гөлдихан Миңлебай кызы Абышева (1949 елгы) белән күрешеп сөйләштек.

Мариларның халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгате матди культура белән бәйле кул эшләрендә аеруча ачык чагылыш тапкан. Ул, кием һәм бизәнгечләрдә, нәкышьләп тукуда һәм чигүдә, торак йортларның архитектур бизәлешендә үзенчәлекле юнәлеш алып, безнең көннәргә хәтле сакланган.

Мари халкы тормышында тукучылык һәм чигү элек-электән аерым урын тоткан. Археологик материаллар чигү

орнаментлары һәм тукучылык нигезенең борынгы гореф-гадәтләргә барып тоташуын дәлилли[1]. Күп кенә кул эшләре һәм бизәү мотивлары, буыннан-буынга күчә барып, композицион алымнарның сакланып калуына ярдәм иткән. Декор үзенчәлекләре, теге яки бу бизәү мотивларына, нәкышь һәм техник алымнарга өстенлек бирү, этник төркемчәләргә бүленгән болын, тау, көнчыгыш һ. б. мариларның территориаль аерымлыклары һәм мәдәниятләре белән тыгыз бәйләнгән.

Археологик һәм фольклор материаллары тукучылыкның бик борынгы заманнардан ук мариларның төп кәсебе булуын күрсәтә. Кысасыз һәм арткы күшәсез, нигезе белән чәч толымы сыман таякка беркетелгән иң гади туку станогын *(марло кумо стан)* һәр йортта очратырга була[2]. Шуңа охшаш гади станнарны удмуртлар[3], мордвалар, татарлар да үзләренеке дип саныйлар. XIX–XX гасыр башында кысалы һәм арткы күшәсез (күшә урынына нигез җепләре толым рәвешендә беркетелгән таяк файдаланыла) туку станнары киң таралыш ала. Соңрак русларныкына охшаган рамлы һәм арткы күшәле стан файдаланыла башлый[4].

Төсле җепләрдән чуарлап һәм бизәкләп туку марилар арасында тигез таралыш алмаган. Идел буе болын һәм тау мариларыннан аермалы буларак, хәзерге Татарстан, Башкортстан җирлегендә, Пермь краенда һәм Свердловск өлкәсендә яшәүче көнчыгыш мариларда бу техника, татар, башкорт, удмуртлардагы кебек үк, элек-электән кулланыла. XIX гасырда һәм XX гасыр башында марилар бизәкләп тукуда киндер кулланганнар, соңрак аны җитен һәм мамык алыштырган. Бизәкләрне, гадәттә, йон җепләрдән эшләгәннәр[5]. Болын мариларында бу

---

[1] *Никитин В. В., Никитина Т. Б.* К истокам марийского искусства: Научное издание. – Йошкар-Ола: МарНИИЯЛИ, 2004. – С. 11.

[2] *Крюкова Т. А.* Материальная культура марийцев XIX в. – Йошкар-Ола, 1956. – С. 53.

[3] *Ефимова Л. В.* Ткани из финно-угорских могильников I тыс. н.э. // КСИА. – Т. 107. – М., 1966. – С. 134.

[4] *Молотова Т. Л.* Традиционное марийское ткачество: Монография. – Йошкар-Ола: МарНИИЯЛИ, 2004. – С. 57.

[5] *Меджитова Э. Д.* Марийское народное творчество. – Йошкар-Ола, 1985. – С. 17.

ысул киң таралмаган, ул фәкать йола һәм туй сөлгеләре бизәлешендә генә очрый. Мариларның төрле этник төркемнәрендә очрый торган сөлгеләрне болай бизәп туку принцибы мари хатын-кызларының гадәти баш киеме – *«шарпан»*ны чигеп эшләү элементларын хәтерләтә.

Бизәкләп тукуның бер формасы чәмчәләп тукудан гыйбарәт. Бу ысул көнчыгыш мариларда аеруча зур таралыш алган. Чәмчәләп тукыганда бизәкнең аркау җебе тукыманың бөтен киңлеге буенча (аның әле уң ягыннан нәкышьләп, әле тискәре ягыннан шул нәкышьнең негатив сурәтен чагылдырып) бара. Шулай тигез чиратлашып урнашкан геометрик фигуралар орнаменты барлыкка килә. Чәмчәләп тукуда бер үк бизәкне рәсем дип тә, төп фон дип тә кабул итәргә мөмкин. Бу очракта әйбернең уң ягын тискәре ягыннан аерып булмый.

Мари Суыксуы авылында әлегә хәтле мариларның бизәкләп туку традицияләрен дәвам итүче осталар яши. Балкыя Миңлебай кызы Абдуллина тарафыннан чәмчәләп һәм бизәкләп тукылган сөлге ыргаклы энә белән бәйләнгән челтәр катнаштырып эшләнгән (120 рәс.: а, б). Тукучылыкның моңа охшаш үрнәген шул ук авылда яшәүче Гөлдихан Миңлебай кызы Абышева суккан сөлгедә дә күрергә мөмкин (120 рәс.: в). XX гасырның 50 нче елларында чәмчәләп һәм сайланма нәкышьләр белән тукылган *(ош вынереш нолтен куымо)* сөлге үрнәге Мари Суыксуы авылы мәктәбе музеенда да саклана (129 рәс.). Аның авторы – Гөлшикәр Ишембай кызы Әхмәрова (1921–2003). Әлеге зур сөлге өй шартларында агартылган җитен сүсеннән тукылган. Аның баш-башларына кызыл, куе зәңгәр, ачык яшел, сары йон җепләр белән бизәкләп сугылган тукыма ялганган. XX гасырның икенче яртысында тукылган бу сөлгенең үлчәме – 39×224 см (129 рәс.). Кызыл аркау җебеннән эшләнгән орнаментлар сөлгенең ике башында да кабатлана.

Музейда бу останың башка эшләре дә бар. Аларның берсе – катнаш ысуллар[1] белән кызыл, куе зәңгәр, ачык яшел, сары, ал,

[1] Бу техника көнчыгыш мариларга һәм Идел–Урал буенда яшәүче башка халыкларга (шул исәптән татарлар белән удмуртларга) да хас. Ул Актаныш төбәгендә шактый киң таралган.

соры, зәңгәрсу һәм кызгылт-сары йон җепләрдән бизәкләр төшереп, җитен сүсеннән өй шартларында тукылган 39×224 см зурлыктагы сөлге (*шурго шовычо* – 130 рәс.). Икенчесе – җитен сүсе җебен агартып, кызыл, чия төсле, зөбәрҗәт-яшел, сары, ал, куе соры, куе ал, ачык ал һәм кара төсләрдәге йон җепләре белән сайланма нәкышьләр төшереп *(ош вынереш нолтен куымо)* сугылган (сатып алынган кәрәзсыман киҗе-мамык тукыманың баш-башларына тегелгән) сөлге. XX гасырның икенче яртысында эшләнгән бу сөлгенең үлчәме – 40×254 см (117 рәс.).

Моннан тыш, мәктәп музеенда мари халкы сәнгате традицияләрендә эшләнгән түбәндәге экспонатлар бар:

– XX гасырның икенче яртысында эшләнгән, башы бизәкләп тукылган сөлге фрагменты. Ул җитен сүсенең өй шартларында эрләнеп агартылган җебеннән, кызыл, ачык яшел, сары, ал, куе соры, күк төсле, ачык шәмәхә төстәге киҗе-мамык җепләрдән сайланма нәкышьләр төшереп сугылган. Үлчәме – 60×46 см, авторы билгесез (128 рәс.).

– XX гасырның икенче яртысында җирле оста Шәмсебанат Мөхәммәтша кызы Мөхәммәтшина (1887 елда туган) иҗат иткән сөлге *(шурго шовычо)*. Ул җитен сүсе җебеннән өй шартларында тукылган; кызыл, куе зәңгәр төсләрдәге киҗе-мамык җепләрдән сайланма нәкышьләр белән бизәлгән; сөлгенең баш-башлары өчен эшләнгән бизәкле өлешен әз генә беленеп торган мережка тасмасы аерып тора. Сөлгенең үлчәме – 39×234 см (118 рәс.).

Мари халкының мәдәнияте, дөньяга карашы һәм матурлык турындагы күзаллаулары аларның милли киемнәрендә ачык чагыла. Көндәлек киемнәр (ир-атларныкы да, хатын-кызларныкы да), нигездә, өй шартларында эшләнгән, һәм күлмәк, ыштан, кафтан, билбау, баш киеме, аяк киеменнән гыйбарәт булган. Хатын-кыз киеме үзенең бизәлеше белән аерылып торган. Өс һәм аяк киемнәренә нигез итеп киндер һәм җитен сүсе җепләреннән сугылган тукыма, өйдә эшләнгән постау яки ярымпостау алынган.

Гадәти эчке күлмәк *(тувыр)* туникасыман итеп тегелә. Икегә бөкләнгән тукыма күлмәкнең алдын һәм арка өлешен тәшкил итә, аңа турыпочмаклап җиңнәр (җиң астына, аның озынлыгы-

на туры китереп, буйлап киселгән дүртпочмаклы тукыма өстәп тегелгән була) беркетелә[1]. Борынгы ирләр күлмәге дә шушы рәвешле тегелгән, тик бераз кыскарак булган.

Функциясе буенча мари киеме көндәлекнекенә, бәйрәмнекенә һәм йолалар вакытында киелә торганга аерыла. Күпчелек киемнәрдә ак һәм кызыл төсләр өстенлек итә.

Гадәттә, күлмәктәге һәр детальнең читләре каймалап чигелә. Чигүләр яка, түш уемы, арка, җиң кайтармасы һәм итәк очларына урнаштырыла. Чигелеш урыннарын билгеләү беренче чиратта халыкның борынгы күзаллаулары белән бәйле. Әйтик, яшәү өчен аеруча мөһим әгъза-органнар урнашкан урыннар явыз көчләрдән һәм күз тиюдән сакланырга тиеш булган.

Мариларның чигү үрнәкләрендә өч төрле орнамент очрый: геометрик фигуралар, үсемлек һәм хайван рәсемнәре. Чигү бизәкләрендә үзләре табына торган тотем хайваннар яки кошлар (үрдәк, болан, поши, яисә болан мөгезе), «яшәү агачы» («древо жизни»), сигез кырлы геометрик фигура сурәтләнә. Орнаментларның композициясе һәм урнашу принцибы бизәлә торган әйбернең формасына, үлчәменә һәм максатына буйсындырыла. Чигү бизәгенә, фин-угор халыклары үрнәкләреннән тыш, рус чигелешенә хас җөйләп чигү ысулы да йогынты ясый[2]. Киемгә бизәк төшерү кешенең яше, җенесе һәм социаль үзенчәлекләреннән чыгып башкарылган.

Мариларның чигү үрнәкләрендәге төсләр гаммасына күз салсак, аларның аерым төсләргә өстенлек бирүләрен күрербез. Мисал өчен, төп рәсем кызыл җеп белән чигелгән, аның контуры кара яки куе зәңгәр (карга күзе төсе – *корак шинча*) җеп белән йөртелгән[3].

Элек җепләрне өй шартларында табигый буяуларга манганнар. XIX гасыр ахырында, анилин буяулар барлыкка килгәч,

---

[1] *Молотова Т. Л.* Марийский народный костюм. – Йошкар-Ола: Марийское кн. изд-во, 1992. – С. 48.

[2] *Соловьева Г. И.* Декоративно-прикладное искусство марийцев (конец XVIII – начало XX в.) // Историко-культурный комплекс Республики Мари Эл. – Йошкар-Ола: МарНИИЯЛИ, 1994. – С. 39.

[3] *Соловьева Г. И.* Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 40.

төсләрнең гаммасы үзгәрә: гадәти чигелеш төсләренә хас булмаган ачык кызыл, куе алсу, ал, ачык зәңгәр, шәмәхә, ультрамарин, аксыл шәмәхә, ачык сары, зөбәрҗәт-яшел һәм башка төсләр кулланыла башлый[1].

XIX гасыр урталарында көнчыгыш мариларда фабрикада эшләнгән әзер тукыма куллану, әзер җепләрдән чуарлап туку тарала. XIX гасыр азагында инде алар киемнәрен күптөсле җепләрдән сугылган тукымадан тегә башлыйлар. Гадәти күлмәкләр дә үзгәреш кичерә: башта ак күлмәккә чуар җиң тегеп кияләр, тора-бара күлмәкне тоташы белән чуар тукымадан тегә башлыйлар. Чигелгән чуар киемне башка төстәге тукыма кисәкләре, тасма, тәңкә, сәйләннәр белән бизиләр. Чигү вагая төшә, орнаментлары чәмчәләп туку бизәкләренә охшый бара. Йолалар үткәндә ак кием кию дәвам итә.

Рус киемнәре йогынтысында ирләр кияме бик нык үзгәреш кичерә. Шулай да XX гасыр урталарына кадәр мари киемендәге үзенчәлекле сыйфатлар саклана әле. Бу, нигездә, тегелеш, бизәлеш, киемдәге теге яки бу элементларны тагып йөрүдә чагыла.

Мари Суыксуы мәктәп музеенда мариларның ирләр күлмәге үрнәкләре саклана. Аларның берсе – XX гасыр урталарында җитен сүсе җебеннән сугылган тукымага кызыл һәм кара төстәге киҗе-мамык җепләр белән чигеп бизәлгән, гадәти тегелешле ирләр күлмәге *(порьен тувыр)* (123 рәс.). Икенчесе – киҗе-мамык тукымадан тегелгән гадәти күлмәк, аның якасы, итәге һәм җиңнәре башка төрле тукыма белән бизәкләп чигүгә охшатып эшләнгән. Күлмәкнең монысы XX гасырның ахырына карый (126 рәс.).

Көнчыгыш мариларның хатын-кыз күлмәкләре гадәти сыйфатларын озаграк саклаган. Аларны әле XX гасыр урталарында да кигәннәр (әлбәттә, күпмедер үзгәреш кичергән хәлдә: әйтик, ак постауны чуар тукыма алыштырган һ. б.). Мариларның туникасыман тегелгән күлмәкләре, күрше (татар, башкорт) халыкларныкына охшатып, киң итәклегә әйләнә. Тора-бара чигүне

[1] *Крюкова Т. А.* Марийская вышивка. – Л., 1951. – С. 124–145.

тукыма бизәкләр, бөрмәләр, төсле тасмалар белән матурлау алыштыра[1]. Көнчыгыш мари хатын-кызларының гадәти баш киемнәре *«шымакшу»*га алмашка XX гасыр уртасыннан фабрикада эшләнгән яулыклар килә.

Мари Суыксуы авылы мәктәбе музеенда хатын-кыз киемнәренең берничә үрнәге саклана:

– XX гасыр ахырына караган концерт костюмы (күлмәк, билбау). Бу күлмәк *(удырамаш тувыр)* фабрикада тукылган киҗе-мамык тукымадан тегелгән; түше, итәк, җиң очлары кызгылт-сары, кызыл, зәңгәрсу, ак төстәге атлас тасмалар, ак челтәр һәм ачык зәңгәрсу төстәге тар киҗе-мамык тукымага төшерелгән тишекле бизәкләрне үз төсендәге җеп белән чигеп эшләнгән кайма ярдәмендә бизәлгән; билбавы киҗе-мамык тукымадан тегелеп, сатып алынган зиактан бизәкле өстәмәләр куеп эшләнгән.

– XX гасыр ахырына караган концерт костюмы (күлмәк, билбау). Хатын-кызлар өчен тегелгән бу күлмәк *(удырамаш тувыр)* фабрика киҗе-мамык тукымасыннан тегелгән; түше, итәк, җиң очлары мулинә җепләрдән тоташ ысул белән чигелгән, шулай ук кызгылт-сары, яшел, зәңгәрсу атлас тасмалар, фабрика тукымасыннан өстәмәләр һәм сатып алынган ак челтәр (киҗе-мамык) белән бизәлгән; билбавы фабрикада эрләнгән кызыл төстәге җептән эшләнгән (125 рәс.).

– Кыз балалар өчен тегелгән концерт күлмәге. XX гасыр ахырына карый. Күлмәк *(йоча тувыр)* фабрикада эшләнгән киҗе-мамык тукымадан тегелгән; түше, итәк, җиң очлары төсле җепләрдән тоташ ысул белән чигелгән, шулай ук кызыл төстәге атлас тукымадан өстәмәләр һәм сатып алынган ак челтәр (киҗе-мамык) белән бизәлгән (122 рәс.).

– Кыз балалар өчен тегелгән концерт күлмәге. XX гасыр ахырына карый. Күлмәк фабрикада эшләнгән киҗе-мамык тукымадан тегелгән; түше, итәк, җиң очлары төсле җепләрдән тоташ ысул белән чигелгән; кызгылт-сары, сары, ал, зәңгәрсу

---

[1] *Мухамедова Р. Г.* Татарская народная одежда. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1997. – С. 131.

төсләрдәге атлас тасмалар, кызыл төстәге атлас тукымадан өстәмәләр һәм ак челтәр белән бизәлгән (124 рәс.).

– Кыз балалар өчен тегелгән концерт күлмәге. XX гасыр ахырына карый. Күлмәк фабрикада эшләнгән киҗе-мамык тукымадан тегелгән; түше, итәк, җиң очлары кызгылт-сары, сары, ал, зәңгәрсу төсләрдәге атлас тасмалар, кызыл, зәңгәр төстәге зиак (тесьма) һәм кызыл тукымадан өстәмәләр белән бизәлгән.

Көнчыгыш мариларның XX гасыр урталарында кулланышта булган хатын-кыз киемнәре (күлмәк, алъяпкыч, баш яулыгы) зур кызыксыну тудыра. Алар хәзер концерт костюмы буларак кына файдаланыла (121 рәс.). Бу киемнәр түбәндәге детальләрдән торалар:

– алъяпкыч *(ончыласакыш)* агартылган җитен тукымадан (бизәкләп туку ысулы белән) эшләнгән; кызыл, зөбәрҗәт-яшел, сары, ал, шәмәхә, зәңгәрсу төсләрдәге йон җепләр белән бизәлгән; алъяпкыч бавы кызыл төстәге киҗе-мамык тукымадан (фабрика тукымасыннан) эшләнгән; гомуми зурлыгы – 45×61 см (119 рәс.);

– көнчыгыш мариларда киң таралган туникасыман тегелешле күлмәк *(тувыр)* кулдан сугылган чуар тукымадан *(олача вынер, кезе вынер)* эшләнгән. Алар төрле төстәге җепләрдән буйбуй итеп *(корман вынер)* (127 рәс., а), шакмаклар белән *(шакмакла вынер)* (127 рәс.: б, в), чәмчәләп туку *(нолтымо вынер)* техникасы буенча сугылганнар (127 рәс.: г, д).

– фабрикада эшләнгән йон яулык та XX гасыр ахырына карый;

– чуарлап сугылган тукыма, фабрика тукымасы һәм челтәрдән киселгән тасма куе зәңгәр буйлы көрән төстәге нигез тукымага ялгап куелган.

Көнчыгыш марилар кием теккәндә кулдан сугылган чуар тукыманы аеруча яратып кулланганнар. Элек-электән төп нигезгә сары, ак, зәңгәрсу, кара, яшел, көрән җепләрдән вак буйлар төшерелгән тукымаларны үз иткәннәр. Татарлар да шуңа охшаш күп төсле тукымадан халат, күлмәк, ыштан теккәннәр (алар тукыманың буйларын киңрәк итеп,

ак-кызыл, кызыл-зәңгәр, кызыл-кара һ. б. төсләргә өстенлек биргәннәр)[1].

Көнчыгыш марилар шакмаклап сугылган тукымадан ирләр күлмәге дә, хатын-кызлар күлмәге дә теккәннәр. Андый материалны татарлар, төньяк чувашлар һәм удмуртлар[2] да файдаланган. Төрле милләт халыкларының үзара аралашып гомер кичерүе нәтиҗәсендә Башкортстанның күп кенә районнарында, Татарстанның көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгышында, аерым алганда, Актаныш һәм Мамадыш якларында яшәүчеләрнең киемнәрендә уртаклык барлыкка килгән. Көнчыгыш мариларның гадәти киемнәрен Идел һәм Урал буйларында яшәүче халыкларныкы белән чагыштырып карау удмурт, татар, башкорт, мордва, чувашларның киемнәрендә мондый охшаш сыйфатларның күп булуын раслый.

Чуар материалдан марилар, кием генә түгел, мендәр-ястык тышлыклары *(тушак умбал),* пәрдәләр *(чаршау),* эскәтерләр *(устембал шовыч)* кебек көндәлек куллану әйберләре дә теккәннәр. Музейда XX гасырның икенче яртысына караган шундый түшәк тышлыгы саклана; ул ак, кызыл, сары, зәңгәрсу, куе зәңгәр һәм кара төстәге җепләрдән чуарлап тукылган, зурлыгы – 127×118 см.

Көнчыгыш марилар, шул төбәктә яшәүче татарлар, башкортлар һәм удмуртлар кебек, калын җепләрне үсемлекләрдән ясалган табигый буяуларга манып, бик матур идән җәймәләре тукыйлар[3]. Аның җебе, нигездә, киҗе-мамыктан яки йоннан була. Мондый палас, идән җәймәләре ал, кызгылт-сары, яшел һәм кызыл төсле җепләрдән аркылыга буй-буй итеп яки ромб рәвешендәге төрле орнаментлар белән бизәкләп сугыла (131–134 рәс.).

---

[1] *Сафина Ф. Ш.* Ткачество татар Поволжья и Урала: Историко-этнографический атлас татарского народа. – Казань, 1996. – С. 77.

[2] *Климов К. М.* Удмуртское народное творчество. – Ижевск, 1979. – С. 18.

[3] *Валеева-Сулейманова Г. Ф.* Декоративное искусство Татарстана: монография. – Казань, 1995. – С. 81–86.

Бизәкләп тукуда һәм милли киемнәр әзерләүдә көнчыгыш марилар, үзләренең мари (фин-угор) культурасыннан тыш, татар-башкорт (төрки) компонентларыннан да файдаланалар.

Көнчыгыш мариларның традицион тукучылыгы, аеруча чуарлап һәм бизәкләп туку (шул исәптән келәм туку) үзенчәлекләре әлегә кадәр ныклап өйрәнелмәгән. Галимнәрдән бу өлкәдә гаять киң тикшеренү эшләре алып бару сорала[1]. Кызганыч, XX гасырның 60–70 нче елларыннан көнчыгыш мариларның өй шартларындагы кәсепчелегеннән саналган бизәкләп туку үрнәкләре әкренләп юкка чыга бара. Бу, бер яктан, көнкүрешкә сәнәгать эшләнмәләре күпләп керү белән бәйле булса, икенчедән, хәзер авылларда туку эшләре өчен чимал – җитен, киндер үстерелми. Тагын шуны да билгеләп үтәргә кирәк: мариларның өй шартларындагы тукучылыгы йолалар, гореф-гадәтләр уздыруның төрле формалары белән тыгыз бәйләнгән. Мәсәлән, өйдә бизәкләп суккан сөлге һәм тукымалар туй, бала туу һәм мәет күмү йолалары вакытында, авыл хуҗалыгы белән бәйле бәйрәмнәрдә, дини гыйбадәтләр кылганда һ. б. да файдаланыла. Йола-гадәтләрнең көндәлек тормыштан китә баруы алар өчен әзерләнә торган әйберләргә ихтыяҗны да киметә. Шуңа күрә Мари Суыксуы авылындагы борынгыдан сакланып килгән күркәм сәнгать үрнәкләрен дәвам итүче осталар – Балкыя Миңлебай кызы һәм Гөлдихан Миңлебай кызының тукучылык хезмәте бүген тагын да югарырак бәяләнә.

[1] *Молотова Т. Л.* Традиционное марийское ткачество: Монография. – Йошкар-Ола: МарНИИЯЛИ, 2004. – С. 9.

## БОРЫНГЫ ДА, МОҢЛЫ ДА

**Музыкаль фольклор традицияләре**

*Эльмира Каюмова*

Халык музыка үрнәкләрен туплау һәм өйрәнү максатыннан Актаныш, Минзәлә һәм Мөслим районнарына 2004 елның 11–21 июнь көннәрендә кылган сәяхәтебездә 9 авылда – Зөбәер, Түке (Актаныш районы), Тауасты Байлар, Дәвек, Урус, Тулбай, Татар Мөшеге, Рус Мөшеге (Минзәлә районы), Исәнсефтә (Мөслим районы) барлыгы 18 сәгатьлек 12 аудиотасма язып алынды. Материалларның төп өлешен музыкаль фольклор әсәрләре, җырлы-биюле уеннар, бәйрәмнәр тасвирламасы, халык терминологиясе, авыллар тарихына кагылышлы мәгълүматлар һ. б. тәшкил итә. Алар арасында башкаручыларның кулъязма дәфтәрләреннән күчереп язылган шигъри текстлар һәм фоторәсемнәр дә бар.

Атап үтелгән районнарда һәм Башкортстанның аларга чиктәш авылларында яшәүче татарларга, тел үзенчәлекләреннән тыш (биредә урта диалектның минзәлә сөйләше таралган), матди һәм рухи культура уртаклыгы да хас. Санап киткән авыллар элек Уфа губернасының Минзәлә өязенә кергән булган. Анда яшәүчеләр арасында туганлык бәйләнешләре еш очрый (әйтик, кызлар күрше авыл егетләренә кияүгә чыкканнар, егетләр тирә-як авылларының кызларын алганнар), шуңа күрә Актаныш районында чыгышы белән Минзәлә, Мөслим кешеләрен очрату (яки киресенчә) бер дә гаҗәп түгел. Димәк, хәзерге административ-территориаль бүленеш шартлы чикләрне генә билгели.

Бу язмада Актаныш районының Түке, Зөбәер авылларында һәм тумышы белән Актаныш якларыннан булып, бүгенге көндә Мөслим районының Исәнсеф авылында яшәүчеләрдән җыелган материаллар нигез итеп алынды. Өстәмә чыганак буларак, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 2009 елда оештырылган комплексы экспедициясе вакытында Күҗәкә, Карт, Уразай авылларында тупланган музыкаль язмалар да файдаланылды.

Актаныш районында яшәүчеләр белән аралашу вакытында аларның эчкерсезлегенә, кунакчыллыгына хәйран калдык. Һәр йортта, хәтта анда ялгыз картлар гына яшәсә дә, кыстап табынга утырталар, чәй белән сыйлыйлар. Әле, җитмәсә, үзләрендә чәйне һичшиксез ике чынаяк эчәргә кирәк, югыйсә парсыз (ягъни ялгыз) каласың дигән ышану да бар. Ризыкны өстәлгә бик мул куялар, аз кую саранлык билгесе санала икән. Көненә берничә йортта булырга туры килә. Өлкән кешеләргә мәшәкать ясыйсы килмәгәнлектән, чәйдән баш тартып та карыйбыз, әмма аны хуҗалар *«саннамау»* дип кабул итәләр. *«Чәй эчмичә чыгып киткәч мәдәк була ич»* дигәнне бик еш ишетергә туры килде. Шуңа күрә хуҗаларга хөрмәт йөзеннән, һәркайсында табын артында утырып, җирле ризыклардан авыз итеп, рәхмәтләребезне әйтеп китә идек.

Актанышлылар белән сөйләшә башлауга ук, аларның сөйләмендәге диалекталь сүзләргә игътибар итәсең. Мәсәлән, *нәмәкәй* (нәрсә), *нәмәгә* (нәрсәгә), *инәкәй* (әни), *биана(й)* (каенана), *биата(й)* (каената), *алҗыдым* (арыдым), *нык* (бик): *нык матур* (бик матур), *кырына* (янына): *сигез кыз кырына әтәй тугачтын, бабай белән икесенә җир булган, уш* (хәтер, акыл): *ушым бәләкәйләнде, уш юк хәзер, ушым китте, әле ушлары бик дөрес.* Әлеге һәм башка тел үзенчәлекләре музыкаль әсәрләрдә дә чагылыш таба. Аларны без үзгәртмичә, әлеге төбәккә хас үзенчәлекләре сакланган килеш тәкъдим итәбез.

Бу төбәктә яшәүче өлкәннәрнең бормалы, матур яңгырашлы борынгы исемнәре сокландырды. *Абызгәрәй, Асылгәрәй, Бәхтигәрәй, Дәүләтгәрәй* (бертуганнарны шулай атаганнар), *Фәхразый, Шәехразый, Мөхәммәтхан, Тимершәех* кебек ир-ат

исемнәре һәм *Гөлрәйхан, Өммерәйхан, Миңлехая, Гайнелхәят, Хансафа* һ. б. хатын-кыз исемнәре үзләре үк музыка сыман яңгырыйлар.

Халкыбызның, бу очракта актанышлыларның, гаять зур иҗади потенциалын, искиткеч сәләтлелеген ассызыклап үтәсе килә. Һәр авылда диярлек шигырь, җыр иҗат итүчеләрне, үзенчәлекле башкаручыларны очратасың. Димәк, монда моң чишмәсе генә түгел, ә моң диңгезе бар!

Ике экспедиция (2004 һәм 2009 еллардагы) дәвамында 1910–1946 еллар арасында туган 22 кешедән күп төрле мәгълүматлар язып алынды. Шунысы сөендерә – өлкәннәр арасында үзләренең яшьлек чорындагыны гына түгел, ә эти-әниләреннән, хәтта әби-бабаларыннан өйрәнеп калган музыкаль-фольклор үрнәкләрен хәтерләүчеләр бар. Ә бүгенге яшьләр аларны саклый һәм түкми-чәчми киләчәк буыннарга тапшыра алырмы? Шунлыктан тормыш-көнкүреш рәвеше тиз үзгәрә торган бүгенге шартларда, олы буын башкаручыларның хәтерендә генә сакланып, инде онытыла барган җыр-көйләрне, йола-гадәтләрне язып-теркәп калу аеруча мөһим.

Актаныш якларында гаҗәеп бай һәм күптөрле материаллар тупланды. Без аларны җиде төркемгә бүлеп тикшерәбез: 1) җырлар (авыл көйләре, озын көйләр, кыска көйләр, салмак көйләр, уен көйләре); 2) такмаклар, бию көйләре; 3) мөнәҗәтләр, китап көйләү әсәрләре; 4) Коръән сүрәләрен көйләп уку, салават әйтү, азан әйтү; 5) балалар фольклоры һәм «аналар поэзиясе» (бишек җырлары, санамышлар, юаткычлар, үртәвечләр); 6) инструменталь музыка (җыр һәм бию көйләрен гармунда уйнау); 7) композиторлар иҗат иткән көйләр.

Актаныш якларында халык музыкасын язып алу эше элегрәк танылган композиторларыбыз Җәүдәт Фәйзи һәм Александр Ключарев тарафыннан башкарылган иде.

А. Ключаревның 1955 елда басылып чыккан (2 нче басмасы 1986 елда) җыентыгында 1939, 1940 һәм 1946 елларда тупланган 21 көй бирелгән. Кызганыч, анда чыганаклар (авыл исеме, башкаручының яше һ. б.) тулы күрсәтелмәгән. Мисалларның күбесен лирик җырлар *(авыл көйләре, кыска көйләр)* тәшкил итә,

рекрут һәм солдат җырларына һәм берәр борынгы туй җырына, балалар уенына, инструменталь көйгә урын бирелгән[1].

1952 елда Җәүдәт Фәйзи тарафыннан Актанышның район үзәгендә, Такталачык, Мәсәде, Бурсык авылларында тупланган 20 көй 1971 һәм 1987 елларда нәшер ителгән «Халык җәүһәрләре» дигән җырлар җыентыгында дөнья күрделәр[2]. Бу исемлеккә 231 нче номерлы бию көен һәм «Бөдрә тал»ны да кертергә мөмкин. Искәрмәдә аның турында «Татарстанның төрле районнарында таралган, ә бер вариантын Актаныш районы Качкын авылыннан Фарсил Зыятдинов* тапшырган»[3], диелгән. Китаптагы бүлекчә исеменнән аңлашылганча, җыючының максаты – «татар халкының хәзерге заман музыка фольклоры»н чагылдыру булган. Җ. Фәйзи тарафыннан Актаныштa язып алынган материалларны жанр ягыннан түбәндәге төркемнәргә бүләргә мөмкин: *авыл көйләре, кыска көйләр, уен җырлары, такмаклар һәм бию көйләре* (бию көенә бер генә мисал). Җ. Фәйзи язып алган дүрт әсәр М. Нигъмәтҗановның ноталы басмасына[4] да кертелгән.

Күрсәтеп үтелгән җыентыкларда Актаныш районы татарларының халык музыка сәнгате өлешчә генә яктыртылган. Аерым алганда, ул еллардагы идеологик карашлар аркасында, ислам дине белән бәйле көйләп башкарыла торган әсәрләр *(мөнәҗәтләр, китап көйләре)* игътибардан читтә калган. Балалар музыкаль фольклоры үрнәкләре бөтенләй юк диярлек.

Бу җитешсезлек XXI гасыр башында берникадәр төзәтелде. 1968 һәм 1998 елларда Актаныш районының Яңа Богады һәм башка авылларында язып алынган 8 мөнәҗәт К. Хөснуллинның шактый зур күләмле «Мөнәҗәтләр һәм бәетләр: Көйләп укуга

---

[1] *Ключарев А. С.* Татар халык җырлары. – Казан, 1986. – № 5–12, 15, 17, 56, 141, 150, 159, 161–162, 175–178, 187, 226.

[2] *Фәйзи Җ.* Халык җәүһәрләре: Татар халкының хәзерге заман музыка фольклоры (Ноталары һәм тарихи аңлатмалары белән). – Казан, 1971. – № 18, 21, 36, 47, 49, 52, 55, 60, 74, 77, 85–86, 92, 131–132, 144, 146, 148, 179–180. (Икенче басмасы 1987 елда дөнья күрде.)

* Хәзер танылган галим һәм язучы.

[3] Шунда ук. – Б. 43.

[4] *Нигмедзянов М.* Татарские народные песни. – М., 1970. – № 179, 181, 189, 228.

нигезләнгән жанрлар»[1] хезмәтендә укучыларга тәкъдим ителде (аларның өчесе генә көе белән бирелгән).

Шуларны истә тотып, тәкъдим ителә торган басмада Актаныш төбәгенең музыкаль байлыгын мөмкин кадәр тулырак чагылдырырга тырыштык. Автор йөреп чыккан авылларда моңарчы музыкаль-шигъри фольклорны җыю һәм өйрәнү эше алып барылмаган булса кирәк. Шунлыктан халык әсәрләренең кайберләре беренче тапкыр (һәрхәлдә, безгә очраганы булмады) басыла, икенчеләре исә әлегә хәтле мәгълүм булган яки инде китапларда дөнья күргән үрнәкләрнең үзенчәлекле вариантлары булуы белән кызыклы. Актаныш районының халык традицияләре этномузыкаль яссылыкта беренче тапкыр тикшерелә.

Инде материалны турыдан-туры тасвирлауга күчик.

Билгеле ки, фольклор халыкның көндәлек тормышы белән тыгыз бәйләнгән. Соңгы елларда күп кенә традицион әсәрләр югалып бара. Аерым жанрларның хәзергә кадәр яшәп килүе исә аларның заман таләпләренә, көнкүреш рәвешенә яраклашуы яисә туры килүе белән аңлатыла.

Бүгенге көндә авылларда җыр-көйләрнең яңгыравы, нигездә, күмәкләшеп уздырыла торган сабантуйлар һәм бәйрәм мәҗлесләре белән бәйле. Танылган «Шахта», «Арча», «Герман», «Алмагачы», «Баламишкин», «Күбәләгем», «Әпипә» һ. б. көйләр әлегә хәтле халык тарафыннан яратып башкарылалар. Әйтик, киң таралган «Шахта» көе (аны информантлар *озын көй* дип атыйлар) элек *урам көе* функциясен үтәгән, ә хәзер аны өлкән буын вәкилләре, үзләренең яшь чакларын искә төшереп, табын янында җырлыйлар (Түке, Зөбәер авылларында).

Гадәт буенча, мәҗлестә катнашучылар җиңелчәрәк бер көйгә *кара-каршы җырлашалар.* Мәсәлән, Түке авылында яшәүче Рәвидә Гыйльметдинова (1937 елда туган) кодагыйларга багышланган мондый җыр юллары белән таныштырды:

Парлап костюм тектерәек
Икебезгә карадан,

[1] *Хөснуллин К. М.* Мөнәҗәтләр һәм бәетләр: Көйләп укуга нигезләнгән жанрлар. – Казан, 2001. – Б. 646–647, 654, 664.

Ефәктәй җил дә үтмәсен
Икебезнең арадан.

Моңа охшаш дүртьюллык («Баламишкин» көенә) 1992 елда Теләче районының Олы Нырсы авылында керәшен татары Анастасия Кутузовадан (1937 елгы, Субаштан) язып алынган иде:

Кодагый, күлмәк тектерик
Икебез дә карадан,
Дошман сүзләре йөрмәсен
Икебезнең арадан.

Халкыбыз күңелендә саклана һәм буыннан-буынга тапшырылып килә торган музыкаль фольклор әсәрләрнең һәрберсенең үз башкарылу урыны һәм вакыты, үз вазифасы бар. Балалар үстергәндә һәм тәрбияләгәндә *бишек җырлары, юаткычлар, мавыктыргычлар* игътибар үзәгендә булса, бала туу, никах мәҗлесләрендә, күмү һәм искә алу йолаларында *көйләп дога уку, мөнәҗәт әйтүгә* төп урын бирелә.

Җәмгыятебездә исламга тартылу көчәйгәч, дини бәйрәмнәр зурлап үткәрелә һәм мәчетләр салына башлады. Болар үз чиратында ислам музыкаль традицияләренең үсешенә уңай тәэсир ясады. Мәчет манараларыннан *азан* яңгырый, Корбан бәйрәме һәм Ураза бәйрәмендә, Рамазан ае вакытында *салаватлар, Коръән сүрәләре* көйләп башкарыла.

Шул ук вакытта кайбер милли традицияләрнең дәвам ителүе иҗтимагый сәбәпләрдән генә түгел, ә кешенең ихтыяҗыннан (ягъни шәхси тормышына бәйле сәбәпләрдән) да тора. Туганнарны югалту яисә алардан аерылу, ялгызлыктан туган авыр кичерешләр шигъри формалар *(шигырь, җыр, мөнәҗәт)* аша белдереләләр. Шунысы игътибарга лаек, халык башкаручылары үз әсәрләрен традицион темалар һәм образларга нигезләнеп иҗат итәләр. Мисал өчен, Түке авылында гомер итүче Лүфә Фәтхиева, улы вафат булгач (2004 елда) иҗат иткән шигырендә татар халык җырларына хас булган *ага сулар, ага сулар; матур йөзләрең, зифа буйларың; өзелә үзәккәем* кебек сүзтезмәләр куллана (карагыз: Кушымта, III, № 10). Хәниф Гәрәевнең (Зөбәер авылы) үз хатынына багышланган мөнәҗәтендә 1, 2, 6, 8 стро-

фалар *сабырлыклар бирсен Алла* дигән типик формула белән тәгәлләнә (Кушымта, III, № 9). «Ялгызлык моңы» исемле шигъри композициянең (авторы – Саһира Газизуллина) 21 куплеты да традицион калыпка салынган (Кушымта, III, № 11). Монда халык җырларында еш очрый торган башлангыч юллар (*биек тауның башларында; тал бөресе, тал бөресе; уйлый күңелем, уйлый күңелем)*, төсләр символикасы *(Кулым тисә – бакчаларда / Саргая кызыл балан)* чагылыш тапкан.

Ана һәм бала темасы мөнәҗәтләрнең аерым төркеме өчен дә хас. Шунлыктан С. Газизуллинаның бу әсәрне мөнәҗәт көенә башкаруы очраклы түгел. Әлеге көй *гаруз* үлчәменең бер төре булган *хазаҗ*га – ♪♩ ♩ ♩ корылган. Билгеле булганча, «Мөхәммәдия» китабы текстлары да шушы ритм формасы (1:2:2:2) буенча көйләп укыла.

Безнең күзәтүләр буенча, шигъри әсәрләр иҗат итү катнаштыру принцибына нигезләнгән. Милли мохиттә тәрбияләнеп, шул традицияләрне дәвам итүчеләр буларак, халык башкаручылары (кайвакытта үзләре дә сизмичә, ә еш кына – аңлы рәвештә) үзләре кичергән вакыйгалар тәэсирендә иҗат иткән текстларын инде халыкка мәгълүм шигъри формалар белән аралаштырып төзиләр. *«Үзем чыгардым. Готовыйлар да катнашты микән инде? Анысы да бар»*, – диләр еш кына. Шулай итеп, автор «иҗат җимеше»нә аерым җырларның кечкенә өзекләре дә, хәтта тоташ строфалар да кереп китәргә мөмкин. Сайланган үрнәкләр кайдан гына алынган булса да (аралашу даирәсеннән, өлкән туганнардан, радио, телевидение, китаплардан һ. б.), иң мөһиме – алар шул моментта иҗатчының кәефенә, хисләренә, күңел халәтенә туры килгән булган. Моны дәлилләү өчен аерым мисалларга тукталып үтик.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр урындык.
Алты почмак йорт салалар,
Карчыкларга урын юк.

Картайган ананың бәхетсез язмышын бәян иткән бу дүртьюллык Түке авылында язып алынды. Андагы *урындык – урын юк* типик рифмасы татар җырларының аерым бер төркемендә очрый торган *Әнә килә автомобиль* сүзтезмәсе белән берләшә.

Шуңа охшаш вариант 1992 елда Теләче районының Кече Мирәтәк (Бичер) авылында Әминә Гаффаровадан язып алынган иде. Анда рифмалашкан традицион юлларга бүтән башлама кушыла:

Ишегалдым яшел чирәм,
Әйләнәсе урындык, ди.
Биш балага – биш урындык,
Бер анага урын җук.

Информантларның әйтүенә караганда, алар күңелләренә килгән текстларны дәфтәрләренә теркәп куялар да шуңа даими рәвештә яңа шигъри юллар өсти торалар.

Лүфә Фәтхиева «Герман» көенә балаларны сагынып җырлана торган текстларны башкарып күрсәтте (Кушымта, II, № 4). Җырның икенче куплетын ул әтисеннән отып калган, калганнарын, әзер шигырь материалы өстәп, үзе уйлап чыгарган. Типиклашкан стилистик алымнар арасында *бирсен Ходай сабырлык* формуласы (4 нче куплет), сары төс семантикасы (1 һәм 3 нче куплетлар) һ. б. игътибарны җәлеп итә.

Экспедиция барышындагы тикшеренүләр күрсәткәнчә, өлкән буын вәкилләре үзләренең ялгызлыгы, якын кешеләре белән аерылулары турындагы моңсу, үзәк өзгеч текстларны, гадәттә, рекрутлар һәм солдатларны озату көйләренә җырлыйлар. Еш кына Беренче бөтендөнья сугышы (1914) елларында барлыкка килгән һәм аерылышу символына әверелгән «Герман» көенә мөрәҗәгать итәләр. Югарыда телгә алынган Л. Фәтхиева да, үзе иҗат иткән шигырьләрдән тыш, шул ук көйгә традицион рекрут текстын җырлады:

Чәчәк идек илләрдә,
Чәчелдек чит җирләргә.
Таг[ы] да чәчәк булыр идек
Кайтсак туган илләргә.

Милли традицияләр, гореф-гадәт, йолаларыбызны саклау, торгызу, киләчәк буыннарга җиткерүдә мәгълүмат чараларының, бигрәк тә телевидениенең, әһәмияте зур. Җирле сәнгать осталарының репертуары һәм башкару осталыгына профессиональ җыр-

чыларның эшчәнлеге дә йогынты ясый. Кайвакыт җыр текстларын басылган хезмәтләрдән дә алабыз, диләр халык җырчылары.

Фольклор әсәрләре безнең көннәрдә икенчел (аутентик булмаган) формалар аша яңгыраш ала. Балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә гореф-гадәтләрне, йолаларны җанландыруга юнәлдерелгән чаралар уздыру халкыбызның алтынга тиң җәүһәрләрен буыннан-буынга тапшыру, саклап калу юлында изге гамәл булып торалар.

Шулай итеп, хәзерге чорда татар халкының музыкальшигъри хәзинәсенең җәмгыять һәм аерым шәхес таләпләренә җавап бирә алган аерым бер өлеше генә актив файдаланыла. Әмма халык җырларының шактый өлеше мирас формасында яши. Нигездә, алар өлкән яшьтәге кешеләрнең хәтерендә саклана. Бу бигрәк тә *уен көйләре*нә һәм *озын көйләр*гә карый.

Башкаручылар сөйләвенчә, элегрәк «Кара урман», «Рамай», «Сарман», «Шомыртым», «Зөләйха» җырлары аеруча популяр булган. Киң таралган уен җырларыннан «Суда, суда», «Челтәр элдем читәнгә», «Гөлбану», «Чума үрдәк, чума каз» («Оча үрдәк, оча каз» варианты да бар) һ.б. атарга мөмкин. Кайбер уеннарны оештырганда «Шахта» көе кулланылган.

Алдагы елларда Актаныш районында «Колхоз түгәрәге» дигән уен булуы ачыкланды. Пучыдагы уен тәртибе буенча, мәсәлән, катнашучылар түгәрәкләнеп басалар һәм уртага егет белән кызны утыртып, аларга атап җырлый башлыйлар. Әгәр түгәрәк эчендәгеләр башкаларны хупласалар – аларга җыр сүзләренең матурларын сайлыйлар, киресенчә булса – чәнечкеле, төртмәле куплетлар башкаралар. Әйтик, түбәндәгечә:

Су буйлары абага,
Син дустымны охшатамын
Җон бәйләгән кабага.

Мичтә бәрәңге пешә,
Кишан да мишан киләсең –
Әллә ыштаның төшә?

Айман жулы шулмени?
Артыңны сузып йөрисең,
Авторитың шулмени?

Җырны тапшыручы Фәрсия Камалетдинова (1936 елда туган) әйтүе буенча, Пучы авылы яшьләре элегрәк *Әнәк яланы, Тәкәрлек очы яланы, Ферма яланы* кебек махсус билгеләнгән урыннарда җыелып күңел ачканнар. Гөлчирә Ямалетдинова (1931 елда туган) Зөбәер халкының элек бу уенны ял көннәрендә авыл клубында оештыруларын искә алды.

Яшьләрнең җырлы-биюле уеннары *җыен* бәйрәменең аерылгысыз бер өлеше булып торган. Зөбәер авылында яшәүче Хәниф Гәрәев (1914) һәм Сафия Нәбиева (1920 елда Апач авылында туган) сөйләүләре буенча, узган заманнарда якын-тирә авыл халкы атна дәвамында бер-берсенә кунакка йөрешкән. Җигүле арбаларга утырып, гармуннар уйнап, җырлар җырлап җомга көнне Иске Кормашка, якшәмбе – Пучыга, дүшәмбе – Бикбауга (хәзер Минзәлә районына керә), сишәмбе Татар Суыксуына барганнар. Һәрбер җыенның үз исеме (мәсәлән, *Бикә җыены, Туерга җыены* һ. б.) һәм үткәрелү вакыты булган. *Олы җыен* – июньнең 20 ләрендә Пучыда (элек Калинин районы үзәге) уздырылган. Туйларны да шул вакытка көйләгәннәр, кәләшләр яңа гаиләгә күчеп килгән. Кичләрен Бәҗәнә елгасы буенда уеннар оештырылган.

Җыен белән бәйле бәйрәм чараларын язгы чәчү төгәлләнеп, урак өсте башланганчы уздырырга тырышканнар. Шунысы кызык: урак вакытын, шаяртып, *Кәкре җыен* дип йөрткәннәр. Бу очракта, уракның бөгелгән формада булуы күздә тотылгандыр, мөгаен. Уракка төшүнең беренче көне зур вакыйгага әйләнгән: авыл халкы җыелып, гармунга кушылып җырлап, догалар укып уракчыларны кырга озаткан. Бу матур гадәт колхозлашу чоры башлангач төшеп калган.

Актаныш төбәгендәге *бию көйләренең* исемлеге бик үзенчәлекле. Татар халык көйләре «Әпипә», «Өммегөлсем» белән беррәттән, элек башка милләт көйләренә дә биегәннәр. Әйтик, «Барыня», «Краковяк» (актанышлыларча – *кәркәбият)*, «Ту-степ» (*ту-стеф)*, «Казачок». Музыка коралларында уйнаучылар булмаганда, иҗекләрне көйгә салып («телдән» җырлау дип атарга була), *әллә-лиллә-лиллә-ләгә* биегәннәр.

## Халык җырчылары

Экспедиция вакытында халык сәнгатен чын мәгънәсендә саклаучы искиткеч башкаручылар белән очрашу бәхете насыйп булды. Аларның кайберләре турында тәфсилләбрәк язарбыз[1].

### *Түке авылы*

*Газизуллина Саһира Тимершәех кызы* 1929 елда Актаныш районының Күҗәкә авылында туган, Түкедә яши. Аны өлкән яшьтә дип әйтеп тә булмый. Ул – тормышта күп кыенлыклар, кайгы-хәсрәтләр күрсә дә, күңел төшенкелеген сиздермичә яши торган зифа буйлы хатын. Гаиләдә олы бала буларак, ул әти-әнисенә, өй эшләрендә булышуда һәм кече эне-сеңелләрен карап үстерүдә төп ярдәмче була. Өлкәнәйгәч тә, язмыш үзен гел сынап тора: 7 баласының икесе кечкенә чакта ук үлә, 49 яшендә тол кала (ире фаҗигале рәвештә вафат була). Шуның өстенә Саһира апа 17 ел буе сукыр кайнанасын (*бианасын*) тәрбияли.

Саһира апа – күпкырлы талант иясе. Аның кулыннан килмәгән эше юк. Гүзәллеккә омтылышы бик көчле: тирәсендәге һәр нәрсәне бизәп, матурлап тотарга ярата (өендәге бизәкләр төшерелгән мич, бакчасында төрле төсләргә буялган умарта оялары һ. б.).

Саһира Газизуллинаның зур форматлы калын дәфтәре бар, ул анда үзе чыгарган шигырьләрне, дини эчтәлектәге текстларны теркәп бара. Аның башкаруында магнитофон тасмасына язылган әсәрләр арасында мөнәҗәтләр (хәтта бала чагында әнисеннән һәм әбисеннән отып калганнары да), мөселман бәйрәмнәрендә башкарыла торган көйләр, бер бишек җыры бар. Халык җырчысы үзе иҗат иткән берничә шигырьне көйләп тә күрсәтте (Кушымта, III, № 11).

*Гыйльметдинов Фәхразый Мәүләветдин улы* 1939 елда Түкедә туган, шунда гомер кичерә. Ул – *озын көйләр* башкару традициясен дәвам итүче. Бөтен көчен куеп, басып җырларга ярата (утырып җырлау җайсыз, ди). Җырчының иҗади сандыгында халык җырларыннан – «Галиябану», «Зәңгәр төймә», «Сөенечкә

---

[1] Кызганыч, биредә аларның барысы турында да язу мөмкинлеге юк (информантларның тулы исемлеге хезмәтнең ахырында бирелә).

дисәм»; композиторлар әсәрләреннән – «Яшь наратлар» (Җ. Фәйзи муз., И. Юзеев сүз.), «Сине сөйдем, гүзәлем» (Ф. Әхмәдиев муз., Т. Вәлиев сүз.), «Ана сагышы» (К. Әһлиуллин муз, Ә. Игебаев сүз.) кебек үрнәкләр бар. Ул мәшһүр җырчы Илһам Шакиров репертуарындагы «Сөенечкә дисәм» һәм «Ана сагышы» җырларын аеруча яратып башкара. Яраткан җырчысының югары дәрәҗәдәге башкару осталыгы Ф. Гыйльметдиновның җырлау манерасына да йогынты ясамый калмаган.

Бу җыр остасыннан *азан көе* дә яздырып алынды (әлеге көй ике нотаның $d-c$, $c-d$ төрле ритмик комбинацияләрдә кабатлануы белән үзенчәлекле).

Түке башкаручылары арасыннан *Солтановлар* нәселенең моң ияләрен: *Гөлрәйхан Әгъләм кызын* (1936 елда туган), *Рифкать Бәхтигәрәй улын* (1934), *Мэльс Асылгәрәй улын* (1940) билгеләп үтми мөмкин түгел (Кушымта, II, № 3, 5).

### *Зөбәер авылы*

*Хәбибуллина Светлана Фатыйх кызы* 1946 елда Яңа Богады авылында дөньяга килгән. Балачагы Башкортстанның Илеш районында узган. Казакъстанда белем алгач, Светлана ханым туган ягына әйләнеп кайткан, хәзер Зөбәердә яши. Ул 38 ел рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгән.

Кыз чагында йөрткән *Акчүвәкова* фамилиясенең тарихы бик кызык. Җиденче буын бабаларының исеме Акчура булган, үзгәрә-үзгәрә, ул Акчүвәккә әйләнгән. Фамилия шул исемнән килеп чыккан да инде.

Халык җырчысы табигатьтән бирелгән музыкальлегә, эстетик тоемлау сәләте, йомшак саф тавышы белән аерылып тора.

Светлана Хәбибуллина 1965 елдан башлап шигырьләр иҗат итә (кызганыч, аларны язып барган бер дәфтәрен югалткан). Бу сәләтле башкаручы белән очрашу бик уңышлы булды. Аннан күп төрле музыкаль-шигъри үрнәкләр (*мөнәҗәтләр, догалар, озын көйләр, уен көйләре, бишек җырлары*, *юаткычлар, санамышлар*), этнографик материаллар, инструменталь традицияләргә кагылышлы һ.б. бәһале мәгълүматлар язып алынды (Кушымта, II, № 9–12; III, № 1, 4–8).

*Гәрәев Хәниф Сәетгәрәй улы* 1914 елда туган. Кием тегүче, кисүче булып эшләгән. Башта фин сугышы, аннан Бөек Ватан сугышларында катнашкан. Мәчеттә имам хатип булган.

Хәниф ага башкаруында борынгы *лирик җырлар* («Зөлфия», «Әни җыры»), хатынының үлеменә багышланган *мөнәҗәт, азан, догалар, Коръән сүрәләре, «Бәдәвам» көе*, шулай ук авыл тарихы, халык терминнары, элеккеге гореф-гадәтләр, йолалар турындагы күпсанлы мәгълүматлар язып алынды (Кушымта, II, № 1–2; II, № 9).

*Ямалетдинова Гөлчирә Госман кызы* 1931 елда Зөбәер авылында туган һәм шунда гомер кичерә. Ул – язма текстларны *көйләп уку* традициясен саклап килүче. Аннан *мөнәҗәтләр*, *Коръән сүрәләре, «Бәдәвам» көе* язып алынды (ул аларның күбесен әнисеннән отып калган). Бер матур гына *уен җыры* үрнәге дә бар (Кушымта, II, № 6, 13–15).

## Музыка коралларында уйнау традицияләре

Актаныш районында хәзерге көндә төрле гармуннар (хромка, саратов һәм тальян) кулланышта йөри. Хромка гармунында моңлы көйләрне Түке авылыннан Солтанов Мэльс Асылгәрәй улы (1940 елгы), саратов һәм тальян гармуннарында Карт авылында яшәүче Нәгыймов Мәган Хәсән улы (1928 елда туган) өздереп уйный. Гармунчылар репертуарында «Шахта», «Алмагачы», «Рамай» һәм башка *авыл көйләре, кыска көйләр, уен көйләре* аерым урын алып тора. Бию көйләре аеруча популяр.

Этнофорлар (информантлар) әйтүенә караганда, әүвәлге елларда тальян һәм биш планкалы «рус» гармуннары киң таралган булган. Бу якларда элек ир-атларның скрипкада, хатын-кызларның курайда уйнау традицияләре үсеш алуы да мәгълүм.

Зөбәер авылыннан – *Яппаров Нуриәхмәт* (якынча 1885 елда туган), Иске Айманнан *Хаҗиев Гөлүм* – аеруча танылган скрипкачылардан. Аларның беренчесе «Тәфтиләү», «Шахта» көйләрен уйнарга яраткан, шул ук вакытта оста биюче дә булган. Икенче скрипкачы репертуарын «Ишкәкче карт», «Салават батыр», «Ямбикә», «Зәлилә» һ. б. көйләр тәшкил иткән.

Шул ук Зөбәер авылыннан *Гәрәева Хәнифә Мөхәммәтлатыйп кызы* (1882 елда Адайда туган) курайда уйнаган. Улы Хәниф Гәрәев (безнең информант) сүзләренә караганда, гөпшә үләнен *(гөпшәкәй)* җыеп киптереп, курайны ул үзе ясаган.

*Мәдьярова Галия Бәдретдин кызы*ның (1902 елда Пучыда туган) төрле озынлыктагы 10 лап курае булган. Ул аларны әрекмәннең үскән сабагыннан кыйгачлап кисеп ясаган. Курайларын коры урында (мич башында) саклаган. Бу башкаручының репертуарында *озын көйләрдән* «Аккош» һәм каз, торна тавышларына охшатып чыгарган көйләр булган. Аның кызы Фәрсия Камалетдинова әйтүенчә, әнисен еш кына концертларда чыгыш ясарга чакырганнар.

Сугыш дәверендә хатын-кызлар әле берсендә, әле икенчесендә җыелышып, бергәләп кич утырганнар, анда Коръән сүрәләре, пәйгамбәрләр тормышы турындагы хикәяләр укыганнар. Бигрәк тә Бикә-абыстай өенә кеше күп килә торган булган. Биредә дин сабакларын өйрәнү кул эше һәм күңел ачулар белән чиратлаштырып алып барылган. Андый җирләргә Галия Мәдьярова үзе белән һәрвакыт кураен йөрткән һәм җыелган хатын-кызлар үтенече буенча төрле көйләрне уйный торган булган.

Курайчы *Кафия (Куфия) Бәйрәм кызы* Әтәс авылында туып үскән, Апач авылына кияүгә чыккан. Кафия апа, хәтта кыр эшләренә йөргәндә дә, уен коралын үзеннән калдырмаган. Төшке аш вакытында кураенда кызу көйләр уйнап, башкаларның күңелен күтәргән, биергә дәртләндергән. *Эш эшләгәндә – урак урганда абәткә утыргач, курай уйнап биетәдерие кешене*, – дип, бу хакта Нәбиева Сафия Салихҗан кызы сөйләде. Курай өчен үсемлекләрне халык *Апач әрәмәсеннән* җыйган. Информантның «*Элек уйнадылар бит аны. Курайны бөтен кеше диярлек уйнады элек*», дигән сүзләре аерым кыйммәткә ия.

Экспедиция барышында очраткан барлык халык башкаручыларына халкыбызның музыкаль җәүһәрләрен гомер буе күңелләрендә йөртеп, мәдәни мирасыбызны киләчәк буыннарга җиткерергә ярдәм итүләре өчен ихластан тирән рәхмәтебезне белдерәбез.

*КУШЫМТА*

Кушымта өч кисәктән тора. Беренчесендә – Актаныш районында язылып, А. Ключарев һәм Җ. Фәйзи җыентыкларында дөнья күргән кайбер мисаллар урнашкан. (Нота язмалары өлешчә редакцияләнеп бирелде.) Икенче һәм өченче кисәген 8 нче номерлы «Уен такмаклары»ннан кала, үзебез туплаган материаллар тәшкил итә (II – фольклор әсәрләре ноталар белән, III – шигъри текст үрнәкләре). Көйләрне нотага салу һәм текстларны кәгазьгә күчерү мәкалә авторы тарафыннан башкарылды.

Әлеге хезмәттә экспедиция материалларының бер өлеше генә урын алды. Актаныш төбәге халык музыка сәнгатен тирәнтен һәм җентекләп өйрәнү – киләчәк эше.

ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР

1. Бу басмада көйләрне юллап (ягъни шигырь юлына туры китереп) урнаштыру тәртибе кулланыла.

2. Ачкыч янында реаль файдаланылган альтерация билгеләре күрсәтелә.

3. Музыкаль вариантлар өстәмә нота сызыкларында урнаштырыла.

4. Сүзләрне әйтү үзенчәлекләре саклана: *ваянкамат* (военкомат), *бәдүвам* (бәдәвам), *моңны* (моңлы).

5. Башкарган вакытта барлыкка килгән өстәмә сузык авазлар түгәрәк җәяләр эчендә бирелә: *күңел(е)ләрем(е).*

6. Җырлаганда төшеп калган сузыклар квадрат җәяләр белән күрсәтелә: *әл[е] дә, күр[е]шербез.*

7. 𝄠 – көйнең бер октавага түбән яңгырашы.

8. V – башкару сулышы билгесе.

9. (𝄽) – метрга кермәгән башкару паузасы.

10.  – глиссандо.

11. 𝄐 – авазны сузу (озынайту).

12. 𝅘𝅥𝅮 – билгесез югарылыктагы аваз.

## I. А. КЛЮЧАРЕВ ҺӘМ Җ. ФӘЙЗИ ҖЫЕНТЫКЛАРЫННАН

### А. Ключарев җыентыгыннан[1]

#### *1. Авыл көе*




Сандугачлар басып сайрый
Су буенда тирәккә шул;
Яшь урманнар утыртабыз
Туган илгә кирәккә.

Алмагачлар күп утырттык,
Утыртабыз урманнар шул;
Бакча, урманнар утыртып,
Без дан алыйк, туганнар!

*С. Ситдыйкова тапшырды, Актаныш районы, 1939*

#### *2. Мәдинә, гөлкәем*




[1] *Ключарев А. С.* Татар халык җырлары. – Казан, 1986.

Бәйлә кызыл яулыгыңны,
Син ударница бит инде,
Мәдинә, гөлкәем,
Өзелә үзәккәем,
бәгырькәем.

Һәрбер эштә тырышып эшләп
Күтәр авторитетыңны,
Мәдинә, гөлкәем,
Өзелә үзәккәем,
бәгырькәем.

*Ш. Харисова тапшырды, Актаныш районы, 1946*

### *3. Аерылу җыры*




Әйдә, дустым, озат мине
Уйсу җиргә җиткәнче,
озат мине
Уйсу җиргә җиткәнче.
Таңнар атар, чулпан калкыр,
Без аерылып киткәнче,
чулпан калкыр
Без аерылып киткәнче.

Бакчадагы алмагачның
Тамырын корытмагыз,
алмагачның
Тамырын корытмагыз,
И дусларым, әгәр китсәм,
Сез мине онытмагыз,
әгәр китсәм,
Сез мине онытмагыз.

*С. Рәхимҗанов тапшырды, Актаныш районы, 1939*

## *4. Рекрутлар көе*




Өстемдәге күлмәгемнең
Кара чуар парчасы;
Газиз башым солдат булды,
Бәхил булсын барчасы.

Без йөрибез урамнарда,
Тальян гармуннар тотып;
Безнең хәлне кеше белми,
Без йөрибез ут йотып.

Содат итеп алсалар да
Будырмам билләремне;
Ун елга дип алсалар да
Тутырмам елларымны.

*Ш. Хәнәфиева тапшырды,*
*Актаныш районы, 1939*

## Җ. Фәйзи җыентыгыннан[1]

### *5. Туган җирем*




Сагынам туган-үскән җиремне,
Бөтен тирәң синең ямьл[е] иде.
Сөямен,
Илкәемне уйлап көямен.

Салкын чишмәләрдән чылт[ы]рап аккан
Сулары да татлы, тәмл[е] иде.
Бигрәк тә
Чишмәләре тора йөрәктә.

Яланына чыгып йөргән чакта,
Таныш иде аның бар ягы.
Түз[ә] алмыйм,
Туган-үскән илдән биз[ә] алмыйм.

Бу җыр 1952 елда Татарстанның Актаныш район үзәгендә укытучы Хаҗәр Шәехова иптәштән язып алынды. Аның әйтүенә караганда, «Туган җирем» бик популяр җыр булып, «аның сүзләрен отып бетерерлек түгел, алар бик күп» икән. Ул аны әнисеннән ишеткән.

Җырның икенче, борынгырак варианты А. С. Ключаревның «Татар халык көйләре» җыентыгында да бар. Анда ул «Пленныйлар җыры» дип исемләнгән (1941 ел, 96 бит). Искәрмәдә аның Себердә «Туган ил»

[1] *Фәйзи Җ.* Халык җәүһәрләре: Татар халкының хәзерге заман музыка фольклоры (Ноталары һәм тарихи аңлатмалары белән). – Казан, 1971.

дигән варианты булуы әйтелә. Көйне Ключаревка тапшыручы К. Утяшевның әйтүенә караганда, ул аны 1915 елны Германиядә әсир чагында ишеткән булган.

Фольклорчы И. Надировның «Татар халык җырлары» китабында бу көйнең җиде строфа сүзләре урнаштырылган (1965, 90 бит). Үзенең искәрмәсендә иптәш Надиров: «Җырның фольклор фондына Минзәлә шәһәреннән Рокыя Усманова тапшырган төрдәше дә бар», – дип язган. Бу җыр белән Ә. Абдуллин иптәш тә кызыксынган икән. Ул тел-әдәбият институтының фольклор фондына Оренбург өлкәсендә этнограф композитор Антон Эйхенвальд язып алган вариантны тапшырган.

### *6. Такталачык көе*




Сандугачлар сайрый микән
Гөлбакчада-ояда шул;
Бергә эшләп, рәхәт яши
Колхозчылар дөньяда.

Зәңгәр чиләкләрем белән
Суларын алыйм әле шул;
Колхозларда тыр[ы]шып эшләп,
Иң алдан барыйм әле.

Ике басу арасында
Шаулап үсә яшь каен шул;
Яшь каендай шаулап үсә
Безнең колхоз көн саен.

Авыл көйләре төренә кергән бу җыр 1952 елда Актаныш районы Такталачык авылында колхозчы кызлар Гатия Әнвәрова белән Фаягөл Ишалиналардан язып алынды. Алар аны: «Күптән җырлана торган үз көебез», – диделәр. Шуңа күрә җырның исемен «Такталачык көе» дип куярга булдык.

### *7. Күңелле яшьлек*




Җил булсам исәр идем лә,
Гөл булсам үсәр идем;
Аккош яки былбыл булсам –
Дөньяны гизәр идем.

Тәрәзә төпләребездә
Үрмәле гөлләребез;
Күп дошманның йөрәгенә
Ут салган көннәребез.

Ерак җирләрдән күренә
Агыйделнең ак ташы;
Кая барып, кайда йөрмәс
Уңган егетләр башы.

Бик күптәнге көй. Безнең көннәрдә дә яңа сүзләр белән җырлана. Мин аны 1952 елда Татарстанның Актаныш район үзәгендә яшь җырчы

Асия Нуруллинадан язып алдым. «Мондый күңелле җыр борынгы буламыни?» – диде ул. Ләкин карт музыкантларыбызның әйтүенә караганда, бу көй элек «Җомга көе» дип аталган. Казан яшьләре, приказчиклар җомга көннәрендә Кабан күлендә көймәдә йөргәндә, гармун, скрипка уйнап, шушы көйгә җырлый торган булганнар.

### *8. Ай, тыр-дыр, там-там*




И ал бит ул, ал бит ул шул,
Ай, тыр-дыр, там-там
Ал кибеттә бар бит ул шул,
Ай, тыр-дыр, там-там.

Үзен мактап, кеше хурлап,
Ай, тыр-дыр, там-там,
Йөрүчеләр бар бит ул, шул,
Ай, тыр-дыр, там-там.

Иртә дә кил, кич тә кил, шул,
Ай, тыр-дыр, там-там,
Тәрәзәмне чиртә кил, шул,
Ай, тыр-дыр, там-там.

Кич дигәч тә соңга калма,
Ай, тыр-дыр, там-там,
Кичке сәгать биштә кил, шул,
Ай, тыр-дыр, там-там.

Бу такмакны да шул ук Такталачыктагы Шәйхаттар ага Зәйнуллин тапшырды. Ул аны «базар йөргән» яшь чакларда кашык кагып җырлаган. Җыр юллары арасына кергән «ай, тыр-дыр, там-там» шул кашык шакылдавын бирә торган сүзләр булгандыр, күрәсең.

Бу җырны концертларда Җәваһирә Сәләхова бик яратып башкара иде.

## II. НОТА ЯЗМАЛАРЫ

## Лирик җырлар

### *1. Зөлфия*






1. Йә яратам(ы), йә юк(ы) диеп
Үп(е)кәләмә, Зөл(е)фия.
Үп(е)кәләсәң(е) бер(е) дә дәш(е)мәм(е),
Үкенер(е)сең, Зөл(е)фия.

Зөл(е)фия, Зөл(е)фия,
Күңелем(е) сине сөя.

2. Акчарлаклар очып(ы) уйный
Агыйдел буйларында.
Ир(е)тә тор(ы)сам(ы), кич(е) ят(ы)сам(ы) да,
Син генә уй(е)ларым(ы)да.

Зөл(е)фия, Зөл(е)фия,
Күңелем(е) сине сөя.
Зөл(е)фия, Зөл(е)фия,
Күңелем(е) сине сөя.

2004 елда Зөбәер авылында Гәрәев Хәниф Сәетгәрәй улыннан (1914 елгы) язып алынды. Башкаручының әйтүе буенча, бу – «*иске, күптәнге көй*». Җырның тагын бер куплеты бар иде. Көе һәм сүзләре башка җыентыкларда очрамый. Интонацион-җай[1] төзелеше белән ул бераз «Рәйхан» җырына охшаш.

[1] Җай – «лад» төшенчәсен аңлата.

## 2. Әни җыры




Сабыным(ы) калды, сабыным(ы) калды,
Сабыным(ы) калды – алыгыз.
Ят(ы)кан урыннарым калды,
Сагынсагыз – ятыгыз.
Ят(ы)кан урыннарым калды,
Сагынсагыз – ятыгыз.

2004 елда Зөбәер авылында Гәрәев Хәниф Сәетгәрәй улыннан (1914 елгы) язып алынды. Әлеге җырны ул әнисеннән – Хәнифә Мөхәммәтлатыйп кызыннан (1882 елда Актаныш районының Адай авылында туган) отып калган, тик аның бер куплетын гына искә төшерә алды.

## 3. Авыл көе






1. Уйна талиян гармуныңны
Без(е)нең авыл көенә шул.
Шул авылым(ы)ның көенә
Күңел(е)ләрем сөенә.
Шул авылым(ы)ның көенә
Күңел(е)ләрем(е) сөенә.

2. Уйна, дустым, гармуның(ы)ны,
Син матур уйнатасың.
Уйнатасың, җырлатасың,
Күңелемне юатасың.
Уйнатасың(ы), җырлатасың,
Күңелемне юатасың.

2004 елда Түке авылында Солтанов Мэльс Асылгәрәй улыннан (1940 елгы) язып алынды. Ул аны үзе хромкада уйнап башкарды. «Элегрәк аны яшьләр урамда, яланга кич җыелып җырлыйларые. Мәҗлесләрдә дә бик яратып җырлый торган иделәр, хәзер генә ташланды, күбесенчә олылар гына җырлый аны», – ди Мэльс әфәнде. Аның фи-

керенчә, бу көй кыска көйләргә тартым, чөнки «*анда такмаклар җырлана: береңә-береӊ җырлап каршы, сүз белән җавап бирәләр шулай*». Ә *озын көй* ул – *урам көе, «Шахта көе»* булды.

### *4. Герман көе*






1. Болыннарда чәчәкләр күп,
Сарыларын алмагыз.
И балалар, аналарны
Кайгыларга салмагыз.

2. Киләә, китә, гүләйт итә
Камаларда парахут.
Мәңге сүнмәс утлар булмас,
Сүнәр әле бер вакыт.

3. Сары сандугач баласын
Кулларымда уйнатам.
Килер бер көн, күр[е]шер(е)без дип,
Күңелемне юатам.

4. Болыннарда әрәмә,
Әрәмәдә камырлык.
Ике балам чит җирләрдә,
Бирсен Ходай сабырлык.

5. Һаваларда кош тавышы,
Әллә алар китәме?
Күңелләрең нигә боек,
Балаларың читтәме?

2004 елда Түке авылында Фәтхиева Лүфә Зәки кызыннан язып алынды. Ул 1940 елда Минзәлә районы Тау асты Байлар авылында туган, 1966 елдан бирле Түке авылында яши. Рус теле һәм башлангыч мәктәп укытучысы булып эшләгән. Текстның 2 нче куплеты – әтисенең җыры, калганнарын, балаларын сагынып, үзе чыгарган.

Көй вариантлары: Музафаров М., Виноградов Ю., Хайруллина З. Татарские народные песни / Ред. А. Абдуллин. – М., 1964. – № 28; Ключарев А. Татар халык җырлары. – Казан, 1986. – Китап 1. – № 60.

### *5. Көтәм әле*

а)






б)




1. Билендәге сары каеш
Әл[е] дә билендә микән?
Үле микән, тере микән(е),
Раниллары каты булып
Әллә п(е)линдә микән?
Үле микән, тере микән(е),
Раниллары каты булып
Әллә п(е)линдә микән?

2. Көтмә, кызый, сөйгәнеңне,
Кайт(ы)мый туган иленә.
Сугышның киң кырларында,
Җимерек окуп буйларында
Пуле тигән иңенә.
Сугышның киң кырларында,
Җимерек окуп буйларында
Пуле тигән иңенә.

3. Көтәм әле, көтәм әле,
Көтәм әле үлгәнче.
Үлде диеп, күмдек диеп,
Ваянкамат өстәленә
Повисткысы килгәнче.
Үлде диеп, күмдек диеп,
Ваянкамат өстәленә
Повисткысы килгәнче.

2004 елда Түке авылында Солтанова Гөлрәйхан Әгъләм кызыннан язып алынды. Җырчы 1936 елда элекке Калинин (хәзер – Мөслим) районына кергән Исәнсеф авылында туып үскән, 1957 елдан Түке авылында яши. Бу җырны ул бәләкәй чагында әниләреннән ишеткән. Аны Исәнсеф хатыннары, ирләре сугышка киткәч, атка атланып сабан сөрергә барганда җырлый торган булганнар.

Гөлрәйхан ханым җырны ике тапкыр башкарды. Беренчесендә, тавышын түбәнрәк алганга күрәдер, көйнең соңгы өлеше югарыга күчерелә. Мисал өчен ике вариантын да китерәбез.

Бу әсәрне башка басмаларда табып булмады.

## Уен җырлары, такмаклар

### *6. Уен җыры [Алмагачы көе]*






1. Ак алъяпкычлар бәйләдем
Билләремә таратып.
Һич бер(е)кемнәрне сөймәдем
Синең кебек яратып.

2. Аклы яулык, юка яулык,
Яраткан яулыккаем.
Яратмасам йөрмәс идем,
Яратам, яныккаем.

3. Алмалы паласыңны ла
Элеп куйдым киртәгә.
Сөя микән, сөйми микән,
Белермен әл[е] иртәгә.
Сөя микән, сөйми микән,
Белермен әл[е] иртәгә.

4. Кулымдагы йөзегемнең
Исемкәйләре Фоат.
Теләгән кешеләр сөйсен,
Минем куллардин азат.
Теләгән кешеләр сөйсен,
Минем куллардин азат.

2004 елда Зөбәер авылында Ямалетдинова (Госманова) Гөлчирә Госман кызыннан (1931 елгы) язып алынды. *«Аулак өйләрдә, бичерларда да җырлый торганыек, кара-каршы утырып».*

«Алмагачы» көе – иң таралган һәм халык тарафыннан яратылып башкарылган көйләрнең берсе. Җ. Фәйзи аны юкка гына «көйләр солтаны» дип атамаган. Көй вариантларын төрле җыентыкларда күрергә мөмкин.

### *7. Уен җырлары*



1. Күфәйкәләре яшел,
Уеннарны ямьләп тора,
Их, үзебезнең нәсел.

2. Сандугач күгәрчен булмый,
Аралаш төзелсә дә.
Бер айрылгач күр[е]шеп булмый,
Үзәкләр өзелсә дә.

2004 елда Түке авылында яшәүче Гыйльметдинова Рәвидә Әбелгасан кызыннан язып алынды. Башкаручы 1937 елда Актаныш районының Усы авылында туган. Аның сөйләве буенча, биредә китерелгән үрнәк – түгәрәк уен җырының такмак өлеше (аны яланда әйләнеп, җырлап бии торганнар иде).

### *8. Уен такмаклары*




1. Тимерчыбык, нечкә чыбык
Сынмаса ярар иде.
Биле нечкә, үкенечкә
Булмаса ярар иде.

2. Алыйк әле, басыйк әле
Амирика туласын.
Алыйк әле шуның ярын,
Бер утырып еласын.

3. Зәңгәр чиләк матур була,
Су белән тулса гына.
Ярны яр дип сөеп була,
Сүзендә торса гына.

2009 елда Уразай авылында Саматова Кадрия Шәрип кызыннан (1939 елгы) язып алынды (Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фонды).

### *9. Аулак өйдә ишек аша такмак әйтешү*



Егетләр: Кунакка килдек сезгә,
Кызлар, ишек ачыгыз.

Кызлар: Керерсез безнең янга,
Ике булса башыгыз.

Егетләр: Буш килмәдек сезнең яңга,
Күчтәнәч белән килдек.

Кызлар: Оста башлар, безнең бәлеш
Икәнен инде белдек.

Егетләр: Исән-имин бәлешегез,
Шаярып кына алдык.

Кызлар: Бирмәсәгез дә була,
Тагын яңаны салдык.

Егетләр: Бергәләп күңел ачарбыз,
Кертегез инде безне.

Кызлар: Тәртипле генә булыгыз,
Кертәбез инде сезне.

2004 елда Зөбәер авылында Хәбибуллина Светлана Фатыйх кызыннан (1946 елгы) язып алынды. Аулак өй көнне малайлар бәлешне урлап чыгып киткәннәр, аннан соң, кызлар кич җыелып утыргач, ишеккә шакып: «Кертегез безне, тәмле әйбер ашатабыз» – дип, теге бәлешне кире керткәннәр. Килгәч, ишек төбендә басып, кызлар белән ишек аша такмак әйтешкәннәр. Шуларны С. Ф. Хәбибуллина башкарып күрсәтте. Бу хәл 1962–1963 еллар тирәсендә Башкортстан Республикасының Илеш районы [Иске] Татыш авылында булган.

Көй «Челтәр элдем читәнгә» яисә «Яшьләр уены» исеме белән мәгълүм. Вариантларын карагыз: Музафаров М., Виноградов Ю., Хайруллина З. Татарские народные песни / Ред. А. Абдуллин. – М, 1964. – № 88; Ключарев А. Татар халык җырлары. – Казан, 1986. – Китап 2. – № 38.

## Бишек җырлары

### *10. Бишек җыры (курчакларны йоклату)*



1. Йокла, балам, бәү ит,
Тиз генә йоклап кит.
Тыңла әниең сүзен,
Син бит акыллы бит.

2. Йокла, балам, елама,
Әтиең эшкә китә.
Тәмле ашлар пешереп,
Әниең аны көтә.

3. Әлли-бәлли,
Әлли-бәлли, бәбием,
Син бит минем тәтием.

2004 елда Зөбәер авылында Хәбибуллина Светлана Фатыйх кызыннан (1946 елгы) язып алынды. Аның әйтүенчә, *«безгә бабайлар бәләкәй генә кәрҗиннәр үреп бирәләрие талдан. Курчакларны шуңа салып, аларны йоклатадырыек без көйләп-көйләп».*

Көй башка җыентыкларда очрамый.

### *11. Бишек җыры (оныкларны йоклату)*






1. Әлли-бәлли, бәү итә,
Кызым йокыга китә.
Кызым йокыга киткәч,
Нәнәсе[1] чыгып китә.

2. Аннан кәрҗинен ала,
Җиләк җыярга бара.
Анда аю юк икән,
Җиләкләре күп икән.
Җиләк җыям, как коям
Айгөлемә бүләккә.

2004 елда Зөбәер авылында Хәбибуллина Светлана Фатыйх кызыннан язып алынды. Монысы оныкларны тирбәткәндә җырлана. «*Малайларны йоклатканда, аларның исемнәрен (Руслан, Илдар) куша идем*», – ди Светлана ханым. Әлеге көй – алдагы «Бишек җыры»ның варианты.

## Мөнәҗәтләр, китап көйләре

### *12. Муса мөнәҗәте*




[1] Нәнәй – оныкларның әбисенә эндәшүе.


2. Йә, бе-р(е) Хо - дам, Раб - бым, Ал - лам,
Бу - лы-р(ы) ми - кән о-ж(ы)-мах ми - ңа?
О-ж(ы)-ма-х(ы) бу - лыр си - ңа, Му - са,
О - ж(ы)-мах
Кыз ту - га - ның ра - зый бул - са.
3. Йә, бе-р(е) Хо - дам, Раб - бым, Ал - лам,
Бу - лы-р(ы) ми - кән о-ж(ы)мах ми - ңа?
О-ж(ы)-ма-х(ы) бу - лыр си - ңа, Му - са,
Ир ту - га - ның ра - зый бул - са.
4. Йә, бе-р(е) Хо - дам, Раб - бым, Ал - лам,
О-ж(ы)-ма-х(ы) бу - лыр ми - кә-н(е) ми - ңа?
О-ж(ы)-ма-х(ы) бу - лыр, си - ңа Му - са,
Күр - ше - лә - рең ра - зый бул - са.
Күр - ше - (е)–




1. И бер Ходам, Раббым, Аллам,
   Булыр(ы) микән миңа ож(ы)мах?
   Ожмах(ы) булыр сиңа, Муса,
   Әткәң-әнкәң разый булса.
   Ож(ы)мах(ы) булыр сиңа, Муса,
   Әткәң-әнкәң разый булса.

2. Йә, бер(е) Ходам, Раббым, Аллам,
   Булыр(ы) микән ож(ы)мах миңа?

Ож(ы)мах(ы) булыр сиңа, Муса,
Кыз туганың разый булса.
Ож(ы)мах булыр сиңа, Муса,
Кыз туганың разый булса.

3. Йә, бер(е) Ходам, Раббым, Аллам,
Булыр(ы) микән ож(ы)мах миңа?
Ож(ы)мах(ы) булыр сиңа, Муса,
Ир туганың разый булса.
Ож(ы)мах(ы) булыр сиңа, Муса,
Ир туганың разый булса.

4. Йә, бер(е) Ходам, Раббым, Аллам,
Ож(ы)мах(ы) булыр микән(е) миңа?
Ож(ы)мах(ы) булыр сиңа, Муса,
Күршеләрең разый булса.
Ож(ы)мах(ы) булыр сиңа, Муса,
Күрше(е)ләрең разый булса.

5. Йә, бер(е) Ходам, Раббым, Аллам,
Ож(ы)мах(ы) булыр микән(е) миңа?
Ож(ы)мах(ы) булыр сиңа, Муса,
Гарип(е)-горәбәң разый булса.
Ож(ы)мах(ы) булыр сиңа, Муса,
Гарип(е)-горәбәң разый булса.

6. Йә, бер(е) Ходам, Раббым, Аллам,
Ож(ы)мах(ы) булыр микән(е) миңа?
Ож(ы)мах(ы) булыр сиңа, Муса,
Һәммәсе дә разый булса.
Ожмах(ы) булыр сиңа, Муса,
Һәммәсе дә разый булса.

2004 елда Зөбәер авылында Хәбибуллина Светлана Фатыйх кызыннан (1946 елгы) язып алынды. Мөнәҗәтне ул үзенең әбисе Ягъфәрова Сөхбиямалдан отып алган булган. 6 строфада да текст бер үк төрле диярлек (соңгы юлларның башында гына үзгәрә). Әмма халык җырчысы аны һәрберсендә төрлечә (йә көйне үзгәртеп, йә сүзләрнең яңгырашын төрлеләндереп, йә бу элементларның икесен бергә яңартып) башкара. Шуңа күрә әсәр тулысынча китерелә.

Мөнәҗәт тантаналы һәм җитди яңгырый. Мондый сыйфатка ирешү өчен, иҗекләрне көйләгәндә авазлар еш кына аерымрак сыман башка-

рыла. Шуның нәтиҗәсендә *кыз ту-га-ның* урынына – *кыз ту-(у)-га-(а)-ның*, *күр-ше-лә-рең* урынына *күр-ше-(е)-лә-(ә)рең* барлыкка килә. Әлеге үзенчәлек ноталар өстенә сызыкчалар куеп күрсәтелгән. Бу очракта лига тоташ, өзмичә җырларга кирәклеген түгел, ә метрик өлешне белдерә.

Текст вариантлары (башка көйләре белән): Хөснуллин К. М. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр: Көйләп укуга нигезләнгән жанрлар. – Казан, 2001. – Б. 42, 646–647; Нурлат районының татар җырлары / Төз. З. Н. Сәйдәшева. – Казан, 2001. – № 5; Татар Каргалысы җырлары / Төз. Е. М .Смирнова. – Казан, 2007. – № 10.

## *13. Менә шундый заман җитәр*



1. Укулары нәүбәт белән,
Хезмәтләре сәгать белән,
Ризыклары үлчәү белән –
Менә шундый заман җитәр.
Ризыклары үлчәү белән –
Менә шундый заман җитәр.

2. Бала-чага алдан барыр,
Халык бетәр, булыр ял(ы)ган,
Гавәм хал(ы)кы бар[ы] да
аз(ы)ган –
Менә шундый заман җитәр.
Гавәм хал(ы)кы бар[ы] да
аз(ы)ган –
Менә шундый заман җитәр.

3. Хатын-кыздан хая китәр,
Ирләрендә гайрәт бетәр,
Балалардин рәхим бетәр –
Менә шундый заман җитәр.

4. Хатын-кызда өмет бетәр,
Хәмер эчер, зина кылыр,
Өммәтләре зәгыйфь булыр –
Менә шундый заман җитәр.

5. Биналары биек булыр,
Эче тулы зиннәт булыр,
Дин догасы бозык булыр –
Менә шундый заман җитәр.

6. Атасыз бала күп булыр,
Маллы кеше саран булыр,
Мәҗлесләрдә хәмер булыр –
Менә шундый заман җитәр.

2004 елда Зөбәер авылында Ямалетдинова Гөлчирә Госман кызыннан (1931 елгы) язып алынды. Башкаручы 3–6 строфаларны көйләмичә генә укыды.

Шигъри вариантлар (башка көй белән): Хөснуллин К. М. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр: Көйләп укуга нигезләнгән жанрлар. – Казан, 2001. – Б. 230–232, 664; Татар Каргалысы җырлары / төз. Е. М. Смирнова. – Казан, 2007. – № 21.

### *14. Мөхәммәткә салават*






1. Төннәр(е) ятып йокламады
Гыйбадәтле Мөхәммәт.
Аллаһымә сәли галә,
Сәйединә Мөхәммәт.

2. Юлдан(ы) язган бәндәләр(е)гә
Юл күрсәтте Мөхәммәт.
Аллаһымә сәли галә,
Сәйединә Мөхәммәт.

3. Ураза намаз тотканнар(ы)га
Рәх(е)мәтле ул Мөхәммәт.
Аллаһымә сәли галә,
Сәйединә Мөхәммәт.

2004 елда Зөбәер авылында Ямалетдинова Гөлчирә Госман кызыннан (1931 елгы) язып алынды.

Текст вариантын карагыз: Хөснуллин К. М. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр: Көйләп укуга нигезләнгән жанрлар. – Казан, 2001. – Б. 18.

## *15. Бәдәвам*


♪ = 180
1. Хөл - лә тун - на-р(ы) ки - яр - ләр,
Пар ат - лар - га ме - нәр - ләр,
Хур кыз - ла - рын ко - чар - лар,
Ал - ла ди - ге-л(е) бә - дү - вам.
2. И - ман бел - мәс ха - тын - нар,
Ир - гә бар - са һәм а - лар
И-р(е)-не хә - рәм - дер а - лар,
Ал - ла ди - ге-л(е) бә - дү - вам.
3. И - се - рек - кә сә - ләм бир - мә,
Ул бир - сә дә син ал - ма,
А - нар ку - лың - ны суз - ма,
Ал - ла ди - ге-л(е) бә - дү - вам.

1. Хөллә туннар(ы) киярләр,
Пар атларга менәрләр,
Хур кызларын кочарлар,
Алла дигел(е) бәдүвам.

2. Иман белмәс хатыннар,
Иргә барса һәм алар
Ир(е)не хәрәмдер алар,
Алла дигел(е) бәдүвам.

3. Исереккә сәләм бирмә,
Ул бирсә дә син алма,
Аңар кулыңны сузма,
Алла дигел(е) бәдүвам.

2004 елда Зөбәер авылында Ямалетдинова Гөлчирә Госман кызыннан (1931 елгы) язып алынды. Бу әсәрне көйләп укырга ул әнисеннән – Госманова Әминә Илдархан кызыннан өйрәнгән булган.

Әлеге көйнең үзенчәлеге өченче юлны бер өлешкә кыскартудан гыйбәрәт (нәтиҗәдә, 4/8 һәм 3/8 үлчәм алмашы барлыкка килә).

## III. ШИГЪРИ ТЕКСТЛАР

## Уен такмаклары

### *1. Кичке уен такмаклары*

1. Без дә төштек уенга,
Сез дә төшкәнсез икән.
Кара-каршы җырлаганда,
Безне узарсыз микән?

2. Матур күлмәк кигәнсез,
Ак алъяпкыч япкансыз.
Безнең якка карамыйсыз –
Әллә башканы тапкансыз.

3. Егет асылы булсагыз –
Үпкәләмәгез безгә.
Җырларбыз да, биербез дә,
Такмак әйтербез сезгә.

4. Уйныйк әле бергә-бергә,
Сызылып таңнар атканчы,
Вахит бабай сыерларга
Сыбыркы шартлатканчы.

5. Газиз, кичә кая бардың
Көянтә-чиләк асып?
Кемнән шулай ояласың,
Йөрисең качып-посып?

6. Әй Зөһ(е)рә, олы авыз,
Миннән көлгән буласың.
Йокы чүлмәге бит үзең –
Абит җиткәч торасың.

7. Камил кигән буйлы ыштан,
Каптырмасы юк бугай.
Кызлар артыннан күп чабып,
Ыштансыз калган бугай.

8. Камилә дә төшкән булган,
Битен-күзен буяган,
Авызын ача да исни –
Әллә йокысы туймаган?

9. Хәләф тә йөр(е)гән була,
Озын буен селкетеп.
Йодрык төйнәп, маймылланып,
Кыз-кыркынны өркетеп.

10. Дамирә бии башласа,
Җир селкетә, чын әгәр.
Егетләр ерак тормаса –
Җиленнән үк тәгәрәр.

11. Шәрифне кызлар ярата,
Әллә кайдан таныйлар.
Кызларга димче җибәрә –
Тик кияүгә чыкмыйлар.

12. Шаярып-көлеп җырладык
Бу такмакларны бары.
Үпкәләшми таралышыйк,
Иртәгә килербез тагы.
[Иртәгә килик тагы.]

2004 елда Зөбәер авылында Хәбибуллина Светлана Фатыйх кызыннан (1946 елгы) язып алынды. *«Такмакларны әйткәндә, кара-каршы басалар да (егетләр – бер якта, кызлар – икенче якта), араларында кычкырып көләсең инде»,* – ди башкаручы.

### *2. Уен такмаклары*

1. Роза, Роза, Роза,
Лена, малина.
Оча, оча, куна, куна
Барыр идем янына.

2. Оча үрдәк, оча каз,
Тирән күлне ярата, ярата.
Илнара үзенә иптәш эзли,
Ул Илнурны ярата, ярата.

2004 елда Мөслим районының Исәнсеф авылында Камалетдинова Фәрсия Хәлфи кызыннан (1936 елгы) язып алынды. Башкаручы тумышы белән – Актаныш районының Пучы авылыннан. Әлеге такмакларны башкарганда парлап басалар да, кулларны болгый-болгый, уртадан уза торган кеше берсен алып китә.

## Балалар фольклоры

### *3. Бишек җыры*

1. Әлли-бәлли, бәү сиңа,
Җырларым җырлыйм сиңа.
Сандугачлар да җырларын
Багышлап җырлый сиңа.

2. Әлли-бәлли, бәллием,
Сөя әбиең синең.
Гүзәлләр гүзәле ул,
Сөя әбиең синең.
Тал тибрәткәндәй тибрәтер,
Әкият сөйләп юатыр.

2004 елда Исәнсеф авылында яшәүче Камалетдинова Фәрсия Хәлфи кызыннан язып алынды (1936 елда Пучы авылында туган).

### *4. «Үчти-үчти» иттерү*

Үчтеки, үчтеки,
Улым әле кечкенти.
Менә тиздән зур үсәр,
Кулдан идәнгә төшәр.
Ийеме, улым?

Тәпи, тәпи дә атлар,
Мәктәпкә йөри башлар.
Егет булыр аннары,
Армияга да барыр,
Безгә аннан көн саен
Сәлам хатлары салыр.

2004 елда Зөбәер авылында Хәбибуллина Светлана Фатыйх кызыннан (1946 елгы) язып алынды. «*Көйли-көйли, такмаклап әйтәм, кулда сикертеп әйтәм», –* ди аны Светлана ханым.

## Санамышлар

***5.*** Бер, ике, өч,
Син калып тор,
Ә син – оч.

***6.*** Бер дүдәк, ике дүдәк,
Ә син – үрдәк.
Үрдәк кала,
Дүдәк моннан тая.

*7.* Бер каз, ике каз,
Өченчесе – таз.
Таз, син кал,
Каз, кит тә, бар.

***8.*** Бер, ике, өч, дүрт, биш,
Алтынчысы чыгып китә ич.
Бүген кайтып тор,
Килерсең иртәгә кич
[Иртәгә килерсең кич].

2004 елда Зөбәер авылында Хәбибуллина Светлана Фатыйх кызыннан (1946 елгы) язып алынды. Башкаручының аңлатуы буенча, «*кызу әйтәләр, ишетмичә калсаң – җәза бирәләр. Парлашып уйный торган уеннар була торганые, менә шундый вакытта парларны табышу өчен санашып алабыз»*.

Биредә урнашкан санашу үрнәкләре башка басмаларда очрамады.

## Башкаручылар иҗат иткән әсәрләр (шигырьләр, мөнәҗәтләр)

### *9. Мөнәҗәт*

1. Яна бәгърем, уты сүнмей,
Бер кайгысыз кеше булмый,
Бу кайгыдан бәндә үлмей –
Сабырлыклар бирсен Алла.

2. Сыңар канатларым сынды,
Нишләргә соң, туганнарым?
Кемнән киңәш сорыйм микән?
Сабырлыклар бирсен Алла.

3. Аерылдык – сизми калдым,
Бу хәлләргә ышанмадым,
Күңелемә җара салып
Китәрсең дип уйламадым.

4. Исемнәрең Хаякаем
Ташта гына калды инде хәзер,
Ничек кенә эзләсәм дә –
Таба алмам инде сине хәзер.

5. Кавышканда сүз бирештек
Аерылмаска гомерлеккә,
Саубул, иркәм, күрешербез
Ахирәткә баргач кына.

6. Күршеләрем, туганнарым:
«Сабыр ит», – дип киңәш бирә,
Ничек итеп сабыр итим?
Сабырлыклар бирсен Алла.

7. Күңелләрем сине уйлый
Дәрья суын кичсәм дә,
Иртән торып сине көтәм
Шәфәкъ таңнар атканда.

8. Урамнарга чыксам – карап торам,
Күңелләрем сине эзлидер,
Күрә алмый сине кереп китәм –
Сабырлыклар бирсен Алла.

2004 елда Зөбәер авылында Гәрәев Хәниф Сәетгәрәй улыннан (1914 елгы) язып алынды. Бу әсәрне ул 53 ел бергә яшәгән Миңлехая исемле хатынына багышлап чыгарган. Көйгә салып укыды.

### *10. Ленар улыма багышлыйм*

1. Матур иде йөзләрең,
Зифа иде буйларың.
Сине эзлим, сине сагынам,
Синдә минем уйларым.

2. Ага сулар, ага сулар,
Акмас инде үрләргә.
Газиз улым, мине ташлап
Кереп яттың гүрләргә.

3. Җитте язлар, сине сагынып
Өзелә үзәккәем.
Бу кадәрле сагышлардан
Чыдармы йөрәккәем?

2004 елда Түке авылында яшәүче Фәтхиева Лүфә Зәки кызыннан (1940) язып алынды. Шигырь 2004 елда иҗат ителгән.

### *26. Ялгызлык моңы*

1. Агыйделне иңләп-буйлап
Йөзеп килә аккошлар.
Карт көнемдә ялгыз калдым,
Моңнандыра язмышлар.

2. Ялгызлыкны авыр диләр,
Белмим нәрсә диергә.
Ялгыз коштай моңаерга
Язган икән картлыкта.

3. Кояшларда киеп йөрмә
Ал күлмәгең – уңмасын.
Башкайларың картайгачтин
Минем кебек булмасын.

4. Безнең яктан кошлар килсә,
Тота алсаң – тотып кал.
Гүргә кергәч – бер укырсыз,
Бу сүзләрне язып ал.

5. Язгы сулар аккан чакта
Су буенда йөрмәгез.
Моны нигә язган диеп
Ачулана күрмәгез.

6. Аерылдым урманнарда,
Җир җиләкле аланда.
Бик ямансу була икән
Бер ялгызың калганда.

7. Утырмагыз машинага,
Машина алып китә ул.
Ышансаң да балаларга,
Сине ялгыз итә ул.

8. Челтерәп аккан су буенда
Таллар тамырсыз икән.
Бер анасын ташлап киткән
Бала бәгырьсез икән.

9. Биек тауның башларында
Чәнечкеле гөлҗимеш.
Балалар аякка баскач –
Мин кирәк түгел имеш.

10. Ындыр артларыннан ага
Көмеш сулы бер инеш.
Аналар белән яшәүнең
Кирәге беткән имеш.

11. Тал бөресе, тал бөресе,
Тал бөресе каенда.
Бер төне дә елга тора
Шул сагынган чагында.

12. Безнең турда су буенда
Шаулап үсә бер тирәк.
Чыгып киткән ир баланың
Кайтулары бик сирәк.

13. Карурмандагы аланның
Уртасында бер балан.
Карт көнемдә карт анасын
Ташлап китте бар балам.

14. Чәчелеп үскән, чәчелеп
төшкән
Түтәлләрдә бер йөзем.
Ялгыз тор[а] алмам дисәм дә,
Гомерем уза бер үзем.

15. Уйлый күңелем, уйлый
күңелем
Кичен дә, иртәсен дә.
Кычкырып җырлап җибәрәм
Җиде төн уртасында.

16. Минем кебек моңланадыр
Урманда кара каен.
Каргасам – табар каргышым,
Каргамыйм, балаларым.

17. Кулым тисә – бакчаларда
Саргая кызыл балан.
Аңнарсың минем хәлләрне
Картайгач кына, балам.

18. Айкаладыр, чайкаладыр
Су буенда бөдрә тал.
Мин үлгәч тә сүзләремне,
Балакаем, искә ал.

19. Җырлыймын да, елыймын да,
Күңелем биг[е]рәк моңны шул.
Җырламыйча төннәремне
Уздырыплар булмый шул.

20. Җыр җырлап та җиңел генә
Таң аттырып булмый шул.
Уф дип алам тыннарымны,
Аны бала белми шул.

21. Языйм әле, языйм әле
Эчем пошкан чакларда.
Балаларны бик сагынам
Кич ямансу чакларда.

*28.02. 1994 ел*

2004 елда Түке авылында Газизуллина Саһира Тимершәех кызыннан (1929 елгы) язып алынды. Информант әйтүенчә, ире «*Галимулла үлгәч чыгарган җырлар бу*». Автор әсәрне традицион мөнәҗәт көенә салып укыды.

## Мәгълүмат бирүчеләр исемлеге

### ***Түке авылы*** *(2004 ел экспедициясе)*

1. Газизуллина Саһира Тимершәех кызы (1929 елгы).
2. Ганиева Мәрзия Вагыйз кызы (1939 елгы), Алабуга районының Морт авылында туган.
3. Гыйльметдинов Фәхразый Мәүләветдин улы (1939 елгы).
4. Гыйльметдинова Рәвидә Әбелгасан кызы (1937 елгы), Мөслим районы Усы авылында туган.
5. Солтанов Мэльс Асылгәрәй улы (1940 елгы).
6. Солтанов Рифкать Бәхтигәрәй улы (1934 елгы).
7. Солтанова Гөлрәйхан Әгъләм кызы (1936 елгы), Мөслим районының Исәнсеф авылында туган.
8. Фәтхиева Лүфә Зәки кызы (1940 елгы), Минзәлә районы Тау асты Байлар авылында туган.

### ***Зөбәер авылы*** *(2004 ел экспедициясе)*

9. Гәрәев Хәниф Сәетгәрәй улы (1914 елгы).
10. Мусина Нәкыя Муса кызы (1918 елгы).
11. Мөхәммәтханова Латыйфа Мөхәммәтхан кызы (1910 елгы).

12. Нәбиева Сафия Салихҗан кызы (1920 елгы), Апач авылында туган.

13. Хәбибуллина Светлана Фатыйх кызы (1946 елгы), Яңа Богады авылында туган.

14. Ямалетдинова (Госманова) Гөлчирә Госман кызы (1931 елгы).

15. Ямалетдинов Зөфәр Ямалетдин улы (1929 елгы).

***Күҗәкә авылы** (2009 ел экспедициясе)*

16. Мөяссәров Мөхтәсәр (1926 елгы).

17. Хәйбиев Зәки Мөхәммәтгазиз улы (1934 елгы), Үмәнәй авылында туган.

***Уразай авылы** (2009 ел экспедициясе)*

18. Саматова Кадрия Шәрип кызы (1939 елгы).

***Карт авылы** (2009 ел экспедициясе)*

19. Нәгыймов Мәган Хәсән улы (1928 елгы).

***Мөслим районы, Исәнсеф авылы** (2004 ел экспедициясе)*

20. Камалетдинова Фәрсия Хәлфи кызы (1936 елгы), Актаныш районы Пучы авылында туган, 1957 елдан Мөслим районының Исәнсеф авылында яши.

21. Мәхмүтова Әдибә Сафа кызы (1942 елгы), Актаныш районы Кадермәт авылында туган, Исәнсеф авылында яши.

# ӘКИЯТ ДИГӘН ДӨНЬЯ БАР

*Илсөяр Закирова*

Хәзерге вакытта әкиятләр балалар жанры буларак кабул ителсә дә, алар озак гасырлар балаларга гына түгел, өлкәннәр өчен дә сөйләнелгән. Әкият сөйләүчеләрне бөтен кеше яхшы белгән, аларны хәтта күрше авылларда да көтеп алганнар. Бер яктан, вакытлыча гына булса да могҗизалы әкият дөньясына күчү кешегә бу тормыштагы авырлыклардан, дөнья мәшәкатьләреннән арынып яки онытылып торырга ярдәм иткән. Икенче яктан, әкиятләрдә үгет-нәсыйхәт, дидактика булмау, инсани-гуманистик идеяләр, яхшылыкның явызлыкны җиңеп чыгуы, һәрбер ситуациядән чыгу юлын табылу кешеләрдә үз-үзенә дә, киләчәккә дә ышаныч, өмет уяткан. Татар халкында чичәнҗырау традициясе күренеш буларак күптән юкка чыкса да, оста әкиятчеләрне һәр татар авылында очратырга мөмкин. Актаныш районында узган экспедиция вакытында да шактый гына әкиятләр язып алынып, шул елларда авылларда шактый гына әкиятчеләр булуы, әкият сөйләү традициясенең дәвам итүе ачыклана.

Институтның Хәмит Ярми җитәкчелегендәге фольклор экспедициясе Татарстан АССРның Актаныш, Калинин һәм Мөслим районнарында 1948 елның июнь-июль айларында эшли (Калинин – 1935–1959 елларда хәзерге Актаныш һәм Мөслим районнарыннан кушылып формалашкан, соңыннан шушы районнарга бүленгән район. Бу мәкаләгә Калинин районында тупланган материаллар да кертелде). Экспедициядә Институтның ике галиме – экспедиция җитәкчесе Хәмит Ярми һәм Халидә Гатина,

Казан Дәүләт университетының ике студенты – киләчәктә тарихи романнар авторы булып танылачак Нурихан Фәттах һәм танылган язучы Гариф Ахуновның булачак тормыш иптәше язучы һәм тәрҗемәче Шаһидә Максудова катнашалар. Бу мәкаләдә әлеге экспедиция вакытында язып алынган әкиятләр турында сүз бара.

Әкиятләр – халык иҗатының иң борынгы эпик жанрларыннан берсе. Могҗизалы яки фантастик уйдырмага корылган әкиятләр, чынбарлыкны иҗади хыяллар белән үреп тасвирлаулары, халыкның матурлыкка, гаделлеккә омтылышын чагылдырулары белән дә, сәнгати-эстетик функцияләре ягыннан да фольклорда үзенчәлекле урын тоталар. Галимнәр әкиятләрнең эчтәлеген өйрәнеп, образлар системасын тикшереп, аерым мотивларны анализлап, бу төр иҗатның барлыкка килә башлавын кешелек җәмгыятенең бик борынгы дәверенә, ыруглык җәмгыятенең җимерелүгә йөз тотуы чорына нисбәт итәләр. Табигатьнең һәм әйләнә-тирәнең серләренә төшенә барган саен, кешелекнең дөньяны танып белүгә юнәлтелгән карашларының үзгәрә баруы, мифологик ышануларның нигезендә фантазия ятуын аңлау, яңа карашлар барлыкка килү, ыруглык җәмгыятендә формалашкан мифларның әкияткә әверелүенә этәргеч биргән. Әкиятләргә хәрәкәт, динамика хас, аларда маҗаралылык көчле. Уңай герой белән аның дошманнары арасындагы каршылык кискен төстә гәүдәләнә. Әкият текстларының композицион төзелеше дә үзенчәлекле. Жанрның классик үрнәкләре төзелеше норматив характерда: күләмле текст, кагыйдә буларак, төп геройның эш-хәрәкәтен, көрәшен чагылдырган функция-мотивлар тезмәсеннән тора, текстның традицион башлам һәм бетем өлешләре була.

Татар әкиятләрендәге капма-каршы куеп тасвирланган ике дөнья – бу дөнья белән теге дөнья (җир асты дөньясы), каһарманның могҗизалы маҗаралары һәм тылсым көченә таянып явыз мифик көчләргә каршы көрәше, мифологик ышануларга нигезләнеп иҗат ителгән мотивлар һәм образлар системасы бу жанрның борынгы чорда барлыкка килүе турында сөйли. Ягъни әкиятләр кешенең үз әйләнә-тирәсендәге вакыйгаларны,

табигатьтә булып торган хәлләрне аңларга, белергә омтылуы нигезендә иҗат ителгәннәр. Шулай да тылсымлы әкиятләрнең жанр төре буларак формалашу чоры борынгы заманнарга нисбәт ителсә дә, әкиятләр арасында, әкият традицияләренә һәм жанр кысаларына туры китереп, чагыштырмача соңрак ителгән әсәрләр дә аз түгел. Мәсәлән, тормыш-көнкүреш әкиятләре чагыштырмача яшь жанр төренә карый. Тылсымлы әкиятләр, жанр буларак формалашканнан соң, гасырлар дәвамында иҗат ителә. Бу әсәрләрдә традицион эчтәлеккә халыкның феодаль җәмгыятьтәге тормышын, иҗтимагый-социаль мәсьәләләрне, төрле катламнарны, хөкемдар образын бәян иткән яңа мотивлар өстәлгән. Татар әкиятләре арасында халыкара сәүдә, солдат хезмәте, юлбасарлар, бәхет яки эш эзләп читкә чыгып китүчеләр турындагы сюжетларга караган әсәрләр шактый соң чорларга карый.

Әкиятләрнең иҗтимагый-эстетик функцияләренә килгәндә, алар һич тә тыңлаучыларны яки укучыны могҗиза һәм тылсым дөньясына, гадәттән тыш хәлләр стихиясенә алып керү, мавыктыру белән генә чикләнми. Чөнки «хыял һәм фантазия белән өретелгән һәрбер әкиятнең тирән тормышчан мәгънәсе бар, алар кешене олы тормышка әзерли. Әкиятләрне фольклорчылар гына түгел, этнографлар, психологлар, тарихчылар, философлар да өйрәнә. Галимнәр, әкиятләрнең әлегә кадәр ахырынача ачыкланып бетмәгән көчен танып, бала көткән аналарга да әкиятләр укырга киңәш бирәләр. Бу, әкиятләрнең гадәти мавыктыргыч хикәятләр генә булмыйча, зур ышану көченә дә ия әсәрләр икәнлеген раслап тора. Әкият тыңлап, дөньяда яхшылык җиңүенә, аның куәтенә ышанып туган һәм үскән бала үз көченә таяна, көчле һәм сәламәт була. Әкиятләр баланы яхшылык белән явызлык арасында барган көрәштә яхшылык җиңүенә ышандыралар. Тормыш киртәләренә каршы көрәшкә әзерлиләр. Әкиятләрдә күп катлы кодлар рәвешендә борынгыларның тәҗрибәсе, алдагы буыннарга да юнәлдерелгән белеме саклана. Мәсәлән, фольклорчылар дию образын үлем дөньясы белән бәйләп караганда, психологлар бу образда борынгы кешенең куркуы гәүдәләнгәнлеген күрәләр, әкият героеның диюне җиңүе – кешенең акыл көче белән курку хисен җиңәргә омтылуы рәвешендә кабул ителә.

1948 елгы экспедиция вакытында Актаныш районында 30 дан артык әкият язып алына (әкиятләрнең төгәл санын күрсәтү мөмкин түгел, чөнки кайбер текстлар архивка тапшырылмаган булырга да мөмкин. Мәсәлән, «Каракош» әкияте экспедициядә катнашкан галим Халидә Гатинаның шәхси архивында сакланган). Тупланган текстлар арасында тылсымлы әкиятләр дә, тормыш-көнкүреш әкиятләре дә, хайваннар турындагы әкиятләр дә бар. Аерым бер жанр буларак карала ала торган алдавыч әкиятләр дә шактый очраган. Алдавыч әкиятләр, исемнәреннән үк күренгәнчә, кешеләрне, кагыйдә буларак, вакытлы-вакытсыз әкият сораган бабалаларны шаяртып сөйләнелә. Шактый гына алдавыч әкиятләрне Иске Байсар авылының ТБУМ (Тулы булмаган урта мәктәп) директоры, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сәфәргалин Әхәт (1948 елда 44 яшендә) үзенең укучыларыннан язып алган һәм экспедициягә килгән фольклорчыларга үзе туплаган такмазалар белән алдавыч әкиятләр дә тапшыра. Мәсәлән, әлеге укытучы тапшырган дәфтәрдә мондый алдавыч әкиятләр очрый:

*Бар иде бер патша, ярдырды ди такта, салдырды ди капка, ясатты ди бик зур бакча. Чәчтерде ди җимеш. Каравылчы куйды ди, имеш. Иртә белән торып караса, бернинди җимеш тә юк ди, имеш. (Лотфуллина Гөлзар)*

*Әүвәл заманда, кәҗә команда булганда, булган, ди, бер ирле-хатынлы кешеләр. Аларның булган, ди, бер ак кәҗәсе. Ул кәҗәнең бар җире дә булган, ди, ак. Башы да ак, колагы да ак, тәпие дә ак, калганын үзең сөйләп бак! (Гәрәева Нәгыймә)*

*Борын-борын заманда булган, ди, бер йозак. Мин сөйләр идем ул йозакны, аны сөйләү бик озак. (Хәйбрахманова Зәмзәмия)*

*Әүвәл заманда булган, ди, бер карт белән карчык. Аларга кое бик ерак булган ди. Алар уйлаганнар, ди, мич башында кое казырга. Мендергәннәр, ди, таш өстенә таштан, сөйлимме баштан. (Басыйрова М.)*

Тылсымлы әкиятләр – сюжет составы ягыннан да катлаулы жанр. Теләсә кайсы тылсымлы әкият берсе икенчесен ачыклап килгән мотивлар тезмәсеннән тора. Тылсымлы әкиятләрдә сюжетның төп шарты булган конфликт һәрвакыт дәлилләнә.

Геройның эш-гамәлләре аның үзенә яки гаиләсенә зыян салган дошманга каршы көрәшүгә, ниндидер тылсымлы предметны яки кәләш эзләүгә, гаилә коруына юнәлтелгән була. Шуңа бәйле рәвештә тылсымлы әкиятләрдәге вакыйгалар барышын шартлыча өч өлешкә бүләргә мөмкин: геройның чыгып китүе, маҗаралары, дошман як белән көрәше һәм ахырда, максатына ирешеп, кире кайтуы.

Геройның өеннән чыгып китүенең максаты югалган яки урланган, табып китерелергә кушылган әйберне эзләү дә, Дию урлап киткән патша кызын, үзенең анасын коткару нияте дә, белем яки һөнәр алу максаты бәйләнешле булырга мөмкин. Тылсымлы әкиятләрдә герой үзенә кәләш эзләп яки патша кызына өйләнү максатында да чыгып китә. Үги ана куып чыгарган, я булмаса аның мәкере аркасында чит җиргә барып юлыккан геройлар да бар. Тылсымлы әкиятләрнең нигезендә геройның төрле маҗараларга юлыгуы, юлдашлар очратуы, ярдәмчеләр табуы, дошман як белән көрәше ята. Максатына ирешү өчен, әкият каһарманына авыр сынаулар үтәргә туры килә. Каршылыкларны җиңәргә, Дию яки Аждаһадан, шулай ук башка дошманнарыннан өстен чыгарга аңа тылсым куәтенә ия булган әйберләр һәм юлда очраган гайре табигый көчкә яки сәләткә ия юлдашлары ярдәм итә. Әкият геройның максатына ирешеп кәләш алып кайтуы яки киткән җирендә өйләнүе һәм патша булып тәхеткә утыруы белән тәмамлана. Күп кенә әкиятләрнең шул рәвешле тәмамлануы, әлбәттә, халыкның иллюзион карашы – гадел патша турындагы өмет-хыялы белән бәйләнгән.

Актаныш районында тылсымлы әкиятләргә караган «Алтын чүлмәк», «Каракош», «Яшьлек суы», «Урман каравылчысы», «Кыз патша», «Батыр егет» исемле әкиятләр язып алына. Бу әкиятләр «Татар халык иҗаты»ның «Әкиятләр» томнарында урын алган. Аеруча кызык тоелган берничә әкияткә тукталып үтик. «Алтын чүлмәк» әкиятен Татар Әҗбие авылында яшәүче 22 яшьлек Шәриф Закировтан Х. Ярми язып ала. Әлеге әкият татар халкына гарәп фольклорыннан кереп, аның сюжеты халыкка яхшы таныш. Әкиятне шартлы рәвештә икегә бүлсәк, беренче өлеше чагыштырма сюжет күрсәткечендәге «Чүлмәктәге

җен» дигән 311 номерга туры килә[1]. Бу барыбызга да таныш «Хоттабыч карт» әкиятенең варианты. Икенче өлеше, сюжет күрсәткечендәге «Сихерләнгән шәһәр» дигән 413 номерга туры килә, гарәп халкының «Мең дә бер кичә» исеме белән мәгълүм әкият җыентыгына кергән сюжет. «Алтын чүлмәк» әкияте татар халкының гарәп әкиятләре тупланган «Мең дә бер кичә» китабын яхшы белүен, бу текстларның халыклашуын күрсәтә. Иске Кормаш авылында Хәлисә Зиязовадан Х. Гатина язып алган Каракош әкиятенең сюжеты «Ал чәчәк» дигән 425 С номерга туры килә. Әкият әлеге мәгълүм сюжеттагы кебек кече кызның төшендә бер чәчәк күреп, әтисеннән шуны алып кайтып бирүен үтенүе белән башланып китә. Атасы, күп кенә киртәләрне үтеп, чәчәкне эзләп тапкач, кызын әлеге чәчәкнең иясенә – Каракошка бирергә вәгъдә бирә. Кызның, Каракошны хөрмәт итүен, сүзен тотуын белгәннән соң, кош егеткә әйләнә. Бу сюжет төрле вариантларда татар әкиятләрендә еш очрый. Әкият гаилә тормышы, ир белән хатын, кыз белән егет мөнәсәбәтләре турында шактый четерекле мәсьәлә күтәрә. Гаилә бәхетенең нигезе үзара хөрмәт, бер-берсенә ышану, юл куя белү кебек сыйфатлардан башлана, шул вакытта гына яныңдагы кеше, әкияттәге Каракош кебек, сиңа кирәк һәм кадерле кешегә әйләнә. Иске Кормаш авылында Насыйр Фәттәховтан Х. Ярми язып алган «Урман каравылчысы» әкияте «Тылсымлы балдак» дигән 560 номерлы сюжетка корылган. Әкият герое ике диюнең сугышканын күреп, берсенә ярдәмгә килә. Татар фольклорында бу мотив еш очрый. Диюләр, егеткә рәхмәт белдереп, тылсымлы көзге бүләк итәләр. Егет, шушы көзге ярдәмендә авырлыкларны җиңеп чыгып, патша кызына өйләнә.

Институтның архивында экспедиция материаллары гына түгел, аерым кешеләр язып җибәргән әкиятләр да саклана. Шундый әкиятләрнең берсе Актаныш районы Затон Дербёшка поселыгында яшәгән Андров Александр Никифорович язып җибәргән «Батыр егет» әкияте. Бу әкият татар халкында дастан

[1] Сравнительный указатель сюжетов. Восточнославянская сказка / сост.: Л. Г. Бараг, И. П. Березовский, К. П. Кабашников, Н. В. Новиков. – Л.: Наука, 1979. (сюжетлар алга таба да шушы сюжет күрсәткече нигезендә күрсәтелә)

жанрының XX йөз башына кадәр килеп җитүен исбатлый торган әсәр. Ул – төрки халыкларның уртак мирасы «Алпамыш» дастанының әкиятләшкән варианты.

Актаныш районында язып алынган әкиятләр, – нигездә, күп халыкларда мәгълүм әкиятләрнең вариантлары. Бары «Серле чүлмәк» әкиятенең сюжеты гына башка әкиятләрдә очрамый. Бу әкият халыкка язма чыганаклардан, китап аша кергән.

Актаныш районында тормыш-көнкүреш әкиятләре дә, эчтәлекләре белән тормыш-көнкүреш әкиятләренә якын торган Хуҗа Насретдин мәзәкләре дә язып алынган. Тормыш-көнкүреш әкиятләре тематик яктан да бай. Аларда кешенең шәхси тормышы, көндәлек вакыйгалар, язмыш һәм язмышны үзгәртеп булмау, төрле кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, өйләнү, кияүгә чыгу, кәләш сайлау, кияү яки кәләшне сынау, хыянәт яки чит хатынга күз салган бозык байны акылга утырту, алдакчылар, тапкыр кешеләр, никах мөнәсәбәтләре турында сүз бара. Бу әкиятләрнең нигездә барлык персонажлары да – реаль тормыштан алынган геройлар: ир белән хатын, никахка кадәр мөнәсәбәтләрдә торучылар, аерылган гашыйклар, яла ягылган хатын яки кәләш, куылган ул яки кыз, гөнаһсызга рәнҗетелгән хатын, кардәшләр, туганнар, зирәк кешеләр, гашыйклар, егет белән кыз, ир белән хатын, кире, иркә, холыксыз, үткен һ.б. хатыннар, кыз һәм разбойниклар һ.б. Тормыш-көнкүреш әкиятләренә җен, дию кебек тылсымлы әкиятләргә хас персонажлар да килеп керә. Бу әкиятләргә фантастик элементлар килеп кереп, алар тылсымлы әкиятләр белән көнкүреш әкиятләре арасында торалар. Әлеге фантастик элементлар реаль чынбарлыкны тасвирлаганда, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләгәндә ярдәмгә киләләр. Фантастик элементлар белән «Кулсыз кыз» әкиятендә дә очрашабыз. Бу әкиятне Илчебай авылында 51 яшьлек Кәрам Афзаловтан Н. Фәттах язып алган. Гаепсезгә рәнҗетелеп яки яла ягылып, кулларын чабып ире тарафыннан куып җибәрелгән кыз турындагы сюжет (№ 706 «Кулсыз кыз»), күп халыкларга таныш. Кызны, яла ягып, өеннән куып чыгаралар, биләүдәге баласын да иңенә асалар. Иелеп су эчкән вакытта, кулсыз кызның биләүдәге баласы суга төшеп китә.

Шул чакта Алланың кодрәте белән кызга куллар үсеп, ул баласын тотып ала. Әкият кануннары буенча, барлык гаеплеләр җәзага тартыла, кызның гаепсез булуы ачыклана. Бу әкият явызлыкның, әшәкелекнең җиңелүен бәян итә.



Нурихан Фәттах.
Әкиятче карт портреты. 1948 ел

Зирәк кызлар турындагы әкиятнең вариантларын (сюжет № 875, Зирәк кыз») Татар Әҗбие авылында Шәрип Закировтан Х. Ярми, Куян авылында Мингали Абзаевтан Н. Фәттах язып алалар. Бу әкиятләр халык арасында бик популяр булып, төрле вариантлары билгеле. Барлык вариантларда да тапкыр кызлар кыенлыклар яки катлаулы сораулар алдында югалып калмыйлар, зирәклекләре белән теләсә кайсы сорауга җавап табалар. Алар аталарына патша яки бай белән ничек сөйләшергә, аның сорауларына ничек җавап бирергә, патшаның биремнәрен үтәргә өйрәтәләр. Мәсәлән, бер патша картка үти алмаслык шартлар куя: «Ач та килмә, тук та килмә; ялангач та килмә, кием белән дә килмә; атланып та килмә, җәяү дә килмә». Кызының киңәшен тотып, карт, патша янына ятьмәдән тегелгән кием киеп, кәҗә тәкәсенә атланып бара.

Бу әкияттә патша белән зирәк кыз кат-кат биремнәр, сораулар белән бер берсен сыныйлар. Патша кызга өч чирек җептән киндер сугып, күлмәк-ыштан тегәргә куша. Кыз үз чиратында патшага шырпы буе чыбык җибәреп, киндер сугу өчен стан ясап бирүне таләп итә. Патша җиде яшьлек сарык тәкәсен бәрәнләтү бурычын йөкләгәч, кыз патша килгән төшкә этисен мунчага «бәбәйләргә» җибәрә. Ахыр чиктә патша мондый табышмаклар белән кызны җиңә алмый һәм аңа өйләнә. Шулай итеп, әкияттә табышмаклар әйтешеп ярышу кинаяле формадагы никах килешүе булып аңлашыла.

Зирәк кызлар турындагы әкиятләр кайбер вариантында аларның зирәклеге, тапкырлыклары белән бәхәсләрдә өстен чыгуы, авыр хәлләрдән котыла алулары турында сүз бара. Мәсәлән, Шәрип Закировтан язып алынган әкияттә кызның атасы мәкерле бай абзасы белән судка җитә. Бай абзаның алаша, хәерче энесенең бия була. Иртә белән торгач, яңа туган колын күреп, бай абзый колынның үзенең алашасыныкы икәнен әйтә, колынны энесенә бирми. Суд та байны яклый. Шуннан энесе, гаделлек эзләп, патшага бара. Ул, картның җәберен тыңлап торгач:

– Мин биргән сорауларга җавап бирсәң, колыныңны алып бирермен, – ди. Патша картка берсеннән берсе авыр сораулар һәм биремнәр яудырып, ахырда колынны алып бирә.

Татар халык әкиятләре арасында зирәк кешеләргә һәм аларның тапкыр җавапларына багышланган цикл аерым урын алып тора. Бу төр әкиятләрдә табышмаклар читләтеп әйтү, кинаяле сөйләмгә корылган. Еш кына кинаяле сөйләм сорау һәм җаваплар аша бирелә. Ш. Закировтан язып алынган «Патша белән мужик» әкияте дә сорау һәм җаваплардан тора.

Бер мәкалә кысаларында һәрбер әкияткә тукталу мөмкин түгел. Шуңа күрә берничә әкиятне генә атап киттек. Экспедиция вакытында тупланган әкиятләр һәм информантлар турындагы мәгълүматлар хәзерге вакытта Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге архивының фольклор фондында саклана.

Актаныш районында 1948 елда әкият яздырган информантларның иң яшенә 14, иң өлкәне 70 не узган була. Алар арасында фронттан кайткан фронтовиклар да, мәктәп укучылары да, өлкән яшьтәгеләр дә бар. Түбәндә әлеге информантлар турында архивта сакланган мәгълүматларны һәм алардан язып алынган әкиятләр исемлеген бирәбез.

## ӘКИЯТЧЕ ИНФОРМАНТЛАР ҺӘМ АЛАРДАН ЯЗЫП АЛЫНГАН ӘКИЯТЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

Татарстанның Актаныш районы **Бурсык авылында Мансур Шәйхетдинов**тан (54 яшь) язып алучы Н. Фәттах. 1948, ФФ.

1. Мулла белән абыстай һәм ярлы аучы (колл. 34. п. 4, сак. бер. 53).
2. Матур һәм җәмсез хатын (колл. 34. п. 4, сак. бер. 49).

Татарстанның Актаныш районы **Әнәк авылында Рәхмәтулла Хисмәтуллиннан** язып алучы Н. Фәттах. 1948, ФФ.

Рәхмәтулла Хисмәтуллин әкиятләрне үз кулы белән язып та тапшырган. Бу информант – 14 яшьлек үсмер – киләчәктә Рахмай Хисмәтуллин дигән исем белән билгеле әдип булачак.

3. Таяк – хәйләкәр Таз (колл. 34, п. 4, сак. бер. 52).
4. Сихерле таяк (колл. 34, п. 4, сак. бер. 52).
5. Кыр аты (колл. 34, п. 4, сак. бер. 52).
6. Зирәк егет (колл. 34, п. 4, сак. бер. 52).

Татарстанның Актаныш районы **Затон Дербёшка** поселогында яшәгән **Андров Александр Никифорович** язып җибәргән. ФФ.

7. Батыр егет (колл. 16, п. 1, сак. бер. 4) (Не имеет типологических соответствий).

Татарстанның Актаныш районы **Илчебай авылында Кәрам Афзалов**тан (51 яшь) язып алучы Н. Фәттах. 1948, ФФ.

8. Кулсыз кыз (колл. 34, п. 4, сак. бер. 56) (СУС 706 – Кулсыз кыз).
9. Ике туган (колл. 34, п. 4, сак. бер. 55).
10. Сихерле йөзек (колл. 34, п. 4, сак. бер. 57).

Татарстанның Актаныш районы **Иске Кормаш авылында Насыйри Фаррах улы Фаррахов**тан (40 яшь). Язып алучы – Х. Ярми. 1948, ФФ.

Иске Кормаш авылы гражданины Фаррахов Насыйри Фаррах улы 1908 елда шушы ук авылда ярлы гаиләсендә туган. 1930 елдан «Үрнәк» колхозы члены. 1931 елдан 1934 елга кадәр Березняковский химкомбинатында кара эшче, аннан соң бетонщик булып эшли. 1936 елдан сугышка кадәр шофер булып эшли. Сугыш башыннан машинасы белән сугышка китә. Сугышта башта шофер, аннан соң, 1941 елны ук десантный бригадада разведчик. Кавказ фронтында була. 1942 елны алты айлык разведчиклар курсын үткәч, өч мәртәбә

парашют белән дошман тылына төшә. Бу десант сугышлар белән үзебезнең фронтка кушыла. 1943 елның октябрь аенда II Украинский фронтында Днепрны кичеп чыкканның соңында каты яралана. 1944 елда ранение белән авылга кайта. Хәзерге көндә III группа инвалид. 1944 елдан хәзерге көнгә хәтле авылда пожарный начальнигы булып эшли (нач. ДПД – добровольн. пож. дружина). Наградалар: Орден Отчественной войны Iстепени, медаль «За боевые заслуги», медаль «За доблестный труд».

Фронтта 110 гвардейский Александровский дивизиядә хезмәт итә. Бу экиятләрне Березняковский комбинатында эшләгән вакытта ишеткән. Партиясез (9 июль 1948 ел).

11. Көтүче солдат (колл. 34, п. 2, сак. бер. 34).

**Насыйри Фәрраховтан** язып алынган. Алабуга педагогия институты материалларыннан. 1953, ФФ.

12. Көлке һәм кайгы (колл. 52, п. 1, сак. бер. 10) (СУС 910 В Три добрых совета).

13.Гали белән Фатыйма (колл. 52, п. 1, сак. бер. 10).

Татарстанның Актаныш районы **Иске Кормаш авылында Насыйр Фаттаховтан (40 яшь**) Хәмит Ярми язып ала.

14. Урман каравылчысы (колл. 34, п. 2, сак. бер. 35) СУС 560 (Волшебное кольцо).

Татарстанның Актаныш районы **Иске Кормаш авылында Халисә Зиязова**дан язып алучы Х. Гатина. 1948 ел. 1928 елда туган, колхозда зоотехник булып эшли. «Бу экиятне кечкенә чагында әткәйнең абыйсыннан ишеткән идем», – ди.

15. Каракош (Х. Гатина төзегән «Вакытында табылган якутлар» китабында, 2006., архивка тапшырылмаган) (СУС 425 С Аленький цветочек).

Татарстанның Актаныш районы **Куян авылында Мингали Абзаев**тан (58 яшь) язып алучы Н. Фәттах. 1948, ФФ.

16. Тапкыр кыз (колл. 34, п. 4, сак. бер. 54)9 СУС 875 Мудрая девушка).

Татарстанның Актаныш районы **Мәчтей авылында Госманов Габделгани**дән (73 яшь) язып алучы Н. Фәттах. Госманов Габделгани Герман сугышында булган. 1948, ФФ.

17. Өч ул (колл. 34, п. 4, сак. бер. 49).

18. Песи, эт, җылан (колл. 34, п. 4, сак. бер. 49).

Татарстанның Актаныш районы **Пучы авылында Гыйльметдинов Гайфидән.** 1948, ФФ.

19. Әкият (колл. 34, п. 2, сак. бер. 37).

Татарстанның Актаныш районы **Такталачык авылында Бәхтегәрәев Хафиздан** Нурихан Фәттахов язып алган. 1948, ФФ.

20. Бида (колл. 34, п. 4, сак. бер. 49).

Татарстанның Актаныш районы **Такталачык авылында Бәхтегәрәева Мәчтүрәдән** (73 яшь) язып алучы Н. Фәттахов. 1948, ФФ.

21. Утау су (колл. 34, п. 4, сак. бер. 49).
22. Кәләш кырына бару (колл. 34, п. 4, сак. бер. 49).

Татарстанның Актаныш районы **Татар Әҗбие авылында Шәриф Закиров**тан язып алучы Х. Ярми, Х. Гатина. 1948, ФФ.

1926 елда туган. «Кызыл Кама» колхозында төрле эштә эшли. Партиясез. Бу әкиятләрне үз авылларында төрле картлардан ишеткән.

23. Хезмәттән кайтканда (колл. 34, п. 2, сак. бер. 28).
24. Алтын чүлмәк (колл. 34, п. 2, сак. бер. 27) (Золотой горшок) отчасти СУС 331 (Дух в бутылке (кувшине): человек освобождает нечистого из бутылки) + СУС 413 * (Заколдованный город-озеро: чародейка усыпляет город и превращает его в озеро, а людей в рыб).)
25. Тапкыр кыз (колл. 34, п. 2, сак. бер. 30) (СУС 875 Мудрая девушка).
26. Патша белән мужик (колл. 34, п. 2, сак. бер. 29) (СУС 921 А Куда тратятся деньги).

Татарстанның Актаныш районы **Югары Гәрәй авылыннан Сәгыйть Фәхразиев** язып җибәргән. 1947, ФФ.

27. Усал мужик һәм аның хәйләкәр хатыны (колл. 1, п. 23, сак. бер. 360).
28. Аю хәзрәт (колл. 1, п. 23, сак. бер. 360).

Татарстанның Калинин районы **Иске Байсар авылында** (хәзерге Актаныш районы) **Шәйхрази Фәхразиев**тан (70 яшь) язып алучы Н. Фәттах. 1948, ФФ.

29. Акылның башы (колл. 34, п. 4, сак. бер. 49) (СУС 910 В Три добрых совета).
30. Чуркин бур (колл. 34, п. 4, сак. бер. 49) (СУС 1525 А Ловкий вор + СУС 1525 D Вор обманывает прохожих (бросает сапог)).

Татарстанның **Актаныш районы Куян авылында Салиха Зарипова** тапшырган дәфтәрдән.

31. Әкият. 1948, ФФ, колл. 34, п. 3, сак. бер: 69.

Татарстанның **Калинин районы Әмәкәй авылында Шәфикъ Хөснулли**ннан (49 яшь) язып алучы Х. Ярми, Х. Гатина. 1948, ФФ.

Шәфикъ Хөснуллин 1899 елда туган. Партиясез. «Правда» колхозы члены. Хәзерге көндә колхоз председателе ярдәмчесе, ферма мөдире булып эшли. 1942 елдан 1946 елга кадәр Кызыл Армия сафында була. Хәзерге вакытта II группа инвалид. Читтә йөрмәгән. Үз колхозында гына түгел, бу тирә колхозларында да билгеле әкиятче. Безгә сөйләгән әкиятләрне үз авылында ишеткән. Укый-яза белә. Кайбер әкият китапларын укып белүе турында әйтте. 1946 елда чыккан «Татар халык әкиятләре»җыентыгындагы кайбер әкиятләр белән таныш. Язылып алынган әкиятләр безнең җыентыкларда күренмәгәнрәкләр.

32. Алтын балык (колл. 34, п. 2, сак. бер. 22).

33. Яшьлек суы (колл. 34, п. 2, сак. бер. 24) СУС 551 (Молодильные яблоки, молодильная вода).

34. Солдат әкияте (колл. 34, п. 2, сак. бер. 25).

35. Кыз патша (колл. 34, п. 2) отчасти СУС 551 (Молодильные яблоки, молодильная вода).

36. Мулла остабикәне никахлый (колл. 34, п. .2, сак. бер. 23).

37. Тапкыр егет (колл. 34, п. 2, сак. бер. 26).

Татарстанның **Калинин районы Уразмәт авылында Гыйззәтулла Гарифуллин**нан (73 яшь) язып алучы Н. Фәттах. 1948, ФФ.

38. Купец малае һәм крестьян кызы (колл. 34, п. 4, сак. бер, 49) (СУС 883 А Оклеветанная девушка).

39. 25 ел хезмәт иткән солдат әкияте (колл. 34, п. 4, сак. бер. 49).

40. Торна малае (колл. 34, п. 4, сак. бер, 49).

41. Өч ул (колл. 34, п. 4, сак. бер. 49).

# ОНЫТЫЛМАС ДОГА АҺӘҢНӘРЕ

## Актаныш районы татар-мөселманнарының дини-музыкаль йолалары

*Гүзәл Туймова*

Музыкаль-шигъри әсәрләр эчтәлекләре һәм формалары буенча төрле. Алар дини китапларда очраган, кайчандыр музыкаль-шигъри композиция рәвешендә яшәп килгән һәм тоташ җырланган текстларның өзекләре дә булырга мөмкин. Мәсәлән, госманлы шагыйрьләр Мөхәммәд Чәләбинең (XV г.) *Мөхәммәдия китабы* һәм Сөләйман Чәләбинең (XV г.) *Вәсиләтен нәҗат*, төрле авторларның әсәрләреннән тупланган (алар арасында Мәүлиди Шәрифтән дә өзекләр очрый) *Мәүлид китабы* (Мөхәммәд пәйгамбәрнең тууы турында), Урта Азия шагыйре Сөләйман Бакырганиның *Ахырзаман китабы, Бәдавам китабы* («Һәрвакыт Аллаһ дип кабатла»), *Йосыф – Зөләйха, Таһир – Зөһрә, Ләйлә – Мәҗнүн, Кисекбаш, Тутыйнамә* Идел буе татарларының «*көйләп китап уку*», «*китап көйләре*» кебек үзенчәлекле йолаларына нигез салган тарихи ядкярләрдән санала.

2009 елның 1–10 июлендә Актаныш районына оештырылган комплекслы экспедиция барышында биредә яшәүче татарларның дини музыкаль-шигъри җәүһәрләрен барлау һәм туплау эшенә зур игътибар бирелде. Очрашулар вакытында көйләп укыла торган текстлар (мөнәҗәтләр, зикер, салават, китап текстлары) һәм элегрәк бу җирлектә киң таралган йолалар турында мәгълүматлар язып алынды. Барлыгы 40 лап музыкаль-шигъри

үрнәк (аларның кайберләре кабатлана) тупланды. Әлеге мәгълүматлар ислам диненең бу төбәктә электән яшәп килгән шактый бай культурасын күзалларга ярдәм итә.

Актаныш районында дини музыкаль-шигъри текстлар, нигездә, Идел буе татарлары яратып башкара торган *мөнәҗәт* рәвешендә сакланганнар.

Буыннан-буынга тапшырылып килә торган әлеге үзенчәлекле дини әсәрләрне җырлап, сөйләп күрсәткәч, дини йолаларны уздыру үзенчәлекләрен дә искә төшерделәр актанышлылар.

Актаныш районында язып алынган иң кыйммәтле җәүһәрләрнең берсе *Кадер кичәсендә* көйләп укыла торган *Мөхәммәдия китабы* булды. Актанышлылар Мөхәммәд пәйгамбәр туган *рабигыләүвәл* аен бик зурлыйлар, ул көннәрдә *Мәүлид кичәләре* уздыралар һәм мәҗлесләрдә Пәйгамбәрнең тууын сәламләп, *Мәрхаба* (күрешү) белән *Әлвидаг*ны (саубуллашу) башкаралар.

Идел буе татарлары культурасында «Мәүлид»нең төрле текстлары булуы мәгълүм, аларның зур күпчелеге ислам дөньясының төрле телләрендә, шул исәптән төрки телләрдә дә, иҗат ителгән. Идел буе татарлары арасында төрки телдәге мәүлидләрдән «Мәүлиди шәриф», С. Чәләбинең *Мәүлид китабына* кергән *Вәсиләтен нәҗат* өзекләре танылу алган һәм киң таралган булган. Кызганыч, Актаныш төбәгендә «Мәүлид» буенча музыкаль-шигъри материал очрамады. Шунлыктан биредә «Мәүлид»нең ничек уздырылган һәм ничек җырланган булуы әлегә билгеле түгел.

Һәрбер музыкаль текст билгеле бер вакытта һәм билгеле бер вакыйга уңаеннан башкарыла. Халык хәтерендә сакланган мәгълүматлар дини текстларның максаты-вазифасы турында фикер йөртергә һәм аларның функциональ әһәмиятен торгызырга ярдәм итә.

Әйтик, *Мәүлид китабын* пәйгамбәр туган *рабигыләүвәл* ае дәвамында көйләп укыйлар. *Мөхәммәдиянең рамазан* аендагы Кадер кичәсендә яңгыравы да юкка түгел. Мәгълүм булганча, Мөхәммәд пәйгамбәр мөселманнар тарафыннан аеруча ихтирам ителә. Музыкаль-шигъри догалар ярдәмендә мөселманнар

пәйгамбәргә тирән хөрмәтләрен белдерәләр һәм Кыямәт көнендә аның шәфәгатенә өметләнәләр.

Татар музыкаль культурасына мөнәҗәт буларак кереп урнашкан дини җырларның һәрберсенең үз максаты һәм урыны бар. Мисал итеп түбәндәгеләрне атап үтәргә була:

– *«Изге ай Рамазан»* – Рамазан аенда башкарыла;

– *Гата кылдың Кәрәм ханнан»* – намаз вакытында башкарыла; ул Рамазан аенда өстәмә төнге намаз саналган *Тәравих намаз*ыннан соң, яисә гадәти намаздан соң да көйләнергә мөмкин;

– *«Сөбхан әйтик, зикер әйтик»* – Рамазан аенда көйләп укыла;

– *«Мәрхаба»* – Рамазан аеның беренче яртысында укыла;

– *«Әлвидаг»* – Рамазан аеның икенче яртысында укыла;

– *«Корбан ае – изге ай»* – мөселманнар тарафыннан иң зурлап уздырыла торган *Корбан бәйрәменә* багышланган;

– *«Намаз мөнәҗәте»* – намаздан соң укыла;

– *«Шунда булсын зикер Аллаһ»* – дини мәҗлесләрдә бергәләп дога кылганда көйләп укыла.

Актаныш районында материаллар җыеп йөргәндә әлегә кадәр беркайда да очрамаган яңа дини текстларга да юлыгырга туры килде. Алар мәет күмү йоласы вакытында – *җеназа*да көйләп укыла:

– *«Үлем турында мөнәҗәт»*;

– *«Салават»;*

– *«Үлемне искә төшерик»*.

Башкару вакыты һәм урыны әлеге көйләрнең төп үзенчәлеген билгели. Мәет өстендә (мәет саклаганда) укыла торган бу текстларны төнгә мәет янына җыелган хатын-кызлар мәетне юып салганчыга (госел алдырганчыга) кадәр көйләп укыйлар. Мондый дини йола хакындагы мәгълүмат әлегә кадәр басылып чыккан җыентыкларда да, татар музыкаль фольклоры буенча алып барылган фәнни тикшерү эшләрендә дә очрамый. Әлеге йола турында сөйләгән Чуракай авылында яшәүче *Суфиева Сәвия Нургали кызы* (1927 елда туган) ул текстларны көйләп тә күрсәтте. Чуракайда элек мондый йола булмаган (Сәвия ханым аларны Колын авылында ишетеп өйрәнгән).

Мәет күмгәндә көйләп дини текстлар уку йоласы башка халыкларда да, аерым алганда кырым татарларында яшәп килә. Идел буе татарларында мондый йоланың кайчан барлыкка килүе һәм ни дәрәҗәдә таралган булуы турында әйтүе кыен. Моны яңа фактлар, өстәмә мәгълүматлар һәм Татарстанның башка төбәкләренә оештырылган экспедицияләрнең нәтиҗәләре ачыклар дип өметләнәбез.

Актаныш районында сакланып калган кайбер китаплар аларның авторларының нинди дә булса бер тарикать вәкиле булуын раслый. Экспедиция материаллары суфичылык юнәлеше үсеш алган дигән гипотезаларга нигез бирә һәм якын киләчәктә шул юнәлештә махсус тикшеренүләр алып барырга кирәклеген искәртә.

Кызганыч, халык инде дини китапларның күбесен белми. Ул көйләрне башкарырдай, йоланы бөтен тулылыгы белән дәвам итәрдәй варислар юк дәрәҗәсендә. Сөйләшкән кешеләр арасында татарларда аеруча популярлык яулаган *Мөхәммәдия* китабының аерым фрагментларын булса да хәтерләп, көйләп күрсәтүче булмады.

Ә менә *Ахырзаман китабы* белән *Бәдавам* китапларындагы аерым өзекләрне көйләп укучылар булуы сөендерде. Алар да – бүгенге көндә безнең өчен бик кыйммәтле табыш.

Көйләп укыла торган дини текстлардан иң киң таралган һәм танылганнары түбәндәгеләр: *Муса мөнәҗәте, Сабырлык мөнәҗәте, Аятелкөрси мөнәҗәте, Укы Коръән илә намаз, Илаһым, сорыйм синнән.* Актаныш районы авылларында нәкъ менә шушы текстлар еш очрады.

Без өйрәнгән төбәктә элек мәчетләрнең күп булуы халыкның гыйбадәткә нигезләнгән көнкүреше хакында сөйли. Мәчетләр каршында оештырылган мәктәп һәм мәдрәсәләрдә укыту да тиешле югарылыкта алып барылган. Дини уку йортлары программасы өч тел – гарәп, фарсы һәм төрки телләрне өйрәтүне һәм ислам классикларын шул телләрдә укуны (аларның күбесе көйләп укыла) күздә тоткан. Моннан тыш, дини уку йортлары шул юнәлештәге белгечләр (мәсәлән: *карилар, хафизлар, казыйлар, имамнар*) әзерләп чыгару бурычын да куйган. Болар

барысы да без өйрәнгән төбәктә элекке чордан ук ислам музыкаль культурасының үсеш алуына китергән. Иң мөһиме, Актаныш районында язып алынган текстларның музыкаль төзелеш үзенчәлекләре Идел буе татарларының дини-музыкаль традицияләрен сыйфатлый торган принципларга туры килә.

Ислам классиклары нормасының сакланышы һәм яшәеше бүгенге дини музыкаль мирасыбызның үткән йөзьеллыклардан килгән «тере» музыкаль тукыманы үзендә саклап калуын дәлилли торган мөһим күренеш булып тора. Халыкчан традициядәге ислам музыкаль культурасында ислам классик музыкаль-шигъри сәнгатен һәм төрки халыклар иҗатын чагылдырган принципларның янәшә үсеше уникаль күренешләрдән санала.

Без язып алган көйләрнең яңгырашы (аһәң) гадәти пентатоника системасына нигезләнә. Бу – Идел буе татарларының музыкаль культурасындагы төп үзенчәлекләрнең берсе. Аһәң төзелешенең җирлеге интонацион башлангычлар – пентатоник күзәнәкләр кушылуның төрле ысулларыннан, төрләреннән гыйбарәт. Бу күренеш татар музыкаль фольклорына да хас.

Көйләрнең метроритмик төзелеше, гадәттә, төрки музыкаль-шигъри иҗатка хас булган ике система ярдәмендә сурәтләнә:

– *бармак* – шигырь төзүнең силлабик иҗек тибы;

– *төрки гаруз* – классик шигырь төзелешенең иң популяр бәхер (рәмел белән хазаҗ) алымы нигезендә язылган көй.

Ислам көйләрен башкаручылар һәр очракта да моңнар кушылмасында яңа моң-ритм моделе китереп чыгара торган метроритмик нигезне ачык һәм төгәл саклыйлар. Шунысы гаҗәп: махсус дини белеме булмаган, атеистик һәм коммунистик чор кичергән башкаручылар ислам классик музыкаль-шигъри мирасы принципларын саклап кала алганнар.

Һәр башкаручының мозаикасыман аһәңнәрдән төзелгән интонацион көйләүләрнең үзенә генә хас булган шәхси арсеналы бар. Метроритм формуласы тезелмәсендә ул башкалардан аермалы үзенә бер аһәң барлыкка китерә.

Татарлар арасында ислам дине йолаларын саклауда Татарстанның наширлек эшчәнлеге дә зур роль уйный. Басылып чыккан күпсанлы дини шигъри текстлар республиканың барлык

территориясендә (иң ерак төбәкләргә хәтле барып җитеп) тарала, өлкән буын вәкилләре арасында киң популярлык яулый, аларга яңа тормыш «сулышы» өрә. Нәкъ менә өлкән буын вәкилләре бәрабәренә татарларның ислам мирасы үзенең яшәешен дәвам итә. Бу хакта мәгълүмат йөртүчеләр, – нигездә, 1914–1919 һәм 1941–1942 еллар арасында туучылар. Ә дини мәгълүматларны саклаучыларның күп өлешен XX гасырның 30 нчы елларында туган буын тәшкил итә.

Дини көйләрне башкаручыларның һәркайсында үз әти-әни, әби-бабаларыннан күңелләренә сеңеп калган көй-моңнар һәм метроритмик модельләр сакланган. Җыелышып дога укулар, мәҗлесләрдә үзалмашлар булган: берсе укый башлаганны икенчесе дәвам иткән, аннан өченчесе кушылган һ. б. Бу күренеш дини йолаларның туктаусыз үсешенә китергән.

Шигъри текстлар үз урыннарын алмаштырырга, ягъни төрле урында һәм төрле шигырьләр белән яңгырарга, функцияләрен һәм максатларын үзгәртергә мөмкиннәр. Бу хәл дини культураның даими яңарып торуына китерә. Күчеп йөрүче шигъри текстларга мисал итеп *Аятелкөрси мөнәҗәтен, Муса мөнәҗәтен, Укы Коръән илә намаз*ны китерергә мөмкин. Аларны көйләп уку һәр башкаручы хәтеренең моң-ритм тирәнлегенә бәйле.

Аерып күрсәтелгән көйләрнең *җеназа* белән башкарыла торган төркеме бер үк моң-ритм формасында көйләнә һәм үз чиратында К. Хөснуллин җыентыгында[1] әйтелгәнчә, *Адәмгаләйһиссәлам кыйссасы* тексты белән яңгырый. Бу очракта ул мәет күмү йоласын үтәү белән бәйле.

Моңа охшаш процесслар ислам белән бәйләнмәгән музыкаль-шигъри фольклор төрләрендә дә очрый. Дини иҗат өлкәсенә хас булганча, текстны, аның белән бергә көйнең функциясен алыштыру принцибы татар җыр фольклорының төп принципларыннан санала[2].

---

[1] *Хөснуллин К.* Мөнәҗәтләр һәм бәетләр: Көйләп укуга нигезләнгән жанрлар. – Казан, 2001. – 692 б.

[2] *Каюмова Э. Р.* Татарская народная-песенная культура нового времени: Проблемы традиционного мышления и жанровой атрибуции. – Казань, 2005.

Әлегә без Идел буе татарларының дини культурасы, аерым алганда аның музыкаль үзенчәлекләре турында ачык һәм төгәл итеп әйтә алмыйбыз. Узган йөзьеллыкларда нинди көйләр яки нинди шигъри текстлар һәм ислам йолалары булганлыгын, дини текстларның музыкаль параметрлары нинди үзгәрешләр кичергәнлеген раслау да кыен. Чөнки текстларның бер өлеше XX гасыр башында яңа көйләр, яңа аһәңнәр белән яңгырауларын дәвам итәләр. Әмма, үзгәрешләр булуга да карамастан, ислам йолалары традицион татар музыкасының яңа шартларына һәм таләпләренә ярашып яшәүләрен дәвам итәләр.

Авылларда алып барган тикшеренүләр вакытында, музыкаль-шигъри текстлардан кала, ислам диненең бу җирлеккә генә түгел, ә бөтен Идел буена хас йолаларын чагылдырган мәгълүматлар да язып алынды.

Кызганыч ки, татарлардагы традицион ислам культурасының хәзерге халәте юкка чыгу дәрәҗәсендә. Ул, барыннан да элек, шул йолаларны саклаучыларның кимүенә бәйле. Алар белән бергә Идел буе татарлары мәдәни мирасының да билгеле бер өлеше югала бара.

Шулай да дини текстларны көйләп укучылардан язып алынган материаллар һәм кыйммәтле мәгълүматлар, тарихи дәверләр кичкән ислам йола-гадәтләренең кайбер аспектларын һәм әлеге йолаларны уздыру үзенчәлекләрен торгызырга ярдәм итәчәк. Чөнки Актаныш районындагы ислам музыкаль-шигъри культурасы Идел буе төбәгенең электән килгән дини музыкаль-шигъри традицияләренең бердәм системасына керә һәм төрки-мөселман дөньясының аерылмас өлешен тәшкил итә.

## ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

### Актаныш төбәгендә сакланган фольклор үрнәкләре

*Ленар Җамалетдинов*

Бу китапта актанышлылар күңелендә яшәгән халык иҗаты әсәрләренең дә кайбер үрнәкләре белән танышырга мөмкин.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Актаныш районына барлыгы 4 фольклор экспедициясе оештырыла (1948, 1981, 1987, 2009 елларда).

Күренекле фольклорчы Х. Ярми җитәкләгән 1948 елгы беренче экспедициядә Х. Гатина, Н. Фәттах, Ш. Максудовалар катнашкан. Алар 40 көн дәвамында шул дәвердәге Актаныш районына кергән 15 авылда (Әҗмәт, Бурсык, Илчебай, Иске Балтач, Иске Кормаш, Куян, Мәсәде, Меңнәр, Такталачык, Татар Әҗбие, Татар Суыксуы, Уразай, Чалманарат, Шәбез, Югары Гәрәй) һәм Калинин районына кергән 12 авылда (Әмәкәй, Әнәк, Исәнсеф, Иске Байсар, Иске Сәфәр, Мәчти, Пучы, Сикия, Татар Бүләре, Түбән Яхшый, Уразмәт, Яңа Байсар) фольклор материаллары җыйганнар. Шулай итеп, бу экспедиция 27 авылда эшләгән. Исәпләүләр буенча, җыелган фольклор материалларының гомуми саны 4746 данә.

Экспедициядә язып алынган 37 әкиятнең 9 ы төрле елларда 7 җыентыкта басылып чыккан. Иске Кормаш авылында яшәүче Насыйр Фәррахов сөйләгән «Урман каравылчысы» исемле әкият, шул ук авылдан Халисә Зиязова сөйләгән «Каракош», Әмәкәй авылыннан Шәфикъ Хөснуллин сөйләгән «Мулла остабикәне никахлый» әкиятләре татар фольклорының 13 томлык

җыелмасындагы әкият томнарында (I – 1977, II – 1978, III – 1981) басылырга лаеклы дип табылды. Соңрак алар рус телендә дә дөнья күрде. Ә Татар Әҗбие авылында Шәрип Закиров сөйләгән «Җилән» әкияте 1956 елда ук басылып чыккан иде. Янә берничә әсәр, Х. Гатина тарафыннан төзелеп, соңгы елларда бастырылган әкият китапларына кертелде.

Югарыда искә алынган 13 томлы абруйлы җыентыкта йола һәм уен җырларыннан өч әсәр, бер риваять һәм табышмаклар, мәкальләр, кыска җырлар урын алган, бер бәет, тарихи һәм лирик җырлардан өч әсәр, янә балалар фольклорына караган кеч-кенә күләмле 72 әсәр дөнья күргән.

Алда әйтелгәнчә, бу якларда композиторлар Александр Ключарев һәм Җәүдәт Фәйзи дә булганнар. Җ. Фәйзи, мәсәлән, Актаныш районына караган авылларда халыктан 20 лирик җыр язып ала (Актанышта – 5, Такталачыкта – 12, Мәсәде авылында – 2, Бурсыкта – 1) һәм аларны, ноталары белән бергә, үзенең «Халык җәүһәрләре» китабында бастырып чыгара[1]. Бу җырлар 1987 елда кабат басылды[2].

Актаныш төбәгенә икенче экспедиция 1981 елда оештырылды. Бу сәфәргә мин берүзем чыгып киттем.

Июльнең икенче яртысы иде. Кояш чамасыз кыздыра. Тезгә дә җитми катып калган игеннәр яңгырга тилмереп утыра. Хәтта җирнең үзенә дә ут кабар сыман. Елга ярлары саргаеп кипкән. Терлекләр көтүдән ач кайта. Бер капчык печән табу да мөмкин булмаган эш. Менә шул була икән инде ул – корылык дигән коточкыч нәрсә.

Мин килгәндә, КПСС райкомында зур киңәшмә бара иде. Көн тәртибендә – камыл җыю мәсьәләсе. Быел игеннәрне болай да мөмкин кадәр төптән урдыралар, аның камылы ничә генә сантиметр булыр икән соң? Әмма барыбер җыярга. Гадәттән тыш хәл шулай куша. Җитмәсә, моны ашыгыч рәвештә эшләргә кирәк, чөнки җирне туңга сөрәсе бар. Камыл җыя торган машина

---

[1] *Фәйзи Җәүдәт.* Халык җәүһәрләре: Татар халкының хәзерге заман музыка фольклоры. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – 288 б.

[2] *Фәйзи Җәүдәт.* Халык җәүһәрләре: Күңелем кыллары. Татар халык көйләре. Истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 392 б.

юк (аны җыярга бүтән язмасын да), ә инде быел җыярга мәҗбүрбез икән, моның өчен башта махсус җайланмалар ясарга кирәк бит! Әнә, «Маяк» колхозы эшчәннәре аеруча өлгерлек күрсәткәннәр – камыл җыюны башлаганнар да икән. Киңәшмәдәге халык, озакка сузмыйча, тәҗрибә өйрәнергә шунда ашыкты. Мине дә язмыш шулар арасына китереп керткән иде. Борылышта санап алам: машиналар саны ике дистәдән артык. Алдагыларында – район җитәкчеләре, калганнарында – колхоз-совхоз вәкилләре, белгечләр. Колонна тиз бара. Бу минутларда мин аларны бәла-казага юлыкканнар янына ашыгучы янгын сүндерү машиналарына охшаттым. Чыннан да, болар да бит коткарырга ашыга! Ничек кенә булса да терлек-туарны саклап калырга, халыкны ит-майдан мәхрүм итмәскә, сабыйларны сөтсез калдырмаска...

Актаныш ягы – гүзәл табигатьле, җырлы-моңлы як. Моңарчы бу якта булмаган берәр шагыйрь, Актанышның мәдәният сарае бусагасына басып, Агыйделгә генә карасын – илһамын дөрләтергә шул бик җитә!

Агыйделдән, Сөн буйларыннан Мохтар Мутин, Әлфия Афзалова, Риза Ишморат, Гамил Афзаллар күтәрелгән, аның туфрагында киләчәктә Советлар Союзы Герое булачак биш бала тәгәрәп үскән. Шул каһарманнарның берсе – сугыштан соң күпме еллар яшәп тә, үзенең герой икәнен белми дөньядан киткән һәм шушы сокландыргыч тыйнаклыгы белән җырга күчкән Хәсән Заманов. Янә дә исеме җырда яңгырый торган Ардуан батыр – Мирсәет Ардуанов та шушы яктан, Иске Кормаштан. Монысы – тынычлык фронты каһарманы. Бу гади татар эшчесенә хәтта Татарстаннан читтә, Березники шәһәрендә һәйкәл куелган.

Кояш һаман да рәхимсез. Радио хәбәр итә: бүген Татарстанның көнчыгышында эсселек 43 градус булачак. Көн тәртибендә шул ук бер мәсьәлә: печән, печән... Бер капчыкмы, бер учмы – һәр көнне табарга, мотлак табарга. Печән генә түгел, бәрәңге дә проблема. Хатын-кыз, бакчага чыгып, бер пешерерлек бәрәңге таба алмый керә.

Менә шундый авыр шартларда, уттай эш өстендә халык авыз иҗатын җыю белән шөгыльләнү беркадәр уңайсызрак та шикелле. Халык моны ничек кабул итәр? Мондый эшкә ул ничек карар?

Печән җыюдан гадәти елда да беркем читтә калмый, шул исәптән авыл интеллигенциясе дә. Шунлыктан, печән өстендә клуб, китапханә, медпункт ябык булса да, гаҗәпләнергә туры килми. Ә ул елда… хәтта Актаныш райбашкармасы коллективының тулы составта печән өмәсендә эшләгән көннәре булды. Нинди җаваплылык!

Нәкъ менә шул җаваплылык хисе фольклорчыны да авыл хезмәтчәннәре кебек фидакяр булырга өнди. Тирәнрәк уйлап карасаң, мин дә бирегә коткаручы булып килгәнмен бит! Халкыбызның җәүһәрләргә тиң рухи хәзинәсен саклап калыр өчен! Сүз дә юк, изге эш.

Моннан берничә еллар элек язып алынып, кайберләре калын-калын томнарда басылып чыгарга да өлгергән шундый җәүһәрләрне безгә бүләк иткән, халкыбызның моңлы җырларына, серле әкиятләренә, гаҗәеп риваять-легендаларына икенче гомер бирергә булышкан хөрмәтле кешеләребезнең байтагы бүген инде дөньяда юк. Димәк, фольклорчылар да ашыгырга тиеш. Нинди шартлар булуга да карамастан, аларның игелекле эшләрен сүлпәнләндерергә хаклары юк.

Халык арасында эшне башлап җибәргәч, киеренкелек беркадәр сүрелә төште. Беренчедән, халык бәргәләнми-сугылмый, беркем дә ах-ух килми. Быелгы шартларның 1921 елгыдан да кырысрак икәнен белсәләр дә, күңелләре тыныч, алар хөкүмәтебезгә ихлас ышаналар – ачлык булмаячак. Икенчедән, эшемнең башында ук халык миңа зур теләктәшлек күрсәтте. Фольклор туплауның шулай ук мөһим эш булуын яхшы аңлыйлар икән. Шул вакытта райбашкарма рәисе урынбасары Миңтимер Салихҗан улы Әхмәтхановның сүзләре искә төште. Ул мине сәфәргә озатканда: «Иске Кормашның халкы бик әйбәт, анда керсәгез үкенмәссез», – дигән иде. Бирердә халыкның күңеленә «ачкыч яратырга» өстәмә вакыт кирәк булмады.

Теге яки бу авыл халкының белемле, тәрбияле, культуралы булуы – буыннан-буынга күчеп килә торган традицион күренеш. Бу беренче чиратта туган җирне, аның халкын яратудан, тарихын хөрмәтләүдән килә торгандыр. Үз авылының тарихын һәм бу төбәккә мөнәсәбәтле риваятьләрне сөйләгәндә Иске

Кормашта туып үскән Бөек Ватан сугышы ветераны, 68 яшьлек Хөснимәрдән Мәрдәновның халкыбыз тарихына булган зур ихтирамын һәм самими күңел җылысын тоймый мөмкин түгел иде. Авыл кайчан салына башлаган, Кормаш бабайның ничә улы булган, соңрак нинди нәселләр яшәгән – болар барысы да Хөснимәрдән аганың хәтер сандыгында кадерләп саклана.

Риваятьләргә караганда, Иске Кормаштан ерак булмаган Умбы елгасы буенда Җизмыек дигән кавем дөнья көткән (алар күптән инде биредән күчеп киткән, шулай да нәселләренең дәвамчыларын очраткалыйлар икән). Җизмыеклар янында, авыл булып, Нократлар яшәгән. Тик алар да, ни сәбәпледер, бу җирдән күчеп киткәннәр, елга буенда зиратлары гына торып калган.

Бу риваятьне, бер-берсен тулыландырып, Хөснимәрдән ага белән шул ук авылда яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераны Хәниф ага Миңнеханов сөйләделәр.

Хәниф ага риваятьләре буенча, патша заманында Кормаш авылы җирсезлектән интеккән. Чөнки ул башкорт булып язылмаган, типтәр (ягъни көчләп чукындыруга каршы торганы өчен, Идел-Чулман буйларыннан куылган, тибәрелгән халык) булып калуны артыграк күргән. Ә типтәргә җир дә, болын да юк. Ләкин авыл халкы баш имәгән, көрәшкән һәм бу көрәш бөтенләй үк нәтиҗәсез дә калмаган: Кормаш халкына җир бирелгән, тик үз авыллары яныннан түгел, ә утыз чакрымдагы Чуракай авылы тирәсеннән. Бу, әлбәттә, күз буяу, халыкны мыскыл итү булган.

Күпме генә изелсә дә, гел кайгырып-хәсрәтләнеп кенә яшәмәгән халык, җырларга-биергә, күңел ачарга, кунакка йөрешергә дә вакыт тапкан. Хөснимәрдән ага бу якларда булган җыеннарның барысын да яхшы хәтерли. Әйтик, Нарат асты җыены Чалманарат авылында узган. Бу вакытта инде кыраулар бетеп, игенчеләр тары, карабодай чәчкән, кыяр, кавын утырткан булган. Шуннан соң, атна саен алар башка җыеннарга юнәлгәннәр: Олы җыен, Җамалы җыены, Кара Зирек, Элбәк, Бикә җыены, Туйра, Энҗел. Иске Кормашта уза торган Бикә җыены Туйбикә әби исеме белән бәйле. Имештер, яу килгәч, дошманнардан качып, Туйбикә әби Болгар иленнән Шәбез елгасы буена килеп утырган.

Әлеге әби салдырган күперне әле дә Бикә күпере дип йөртәләр икән. Халык аның исемен җырга кертүне дә кирәк тапкан:

Безнең ындыр артларында
Була кызлар уены,
Унике айга бер килә
Безнең Бикә җыены.

Төрле җирләрдә таулар, урманнар, чишмәләр күреп сокланганыбыз, аларның матур яңгырашлы исемнәрен кабатлап ләззәтләнгәнебез бар. Бактың исә, шигъри йөрәкле халкыбыз гади генә чокырларга да гүзәл исемнәр кушкан: Хөрмәкәй, Кымызлы күл, Нечкә әйлән, Чишмә башы чокыры, Өшмышты чокыры, Торна сазы, Кара тәкә, Сулы куак, Күперле сыза, Мүк юлы, Җилпәк нарат, Ташлы елга чокыры, Кушнарат, Алдырыш башы чокыры һ. б. Риваятьләргә караганда, борын заманда бу урыннарда кара урманнар һәм сазлыклар булган. Халык урманнарны кисеп иген чәчкән. Заманнар узу белән, сазлыклар кибеп беткән. Әлеге чокырлар – шул сазлыкларның урыннары, имеш.

Авыллар тарихында халык тарихы, нәселләр тарихы, гаиләләр һәм аерым шәхесләр тарихы чагыла. Ахыр чиктә, Ватан тарихы да әлеге тарихларның кушылуыннан тора бит. Халкыбызның борынгыдан килгән бер күркәм таләбе бар: һәркем ата ягыннан үзенең җиде бабасын белергә тиеш. Кайбер нәселләрнең зирәк вәкилләре, нәсел үсешен даими яза барып, зурзур шәҗәрәләр төзегәннәр. Әнә шундый зур һәм бер үк вакытта гаҗәеп камил эшләнгән шәҗәрә миңа Яңа Балтач авылында очрады. Аны Камал Закиров (1896–1967) язып калдырган. Ул шушы авылда беренче колхозны оештырган, районда беренче электр станциясен төзегән хөрмәтле ил агасы булган. Шәҗәрәне Камал ага сугышка кадәр үк эшли башлаган булган, тик сугыш вакытында аны югалтканнар. Сугыштан соң ул үзенең әлеге шөгылен өр-яңадан башлый, төрле документлардан, архив материалларыннан файдаланып, эшне ахырынача җиткерә. Шәҗәрә, Болгар иленә монгол яулары ябырылгач, бирегә килеп утырган Чуяр бабай исеме белән башланып китә. Аннары аның улы Чарлакдиван, аның улы Шөгыльлүәт (варианты – Шәгълүвәт), аның улы Тимиян, һәм шул рәвештә дәвам итеп, нәсел агачының

ботакларын түбәндәге исемнәр тәшкил итә: Туктамыш, Көтексә, Нугай, Яхшыхуҗа, Уразак, Исәндәүләт, Тунлачы, Байтирәк, Тайдым, Карач, Мөслим. Мөслим бабайның балалары Әхмәт, Мөстәкыйм һәм Мөрсәлим XVIII гасырда, Иске Балтачтан китеп, Яңа Балтачка нигез салганнар. Нәсел агачының иң очтагы ботакларын 60 нчы елларда туган балалар тәшкил итә. Ана артыннан иярә килгән балалар, авылны ташлап читкә китүчеләр, Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр һәм сугышта һәлак булучылар аерым билгеләр белән тамгаланган. Шәҗәрә зур кәгазьгә тушь белән матур, тигез итеп язылып, пыяла рамга куелган. Исемнәр хәзерге алфавит белән дә, гарәпнеке белән дә язылган. Теләгән һәр кеше аны килеп карый алган, үзенең бабаларын тапкан.

Чат авылында яшәүче колхоз ветераны Таһир Ногманов та үз авылының тарихын тәфсилләп сөйләде. Ул – шәхес буларак та кызыклы кеше. Таһир ага ярлы крестьян гаиләсендә егерменче бала булып дөньяга килгән. Колхоз төзүдә һәм аны аякка бастыруда зур көч куйган. Медальләре, мактау кәгазьләре бар. Гаделсезлекне җене сөйми. Уртача гына тормышта яшәүче бу ветеран ел саен бер айлык пенсиясен Тынычлык фондына биреп бара. Шул уңай белән, Тынычлыкны саклау буенча Татарстан республика комитетыннан рәхмәт хаты да килгән үзенә...

Тарихка караган мәгълүматлар күбесенчә ир-ат даирәсендә булса, бәет-мөнәҗәт кебек әсәрләр башлыча хатын-кызлар тарафыннан башкарыла. Иске Кормаш авылында, мәсәлән, бәет һәм мөнәҗәтләрне мин 87 яшьлек Гыйльменур Кәшшапова һәм 70 яшьлек Бибидәнә Маннапова дәфтәрләреннән күчереп алдым.

Әбиләрдә бәеткә мәхәббәт аеруча зур. Кыр Каентүбә авылында яшәүче 71 яшьлек Хафаса Гәрәева үзенең апасына багышлап чыгарган бәетен укып күрсәтте. Апасы, читтә картаеп, үз үлеме белән вафат булган. Әмма шушы үлем нечкә күңелле туганын гомерендә беренче тапкыр бәет чыгарырга мәҗбүр иткән. «Түтекәем турында минем моңнарым» исемле бу бәеттә күпне күргән халкыбызның олы хәсрәтләр кичергәндә дә сәламәт калган саф күңеле, шигъри йөрәге һәм балдай татлы теле ярылып ята.

Үзәккәйләремә үтеп,
Йөрәккәйләремә төшеп,
Түтекәем үлеп китте,
Кайгы утларына күмеп, –

диелә бу бәеттә. Анда күбесенчә сүзләрнең әнә шундый иркәләү формасы кулланылган: туганкайлар, бакчакайлар, васятькәйләр, башкайларың, бәбекәйләрең, күлмәккәйләрең, бәхеткәйләрең. Хафаса ханым гади кебек тоелган сүзләргә дә кушымчалар ярдәмендә йомшаклык төсмере өстәгән (тилмерепләр көтү, гаҗәпләргә калу һ. б.).

Актык басуларың булган,
Түтекәм, тупсакаема;
Түзә алмыйм, түтекәем,
Сине сагынукаема.

Адәм баласының башына күп бәлаләр гыйбрәт алмаудан яисә ала белмәүдән килә. Ә бәетләрнең күбесендә сурәтләнгән трагедия – халык өчен зур гыйбрәт ул. Бер бәет әллә нинди һәм әллә ничә кисәтү хатларына караганда да тәэсирлерәк булырга мөмкин! Мәсәлән, бәетләрнең берсендә башлангыч сыйныфта укучы кыз баланың үз иптәшләре белән качышлы уйнаганда кинәт юкка чыгуы сурәтләнә. Иртәгесен мәгълүм була: су торбасы өчен казылган чокырга качкан бу баланы җир тигезләп йөрүче бульдозер күмеп киткән икән. Җан өшеткеч вакыйга. Әле генә йөгереп йөргән сабый бер мизгелдә юк булган – тереләй күмелгән. Хәзер авылда аның бәете генә яши. Очраклы хәл, әмма балаларның үзләренә дә, игътибарсыз олыларга да зур сабак, үтемле гыйбрәт бу.

Әнә шундый бәетләрне язып алганда, ирексездән кешеләрнең йөрәк яраларына да кагылып узарга туры килә. Нишләмәк кирәк, тормыш «Баламишкин» көеннән генә тормый шул…

1981 елгы экспедициядә, 6 көн дәвамында 5 авылда (Актаныш, Иске Кормаш, Кыр-Каентүбә, Чат, Яңа Балтач) булып, 58 берәмлек фольклор материалы тупланды. Шушы материаллардан 5 әсәр 13 томлык фольклор җыелмасының «Риваятьләр һәм легендалар» томында басылды.

Актаныш районының фольклорга бай төбәк булуында шик юк иде, һәм бу янә расланды. Бирегә тагын, тагын килергә

кирәк, дип кайттым мин. Мотлак килергә! Һәм... мондый форсат тагын 6 елдан соң насыйп булды.

Ниһаять, 1987 елның җәендә хезмәттәшем Сәлим Гыйләҗетдинов белән икәү, Идел, Чулман һәм Агыйдел дәрьяларын кичеп, янә Актаныш җиренә аяк бастык. Бу юлы без 10 көн дәвамында 5 авылда булдык: Зөбәер, Иске Уръяды, Күҗәкә, Түке, Чәчер.

Сәяхәтебез Иске Уръяды авылыннан башланды. Бу авылның аксакалы 77 яшьлек Минсалих Кәримовның гаҗәеп шәҗәрәсе бар икән. Минсалих ага һәркем белергә тиешле җиде бабаны гына түгел, хәтта ун бабасын белә. Иң борынгы бабасы Әсфиян Казан ягыннан килгән икән. Әсфиянның улы – Чурай, Чурайның улы – Сырам, аның улы – Уразай, аның улы – Үткә, аның улы – Шешә. Болар барысы да борынгы төрки исемнәр. Шуннан соңгы бабалар: Мөхәммәт, Колшәриф, Ибраһим, Мөхәммәтхафиз.

Минсалих аганың әтисе – Мөхәммәткәрим. Аның сигез улы булган. Улларының исемнәре дә я Мөхәммәт, я Мулла дип башлана, бары кече улына гына, миңе булганлыктан, Миңлесалих дип кушкан. Халык аны Минсалих дип кенә йөртә. Һәм шушы буын белән «Мөхәммәт»ләр, «Мулла»лар тәмамлана, «Миңле»ләр башлана. Минсалих аганың улы – Миңлефеликс, абыйсы Мөхәммәтҗанның уллары – Миңлефәвасим, Миңләәҗеп. Ә әтисе белән бертуган абыйсының оныклары – Миңлешәриф һәм Миңлегабдулла.

Заманалар үзгәрә, нәтиҗәдә «Миңле»ләр дә тәмамлана. Нәсел агачының иң очындагы яфракларын заманча исемнәр йөрткән яшьләр тәшкил итә: Таһир, Васил, Альберт, Рамил.

Минсалих аганың шәҗәрәсе, – әлбәттә, зур хәзинә. Тагын бер шундый ук борынгыдан килгән шәҗәрәне без, Әбүбәк ага Шәехов ярдәме белән, Күҗәкә авылында таптык.

Күҗәкәнең 82 яшьлек аксакалы Имаметдин Гыймазетдинов, бик мавыгып, авыл тарихын, элеккеге тормыш-көнкүрешне сөйли. Алар буынына тормышның ачысы-төчесе күп эләккән. Ләкин халык, тормыш авыр дип, кайгырып кына утырмаган, бәлки иң авыр дәверләрдә дә күңел ачуны кирәк санаган, бөтен авыл бердәм булып, рәхәтләнеп бәйрәм иткән.

Бәйрәмнәрнең иң күркәме ул чорда да Сабан туе булган. Сабан туе хәзерге кебек җәй көне яисә язгы кыр эшләре беткәч түгел, бәлки борынгыча, язгы кыр эшләре башланыр алдыннан, ягъни апрель аенда уздырылган. «Сабан туенда ат та йөгерде, адәм дә йөгерде, кыз ярәшкән кешеләрдән бүләк тә җыйдылар, – ди Имаметдин ага, үзенең балачагын искә төшереп. – Көрәш мәйданы кипкән, сукмаклар салынган була иде, су эчәсе килсә, чокырга төшеп кар ашый идек».

Язгы чәчү тәмамлангач, озакка сузылган җыеннар чоры башланган. Крестьян агай, арбасына гаиләсен төяп, башка авылларга – туганнарына, дусларына яисә танышларына кунакка йөргән. Иң элек, май башында, күҗәкәлеләр Юа җыенына юнәлгәннәр. Әлеге җыен (хәзер инде исеме генә калган) Үмәнәй авылында өч атна буе һәр җомга саен уздырылган. Бу җыеннан көнендә үк кайтканнар, кунмаганнар. Имаметдин ага болай дип сөйли: «Егетләр-кызлар, тау башына менеп, түгәрәк уены уйныйлар иде, ә өлкәннәр түбәндә гармунга, скрипкәгә кушылып җырлыйлар иде. Аннары Бикбау авылыннан Кәлимулла дигән кеше килеп, үзе җырлый, үзе бии торган иде. Гармунга кушылып, сандугач булып та сайрады, карга булып та кычкырды. Гаҗәеп кеше иде».

Шулай, Юа җыены белән юанып, майның өч атнасы узып та киткән, ә дүртенче атнада инде Күҗәкә халкы Олы җыенга Пучы авылына юнәлгән. Бирегә кунаклар шулай ук җомга көнне килгәннәр һәм ике яисә дүрт кич кунганнар. Бер яки өч кич кунарга ярамаган, чөнки алар – так саннар.

Июнь аенда Әмәкәй авылында Мәрди җыены, ә июль башында Иске Кормашта Бикә җыены узган. Бикә җыенында шулай ук дүрт көн кунак булганнар. Бурсык чишмәсе яланына яше-карты чыккан. Егетләр кунак кызлары белән танышканнар, түгәрәк уеннар уйнаганнар, олылар исә күбрәк вакытларын, гармун-скрипкага кушылып, җырлап уздырганнар.

Бикә җыеныннан соң июльнең икенче җомгасында Ямалы җыены башланган, ә аннан соң халык Мәлкән дигән керәшен авылына Туйра җыенына юнәлгән. Бу инде соңгы җыен булган, Туйрадан кайтуга уракка чыкканнар. Хәер, кунаклар арасында

кайвакыт бу җыенга икешәр җир[1] урак урып килүчеләр дә булган. Бәйрәм барыбер дүрт көн дәвам иткән.

Шулай итеп, урак алдыннан аек халык аек акыл белән, аек хискә бирелеп, кайгы-хәсрәтләрен онытып, ихластан бәйрәм иткән, күңел ачкан. Без Иմаметдин агадан әнә шуларны белдек.

Менә инде без «өметсез» дип аталган һәм ике генә карчык яшәп калган Илтимер авылы яныннан узып, күпер аша Түке авылына килеп кердек. Биредә, нишләптер, безне кәкре койрыклар һау-һаулап каршыламады. Гомумән күренмәде алар. Соңыннан белдек: авыл җыены «маэмайларсыз гына яшәргә» дигән карар чыгарган икән. Казанның үзәк мәйданнарында да зур-зур эт туйлары күреп гадәтләнгән без фәкыйрьләрегезгә бу карар хәтта сәер булып тоелды.

Уйлап карасак, чыннан да, ни хаҗәтемә соң ул маэмай?! Урлашулар булса, иң элек ишек-капкаларны бикләп йөрерләр иде, ә биредә алар тәүлек буе ачык. Дөрес, кайвакыт йозаклы ишек очрый очравын. Андый вакытта хуҗаларның кайтканын бераз көтеп торырга туры килә. Әнә хуҗабикә инде кайтып та килә. «Нишләп тышта торасың, апаем», – ди ул, ягъни энем дигән сүз инде. «Соң, ишектә йозак ич», – дигәч, «И-и… ул бит фасун өчен генә. Аның ачкычы югалганга да биш-алты ел бар инде», – дип гаҗәпләндерә.

Шулай итеп, монда йозак өйдә кеше юклыгын гына белдерә икән.

Әгәр инде маэмайга мәхәббәтең зур икән, рәхим ит, асра, әмма ләкин бәйгә куй. Бәйдән ычкындырасың икән – ясинын да укып озат.

Менә шундый булып чыкты бу Түке дигән авыл. Анда әтәч тавышы гына ишетелә. Хәер, тагын бер тавыш бар икән – матай тавышы. Биредә малайлар тәпи йөри башлагач ук матайга атланалар микән әллә дип, гаҗәпләнеп тордык. Басмасына аяклары да җитми, ә үзләре җилдерәләр генә. Яңгырсыз җәйге челләдә кирәксә-кирәкмәсә дә арлы-бирле тыз-быз чабып, авыл

[1] Чәчүлек җир мәйданын үлчәү берәмлеге: 2 дисәтинә, ягъни буе 80, иңе 60 сажиннан гыйбарәт мәйдан.

урамнарын тузанга күмеп йөргән ташбашларның бу кыланышларын бик үк өнәп бетермәсәк тә, күңелне бер сөенеч рәхәтләндереп торды: яшьләр бар биредә, техника белән җенләнгән балалар бар! Димәк, авыл яшәячәк. Югыйсә күршедәге үк Чәчер авылында 72 хуҗалык исәпләнсә дә, яшьләр ике генә бөртек, диделәр. Алары да читтән килгән белгечләр икән. Шуннан авылның киләчәген күзаллау кыен түгел инде. Ә Түкедә без матайга атланып чапкан үсмер кызларны да күрдек хәтта.

Хуш… Сүз башым бит шүрәле дигәндәй, мин бит әле биредә әкият, җыр, бәет юллап йөрүче. Әйе, Фәрзәнә Солтановадан нәкъ менә шүрәле турындагы, Мөслимә Солтановадан өч бур, Гыйльмегали Ганиевтән бай һәм чегән турындагы әкиятләрне, ә Нурлыҗиһан Зариповадан бәет һәм мөнәҗәтләрне язып алганнан соң, мин 85 яшьлек Хәмидә әби Халикова капкасына килеп җиттем.

Хәмидә әби җырлап торды, ә мин аның җырларын кәгазьгә төшереп тордым. Ниһаять, ул: «Җыруым бетте», – диде. Таныш сүз бу, аны һәр информанттан ишетергә мөмкин. Ләкин «бетте»дән соң да, гадәттә, күп нәрсә искә төшүчән була. Әмма Хәмидә әбинең ноктасы катгый булган икән. Шуны ул тагын бер куплет җыр белән ныгытып куйды:

Бишмәтеңдә биш төймә,
Алтынчысы – каптырма;
Бар җыруым шушы инде –
Юк җыруны таптырма!

Менә шулай. Ышанабыз – җыр сандыгының бушап калуы да бик мөмкин.

Ә менә Зөбәер авылында яшәүче 72 яшьлек Мөзәянә Садыйкова 200 куплет җыр яздыргач, мин аңардан үзем сорадым: «Беттеме?» – дидем. «Һәй, җыру бетми инде ул, – диде Мөзәянә апа. – Тик менә искә генә төшми тора».

Хәер, бу 200 кыска җырны, ягъни дүртьюллыкларны искә төшерергә Мөзәянә апаның Пермь өлкәсеннән кунакка кайткан кызы Фәйрүзә дә ярдәм итте. Ул үзеннән берни дә өстәмәде. «Барысы да әни җырлары», – диде. Аның хәтере дә галәмәт икән – яшь чагында әнисе җырлаган җырларны әлегәчә исендә тоткан! Югыйсә күп гомер узган бит инде, ул үзе дә 50 не тутырган. Алар аналы-кызлы, бер-берсе белән ярышкандай, җырларны искә

төшереп, икесе бер үк вакытта әйтеп яздыралар. Әйтеп торып яздырганда бер кешене ике кеше язса гына өлгереп була. Димәк, ике кешене язганда дүрт писер таләп ителә, ә мин берүзем. Язып өлгерә алмагач, кайбер куплетлар шунда ук онытылып та китә. Аннан бергәләп эзли башлыйбыз: «Беттеме?» дип соравым да «җитте инде» дигән мәгънәдә түгел, ә арыган бармакларны язгалап алганда болай гына, әлеге дә баягы «фасун» өчен генә, әйтелгән сүз. Югыйсә фольклорчы беркайчан да язып туймый, әсәрләр күп язып алынган саен: «тагын, тагын» дип кенә тора ул. Мин дә, бармакларым бераз язылгач, әлеге шул «тагын»ны кабатлыйм. Мөзәянә апа: «Искә төшми бит әле, тукта, бер әйләнеп керим», – дип, тышка чыгып китте һәм озакламый килеп тә керде. «Биш җыру искә төште», – диде ул зур канәгатьлек белән.

Ишек алдым яшел чирәм –
Атларга кимертмәгез;
Чит илләрдә ялгыз башым –
Хатларга тилмертмәгез.

Мөзәянә апаның күп җырлары «сандугач» дип башлана иде. Соңыннан санадым: алар 31 данә. Алардан кала 20 җыр «Кулымдагы йөзегемнең» дип башлана. «Алма» һәм «Алмагач» дип башланганнары – 15, «Гармун» һәм «Уйна, дустым» дип башланганнары – 12. Аннан инде «Агыйдел», «Җырлыйк әле», «Китә казлар», «Тәрәзә төбем» дип башлана торганнар һәм башкалар. Арада шаян җырлар да бар.

Шаян җырлар уңае белән Мөзәянә апа үзенең җор телле авылдашы Нургалине искә төшерде.

Нургали үзенең хәләл җефете Саҗидә белән чүкердәшеп кенә яшәп ятканда, Бөек Ватан сугышы башлана. Саҗидә иренә язган сагыну-сагыш тулы хатларының азагына җырлар да теркәп җибәрә. Аның бер җыры болай:

Стена көзгем ватылды
Ал пудр ягынганда,
Төннәргә көннәр ялгана
Өзелеп сагынганда.

Шаян кеше – һәрвакыт шаян инде ул. Утлы дәһшәт эченнән, салкын окоптан Нургали үзенең хатынына җавап юллый:

Стена көзгең ватылгач,
Ник пудр ягынасың?
Ул пудрларны ягынгач,
Ник мине сагынасың?

Хатынының икенче җыры:

Одеал микән, юрган микән
Синең ябынганнарың?
Син дустыма мәгълүм микән
Минем сагынганнарым?

Ире болай дип җавап бирә:

Одеал да юк монда,
Юрганнар да юк монда,
Көне-төне пуле ява –
Синең кайгың юк монда.

Күренеп тора: Нургали солдат – Василий Тёркиннар токымыннан. Һәр халыкның үз Тёркиннары булган, бар һәм булачак.

Мөзәянә апа тагын тукталып калды. Аннары җәһәт кенә торып, үзенең 72 яшьтә булуын да онытып, җиңел генә идән астына төшеп китте һәм шунда ук кире килеп чыкты. Тагын бер җыр артты:

Җаныемның исемнәре
Кулымдагы йөзектә,
Төштем кайгы күлләренә –
Чыгалмыймын ничек тә.

Җырчыбыз янә аска чумды, һәм бераздан апаның башы кабат күренде, янәшәдә «варенҗе» банкасы пәйда булды. «Кара син аны, базда яткан икән җырулар», – диде ул. Дәфтәргә тагын берничә куплет өстәлде:

Алларын сана миңа,
Гөлләрен сана миңа.
Өйләнмәгән булсаң гына,
Елмаеп кара миңа.

Алым син, җаныкаем,
Гөлем син, җаныкаем.
Ярларымның азаккысы
Булырсың, җаныкаем.

Көмеш йөзеккәем сынды –
Бакырын киям инде;
Көзге яф(ы)раклар кебек,
Саргаеп кибәм инде.

Шулай итеп, Зөбәер авылының хезмәт ветераны Мөзәянә апа Садыйкова җырлар саны буенча рекорд куйды – аның дүртьюллыклары 232 данәгә җитте. Дөрес, мондый кыска җырларны без кайбер һәвәскәрләрдән күбрәк тә алып кайтканыбыз бар. Әмма алар альбомнарга, дәфтәрләргә тупланган була иде. Ә хәтердән шул кадәр җыр яздыручы безгә беренче мәртәбә очрый. Хәтер дисәң дә хәтер!

Мөзәянә апаның җырлары гына түгел, һөнәрләре дә хәзинә икән! Ул колхозда эшләгән, балалар үстергән, палас тукыган, чабата үргән… Кирәк икән, бүген дә тукый да, үрә дә ала. Кирәкми генә. Шулай да, бүгенге яшьләргә әлеге һөнәрләрне гамәлдә күрсәтәсе иде. Гыйбрәт өчен.

Безне озатканда ул болай дип җырлады («Баламишкин» көенә):

Түбәтәең сәйләндер,
Сәйлән ягын әйләндер;
Бик сагынган чакларыңда
Зөбәердән әйлән бер.

Әйләнербез, нигә әйләнмәскә! Зөбәернең матур су буйлары, аның искиткеч буасы, ямь-яшел чирәм белән капланган киң урамы, бигрәк тә без очрашкан гүзәл кешеләре сагындырыр, әлбәттә. Аннары бит Мөзәянә апа безне озатып калганда да «җыру бетми инде ул» дип кабатлаган иде. Бәлки әле исенә төшеп, аларны язып та куйгандыр. Әйләнербез. Боерган булса, әйләнербез. Барыбыз да сау-сәламәт кенә булыйк!

Һәм менә 22 ел гомер узганнан соң, без – тагын Актаныш җирендә. Профессор Дария Рамазанова җитәкләгән әлеге комплексны экспедициядә тел, әдәбият, тарих, музыка һәм фольклор өлкәсендә эшләүче галимнәр һәм аспирантлар катнашты. Экспедициянең эше Актанышка – 300 ел һәм районының оешуына 80 ел тулу уңаеннан тантаналы чараларга әзерләнү вакытына туры килде.

Юбилейлар уңаеннан «Актаныш таңнары» газетасы район авылларына бәйле тарихи белешмәләр, риваятьләр, өлкән буын вәкилләренең истәлекләрен бастыра башлаган. Газетаның бер санында педагог Гавис Гаязов тәкъдим иткән материалдагы риваятькә караганда, Актанышка хәзер 300 түгел, ә 470 яшь булырга тиеш. Әлбәттә инде, риваять тарихи дәлил була алмый, әмма халыкта шундый фикер дә бар икән. Хәтта бу фикерне раслый торган ниндидер документ та булган, имеш.

Ә район тарихындагы әлегә кадәр ачыкланмаган мәсьәләләргә килгәндә, аларның берсе авыл зиратларындагы гарәп хәрефләре белән язылган кабер ташларының укылмаганлыгы булып чыкты. Шуңа күрә кайбер могтәбәр затларның каберләре дә әлегәчә мәгълүм түгел икән. Бу җиңел булмаган эшне хезмәттәшебез – тарихчы-археограф Рәшит Кадыйров бик уңышлы башкарып чыкты.

Фольклорчылардан без дүрт кеше идек: фәнни хезмәткәр Ильмир Ямалтдинов, аспирантлар Гөлия Гыйләҗиева, Алсу Гайниева һәм мин. 8 көн дәвамында Актаныш районының 14 авылында булдык. Әлбәттә, татар мохитендә фольклор хакимлек иткән чорда бу вакыт кысасында эшләү өчен 4–5 авыл да җитәр иде, әмма хәзер заманы башка, кешеләр башка, рухи мираска мөнәсәбәт башка... Фольклор бүгенге көндә, аерым очракларны исәпкә алмаганда, нигездә, 60 яшьтән өлкән кешеләрдә генә очрый. Кешенең уртача гомер озынлыгы шушы сан тирәсендә тирбәлгән безнең илдә фольклорчыларның әңгәмәдәшләре (информантлары) күпме булуын чамаларга мөмкиндер. Шуның өстенә авылларның зурлыгы да элеккечә түгел ич. Дөрес, районның 540 хуҗалыктан торган Татар Суыксуы, 283 хуҗалыктан гыйбарәт Такталачык кебек чагыштырмача зур авыллары бар барын. Әмма алар тирәсендә 26 йортлы Түмерҗә һәм 2 генә йорты калган Түбән Карач кебекләре дә бар бит әле...

Түбән Карачта 76 яшьлек Гөлҗәннәт әби яши. Әби фикеренчә, аның авылын, ике йорт кына калсын, дип, шүрәле каргаган булган. Аңарда башка фольклор әсәре булмаса да, без канәгать булдык, чөнки әби бернидән дә курыкмый, шушында яши бирә. Фамилиясе дә – Арсланова.

Ә менә сәнгать фәннәре докторы Гали Арслановның туган авылы Түмерҗәдә дөньяга килгән 78 яшьлек Җәмилә әби Шәмсиева, хәтере начарлыктан зарланса да, безне буш кул белән чыгармады – ике куплет кына булса да җыр яздырды. Берсе болай:

Агыйделдә ике сал:
Берсе – имән, берсе – тал;
Коммунизм яшәгәндә
Яши алмый капитал.

Совет халкының бу буыны әнә шундый җырлар җырлап үскән.

Уразай авылында яшәүче Зәкия әби Халикова да җыр ярата. Аңа 96 яшь. Дөм сукыр булса да, аның күңелен җыр яктырта. Тукай вафат булган 1913 елда туган Зәкия әбигә әйтерсең лә шагыйрьнең халык җырларына булган мәхәббәте дә күчкән. Биш куплет җыр яздырды Зәкия әби.

Сабырлар ит, җаныкаем,
Сабырлар – сары алтын;
Мин сабырлар итәлмимен –
Эчләрем тулы ялкын.

Инде җыр турында сүз чыккан икән, авылларда җырның иң популяр жанр булуын искәртеп узыйк. Барлыгы 27 лирик җыр, 3 уен җыры һәм 72 кыска җыр (дүртьюллыклар) тупланды. 72 саны бу экспедиция хисабында иң зур сан булып тора. Ә бит әлеге шартлы рәвештә «кыска җыр» дип атап йөртелә торган, үзенә беркетелгән махсус көе булмаган һәм төрле көйләргә башкарыла ала торган мондый дүртьюллык поэтик әсәрләрне элгәреге экспедицияләр меңнәрчә данә туплыйлар иде. Мәсәлән, 1948 елгы экспедиция Актаныш районыннан 4288 кыска җыр алып кайткан! Бүген инде моңа ышануы да кыен. Әле соңгырак чорда да кыска җырлар шактый күп җыела иде. Мәсәлән, алдарак әйткәнемчә, 1987 елгы экспедиция вакытында Зөбәер авылында 72 яшьлек Мөзәянә Садыйкова, Фәйрүзә исемле кызы белән бергә, 232 кыска җыр әйтеп яздырды. Ул вакытта Актаныш районы буенча җәмгысы 267 кыска җыр тупланды. Ә быел, әйткәнемчә, 72 генә. Рухи мирасыбызның иң популяр,

иң ләззәтлесе булган, күңелләрне айкап ташлый торган, җилкендерә, уйландыра, моңландыра, елата, юата, рухландыра, дәртләндерә торган төре – халыкның үз җыры, газиз баласыдай якыны, аның җан азыгы югалып бара икән ләбаса... Шуннан инде фикер йөртик: кайсы чор кешеләре рухи яктан баерак?

Кызганыч, рухи җәүһәрләр яшь буынга күчми, тапшырылмаган мирас булып, өлкәннәр күңелендә кала, әкренләп онытыла һәм ахыр чиктә бөтенләй югала. Югалган байлыкның күләмен кем генә исәпләп чыгарыр икән...

Мөнәҗәт әйтүче әбиләр исә без булган авылларның күбесендә очрады. Барысы 18 берәмлек (456 юл) мөнәҗәт язып алынды.

Актаныш төбәгендә бигрәк тә бәетләр популяр икән. Аеруча Такталачык авылында. 23 бәетнең (1083 юл) 16 сы бередә тупланды. Күбесе Альберт Яркәев чыгарган бәетләр. Шушы авылда үскән яшь шагыйрь Ленар Шәехнең дә бу өлкәдә үз өлеше бар. Ә бәет өчен сәбәп, ни кызганыч, тормышта булгалап тора шул.

Инде фольклор байлыгының төп үлчәме булган әкиятләр турында берничә сүз. 1948 елгы экспедиция вакытында әкиятчеләр күп авылда булган әле. Әлеге сәяхәт нәтиҗәсендә, алда әйтелгәнчә, барысы 37 әкият тупланган. Шушы экспедициядә студент буларак катнашкан Нурихан Фәттахка Әнәк авылында яшәүче 14 яшьлек Рахмай Хисмәтуллин да (икесе дә язучы булып танылдылар, инде урыннары җәннәттә булсын) дүрт әкият сөйләгән. Димәк, ул чорда фольклор әле балалар телендә дә актив яшәгән.

1987 елгы экспедиция материаллары арасында, әйткәнемчә, Түке авылында өлкәннәр авызыннан язып алынган 3 кенә әкият саклана. Безнең соңгы 2009 елгы экспедициябез исә Актаныштан бөтенләй әкиятсез кайтты. Димәк, әкият учагы тәмам сүнгән... Кызганыч, бу хәл һәркайда да шундый хәзер.

Ә менә бу сәяхәтебездә фольклорның чагыштырмача сирәк очрый торган, атап әйткәндә, сөйләк жанрына караган әсәрләргә юлыгуыбыз экспедициянең үзенә күрә бер табышы дип бәяләнергә хаклыдыр. Реаль тормышта күптән түгел булып узган игътибарга лаек вакыйга сурәтләнгән мондый әсәрләр турында

фольклорчыларның үз араларында да әлегә бердәм фикер юк. Кемдер аны истәлек белән тиңли, кемдер сөйләү үзенчәлеген жанрның төп билгесе итеп саный. Дөресен әйткәндә, бу жанрга игътибар җитенкерәми, шуңа күрә андый әсәрләр аз җыела да инде.

Менә, мәсәлән, Күҗәкә авылында Рамил Хәйбиев сөйләгән бер әсәр.

Вакыйга Сталин хакимлек иткән чорга карый. Авылның бер кешесен төрмәгә утыртырга телиләр. Әмма гаеп табарга кирәк бит. Ат белән эшли торган бу абзый кич эштән кайтыр вакытта, аның юлына бер капчык ашлык ташлыйлар. Абзый шул капчыкны алып арбасына салса, ул инде урлаган саналачак. «Пүнәтәй»ләр күзәтеп тора. Бәхеткә, абзый арбада теге капчык ягына түгел, икенче якка карап утырган була. Шулай итеп, ул бәладән котылып кала. Соңрак, бу хәлләр мәгълүм булгач, ул үзен Алла саклаган дигән нәтиҗәгә килә.

Тормышта булган вакыйга турындагы әлеге әсәр – сөйләк жанрына бер мисал. Ә беренче зат авызыннан сөйләнсә, ул истәлек булыр иде. Истәлек исә фольклор әсәре була алмый, чөнки фольклор кагыйдәләренә туры килми. Әмма аның бик мөһим үз вазифасы бар. Бу экспедициядә фольклорчыларга 6 сөйләк һәм 12 истәлек язып алу насыйп булды.

Фольклорның башка жанрларына килсәк, 10 табышмак, 11 мифологик хикәят, 22 мәзәк, 31 мәкаль, берничә риваять һәм дистәдән артык авыл тарихы язып алынды. Халык уеннары турында 30 дан артык язма (уеннарның саны исә 5–6 гына) тупланды.

Турыдан-туры фольклорга карамаган материаллар да читтә калмады: шәҗәрәләр, йолалар, шигырьләр һәм ономастикага кагылышлы 40 тан артык мәгълүмат тупланды. Иске Teләкәй авылыннан Әдибә Хәбирова (76 яшь) һәм Иске Богады авылыннан Рәзилә Салихова (70 яшь) безнең Институтка гарәп графикасындагы язмалар, кульязма һәм басма китаплар һәдия кылдылар. Бу материаллар барысы да Институт мирасханәсендә саклнаначак һәм фәнни тикшеренүләрдә файдаланылачак.

Гомумән, 2009 елгы экспедициянең эшчәнлеге уңышлы саналырга хаклы. Тугыз көндә без 14 авыл (Адай, Әҗәкүл, Әнәк,



Факирә Мусинаның дәфтәре
юка булса да, җыры күп.
Күҗәкә. 2009 ел



Хәниф Гәрәев күп җырларның
тарихын белә икән.
Зөбәер. 2009 ел



Истәлеккә сурәт. Институт вәкилләре Чуракай авылында.
Беренче рәттә – «Алга» хуҗалыгы җитәкчесе Назыйм Шәехов
әнисе Рәүфә апа һәм әтисе Зөфәрит ага белән. 2009 ел

Ирмәш, Иске Сәфәр, Иске Уръяды, Карт, Күҗәкә, Такталачык, Татар Суыксуы, Түбән Карач, Уразай, Чөгәнә, Чуракай) халкы белән танышып, җәмгысы 346 берәмлек хәзинә тупладык, шуның 270 е саф фольклор әсәрләре. Шигъри әсәрләрнең юл саны 1818 данә. Әлбәттә, бу нәтиҗәләрдә район хакимиятенең, җирле үзидарә башлыкларының, хуҗалык җитәкчеләренең һәм мәдәният хезмәткәрләренең ярдәме зур булды. «Юл газабы – гүр газабы», – ди халык. Әмма без юлда газап күрмәдек. Актанышлыларның олысы-кечесе безгә теләктәш булды. Иң элек экспедицияне районның хакимият башлыгы Энгель Нәвап улы Фәттахов үзе кабул итте, безне район белән таныштырды, фәнни эшебездә уңышлар теләде. Хакимият вәкиле Кадрия ханым Идрисова һәрвакыт безнең белән элемтәдә булды, еш кына без эшли торган авылларга килеп чыкты, кайберләренә хәтта үзе озатып куйды.

Безнең алга куелган бурычны башкарып чыгуда, мәсәлән, Күҗәкә җирлегендә Р. З. Хәйбиев, Татар Суыксуында Р. Г. Харисов, Уразайда Р. М. Исламов, Иске Сәфәрдә Р. Н. Фарсыев, Чуракайда Т. Р. Хәсәнов, Н. З. Шәехов һәм башка җаваплы затлар, экспедициянең ихтыяҗларын аңлап, төрле яклап ярдәм иттеләр. Бигрәк тә Рамил Хәйбиев һәм аның әтисе Зәки ага, шулай ук Назыйм Шәехов һәм аның әтисе Зөфәрит ага, безнең эшебез җайлы һәм тоткарлыксыз барсын өчен, барысын да эшләделәр. Эш җайлы бармаган булса, 9 эш көне дәвамында фольклорчылар 14, ә башка белгечлек галимнәре 36 авылда булып, бай материал туплый алырлар иде микән?! Шуңа күрә без Актаныш төбәгенең биредә исемнәре аталган һәм аталмаган бик күп мәрхәмәтле затларына – җитәкчеләргә һәм мәгълүмат җиткерүчеләргә – олуг рәхмәтебезне белдерәбез.

Хөрмәтле укучылар! Менә без сезгә Актаныш төбәгенә оештырылган фольклор экспедицияләре турында беркадәр мәгълүмат ирештердек. Бу экспедицияләрдә халык иҗатының төрле жанрларына караган әсәрләрне, күңелләрендә кадерләп саклап, безгә ирештергән могтәбәр затларның күбесе әле дә күз алдыбызда тора. Ә бит аларның шактые инде бакыйлыкка күчкән. Әмма алар теле белән сөйләнгән әсәрләр исән. Әлеге

әсәрләрнең бер өлеше кулыгыздагы китапка да кертелде. Ул әсәрләрне сөйләгән затлар арасында сез авылдашларыгызны, туганнарыгызны, танышларыгызны очратырсыз, хәтта үзегез белән дә очрашуыгыз мөмкин. Узган гасырның 70–80 нче елларында безгә балалар фольклоры әсәрләрен язып җибәргән 10–13 яшьлек сабыйлар да бүген 40–50 яшьлек ил томкасы затлар ич! Рәхим итеп, танышыгыз әле фольклор дөньясындагы актанышлылар репертуары белән.

## ӘКИЯТЛӘР

### Урман каравылчысы

Борын-борын заманда булган икән, ди, бер урман каравылчысы. Моның булган, ди, унбиш яшьләрендә бер малае. Көннәрдән бер көнне карт авырып китә дә малаен чакырып әйтә:

– Улым, – ди, – бездән без булмаенча, шөшле булмас инде, – ди, – мин үлгәч, син минем урынга урман каравылчысы булып калырсың, – ди.

Бераз рәтләнү белән, карт үзенең урман чикләрен күрсәтергә дип, малаен ияртеп чыгып китә.

Биш-алты көннәр йөреп, урман чикләрен әйләнеп чыкканның соңында, карт малаена әйтә:

– Мин күп еллар урман каравылчысы булып эшләдем, ләкин менә бу юлга кергәнем булмады, бел аны: ул юлга керергә ярамый, – дип, малаена бер юл күрсәтә бу.

Шулай йөреп, урман чикләре белән танышып кайталар болар. Күп тә тормый, карт үлеп китә.

Әтисе үлгәч, малай үзе урман каравылчысы булып кала. Өч-дүрт еллар буена урман каравыллап йөргәннең соңында, беркөнне малай, карыны бик ачыгып, әтисе «керергә ярамый» дигән теге юл чатына килеп утыра. Уйлый инде бу: «Әти ничә еллар буена шушы урманда йөреп, шушы юлга керергә куркып үлеп китте. Нәрсә бар икән, монда кереп карасам нәрсә булыр икән?» – дип уйлый.

Бераз ял итеп утырганнан соң, тора да бу кереп китә. Озак та үтми, ике дию пәриенең сугышып яткан җиренә барып чыга бу.

Моның үзе белән бер кәрзине, бер песие, бер балтасы була. Дию пәрие, суырып, боларны үз янына тартып китерә. Шул арада песи, йоннарын кабартып, диюгә ташлана, аның башына кадәр менеп, ике күзен тырмап чыгара. Егет бу сукыр диюне балтасы белән чапкалап, тураклап бетерә. Җиңгән дию белән бергәләп, җиңелгән диюнең сөякләрен зур-зур әрдәнә итеп өеп куялар. Шуннан соң теге егет ярдәмендә җиңеп чыккан дию егеткә әйтә:

– Син зур егетлек күрсәттең, – ди, – мин сине үзебезгә кунакка алып китәм, – ди. – Атланып утыр минә минем сыртка, – ди, – песиеңне дә калдырма, – ди.

Хәзер җил-давыл куптарып күккә күтәрелеп китәләр болар. Бервакыт бер зур двор эченә барып төшәләр. Тирә-ягы амбар, канюшниләр белән әйләндереп алынган өч катлы зур йорт.

Дию малайга әйтә:

– Син шушында торып тор, ә мин этиләр янына кереп: «Бер кунак алып килдем, сез аңа тимәгез, мин шул егет аркасында гына җиңеп чыктым», – дип әйтермен, – ди.

Дию этиләре янына кереп чыга да малайны өенә алып керә. Егетне ике көн бик шәп кунак иткәннән соң, дию әйтә моңа:

– Без кунакны өч көннән артык тотмыйбыз, мин сине иртәгә теге без очрашкан урынга илтеп куярмын, – ди. – Тик шунысы, – ди, – иртәгә эти сиңа бөтен байлыгын, амбар тулы алтын-көмешләрен күрсәтер, шуларны бүләк итәргә тырышыр, син аларның берсен дә алма, – ди. – Алар, бездән китү белән, чүп-чарга әвереләчәкләр, – ди. – Әтинең тәрәзә төбендә бер кечкенә генә көзгесе булыр, син шуны сора. Аның ул көзгене сиңа бирәсе килмәс, мин аның ирегенә куймаенча бирдерермен. Син шул серле көзге ярдәмендә яхшы гомер итәрсең, – ди.

Өченче көнне иртә белән карт дию кунак егетне чакырып алып, бөтен байлыкларын күрсәтеп чыккач әйтә моңа:

– Улым, – ди, – син миннән берәр бүләк алып кит, – ди, – сиңа миннән нәрсә кирәк: алтынмы, көмешме? – ди.

Малай бабайга әйтә:

– Безнең үзебездә дә алтын-көмеш бик күп, – ди, – миңа әнә шул тәрәзә төбендәге кечкенә генә көзгеңне бирсәң, бик шәп булыр иде, – ди.

Бабай:

– Улым, – ди, – нәфесең бик зурдан икән, мин сиңа аны бирә алмыйм, – ди.

Алай булса да диюнең малае, әтисеннән бик каты үтенеп, сихерле көзгене егеткә бирдерә.

Көзгене бирдерү белән, дию малае урман караучы егетне сыртына утыртып, үзе алып килгән җиргә илтеп куя да, егет белән саубуллашып, өенә кайтып китә.

Каравылчы малай, кичкә кадәр урман буйлап йөреп бик нык арыганнан соң, бер зур аланда ял итәргә утыра. Бу егет бик каты ачыккан була. Шуннан соң уйлый бу: «Мин җүләр дә инде, ник соң мин бу көзгене алганмын, – ди. – Берәр капчык бик яхшы ашамлыклар алган булсам, ул миңа унбиш-егерме көн буена ашарга җиткән булыр иде», – ди. Шулай ди дә, диюдән алган көзгене кесәсеннән алып җиргә ташлый, көзге ачылып китә. Көзге ачылып китү белән, моның каршысына ике солдат килеп баса:

– Нәрсә кирәк сезгә? – диләр болар.

– Миңа ашарга китерегез, башка бернәрсә дә кирәкми, – ди.

Күз ачып йомганчы агачларның һәр яфрагы, бөтен үләннәр тәмле ашамлыкка әвереләләр. Малай тамак туйдырып йокыга ята. Йоклап торгач, серле көзгене кулына алып, әлеге солдатларны үз янына чакырып ала да боларга әйтә:

– Бу урманнар зур диңгез булсыннар. Бу алан урынына бер шәһәр салынсын. Ул шәһәрдә бик зур сарай булсын. Бакчадагы алмагачларның алмалары пешеп торсыннар. Мине шул шәһәрнең сараена илтегез, яныма бер бик матур патша кызын табып китерегез, иптәшлеккә, – ди дә тагын ятып йоклый бу.

Йоклап торуына зур бер сарайда була бу, үзе патша икән, янында бер патша кызы да була.

Бу егет һәр көн ауга барып, һәр көн ике үрдәк атып алып кайта икән. Көннәрдән бер көнне бу ауга чыгып китү белән, боларның йортына бер карчык килеп керә. Карчык бу егет хатынының таныш әбисе булып чыга. Әби әйтә теге патша кызына:

– Әй бәбкәем, – ди, – мин ерак иллләрдән сине эзләп, сагынып килдем, – ди, – син исән икәнсең, – ди. – Мин, бәлки, үзем

атаңнар янына кайта алмам инде, – ди, – мине үзегез янында тәрбияләп асрасагыз бик яхшы булыр иде, киявең нәрсә әйтер икән бу эшкә? – ди.

– Әй әбекәем, – ди, – патша кешегә бер карчыкны тәрбияләү берни түгел. Ул хәзер кайта, үрдәк атып алып кайтыр, син шул үрдәкне тазартып, аш әзерләрсең, – ди.

Күп тә үтми, егет өч үрдәк атып кайтып керә. Үрдәкләрне йолкып, чистартып аш әзерлиләр. Ә әбигә үзләрендә торырга рөхсәт итәләр.

Көннәрдән бер көнне әлеге патша-егетауга киткәчтен, әби кызга әйтә:

– Балам, – ди, – сез бик үк тату тормыйсыз бугай? – ди.

Кыз әйтә:

– Әбекәем, – ди, – ни телең белән әйтәсең бу сүзне, – ди. – Безнең чаклы тату торган беркем дә юктыр әле, – ди.

– Ай-һай, балам, – ди, – әгәр тату торсагыз, – ди, – кияү, – ди, – үзенең серле көзгесен сиңа күрсәтер иде, – ди.

– Әй әби, әнә безнең стеналар көзге белән тулган, ул яшь вакытында да кесәсенә көзге тыгып йөрмәгән, – ди.

Әби әйтә:

– Юк, – ди, – аның кулындагы көзге бик хикмәтле, бик серле көзге шул, – ди, – син аны алып кара әле, – ди.

Бер көнне шулай йокларга яткач, патша кызы иреннән көзгене сорап ала. Көзгене алып ачып карау белән, ике солдат моның каршысына килеп баса. Бу хатын, куркуыннан нишләргә белмичә, көзгене стена ярыгына кыстырып йокыга китә. Хатын йокыга китү белән, теге әби, иплэп кенә болар бүлмәсенә кереп, көзгене ала да ачып карый. Көзге ачылу белән, моның каршысына ике солдат килеп баса. Әби боларга әйтә: «Менә, – ди, – бу җирләр әүвәлдә ничек булган, хәзер дә шулай булсын, – ди. – Пристаньда бер генә пароход торсын, – ди. – Без дүртәүләп үзебезнең илгә кайтып китәрбез. Ә бу диңгезләр әүвәлгечә урман булып калсыннар, – ди. – Урман каравылчысы үзенең кәрзиненә башын салып, песиен кочаклап, урманы буенда йоклап калсын», – ди.

Бервакытны урман каравылчысы йокысыннан уянып китә, уянып китсә, ни күзе белән күрсен: пристаньдагы пароход

икенче свистокны бирә. Шәһәрләр, сарайлар юкка чыккан. Урыныннан сикереп торып, пароходка йөгерә башлый бу. Йөгерә торгач, бер каты тоз кисәгенә абынып егыла. Торып, билендәге балтасын алып тозга суга да, тоз берничә кисәккә ватыла. Тозның бер зур кисәген ала да, кәрзиненә салып, өченче свистокны биргән вакытта гына пароходка барып керә. Керү белән пароход та кузгалып китә. Сәгатьләр буена койрыкта утырып бара бу. Пароход артыннан диңгезнең сулары кибеп, урман үсеп килә.

Бер тәүлек чамасы вакыт үткәч, егет пароходның палубасына чыгып йөри башлый. Палубада йөргәндә, «Пароходка поварлар кирәк» дип язылган бер язу күрә дә бу капитанны күреп әйтә:

– Мин, – ди, – патшаның повары идем, – ди, – отпускыга илемә кайтып авырдым да патшага бара алмадым, мин повар булып эшли алыр идем, – ди.

Капитан кечкенә генә записка биреп, кухняга төшереп җибәрә моны. Бу тарихта беренче тапкыр тоз салып пешерә башлый. Бу илдә әле беркемнең дә тозлы аш ашаганы булмаган икән, ди. Бу пешергән аш шундый тәмле була икән, аның ашын бер ашаган кеше яңадан сорап, теңкәсенә тия икән, – ди. – Моның хатыны да дүрт обед алып, атасы, анасы, явыз карчык белән бергә ашыйлар икән, – ди.

Тора-бара бу үзенең хатыны белән очрашып сөйләшә.

Хатынына әйтә:

– Син, – ди егет, – этиеңнән рөхсәт алып, монда минем янга повар булып кер, – ди.

Кыз әйтә этисенә:

– Әти, – ди, – повар абый, өч-дүрт көндә шундый тәмле ашлар пешерергә өйрәтәм, дип әйтте, – ди, – мин аңа ярдәмче булып керим әле, – ди.

Әтисе рөхсәт итә. Патша кызы ярдәмче повар булып керү белән, обед алырга теге карчык йөри башлый. Кухняга керү белән, карчык урман каравылчысын таный да патшага барып әйтә:

– Безнең кызны урлап качкан урман каравылчысы пароходка повар булып кергән. Кыз да аның янында, ул сиңа оят китерер, хәзер үк ул егетне кулга алырга кирәк, – ди.

Шулай дигәч, патша бу малайны арестовать итеп, үз иленә алып кайта. Кайту белән, бөтен гаскәрләрен, вәзирләрен җыеп әйтә:

– Менә бу, – ди, – минем кызны урлап качкан урман каравылчысы, – ди. – Моңа нинди җәза бирәбез? – ди.

Күбесе:

– «Атарга!» дип хөкем чыгарырга, – диләр.

Бер полк карт солдатлар:

– Үзен, песиен, кәрзинен, балтасын бергә тугыз кат капка салып, таш бәйләп, диңгез уртасына батырыйк, – ди.

Моңа һәммәсе дә күнәләр дә, егетне тугыз катлы капка салып, тегеп, таш бәйләп, көймәгә утырып диңгезнең эченә үк кертеп суга аталар. Диңгез төбенә төшә-төшә зур ташларга бәрелеп, капның берничә каты ертыла да өскә күтәрелеп, егеткә бераз иркенлек туа. Ул балтасын алып капларны кисә дә су төбендә йөри башлый. Су төбендә йөри торгач, бер тар гына ишек кебек нәрсәгә барып төртелә. Кәрзине белән песие дә, балтасы да үзеннән ерак китми. Күрә бу: кечкенә генә ишек, ә токасы юк. Балта белән ишекне каерып ачып җибәрсә, ни күзе белән күрсен, күселәр шәһәре икән бу. Монда килеп керү белән, моның песие ике йөздән артык күсене үтереп, өеп куя. Шуннан соң песи әйтә:

– Хәзер мин сезнең патшагыз, – ди. – Миңа кадәр сездә кем патшалык сөрде, шул кешене миңа китерегез, – ди.

Күселәр әйтәләр:

– Ул килә алмас, бик карт инде, аңа хәзер өч йөз җитмеш яшь, тәхеттә генә утыра, – диләр.

Урман сакчысы чабатасын салып бирә дә, чабатага өч күсене тройка итеп җиктереп, коба тычканны ат башына утыртып: «Күсе патшасын алып кайтыгыз», – дип җибәрә. Күсе патшасын китерү белән, песи сорый тегеннән:

– Бу илдә сез патшалык сөреп тордыгызмы? – ди.

Карт күсе, бик куркып кына:

– Мин патшаның урынбасары гына булып тордым, – ди.

Песи әйтә:

– Менә мин приказ бирәм, – ди, – минем хуҗамның серле көзгесе югалды, – ди, – шуны хәзер үк табып китерегез, – ди.

Карт күсе әйтә:

– Көзгенең кайда икәнен белүен беләм мин, – ди, – ну бик ерак, – ди, – фәлән шәһәр читендәге бер кечкенә генә йорттагы карчыкның чәч толымында ул, – ди.

Ярар, өч күсене чабатага җигәләр, берсен кучерга утырталар, чикләвек кабыгыннан кыңгыраулар тагалар да, китәләр болар көзгене эзләп. Шәһәргә барып җитәләр. Шәһәргә барып җитү белән, карт күсе әйтә:

– Кыңгырауны бәйләгез, – ди, – пожар бар дип безне тотып алмасыннар, – ди.

Әлеге карчык өе янына барып җитәләр. Коба күсе разведкага кереп китә. Тәрәзәдән барып карый, әби ботка ашап утыра, янында бер колагы өшеп төшкән карт песие бар.

Болар бераз көтеп торалар да, әби йокыга китү белән, шыпырт кына бусага астыннан тишеп керәләр. Башта коба күсе кереп, әбинең өстәл астына куйган боткасын ашап туя да әйтә тегеләргә:

– Сез ботка ашый торыгыз, – ди, – ә мин, – ди, – көзгене алырга барам, – ди.

Бара әби янына, әби гырылдап йоклый. Шул арада әбинең чәч толымын кетер-кетер кисеп, көзгене алып чыгып карт күсегә тапшыра. Болар хәзер тиз генә кайтып китәләр. Шәһәрне чыккач, кыңгырауны чишеп җибәрәләр. Кайту белән песигә, ничек алып чыкканнарын бәйнә-бәйнә әйтеп, көзгене тапшыралар.

Песи көзгене егеткә тапшыра. Егет, зур рәхмәтләр әйтеп, көзгене алып ачып җибәрүгә, ике солдат килеп чыга. Егет әйтә:

– Безне шушы җирдән чыгарып, патша шәһәренә биш километр ара куеп, аныкыннан биш тапкыр зур итеп йорт төзеп бирегез, – ди.

– Була ул, – диләр солдатлар.

Иртә торышка йортлар төзелгән була. Патша, бу хәлне күреп:

– Минем җиргә, минем рөхсәтемнән башка кем шундый йорт төзегән, ул кешегә каршы мин ике сәгатьтән дә соңга калмыйча, сугыш ачам, – ди патша.

Егет моны ишетеп җавап бирә:

– Без әллә кайчан әзер, – ди.

Шуннан соң егет көзгене ачып җибәрә дә җыйналган солдатларга әйтә:

– Хәзер үк патша гаскәрләрен әйләндереп алыгыз, – ди.

Патша кызы, моның хатыны, бу эшне сизеп, этисенә әйтә:

– Әти, – ди, – бу минем иремнең эше, – ди, – без аны җиңә алмыйбыз, мин аның янына барып сөйләшеп кайтыйм әле, – ди.

Кыз егет янына барып үтенә, халыкны һәлак итмәвен сорый. Шулай дигәч, егет тә риза булып, хатыны белән килешеп, патшаны пенсиягә чыгарып, үзен патша итеп, әле дә булса хөкем сөрәләр, ди.

*Иске Кормаш авылында*
*Насыйр Фәрраховтан (40 яшь)*
*Х. Ярми язып алды. 1948*

## Каракош

Борын заманда булган икән, ди, бер карт. Бу картның өч кызы булган.

Көннәрдән бер көн карт базарга барырга җыена башлый. Китәргә җыенганда, ике кызын уятып сорый:

– Нинди бүләк алып кайтыйм? – дип.

Кечесен уятырга жәлли.

Китә бу базарга. Шушы вакытта кече кызы төш күрә. Төшендә биек коймалар белән әйләндереп алынган бер бакчада бик матур чәчәк белән уйнап йөргәнен күрә. Чәчәк белән озак кына уйнагач, чәчәкне югалта бу, эзли-эзли һич тә таба алмый. Чәчәкне таба алмавына кайгырып, җылап уянып китә.

– Сиңа нәрсә булды, ник җылыйсың? – дип, нихәтле генә сорасалар да, кыз җавап бирми.

Бакчаларына чыгып, аннан да теге чәчәкне эзләп карый кыз, андый чәчәк булмый.

Әтиләре базардан кайта, алган бүләкләрен бирә. Кече кызга апаларына караганда да күбрәк бүләк алган була. Шулай булса да кече кыз бүләкне этәреп кенә куя. Атасы гаҗәпләнеп:

– Ник алмыйсың? – диюенә кыз, яшьле күзләрен сөртә-сөртә, төшендә бик матур чәчәк күрүен сөйли.

– Миңа шул чәчәкне табып алып кайтсаң, бернәрсә дә кирәкми башка, – ди.

Атасы, бу чәчәкнең бик еракта булуын белсә дә, алып кайтырга сүз бирә. Атасы әйтә:

– Алып кайтуын кайтырмын, тик ул чәчәк безгә файда китермәс, – ди.

Кыз анысына да карамый:

– Шул чәчәк кенә булсын! – ди.

Карт юлга чыгарга әзерләнә башлый. Шулвакыт бабасыннан калган бер кечкенә сандык исенә төшә. Үләр алдыннан бабасы: «Берәр авырлыкка төшсәң, шушы сандыктагы әйберләрне алырсың», – дип әйтеп калдырган була. Исенә төшереп, карт шул сандыкны ачып караса, сандыкта сыбызгы, өч бөртек чәч, башлары көмешләнеп, бөкләргә җайланып эшләнгән бер метрлы таяк була, ди. Карт шушы әйберләрне алып, азык-төлек алып саубуллашып, сәфәр чыгып китә.

Байтак юллар киткәч, бик калын урманга җитеп, адашып йөри бу, бүреләр сырып алалар моны. Шулай аптырап торганда, кесәсендәге сыбызгысын исенә төшереп ала да өч тапкыр сызгырта. Шулчак, җир белән күкне бергә орып, бик каты өермә чыга, ди, агачлар шатыр-шотыр сына башлыйлар. Давылдан көч-хәл белән качып өлгерә. Шулай итеп, күп михнәтләр күрә-күрә бер ай барганда, урманны кичеп, бер аланлыкка килеп чыга. Карт бик сусый, ачыга, хәле бетә. Су эзләп йөри-йөри, бик калын бер тирәк янына барып чыга. Тирәк төбеннән су чыгып тора икән, карт шул суны эчеп бетерә. Бу су ерткыч хайваннар эчә торган су булган икән, ди. Суны эчеп бетергәч, ерткыч хайваннар картка ташланалар. Карт тагын сыбызгысын сызгыртып, өермә чыгарып, көч-хәл белән исән кала.

Бара-бара карт килеп чыга сахрага. Ашарына бетә моның. Барырлык рәте калмый. Шулвакыт кесәсендәге өч бөртек чәч исенә төшеп, берсен алып җилгә очыра. Җилгә очыргач, моның алдында иксез-чиксез күп ризык барлыкка килә. Карт, өнемметөшемме дип, шаккатып карап тора. Карт тамагын туйдыра да, ком сахрасын үтеп, бер биек кенә тауга күтәрелә. Ерактан

гына ялтырап бер сарай күренә. Әлеге чәч бөртегенең берсен очырып, тамагын туйдырып ала да, бераз ял итеп, китә шул сарайга таба.

Дүрт ай тулып, бишенче айның беренче көнендә сарай янындагы бик матур бер бакча янына килеп чыга. Бу килеп җиткәндә, караңгы төшкән була инде. Соңгы чәч бөртеген очырып тамагын туйдыра да ятып йоклый бу.

Яктыра башлагач, карт сискәнеп уяна да, чәчәк эзләп килүе искә төшеп, коймадан бакчага төшә. Бакчада төрле җимеш агачлары үсеп утыра, җимешләре пешеп тора, ди. Җимеш агачлары арасында карт эзләп килгән матур чәчәк тә үсеп утыра. Карт өч кызына өч чәчәк өзеп алып, коймадан чыгып китим дигәндә генә, моның каршысына тимер томшыклы, тимер тырнаклы бер зур Каракош килеп чыга. Кош карт янына килеп җитә дә киеменнән томшыгы белән эләктереп алып:

– Син кем рөхсәте белән минем бакчама кереп чәчәкләремне өзәсең, кая алып барасың аларны? – дип сорый.

Карт башта әйтергә курка, соңыннан, җибәрмәгәч, өч кызы барлыгын, кече кызының шушы чәчәкне төшендә күреп, гашыйк булганлыгын әйтеп бирә. Шуннан соң Каракош:

– Кече кызыңны миңа бирсәң, чәчәкне алырсың, кызыңны бирмәсәң, чәчәкне бирмим, – ди.

Картның кече кызын бер дә бирәсе килми инде. Нишләсен, буш кул белән борылып кайтасы килми, теләсә-теләмәсә дә риза була.

Киткәндә кош әйтә:

– Фәлән сәгатькә кызыңны китереп җиткер, – ди, бик тиз килергә куша инде.

Ярар, кайтырга чыга бу юлга. Кайтканда, зур елга буена килеп җитә, ну, һич чыгар әмәл юк. Шулай аптырап торганда, өйдән алып чыккан таяк исенә төшә. Шул таяк белән су өстенә өч мәртәбә суга да, суның өстендә зур бер күпер ясала. Күпердән чыгып китә бу. Бара-бара әлеге урман буена килеп җитә. Бу шулхәтле алҗыган, арган, шулай нишләргә белми аптырап торганда: «Нигә бу бик озак килми?» дип, Каракош моны эзли чыга. Кош картны куып җитә дә әйтә:

– Мин сине килеп җитә дип көтә идем инде, нишләп болай озакладың, инде икеләтә срок узып китте бит, – ди. Шуннан соң картны үзенең җилкәсенә утыртып, үз иленә кайтарып куя да әйтә: – Кызны шушында фәлән сәгатькә китереп җиткер, – ди.

Карт бик кайгырып өенә кайтып китә. Өйдәгеләр бик сагынган булалар инде. Кече кызына чәчәкне бирә дә әйтә:

– Кызым, – ди, – бу чәчәкне синең башыңа җитәр өчен генә алып кайтканмын икән, – ди. – Чәчәкнең хуҗасы тимер томшыклы Каракош синең үзеңне сорый, – ди. – Сине алырга ук килде, фәлән төштә көтеп тора, – ди.

Шулай дигәч, бөтенесе дә «бирмибез» дип җылашалар, кызны чыгармыйлар, ишек-тәрәзәләрен бикләп, йокларга яталар болар.

Каракош көтеп тора-тора, караңгы төшә. Ахыр чиктә түзми, йорт янына килеп, тәрәзәне ватып керә дә картның кече кызын урлап, үз иленә очып китә.

Кош кызны алып кайта да үзенең бакчасы эчендәге бер сарайга урнаштыра. Бу сарайда Каракоштан башка бернинди җан иясе булмый. Ялгыз кыз бик сагына, бик саргая. Шулай ике ел яшәгәч, кыз өйгә кайтырга рөхсәт сорый.

Каракош әйтә:

– Ике сәгать унбиш минут барырсың, дүрт сәгать анда торырсың, ике сәгать тә унбиш минут кайтырсың, – ди. – Бер минут кына кичексәң дә, миннән яхшылык булмас, – ди.

Кыз шуңа риза булып, кош өйрәткән тылсым белән өенә кайтып китә. Кайтып җитүгә, кочаклашып җылашалар. Кыз үзенең дүрт сәгать кенә торачагын әйтеп куйган була. Шул арада апалары, моңа белгертми генә, сәгатьне өч сәгатькә артка чигереп куялар.

Җиде сәгать торып китә бу. Өенә кайтып керсә, Каракош моны көтеп зарыгып беткән була.

– Син, – ди, – мин әйткән вакытка кайтып җиттеңме? – ди Каракош.

– Җиттем, – ди кыз.

– Син вакытына килеп җитмәдең, өч сәгатькә соңгарып кайттың, – ди. – Син моны үзең белмәдең, апаларың сәгатьне

борып артка җибәрделәр, шуңа син соңгардың, шуның өчен мин сине кичерәм, – ди.

Шуннан соң Каракош талпына да бик матур егет кыяфәтенә керә. Егет әйтә:

– Син мине кош дип уйладың, – ди. – Мин, сине сынар өчен генә, кош кыяфәтендә йөрдем, – ди. – Өеңә киткәч тә, вәгъдәңне бозмый килдең, – ди.

Шуннан соң егет кызны үзенә хатынлыкка алып, бик шатланышып, әле дә булса бергә гомер итәләр, ди.

*Иске Кормаш авылында*
*Халисә Зиязовадан (20 яшь)*
*Х. Гатина язып алды. 1948*

## Мулла остабикәне никахлый

Элек заманда була җитмеш яшьлек бер мулла. Ул унҗиде яшьлек яшь кызга өйләнә. Болар күршесендә Тәхәү исемле яшь егет була. Егет кызны күреп, бик сокланып йөри. Кыз суга төшкәндә, ат эчерү сылтавы белән ат җитәкләп төшә. Егет кыз белән мулла абзыйның бик карт булуы турында сөйләшә. «Монда бик озак сөйләшеп торып булмый, кеше күрер», – дип куркып, егеткә кич ястү вакытында, мулла мәчеткә киткәч, килергә куша. Мулла ясыйг укып тормый, ниндидер сәбәп белән кайтып килә. Кыз шулвакытта егетне ат абзарына яшергән була. Мулла өйгә килеп кергәч, кыз әйтә муллага:

– Ат абзарында кеше бар, – дип.

Мулла чыгып караса, ни күзе белән күрсен, улак янында күрше егете тора.

– Нәрсә эшлисең? – дип сорагач:

– Безнең ат чирлидер иде, улактан апара җыеп ашатырга куштылар, шуңа кердем, – ди.

– Алайса, егет, күбрәк ал, – дип, егеткә апараны биреп чыгара мулла.

Шуннан соң икенче көнне кыз тагын суга төшә. Тәхәү дә, атны җитәкләп, су буена төшә. Болар тагын егет белән очрашалар. Тагын кыз белән сөйләшәләр.

Кыз:

– Бүген кич ясыйг вакытында кил, – дип, тагын чакыра.

Егет кич килә. Кыз егетне ак өйгә кертә. Тагын шулвакытта мулла ясыйгдан кайтып килә. Кыз әйтә муллага:

– Ак өйдә кеше бар, ахрысы, бернәрсә чаштырдый, – ди.

Мулла чыгып караса, Тәхәүне күрә.

– Нишләп йөрисең? – ди мулла.

– Минем өем начар булса да, сезнең морҗагызны бик әйбәт күргән идем, шуның күчергечен алырга кердем, – ди.

Мулла, остабикәсен чакырып ут яндыртып, күчергечен биреп чыгара.

Өченче көнне кыз тагын суга төшә. Егет тә чыккан ат җитәкләп. Сөйләшәләр болар. Кыз әйтә:

– Син егет белән нәрсә дә эшләп була икән. Син хәзер үзегезнең өй базыннан безнең базга чаклы юл яса, – ди.

Егет юл ясый. Мулланың йортына барып керә. Остабикәне күрә, сөйләшәләр. Остабикә:

– Мин сиңа барам алайса, – ди, – иртәгә үк туй яса, – ди.

Егет, аш салып, туй мәҗлесе кора. Муллага барып ашка әйтә. Мулла ашка килә, мәҗлес җыелган була. Мулла кызның күлмәгеннән танып шикләнә.

– Минем дәфтәр өйдә калган, кайтып дәфтәрне алып килэм, – дип, өенә кайтып китә.

Мулла өйгә кайтып җиткәнче, кыз алдан кайтып җитә җир асты юлыннан.

Мулла кайткач, сорый кыз:

– Мулла, нигә кайттың? – ди.

– Дәфтәр онытылып калган, шуны алырга кайттым, – ди.

Кыз әйтә:

– Онытылып калса, башка вакытта кайткач яза идең бит, кайткач язар идең, – ди.

Мулла дәфтәрне күтәреп чыгып китә ашка. Ул барып җиткәнче, җир асты юлы белән кыз да барып керә. Мулла кызны күрсә дә, үзенең остабикәсе түгел икәнлегенә ышана инде.

Никах укып эшне бетергәч, остабикәсе:

– Рәхмәт сезгә, карт, мин кияүле булдым инде, – ди. Болар куанып калалар.

Шулай итеп, егет үзенең тапкырлыгы аркасында яраткан кызы белән әле дә булса яшәп ята икән, ди.

*Әмәкәй авылында Шәфикъ Хөснуллиннан (49 яшь)*
*Х. Гатина язып алды. 1948*

## Кыю кыз

Борын-борын заманда булган ике туган. Боларның кечкенәсе бай булып, олысы бик ярлы булган. Болар икесе дә бер авылдан икенче авылга йөк ташыганнар. Энесе, бай булгач, алаша җиккән, ә абыйсы колынларга җиткән буаз бия җиккән.

Бер дә бер көнне, башка авылда кунганда, төнлә белән бия колынлый да, колын алаша булган арба астына барып ята. Төнлә энесе тышка чыкса, үзенең арбасы астында колын ятканын күрә. Кереп, абыйсын уята:

– Тор әле, абый, тор, минем алаша колынлаган, – ди.

Абыйсы әйтә:

– Юк, энем, синең алаша колынламас, минем бия колынлагандыр, – ди.

– Юк, абый, колын минем арба астында ята, – ди. – Синең бия колынлаган булса, бия кырында булыр иде, – ди.

Бай энесе, комсызланып, колынны бирми. Эшне судка бирәләр. Суд байны яклый инде. Шуннан соң абыйсы үзәк судка бирә. Үзәк суд та байны яклый. Колын алашаныкы булып кала.

Ярлы, дөреслекне тикшерү өчен, патшаның үзенә бара.

Патша әйтә:

– Мин биргән сорауларны үтәсәң, колыныңны алып бирермен, – ди.

Ярлы:

– Үтәрмен, – ди.

Патша әйтә:

– Менә сиңа кырык йомырка, – ди, – иртәгә шушы кырык йомыркадан кырык тере чеби чыгарып китер, – ди.

Ярлы бик аптырап өенә кайта. Моның була бер кызы. Кыз, әтәсенең аптыраганын күреп:

– Нигә бу хәтле кайгыга төштең, әтәй? – ди.

Атасы әйтә:

– Әй кызым, яшьли генә анаңдин калдың, 17 яшькә җиткәчтән, миннән дә каласың, – ди.

– Нигә инде ул алай, әтәй? – ди.

– Миңа патша көч җитмәслек эш кушты, – ди, – иртәгә минем башны кисәчәк ул, – ди.

– Нинди эш ул, әтәй? – ди.

– Менә кырык йомыркадан кырык чеби чыгарырга кушты, – ди.

Кыз әйтә:

– Кайгырма, әтәй, чыгарырбыз, – ди.

Кыз атасының тамагын туйдырып йокларга яткыра. Кыз иртән-иртүк торып чәй кайната. Алып кайткан бөтен йомыркаларны самавырына тутырып пешерә дә әтисен уята.

– Тор, әтәй, аша да, патшага бар, – ди.

Әтисе торгачтын аптырап китә.

– Әй, кызым, йомыркаларның барысын да пешереп бетергәнсең бит, – ди.

– Әтәй, пешкәч, ашарга җиңелрәк була ул, – ди.

– Соң, патшага ни дип әйтербез? – ди.

– Курыкма, әтәй, – ди. – Әйбәтләп тамагыңны туйдыр, аннан соң патшага барып, «чебиләр чыкты» дип әйтерсең, – ди, – хәзер үк, бер көн эчендә чәчеп, үсеп, сугылып, суыртылган ярма сорыйлар, дип әйт, – ди.– Тиз булмаса, чебиләр үлеп бетә, дип әйт, – ди.

Әтисе тамагын туйдырганның соңында, патшага барып, кыз әйткәннәрне әйтеп бирә. Патша бу эшне үти алмый, билгеле. «Ну, мужик, иртәгә килерсең әле», – дип кайтарып җибәрә.

Мужик, кайтып кереп йомыркаларны ашаганның соңында, яхшы гына ял итеп, иртәгесен тагын патшага бара.

– Ну, мужик, килдеңме? – ди.

– Килдем, – ди мужик.

– Килсәң шул, – ди, – менә сиңа бер аршын озынлыктагы җеп, – ди, – менә шушы җептән иртәгә миңа бер аршын озынлыктагы сөлге сугып китер, – ди.

Мужик, башын түбән иеп, тагын өенә кайтып китә. Кайтып кызына сөйли.

Кыз әйтә:

– Кайгырма, әтәй, сугарбыз, – ди.

Иртәгесен торганның соңында кыз әтисенә бармак буе бер агач бирә.

– Бар, патшага әйт, бер аршын озынлыктагы җептән бер аршын сөлге сугу өчен бөтен киндер коралларын да эшләтеп бирсен, – ди.

Атасы, кызның тапкырлыгына хәйран калып, патшага бара. Патша кыз әйткәннәрне сөйләгәннең соңында моны тагы да кайтарып җибәрә өенә.

Өченче көнне мужик тагы бара. Патша әйтә:

– Сиңа, – ди, – бу җавапларны кем өйрәтә соң? – ди.

Мужик әйтә:

– Минем унҗиде яшьлек кызым бар, шул өйрәтә мине, – ди.

– Ул хәзер өйдәме? – ди. – Мин ул кызыңны барып күрер идем, – ди.

Мужик әйтә:

– Телисең икән, барасың, күрәсең, – ди.

Шуннан соң патша, мужикка ияреп, кызны күрергә бара. Патша килгәндә, кыз киледә тары төеп ятадыр ие. Патша кыз янына килде дә:

– Әй кызым, әйтә алмассыңмы, синең килеңдә ничә бөртек тарың бар? Шуның ничәсе ярма булган, ничәсе тары көе тора? – ди.

Кыз әйтә:

– Мин әйтермен шул вакытта, син монда килгәнче ничә рәт атладың? – ди.– Ничә рәт уңга, ничә рәт сулга борылып карадың? – ди.– Шуны әйтсәң, мин дә әйтермен, – ди.

Патша моны белми билгеле, шулай булгач, кыздан да сорый алмый. Шуннан соң патша иртәге көнгә кызны үзенә кунакка чакыра. Патша әйтә:

– Син миңа кунакка бар, – ди, – ләкин кием дә кимә, киемсез дә барма, – ди.– Җәяү дә барма, атка да атланма, – ди.– Бүләк тә алып барма, бүләксез дә барма, – ди.– Юлдан да барма, юлдан да чыкма, – ди.

Кыз ризалык биреп кала. Патша киткәннең соңында, кыз, балыкчыга барып, балык тота торган җәтмә, аучыга барып, бер куян, бер боҗыр алып кайта.

Иртән торгач, кыз киемнәрен салып ташлый да өстенә җәтмә бөркәнә, кулына боҗырны тота, куянны бот арасына кыстыра да патшага кунакка китә. Кыз, бер юлга кереп, бер юлдан чыгып, патшага барып җитә. Патша кызның килгәнен күреп каршы ала. Кыз:

– Мә, падишаһым, бүләгем шушы булыр, – ди дә боҗырны бирә. Патша боҗырны тота алмый, кош очып китә.

Патша әйтә:

– Нигә бүләксез килдең? – ди.

– Бүләкне үзең очырдың бит, бүләк түгелмени ул, – ди.

– Алай булгач, нигә бүләк алып килдең миңа? – ди.

– Кая, алып килгән бүләгемне күрсәт, – ди.

Патша әйтә:

– Нигә киемсез килдең? – ди.

Кыз җәтмәне тотып күрсәтә:

– Бу кием түгелмени? – ди.

– Алай булгач, нигә кием кидең? – ди.

Кыз әйтә:

– Бу киеммени, бөтен тәнем күренеп тора бит, – ди.

– Нигә җәяү килдең? – ди патша.

Кыз әйтә:

– Нигә җәяү килим ди, мин куянга атланып килдем, – ди, куянга атланып күрсәтә.

Патша әйтә:

– Нигә ул вакытта куянга атланып килдең? – ди.

Кыз куян өстеннән тора да:

– Нигә мин атланып килим ди, аякларым белән җиргә басып торам бит, – ди.

Патша кызны үз бүлмәсенә кунак итәргә алып кереп китә. Ашап-эчкәннең соңында, патша кыздан сораштыра башлый:

– Ну, кыз, ничек көн күрәсез, – ди, – ничек тукланып торасыз? – ди.

Кыз әйтә:

– Безнең бер генә һөнәребез бар, – ди, – басудан балык тотып ашыйбыз, – ди.

Патша әйтә:

– Их, кыз, барысын да дөрес эшләдең, ләкин, – ди, – азакта ялгышасың, корыда балык булмый бит, – ди.

Кыз әйтә:

– Патша, син дөрес сөйлисең, – ди, – корыда балык булмый, – ди, – шулай булгач, алаша да колынламый, – ди.

Патша кызны бик зурлап, колынны аларга алып биреп, өенә кайтарып җибәрә.

Кыз атасы белән әле дә булса шулай рәхәт кенә яшәп яталар икән, ди.

*Татар Әҗбие авылында Шәрип Закировтан (22 яшь)*
*Х. Ярми язып алды. 1948*

## Җилән

Борын-борын заманда булган икән, ди, ярлы гына бер кеше. Моның булган, ди, өч улы, бер кызы. Бу кеше балаларын, бик күп авырлыклар күреп булса да тәрбияләп үстерә. Балалары да бик акыллы, бик һөнәрле була моның. Олы улы шундый һөнәргә өйрәнә: ул теләсә нәрсәне бик ерактан исе белән сизеп белә торган була. Уртанчы улы оста атучы, кече улы авыр әйберләр күтәрүче көчле батыр; сеңелләре дөньяда тиңе булмаган матур кыз булган, ди.

Егетләр үсеп җитүгә, боларның аталары авырып үлеп китә.

Ярар. Көннәрдән бер көнне бу егетләр өчәүләп ауга чыгып китәләр. Аналары да урманга җиләккә китә, ди. Аналарының киңәшен тотып, болар матур сеңелләрен өйдә калдырып, тышкы яктан бикләп китәләр, ди.

Боларның сеңелләренә дию пәрие кызыгып йөри торган булган. Агаларының өйдә юклыгын белеп, дию пәрие килеп, өйнең ишеген ватып керә. Боларның сеңелләрен урлап алып китә.

Ярар. Егетләр аудан кайталар. Кайтып керсәләр, өй ишеге ватылган, өйдә сеңелләре юк. Егетләр, аналарыннан рөхсәт сорап, чытып китәләр сеңелләрен эзләргә.

Баралар, баралар, ди, болар диюне эзләп. Бик күп суларны кичәләр, биек-биек тауларны үтәләр болар. Шулай йөри торгач, олы абыйлары, сеңелләренең исеннән сизеп, диюнең эзенә төшә. Шул ис белән бара торгач, барып җитәләр, ди, болар дию пәрие яшәгән кап-караңгы бер урманга. Урман эченә кереп китәләр. Болар барып җитәләр, ди, дию пәриенең өенә. Болар барганда, дию пәрие бик каты йоклап ята икән, ди. Иплэп кенә сеңелләрен алып чыгып киттеләр, ди, болар.

Киттеләр. Көн бардылар, төн бардылар, бара торгач, барып җиттеләр, ди, болар бер зур күл буена. Ял итәргә кирәк булыр дип уйлап, шул күл буенда бер төн кунып китәргә булдылар.

Ярар. Яттылар йокларга. Дию пәрие йокысыннан уянып китсә, кыз юк. Дию пәрие, тиз генә торып, куып китте, ди, егетләр эзенә төшеп. Күл буена барып җитте дию. Егетләр йоклап калдылар, дию сеңелләрен күккә күтәреп китте, ди. Диюнең кызны күтәреп алып китүе була, уртанчы егет уянып китә дә агасы белән энесен уята. Шуннан үзе дию пәриенә карап атып та җибәрә, ди. Беренче мәртәбә атып җибәрүдә үк дию пәриенең бер кулын өзеп алып китә, ди. Икенче мәртәбә атып җибәрә, икенче кулын өздерә. Өченче мәртәбә атып җибәрүгә, дию пәриенең үзенә тиеп, кызны ычкындырып төшереп җибәрә. Шул вакытта кече туганнары йөгереп барып, кызны үлемнән коткарып кала. Болар, шатланышып, сеңелләрен алып кайтып китәләр.

Болар кайтканчы, аналары, кызны коткарган улына бүләккә дип, бер җилән тегеп куйган икән, ди. Уллары сеңелләрен аналары кулына алып кайтып тапшырып, һәрберсе үзенең һөнәрен мактап сөйли башладылар, ди. Олы уллары әйтә:

– Мин булмасам, сеңелебезнең кайда икәнен дә белә алмас идек, аны минем аркада гына таба алдык, – ди икән.

Шуннан уртанчы улы торып әйткән:

– Мин булмасам, дигән, дию пәрие сеңелебезне әллә кайларга алып киткән булыр иде, ярый, әле дә мин аны атып үтердем, – дигән.

Кече уллары әйткән:

– Сеңелебез һавадан төшеп килгәндә мин тотып алмаган булсам, ул җиргә төшеп үлгән булыр иде, – дигән ди.

Боларның сүзләрен тыңлап торган аналары җиләнне кайсысына бүләк итәргә дә белми аптырап та калган, ди. Я, җилән кайсысына тиешле?

*Тат. Әҗбие авылында Шәрип Закировтан (22 яшь)*
*Х. Гатина язып алды. 1948*

**Өч бур**

Ике бур булган. Үткер бурлар булган инде болар.

Хәзер бер кешене ияртканнәр болар. Аны аңгыра дип уйлыйлар, «тотылсак та ул тотылыр», – диләр. Кыш була бу, китәләр шулай.

Хәзер болар бер байның келәтенә керергә булалар. Астан бастырык тыгып, келәтне күтәрткәннәр дә бер почмагыннан, теге кешене кертеп җибәргәннәр. Теге кеше сүс тә, каз итләрен дә ташлый, ди, йоннарны, тиреләрне ташлаган тышка.

– Җитте инде, – дигәннәр теге эчтәге бурга, – хәзер чыгарсың дигәннәр.

Үзләре бастырыкны тартып алганнар да теге шунда эчтә калган инде. Ишек йозаклы бит.

Хәзер болар кайтып киткәннәр инде, моны ташладык дип. Теге мескен төн чыккан инде салкын келәттә, чыгып булмый бит.

Иртә белән теге хуҗаның хатыны он иләргә чыккан. Эчтә калган бур хуҗа хатынның күзенә он сипкән дә чыгып йөгергән. Үзе, «Фәлән абзыйга бур кергән», – дип кычкырып кешеләр җыеп, эзләшеп йөргән була.

Болар бурны тапмагач, теге кеше ике бур янына китә. Барып керсә, тегеләр келәттән чыккан әйберләрне икегә генә бүлеп яталар икән.

– Мине частник итмисез мени, – дигән бу.

Болар бирмәскә торганнар.

Бу әйткән:

– Әле мин кешеләрне алып килеп, сезне тоттырсам, ни була иде? Хәзер дә тоттыра алам мин, – дигән.

Шулай дигәч, моңа күбрәк тә биргәннәр.

Теге атаман бурлар куркып туктаганнар, ди, бурлыктан. Бу кеше исә, үткерлегем бар, дип, яңадан ныгытып урлашырга тотынган.

*Түке авылында Мөслимә Солтановадан (72 яшь)*
*Л. Җамалетдинов язып алды. 1987*

**Бай белән чегән**

Бер байга чегән хезмәткә ялланган. Чегән байдан ит сораган.

– Бер үгез бирсәң, печәнеңне чабып бетереп бирербез, – дигән.

Байның үзенең хезмәтчеләре үгезне җитәкләп болынга печән чабарга китәләр. Үгезне суялар, үзләренә ашарлык кына калдыралар да, калганын сатып, аракы алалар. Аракы эчәләр дә печән чапмый яталар, үгез ите ашап.

Хезмәтчеләр әйтә чегәнгә:

– Давай, печәнне чабаек, – диләр.

– Кайгырмагыз, мин үзем җавап бирермен байга, – ди чегән.

Үгез итләре һәм аракылар беткәч, тагын кайталар бай янына, печәнне чапмый гына.

Байга әйтәләр:

– Без чабып бетерә алмадык әле печәнне, тагын бер тана бирсәң, чабып бетереп кайтырбыз, – диләр.

Бай, тананы биреп, икенче көнне тагын җибәрә печәнне чабарга.

Баралар да тананы суялар. Тана итен үзләренә җитәрлек кенә калдыралар да калганын сатып, аракы алып, эчеп яталар.

Ашап-эчеп бетергәч, тагын кайталар байга, печәнне чапмаенча.

Кайталар да:

– Печән чабылып бетмәде, бер сарык бирсәң, чабып бетереп кайтырбыз, – диләр.

Икенче көнне бай тагын бер сарык биреп җибәрә.

Сарыкны суялар, итен пешерергә салып, калганын саталар да тагын аракы алып эчеп яталар.

Сарыкны ашап бетергәч, янә кайталар:

– Тагын бер тавык бирсәң, чабып бетерәбез, – диләр байга.

Бай әйтә:

– Тавык биреп булмас инде сезгә, – ди.

Чегән әйтә:

– Алайса, бөтен печәннәр, үз урыныгызга утырып бетегез, – дип кулын селти дә чыгып китә.

Чегән чыгып киткәч, бай, үзенең хезмәтчеләрен ияртеп, болынга печәнне карарга бара.

Бай барып караса, болынның печәне үз урынында үсеп утыра. Хезмәтчеләр әйтәләр:

– Бай абзый, менә монда фәлән кибән куйган идек, ә монда фәлән кибән куйган идек, – диләр.

Бай:

– Эх, тавыкны җәлләмәсәм, печәнем эшләнеп беткән булыр иде, – дип, бик үкенә.

*Түке авылында Гыйльмегали Ганиевтан (57 яшь)*
*Л. Җамалетдинов язып алды. 1987*

## МӘЗӘКЛӘР

### Хуҗа Насретдин чүлмәге

Көннәрдән бер көнне Хуҗа күршесеннән бер чүлмәк алып чыга. Чүлмәкне кертми, бик озак тота. Күршесе:

– Хуҗа, чүлмәкне керт инде, – ди.

Хуҗа чүлмәкне кертә, кырында бер кечкенә чүлмәк тә була.

Күршесе:

– Нишләп болар икәү соң әле? – ди.

– Бәй, чүлмәк бәбәйгә авырды, – ди, – шуның өчен озак тоттым, – ди, – менә бәбәйләде инде, – ди.

Хуҗа икенче тапкыр тагын алып чыга чүлмәкне, тагын кертми. Күршесе сорый инде.

Хуҗа:

– Чүлмәгең үлде, – ди.

Теге кеше әйтә:

– Бәй, чүлмәк үләмени ул? – ди.

Хуҗа әйтә:

– Чүлмәкнең бәбәйләгәненә ышангач, үлүенә дә ышанырга кирәк, – ди.

*Иске Кормаш авылында Насыйрый Фәрраховтан (40 яшь)*
*Х. Ярми язып алды. 1948*

### Хуҗа Насретдин мажаралары

Көннәрдән бер көнне Хуҗа, урманга барып, бер агачка менә дә үзе утырган ботагын кисә башлый.

Менә икенче берәү килеп:

– Хуҗа, нишлисең син, егылып төшәсең бит, – ди.

– Төшмим мин, – дип, кала Хуҗа шунда.

Күп тә үтми, Хуҗа ботагы белән егылып та төшә. Төшә дә, ишәгенә атланып, тегеләр артыннан куып китә. Куып җитә дә:

– Син минем егылуымны белдең, үләремне дә беләсеңме? – дип сорый.

Теге кеше әйтә:

– Үләреңә дә күп калмаган инде синең, – ди. – Ишәгең кайчан йөкне авыр тартып атлый башлый, шул синең үлем авыруың була инде, – ди.

Кайтып китә инде бу. Кайткан чакта тау менгәндә ишәк бик көч белән атлый башлый. Хуҗа, «Алла, эчем» дип, эчен тота. Тау менеп җиткәндә «Алла, башым» дип, башын тота. Ишәк күпергә менеп җитү белән, Хуҗа егыла.

Ишәк күпердә аркылы басып тора. Юлдан килүче кәрваннарның атлары, өркеп, ишәкне күпер астына бәреп төшерә. Үзләренең йөкләре дә Хуҗа кырына тарала.

Хуҗа аңына килеп караса, ни күзе белән күрсен, янында төрле җимешләр таралып ята. Ул аларны ашый да башлый, «оҗмах-оҗмах, диләр иде, шушы икән инде ул», – дип.

Бераздан соң кәрванчылар әйберләрен җыеп алалар да, Хуҗаны бик каты чыбыркы белән кыздырып, китеп тә баралар. Хуҗа әйтә: «Җимешләре татлы икән, газаплары каты икән, – ди, – тәмугысы да шушында икән», – ди.

Хәзер Хуҗа ишәген җитәкләп кайта. Хатыны капка төбендә каршы ала да әйтә:

– Әй Хуҗа-Хуҗа, ник озак тордың, сине фәлән байлар күптән инде ашка көтәләр, – ди.

Хуҗа, ишәген хатынына биреп, үзенең өстендәге чобалары[1] белән ашка керә. Керү белән, Хуҗага беркем дә игътибар бирми, ул ишек төбендә генә утыра да шуннан соң чыгып та китә. Өйгә кайтып, Хуҗа камалы тунын киеп бара.

Киенеп баргач, «Хуҗа әфәнде, хуш килдегез», – дип, моны түргә үк утырталар. Ашны китереп кую белән, Хуҗа үзенең тун җиңен ашка китереп тыга да: «Аша, тункай, Хуҗаны түгел, сине чакырганнар икән ашка», – ди.

Кунаклар, гаҗәпләнеп, Хуҗадан сорыйлар:

– Ник алай туныңны ашка тыгасың? – дип.

– Чөнки чоба белән килгән вакытта мине беркем дә танымады, – ди, – ә яхшы тун киеп килгәч, таныдылар, – ди. – Шуның өчен туным сыйлансын, – ди.

*Иске Кормаш авылында Насыйрый Фәрраховтан (40 яшь)*
*Х. Гатина язып алды. 1948*

## Акчаларның оҗмахка керүе

Акчалар оҗмахка керергә чират торалар икән. Менә 10 сум ишекне ачкан да кереп киткән. 50 сум да, 100, 500 сумнар да кереп киткәннәр. 1000 сум ишекне ачкач, сакчылар бераз уйланып торганнар да моны да кертеп җибәргәннәр. Инде 5000 сум ишекне ачып кереп бара икән – моны туктатканнар.

– Юк-юк, син кермисең, – дигәннәр.

– Ничек инде, 50 тәңкә, 100 тәңкәлекләр оҗмахка кереп китте, ә мин – 5000 тәңкәлек оҗмахка кермим, имеш?

– Юк, юк, синең әле мәчеттә күренгәнең юк, – диләр моңа.

*Күҗәкә авылында Рамил Хәйбиевтән (36 яшь)*
*Л. Җамалетдинов һәм Г. Гыйләҗиева язып алды. 2009*

---

[1] Чоба – киндердән эчсез генә тегелгән озын өс киеме.

## Ябык нәсел

Авылда бер ябык нәсел бар, бөтенесе дә ябык инде.

Элек бит пионерлар авылда тимер-томыр, сөяк җыялар иде, мәктәптән киләләр инде. Болар килеп кергәннәр бервакыт Минсалих абзыйга, «Минсалих абзый, синдә сөяк юкмы?» дип инде.

Минсалих абзый әйткән пионерларга:

– И… миндә нинди сөяк булсын инде, сөяк бит ул әнә тау асты фәләннәрдә күп, андагы сөяк сезгә генә түгел, бөтен мәктәбегезгә җитә, – дигән.

Хәзер мәктәпнең бөтен пионерлары, җыелып, теге абзыйларга барганнар инде:

– Менә Минсалих абзый, сездә сөяк күп, дип әйтте, сөяккә килгән идек, – диләр.

Теге апа аңлап алган инде эшнең нәрсәдә икәнен. Уръядыда тагын бер шундый ябык нәсел булган. Апа пионерларга:

– Нигә әле безгә генә җибәргән ул, әнә фәләннәргә дә барыгыз, – дип, шуларга озаткан боларны.

*Күҗәкә авылында Рамил Хәйбиевтән (36 яшь)*
*Л. Җамалетдинов һәм Г. Гыйләҗиева язып алды. 2009*

## Корбангали абзый

Элегрәк бит Дербешкидә пристань бар иде, ә пристаньда – базар. Якын-тирә авыллардан шул базарга барып, әйбер сата торган булганнар. Безнең авылдан да Корбангали абзый белән Хәернисәттәй дә киткәннәр шунда ит сатарга (хәзер мәрхүмнәр инде). Барганнар. Итне сатып бетерә алмаганнар болар. Кыш көне була бу, салкын. Итне яшереп куйганнар инде, төнне үткәрергә кирәк бит әле. Шул көнне авылга концерт бригадасы килгән була. Болар икесенә бер билет алалар да, берсе концерт карый, икенчесе ит саклый. Тегесе җылынгач чыга да, шул билет белән монысы кереп китә инде концертка. Корбангали абзый озын буйлы, олы борынлы иде шундый.

Менә бермәлне, Корбангали абзый үз йомышын йомышларга киткән арада, итне урлаганнар бит. Пристань булгач, аның караклары да була бит инде. Корбангали абзый клуб тирәли

бөтерелеп йөри икән, Хәернисәттәйгә кереп әйтергә кирәк бит инде, итне урладылар, дип. Билет юк, акча юк, кертмиләр бит клубка. Корбангали абзый тегеләй итә, болай итә, икенче ишектән кереп, гримёрный аша үтеп, сәхнәгә йөгереп керә бит! Өстендә толып, башында бүрек, аякта киезката, кулда тире бияләй, озын борын… Ә монда чыгып әйткән генә булалар инде: «Нәфис сүз остасы Фәлән Фәләнев», – дип. Нәкъ шулвакыт сәхнәгә Корбангали абзый йөгереп керә. «Хәерниса, нәрсә утырасың җәелеп, итне урлаганнар», – дип әйтә дә чыгып та чаба. Теге нәфис сүз остасы чыга да инде, мескен, аны тыңламыйлар да, бөтен халык Корбангали абзыйны чакыра, кул чабып. Әмма Корбангали абзыйның сәхнәгә чыгу кайгысы булмый инде.

*Күҗәкә авылында Рамил Хәйбиевтән (38 яшь)*
*Л. Җамалетдинов һәм Г. Гыйләҗиева язып алды. 2009*

## МИФОЛОГИК ХИКӘЯТЛӘР

### Мал тирләүнең сәбәбе

Абзар иясе яраткан атының ялын уникешәр толым итеп үрә иде. Инде атны яратмаса, аны җәфалый. Атлар бик нык тирләгән була иртәнгә. Шуның билгесе инде бу. Абзар иясе яратмаса, сыер да тирли. Безнең сыерның һәр йонынннан тамчы-тамчы тамып торыр иде иртә белән. Сеңлемә биреп җибәрдем, анда тирләми башлады сыер.

*Иске Кормаш авылында Сәгыйдә Хафизовадан (63 яшь)*
*Л. Җамалетдинов язып алды. 1981*

### Токый чокыры

Токый кушаматлы Хәмәкәй бабай, үлгәч, убыр булып, ут булып авылга – Иске Кормашка, өенә кайта. Ишек-тәрәзәләр бисмилла әйтеп ябылганлыктан, аннан керә алмый – морҗадан керә. Ул кайтып керүгә, өйдәге бар кеше гырлап йоклый башлый.

Минем хатынның әтисе – минем бабай – аларның өенә эшкә әйтергә барган да дөбердәткән. Ишек ачучы булмаган, берәүне дә уята алмаган. Капкадан кире чыгып барганда күрә: морҗадан

тубал кебек ут атылып чыга да югары очка – зияратка таба тәгәрәп китә. Шуннан соң гына өй хуҗасы уяна. Ул чыгып: «Кем бар анда, нәмә эшләп йөри?» – дип эндәшә. Бабай берни әйтми кайтып китә.

Тәгәрәп йөргән тубал кебек утны күреп, авыл халкы – хатын-кызлар, бала-чагалар, карт-коры бик курыкканнар. Шуннан соң аның каберен ачып, ләхетен чатлык агач белән кадаклап куялар. Алай да җиңә алмыйлар – убыр һаман чыга. Хәзер мир җыены карар чыгара: казып алып яндырырга.

Шуннан соң казып алалар да Әшмышты чокырына алып килеп, әрдәнә өеп, керосин сибеп, ут төртеп яндыралар. Шуннан андый утның йөргәне булмаган, диләр. Әлеге чокыр «Токый чокыры» дип йөртелә башлый.

*Иске Кормаш авылында Хөснимәрдән Мәрдәновтан (68 яшь)*
*Л. Җамалетдинов язып алды. 1981*

## Мөселман җеннәр

Актанышта бер таныш апа яшәде. Ул вафат булды инде. Мин Актанышка эш белән төшкәч, аларга кунарга кердем. Шул апа сөйләгән иде.

– Менә, – ди, – Җылан авылының мәчет манарасын җимереп төшергәндә мин клуб мөдире идем, – ди. – Урамда туп-тулы мөселман җеннәре күренеп йөрде, – ди. – Кая барырга белмәенчә дулап йөрделәр, беребез дә кич чыга алмадык, кайтып киттек, – ди.

Җеннәр бит алар ике төрле: мөселман җеннәр була, тегенди җеннәр була. Мәчеттә бары мөселман җеннәр генә була. Манараны кискәч, боларның бит инде урыннары җимерелгән.

Без Коръән укыткан вакытта да алар, безнең өйләргә кереп, Коръәнне тыңлап чыгып китәләр, – ди. – Кешегә тимиләр. Әгәр дә, кояш баегач, бисмилласыз су түксәң, аларга кагылсаң, яисә алар кагылса – чирлисең, бу чир китми. Шуңа күрә безнең әбиләр кояш баегач, су түкмәскә кушалар, ишекләрне, тәрәзәләрне бисмилла әйтеп ябарга кирәк. Мөселман җене кагылса куркынычрак, тегенди җенгә караганда, чөнки алар безнең

шикелле. Коръән кешеләр өчен генә түгел бит, җеннәр өчен дә чыккан.

*Чуракай авылында Рәүфә Миргатауллинадан (70 яшь)*
*Л. Җамалетдинов һәм А. Гайниева язып алды. 2009*

## Ияле агач

Яшь чакта егетем белән төнге уникегә чаклы утырдык та, өйләребезгә кайтып киттек. Мин ишек шакып керүем булды, әнкәй ике бидрәсе белән көянтә тоттырды миңа.

– Бар, – ди, – өйдә бер грамм су юк, – ди, – суга бар, – ди.

Без бит инде тыңлаучан – киттем, көянтәне, бидрәне алып, суга. Безгә ике өй аркылы ул кое. Бардым, ипләп кенә бидрәләремне куйдым, теге сиртмәле кое бит, төшерә башладым бидрәне… Каршымда бер бәләкәй генә агач бар, шул агачтан кап-карадан киенгән бәләкәй генә кортка чыкты да килә башлады минем кырга. Бу миңа күршедәге кортка булып күренә. Шундый ук кыяфәттә, бәләкәй генә Фатыйма әби… Хәзер минем әйтәсе килде: «Фатыйма әби, әллә берәр малың кайтмадымы?» – дип. Шулвакытта миңа фәрештәләр тарафыннан әмер бирелгәндер инде: «Бу вакытта нинди Фатыйма кортка булсын, бисмиллаһны әйт», – дип. Хәзер бисмилланы әйтергә тырышам, һич әйтә алмыйм, телемне бәйләп куйды бит инде. Оныттым бисмилланы. Ә кортка миңа якынлаша, коймадагы тимерчыбыкны сыдырып килә бу. Килеп җитте дигәндә, бисмилланы әйтеп җибәрдем, сиртмәне дә ычкындырып җибәрдем – ул күтәрелеп китте, әби дә юкка чыкты.

Шуннан тиз генә ике бидрәне, көянтәне алдым да сусыз-нисез җиппәрдем өйгә.

Әнкәй әйтә:

– Кая су? – ди.

– Әнкәй, – мин әйтәм, – кыз баланы шундый җиргә җибәрәләрме төнге сәгать бердә; бер кортка чыкты, ярый бисмилланы әйтеп өлгердем, – димен.

Иртәгесен әнием теге коега барган да, ишегалдында мунча янында бер апа тора икән, аңа әйткән иде:

– Әй, Гөлбикә, кызны төнлә суга җибәргән идем, әнә шул агач ягыннан килгән бер кортканы күргән, сусыз кайтты, – дигән.

– Әй, Латыйфа, Латыйфа, – дигән, – ул бит яшен суккан агач, ияле агач, – дигән, – бәхете бар икән кызыңның, әгәр эндәшкән булса, кулсыз, телсез булып шунда ятар иде иртәнгә чаклы, – дигән.

*Чуракай авылында Рәүфә Миргатауллинадан (70 яшь)*
*Л. Җамалетдинов һәм А. Гайниева язып алды. 2009*

## РИВАЯТЬЛӘР

### Чалманарат

Чалманарат авылы исеме авылның төньягында үсеп утырган чалмага охшаган наратлардан алынган, диләр. Буыннан-буынга килгән исәпләр буенча, авылга өч йөз еллар элек нигез салынган.

Торалы исемле кеше Бүләр Түбә дигән җирдән хәзерге Чалманарат авылыннан бер-ике чакрым чамасы көнчыгыштагы Печмән елгасы буена күчеп килгән. Тирә-ягы урман булган. Ерткыч хайваннар йөдәткәч, Торалы нәселе Ямалы ягына, соңыннан хәзерге Чалманарат урынына күчкән. Авылның Шәбез елгасының уң ярына урнашкан өлеше үзе бер авыл булган. Ул Җәләй Түбә дип аталган. Соңыннан «Чалманарат» дип кушканнар. Торалы нәселеннән Искәндәр, Исәргән, Габдрәшит, Фәтхетдин, Шәйхетдин, Шәрәфетдин, Таҗетдин, Хатыйп (хәзер дә исән) исемнәре билгеле.

Борынгы заманда авыл кешеләре аучылык, терлекчелек, соңрак игенчелек белән шөгыльләнгәннәр. Алар сугышларда да катнашкан булырга тиеш. Чөнки Торалының уналты походта булуын искә алып сөйлиләр.

Чупанай Түбә кешеләре – башкорт һәм типтәр дигән төркемнәргә, ә Җәләй Түбәдәгеләр – вотчинникларга[1] һәм

[1] Вотчинниклар – элекке Башкортстан территориясендә җир биләүчеләр сословиесе.

пропущинникларга[1] бүленгәннәр. Типтәрләр һәм пропущинниклар җирсезлектән интеккән.

*Актаныш авылының туган якны*
*өйрәнү музеендагы альбомнан*
*Л. Җамалетдинов күчереп алды. 1981*

## Бикә җыены[2]

Бикә җыенының килеп чыгуы шулай.

Борын-борын заманда бу тирәдә бер карт белән карчык яшәгән. Карт бик күңелле кеше булмаган, ә Бикә карчык бик акыллы һәм бөтен эшне үзе алып бара торган булган. Аларның йортлары моннан ерак түгел, тау башында булган. Безнең җыен менә шул карчык исеменә аталып, «Бикә җыены» дип йөртелгән...

*Иске Кормаш авылында*
*Гыйзетдин Җамалетдиновтан (84 яшь)*
*Х. Гатина язып алды. 1948*

## Чәчер авылы һәм аның тирә-ягы

Чәчер авылында типтәрләр яшәгән, җире аз булган. Ике елга бар монда. Берсе – Өшәр елгасы. Аның буе биш йөз-алты йөз метр, киңлеге – дүрт-биш метр. Баҗана елгасына коя. Икенчесе – Баҗана елгасы, ул Ык елгасына коя.

Күл буенда элек керәшен авылы булган. Өч күл бар монда: Шәйхерази күле, Мазарка күле (озынлыгы сигез йөз метр, тирәнлеге дүрт-биш метр, иң тирән җирен тугыз метр диләр),

---

[1] Пропущенниклар (русча «припускать» – «җибәрү», «кертү» сүзеннән) – элекке Башкортстан территориясенә читтән, башлыча Татарстаннан күчеп килеп, вотчинниклар җиренә договор нигезендә урнашкан крестьяннар сословиесе. Җир өчен алар вотчинникларга оброк һәм дәүләткә ясакның бер өлешен түләргә тиеш булганнар.

[2] Бикә җыены Иске Кормаш авылында 10 июльдә булган. Бу җыенны түбәндәге авыллар үткәргән: Сәфәр, Адай, Усы, Уръяды, Балтач, Каентүбә, Бикчәнтәй, Шәбезбашы, Агач, Әтәс, Чирү, Чыньк, Теләкәй, Яңа Кормаш, Кәлтәү, Татар Суыксуы, Мари Суыксуы.

Өчаер күле (өчкә аерылып тора ул, өч тармакка, Нур Баян колхозына керә).

Чишмә бар, күлгә коя ул. Тау астыннан чыга торган тагын бер чишмә бар – аны Бояр чишмәсе диләр, авылдан 1,5 км ераклыкта. Сазлыклар бар: Рәгат сазлыгы (мәйданы 80 гектар), Баҗана башы һәм Күл башы сазлыклары (5–6 гектар).

Тагын мондый урыннар бар: Сәйфулла почмагы, ул ике басу арасындагы почмак. Анда Сәйфулла исемле кеше үлгән. Үлгән җирендә үк күмгәннәр. Чөнки басу аша мәетне күчерергә ярамаган – күчерсәң, яңгыр яумый, имеш. Басулар урлар (канау) белән әйләндереп алынган булган.

Зөләйха култыгы бар Пучы авылы болынында, моннан 2 км ераклыкта. Карлыганга баргач, Зөләйха шул аланлыкта үлгән, шунда ук күмгәннәр дә. Култык алан дигән сүз шул мәгънәдә.

Биткол чокыры бар. Анда иске зират булган.

Варка басуы. Аның мәйданы 40 гектар, Нур Баян колхозына керә. Мазарка күле шул басуның читендә, Олы әрәмә белән ике арада.

Игем басуы. Игем дигән урыс авылы кешеләре килеп иген иккән. Бу авыл Минзәлә районына керә. Ул басуны Чәчердән Ситдыйк исемле кеше караган. Шуңа күрә аны Ситдыйк хуторы дип тә атаганнар (күрәсең, анда йорт та булган).

Олы әрәмә дигән урын бар әле тагын.

Алгазин тавы. Революциягә кадәр Алгазин дигән бояр (алпавыт) имениесе була ул.

Иван болыны дигән болын да Алгазин һәм Белицкий дигән боярлар кулында булган.

Алгазин соңыннан прокурор булып эшләгән, бирегә үткәндә-сүткәндә генә кереп чыга торган булган. Үзен немец кавеменнән, ди икән.

Ә Белицкийның улы, Шапкин дигән фамилия белән авылга кайтып, колхоз председателе булып эшли. 30 меңче булып кайта 1957 елда. Өч ел эшли.

Чәчердән Аллаяр Сәлимов дигән кеше Шапкинны танып ала, битендәге җөе буенча, югыйсә Шапкин үзе, танытмас өчен, сакал-мыек та җибәргән була. Шапкин аңа: «Кешегә әйтмә,

минем кем икәнлегемне, мин сине обеспечить итәрмен», – ди. Чыннан да Аллаяр итен-маен алып тора тегеңәрдән.

*Чәчер авылында*
*Шәрхемулла Шәйморатовтан (72 яшь)*
*Л. Җамалетдинов язып алды. 1987*

## СӨЙЛӘКЛӘР

### Утырта алмаганнар

Сталин чорында минем бабакайны төрмәгә утыртырга теләгәннәр. Башта гаеп табарга кирәк бит әле. Бабакай ат җигеп эшли торган була. Ул эштән кайтыр вакытта аның юлына бер капчык ашлык ташлый торган булганнар. Бабакай бу капчыкны арбасына алып салса, урлаган санала инде. «Пүнәтәйләр» моны көн саен көтеп торалар, күзәтәләр. Бәхетенә, теге капчык, аны кайсы якка ташласалар да, арбаның бабакай утырган ягында түгел, аркасы ягында булып чыга. Бабакайны Аллаһы Тәгалә саклаган инде: аңа әлеге капчыкны күрсәттермәгән.

*Күҗәкә авылында Рамил Хәйбиевтән (37 яшь)*
*Л. Җамалетдинов һәм А. Гайниева язып алды. 2009*

### Чуракай бае

Чуракайда Батыршин Фәттахетдин дигән бай кеше булган. Бу байда әниемнең әтисе хезмәтче булып эшләгән. Биредә әтиемнең әнисе дә хезмәтче булган. Кәшапова Мәрьям дигән апа моңарда савымчы булып эшләгән. Монда урманнар бар бит инде безнең. Шул урман эчендә бу бай бик күп сыер асраган. Бабай балта остасы булган, йортлар төзегән Фәттахетдингә. Әби инде көндәлек хатын-кыз эшләрен эшләгән.

Бик бай булган инде бу Фәттахетдин. Моның сандыгы була, алтыннарын, акчаларын саклый торган сейфы инде. Беркөнне ул шунда актарына да, бабайны сынар өчен, сандыгын ачык калдырып чыгып китә. Шуннан безнең бабай моның артыннан йөгереп чыккан да: «Фәттахетдин агай, Фәттахетдин агай, ачкычың калды бит, сандыгыңны бикләмәдең», – дигән.

Бай әйләнеп кергән дә: «Әй, Хөснулла, мин сине әллә алырмы икән, дигән идем, бигрәк гадел булдың инде, – дигән.

Революциядән соң Фәттахетдин байны Себергә куалар, раскулачить итәләр. Ничә елдан соңдыр ул, авылга кайтып, авырып үлә. Кабере билгеле түгел.

Фәттахетдиннең элек яшәгән зур йортында мәктәп ачалар. Мин шул мәктәптә укыдым. Шуннан ничә еллар үткәч, мин инде эшли башлаган идем, безнең авылга кара «Волга» белән бер кеше кайта да шушы мәктәпкә керә, әлеге шул бай өенә. Мәктәп директорыннан сорый инде: «Кереп чыгыйм әле», – ди. Керә бу. Аны күзәтүче дә булмый, авыл халкы бит инде бик ышанучан, шундый яхшы кара машинада да кайткач…

Озак тормый, бу кеше чыгып та китә. Шуннан соң керсәләр, күрәләр: стенада озын тимерчыбык асылынып тора. Тикшереп карагач, шул мәгълүм була: Фәттахетдин бай алтыннарын комганга тутырып ике катлы стена арасында калдырган булган, ә комганга бәйләнгән тимерчыбыкның очы стенаның җиңел генә ачыла торган урынына беркетелгән була. Теге кеше әлеге тимерчыбык белән алтын тутырылган комганны тартып чыгара да үзе белән алып китә, тимерчыбыгы исә асылынып кала, ә аста комганның эзе күренә икән.

Бу кешенең кабат кайтканы булмады. Ул әлеге Фәттахетдин байның улы булгандыр инде. Аның балалары, оныклары Мәскәүдә яши, диделәр. Барысы да укымышлы, ди. Без аларны белмибез инде. Шулай да сугыш вакытында шушы якның бер кешесе очрата байның бер малаен. Үзенең Фәттах малае икәнен сиздерми инде бу офицер. Ул авылдагы бөтен кеше турында сораштыра моңардан, якын тирәдәге кешеләрне дә… Моңа да яхшылык эшли. Бу солдат әсирлеккә төшкәндерме инде, нindидер гаебе була моның. Моңа ул чиста документлар ясап бирә.

Әлеге офицерның Фәттахетдин малае икәнен фаразлыйлар гына инде. Фамилияләре дә үзгәртелгән инде аларның. Кулак балаларына үз фамилияләрен калдырырга ярамый бит инде, аларны эзәрлеклиләр ич.

Бетте инде алар. Фәттахетдиннең нәселе хәзер юк инде авылда.

*Чуракай авылында Рәүфә Миргатауллинадан (70 яшь)*
*Л. Җамалетдинов һәм А. Гайниева язып алды. 2009*

## Зирәк бабай

Гражданнар сугышы вакытында аклар безнең өйгә дә килеп кергәннәр. Әнкәйләр ул чакта бала-чага бит инде, аларны әбекәй, ястык-мендәрләр белән бергә, алдан ук базга төшереп куйган.

Аклар кергәндә бабай, авырган булып, сәкегә сузылып яткан, аның баш очында әбекәй утырган.

Безнең әбекәй бик чибәр булган. Аклар русча сөйләшәләр, ди. «Ну моның хатыны шәп, йокларга әйбәт булыр иде», – дип әйтәләр, ди. Бабай русча аңлый торган була. Ул ыңгырашып кына әбекәйгә: «Тиф белән авырый, дип әйт», – дигән. Әбекәй шулай дип әйткән тегеләргә. Аклар аңлаганнар да тиз генә өйдән чыгып та киткәннәр. Балалар да сау-сәламәт, әбекәйгә дә кагылмаганнар, бабай да исән калган.

*Чуракай авылында Рәүфә Миргатауллинадан (70 яшь)*
*Л. Җамалетдинов һәм А. Гайниева язып алды. 2009*

## МӘКАЛЬЛӘР

Батыр ярасы яуда ямалыр.
Ил эче – алтын бишек.
Дустың нинди – кадерең шундый.
Яхшыга ияргән – чәкчәккә, яманга ияргән – тозакка.
Җир – безнең тәлинкә ул: ни салсак, шуны алабыз.
Көчле күккә менәр, көчсез җиргә сеңәр.
Язның байлыгы – кояш, көзнең байлыгы – уңыш.
Галим булсаң, галәм синеке.
Дөягә атланган килеш печән чабып булмый.
Ишек янында урын барда түргә узма.
Сикәлтәсез юл булмас, капкан саен бал булмас.

*Күҗәкә авылында Фәния Фәррахобадан (79 яшь)*
*Г. Гыйләҗиева язып алды. 2009*

Яхшы кызның капкасына кырык ат бәйләнер.

*Күҗәкә авылында Шәмсинә Гайнетдиновадан (81 яшь)*
*Л. Җамалетдинов һәм Г. Гыйләҗиева язып алды. 2009*

Байның бура төбен кырсаң да бер күәслек он чыга.

*Күҗәкә авылында Рамил Хәйбиевтән (37 яшь)*
*Л. Җамалетдинов һәм А. Гайниева язып алды. 2009*

Мулладан мулла туа, юргадан юрга туа.
Аягың тәпелдәмәсә, авызың чәпелдәмәй.

*Адай авылында Васил Галимовтан (60 яшь)*
*И. Ямалтдинов язып алды. 2009*

Яманның – юлдашы, яхшының көндәше күп.

*Уразай авылында Хәсинә Әхмәтшинадан (84 яшь)*
*И. Ямалтдинов язып алды. 2009*

Берәүгә берәү ярый, баганага терәү ярый.

*Чөгәнә авылында Вәзирә Гаязовадан (76 яшь)*
*И. Ямалтдинов язып алды. 2009*

**ТАБЫШМАКЛАР**

Тимер чыпчык, сүс коерык. (Энә)

Озын агай, кая барасың? Кара пәри, син ни беләсең? (Төтен һәм корым)

Сыңар аяклы саескан су буенда су эчә. (Чүмеч)

Пич астында юеш бозау. (Тел)

Җиз сарай эчендә җизнәй аты кешнидер. (Кыңгырау)

Тимер тәкә тау шуа. (Машинка белән чәч алу)

Койрыгы бар, йоны юк; гәүдәсе бар, эче юк; башы бар, мие юк. (Чабата)

*Әнәк авылында Рәхмәтулла Хисмәтуллин (14 яшь)*
*Н. Фәттаховка язып тапшырган. 1948*

Бер төрлене саласың, ике төрлене аласың. (Сепаратор)

Җәен – соры, кышын – ак. (Куян)

Төбе юан, очы нечкә, чыгаруы көчкә. (Борау)

Суясың, туныйсың, тунаганда җылыйсың. (Суган)

*Күҗәкә авылында Зәки Хәйбиевтән (75 яшь)*
*Л. Җамалетдинов язып алды. 2009*

Күтәрелде – бәрелде, утыз өчкә ярылды. (Утын яру)
Мөтри башлы, мең күзле. (Уймак)

*Күҗәкә авылында Факирә Мусинадан (80 яшь)*
*И. Ямалтдинов һәм Л. Җамалетдинов язып алды. 2009*

Олы абзардан кече абзарга хөс-хөс. (Олы мичтән казан астына күмер тарту).

Кешегә ике тапкыр Ходай Тәгалә бирә, соңыннан кеше үзе ясата. (Теш)

*Татар Суыксуы авылында Фәхриназ Галимовадан (84 яшь)*
*И. Ямалтдинов язып алды. 2009*

## БӘЕТЛӘР

### Пугачёв бәете

Пугачёв патша бар, диләр,
Постау бишмәтләре тар, диләр,
Җаек та буе яу җирләрен
Айкап та йөргән шул, диләр.

Пугачёв патшаны күрсә идең,
Алларыннан буй бөгеп узса идең,
Аргамак менеп, дан тотып,
Җаек яуларында йөрсә идең.

*Пучы авылында язучы һәм галим*
*М. Гали тарафыннан язып алынды. 1930*

## Перепись бәете

Общий перепись язарга отчетчиклар куелды,
Мәзкүр[1] язу хакында күздән яшьләр коелды.

Отчетчиклар бересе – мөселманнан Моратов,
Икенчесе – Иштирәктән[2] Шәрәфетдин Сәлимов.

Обжорский команда – алар кемнәр? – дисәгез,
Түбән юлда язармын, аңлатырмын белсәгез.

Справник бересе, становой дүртесе,
Сотскийның саны юк, урәтникләр алтысы.

Дисәтский күптән-күп, солдатлары йөздән күп,
Жандармнар ничәдер, староста дәхи күп.

Барын җыеп санасаң, ике йөздер хисаптан,
Ихтималдыр артмагы бу әйтелгән нисабтан[3].

Сеңерән авылы китерде, бу микъдарга җиткерде,
Никадәре булса да, обжор ашап бетерде.

Өйгә кереп талыйлар, ни бар-югын карыйлар,
Җәфа өчен килгәчтән, әйтеп булмый, агайлар.

Сыерларны суйдылар, ашап-эчеп туйдылар,
Биш бидрә хәмерне эчеп гакыл җуйдылар.

Сигез кадак бөртек чәй, бар да кытай чәйләре,
Бу вакыйга булган көн газиз шәгъбан[4] айлары.

Дистә ярым сарыкны, симезне һәм арыкны,
Солдатларга өләштек йөздән артык тавыкны.

Бер пот ярым шикәрне ашап беткәч китәрме?
Аның белән белеп булмый закон ничек итәрне.

Сары майны майлыйлар, бар урынны кармыйлар,
Майны ашап бетергәч, иреннәрен ялмыйлар.

Обжорский команда күпме тордылар анда,
Түбән юлда язармын, аңлатырмын һаман да.

---

[1] Мәзкүр – югарыда әйтелгән.
[2] Иштирәк – Башкортстанның Илеш районындагы авыл.
[3] Нисаб – биредә: сан, күләм.
[4] Шәгъбан – мөселман ел исәбе буенча, елның сигезенче ае.

Тугыз тәүлек тордылар, күп кемсәне ордылар,
Үрле-түбән чабышып, чана-живот[1] кырдылар.

*Яңа Балтач авылында*
*М. Садри тарафыннан язып алынды. 1939*

**Беренче бөтендөнья сугышы бәете**

«Бисмилла», дип башладым быелның сугышларын,
Хак Тәгалә коткарырмы монда адашкан колларын?

Хактан ярдәм телимен, моңлы көйләр көйлимен,
Баштан кичкән хәлләремнән бераз кыйсса[2] сөйлимен.

Тугыз йөз ундүртенче ел туды илгә хәтәрләр,
Хәтәр башының сәбәбе – сугыштыр, зур каһәрләр.

Июльнең унсигезендә килде илгә бер фетнә,
Җиденче ай белән бара, юк сугышсыз бер көн дә.

Безнең чапкан печәнебез калды тарау болында,
Газиз хатыным, яшь балам, калды ятлар кулында.

Бу сугышның фетнәсеннән ябылды күп кибетләр,
Солдат булмаган калмады илдә һичбер егетләр.

Уналтынчы сентябрьдә булды хәбәр чыгарга.
Һичбер тәкать[3] тота алмадым кардәшләрем җылауга.

Икенче көн иртә белән җыелдык без авылга.
Безгә Ходай язган икән бала ятим калырга.

Сентябрь унтугызында килеп кердек калага,
Тотмадылар ул калада, китте башлар далага.

Калабыздан чыгу белән пароходка утырдык,
Авыр хәсрәткә җылашып, күз яшьләрен тутырдык.

Пароходка утыргачтын уйламадым кайтырга,
Инде безгә язган икән бу михнәтне татырга.

---

[1] Чана-живот – «чана-сбруй» мәгънәсендә.
[2] Кыйсса – хикәят, вакыйга.
[3] Тәкать – чыдамлык, көч, куәт.

Без авылдан чыккан чакта тәкбир әйтеп калдылар.
Бәхил булың, кардәшләрем, инде безне алдылар.

Инде хәзер килеп җиттек хак сугышның үзенә,
Яшь хәләлем, газиз балам калды ятлар күзенә.

Инде ниләр булыр, диеп, карасам як-ягыма,
Очып төшкән кошлар кебек бомба төште яныма.

Германнар туп аталар, крепостьне ваталар,
Ранен булган солдатлар күпер кебек яталар.

Иртән торып тышка чыксам, солдат килә каладан.
Котылыр микән башыбыз ахырында бу бәладән?

Мылтыгымның түтәсе, җиргә төшә шәүләсе,
Вәйран булып ятадыр мескен солдат гәүдәсе.

Һичбер белеп булмыйдыр германнарның хәйләсен.
Бу җирләрдә вафат булсам, Ходаем шәһид әйләсен.

Германнарның коймасы биек ябышып менәргә,
Чит илләрдә вафат булсак, кардәшләр юк күмәргә.

Кайда безнең илдәге тәмле-татлы ашыбыз?
Чит илләргә аерылып китте газиз башыбыз.

Солдатларның ашаганы кәбестә дә бәрәңге,
Бу җирләрдә вафат булсам, кемнәр җыяр гәүдәмне?

Солдатларның яткан җире каты сары камыштыр,
И Илаһым, рәхмәтең күп, илем белән кавыштыр.

Мескен солдатлар ятадыр каткан сохари кимереп,
Бу җирләрдә вафат булсам, бәбкәем кала тилмереп.

Ранен булган солдатлар ята җиргә тезелеп,
Зинһар алып китегез, дип, еглашалар өзелеп.

Җилбер-җилбер киләдер менгән атым яллары,
Чебен кебек кырыладыр мескен солдат җаннары.

Атсыз тимер арба илән китте газиз башыбыз,
Җиргә төшсә дәрья була күздин аккан яшемез.

Солдат итеп алдылар, өскә шинель салдылар,
Яшь хәләлем, газиз балам бигрәк ятим калдылар.

Без мылтыкны атабыз, ике җиңне сызганып,
Ранен, бичаралар, ята, тора алмыйча сызланып.

Җилбер-җилбер киләдер элеп куйган керләрем,
Солдат булып үтәдер бәнем яшь гомерләрем.

Германнарның урамы, туза аның тузаны,
Кадерле йөрегән башым инде күрә нужаны.

Туп арбасын тарткан чакта талды бәнем беләгем,
Туган илем исемә төшсә, яна бәнем йөрәгем.

Германнарның пулясе кургаш белән җиз генә,
Сагынсам да нихәл итим, кайтармыйлар тиз генә.

*Актаныш авылында Шәмсекамәр Хәнәфиевадан*
*М. Садри язып алды. 1939*

## Сугышта үлгән ир турында

Геройларча сугышып үлде минем газиз җанашым,
Шул Гитлер кабахәт җанга төшсен бу канлы яшем.

Минем җаныем һәлак булды Ысталинградларда,
Шул кадерле җаныемны сагынам ифратлар да.

Ноябрьдә хаты килде, бәхил булыгыз, диеп.
Мин югалсам, шушы әдрис белән юллагыз, диеп.

Ноябрьдә язган хаты булды азаккы хаты,
Хаты килгәч, ун көн торды – «үлде» хәбәрен алдым.

Әткәй кайчан кайта, диеп, көтәдер бәләкәе,
Сугыш туктап, кеше кайтыр – өзелер үзәккәе.

Ул кемнәргә каршы чыгар, кайттыңмы әткәем, диеп,
Исән булса кайтыр иде, нихәл итәем инде.

Сугышларда башын салды, калдырды балаларын,
Сугыш туктагач, кайта, дип, көтәләр аталарын.

Кызыл флаг күтәрделәр, сугыш туктады, диеп,
Балаларым җылаштылар, әткәй кайтмады, диеп.

Җаныкаем бар чагында белмәдем кадерләрен,
Җылый-җылый эзләсәм дә, табалмам каберләрен.

Кабер өстендә тактага язылгандыр исемең,
Тәннәрең гел җәрәхәттер – өзелә үзәгем минем.

Берсе анда, берсе монда ята микән сөягең,
Шул сөякләреңне уйлап, өзелә минем үзәгем.

Туралган әрдәнә кебек ята микән тәннәрең,
Төшләремдә шулай күрәм, җылап үтә төннәрем.

Пүлеләр килеп тигәчтен, аның каны аккандыр,
Каннар артык агу белән ушсыз булып җаткандыр.

Санитар кулына кергәч, телләре булды микән...
Яралары каты булып, интегеп үлде микән...

Башта җылыйм, утырып уйлыйм, чыгарам шигырьләрне,
Килешмәгән җире булса – кичерегез безләрне.

*Бәет 1945 елда чыгарылган.*
*Түбән Яхшый авылында*
*Мөфәккирә Галләмовадан (46 яшь)*
*Н. Фәттах язып алды. 1948*

## Риф бәете

*Агыйделнең аръягында урнашкан Такталачык болыныннан печән кибәне тарттырып алып кайтканда, Агыйдел бозы җимерелеп, трактор белән су астына китеп үлгән Такталачык егете Фазлыев Рифкә багышлана. Водолазлар ике тәүлектән соң чоңгылда әйләнеп торган гәүдәсен табып алдылар.*

Мең тугыз йөз туксан өчнең
Кышкы буранлы кичендә
Соңгы сулышларым алдым
Тирән чоңгыллар эчендә.

Кайнар гәүдәмне суырды
Бозлы дулкын кочагына.
Күз алдымнан үтеп китте
Бар гомерем шул чагында.

Гомеркәем кыска булды,
Күзкәйләрем шуңа моңлы.
Күрәчәгем шул булгандыр –
Җимердем бит кайтыр юлны.

Гомеркәем кыска булды –
Кояшлы бер якты көндәй.
Хәзер ятам су төбендә,
Караңгы шул монда төндәй.

Якты кояш нурлары да
Монда төшеп җитми икән.
Үлгәндә иң якыннарың
Күз алдыннан китми икән.

Агыйделкәй өсләрендә
Көчле икән, көчле агыш.
Күңелләрем сизгән икән –
Йөрәктә моң, күздә сагыш.

Су төпләре салкын икән,
Дулкыннары алкын икән.
Әти-әни исән булып,
Бергә яшәү алтын икән.

Үзем дә бит сабый чактан
Үскән идем калып ятим.
Хәзер, газиз балаларым,
Сез каласыз миннән ятим.

Агыйделнең суларына
Гәүдәкәем китә агып.
Дулкыннар да чыгаралмый
Хәзер мине ярга кагып.

Агыйделкәй суларына
Китәм, ахры, китәм агып.
Алыгызчы су төбеннән
Гәүдәкәем тизрәк табып.

Бик яшисем килгән иде
Булган чакта кадерләрем.
Суда түгел, җирдә булсын
Икән, үлгәч, каберләрең.

Бер-бер артлы көннәр-төннәр
Минсез дә үтә торгандыр.
Улым тәрәз төпләрендә
Әтисен көтә торгандыр.

И Рәмзия, кичер мине,
Сезне ташлап киттем инде.
Сезнең янга ашкынсам да,
Өсләремә ярлар инде.

Балаларны карап үстер,
Ятимлекне сизмәсеннәр.
Аларның күңел кылларын
Таш бәгырьләр өзмәсеннәр.

Үкенечем бигрәк ачы,
Кечкенәмне күрми калдым.
Кочагыма алып, назлап,
Әти булып сөйми калдым.

Киткән чакта хушлашмадым,
Бик йомшак шул күңелләрем.
Сезне уйлап өзгәләнәм,
Балаларым – яшь гөлләрем.

Шушы юлдан исән кайтсам,
Башка китмәм, дигән идем.
Гомер кыска, авыр сүзләр
Бер дә әйтмәм, дигән идем.

Кич утырып, гармунымда
Моңлы көйләр уйный идем.
Гомер буе бергә-бергә
Яшәрбез, дип уйлый идем.

Хәзер инде балаларым
Уйнасыннар гармунымда.
Алар өчен гомер буе
Яшәрмен тик җыр моңында.

Әни, син дә бәхилләче,
Гомеремнең бит азагы.
Бәхиллегең җиңеләйтсен
Миңа алда гүр газабын.

Әни, синең сөйгән улың,
Бердәнберең булып үстем.
Гомеремдә күп тапкырлар
Идел-дәрья аша кичтем.

Инде соңгы тапкыр үтәм
Идел-сират күперләрен.
Минем кайгы-хәсрәтемнән
Йөрәккәең күмерләнер.

Яр башында һәр җәй саен
Үсәр сары чәчкәле гөл.
Бик юксынсаң, Рәмзиякәй,
Шул моңсу гөл янына кил.

Гөле аның мин булырмын,
Сары чәчкә – сагышларым.
Сиңа барсын сөйләр идем –
Юк шул телем-тавышларым.

Ә син сөйлә, гөлгә сөйлә,
Бушат эчең, кайгың тынар.
Сине аңлап, яфрагымнан
Чыклар булып яшем тамар.

Өзмә сары чәчәгемне,
Аның сүле – минем каным.
Шул чәчәккә килеп кунган
Күбәләге – минем җаным.

**Өзгәләнү**

Кулкайлары бәке тишә,
Күзе белән бозны тишә,
Күңеле белән төпкә төшә,
Телкәйләре аңа дәшә:

– Балакаем, хәбәр бирче,
Кай тирәләрдә ятасың?
Өстә генә йөзәсеңме,
Бик тирәнгәме баткансың?

Нихәл итим, эндәш инде…
Шунда бәке казыр идем.
Билләремә баулар бәйләп,
Үзем төшеп алыр идем.

Кышның ачы җиле исә,
Ата бәгърен кайгы кисә,
Өзгәләнеп елый-елый,
Ничәнче кат бәке тишә.

*Такталачык авылында Рәмзия Әхмәтовадан*
*язып алынды. 1993*

**Айнур бәете**

*2006 елның 9 октябрендә Такталачык авылы халкын тетрәндергән зур фаҗига булды. Балалар бакчасыннан кайтып килүче Айнурны зур тизлектә килүче машина бәрдерде. Бу бәет бер минут эчендә гомере өзелгән 6 яшьлек сабыйга багышлана.*

«Тып-тын калган көзге урман,
Агач башы ялангач;
Соңгы яфрак төшә калтырап,
Аз гына җил кагылгач».

Ятларга биргән бу шигырь һич кермәде башыма.
Әни-җаным, шул шигырьне язысыз кабер ташыма.

Мин соңгы яфрак булдым шул, өзелеп төштем җирләргә.
Уйламадым алты яшьтән керермен дип гүрләргә.

Бакчалардан кайткан чакта бәрде җиңел машина.
Яфрак сыман әйләндем дә төштем юлның ташына.

Кайтып җиткәч, өебезгә кереп җитә алмадым.
Саимә әбиләр почмагында чыкты минем җаннарым.

Сизгән кебек, кайткан чакта җитәкләдем апаны.
Шофер абый, син ясадың төзәлмәс зур хатаны.

Бәрдергәч тә качып киттең, килмәдең яннарыма.
Ничек яшәрсең тынычлык табалмый җаннарыңа?!

Әти белән әниемә бердәнбер бала идем,
Бакчаларга илтеп куйгач, кул болгап кала идем.

Бер дә җәяү йөретмәде – әтием сизенгәндер,
Кайтып җитмәде ул көнне – үзәге өзелгәндер.

Соңгы тапкыр әниемә ачалмадым күземне,
Теләсәм дә әйтә алмадым аңа әйтер сүземне.

Каным аккан җиргә карап, капкалардан чыгарсыз.
Яныгызда мин булмагач, белмим, ничек чыдарсыз?!

Көзләр җиткәч, яшьтәшләрем мәктәпләргә китәрләр.
Сезнең күңелләрне, әни, бик ямансу итәрләр.

Тезелеп баскан балаларны әкрен генә күзләрсез,
Шул балалар арасыннан, әнием, мине эзләрсез.

Эзләмәгез, табалмассыз, яфрак булып өзелдем.
Бик сагынсаң да елама, әни, җаным, түз инде.

Андый чакта каеннарның яфрагына карагыз.
Соңгы яфрак мин булырмын, мин – бердәнбер балагыз.

Айнур идем – чын нур идем, кыска булды гомерем.
Балкып кына яндым да мин, калды бары каберем.

Нәни чактан иңнәремә килде канат куясым,
Өстән карап бар җиһанны күңелемә уясым.

Инде хәзер мин күкләрдә, кирәк түгел канатлар.
Сезгә биргән күп сорауга таптым әзер җаваплар.

Дәү әнием, намаз саен догалардан калдырма,
Мине көтеп, тәрәз саен карап күзең талдырма.

Кояш чыкканда, нур булып, тәрәзәңә төшәрмен,
Тирән сагышлы моң булып, мин җырларга күчәрмен.

Күзләр саен сары төсләр яңартырлар сагышыңны,
Киткән кошлар сәламендә ишетерсез тавышымны.

Әти-әни, боекмагыз, сабыр итеп түзегез,
Тормышыгыз дәвам итсен – әле яшь сез үзегез.

Шофер абыйлар, сезгә дә әйтер сүзем бар әле:
Ашыкмагыз машинада, юллар бик-бик тар әле.

Авыллардан үткән чакта игътибарлы булыгыз,
Минем урында булырга мөмкин сезнең улыгыз.

Миннән калган бар балалар исән-имин йөрсеннәр.
Җирдә яшәү – олы бәхет, зинһар, шуны белсеннәр.

*Такталачык авылында*
*Гәүһәрия Мусинадан язып алынды*

## МӨНӘҖӘТЛӘР

### Алданмагыз

«Бисмилла» дип башладым,
Тыңлар булсаң мөнәҗәтне.
Бер Ходаем үзе биргән
Ахирәтне вә җәннәтне.
Бу дөньяга алданмагыз,
Алдамады ул кемнәрне...
Җыйган малың бар да калыр –
Гаҗиз булма ул көннәрне.
Дуслар, гайбәт сөйләмәгез –
Гайбәтченең эше харап,
Гайбәт сөйләгән кешегә
Эчермәсләр кәүсәр шәраб.
Сәгадәтле булыйм дисәң,
Мәгърифәтне алыйм дисәң,
Бер Ходайга ярыйм дисәң,
Укы иртән-кичен Коръән.
Бу дөньяга алдандык без,
Акны-караны белмичә.
Ходайныкын белеп булмый
Кара гүрләргә кермичә…

*Адай авылында Гөлфирә Фәрдиевадан (73 яшь)*
*Г. Гыйләҗиева һәм А. Гайниева язып алды. 2009*

## Сабырлык турында

Сабыр итим, сабыр итим,
Сабыр итмәй, ни хәл итим,
Сабырлыкның дәрәҗәсен
Бер Ходайдан өмет итик.

Сабырларны Хода сөйде,
Сабырсызны ләгыйнь сөйде,
Ләгыйнь ни ул, Хода сөрде –
Сабырлар бир, үзең, Аллам.

Сабыр куйды Мораy атлы,
Хода куйды Хәбиб атлы.
Сабырларның йөзе нурлы –
Сабырлар бир үзең, Аллам.

Минем кеби ки кайгылы
Булыр микән бу дөньяда?
Һәмишә кайгылы бәндә-
ләри булам бит, дивана.

Сабыр итмәк кирәк безгә,
Минем кебек кемнәр түзә?
Шулай да бит йөрәк сыза –
Сабырлар бир үзең, Аллам.

Укыйм микән, языйм микән,
Бу гамь бәндин китәр микән?
Бу кайгылар, бу сагышлар
Диваналар итәр микән?

Җылай-җылай күзем бетте,
Гакылым бетте, ушым бетте,
Сабырлар бир үзең, Аллам.

Укыйм микән, языйм микән,
Бу гамь бәндин китәр микән?
Бу кайгылар, бу сагышлар
Гүргә алып китәр микән?

Минем мөнәҗәтем бетмәс,
Каләм белән кәгазь җитмәс,
Бу кайгыдан кеше үлмәс,
Ирешмәсә әҗәлләргә.

Зиярат юллары кара,
Карасам күзкәем тала,
Кигән киемнәрең күргәч,
Дәхи йөрәкләрем яна.

Ачы җил, син кайда истең,
Ничә сәхрә үтеп кичтең,
Балаларны кайда күрдең? –
Диеп сорыйм ки җилләрдин.

*Түке авылында Хәмидә Халиковадан (85 яшь)*
*Л. Җамалетдинов язып алды. 1987*

## Изге теләкләр

Утырмаек фикер белән,
Утыраек зекер белән,
Алга килгән нигъмәтләрне
Без ашаек шөкер белән.

Алланың рәхмәте булсын
Бу өйләр нур белән тулсын,
Әзерләгән нигъмәтләрең
Җәннәтләрдә алда торсын.

«Әгузе» белән «бисмилла»
Һәрбер китапның башында;
Исеңдә тот, һич онытма –
Шулардан үтәр барсы да.

Җәннәтләрдә җимеш булсын,
Дәхи алдыгызда торсын,
Барча кардәшләрең белән
Сигез җәннәт насыйп булсын.

*Татар Суыксуы авылында*
*Хәмдесафа Сәлмәнфарсыевадан (96 яшь)*
*Г. Гыйләҗиева һәм А. Гайниева язып алды. 2009*

## Дөнья малы калачак

Кардәшләрем, уйлыйсызмы
Авыр көннәр киләсен –
Фани дөньяны калдырып,
Җир астына керәсен?

Яман юл белән мал табып,
Үзеңә гөнаһы алма;
Дөнья малына кызыгып,
Иманыңнан коры калма.

Җир астына керү белән,
Телгә киләсебез бар;
Дөньяда калган эшләргә
Җавап бирәсебез бар.

Никадәрле тупласак та,
Дөнья малы калачак;
Иман, изге гамәлләрең
Үзең белән барачак.

Изге юлны юлдаш итик,
Яман юлга юлыкмаек,
Бу дөньяда кунак кына
Булуыбызны онытмаек.

Дөрес, мал табу да кирәк,
Аңа да бар чарагыз:
Хезмәткә һәм гыйбадәткә
Тигез итеп карагыз.

*Татар Суыксуы авылында*
*Сәкинә Шәйхәйдәровадан (57 яшь)*
*Г. Гыйләҗиева һәм А. Гайниева язып алды. 2009*

## Чын мөселман булыйм дисәң...

Чын мөселман булыйм дисәң,
Әгәр дә булса теләк,
Мөселманга беренче шарт –
Иманлы булу кирәк.

Өченчесе – һәрбер елда
Бер ай ураза тоту;
Күңелеңне сафландырып,
Калебеңне пакь итү.

Икенче шарт – биш вакыт
Намаз укырга өйрән,
Коръән аятьләрен укы
Ихлас күңелең белән.

Дүртенчесе – намус белән
Үз көнеңне күрәсең,
Кеременнең бер өлешен
Зәкать итеп бирәсең.

Бишенчесе – көчең җитсә,
Хаҗ сәфәре кыласың;
Менә шуларны үтәсәң,
Чын мөселман буласың.

Әгәр чын мөселман булсаң,
Каберең нурга тулыр,
Кыямәт көне килгәндә
Җавабың җиңел булыр.

*Татар Суыксуы авылында Сәкинә Шәйхәйдәровадан (57 яшь)*
*Г. Гыйләҗиева һәм А. Гайниева язып алды. 2009*

## Менә шундый заман җитәр

*Рәсүлүллаһ салаллаһу галәйһи вәссәламдин сәхабәләре сораганнар: «Йә рәсүлуллаһ, кыямәт көне кайчан була? Безгә шуны бәян кыл», – дигәннәр.*

*Рәсүлуллаһ салаллаһу галәйһи вәссәлам җавап биргән: «Менә сезгә бәян кыламын, кыямәт алларында шул хәлләр булыр»:*

Бу дөньяларда ямь бетәр,
Халык карар уңга-сулга,
Изге гамәл һич тә кыйлмас,
Ләкин мал күп булыр кулда.

Ата-анада гайрәт бетәр,
Балаларда шәфкать бетәр,
Туганнарда рәхим бетәр –
Менә шундый заман җитәр.

Йокылары нәүбәт булыр,
Хезмәтләре сәгать булыр,
Ризыклары үлчәү белән –
Менә шундый заман җитәр.

Җир йөзендә оят бетәр,
Хатын-кызда хәя[1] бетәр.
Әгузе-бисмилла бетәр –
Менә шундый заман җитәр.

Зур-зур биналар салырлар,
Ашыгып эшкә барырлар,
Эчеп гауга чыгарырлар –
Менә шундый заман җитәр.

Биналары биек булыр,
Эче тулы җиһаз булыр,
Дин догасы бозык булыр –
Менә шундый заман җитәр.

Адәмнәрнең өсләрендә
Аллы-гөлле кием булыр,
Берсен салыр, берсен кияр –
Менә шундый заман җитәр.

Берсен салыр, берсен кияр,
Начар сүзләр үзе сөйләр,
«Үземә-үзем хуҗа», – дияр,
Менә шундый заман җитәр.

[1] Хәя – оят.

Атасыз бала күп булыр,
Маллы кеше саран булыр,
Мәҗлесләре уен булыр –
Менә шундый заман җитәр.

Хак әмеренә карышырлар,
Һаман динне онытырлар,
Дин иясе гаҗиз булыр –
Менә шундый заман җитәр.

Гөнаһ икәнен белмәсләр,
Биш вакыт намаз кылмаслар,
Сәдака-фитыр бирмәсләр –
Менә шундый заман җитәр.

Балалары түрә булыр,
Хатыннары солтан булыр,
Ир аларның колы булыр –
Менә шундый заман җитәр.

Адәмнәре гайбәт сөйләр,
Эше белән мактанырлар,
Үз-үзләрен зурга куяр –
Менә шундый заман җитәр.

Галимнәре вәгазь сөйләр,
Наданнары гайбәт сөйләр,
Адәм хәвеф белән үләр –
Менә шундый заман җитәр.

Ефәк киемнәр киярләр,
Мине күрсеннәр, диярләр,
Тәгамне басып ашарлар –
Менә шундый заман җитәр.

Ире-хатыны хәмер эчәр,
Төрле уеннар корырлар,
Ислам динен онытырлар –
Менә шундый заман җитәр.

Базарда ризык күп булыр,
Ягъмурлар бик сирәк булыр,
Хәрәм ашаулар хас булыр –
Менә шундый заман җитәр.

*Күҗәкә авылында*
*Фәния Фәрраховадан (79 яшь)*
*Г. Гыйләҗиева язып алды. 2009*

## Догагыздан ташламагыз

Мөнәҗәтне укысагыз,
Бисмилласыз башламагыз,
Газиз әткәм, газиз әнкәм,
Догагыздин ташламагыз.

Газиз әткәм, сүзем шулдыр,
Аерылдым үз илемдин,
Бу сугышта вафат булсам,
Ташламагыз догагыздин.

*Күҗәкә авылында*
*Фәния Фәрраховадан (79 яшь)*
*Г. Гыйләҗиева язып алды. 2009*

**ҖЫРЛАР**

## Елан керде лә куенымa

Вокзалларга машиналар
Киләләр дә китәләр;
И... туган илем,
Елан керде лә куенымa.

Ай, дусларым, безнең башны
Яшьли әрәм итәләр.
И... туган илем,
Елан керде лә куенымa.

Машиналар, машиналар
Әйләнә дөньяларны;
И... туган илем,
Елан керде лә куенымa.

Машиналар да тарталмас
Без күргән нужаларны.
И... туган илем,
Елан керде лә куенымa.

Машиналар үтеп киткәч,
Тимер юл кызган булыр;
И... туган илем,
Елан керде лә куенымa.

Кайтуларын бер кайтырбыз,
Яшь гомер узган булыр.
И... туган илем,
Елан керде лә куенымa.

*Актаныш районында (авылы билгесез)*
*Х. Сәйфетдиновтан М. Садри язып алды. 1939*

## Яз да була, көз дә була

Яз да була, көз дә була,
Су өсләре боз була;
Ике егет бергә килсә,
Сөйләшкәне кыз була.

Яз да була, көз дә була,
Көзгә таба җил була;
Ике күзем юлда була,
Кайтып килсәң ни була?

Яз да була, көз дә була,
Су читләре боз була;
Яшь вакытта кемне сөйсәң,
Күңелең шуңарда була.

*Актаныш авылында Камәр Әлмиевадан (31 яшь)*
*М. Садри язып алды. 1939*

## Аккош баласы

Биек тауның итәгенә,
Газизә,
Кем казыган кар базы?
Аккош баласы.

Синнән аерылырга сәбәп,
Газизә,
Күрдем ялгыз кыр казы,
Аккош баласы.

Зәйтүн гөле чәчәк ата,
Газизә,
Бармы сезнең илләрдә
Аккош баласы.

Синең тавышың килгән кебек,
Газизә,
Кичке салкын җилләрдә,
Аккош баласы.

Аргы якның күрәнен,
Газизә,
Бирге яктан күрәмен,
Аккош баласы.

Нурлы йөзем саргаюын,
Газизә,
Сине уйлаудан күрәмен,
Аккош баласы.

Су буенда кошлар йөри,
Газизә,
Канатларын кагынып,
Аккош баласы.

Көн дә саен хатлар язам,
Газизә,
Син җаныемны сагынып,
Аккош баласы.

*Актаныш авылында Шәмсекамәр Хәнәфиевадан (37 яшь)*
*М. Садри язып алды. 1939*

## Кавышырбыз

Кар яуган җирләр ак икән,
Яумаган җир бар микән?
Безне дошманнар күралмый –
Әллә дөнья тар микән?

Җаным, шуңа гаҗәпләнәм:
Бер сабакта биш алма;
Изге төшләр күрәм, җаный, –
Кавышырбыз, иншалла.

## Икенче сада көе

Ай-һай, иптәшләр, күп безнең эшләр;
Без тырышмасак, милләт ни эшләр?
Анадан тудык, дөньяда тордык,
Инде хур булдык, нидән бу эшләр?
Без дә инсанбыз, һеб[1] мөселманбыз.
Бик бозылганбыз, нидән бу эшләр?

---

[1] Һеб – юкка чыгу.

Ачлыкта без дә, хурлыкта без дә,
Нур юк һич йөздә, нидән бу эшләр?
Нигә тормыйбыз, гыйлем сөйлибез,
Эшкә көнебез, нидән бу эшләр?
Гайрәтсез калган, хатыннан яман,
Раббым бир әман[1], нидән бу эшләр?
Һич эш тотмыйбыз, ашап йоклыйбыз,
Дисбе чутлыйбыз, нидән бу эшләр?
Көн үтсә дә, без түбән китәбез,
Мәһди көтәбез, нидән бу эшләр?
Йокыдан торсак, эшкә керешсәк,
Ныклап тырышсак, җайланыр эшләр.

*Ошбуны язучы Нурелгаян бине Нурмөхәммәт.*
*Иске кулъязмадан*

## Мөхәммәдия көенә

И, гыйлем мәнбагы[2], сиңа ниләр булды, сөйлә хәлең,
Беләм, белдермәсәң дә, син бәхетсез сөрәсең дәүран[3]
Бүселгән корсагың төшкән, черегән, яңагың күчкән,
Нигезең эт чукып тишкән, кәҗә-сарык итә сәйран[4].
Түбә тактаң да черегән, түшәм рөкүгъка[5] иелгән.
Эчкә төрле кош тулган, хәвефсез итәләр тайран[6].
Түбәң дә тетелеп беткән, мичең дә сәҗдәгә киткән,
Идәнеңә шомырт сипкән кәҗә дигән усал хайван,
Татарларда торасың син булып ятим, фәкыйрь, мескен,
Нәзар[7] кылмый сиңа һичкем фәкыйрьләрдән дәхи байдан.
Шәкерт булмый эчеңдә һич, ут алынмый укырга кич.
Бу хәл эчрә сине күргәч эчемдә фырлады нәйран[8].

---

[1] Әман – тынычлык, иминлек.
[2] Мәнбаг – чишмә, чыганак.
[3] Дәүран – дәверләр.
[4] Сәйран – күңел ачып йөрү, гизеп тамаша итеп йөрү.
[5] Рөкүгъ – иелеп тору, намазда тезләргә таяну.
[6] Тайран – очу, һавага күтәрелү, югары күтәрелү.
[7] Нәзар – карау, игътибар итү, күз салу.
[8] Нәйран – утлар, җәһәннәм уты.

Булып син кәҗәгә абзар, эчендә йөриләр казлар.
Моны күреп, вәсим[1] аглар, һушы китәр булып соңран.
Түгәсең яшь бу хәлләргә, яшең төшсен татарларга,
Мөселман юкмы жәлләргә, диеп киттем булып хәйран.

*Куян авылында Салиха Зарипова дәфтәреннән (50 яшь)*
*Х. Ярми язып алды. 1948.*
*Гарәп язуыннан А. Гайнетдинов күчерде*

## Сабыр итеп түзәм

Безнең турга сулар килгән –
Басмасы китәр инде,
И ходаем, бирмә кайгы –
Биргәнең җитәр инде.

Безнең турга сулар килгән –
Каен басмалар салам.
Каен басмаларга басып,
Кайгымны суга салам.

Агыйделгә күпер салдым,
Кемнәр салган чи киртә,
Чит җирләрдә шунысы кыен –
Сагындыра кич-иртә.

Үзем җырлыйм, үзем уйлыйм,
Үзем гәрәбә тезәм,
Төштем кайгы кулләренә –
Сабырлар итеп түзәм.

*Түке авылында Хәмидә Халиковадан (85 яшь)*
*Л. Җамалетдинов язып алды. 1987*

## Улыма

Кояш кебек нурың сибеп,
Бусагамны атладың;
Кайталмаган елларында
Килеп торсын хатларың.

Бик матур чәчәкләр бирдем,
Кулларыңда корытма,
Әтиеңнең-әниеңнең
Бар икәнен онытма.

Киленебез – Киров ягы,
Кияү ягы – Актаныш,
Туйларыгыз матур узды –
Без китәбез шатланып.

*Күҗәкә авылында Мөзәянә Исмәгыйлевадан (69 яшь)*
*Л. Җамалетдинов язып алды. 1987*

[1] Вәсим – гүзәл, матур йөзле.

## Төркестан

Төркестандин искән ачы җилләр
Бертуктамый тагы да исәрме?
Илем калды ерак, үзем монда –
Кайтыйм, дисәм, тормыш җибәрми.

Иртән генә торып, тышка чыксам,
Ап-ак чәчкә – кая карама;
Бер карыймын байга, бер – фәкыйрьгә,
Фәкыйрь гомере уза заяга.

*Күҗәкә авылында Мөхтәсәр Мияссәревтән (83 яшь)*
*Л. Җамалетдинов һәм А. Гайниева язып алды. 2009.*
*Мөхтәсәрнең әтисе Мияссәр, тормышы авыр булганлыктан,*
*Төркестанга (Урта Азиягә) китә. Бу җырны ул шунда чыгара*

## Төрмә җырлары

Төрмә, диләр, төрмә, диләр,
Анда сарык япмыйлар;
Алтын-көмештән кадерле –
Көне-төне саклыйлар.

Кояшка каршы салынган
Минзәлә төрмәләре,
Яшь йөрәккә курку салды
Караңгы бүлмәләре.

Әнкәй, ашың пешкән булса,
Балаларың җыелыр;
Алар булып, мин булмасам,
Күз яшьләрең коелыр.

Прагулкага чыгабыз
Куркыныч әхрән белән,
Шалтыратып бикләп куя
Богау-йозаклар белән.

*Күҗәкә авылында Факирә Мусинадан (82 яшь)*
*И. Ямалтдинов язып алды. 2009*

## Бәхетләрем булмагач

Өй артына гөл утырттым –
Гөл үсеп китәр инде;
Сине сагынып, сине уйлап,
Гомерем үтәр инде.

Агыйдел каты ага,
Ярлары тулса гына;
Сагынамын, саргаямын –
Һәрчак син уйларымда.

Чәчем кара, бигрәк озын,
Кызганам кистерергә;
Бәхет бит ул гөлләр түгел,
Су сибеп үстерергә.

Өй артында алмагач,
Кистем утын булмагач;
Адайларда көтү көтәм,
Бәхетләрем булмагач.

*Адай авылында Васил Галимовтан (60 яшь)*
*И. Ямалтдинов язып алды. 2009*

## Бас, бас эзенә
## *(Бию такмагы)*

Бас, бас эзенә,
Күз тимәсен үзенә;
Яшел чирәм үсеп тора
Аяк баскан эзенә.

Ай-ли, бөгелми –
Матур баса түгелме?
Тып-тып басып биегәндә
Күңелне ача түгелме?

Каладан кайткан егет,
Оек-чабата киеп;
Монда килеп, итек киеп,
Нишләп йөрисең биеп?

Иске лә шырпы кабы,
Яңа ла шырпы кабы;
Быел алган итегемнең
Туза инде табаны.

Бас-бас эзенә,
Күз тимәсен үзенә,
Җимер тимер коймасын –
Юл өстендә тормасын!

*Адай авылында Гөлчирә Шәехovадан (80 яшь)*
*З. Вәлиева язып алды. 2005*

## Чөгәнә авылы гимны

Үзәккә барып тоташа
Туры асфальт юллары,
Тирә-юньдә дан казанды
Егетләре, кызлары.

Тау читендә үсә җиләк,
Әрәмәдә – бөрлегән;
Бөрлегән өзеп бирермен,
Кил яныма, бер генәм.

Күлләр ягы яшел бәрхет,
Болыны җәйрәп ята;
Авылымның табигате
Ял йортын хәтерләтә.

Туган авылым, Чегәнәм,
Тирә-юньдә бергенәм,
Шул авылда туганыма
Кабат-кабат сөенәм.

Читләргә китсәм сагынам –
Бер дә чыкмый уемнан.
Авылыма кайтам әле
Бормалы су буеннан.

*Чөгәнә авылында Энҗе Якуповадан (53 яшь)*
*И. Ямалтдинов язып алды. 2009*

## Сагыну җыры

Хатлар язам таңның күкрәгендә
Хатлар язам, җилкәй, исми тор;
Чишмәкәй, тын, зинһар челтерәмә,
Үткән гомер, искә төшми тор!

Ага гына сулар, исә җилләр –
Туктатып торырлык чара юк;
Күңелкәем йөри сезнең янда –
Күңел барып җитмәс ара юк.

## Түзми күңелем

Карт булсам да, мин һаман да
Җырлап җибәрәм сабанда;
Түзми күңлем бу заманда
Җырламыйча-моңланмыйча.

Түзми күңлем бу заманда
Җырламыйча-моңланмыйча;
«Әнә җырлый юләр», – диләр,
Тик әйтәләр уйламыйча.

*Уразай авылында Кадрия Саматовадан (70 яшь)*
*Г. Гыйләҗиева һәм А. Гайниева язып алды. 2009*

## Кыска җырлар

Сабырлар ит, җаныкаем,
Сабырлар – сары алтын;
Мин сабырлар итәлмимен –
Эчләрем тулы ялкын.

Өй артындагы бакчамда
Аерым-аерым түтәлләр;
Без аерылган да бик җиткән –
Аерылмасын бүтәннәр.

Алмалар өзәсеңме,
Бауларга тезәсеңме?
Өзелгән алмалар кебек
Аерылдык – сизәсеңме?

Уралып-уралып ага
Уралның ак сулары,
Шул Урал сулары кебек
Уралышырбыз әле.

Тал кискәннәрем юк иде –
Талдыра икән беләкне;
Яр сөйгәннәрем юк иде –
Яндыра икән йөрәкне.

*Уразай авылында Зәкия Халиковадан (96 яшь)*
*Г. Гыйләҗиева һәм А. Гайниева язып алды. 2009*

Кульяулыгым чайкар идем,
Ишек алдым күл булса.
Көн саен да кайтыр идем,
Җир астыннан юл булса.

«Абау, Алла», – диеп кенә
Утырам боек кына.
Үтә яшь гомеркәйләрем,
Чәчәген коеп кына.

Сандугачлар ояда,
Оялары – пыяла;
Кыз бала, газиз балакай
Үсеп җиткәч, югала.

Уфа, диләр, Уфа, диләр,
Уфа биек тауларда;
Бүген монда башкайларым,
Иртәгә әллә кайларда.

Сары матур, сары матур,
Сары матур, сайласаң;
Тавышларыңнан танырмын,
Кошлар булып сайрасаң.

Яшел күлмәкләр кигәнсең,
Яшел төс килешүчән;
Әллә нигә башкайларым
Нахак сүз ишетүчән.

Кара күлмәкләр кигәнсең –
Гел карадан ки, әйдә;
Яшерен ярлар сөйгәнсең –
Гел яшерен сөй, әйдә.

Барган идем урманнарга –
Каеннар кискән идем.
Каен яфраклары кебек
Кайгысыз үскән идем.

Алтын алка авыр тарта –
Алты мыскалдан арта;
Кайгыларым бетәр, дисәм –
Минутлар саен арта.

Атлар килә атлап-атлап,
Алма чәчкәсен таптап;
Сине – миңа, мине – сиңа
Йөрмәсләр ятлар мактап.

Сибелә чәчем, сибелә чәчем,
Сибелсен – тарамагыз;
Төштем кайгы күлләренә –
Дусларым, аралагыз.

Сибелә чәчем, сибелә чәчем,
Сибелсен генә инде;
Бер аерылгач, күңелләрем
Сүрелсен генә инде.

*Уразай авылында Хәсинә Әхмәтшинадан (84 яшь)*
*Л. Җамалетдинов язып алды. 2009*

Агыйделгә басма салдым:
Берсен – безгә чыгарга;
Бергә булган минутларны
Исләреңнән чыгарма.

*Күҗәкә авылында Мөзәянә Шакировадан (89 яшь)*
*Г. Гыйләҗиева язып алды. 2009*

И бәхетләрем булмады,
Кешеләргә булган бәхет
Миңа кулын болгады.

Бәхет күлләрендә йөзә
Минем бар иптәшләрем,
Минем генә бәхетем юк –
Түгелә күз яшьләрем.

Уйлый күңелем, уйлый күңелем,
Уйлый күңелем әллә ни;
Уйлама, күңелем, әллә ни –
Уй бетерә бәндәне.

*Күҗәкә авылында Рәисә Шәйгәрдәновадан (71 яшь)*
*И. Ямалтдинов язып алды. 2009*

Агыйделдә ике сал:
Берсе – имән, берсе – тал,
Коммунизм яшәгәндә
Яши алмый капитал.

Аллар да булалмадым,
Гөлләр дә булалмадым,
Җәйнең ямьле көннәрендә
Иллэрдә булалмадым.

*Түмерҗә авылында туып үскән Җәмилә Гыймазетдин кызы Шәмсиевадан (79 яшь) Л. Җамалетдинов язып алды. 2009*

Хатлар язам мин сиңа,
Син дә язарсың миңа;
Шушы хатта ничә хәреф –
Шулкадәр сәлам сиңа.

Тәрәзә төбем исле гөл –
Исләренә исерәм,
Исләремнән һич чыкмыйсың –
Сагынып гомер кичерәм.

Алсу алмалар төясәм,
Тартыр микән атларым?
Үзем кебек сөйләр микән
Сагынып язган хатларым?

Йөгереп төштем – бәке тиштем,
Бүрек белән су эчтем;
Бүген төнлә төшләремдә
Синең белән күрештем.



Аналы-кызлы
Мөзәянә Садыйкова
һәм Фәйрүзә Кыямова.

Җаныемның исемнәре
Кулымдагы йөзектә,
Кайгы күлләренә төштем –
Чыгалмыймын ничек тә.

Әйдә, дустым, җырлыйк әле
«Алмагачы» көенә;
Күләгәләрен күрсәм дә
Күңелләрем сөенә.

Алма турыйм, алма турыйм,
Алма турыйм кисәкләп,
Төн йокыларым йокламыйм,
Җаныем, сине исәпләп.

Сагынам, иркәм, сагынам, иркәм,
Сагынам, иркәм, гел сине,
Син тугансың аналардин
Саргайтыр өчен мине.

Сандугачлар тезелгәннәр
Ике дилбәгә булып,
Без кайчан кавышырбыз соң
Икебез бергә булып.

Өстәлләрдә тәлинкәләр:
Алмалар тутырганнар,
Исеңдәме сезнең белән
Җырлашып утырганнар?

Иртән торып тышка чыксам,
Казлар каңгылдашалар,
Без китәргә, сез калырга
Көннәр якынлашалар.

Кулъяулыкларым болгадым,
Иркәм, син күмелгәнче;
Син онытсаң онытырсың –
Мин онытмам үлгәнче.

Алма бакчасына кереп,
Хат язуда исәбем;
Ике күзем, бетте сүзем –
Сау бул, алма кисәгем.

Түбәтәең сәйләндер,
Сәйлән ягын әйләндер,
Бик сагынган чакларыңда
Зөбәердән әйлән бер.

*Зөбәер авылында аналы-кызлы Мөзәянә Садыйкова (72 яшь)*
*һәм Фәйрүзә Кыямовадан (50 яшь) Л. Җамалетдинов язып алды. 1987*

## БАЛАЛАР ФОЛЬКЛОРЫ[1]

### Бишек җырлары

Бигрәк матур, күз тимәсен,
Кемгә ошаган, кем төсле? –
Утырадыр бишегендә
Чәчкә аткан гөл төсле.

*Түбән Яхшый авылында*
*М. Зиннәтуллина язып алды. 1984*

Әлли-бәлли бәбкәсе,
Кая киткән әнкәсе?
Каенлыкка җиләккә,
Гөлнарага бүләккә.
Анда җиләк күп икән,
Аю, бүре юк икән.
Әлли-бәлли бәү итә,
Гөлнара йокыга китә.
Гөлнара йокыга киткәч,
Әнисе кайтып җитә.

*Уразай авылыннан Фәнүсә Әхмәтҗанова*
*язып җибәрде. 1982*

### Эндәшләр

Кояшкаем, чык, чык,
Майлы ботка бирербез.
Майлы ботка казанда,
Тәти кашык базарда.
Кирәкми безгә салкын,
Кирәк безгә саф алтын.

*Бурсык авылыннан Ә. Вахитова (13 яшь)*
*язып җибәрде. 1982*

### Әйтенүләр

Тилгән, тилгән,
Чеби урларга килгән.

[1] Бу бүлектәге әсәрләр «Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры» дигән китапка да кергән (төзүчесе, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Р. Ф. Ягъфәров). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.

Бер аягы камырдан,
Бар аягы тимердән.
Көш, карак, көш, карак,
Торабыз һәрчак карап.

*Бурсык авылыннан Ә. Вахитов (13 яшь)*
*язып җибәрде. 1982*

Тук-тук, тукран,
Тукылдатып утырам,
Агачтагы кортларның
Барсын чүпләп бетерәм!

*Яңа Әлем авылыннан Гүзәлия Галиева (13 яшь)*
*язып җибәрде. 1981*

Тәкәри-мөкәри,
Мөгезеңне чыгарый.

*Такталачык авылында Алабуга дәүләт педагогика*
*институты студентлары язып алды. 1982*

### Иярмешләр

Иляһи амин,
Без туйдык, парин.
Кытлык китте
Кырык чакрым ярым.

*Яңа Әлем авылыннан Г. Галиева*
*язып җибәрде. 1983*

### Үртәвечләр

Бәдри, Бәдри-Бәчмәчә,
Бабаң җирен сөрмәсә,
Әтәң ашлык чәчмәсә,
Һавадан яңгыр яумаса,
Инәң урак урмаса,
Әбиең ипи салмаса,
Ни ашарсың, Бәчмәчә?

*Яңа Әлем авылында*
*Динсаф Халиков язып алды. 1983*

Вәчкә, Вәчкә,
Төшеп киткән күәскә.

Күәс төбе апара,
Чыга алмый акыра.

*Түбән Яхшый авылында*
*М. Зиннәтуллина язып алды. 1984*

Шакир-шакмак,
Чабата башмак.
Яргала да мичкә як!

*Яңа Балтач авылында*
*Әнүзә Зиннәтуллина язып алды. 1983*

Котырган, котырган,
Төнлә торып утырган.
Бер бәлеше пешмәй калган,
Шуны көтеп утырган.

*Такталачык авылында Гөлфара Тимеровадан (11 яшь)*
*язып алынды. 1975*

Такталачык – каткан балчык,
Түмерҗә – туң морҗа.

*Чуракай авылында Радик Насретдиновтан (13 яшь)*
*язып алынды. 1975*

## Такмаклар

Биек тауның башларында
Үсәдер мәтрүшкә.
Бер көн килә, бер көн килми
Безнең Илдус дәрескә.

*Бүләк авылында*
*Роза Шәрипова язып алды. 1982*

Рано утром – иртә белән,
Пошли-киттек базарга.
Надо-кирәк, бидрә-чиләк,
Скорее-тизрәк.

*Яңа Әлем авылында Чулпан Миннехановадан (11 яшь)*
*язып алынды. 1975*

## Такмазалар

Бар иде яшь чаклар,
Билдә чыра пычаклар.

Агач атта чапкан чаклар,
Кесә тулы борчаклар.

*Буаз Күл авылыннан А. Баев язып җибәрде. 1978*

Яшәгән, ди, Гришка,
Ашаган, ди, симечка.
Яшәгән, ди, Николай,
Ашаган, ди, Миколай.
Алганнар, ди, Антонны,
Нечкә билле хатынны.

*Чуракай авылында Рафикъ Насретдиновтан (12 яшь) язып алынды. 1975*

Барадыр идем, барадыр идем – таптым бер уймак.
Ул уймакны бирдем әбигә, әби миңа калач бирде.
Ул калачны казга бирдем, каз миңа күкәй бирде.
Ул күкәйне утка салдым.
Каз күкәе шарт итте, песи күзе ялт итте.

* * *

Ары да түмгәк, бире дә түмгәк; чиреҗ булса, миңа имгәк.
Атың булса, атланып бар; чиреҗ булса, капланып кал.

*Куян авылында*
*Ш. Максудова язып алды. 1948*

## Тел көрмәкләндергечләр

Карама башында кара малай, кара каргалар карап, катык кырып утыра.

*Меңнәр авылында Илсөяр Вәлиева язып алды. 1983*

Әни, карале Бибисараны,
Ашъяулыкка түккән караны.

*Иске Байсар авылында Тәнзилә Абдуллинадан (9 яшь) язып алынды. 1975*

## Алдавыч әкият

Бер әби белән бер бабай яшәгәннәр, ди. Аларның булган, ди, әтәчләре. Ул әтәч көн саен менгән, ди, киртәгә, калганын сөйләрмен иртәгә.

*Иске Байсар авылында Ләйсән Исмәгыйлевадан (9 яшь) язып алынды. 1975*

## Уеннар

*Яулык бирешле*

Кыз балалар уены бу. Балалар яулык салучы билгеләп куялар, калганнары читтә бер рәткә тезелеп тора. Яулык салучы, беренче балага килеп, аңа яулык белән суга, ә бу бала яулыкны тотып калырга тиеш. Тотса, яулык салучы белән икесе, читкә китеп, кемгә яулык белән сугарга һәм аны кемгә «кияүгә бирергә» икәнен килешәләр. Шуннан соң, билгеләнгән кеше янына килеп: «Сиңа фәләннән хат!» – диләр һәм яулык белән сугалар. Ул, яулыкны тота алса, урынында кала. Әгәр тота алмаса, аны «кияүгә бирәләр». Аның тәртибе болай: теге парлар тагын читкә китәләр һәм бер кулның бармакларына таныш малайларның исемнәрен атап чыгалар. Аннан теге кыз янына килеп: «Кайсы бармак кирәк?» – дип, бармакларын җәеп күрсәтәләр. Кыз кайсы бармакны күрсәтсә, шуңа аталган исемне кычкырып әйтәләр. Мәсәлән, Зәки булды, ди. Ул кыз Зәкигә кияүгә чыккан була. Уен барлык кызлар «кияүгә чыгып» беткәнче дәвам итә.

*Табанлыкүл авылында язып алынды. 1975*

## Санамышлар

Әке, бәке,
Ышкыланган сәке.
Ары давай, бире давай,
Печәнлектә акча санай.
– Ничә булды?
– Йөз булды, йөз илле дә бер булды. Ситдикъ, митдикъ, маннур, куян.

*Табанлыкүл авылында С. Мирзиевадан (12 яшь)
язып алынды. 1975*

Ипи, шикәр, тоз;
Матур егет, матур кыз.

*Иске Байсар авылында Илдус Шакировтан (7 яшь)
язып алынды. 1975*

Акы, тукы, тумана,
Абель, фабель, умана,
Эки, пики, граматики,
Ингел, угел и один.

*Зөбәер авылыннан Илиза Шәйхенурова (13 яшь)
язып җибәрде. 1978*

## Әйтешләр

– Сезгә кем килде?
– Хатыйп.
– Нәрсә алып килде?
– Катык.
– Миңа да бир әле.
– Чүлмәге ватык.

*Табанлыкүл авылында Гөлфая Авзаловадан (12 яшь) язып алынды. 1975*

– Турымы?
– Туры.
– Күкәй буры.
– Кыекмы?
– Кыек.
– Каткан мыек.

*Меңнәр авылында Илсөяр Вәлиева язып алды. 1983*

## Алдавычлар

– Мәсук белән Мәсуга
Барганнар, ди, басуга.
Мәсуга кайтып киткән,
Кайсы калган басуда?
– Мәсук.

(Шулай диюгә, аңа шаярып сугып алалар).

*Чуракай авылында Әзһәр Вәлиевтән (12 яшь) язып алынды. 1975*

– Минем арттан «мин дә» дип, кабатлап бара аласыңмы?
– Алам.
– Мин урманга бардым.
– Мин дә.
– Җиләк җыйдым.
– Мин дә.
– Чокырга төштем.
– Мин дә.
– Анда бүре бар иде.
– Мин дә.
– Бүре сихерчегә әйләнде.
– Мин дә.

*Яңа Кормаш авылында Зөлфирә Хафизова язып алды. 1983*

## Авторлар турында кыскача белешмә

*Миңнуллин Ким Мөгаллим улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры.

*Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы* – филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә баш фәнни хезмәткәр булып эшләде.

*Баязитова Флера Сәет кызы* – филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Гарипова Фирдәвес Гариф кызы (1941–2014)* – филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлегендә баш фәнни хезмәткәр булып эшләде.

*Гыйбатдинов Марат Мингали улы* – педагогика фәннәре кандидаты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директорының фәнни эшләр буенча урынбасары.

*Җамалетдинов Ленар Шәйхи улы* – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык авыз иҗаты бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Закирова Илсөяр Гамил кызы* – филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык авыз иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Илтубаева Лариса Васильевна* – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлегендә аспирантурада укыды.

*Исхаков Радик Равил улы* – тарих фәннәре докторы, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Керәшен татарлары һәм нагайбәкләрнең тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү үзәге җитәкчесе.

*Йосыпов Фәрит Йосыф улы* – филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге фәнни хезмәткәре.

*Кадыйров Рәшит Мәгъсүм улы* – тарих фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Каюмова Эльмира Ринат кызы* – сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлегендә өлкән фәнни хезмәткәр булып эшләде.

*Ногманов Айдар Илсур улы* – тарих фәннәре кандидаты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Татарстан Республикасы халыкларының тарихи-мәдәни мирасы бүлеге мөдире.

*Рамазанова Дария Бәйрәм кызы (1938–2019)* – филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлегендә баш фәнни хезмәткәр булып эшләде.

*Садыйков Шамил Фәнис улы* – педагогика фәннәре кандидаты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Х. Фәезханов исемендәге Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Салихов Радик Рим улы* – тарих фәннәре докторы, ТР ФАның хакыйкый әгъзасы, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры.

*Солтанова Рауза Рифкать кызы* – сәнгать фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире.

*Туймова Гүзәл Рәфкать кызы* – сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлегендә фәнни хезмәткәр булып эшләде.

*Хисамов Олег Ришат улы* – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фәнни эшләр буенча урынбасары.

*Һадиева Гөлфия Камил кызы* – филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты.

**ЭЧТӘЛЕК**


СҮЗ БАШЫ
3

КЕРЕШ СҮЗ
13

АКТАНЫШ РАЙОНЫ: ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ
*Радик Салихов, Айдар Ногманов,*
*Марат Гыйбатдинов, Радик Исхаков, Шамил Садыйков*
15

Актаныш төбәге – татар шәҗәрәләрендә
*Марсель Әхмәтҗанов*
30

ТАШКА УЕЛГАН СӘХИФӘЛӘР
Актаныш районында эпиграфик һәм археографик эзләнүләр
*Рәшит Кадыйров*
77

АКТАНЫШ РАЙОНЫ АВЫЛЛАРЫ
*Гөлфия Һадиева*
99

АВЫЛ – МИЛЛӘТНЕҢ ТЕРӘГЕ
Авыллар тарихыннан
*Фирдәвес Гарипова*
133

АКТАНЫШ РАЙОНЫ МИКРОТОПОНИМИЯСЕ
*Олег Хисамов*
144

ЙӨЗЛӘРЕ ЯКТЫ, ТЕЛЛӘРЕ ТАТЛЫ
Актаныш төбәгенең сөйләү үзенчәлекләре
*Дария Рамазанова*
190

МИНЗӘЛӘ СӨЙЛӘШЕНЕҢ ФОНЕТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
*Фәрит Йосыпов*
230
АТА-БАБАДАН КАЛГАН
Йолалар һәм көнкүреш үзенчәлекләре: этнолингвистик аспект
*Флера Баязитова*
267
ОСТАЛАР ЯГЫ
Традицион һөнәрчелек һәм халык сәнгате
*Рауза Солтанова*
326
МАРИ БИЗӘКЛӘРЕ
Актаныш ягында яшәүче мариларның декоратив-гамәли сәнгате
*Лариса Илтубаева*
399
БОРЫНГЫ ДА, МОҢЛЫ ДА
Музыкаль фольклор традицияләре
*Эльмира Каюмова*
409
ӘКИЯТ ДИГӘН ДӨНЬЯ БАР
*Илсөяр Закирова*
462
ОНЫТЫЛМАС ДОГА АҺӘҢНӘРЕ
Актаныш районы татар-мөселманнарының дини-музыкаль йолалары
*Гүзәл Туймова*
475
ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ
Актаныш төбәгендә сакланган фольклор үрнәкләре
*Ленар Җамалетдинов*
482

Научно-популярное издание
*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

Первая книга

**НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ: АКТАНЫШ**

На татарском языке

2-е издание

Фәнни-популяр басма
*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*

Беренче китап

**МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ: АКТАНЫШ**

2 нче басма

Корректоры А. А. Дәүләтова
Компьютерда биткә салучысы Н. Т. Абдуллина
Китапта Р. Р. Солтанова, Л. В. Илтубаева һәм Р. М. Кадыйров
фоторәсемнәре файдаланылды

Басарга кул куелды 02.08.2021
Форматы 60×84 $^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 26,5. Шартлы басма табагы 33,25.
Тиражы 1000 д. Заказ

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде
420111, Казан, К. Маркс ур., 12